ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

4. 1992



# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ БҮЛӘГЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ



Ибраһим Нуруллин



Рәшит Әхмәтҗан

Быел Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм «Туган як» мәдәни җәмгыятенең карары белән

Гаяз Исхакый исемендәге премияләр

«Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә чыккан «Фатих Әмирхан» (1988), «Прометей из Ново-татарской слободы» (1991) китаплары һәм Гаяз Исхакыйның иҗат мирасын халыкка кайтарудагы зур хезмәтләре өчен язучы, галим **ИБРАҺИМ ЗИННӘТ улы НУРУЛЛИНГА,**

«Йөрәк бәйрәме» (1988), «Моңлану» (1991) дигән шигырьләр, поэма китаплары һәм сәяси-иҗтимагый эшчәнлеге өчен шагыйрь **РӘШИТ ХӘНИФ улы ӘХМӘТҖАНГА** бирелде.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

4

(834)

1992

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

И. ЮЗЕЕВ. Килеп сөяндең каенга. *Шигырьләр* ........ 3
Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Сират күпере. *Роман* ........ 7
Р. ГАТАШ. Кышкы урманда йортлар бар. *Шигырьләр* ........ 59
Л. ЛЕРОН. Болгавыр заман шагыйрена. *Шигырьләр* ........ 65
М. ГОСМАНОВ. Чәчелгән орлыклар ........ 68
А. ВЕРГАЗОВ. Кайту. *Романнан өзек* ........ 114

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Ф. ИСМӘГЫЙЛЕВА. Сиңа. *Шигырьләр* ........ 111

ПУБЛИЦИСТИКА

Ә. ЕНИКИ. Ялганны яклау ........ 149

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

А. ӘХМӘДУЛЛИН. Тарихны яңадан язганда ........ 160
Тукайга тугры булып. Язучы Ф. Баттал белән әңгәмә ........ 166

ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Р. МОСТАФИН, Р. ДАУТОВ. Репрессияләнгән татар язучылары ........ 175

СӘНГАТЬ

Г. ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА. Сынчы Кадим Җәмитов ........ 184

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 190
Таныш булыйк: Фоат Гарифуллин ........ 192

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**

**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**

**Тәлгат Галиуллин**

**Аяз Гыйләҗев**

**Салих Маннапов**

**Зиннур Мансуров**

**Ростәм Мингалимов**

**Фәрвәз Миңнуллин**

**Минтаһир Минһаҗев**

**Мөхәммәт Мәһдиев**

**Ринат Мөхәммәдиев**

**Рашат Низамиев**

*(баш мөхәррир урынбасары)*

**Индус Таһиров**

**Марс Шабаев**

*(җаваплы сәркатип)*

**Тәүфикъ Әйди**

**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары —
53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чачма әсәрләр, шигърият,
очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: начало романа Р. МУХАМАДИЕВА «Мост над адом»; отрывок из романа А. ВЕРГАЗОВА «Возвращение»; новые стихи И. ЮЗЕЕВА, Р. ГАТАУЛЛИНА, Л. ЛЕРОНА. «Творчество молодых»: стихи Ф. ИСМАГИЛОВОЙ.
«Публицистика»: окончание статьи М. УСМАНОВА «Татары в Китае»; статья А. ЕНИКИ «Защищая ложь».
«Литературная критика»: статья А. АХМАДУЛЛИНА «История пишется заново»; беседа критика М. ВАЛЕЕВА с писателем-сатириком Ф. Батталом.
«К истории литературы»: Р. МУСТАФИН, Р. ДАУТОВ: «Репрессированные татарские писатели».
«Искусство»: «Скульптор К. Замитов» — статья Г. ВАЛЕЕВОЙ-СУЛЕЙМАНОВОЙ.
«Дневник общественно-культурной жизни».
«На наших обложках»: скульптура К. Замитова «Друзья»; известный ученый, академик А. Каримуллин.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Кояш Тимбикова, Тәүфикъ Әйди, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.

Производствога бирелде 11.03.92 ел. Басарга кул куелды 02.04.92 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 39477. Заказ В-88. Бәясе 1 сум 80 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1992 ел.

# ШИГЪРИЯТ

## Илдар Юзеев

### Килеп сөялдең каенга...

Якты уйларга зарыгып,
Урманга барасың да
Ап-ак тоясың үзеңне
Каеннар арасында.
Өлкән яшьтәге каенга
Сөйлисең серләреңне,
Каен җилендә юасың
Җандагы керләреңне.
Тормышның авыр юлында
Йөрәгең тузды сыман,
Дөрләп янарга әзер ул
Каенның тузы сыман.
Килеп сөялдең каенга
Юлыңның яртысында,
Китсен күңелең хәл алып
Каеннар яктысында.
Узмады газиз башыңнан
Ни генә,ниләр генә...
Иркәли хәзер чәчеңнән
Ягымлы җилләр генә...

* * *

Юк инде гамьсез шаяру
Һәм көлеш.
Бөкерәйдем... картайганчы...
Яшь килеш.
Ерак-ерак дәверләрдән
Килгәндер:
Җиде бабамның рәвеше
Сеңгәндер.
Ничә гасыр бөгелгән дә
Сыгылган,
Күпмеләре авырлыктан
Егылган.

---

Илдар ЮЗЕЕВ (1933) — *шагыйрь, драматург. Татар, рус, башкорт телләрендә дөнья күргән утызга якын китап авторы. Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт һәм М. Җәлил исемендәге премияләре лауреаты. Казанда яши.*

Бу сыйфатлар улдан улга
Күчкәннәр...
Турайганның горур башын
Кискәннәр.
Бу гәүдәмне, бәлки, кабер
Турайтыр,
Токымымда «Турайдым!» дип
Кем әйтер?
Үлеп кенә качып булмас
Хурлыктан.
Җирдә кайчан котылырбыз
Коллыктан?
Гомеремне нәселдә кем
Озайтыр,
Гаделсезлек, ялганны кем
Турайтыр?
Дөрес, анысы әлегә бу
Баш исән,
Җәлладларым җиң сызганган —
Баш исән...
Гәүдәм бөкере, тик шулай да
Баш туры!
Күзләремдә — өмет белән
Яшь тулы...

## Нигә?

Бер карасаң, дөнья — нинди гүзәл, хозур!
Мәңге Кояш чыгар, балкып таңнар атар...
Ә нигә соң, нигә, ни өчен бу Җир
Тираннарга — иркен, шигъри җаннарга — тар?!
Нигә шул кадәре хәсрәтле соң бу җыр?
Сандугачлы баглар читлек белән тулган...
Ә нигә соң, нигә, ни өчен бу Җир
Җәлладларга — сарай, шагыйрьләргә — зиндан?

## Өлкәнәйгән бер хис

Шулай, дустым, әле кичә генә
Бәләкәйләр идек, нәниләр.
Олыгаеп, бөкерәеп калдык
Ташлап киткәч безне әниләр.
Аңласа да безнең хәлне аңлар
Күз алдына китерүчеләр:
Тудыручы китте. Калды безне...
Әкрен-әкрен үтерүчеләр.
Шулай, дустым, без дә әкрен генә
Бу дөньядан китә барабыз.
Әллә шуңа, әллә шуңа инде
Хәзер бигрәк моңлы бала без.
Өлкәнәйгән бер хис телә җанны:
Юкка гына тумадым микән,
Мин үзем дә әнкәемнең гомерен
Кыскартучы булмадым микән?..

## Кошлар юлы

Былбыл булалмадым дип тормадым,
Кошлар юлын сайладым, —
Таң алдыннан өзелеп бер җырладым —
Күңелем тулып сайрадым.
Мин дә сезнең кебек газапланам,
Кошлар, гаеп итмәссез,
Яз таңында мин дә канатланам,
Бәлки, ташлап китмәссез?..
Күрешербезме, юкмы бу дөньяда?
Ансы — язмыш кулында...
Очрашасы иде мәңгелектә —
Ерак кошлар юлында...

## Уйлыйсыздыр...

Уйлыйсыздыр: адәмнәргә шагыйрьнең үзе кирәк?
Юк! Шагыйрьнең, үзе үлгәч, даны һәм сүзе кирәк...

## Хәсрәтле җыр

Минутлап, сәгатьләп
 җыелган гомеремнең
　　　　белмәдем кадерен, —
　　　　　　　　син хаклы, бәгырем...
Минутлап, сәгатьләп
 сүтелгән гомеремнең
　　　　йомгагы шул булды:
　　　　йөрәгем — көрәшче,
　　　　кул-аяк — кол булды...
Минутлап, сәгатьләп
 таралган гомеремнең
　　　　хәсрәтле азагын
　　　　　　　　коллыктан ычкынган
　　　　　　　　　　　　кул белән язамын...

* * *

Тормышыңны матурлаган
Аккошың булалмадым,
Күңелеңне гел нурлаган
Балкышың булалмадым,
Хыялларыңда зурлаган
Саф кешең булалмадым.

Тел яшергән килен сыман,
Сак кеше булып калдым,

Хаким фикергә буйсынган
Вак кеше булып калдым,
Кара чәчләр арасында
Ак кеше булып калдым,
Шәфкатьсезләр дөньясында
Чак... Кеше булып калдым.

## Без

Без ничек шәфкатьле булыйк,
Хөр җанлы, изге булыйк,
Без ничек көзге булыйк та
Тәвәккәл сүзле булыйк?
Шунысы гаҗәп: бу дәһшәттән
Без ничек калдык әле...
Без бары тик изгеләрнең
Сау-исән калдыклары.
Бабайларны аттылар ич,
Әтиләрне яптылар,
Себерләргә озаттылар,
Нәселне тараттылар.
Без яшеннең үзе түгел,
Елдырымнары гына,
Без давылның үзе түгел,
Ком бураннары гына.
Болай читтән караганда,
Сүнгәндәй күренәбез,
Нәсел яраларын бәйләп,
Бик әкрен терелгәбез.
Бик тирәнгә яшеренгән
Нәфрәт тулы сагышлар...
Кагылмагыз...Безме? Без ул —
Яралы юлбарыслар...

## Мин югалсам...

Уттан-судан мине эзләмәгез,
Юлда булырмын,
Серле күңелемнениләр тарта, —
Шунда булырмын.
Кошлар кебек мин бик ярсулы да,
Тын да булырмын,
Кайда сайрау, кайда челтерәүләр, —
Шунда булырмын.
Кирәк икән, гармун телләре дә,
Кыл да булырмын.
Кайда шатлык, кайда тирән хәсрәт, —
Шунда булырмын.
Мин югалсам, сулга каерылмам,
Уңда булырмын.
Җаным тынганда да аерылмам, —
Юлда булырмын.

*1991*

Ринат Мөхәммәдиев

# СИРАТ КҮПЕРЕ

РОМАН

## Сүз башы

*Солтангалиев...*

*Октябрь инкыйлабы көннәрендә һәм Совет хакимиятенең беренче бишьеллыгында татарлар арасында гына түгел, илдә исеме еш кабатланган иң күренекле шәхесләрнең берсе ул. Ленин, Сталин һәм Троцкий белән бергә эшләп, аларның һәммәсе белән үзен тиң күреп, аяк терәп сөйләшкән, бәхәсләшкән дәүләт җитәкчесе. Милли мәсьәләне аңлауда һәм аңлатуда мөстәкыйль үз концепциясе булган белгеч, җитәкче. Аның бу өлкәдәге хезмәтләре дистәләгән илдә — Япония, Һиндстан, Иран, Төркия, Алжир, Франция, Германия, Англия һәм башка илләрдә дөнья күргән, бүген дә кызыксыну уята.*

*Солтангалиев — Сталинның якын танышы гына түгел, иң тәүге корбаннарының да берсе. Өч тапкыр кулга алына, ике мәртәбә атарга хөкем ителә. Үзәк КГБ архивларында аның эше ил күләмендә иң зур эшләрнең берсе булып тора. 1923 елдан башлап сиксәненче елларга кадәр совет матбугатында аның кадәр гаепләнгән, каһәрләнгән башка берәү бармы икән?! Булса да, Троцкийны гына аның белән чагыштырып була торгандыр...*

*Солтангалиевне һәм аның өйрәтүләрен юкка чыгару — ул милли аң һәм тигезлеккә булган табигый омтылышны юк итүгә тиң була. Әмма тарих күрсәтер: боларның берсен дә юк итү мөмкин түгел. Солтангалиев исеме үз халкына кире әйләнеп кайткан кебек, изелгән милләтләрнең дә тигезлеккә, азатлыкка булган омтылышы үлемсез.*

*Табигый ки, укучыны романда сурәтләнгән вакыйга һәм фактларның тарихи дөреслеккә туры килү-килмәү дәрәҗәсе кызыксындырырга мөмкин. Җавап бирәм: мин әдәби әсәр яздым. Әмма тарихи дөреслеккә хилафлык китермәү төп максатым булды. Романдагы геройлар, тарихи шәхесләр, вакыйгалар уйлап чыгарылмаган. Моңа кадәр үзебездә һәм чит илләрдә мәгълүм булган фактлар белән генә чикләнмичә, үзәк һәм җирле архивлардан, Солтангалиевне күреп белгән байтак кына кешеләрдән алган өр-яңа мәгълүматларны киң файдаландым. Моңарчы ишекләре һәммә эзләнүчеләр өчен дә ябык булган Үзәк КГБ архивына үтеп керү һәм ике-өч мең биттән гыйбарәт сорау алу беркетмәләрен күздән кичерү сезгә тәкъдим ителгән әсәргә дистәләгән, йөзләгән гыйбрәтле мәгълүматлар өстәде.*

*Шул рәвешле, биш ел чамасы вакытым Солтангалиевне өйрәнү һәм яңа роман язуга сарыф ителде. Ниһаять, бу күләмле әсәр әзер дип әйтергә була. Аның исеме — «Сират күпере». Ни өчен шулай диеп*

---

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ (1948) — *әдип, тәнкыйтьче, филология фәннәре кандидаты. «Беренче умырзая», «Кенәри — читлек кошы», «Якутлар табыладыр вакыт белән» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Әсәр журнал вариантында бирелә.

*атадым соң? Шуның очен, чонки Солтангалиевнең шәхси язмышын булсын, татар халкының азатлыкка омтылышын булсын, кылдан нечкә, кылычтан үткен сират күпере аша үтүдән гайре һичнигә тиңләү мөмкин түгел. Бүгенге хәлебез дә шул чама...*

*Роман шактый зур күләмле булу сәбәпле, аны журнал укучыларга кыскартып тәкъдим итәм. «Сират күпере» тулы килеш якын арада Татарстан китап нәшриятында дөнья күрер дип өметләнәм.*

*Автор.*

* * *

Әти, әйт әле, татарларга да патшага каршы баш күтәрергә ярыймы ул?

— Авызың ни әйткәнне колагың ишетсен, малай актыгы... Әйдә, пычкыны ныграк тарт!

Туктап бераз хәл алырга ниятләгән малай пычкы сабын тагы да үҗәтләнебрәк тартырга керешә. Имән тумранын кисү уен-муен түгел шул. Ике куллап тарта югыйсә, әтисеннән шелтә ишетәсе килми иде дә бит. Ә имән ньк, имән таза. Пычкы зеңгелдәп тора, гүя аның телләреннән чүп түгел, очкын сибелә...

Әтисе аның саен дәртләнебрәк тартуын белә пычкы сабын — йөзъеллык имән төбен түгел, ныклыкка үзенең улын сыный ул шулай. Пәһлеван гәүдәле ир-атның маңгаеннан бөрчек-бөрчек тир тамчылары йөгерешә, инде сулышы ешайганнан-ешая бара, ә унбер яшьлек малай ничек түзәргә тиешле?.. Сизә, күрә ич ул, тегенең пычкы сабын тартыр әмәле калмады, өстерәлсә өстерәлә, әмма кулын ычкындырмый. Арыдым, әти, бераз хәл алыйк, дип әйтергә «егетлеге» рөхсәт бирми, үҗәтлеге. Үлсә-үлә, әмма зарлана белми аның бу малае.

Кем иң элек сер бирер, кем сыгылып төшәр, дип көткәндә, авыр сыкрау авазы чыгарып, имән тумраны үзе икегә аерылды. Анда да, җиңдем, котылдым дип, тизрәк кулын ычкындырырга ашыкмады малай, сер бирергә теләмичә, өлкәннәргә хас бер сабырлык белән, пычкыны үзенә тартып алды.

— Татарга баш күтәрергә ярыймы дидем, әти, җавап бир инде?..

Менә сиңа мә! Хәйдәргали абый билен турайтып башын күтәрергә өлгермәде, тагы үз туксаны-туксан малай актыгының.

— Әйттем бит инде, башны катырма дидем.— Ата кеше янә коры гына кистереп куйды.— Телеңә күп салынасы булсаң...

Теленә салынуы түгел, чынлап торып беләсе килә иде Мирсәетнең. Әтисе даими алдырып килгән «Свет» атлы урыс гәҗитенең һәр санында — патшага каршы баш күтәрү, «восстание» вә «митинг» дигән сүзләр. Ул малай-шалай гына түгел бит инде хәзер, теттереп урысча укый-яза белә. Үзеңә кызык тоелган, аңлашылып бетмәгән нәрсәгә җавап алу гаеп эш түгелдер ләбаса?!. Әтисеннән сорамый, кемнән сорасын, ул бит мөгаллим кеше, урысчага да үзе өйрәтте... Инде ул хакта сөйләшү түгел, ишетергә дә теләмидер дисәң, алай да дөрес булмас. Әле берничә генә ай элек, мөгаллимлек итеп, татар-башкорт балаларын урысчага өйрәтеп, авылдан-авылга күченеп йөргән җирләреннән туган яклары Кырмыскалыга кайтырга чыккач, Златоуст өязендәге Яңа Мөслим авылында тукталганнар иде. Өлкәннәр төне буе пышылдашып чыктылар.

Дөрес, Мирсәетне йоклый дип уйладылар ул чакта. Чынлап та, йоклаганга сабышып ятты, борынын сызгырткан булды, борсаланган булды малай. Ә әтисе әллә ничә кат аның йоклау-йокламавын ачыкларга итеп, янына ук килде, юрганын ябып китте.

Улының тәмам йоклаганлыгына ышангач, хуҗа һәм аңарга кич утырырга килгән тагы берничә ир-ат белән чәй янында әңгәмә кылып утырдылар. Питердагы эшче хәрәкәтләре, Уралдагы канәгатьсезлек турында

сөйләштеләр. Күбрәк аның әтисе сөйләде, ә авыл кешеләре сораштырды. Үз әтисенең шулай күп белүенә, кая барып чыкма, шунда якын әңгәмәдәшләр табуына, хөрмәткә лаек булуына куанып ятты Мирсәет.

Соңыннан алар янына тагы бер мыеклы абый килеп өстәлде. Аның мыеклы булуын, йоклаганга сабышып яткан арада күз чите белән генә чамалап өлгергән иде малай. Шул кеше исә әле генә Златоусттан кайтып төшкән, анда эшчеләр восстание күтәргән икән. Үз күзләре белән күргән...

Нәкъ әнә шул чагында, кызыксынуын баса алмаенча, күз төшереп алды да инде аңарга Мирсәет. «Восстание» дигәнен аңламады аңлавын, әмма аның ниндидер гайре табигый, иллә дә хәйран нәрсә булуын чамалады. Чөнки, шул хакта әйткәч тә, авыл мужиклары гына түгел, аның әтисе булып әтисе «ух»ылдап, баш чайкап куйды. Йокларга яткан чагы булмаса, Мирсәет тә түзмәс иде, һичшиксез, сикереп торган булыр иде. Һәм дә ул хикмәтле «восстание» дигәннәренең ни аңлатканын сораштырмый түзә алмас иде.

Шуннан соң теге мыеклы абый тагы да пышылдыйрак төшеп сөйләп китте. Ике колагын торгызып тыңларга тырышса да, анык кына ишетә алмады Мирсәет. Шулай да әңгәмәнең ни хакында барганлыгын чамалады. Златоуст эшчеләре патшага каршы баш күтәргән икән. Ә тегеләрне атлы казаклар чакыртып бик нык кыйнатканнар. Шуңа да карамастан, бу 1903 ел тыныч булырга охшамаган, әле Питер һәм Мәскәү эшчеләре дә үзләрен күрсәтәчәк, дип әйтеп-әйтте теге мыеклы абый.

Нәкъ шул мәлне әтисенең көрсенеп куйганлыгын хәтерли әле ул тагын.

— Урыс эшчесе кузгалды,— диде ул, кинәт тавышын күтәреп.— Кавказ халкы, латыш һәм яһүдләр дә йоклап ятмый. Ә менә безнең татар-башкорт уяныр микән кайчан да булса...

Әңгәмәләре әле дәвам иткәндер, әмма пышылдау авазлары тәмам изрәткән булса кирәк, Мирсәет башка берни хәтерләми, йокыга киткән.

Шулай да Мирсәет әтисеннән төпченүен туктатмады. Икенче көнне янә, урман юлында карт бияга утын төяп кайтып килгән мәлдә, аңарга шул ук соравын бирде ул:

— Әти, татарлар кайчан баш күтәрер инде?..

Хәйдәргали агай бу юлы да ошатмады улының үҗәтлеген. Гел урынсызга, болай да зур авырлык белән атлап барган атка тал чыбыгы белән китереп сукты. Әмма сүзләре Мирсәеткә төбәлгән иде:

— Сугып торып җибәрермен... Очып барып төшәрсең...

Мирсәет бит белә, шулай дип әйтә генә ул, балаларына кул ягылдырмый аның әтисе. Кая барса да, үзе белән ияртеп йөртә торган Мирсәеткә исә тими дә тими инде. Ул бит аның ике апасыннан соң гына көттереп туган өлкән улы.

Дәшмәде Мирсәет, артык төпченмәде. Алай гына булса бер хәл, исе китмәгәнне күрсәтмәкче булып, шундук «Әпипә» көенә сызгырынырга кереште.

— Сызгырма, җил чыгарасың,— дип, бу юлы да кистереп куйды Хәйдәргали агай. Усал булмаса да, кырыслыкта аңа тиңләшүче булмас. Шуңа әниләре Гайнелхаят булсын, биш кыз, дүрт улының берсе булсын, һичкайчан каршы әйтмәделәр аңарга.

Әле авызга бармак тыкмый гына сызгырырга яңа өйрәнеп килгән чагы иде Мирсәетнең. Үзенең яңа һөнәренә куанып туймаган көннәре. Нишлисең, әти кеше әйткәч, карышып булмый. Әмма утын тумраны да түгел бит инде ул — сөйләшергә ярамасын, сызгырынырга ярамасын, ни эшләргә кирәк соң!?. Ә табигать матур... Шундый матур бит ул Кырмыскалы яклары! Ясмык басуына ике торна төшкән, сикергәли-сикергәли, алар булып алар «торыйк-торыйк» дип җырлап йөри. Баш очында, югарыда, сабан тургайлары зәңгәр бишектә тибрәнә, алары да Мирсәеткә атап сайрый, Мирсәеткә җыр багышлый. Офыкта зәңгәр

рәшә дулкынлана, юл читендә кыр чәчәкләре, аллы-гөлле күбәләкләр... Колак төбендә безелдәшкән кигәвен һәм энәкаракларына кадәр шушы мизгелне, шушы көнне зурлый. «Э-эх»,— дип бер киерелде дә, колачларын киң җәеп, имән ботаклары өстенә сузылып ятты Мирсәет. Шушы матурлыкка тиң җыр язсаң иде ул, шигырь чыгарсаң иде. Әйтергә теләгән сүз, дөньяга аваз бирергә торган моң белән күкрәге тулган. Хисләре күкрәгенә сыймый аның хәзер.

Шунда, уйларына чумып барган әтисе, үзе башлап дәште аңар:

— Патшаны төшерү дигән ул уй каян керде әле синең телеңә?..

Дертләп китте малай, капыл гына торып утырды. Төпченергә җыена идеме аның әтисе, әллә улы белән эчкерсез әңгәмә кылыргамы — аңламассың. Ни генә булмасын, Златоустта чакта йоклаганга сабышып сезнең белән сөйләшкәнне тыңлап яттым, дип булмый бит инде.

— Теге, урысча гәҗиттән укыдым,— дип котылмак булды Мирсәет, сүз эзләп кеше кесәсенә керә торган малай түгел иде ул.— «Свет» дип аталамы әле, теге, синең бездән яшереп кенә укый торган гәҗитең?..

Хәйдәргали агай бераз үзалдына уйланып барды, өенә алдырган ике бөртек гәҗитне дә улыннан яшерә алмавына битәрләде бугай ул үзен.

— Шул гына җитмәгән,— дип мыгырданды аннан җилкә аша,— карагруһ-монархистлар гәҗитен генә укыйсың калган. «Тәрҗеман»ны укы әнә, бераз әдәпкә өйрәнерсең.

— «Тәрҗеман»ны да укыйм, әти.., Гаспринскийны күргәнең юкмы синең?

— Сүз Гаспаралы Исмәгыйль турында түгел бит әле,— дип фырылдап куйды атасы.— «Свет»ка кагыласы булма, кара аны, малай актыгы.

Мирсәетнең исә кәефе күтәренке. Әнә ич, әтисе сөйләшә башлады аның белән. Шул гына кирәк тә...

— Ярар, әти, укырга ярамаса, укымам ул гәҗитне.

Дәшмәде Хәйдәргали агай. Бу аның килешүе, укысаң укырсың инде, дию иде. Хәер, Мирсәет өчен җавапның нинди булуы әллә ни әһәмияткә дә ия булмагандыр, чөнки күзгә чалынган, кул астына кергән һәммә гәҗит-китапларны да ул тоташтан укып бара. Урысчамы ул, татарчамы, төрекчәме — бу телләрнең һәммәсен унбер яшьлек малай су урынына эчә. Кызганыч, гарәпчәне генә өйрәнә алмыйча азаплана әлегә. Үч иткәндәй, өйдәге китапларның яртысы диярлек гарәп телендә.

Авылга җитеп килгәндә, янә сорап куйды әти кеше. Йомшак итеп, ягымлы итеп дәште бу юлы, әйтмәс җиреңнән әйтерсең.

— Йә, улым, тагыниләр укыдың инде соңгы араларда?..

— Урыс китапларыннан Мамин-Сибиряк, Короленко, тагы Сулимский дигән язучыларны. Ни эләкте шуны укыйм инде, әти... Барысы да кызык, хикмәтле итеп яза...

— Тагы, тагы ниләр укыдың? — дип ашыктырды ата, нидер ачыклыйсы, тәгаенлисе килгән сыман.

— Тагымы,— дип уйга калып торды малай. Һәм куанып куйды, аеруча яратып укыган китабын исенә төшерде.— Бәй, онытып торам икән, тагы ниндидер, Гринвуд атлы инглиз язучысының «Маленький оборвыш» дигән романын укыдым.

— «Маленький оборвыш» дисеңме? — дип, уйга калып торды Хәйдәргали агай. Аның өчен яңа исем иде бугай бу.— Ә татарча ничек була инде аның исеме?

— Белмим,— дип иңсәләрен җыерып куйды малай.

— Белмәсәң, тәрҗемә итеп кара. Әзерне кем дә укый аны. Ә син укы да уйлан, бу татарча ничек атала икән диген, төрекчәсен табарга тырыш, гарәпчәсен. Шулай гадәтләнсәң, берьюлы ике-өч куян атарсың. Татарча укысаң, урысчасын уйла...

Кош тоткандай, Мирсәет кинәт елмаеп җибәрде.

— Таптым, татарчасын да таптым... Аның татарчасы «Бәләкәй йолкыш» дип аталачак.— Һәм бераздан, басыла төшеп, сорап куй-

ды ул:— Әти, син ничек уйлыйсың, әгәр дә мәгәр мин шул романны татарчага тәрҗемә итеп чыксам, ә?.. Кырмыскалыда бөтен малайлар белер иде аның турында. Болай да мин ул хакта әллә ничә мәртәбә сөйләдем инде. Безнең дә укыйсы килә бит диләр, ә урысчаны белмиләр.

— Тәрҗемә кылу — изге эш. Булдыра алсаң, тырышып кара,— диде әтисе. Унбер яшьлек малайның кулыннан андый эш килмәс, әлбәттә, Хәйдәргали агай моны яхшы белә. Әмма улының шундый теләге бар икән, ничек хупламыйсың моны.

Ул да түгел, әти кешене тәмам хәйран калдырган тагы бер хикмәтле күренеш булып алды әле.

Нәкъ шул мизгелдә, уйламаган-нитмәгән җирдән, Мирсәет капылт кына арба өстеннән сикерде. Һәм, җигүле атны узып, дөньясын онытып йөгерә үк башлады.

— Нәрсә булды... Кая йөгерәсең алай? — дип кычкырды, моны ничек аңларга белмәгән Хәйдәргали агай.

— «Бәләкәй йолкыш»ны тәрҗемә итәргә.

— Өлгерерсең... Өйгә кайтабыз ич.

— Бия акрын кайта...— дип кулын селтәде малай.— Тәрҗемә итә торам мин.

— Җенле,— дип әйтүдән башка чарасы юк иде атаның да. Ул моны үзалдына әчке бер куаныч һәм хәтта горурлык белән дә әйтте бугай.— Тәмам җенле малай икән бу, хәерлегә булсын...

Арба юлы читендәге чирәмнән йөгерүче малайның күзенә ул-бу күренмәде. Авыл капкасына килеп кергәч тә йөгерүен дәвам итте ул. Тын гына чирәм чемченеп йөргән тавыклар, каз-үрдәк «игагай»лап якякка сибелде. Үзләренең капка төбенә килеп җиткәндә, бөгелә-сыгыла чиләк-көянтә белән судан кайтып килүче дәү апасы Сәрвәрне чак бәреп екмады Мирсәет.

* * *

Көннәр бер-бер артлы уза торды. Көзләр үтеп, кышка керделәр. Мирсәетнең әле булса «Бәләкәй йолкыш»ны тәмамлый алганы юк. Әмма төрле маҗараларга юлыгып, урамда йөрүче бу инглиз малае турында инде Кырмыскалыда ишетеп кенә түгел, укып та беләләр. Романның Мирсәет тәрҗемә иткән аерым бүлекләре кулдан-кулга йөреп таушалып бетте, кайсыберләре югала да башлады көбек инде.

Шуңа да карамастан, Мирсәетнең бу эшне ташларга җыенганы юк, буш вакыты булдымы өстәл янына утыра. Тәрҗемә итә һәм тәрҗемә иткәнен иң элек әнисенә, апалары, әне-сеңелләренә укый. Аннан соң гына кульязма яшьтәшләре, малайлар кулына керә. Һәм өй борынча китә...

Әмма тәрҗемә эшеннән дә аерылып торган кичләре бар иде Мирсәетнең.

Көннәрдән бер көнне уйламаган җирдән аның янына әтисе килеп керә. 1904 ел булдымы икән бу, 1905 кә чыккачмы, төгәен генә әйтеп булмый инде хәзер.

Мирсәет өстәлдәге кәгазь кисәкләрен, әтисеннән яшереп, тиз өстенә шудыра. Гаепле кеше сыман, үз-үзен кая куярга белмичә бөрсаланырга керешә.

Табигый инде, улының, шул рәвешле, яшертен эш белән шөгыльләнүе ата кешедә кызыксыну уята. Яшереп азапланган кәгазь кисәкләреннән берсе, ялгыш, идәнгә төшкән икән. Хәйдәргали агай, иплә генә килеп, шуны кулына ала һәм күз сала. Үз күзләренә ышанырга-ышанмаска белми: аның улы Мирсәет патша хәзрәтләрен бәреп

төшерергә чакырып язылган татарча листовкалар күчереп утыра икән ләбаса!..

Муенында кан тамырлары бүртеп чыга атаның, колаклары кызыша. Әмма тавышын күтәрми, күрше бүлмәдәгеләргә сиздерүдән курка. Мондый эшне ишеттермәгән, белгертмәгән хәерле ич аның өчен дә...

— Бу нәрсә бу! Төннәр буе нәрсә күчереп утырасың син?!. Кая, башкаларын да күрсәт әле...

Капыл гына күтәреп, алдындагы кәгазьләрне малай күлмәк астына тутыра. Үзе куркуга төшкән, әмма күзләре утлы күмер булып яна.

— Бирмим... Сорама, әтием, берсен дә бирмим.

Үҗәтлектә үзеннән дә арырак киткән бу малаеның күрсәтәсе килмәгән әйберен алай җиңел генә алып булмасын белә, аңлый Хәйдәргали агай. Яхшылап сөйләшеп, сораштырып карарга була.

— Кем кушты?

Дәшми.

— Кем өчен күчерәсең аларны?

Малай яман тешләк, һаман дәшми.

— Моның өчен нәрсә булачагын беләсеңме соң син, малай актыгы?! — дип сорый әти кеше, ниһаять.

— Беләм,— дип җавап кайтара Мирсәет.— Патшага каршы баш күтәргән өчен сөргенгә олактыралар яисә асып куялар.

Тетрәнеп куя Хәйдәргали агай.

— Шуны белә торып күчерәсеңме?

— Әйе,— ди малай. Һәм җәлт кенә борынын тарта. Зәңгәр күзләр ялт-йолт як-якка карангалап ала.

Гәүдәсен турайта төшеп, кабатлап сорый әти кеше.

— Кем бирде бу кәгазьләрне? Кем өчен күчерәсең, әйтәсеңме-юкмы, малай актыгы!?.

— Юк, әйтмим, сорама да, әйтмим дә.

Шунда, бер карарга килеп, бөтен бала-чага җыелып чәйләп утырган табын янына төбәп атлап китә Хәйдәргали агай һәм өлкән кызларына дәшә:

— Сәрвәр... Суфия кызым, кайсыгыз бар анда?.. Кирәгез әле.

Сәрвәр белән Суфия ул арада каршысына йөгереп керәләр.

— Нәрсә, әти... Ни йомышың бар, әтием?

— Барыгыз әле, берегез җәт кенә Нуриәхмәт хәзрәтне чакырып килегез... Син бар, Суфия кызым, синең аякларың җитезрәк.

— Әти,— дип, җан авазы белән тавыш бирә шунда почмакта моңарчы шым утыруын дәвам иткән Мирсәет. Әтисенең нәрсә ният итүен яхшы аңлый чөнки, Нуриәхмәт хәзрәт дигәчтен дә, эсселе-суыклы булып китте, яхшыга түгел бу.— Әти, чакыра күрмә хәзрәтне... Ул белми... Белми ул бу хакта.

Мирсәетнең ай-ваена караудан узган иде инде Хәйдәргали агай. Нәрсә булды, ипле генә яшәп яткан җирдән нәрсә килеп чыкты соң дип, шомланып йөгереп килеп кергән әниләре Гайнелхаят апа да аңламады һәм улына ярдәм итә алмады.

— Суфия, дим,— дип кабатлады ата, атлар-атламаска белми онытылып калган кызына.— Бар дидем. Бер аягың монда, икенчесе анда булсын. Әти кәтә диген. Арасы булса, хәзер үк килсен. Ишеттеңме?!.

Суфия җилкәсенә бишмәтен элеп чыгып йөгергәч тә, әнисе он алып кереп коймак тугларга керешә. Энеләре-сеңелләре, әтиләреннән яшереп кенә Мирсәетне кызганырга, сораштырырга керештеләр.

— Нәрсә булды, абый... Нәрсә булды,— диештеләр. Кичләр буе үзе чыгарган әкият сөйләгәне өчендер, яраталар иде аны.

Нуриәхмәт мулла, көттерә төшеп, ут алгач кына килер ара тапты. Таягына таянып, ап-ак сакалын сыпыра-сыпыра аның түбәночтан менеп килүен иң әлек Мирсәет күреп алды. Кәгазьләрен абзарга чыгарып яшергән иде яшерүен, шулай да җаны тыныч түгел. Әтисе нәрсә ният

иткән, ничегрәк сөйләшергә җыена — ул кадәресе билгеле түгел иде бит әле аңарга.

Мулла кешегә хөрмәт зур иде алар өендә. Хәйдәргали Нуриәхмәт хәзрәтне болдырга ук чыгып, ике кулын сузып каршы алды. Өс-башларын салгачтын, сәкегә утырып дога кылдылар, хәл-әхвәл белештеләр. Аннан йорт хуҗасы өйдәгеләрнең һәммәсенә дә ишетелерлек итеп, үзенең хәзрәт белән җитди нәрсә турында киңәшәсе барлыгын игълан кылды. Без түр бүлмәгә узабыз, ишек ябык торсын, кереп-чыгып йөрмәгез, дигән сүз иде бу.

— Ярар, ярар, балалар бу якта булыр,— дип, тәртип өчен җаваплылыкны әниләре алды үз өстенә.— Хәзер, самавырны гына кертеп куям да...

Түр якның такта белән бүленеп алынган иң аулак почмагына узды ир-атлар. Өйдә бала-чага күп, шулай иткәндә генә тыныч булыр.

Кайнар коймак белән юкә балы кабып чәй эчтеләр иң элек. Әле сүз башларга ашыкмады Хәйдәргали. Хәзрәт булып ул да бер түземсезлек белән көтте аның ни дияren. Чөнки белә, юк сүзне бар итеп утыра торган адәм түгел хуҗа кеше, бигүк диндар булмаса да, белеп сөйләшә торган, укымышлы зат.

— Йә, Хәйдәргали-кем,— дип, Нуриәхмәт хәзрәт үзенең тыңларга әзер икәнлеген белдереп хәбәр салды, ниһаять.

— Хәзрәт, мин сезне бик олы борчуым, дөресрәге, икебезгә дә бер дәрәҗә мөнәсәбәте булган олы борчу уңае белән чакырдым бит әле,— дип, иплән, әмма ныклап сөйләшергә башлады Хәйдәргали.

— Әйе, әйе,— диде җитмеш яшьлек хәзрәт.— Без бит туганнан-туган кешеләр, өченче канат булсак та, якын кардәшләр. Беребезнең бакчасына төшкән борчу, икенчебезне читләтеп узмас. Без — туганнар, бәрәкалла.

— Ярар, хәзрәт, туганлык хакында сөйләшү кайгысы түгел әле мондә,— дип, иплән гәпләшергә әзерләнгән картның башына суккандай итте Хәйдәргали.— Шәҗәрәбездәге үрмәкүч челтәрен башка вакытта барларбыз, боерган булса.

Нуриәхмәт хәзрәткә бу ошамады, нәсел-нәсәб җебен яхшы белгәнгә искәртергә кирәк тапты.

— Алай димә, Хәйдәргали энем, без синең белән якын туганнар. Синең атаң Хаҗимөхәммәт белән минем әтием Хаҗиәхмәт бер ата балалары, бабабыз Зөбәернең нәсел тамырын дәвам иткән ике бөртек олан. Ә Зөбәер исә Солтангали улы. Кул селтәргә ярамый алай, син бит укымышлы кеше...

— Әйе, әйе,— дип утырды Хәйдәргали. Үз хатасын аңлап, башка карышмады.

— Бер-берең сыенып яшәгәндә, иншалла, һәммәсе дә имин булыр, Хәйдәргали.

Әмма Хәйдәргали әйләнеп-урап сөйләшергә күнекмәгән, үзенекен итте:

— Алай гына булса икән, хәзрәт. Бу сүз синең улың Мәхмүт белән минем Мирсәеткә кагылышлы. Үзең беләсең, Мәхмүт җиткән егет, Уралны аркылыдан-буйга йөргән, күп кешеләр белән белешкән, күп шәһәрләр күргән кеше.

— Алланың биргәненә шөкер, шулай-шулай,— дип, бер канәгатьлек белән тыңлый иде хәзрәт үзенең төпчек улы турында сөйләгәннәрне.— Тукта әле, Хәйдәргали энем, синең Мирсәетеңнең ни катнашы бар минем Мәхмүткә. Бутамыйсыңмы, башка бер-бер Мәхмүт турында сөйләмисеңме?..

Тынлык урнашып алды беразга. Әнисе чәй хәстәрләп йөргән арада, ачык ишектән түр якның мич артына кереп, чаршау артыннан өлкәннәрнең сөйләшүен шыпырт кына качып тыңлап торган Мирсәетнең йөрәге кысып-кысып куйды шул чагында. Кеше сүзен тыңлау яхшы

түгел-түгелен дә, нишлисең, сөйләшүнең үзенә кагылышлы икәнлеген ул бит белә. Үзен ни көткәнен алдан белеп торганың хәерле. Әтисе бит, әнә ничек, җеп очы кая китеп тоташканлыкны чамалап өлгергән.

— Бутамыйм, хәзрәт, синең улың Мәхмүт Солтангалиев Урал шәһәрләрендә йөри торгач әллә ниткән социал-демократлар белән бәйләнешкә кергән. Нииндидер Хөсәен Ямашевлар белән хат алыша икән... Шуларны да белмисеңме әллә?!.

— Ни дип әйтим, Хәйдәргали энем,— дип, ерактан, әйләнечтән алып китте хәзрәт. Колагы ишеткәннәргә гаҗәпсенү сиздермәде.— Мәхмүт минем улым булса да, ул балигъ булган кеше. Ни эшләргә, кемнәр белән аралашырга, кемнәр белән хат алышырга кирәклекне үзе белә торгандыр дим...

— Менә шул, хәзрәт, синең Мәхмүт мәктәпкә йөрүче малайларга, шул җөмләдән, минем өлкән улым Мирсәеткә дә, патшага каршы язылган нотыкларын күчереп яздырта.

— Белмим шул, белмим,— дип кенә котылмакчы иде Нуриәхмәт хәзрәт.

Әмма Хәйдәргали агай алай гына тукталырга уйламый иде шул әлегә.

— Ә урядниккә яисә өяздәге башка бер-бер түрәгә бу хакта җиткерсәләр ни буласын беләсеңме соң син, Нуриәхмәт абзый? — Картның ни дигәнен көтеп тормады, үзе үк хөкем чыгарырга ашыкты ул.— Беләсеңме ни булыр?!. Иң элек указыңны алырлар... Аннан мәктәбеңне ябтырырлар. Һәм дә тагы үзеңне, улың Мәхмүт белән бергәләп, асып куярга да күп сорамаслар.

Мулла калтыранып куйды, үзен кая куярга белмичә йөткеренгәләргә, борсаланырга керешге.

— Ә нәрсә?!. Ә нәрсә...— дип кенә дәшә алды ул. Җүнле-башлы сүз килмәде теленә.

Мирсәет тә чак егылып китмәде. Шунда гына аңлады ул нинди куркыныч һәм җаваплы эшкә катнашы булуын. Тотылган очракта, димәк, аны да усал малайлар мәчене асып куйган кебек, асулары бик ихтимал...

— Үзе язган, үзе сөйләгәне генә бер хәл. Патшага каршы язылган нотыгын мәктәп балаларына биргән бит әле. Шуларны күбәйттергән... Ай-һай, хәзрәт, баш китәрлек эшләр эшләнә икән синең мәктәбеңдә... Кешегә әйтсәң, кеше ышанмас!..

Тәмам зиһенен югалтты кебек Нуриәхмәт хәзрәт. Шулай иткәч җиңел була торгандыр инде: берөзлексез сакалын сыпырды.

— Алла сакласын... Алла сакласын диген, Хәйдәргали энем.

— Алла сакланганны саклармын дигән. Бу эшне туктатырга кирәк, хәзрәт... Аннан килеп, шәригатькә сыймаган бер нәрсә бит бу. Патша кадәр патшага тел тидерү... Патшага каршы баш күтәрергә чакыру...

Хәзрәт, гүя телен йоткан, берничә кат тамак төбен кырып алды алуын, әмма ни дияргә дә белмәде.

Хәзрәт ни дияр? Патшага буйсынмау, аңа каршы баш күтәрүгә шәригать ничек карый икән?.. Ничә айлар, күпме вакытлардан бирле Мирсәетнең күңеленнән чыкмый, аны көн-төн бимазалаган сорау иң бу. Әтисеннән ничә тапкырлар сорап караса да, җавап ала алмады ул бу сорауга. Хәзрәт авызыннан хәзер чыгачак сүз соң дәрәҗәдә әһәмиятле һәм мөһим бит аның өчен. Шуңа күрә, аның җавабын ишетми калудан куркып, чаршау эченнән арырак узды малай һәм бүлмә тактасындагы ярык аша хәзрәтнең авызына текәлде. Патшада аның эше юк, шәригатькә, аллага каршы эш була күрмәсен: «И, аллам, шәригатькә тел тидерүдән сакла...»

Нуриәхмәт хәзрәт озак кына дәшми утырды. Күрәсең, ул бирәсе җавабын бик җентекләп уйлады. Дәшми калу ярамый, мәсьәлә кабыргасы белән куелган. Янә йөткеренеп алгач, тамагын кырып куйды, ниһаять.

— Шәригатьме? — дип башлады ул. Һәм ипле генә сеңдереп дәвам итте:— Юк, Хәйдәргали, шәригать бу эшне тыймый. Коръән Кәримнең бер хәдисендә халыкның үзен рәнҗеткән хакимнәргә буйсынмыйча баш күтәрү хокукы да бар диелгән. Хәтта аны бәреп төшерү дә хәрам эш саналмас. Әйе!..

Канәгать кенә сакалын сыпырып куйды хәзрәт. Мирсәетнең дә җанына җылы иңде. Димәк, ул да ярамас, хәрам эш белән шөгыльләнми икән, шөкер!

Әмма Хәйдәргали агайның бирешергә түгел иде исәбе.

— Хуш, Нуриәхмәт абзый, бәхәсләшмим, Коръәнне вә шәригать эшләрен син миңа караганда яхшырак беләсең, әлбәттә. Анысы шулай. Тик менә шунысы бар бит әле тагы, изге китапта «хакимнәр» диелгән, патша турында әйтелмәгән. Моңа ни диярсең?..

Мирсәетнең күңеленә янә шом йөгерде. Нигә шулай төпченә, нигә үҗәтләнә инде аның әтисе, хәзрәтнең әйткәннәре белән генә килешсә, ни була торгандыр...

Картның әллә ни исе китмәде бугай бу юлы. Әллә сер бирергә теләмәве иде, өздереп әйтте дә куйды:

— Хакиме ни дә, патшасы ни, шул бер үк нәрсә, ике чабата — бер кием инде ул, Хәйдәргали. Патша да хакимлек итә. Үз халкын рәнҗетә икән, аны төшерү мөмкин диелгән. Китап каршы килми моңарга.

— Ул бит явыз булса, халыкны рәнҗетсә диелгән, Нуриәхмәт абзый. Әле аның явыз булу-булмавын, рәнҗеткәнме-түгелме икәнлеген ачыкларга кирәктер бит әвәл?..

— Ул кадәресен инде, китап түгел, халык үзе ачыкларга тиеш,— диде хәзрәт ике уйлап тормый гына. Үзенең шундый сорауларга җавап табып, Хәйдәргалине тынычландыруына куанып та алды бугай әле ул хәтта. Ә бераздан, уйлана төшеп, дәвам итте:— Аннан, шунысы да бар бит әле, Хәйдәргали, патша — мөселман түгел, артык хафаланма. Гөнаһысы зур булмас!.. Нәрсә, урыс патшасы безне бөтенләй дә рәнҗетми дип әйтергә җыенмый торгансыңдыр бит!.

Мирсәетнең әтисе шунда бөтенләй үзгәреп, ачылып китте.

— Анысы шулай, Нуриәхмәт абзый, безнең татарга көн күрсәтмиләр инде. Хак анысы... Елга янында яшәргә ярамасын, олы юлга якында көн күрергә ярамасын, үз ана телеңдә гәҗит чыгарырга ярамасын — нинди тормыш була инде ул...

— Хак сөйлисең, Хәйдәргали. Хак сүз сөйлисең. Хак сүз,— дип җөпләп утырырга гына калды хәзрәткә.— Безләр өчен гомер кичерү — үзе сират күпере кичүгә тиң бит ул.

Тормышның авырлыгыннан байтак зарланды Хәйдәргали. Үз әтисенең шул рәвешле чишелеп киткәнен бу көнгәчә күргәне юк иде әле Мирсәетнең дә. Тик шулай да, бераздан, иң элгәре хафалануына әйләнеп кайтты. Кисәтергә кирәк тапты.

— Шулай да, Нуриәхмәт абзый, сакланганны — саклармын дигән бит алла да! Бу эшне туктатырга кирәк булыр. Бала-чаганы андый вәсвәсәдән ераграк тотканың хәерле. Каш ясыйм дип, күз чыгармаск...

— Саграк булганың хәерле, дөрес анысы,— дип эләктереп алды хәзрәт тә.— Мәхмүтне мин кисәтермен. Әмма, китап бу хакта балаларга сөйләүне тыймый, артык хафаланма, Хәйдәргали энем.

Әңгәмәнең тәмамланып килүен чамалаган Мирсәет, чаршау артында качып торган җиреннән сак кына чыгып бара иде инде. Шулчак әтисенең калын тавышы туктатты аны.

— Качма, улым, кил әле монда, кер,— диде ул. Күрәсең, улының такта артында торуын сизенгән булып чыга.

Яшен суккандай булды малайга, әмма буйсынмый чарасы юк. Бераз икеләнеп торгач, әтисенең каршысына ук кереп басарга мәҗбүр булды. Җәзаның иң катысына әзер иде ул.

Аңарга түгел, хәзрәткә мөрәҗәгать итте этисе:

— Йә, хәзрәт, син өлкән кеше, шул рәвешле качып-посып олылар сүзен тыңлап йөрүчегә нинди җәза бирәбез?..

Хәзрәтнең җавабы бу очрак өчен дә әзер икән.

— Өлкәннәр сөйләшкәндә качып тыңлап торуны китап хупламый анысы,— диде ул.— Әмма дә ләкин, әүвәл башта тыңлаучының максатын ачыклау лазем диелгән. Яхшы максаттан тыңлыймы ул, бер-бер яман ният беләнме?.. Бу очракта Мирсәетнең тыңлап торуында яманлык күрмим мин үзем... Китапта тагы «Белмәү — гаеп түгел, белергә теләмәү — гаеп», дигән сүзләр дә бар. Шунысын да дикъкатькә алганда, мин уйлыйм, Хәйдәргали туганым, оланның гаебе зур түгел... «Ите — синеке, сөяге — минеке» дигәндәй, син эти кеше, үзең белә торгансыңдыр инде. Малай — синеке...

Хәзрәт сүзләреннәнме, этисе мөлаем елмаеп ук куйды. Мирсәетнең күңеленә җылы иңде, димәк, җәза куркыныч булмаячак.

— Бүтән алай өлкәннәр сүзен тыңлап йөри торган булма,— диде ул, кинәт кырысланган атлы булып. Һәм улының колагын борып куйды. Авырттырып бормады...

— Ярар,— диде Мирсәет, үзенең гаебен танып.

— Патшага каршы баш күтәрергә ярыймы, дип, тинтерәтмәссеңме инде бүтән?!.— диде этисе.— Кара аны!.. Бар, әнә, капка төпләрен көрәп кер. Хәзрәт чыгуга кардан чистарып торсын,— дип, яратып кына, уч төбе белән артына сугып куйгандай итте тагы.

Ишегалдын һәм капка төпләрен көрәп кенә калмады Мирсәет, себереп үк куйды. Нуриәхмәт хәзрәтнең гыйлемле һәм хак кеше булуын ишетеп белә иде, бүген ул шуңа үз колаклары белән ишетеп ышанды. Нуриәхмәт хәзрәт белән этисе арасындагы сөйләшү хәйран калдырган, тирән уйга салган иде аны. Хак эш белән шөгыльләнә икән ләбаса ул. Олыгаеп, җитдиләнеп киткәндәй, бер башка үскән сыман хис итте ул үзен.

Әмма эшен тәмамласа да, өйгә ашыкмады. Нуриәхмәт хәзрәтне, шушында, капка төбендә тагы бер мәртәбә очратасы килә иде аның. Бәлки бер-бер җылы сүз әйтер, аркасыннан сөяр: «Тырыш егет икәнсең», дияр. Шуңа тырыша бит Мирсәет. Җай чыкса, хәзрәткә әзерләп куелган сораулары да бар әле аның.

Соң гына, озак көттереп кенә чыктылар өйдән. Хуҗа кеше буларак, этисе озата чыкты Нуриәхмәт хәзрәтне.

— Бәрәкалла, бәрәкалла... Менә ич, безнең егетебез эшкә дә бик әвәс икән,— дип, чыга-чыгышка Мирсәетнең тырышлыгын игътибарга алды ул.

Борынын тартып куйды малай. Башын түбән иеп, кыенсынып торды, карашын кая юнәлтергә белмәде. Ул арада, этисе, олы кунакка рәхмәтләрен әйтеп, хәзрәт исә, үз чиратында, хәер-дога кылып, саубуллашырга да керештеләр.

— Бар, улым, хәзрәтне озатып кайт, булмаса,— дип әйтмәсенме шунда этисе. Килсә дә килә бит ул бәхет, бер килсә.

Дәшми бардылар бер тын. Малай, дулкынланудан, кулларын куяр урын тапмады. Хәзрәт йөткеренгәләп атлады.

— Йә,— диде ул бераздан, үзе ярдәмгә килеп.— Бер-бер соравың юкмы соң, Мирсәет? Барчасы да аңлашылдымы инде?..

— Аңлашылды, хәзрәт, мең рәхмәтләр үзегезгә,— диде малай, югалып калмады.— Тик менә бер сүзегез аңлашылмады, хәзрәт. Шуны аңлатып бирә алмассызмы?

— Йә, әйт, нинди сүз булды икән ул?

— «Сират күпере» дидегез, хәзрәт. Гомер кичү — сират күпере аша чыгуга тиң дидегез...

Ил агасы адымнарын сирәкләндерә төште һәм янәшәсеннән кыюсыз гына атлап барган малайны аркасыннан йомшак кына сөеп куйды.

— Аны сорыйсың икән... Авыр сорау бирәсең бит әле син,— дип бертын уйланып барды ул. Һәм иплe генә сөйләргә, аңлатырга кереште.— «Сират» сүзе Коръәндә кырыктан артык мәртәбә кабатланган сүздер. Җәһәннәм өстеннән сузылган күпер ул. Кыямәт көнендә аның аша бик сирәк адәм, изге затлар гына үтәр. Чөнки сират күпере — кылдан нечкә, кылычтан үткен булыр, аңлыйсыңмы?.. Гөнаһлылар, игелексез бәндәләр һәммәсе тәмуг утына егылып төшәр.

— Анысын аңлыйм, хәзрәт. Ишеткәнем бар,— дип ачыклык кертергә ашыкты малай.— Тик миңа шуны аңлатыгыз, ни өчен безнең татарга авыр ул яшәү, ни өчен без сират күперен кичә алмый калганбыз?..

— Ә-ә, әнә син кая таба борып алдың сүзне?! — дип, сорауның ни дәрәҗә җитдилеген әле генә аңлаган хәзрәт туктале ук калды.— Ул кадәресе инде китапта язылмаган, улым.

Бу малайдан җиңел генә котылам димә икән...

— Язылмаса да җавап табу кирәктер бит, хәзрәт. Нигә минем әти, кулын селти дә, һәрчак: «Без татарларга кая инде ул!» — ди-ди зарлана?.. Нәрсә булган безнең халыкка? Нигә аңарга гәҗит чыгарырга ярамый? Нигә аңарга Агыйдел буенда яшәргә ярамый? Әти, әнә, патшага каршы мәктүп язарга да ярамый, ди. Башкаларга ярый, ә безгә ярамый — нигә ул шулай, хәзрәт?.. Сират күпере аша чыга алмый калучылар өчен яңадан ул күпергә омтылу хәрам эш түгелдер бит?..

— Аңладым мин сине, улым,— дип, яшьле күзләрен яшерергә азапланган малайны үзенә таба кысты Нуриәхмәт хәзрәт.— Аңладым мин сине... Ул хакта китапта язылган: Җәһәннәмнән җәннәткә юл һичкайчан һәм һичкемгә ябык түгел, диелгән китапта...

— Мин дә аңладым,— диде малай, борынын тарта төшеп. Һәм үзенең шул рәвешле йомшап китүеннән уңайсызланды булса кирәк, карашын аяк очыннан алмый гына саубуллашырга ашыкты.— Мин кайтыйм инде, ярыймы, хәзрәт.

Үз урамнарына таба дөньясын онытып йөгереп менеп барган малай артыннан күзләрен ала алмый онытылып карап калды Нуриәхмәт хәзрәт. Үзалдына: «Бәрәкалла! Бәрәкалла! Бәрәкалла!» — дип кабатлады ул.

* * *

Апрель урталарында Мәскәүдән, Милләтләр эше халык комиссариатыннан ашыгыч телеграмма килеп төшә:

*«Казан губернасының Мөселман эшләре комиссары ип. Солтангалиевка. Татар-Башкорт мәсьәләсе буенча ашыгыч киңәшмәгә килүегез сорала.*

**Сталин. Вахитов».**

Ашкынып-канатланып барды ул Мәскәүгә. Кызы Рәсидәне күрмәвенә ни гомер. Раузаның да Мәскәүдә чагы...

Мирсәет, иң элек, Вахитов янына ашыкты. Дусларча очрашып, хәл белештеләр. Гадәттәгедән дә җылырак күреште бу юлы Мулланур.

— Беләм... Ишетәм, Мирсәет,— диде ул.— Сине анда берьялгызың полкка каршы чыккан, дип сөйлиләр.

— Арттыралар...— дип шаяруга шаяру белән җавап кайтарырга тырышты.

Вахитовның ни хакында сөйләгәнен һәм нәрсәләр белән кызыксынганлыгын яхшы белә иде Солтангалиев. Үзактә эшләсә дә, икенче яртысы Казанда калган ич аның, сабыеннан аерылырга мәҗбүр булып, шул сабыен сагынып өзгәләнгән ана хәлендә ул хәзер. Өстәвенә, Идел буенда һәм Казанда вакыйгаларның соң дәрәҗәдә киеренке чагы, революция язмышы хәл ителгән көннәр...

Казан хәлләрен сораштыра-сораштыра, әллә ни арада чәй дә өлгерткән иде Вахитов. Күрәсең, кружкасы бер генә булгандыр, иң элек кунагына тәкъдим итте ул:

— Әйдә, син юлдан килгән кеше, бераз чәйләп ал.

Тартынып-кыстатып тормады Мирсәет, өстәлгә якынрак утырып хуш исле чәйдән авыз итәргә кереште. Ә Мулланур Вахитов аны кыскача үзәктәге хәлләр белән таныштырды. Әмма төп мәсьәләгә, Татар-башкорт республикасы хакындагы сөйләүгә өлгерә алмый калды. Телефон шалтырады. Ишекле-түрле йөренгән җиреннән өстәл янына ашыкты ул.

— Әйе, Вахитов тыңлый... Килде, иптәш Сталин... Монда... Минем янда утыра... Хәзер... Хәзер үк керәбез.

Трубканы куйгач та Мирсәеткә мөрәҗәгать итте Вахитов:

— Иптәш Сталин чакыра.

Яртылаш эчелгән кружканы читкә этәреп, торып басты Мирсәет. Мин әзер дигән сыман, гимнастерка якаларын җайлап куйды.

Сталин белән беренче күрешүе. Алар килеп кергәндә ул кем беләндер телефоннан сөйләшә иде. Әмма кунакларны күргәч тә, сүзен тиз генә тәмамлап, урыныннан торды. Һәм бераз каршы килеп кулын иң элек Мирсәеткә сузды:

— Солтангалиев сез буласызмыни инде?.. Иптәш Вахитов сөйләгәннәрдән чыгып, мин сезне бик дәү гәүдәле бер каһарман итеп күз алдына китерә идем...

Аздан гына: «Мин дә сезне кыяфәтлерәктер дип уйлый идем»,— дип әйтеп ташламады Мирсәет. Сталинны ул чынлап та таза, мәһабәт гәүдәле кавказ кешесе итеп күз алдына китерергә күнеккән иде. Баксаң, ни гәүдә, ни кыяфәт дигәндәй, гади генә бер адәм икән ул да. Муены алга таба беркадәр бөкерәя төшкән сыман. Сул кулы да сәеррәк тоелды, ул аны урыныннан торгач та, френч кесәсенә яшерде. Куе кара чәчен артка тарап куйган. Өске иреннәрен каплап торган керпе сыман кара мыек. Борын очы, икегә аерылган сыман, урта бер җиреннән эчкә батыбрак тора. Салпы ияге бераз шадралана төшкән... Мөгаен, аеруча игътибарны җәлеп иткәне аның карашы булгандыр. Маңгай астыннан төбәлгән күзләрдә җитдилек кенә түгел, усаллык та булуын тоемлау өчен күрәзәче булуың кирәкми. Ярымшаяра төшеп күрешкән вакытта да яктырмады Сталинның карашы, салкын тимерне хәтерләтте. Хәер, төсе белән дә, бар нәрсәдән бигрәк, тимергә охшатты ул аның күзләрен.

Үз чиратында, Сталин да Мирсәетне җентекләп хәтерендә калдырырга тырышты булса кирәк. Аның күзләренә текәлеп торды.

— Исәнмесез, иптәш Сталин,— дип, беркадәр соңгара төшеп җавап кайтарды Солтангалиев.— Иптәш Вахитов беркадәр арттыра төшкән, күрәсең.

Керүчеләргә урын тәкъдим итте Сталин. Һәм үзе дә өстәл артына утырып трубкасына тәмәке төяргә кереште. Ул да түгел, гел уйламаганда, каш астыннан тимер салкынлыгы бәреп торган карашын текәде Мирсәеткә.

— Сез нәрсә, иптәш Солтангалиев, бер Казанда ике дәүләт төзергә булдыгызмы?..

«Бу мәсьәлә хәл ителгән ич инде, Болак арты республикасы бетерелде»,— дип аңлатырга керешмәкче иде Мирсәет. Әмма ул уеннан кайтты, Вахитов та, иптәш Сталин да бу хакта хәбәрдар. Мәгълүм фактларны нигә яңабаштан куертып торырга...

— Ул кризистан югалтусыз чыктык, иптәш Сталин. Казанда власть Советлар кулында... Әмма хәвеф икенче тарафтан килә, Идел буйлап күтәрелә сыман. Чехлар Самарага җиткән диган хәбәрләр бар...

Сталинның уе ул сөйләгәннәрдә түгел, тәрәзәгә таба ярым борыла төшеп, башка нәрсә хакында фикер йөртә иде сыман. Инде бая ук

тотәтеп җибәргән трубкасын тирән итеп суырды да, кинәт, бөтенләй икенче яктан сорау биреп куйды Сталин:

— Татар-Башкорт мәсьәләсе хакында нинди фикерләр бар?..

— Татар-Башкорт Совет республикасы игълан ителүе турындагы хәбәр мөселман даирәләре тарафыннан бик хуплап каршы алынды, иптәш Сталин. Үзәктән килгән бу яңалык большевикларга шикләнеп караучыларны да уйланырга мәҗбүр итте...

— Ә большевиклар ни уйлый?

— Хуплыйлар, иптәш Сталин. Татарлар һәм башкортлар революцияне яклап утка да, суга да керергә әзер булачак.

Янә трубкасын иреннәренә китерде Сталин һәм, сынаулы карашын Мирсәетнең күзләренә текәп, һәр иҗеккә басым ясап сорады:

— РСДРП(б) члены Солтангалиев иптәшнең дә карашын беләсе килә... Шәхси карашын!

Бу төпченү нигә, ул нәрсә аңлата? дигән сыман, әле Мулланурга, әле Сталинга карап алды Мирсәет. Вахитов үзе дә сорау алуга охшап киткән бу сөйләшүдән канәгать ук түгел иде булса кирәк. Әмма, итагатьле кеше буларак, әңгәмәгә ул катышмады. Турысын әйт, ни уйлыйсың,— шуны сөйлә, дигәнен аңлатып керфек какты Мирсәеткә. Бу мәсьәләдә Солтангалиевнең үз эшен шәп белүче, компетентлы шәхес булуын югары бәяли иде Вахитов.

— Татарлар белән башкортлар бер ананың игезәк уллары сыман, иптәш Сталин. Телләре якын, мәдәниятләре һәм максатлары уртак дигәндәй... Бүлешер нәрсәләре юк...

Җентекләп аңлатырга, үз фикерләрен нигезләргә җыенган Мирсәетне тыңлап бетермәде Сталин. Казаннан килгән большевикның ничек уйлавы аның өчен әһәмиятле түгел иде, күрәсең. Мәсьәләгә үз мөнәсәбәте бар:

— Сезгә, иптәш Солтангалиев, башкортларның бу мәсьәләгә мөнәсәбәте белән кызыксынырга туры килмәдеме? Үз халкыгыз исеменнән генә сөйләмисезме?

— Тумышым белән Уфа якларыннан мин, иптәш Сталин. Казан төбәгенә караганда, башкорт далаларын яхшырак беләм дип саныйм. Соңгы көннәргәчә татар белән башкорт арасында аңлашылмаучанлык килеп чыкканы булмады. Тарихта да шулай булган. Үз иленнән куылган татарга җирен дә, сыен да кызганмаган башкорт. Ә татар мөгаллимнәре гыйлем, мәгърифәт алып килгән башкорт халкына...

Битараф елмая төшеп авызыннан төтен өреп куйды Сталин. Бу әңгәмәнең барышыннан канәгатьме-түгелме икәнлеген һич аңларлык түгел иде әле аның. һәм бу юлы да көтелмәгән сүз кыстырып куйды:

— Ә сез, иптәш Солтангалиев, император университетында нинди фән укыттыгыз? — Үз-үзеннән канәгать иде ул. Әмма шундук, үпкәләргә урын калдырмыйча, сүзен матур гына үз буразнасына борып җибәрде.— Профессорларга охшатып матур сөйлисез... Аңлатыгыз миңа, башкортлар ярык тагарак янында утырып калмасмы соң?

— Республика бер булса да, үзбилгеләнү һәм үзидарә хокукы башкорт халкының үз ихтыярында кала, иптәш Сталин. Стәрлетамакта булырмы, әлегә ачыкланмаган, башкортларның үзидарә органнары да күздә тотыла.

Сөйләшү рәвеше шундый, күрәсең, Сталин төпчүен дәвам итте һаман да. Мәсьәләнең әле бер, әле икенче ягыннан килеп бирде ул сорауларны.

— Аңладым, иптәш Солтангалиев, сез бер республика төзү ягында...

Үзләшә төшкән Мирсәет, Сталинның уйланып торуыннан файдаланып, үзе дә сүз кыстырып куйды:

— Иптәш Ленин һәм иптәш Сталин да шул ук фикерне яклый, дип ишеттек...

Үзен бүлдерүгә каефе кырылганны сиздермәде Сталин. Әмма аңлашылырлык итеп әйтте:

— Иптәш Ленин өчен мин җавап бирә алмыйм. Мәсьәләгә аның үз карашы бар. Мин ашыкмау ягында. Бер адым алга атлап, ике адым артка чигенүләрне...— Ничек йомгакларга икән дип, аз гына тукталып алды,— табигатем кабул итми.

Мулланурга күз төшереп алды Мирсәет. Бу нәрсә, читләтеп Ленинга ишарә ясавы идеме аның?..

Берөзлексез тартуын дәвам итте Сталин. Ни гомер әңгәмә кылып утыралар, ә кулыннан трубкасын төшермәде әле. Чираттагы мәртәбә эченә төтен алгач, кайтарып сорап куйды ул:

— Бу мәсьәләгә иптәш Вахитовның мөнәсәбәте миңа яхшы таныш. Бер тегермәнгә су коясыз... Шулай да сезнең фикер, иптәш Солтангалиев, нинди принципларга нигезләнә?!.

Кулын югары күтәрә төшеп, бармакларын бөгә-бөгә аңлатырга кереште Мирсәет:

— Иң элек, сыйнфый-икътисади принципларга нигезләнә. Терлекчелек һәм игенчелек белән көн күргән башкортларны промышленносте һәм милли пролетариаты булган татарлар белән бәйләргә омтылу.

Икенчедән, әйткәнемчә, культура һәм тел нигезләренең уртаклыгыннан чыгып.

Өченчедән, революция һәм бердәмлек мәнфәгатьләре өчен дә ике тугандаш халыкның бер йодрык булуы кулайрак дип саныйбыз. Татарда да, башкортта да, иптәш Сталин, «Аерылганны — аю ашар, бүленгәнне — бүре ашар», дигән мәкаль бар.

— Бүре дигәнегез рус халкы буладыр инде... Ә аю кем?— дип гел көтелмәгән җирдән бәйләнеп, чөй кыстырды Сталин.

— Сүзләремә андый мәгънә бирмәвегезне үтенәм, иптәш Сталин. Мин бер халыкны да аю-бүрегә тиңләмим... Ә югарыда санаган дәлилләремә колак салуыгызны үтенәм.

Мирсәет санаган дәлилләр һәм принциплар әллә бар, әллә юк иде Сталин өчен, исе дә китмәде. Гомумән, аны фикереннән кире кайтару яисә нәрсәгә дә булса яңадан ышандыру мөмкин булдымы икән?!. Үз туксаны-туксан, дип шундый очракларда әйтә торганнардыр.

— Дәлилләрегез тәмаммы?— диде ул, тыныч кына төтен өреп.

— Әйе, тәмам.— Әмма күңелендәге әйтми кала алмады Мирсәет.— Алар сезне канәгатьләндермәде кебек, иптәш Сталин?..

Юк дип тә, әйе дип тә әйтмәде Сталин. Әмма үзе өстенрәк булып калды:

— Фикерләрегез — кызык... Дәлилләр нигезле... Фикер һәм дәлилләрдән дә югарырак төшенчәләр бар, иптәш Солтангалиев. Сезне тыңлаганда мин әнә шул хакта уйланып утырдым.

Ул «югары төшенчә» дигәне нәрсә? Бармы ул?.. Булса, нидән гыйбарәт?.. Сталин ачыклык кертмәде. Сүзләре һәм фикерләренең шул рәвешчә, бер табышмак сыманрак булып калуын кулай күрә иде.

Хушлашып чыгарга җыенгач, Вахитовның бераз тоткарлануын үтенде ул. Мирсәеткә, кул биреп, уңышлар теләп калды.

Мулланур Вахитов озак тоткарланмады, аның артыннан ук килеп чыкты. Каефе күтәренке. Түбәнге катка илтә торган баскыч янында куып җиткәч тә, кочаклап алды ул Мирсәетне.

— Сталин ошаткан үзеңне,— диде ул, пышылдый төшеп.

— Нәрсә, бер-бер сүз әйттеме?

— «Котелогы буш түгел егетнең, фикерли», диде...

— Шул сүз өчен алып калдымы сине?..— дип, гаҗәпсенү белдерде Мирсәет.— Ә республика хакында бер сүз дә әйтмәдеме?..

Җавап бирергә ашыкмады Вахитов, баскычта килүче-китүчеләр арлы-бирле йөреп тора, үз кабинетына кергәч кенә ачыклык кертте:

— Шуны хәтереңнән чыгарма, Мирсәет: Сталин соң дәрәҗәдә хәйләкәр кеше. Фикерен һичкайчан өзеп әйтмәс. Кешеләрне тыңлый белә, башкалар бәхәсләшкәнне күзәтеп утырырга ярата ул. Үзенекен чыгармый. Күпчелек нинди нәтиҗәгә килсә, ул шуны, үзенеке итеп, йомгак ясый ахырда... Иң акыллы булып кала... Исең китмәсен, Татар республикасымы, Татар-Башкорт Республикасымы — аның өчен барыбер. Җай чыкса — аяк чалачак, эшләр без дигәнчә барып чыкса — син сөйләгәннәрне үзенеке итеп тәкъдим итәчәк. Менә шулай, Мирсәет!..

Тагы бер сәгатьтән Кремльдә, Владимир Ильичның кабул итү бүлмәсендә иде инде алар. Ленин Вахитовтан, үзен Казандагы Мөселман эшләре комиссариаты җитәкчесе белән таныштыруын үтенгән булган.

Владимир Ильич аларны сагындырып килгән кунаклары сыман кабул итте. Ишектән күренүгә, урыныннан капылт кына торып, кабинетының уртабер җиренәчә каршы килде ул аларга.

— Рәхим итегез, түрдән узыгыз, якташлар,— дип иң элек Вахитов белән күреште, аннан Солтангалиевкә кул бирде. Һәм, шундук шаяртып алырга да өлгерде:— Яныма сездәй татар егетләре килеп кергәч, үзем дә яшәргәндәй булып киттем бит әле. Яшьлегемне искә төшердегез, Казанны...

Ул да түгел, җәт-җәт атлап диварда эленеп торган зур карта каршысына төбәп китте Ленин, кунакларны да үзе артыннан әйдәде. Килгән шәптән кулына күрсәткеч таяк алды һәм, картага яны белән басып, карашын Мулланур белән Мирсәеткә таба төбәде.

— Троцкий шалтыратты әле генә. Ак чехлар Самарага һөҗүм башлаган. Самарадан соң чират Казанга җитәчәк... Революция язмышы кыл өстендә, иптәшләр. Халыкара капитализм безне, әнә шулай, Идел буйлап бонҗрага алырга исәп тота...

Сул күзен беркадәр кыса төшеп, сынаулы карашын төбәде ул Мирсәеткә:

— Әйтегез әле, иптәш Солтангалиев, Казанда шундый дәһшәтле дошманга каршы торырдай көчләр бармы?..

Ордым-бәрдем җавап бирә торган сорау түгел, уйлана калды Мирсәет:

— Көчләр бар-барын да ул, иптәш Ленин, әмма әлегә алар таркау.

— Иптәш Вахитов ничек уйлый?

Мулланур үзенең Мирсәет белән килешкәнлеген белдерде. Әмма шул таркау көчләрне тиз арада бер йодрык итеп туплау юлында Казан большевикларының зур эш башкарырга сәләтле икәнлеген дә искәртте.

Ленин татар большевикларының мәсьәләгә аек акыл белән килүләрен ошатты, күрәсең. Башындагы уйлар авырлыгыннан шактый да кысылган күзләрен ача төште.

Өстәл артына чакырды кунакларны, үзе дә аларның янәшәсенә килеп утырды.

— Казандагы фетнәне бастыруда, иптәш Солтангалиев, сезне зур кыюлык күрсәткәнсез дип ишеттем... Кызганыч, Вәисовны гына саклый алмагансыз!.. Хикмәтле кеше — Вәисовлар! Граф Толстой юкка гына мөкиббән китмәгән үзләренә...

Казан хәлләреннән шул дәрәҗәдә хәбәрдар булган Владимир Ильичны сокланып, хәйран калып тыңлады Мирсәет. Шуның өстенә һәр сүзе, һәр яңа фикере белән үзенә якынайта, тарта бара сыман иде ул әңгәмәдәшләрен. Гомерендә Ленинны беренче кат шулай якыннан күреп сөйләшү бәхетенә ирешкән Солтангалиев өчен бу аеруча тәэсирле иде. Югарыдан торып, синең шәхесеңне түбәнәйтергә омтылып, сорау алгандай төпченгән Сталин белән очрашудан соң, бу — чагыштыргысыз дәрәҗәдә ипле, эсталекле әңгәмә иде.

Сүз ара сүз ияреп, сорап куйды Владимир Ильич бераздан:

— Сизәм, иптәш Солтангалиев, сез нидер киңәшергә җөрьәт итмичәрәк торасыз кебек. Турысын әйтегез, аңлашылмаучылык калмаска тиешле без большевиклар арасында?!.

Янә бер мәртәбә Ленинның гадилеге һәм сизгерлегенә сокланып куйды Мирсәет. Һәм инде баядан ук тел очында торган сорау белән мөрәҗәгать итте:

— Иптәш Ленин, үземне күптән борчый торган сорауга җавап ишетәсем килә сездән. Әйтегез әле, нигә ышанмыйлар безгә? Нигә безгә һәрчак шикләнеп карыйлар?

— Тукта, туктагыз...— дип ярты юлда бүлдерде Владимир Ильич. Мирсәетнең соравы гаять дәрәҗәдә җитди икәнлекне тоеп, аның хәленә кереп, кичерешләрен уртаклашырга ашыгып бүлдерү иде бу.— Сезгә кем ышанмый, иптәш Солтангалиев, кем шикләнеп карый? Сөйләгез, аңлатыгыз, зинһар өчен?!.

Сул тарафка башын янтайтыбрак, һәм шул янтайган яктагы күзен кыса төшеп, дикъкать белән тыңларга әзер, җавап көтә иде Владимир Ильич.

Бер Ленинга, бер Вахитовка күз төшереп алды Мирсәет. Ленин көтә, ул аны тыңларга әзер. Ә Вахитовның исә, әллә югалыбрак калган якташын аңлый алмыйчарак торган мәле. Хәтта, юлбашчының башын катырмасаң ни булган (?) дип, шелтәли дә сыман иде үзен.

Күңелендәген яшереп калдырырга күнекмәгән Мирсәет. Нишләтеп тә булмый, табигате шундый. Бу юлы да турыдан ярды:

— Ничә гасырлар, сабан артында гына түгел, патшаның һәр урядникы каршысында да бил бөгәргә мәҗбүр булган татар халкы. Октябрь инкыйлабыннан соң әле аның яңа уңга-сулга карана башлаган, башын күтәрә һәм билен турайтырга иткән чагы. Үз иреген буып торган патша ялчыларын бер селтәнүдә алып ташларга әзер ул. Бөтендөнья капитализмы интервенциясенә каршы көрәштә дә үз-үзен аямаячак безнең халык. Совет дәүләтен яклап утка да, суга да керергә әзер без. Тик бер нәрсә икеләнергә, сагаерга һәм бүлгәләнергә мәҗбүр итә, иптәш Ленин — безгә ышанмыйлар!

— Ул кемнәр? — дип, кабатлап сорарга мәҗбүр булды дикъкать белән тыңлап утырган Ильич.

— Татарлар ризасызлык белдереп урамга чыкса, мәсьәләнең асылы белән кызыксынып тормастан, аларны фетнәдә гаеплиләр. Үз арабызда аз гына берләшү, килешү күренәме — милләтчелек ярлыгы тагыла. Тугандаш халыкларның революцион көчләре — башкортлар, казахлар яисә кырым татарлары белән элемтәгә керсәң, бубый тузы белән каплагандай панисламист дип яла ягалар үзебезгә. «Милләтче» булудан куркып кырыкмаса-кырык фиркагә бүленергә, үзара яла ягышырга һәм үтерешергә тиешлеме без? Панисламизмда гаепләмәсеннәр өчен гомер-гомергә тел-ләгать алмашкан туганнарыбызга сәлам бирмәскә, ярдәм кулы сузмаска тиешлеме?..

Владимир Ильич, бер кулына таянган килеш, Мирсәеткә текәлеп карап утыруында дәвам итте. Татар большевигының шулай ачыктан-ачык күңелендәгеләрне ярып салуы кызыклы иде булса кирәк аңарга. Сөйләүче сулыш алмаштырган арадан файдаланып, куәтләгән сыман, сүз кыстырып куйды:

— Тыңлыйм... Сөйләгез, иптәш Солтангалиев, дәвам итегез... Бу минем өчен бик тә кызыклы бит әле...

Мавыгып сөйләвен дәвам итте Мирсәет, Ильич үзе текәлеп тыңлап утырганда сөйләмиләр димени:

— Урындагы большевиклар арасында милли мәсьәләгә мөнәсәбәттә ике төрле хата караш киң таралган.

Беренчесе, милли мәсьәләнең һәм изелгән халыклар арасындагы милли азатлык хәрәкәтенең әһәмиятен бәяләп җиткермәү яисә күрмәмешкә салыну. Әйтергә кирәк, иптәш Ленин, бу авыру үзәктә генә

түгел, җирле партия оешмаларында да киң таралган. Бигрәк тә милли изелүнең ни икәнлеген үз җилкәләрендә татып карамаган җитәкчеләргә хас бу.

Икенчеләре исә, милли дәүләтчелек һәм милли аң кебек төшенчәләргә турыдан-туры аяк чалу, аларны яралгыда ук юкка чыгарырга омтылучылар. Татар республикасы да, татар-башкортныкы да кирәк түгел аларга. Мин моны большевик буларак һәм һич арттырмыйча, җаным әрнегәнгә сөйлим, иптәш Ленин. Хәтта үземә мәнәсәбәттә дә, бер генә тапкыр түгел, еш туры килә миңа боларны кичерергә. Татар булганым өчен генә икенче сортлы большевик итеп күрәселәре, кайсыберләренең хәтта шуңарга үз-үземне ышандырасылары килә. Ә мин килешмим, чөнки алай түгел икәнлеген беләм!

Ленин кинәт җанланып китте. Түбән иелә төшкән башын күтәрде. Күзләрен зур ачып стенадагы картага текәлде. Шул рәвешле, уйга калып дәшми торды ул бермәл һәм аннан, үзалдына сөйләгән сыман, катгый әйтеп куйды:

— Бар... Бар шул әле бездә андый чир. Бик күп бәлаләрнең башында империя чире — шовинизм тора, кызганычка каршы.

Моңарчы күбрәк тыңлап кына утырырга мәҗбүр булган Вахитов кушылырга кирәк тапты сүзгә. Ильичны, күңеленә кереп оялаган һәм корт сыман эчтән кимерергә керешкән, катлаулы уйларыннан аз булса да аеру, арындыру иде нияте:

— Владимир Ильич, бәхеткә каршы, гади хезмәт ияләре — пролетариат һәм крестьяннар азат андый авырулардан. Казанны гына алыйк, татар һәм рус эшчеләренең үзара бүлешә алмаслык һичнәрсәләре юк... Миңа калса, урындагы кайбер иптәшләр милли хисләрне үзара капмакаршы чәкештерүдән кызык таба кебек. Файда күрә. Иптәш Солтангалиев сөйләгәннәрне миңа да үз җилкәмдә аз татырга туры килмәде...

Үзара аңлашу, бер-береңнең хәленә керү рухында барган әлеге әңгәмә байтак дәвам итте. Ленинның кырыкмаса-кырык эше булгандыр, әмма ул ялгышып кына булса да сәгатенә күз төшермәде, үзенең кая да булса ашыкканлыгын сиздермәде. Иркенләп, мавыгып сөйләште, дикъкать белән тыңлады, уйга калды, хәйләкәр күзләрен кыса төшеп рәхәтләнеп көлеп алырга да ара тапты юлбашчы.

Вахитов тәҗрибәлерәк тә, сабыррак та, аның өчен җавап бирә алмый Мирсәет, әмма үзенә килгәндә, Ленин белән очрашудан ул канатланып, рухланып чыкты. Үзенең бөтен гомерен һәм җегәрен хезмәт ияләренең азатлыгы өчен көрәшкә багышлап ялгышмаган ул...

Кремль ишегалдына чыккач та тәэсирләрен Вахитов белән уртаклашырга ашыкты Мирсәет. Кеше белән әңгәмә кылган, киңәшкән чакларында үз-үзен сыный, фикерләрен бер тәртипкә китерә, барлый да бит әле ул. Бүгенге очрашудан соң тыныч кына атларга, дәшми түзәргә мөмкин түгел. Аннан Мулланур Вахитов үзе дә зур абруйга ия фикердәш Мирсәет өчен.

— Мулланур,— дип башлады ул сүзен,— синең белән киңәшәсе килгән бер сорау бар бит әле миндә. Әйт әле, лозунг югарылыгына күтәрелгән «пролетариат диктатурасы» төшенчәсенә карашың ничек синең? Бу сорауны мин Ленинга да бирергәме әллә дип уйлап утырган идем...

Шул да булдымы соравың дигән сыман, гаҗәпләнеп карап алды Вахитов.

— Дәшми калуың яхшырак булган,— диде ул коры гына.— Маркс һәм Ленин хезмәтләрен укырга кирәк.

Аңламады аны Вахитов. Мирсәет соравын кабатлады:

— Укыган бар да ул...

— Соң?.. Ышандырмыйлармы?..

— Ышандыралар. Әмма күңелдә канәгатьсезлек кала. Үзең уйлап кара, Мулланур, ни өчен дип бөтен хезмәт ияләренә азатлык китергән

революцияне, яңа тормышны пролетариат диктатурасы белән чикләргә. Нигә пролетариат кына?!. Һәм нигә ул «диктатура» булырга тиешле?!.

Вахитов пролетариатның революцион хәрәкәттә башлап йөрүче төп көч булуы һәм «пролетариат диктатурасы» дигән төшенчәнең символик мәгънәгә дә ия икәнлеге хакында кабатларга мәҗбүр булды.

Әмма сөйләп бетерергә ирек бирмәделәр. Мирсәет:

— Беләм... Аңлыйм. Килешәм,— дип, җөпли-җөпли барды да күңеленә кереп оялаган икеләнүләре белән уртаклашырга кереште.— Ярый, без — татарларда беркадәр пролетариат булсын да ди. Ә күп кенә күршеләребез — төрки халыкларның зур завод-фабрикаларда бергә тупланып эшләүче милли пролетариаты юк дәрәҗәсендә ич әлегә. Алар нишләргә тиеш? Эшчеләр сыйныфын ярлы крестьяннарга каршы кую гына түгел, бер милләтне икенче милләткә каршы кую да булып чыга түгелме соң пролетариат диктатурасы?!. Мисал өчен, башкорт, казах һәм үзбәкләр милли пролетариаты булган рус, украин һәм татар янында тигезсез һәм хокуксызрак булып чыга түгелме соң?!. Көнчыгыш илләрендә яшәүче төрек, фарсы, әфган, кытай һәм гарәп халыкларының да, бәлки, Россиядәге революцион хәрәкәткә кушылырга нияте булгандыр. Ә без аңлый торып та, милли азатлык хәрәкәтенең нинди зур революцион көч икәнлеген искә алып җиткермибез, күрмәмешкә салышабыз түгелме?...

Көлемсерәп куйды Вахитов.

— Син күтәргән сорауларның күбесенә җавап бирелгән Ленин хезмәтләрендә. Ә калган өлешенә киләчәк җавап бирер. Һәрхәлдә, мин синениләр борчыганлыкны аңладым, Мирсәет.

Вахитовның, шул рәвешле, ул күтәргән мәсьәләләрне җиңел генә урап узарга омтылуы бигүк ошап җитмәде Мирсәеткә, ә бәлки урыны һәм вакыты ул булмагандыр. Кәефе кырыла төшсә дә, сиздермәскә булды.

Дәшми бардылар бермәл. Кремль ишегалдыннан чыгып килгәндә, сүз уңаена гына дигән сыман, кызыксынып куйды Вахитов:

— Нәрсә, Казанда иптәш Грасис белән борчагыгыз пешмиме әллә?

— Каян алдың, мин алай димәдем,— дигән булды, ә күңеленнән Вахитовның сизгерлегенә хәйран калып куйды. Нәкъ шул тирәдә чуалган чагы иде фикеренең.

— Сүз сөрешеңнән, йөрәк тибешеңнән сизеп барам,— диде Вахитов, барыбер үз фикерендә калуын раслап.

Мирсәет янә, күңелендә ни булса, шуны сөйләргә мәҗбүр иде. Мөселманнарның хәрби оешмаларына булсын, революцион оешмаларына булсын, Казан һәм Уфа губернасы партиясе җитәкчеләренең сагаебрак караулары, бигүк теләктәш булмау очраклары турында искә төшерде ул.

Вахитов аңар һәр саксыз сүзне йөрәгенә якын алмаска, кайчакта дәшми калуның да зур әһәмияткә ия булуы турында искәртте. Нинди генә кыенлыкларга дучар булганда да большевиклар партиясенең бердәмлегенә зыян китермәскә, милләтләр арасындагы ыгы-зыгылардан өстенрәк булырга киңәш итте.

Милләтләр эше халык комиссариаты бинасы каршында аерылышты алар. Вахитовның кереп чәйләп алырга чакыруыннан баш тартты Мирсәет. Кызын һәм хатынын сагынып килде ич Мәскәүгә, шулар янына ашыкты. Юкса, иртәгәсен, таң белән кайтыр юлга чыгасы бар.

* * *

Ул, кучтәнәчләр төяп, караңгы тимер баскычтан менеп килә. Үз гаиләсенә, үзенең газиз кызы һәм сөеп туя алмас Раузасы янына... Дулкынлана... Йөрәк күкрәк читлеген бәреп чыгардай булып тыпырчына. Нигә шулай ул?!. Сталин янына, хәтта Ленинның үзе янына тәүге кабат

кергәндә дә артык дулкынланмаган, үзен тыныч тоткан Мирсәеткә ни булды соң?!. Башкалар кук нигә ул да үз өенә, гаиләсе янына тыныч кына кайтып керә алмый соң?!.

Үзе атлый, ә үзе күңелендә йөргән шигъри юлларын кабатлый:

Кырау тимәс апсу гөлләр белән
Бертуган син, беләм, тумыштан.
Сөйдерәсең, Рау..., көйдерәсең:
Яралгансың ахры син уттан!..

Ишек тоткасына үрелгәч тә, бермәлгә туктап, хәбәр бирмичә үз-үзен кулга алырга тырышып торды ул. Нигә шулай дулкынланамы?!. Чөнки ярата, берәзлексез сагынып яши ул аларны, очрашу сәгатьләрен түземсезлек белән көтеп ала. Беренче күрүдә үк сихерләде, колы итте сыман аны Рауза. Ансыз үткән көннәренең Мирсәет өчен нинди авыр газап булуын ул үзе генә белә. Дөньяга ямь өстәп, бетмәс-төкәнмәс гайрәт һәм илһам китергән бердәнбере, өзелеп сөйгәне, гомерлеккә дип сайлап алганы ич ул аның. Рауза...

Ишекне, гадәттәгечә, әбисе ачты. Бары үз өендә генә була торган җылы рәхәтлек килеп бәрелде йөзенә. Ул да түгел, Рәсидә йөгереп килеп чыкты. Ярты юлда туктап калды ул, ятсынуы иде булса кирәк, сынап карап торды әтисенә һәм таныды, ниһаять:

— Әттә,— дип кочагына атылды Мирсәетнең.

— Менә ничек дәү үскән бит минем кызым...

Йомшак борыны һәм иякләре белән әтисенең муенын иркәләде сабый. Аннан, башын читкәрәк тайпылдырып, сынаулы караш ташлап алды янә бер кабат — ялгышмаганмы, үз әтисеме, янәсе...

Бер кулына уенчык, икенче кулына дәү клиндер тоттырып, сабыен идәнгә төшерде Мирсәет. Бу аның үз-үзен белешмичә, кочагын бушатуы, Рауза белән күрешергә җыенуы булгандыр, күрәсең.

— Әби,— дип дәште Мирсәет, киявенә ялык читеннән генә ягымлы карашын төбәп торучыга кулындагы башка күчтәнәчләрен сузып.— Болары Рауза белән сиңа.

Әби кеше аш-су булмәсенә юнәлде. Рәсидә дә аңарга иярде, әтисе алып кайткан уенчыкны күрсәтеп куанасы, мактанасы бар бит әле...

Аягындагы күнитекне салу белән мәшгуль булган Мирсәет күзләре белән Раузаны эзләде, Раузаны көтте. Бер-бер сәбәп табып үпкәләгәнме соң әллә, нигә күренми?.. Казаннан озаткан чакта: «Сине сагынырмын инде, нишләрмен...» — дип, күз төпләрен сөртә-сөртә аерылышкан иде, югыйсә...

— Рауза өйдә түгелме әллә? — дип тавыш бирде Мирсәет, тисә — тиенгә, тимәсә — ботакка дигән сыманрак.

Үзенең белдекләлеген күрсәтәсе килеп, сорауны ишеткәч тә, иң элек Рәсидә йөгереп чыкты. Әле һаман күп кенә авазларны дөрес әйтергә өйрәнмәгән, үзенчәләп сукалый иде ул, ни әйткәнен аңламассың...

— Әнием ружьега китте, ружье янына...

Көлеп куйды Мирсәет. Әбисе аңлаткач кына төшенде: Рауза доктор Оруджиев янына киткән булып чыкты. Нервларыннан зарлана иде ул, әле Бакуда вакытта ук Оруджиев фамилиясендәге врач янына барып йөргәнлеге мәгълүм иде. Димәк, ул Мәскәүгә күчеп килгән булып чыга.

Көн кичкә авышып килгән чак, шуңа Раузаны каршы алырга кирәк дигән карарга килеп, урамга чыкты. Сагынуы да чиктән ташып ашкан. Әбисе докторның төгәл адресын әйтә алмады алуын, шулай да чама белән кайсы тирәдәрәк яшәгәнлеген аңлатты.

Шәһәр үзәгендәге тыныч һәм тар тыкрыклардан йөри торгач, таштан төзелгән ике катлы аерым йорт каршысына килеп туктады Мирсәет. Ишекнең сул ягына чуеннан коелган игълан язып эленгән: «Бу йортта доктор Оруджиев яши. Кабул итү сәгатьләре — иртәнге 10 нан кичке 6 га кадәрле. Ял көне — җомга».

Чылбырыннан тартып чыгарып, кесә сәгатенә күз төшереп алды Мирсәет. Инде җиденче киткән. Болай булгач Раузаның кайтып киткән булуы ихтимал. Ул да түгел, бүген җомга көн икәнлеге келт итеп хәтеренә төште. Моны ничек аңларга да белмәде ул. Димәк, аның кебегүк атнаның кай көне икәнлекне оныткан Рауза кире борылып кайтырга мәҗбүр булгандыр.

Күңелендә шундый уйлар бөтерелде. Ә кулы кыңгырау җебен тартты. Килгәч-килгәч докторның үзенә сәлам биреп китүнең зыяны булмас, берочтан Раузаның авыруы белән дә кызыксыныр.

Олы гына яшьтәге бер агай килеп ачты ишекне. Борыны һәм мыегыннан күренеп тора — кавказлы. Колакка катырак иде булса кирәк, урынсызга кычкырып дәшүеннән, тыңлаганда авызын ача төшеп, бар дикъкатен әңгәмәдәшенә юнәлтүеннән үк күренеп тора.

— Кем бар анда? — дип кычкырды ул. Югыйсә, пыяла аша бары да күренеп тора, әле кояш баемаган...

— Әссәламе... галәйкем,— дип, сәламләде үзен Мирсәет.

Күренеп тора, агайга килүченең мөселман кешесе булуы һәм шул рәвешле сәламләве ошап китте. Балкып елмайды ул һәм, ишекне ачып, кунакны эчке якка үткәрде:

— Вәгәлайкем әссәлам. Хуш киләсез, хуш... Кем дип торам, үзебезнең кеше икән...

Агай ялгызлыктан җәфа чиккән, күрәсең, килүчене кире борырга ашыкмады, аны җентекләп күзәтергә кереште.

Мирсәетнең исә, киресенчә, вакыт чамалы:

— Доктор үзендәме, агай,— диде ул эшлекле генә, ашыгыч сүзе бар атлы булып.

— Үзендәсен — үзендә,— дип кычкырды карт. Килүчене күргән дә, күрмәгән дә сыман тоела иде бугай аңа. Һаман нидер хәтерләргә теләп, Мирсәетне күзәтә.

— Кирәргә рөхсәттер бит, агай,— дип, ашыгуын белдерде Мирсәет, күз читен затлы стена сәгатенә төшереп алды.

Картның күңеле изгелектә. Күренеп тора, килүчегә ярдәм итәсе килә. Әмма үзен нидер тота:

— Бик ашыгыч идемени?..

Аны-моны уйлап тормады Мирсәет, шундук җавап кайтарды:

— Ашыгыч иде шул.

— Хуҗа кемнедер көтә иде кебек,— дип, нәтиҗә ясады агай үзе өчен. Димәк, килүчене борып чыгарырга ярамас, ачыктан-ачык аңлатырга һәм көтәргә кушарга кирәк.

Мирсәетне өске катка алып менеп, йомшак креслога утыртты карт. Чәй тәкъдим итте.

— Хәзер,— дип тынычландырды ул аны,— бер-бер җаен табып хәбәр итәрбез үзенә.

Юкка вакытын уздыра Мирсәет. Монда ни калган соң аңарга, кемне көтә. Чәйдән баш тартты, тынгысызланып, сорарга мәҗбүр булды:

— Әллә операция ясыймы?

Карт, үз итеп, текәлеп карап алды янә. Һәм мыек астыннан елгыр гына елмаеп куйды.

— Хуҗамны яхшы беләсез, ахры?..

Баш какты Мирсәет.

— Яхшы.

Картның кәефе тагы да күтәрелеп китте.

— Әпирәсия,— дип кабатлады ул аның артыннан. Авызын-мыегын сыпырып кеткелдәп үк көлеп алды тыйнак кына.— Аны әпирәсия үк дими торганнар иде без яшь чакта... Хи-хи-хи...

Берни аңыша алмый торган Мирсәеткә якынрак килде карт һәм күптәнге танышына дәшкәндәй колагына пышылдады:

— Бер Мәскәү кәнтәе белән шунда... Күңел ача...

Янә зур канәгатьлек белән кеткелдәп җибәрде карт. Һәм чәй алып менәргә вәгъдә итеп аскы катка юнәлде.

— Тукта,— дип ярты юлда, баскычта куып тотты үзен Мирсәет.— Кем белән ул анда — марҗамы?

Карт башын чайкады. Бакуда яшәп телен шактый ук шомарткан Мирсәетне әзербайҗанга чыгарды күрәсең:

— Бер татар хатыны шунда,— диде. Кулын күкрәк турысына куеп, аның кыска буйлы икәнлегенә дә ишарәләп өлгерде.

— Исеме ничек?..

— Белмим,— диде ул иң элек битараф кына. Корырак чыкканны аңлады булса кирәк, аннан ачыклык кертергә кирәк тапты.— Кәнтәй-кәнтәй инде, кем кызыксынган аларның исемнәре белән. Үзе дә бутап бетерә торгандыр, хи-хи-хи...

Җавaптан канәгать түгел иде Мирсәет. Әмма кызыксынуын артык дәвам итә алмады, чама белергә кирәк. Ике кат арасындагы баскычның урта бер җирендә торып калды. Чәй китертү, килүчегә кавказлыларга хас кунакчыллык күрсәтү уе белән мавыккан карт юлында булды. Бераздан аскы катта кемнәргәдер дәшкәне, сөйләшкәне ишетелеп куйды аның.

Шунда гына Мирсәет үз-үзенә гаҗәпләнеп куйды: нишләп керде соң әле ул монда? Докторның кабул итү көне түгел, нәрсә калган аңарга?.. Санаулы сәгатьләренең кадерен белми... Сукбай сыман кеше бусагасын атлап керде, хәзер инде бер чынаяк чәй өлгерткәннәрен көтеп торсынмы? Ә өйдә кызы, зәңгәр күзле Раузасы көтә торгандыр... Әллә бер-бер шик, ышанмау оялаганмы аның уена?.. Ни тотып тора соң аны урында, нәрсә җибәрми?.. Хәтта үз-үзенә тану кыен, үз-үзеннән оят. Китәргә, кайтып китәргә, гаиләсенә йөгерергә кирәк хәзер үк... Ә ул тәрәлеп каткан. Аяклары җибәрми.

Чү!.. Нәкъ шул мизгелдә, колагына ялгыш ишетеләме, өске каттагы калын ишекләр артыннан шәл чугыдай сизелер-сизелмәс тибрәнеп бераүнең көлгән авазы ишетелгән кебек булды... Тетрәнеп куйды Мирсәет — таныш көлү түгелме соң бу аңар?!. Йөзләгән, меңләгән авазлар арасыннан да аера иде ул аны...

Колагына ишетелә дисәң, тагын кабатланды. Тагын-тагын шул ук аваз... Үз-үзен белештермичә югарыга ыргылды ул. Ике кат калын ишекләр үтеп, зур, иркен бүлмәгә атылып килеп керде һәм магнитланган сыман катып калды.

Бүлмәнең түрендә ялангач тәнгә халат киеп алган дәү гәүдәле, олы корсаклы бер ир-ат басып тора. Тупас йөзе, иләмсез борыны һәм чал төшкән мыекларын хәтерләп өлгерде ул аның. Бер кулында шәраб тулы шешә, икенчесендә бәллүр касә... Шул касәсен түшәк эчендә чумып назланган болан баласыдай җыйнак гәүдәле хатынга сузып торуы икән.

Ишек катында гаме юк иде әле хатынның. Ә Мирсәетне яшен ташы гүя кыл урталай ярып үтте.— Рауза... Ир-ат исә, аны шундук күрде һәм таныды да булса кирәк. Бакуда чакта күреп беләләр иде бер-берсен. Көтелмәгән очрашу Оруджиевка да тәэсир итми булмагандыр.

Ни эшләргә, кулындагы шешә һәм касәне каярак куярга белмичә торды ул иң элек. Әле урын өстендә анадан тума тәгәрәп иркәләнгән хатынга, әле ишек катындагы чакырылмаган кунакка карап куйды.

Ул да түгел, түшәктән башын калкыткан Рауза аваз салды:

— Әнкәем...— диде ул, уч төбе белән авызын каплап. Зур булып ачылган күзләре ишек катына төбәлде, ә икенче кулы белән капмалап җәймәне эзләргә керешге. Күкрәкләренә таба тартты җәймәне...

Тынычланып өлгермәде, дересрәге, үз-үзен кулга алып өлгерде Оруджиев. Утырып калган тынлыкны ул бүлдерде:

— О-о-о, кунак бар икән,— диде. Һәм кыргый, мыскыллы елмаю чыгарды йөзенә.— Мактап йөрисең икән...

Мирсәетне, гүя аягүрә торган җиреннән чалгы белән чаптылар. Аумас өчен диварга сөялде ул. Урам як ишектәге язуны күргәч тә борылып китәргә тиешле иде, югыйсә. Әнә ни тоткан, ни тартып керткән икән үзен монда. Башка сыймаслык хәл! Өнме бу, төшме?! Күңелендә булып, соңгы араларда үзен берөзлексез эчтән корт сыман кимереп йөргән шик-шөбһә урынсыз булмаган, димәк. Ә ул үз-үзен битәрли, үз-үзен урынсызга көнләшүдә гаепли иде бит... Аяк астында җир чайкалды, гүя. Ни дә булса дәшәргә һәм кырт борылып чыгып китәргә генә иде дә бит — зиһенен югалтты, чарасыз торып калган иде Мирсәет. Кая китә?.. Кая ашыга соң ул хәзер?.. Ярты җаны, бәлки яртысыннан да күбрәге — монда. Берөзлексез үзенә тартып торган һәм кыен чакларында дөньяда аның барлыгын тою белән генә дә, бетмәс-төкәнмәс көч, җегәр бирергә сәләтле булган бердәнбере — Раузасы монда кала. Китә алмый газапланды ул. Әмма китәргә кирәк. Чит ятакта чәчләрен тузгытып, шәрә күкрәкләренә ак җаймә тартып утырган Рауза — ул белгән, ул дөньясын онытып сөйгән Рауза түгел инде... Түгел!

Оруджиевның үгез мөгерәгәндәй борыннан чыккан калын тавышы айнытып җибәрде кинәт:

— Сүзең булса, сөйлә... Нигә терәлеп каттың, әй, большевик!

Ни дип әйтә ала иде соң ул?!. Әле хәзер, аек акыл белән уйлаганда да, андый сүзне табарлык түгел. Ә ул чакта, аяк бармакларыңнан чәч бөртекләреңәчә гарьле нәфрәтләнүдән дер калтырап торган мәлдә, ни әйтә алган булыр иде икән?..

Авызын турсайта төшеп, чал төшкән калын мыеклары астыннан оятсыз елмаю юллады Оруджиев. Үзен гаепле санау янсә аз гына булса да уңайсызлану хисе түгел, үз-үзенең өстенлеген, бу очракта җиңүче икәнлеген расларга, ассызыкларга омтылышы иде бу аның.

— Нәрсә, баҗа, бер касә шәраб салып биримме әллә үзеңә?!. Хәл булыр! — диде ул, кулындагы шешәгә ым кагып.

Шунда гына Мирсәетнең теш арасыннан калтыранулы аваз чыкты:

— Доктор Оруджиев! Син аның ире бар икәнлекне белә идең бит!..

— Белсә соң,— диде мыеклы, мыскыллы көлүендә дәвам итеп. — Ирсез хатын булмый. Кемгә нәрсә?! Берәүләр революция ясый... Ә икенчеләре...

Ятактагы хатынга ишарәләп авызын ерган бу адәмгә тыныч кына карау мөмкин түгел иде. Нәфрәтләнеп, кычкырып җибәрде Мирсәет:

— Доктор Оруджиев!.. Тукта!..

Эт оясында батыр, дигәнне раслап, кеткелдәп көлеп җибәрде хуҗа. Шәраблы бәллүр касәне идәнгә орды кинәт кенә һәм үзе сыман киң бүксәле шешәне югары күтәреп Мирсәеткә таба якынлашырга кереште.

Ул да түгел, үзенә төбәп ыргытылган шешәдән тайпылып, башын иярга мәҗбүр булды Солтангалиев. Шешә, ишек яңагына бәрелеп, чәлпәрәмә килде. Ирексездән, итек кунычына тыгылды Мирсәет.

Өр-яңа браунингтан чыккан шартлау авазы гайрәтле үгез сыман өскә ташланган адәмне идәнгә сузып салды.

Баскычтан кемнәрнеңдер шау-шу килеп йөгерешкәне, ярдәмгә ашыкканы ишетелде. Ахылдап куйган Рауза, урыныннан сикереп торып, кабалана-кабалана шәрә тәнен җаймә белән урарга кереште. Әле берни аңламыйча, үзенә каршы йөгерүчеләрне як-якка этәреп чыгу юлына ашыкты Мирсәет. Бу йортта берни калмады аңарга хәзер, алыш-биреш өзелгән. Югары катка менеп җитүчеләрнең: «Үтергәннәр... Ходаем, үтергәннәр...» — ди-ди кычкырышкан авазлары ишетелеп калды. «Тотыгыз, тот»,— дип, Мирсәеткә төртеп күрсәтүчеләре дә булды кебек. Әмма артыннан куа чыгучы, үзен тотарга омтылучыларны ул күрмәде.

Уң кулына браунинг тоткан килеш берәүгә дә күтәрелеп карамыйча, башын асылындырып урамның нәкъ уртасыннан атлады ул. Аның кулындагы коралын күреп, каршы килүчеләр як-якка тайпылды, тротуарга

елыштылар, берәүгә дә игътибар юнәлтмәде, аяклары кая таба илтсә — шунда атлады...

Җәйге кичнең эңгер-меңгергә авышкан чагы. Күңелен һәм уйларын да шундый ук халәт биләп алган. Ни эшләдем соң әле мин? дигән сорау шактый ук кичегә төшеп килде. Чынлап та, ни кылды, нинди ахмаклык эшләп ташлады соң әле ул?.. Нәрсәле булды һәм нигә иреште?

Үзенең бердәнберенә кул сузган, иң нечкә хисләрен аягастына салып таптаган, аның ир-ат горурлыгыннан көләргә җөрьәт иткән кешене атып үтерде. Хыянәтченең үзен үтерде үтерүен, әмма хыянәтне үтерә алдымы соң ул? Хакыйкатьтән качып буламы соң?! Тапталган хисләр яңарырмы, җанына яңадан тынгылык иңәрме аның?!.

Уй өстенә уй, сорау өстенә сорау... Тик берсенә уңай җавап таба алса икән. Шушы сәгатьтән башлап сөю дә юк, яшәү дә юк инде аның өчен хәзер. Революция һәм яңа тормыш, милли республика турында күпме хыяллары челпәрәмә киләчәк. Юк! Юк инде, берәүгә дә кирәге юк аның хәзер.

Әле санаулы сәгатьләр генә элек, үзенә шундый хөрмәт белән караган Ленинны хәтергә төшерде ул шунда. Сталинга да кирәге чыкмас моннан ары аның!.. Иң аянычы, ул Вахитовны кыен хәлдә калдыра. Үзенә ышангандай ышана, зур өметләр баглый иде бит аңа Мулланур. Ә Мирсәет шул өметләрне акламады, үз хисләренә хуҗа була белмәде...

Шунда гына әле булса уң кулында браунинг икәнлекне күреп тынгысызланып куйды Солтангалиев. Браунинг — Гәрәй Кодрачев истәлеге. Соңгы араларда гына Кодрачевның, ни сәбәпледер, Киевтә үз-үзен атып үтергәнлеге мәгълүм булган иде аңар. Гаҗәпләнгән иде ул бу хәбәрне ишетү белән, аңлый алмый аптыраган иде Гәрәй дустын: ничек итеп кеше үз-үзенә, үзенең газиз гомеренә корал күтәрергә мөмкин икән?!.

Гәрәй Кодрачевның хәлен аңлаган кебек булды ул шунда. Күрәсең, аның да зиһене чуалган, доньяда яшәүнең ямен, мәгънәсен югалткан сәгате булгандыр. Браунинглы кул акыртын гына хәрәкәтләнә төшеп, тимер көпшә чигә турысына ук шуып менде. Шуның белән бетте, димәк... Дөнья белән бәхилләшер алдыннан соңгы кабат күзләрен ачты ул. Тар гына урамның аргы ягында өлкән яшьләрдәге бер бичара җан чүп савытыннан ризык калдыклары җыеп йөри иде...

Йөрәгенә үк барып кадалды бу тетрәндергеч күренеш. Яшәүгә, тормышка кеше, әнә, нинди хәләтендә дә ябышып ята. Ә син, шундый мохтаҗларны бәхетле итәчәк яңа тормыш төзисе урында, көрәшәсе урында, җиңел юл тапкансың... Җинаять кылдың да, инде хәзер качып котылырга исәбең!..

Тагы күпмедер вакыттан эшче-крестьян милициясе идарәсендә иде инде ул. Үз аягы белән килеп, үзенең кеше үтерүе турында хәбәр итте. һәм коралын өстәлгә чыгарып салды. Кылган җинаяте өчен закон каршында җавап бирергә әзер иде Мирсәет.

Бер ай чамасы вакыт ябылуда ята ул. Берәүгә дә хәбәр итми, яклаучы эзләми. Мөселман коммунистлары исеменә тап төшерүдән куркып, хәтта үзенең кем булуын яшерә.

Мулланур Вахитов эзләп таба аны һәм төрмә җитәкчелеге бүлмәсенә чакырттыра.

— Мин барын да беләм,— ди Мулланур сүзен кыска тотып.— Тик бер нәрсәне аңлый алмыйм. Ничек син шул гомер хәбәрсез ята алдың?!.

Мирсәет нык ябыккан һәм сулган иде, күрәсең. Йокысыз төн, тәүлекләр буе үз-үзендә казыну, эчтән янып-көюләр эзсез генә узмаган булгандыр.

— Кара инде син, үз кыяфәтеңә генә кара, базда ятып үргән бәрәңге төсенә кергәнсең ич,— диде Вахитов.

Мирсәет аңлый алмыйчарак торды, аның тышкы кыяфәтендә идемени соң хикмәт?

— Мин кеше үтердем, иптәш Вахитов,— дип кабатларга мәҗбүр булды ул.

— Ишеттем,— диде Мулланур кырт кистереп.— Әйдә, җыен, мин сине алырга килдем.

Мирсәетне сискәнергә мәҗбүр итте Вахитовның бу сүзләре:

— Кая, хәрби трибуналгамы?

— Казанга... Ак чехлар Казанга якынлашып килә. Иртәгә үк минем белән юлга чыгасың...

Юк, берни аңлый алмый иде Мирсәет. Нинди юлга чыгу дигән сүз ул?!. Нинди Казан?!. Ул бит җинаять кылучы...

— Иптәш Вахитов,— диде ул янә.— Бик теләсәм дә синең белән юлга чыга алмыйм, мин кеше үтердем.

Мирсәетнең сакал-мыек баскан яңакларына, чалара төшкән чигәләренә текәлеп карап торды Мулланур. Җитди һәм уйчан иде аның бу карашы. Сүзләрен генә аңламассың...

— Үтерсәң соң,— диде ул, кинәт кенә.— Бер инкыйлаб дошманы ким булганнан җир убылмас шәт. Каш ярылып күз чыкмаган ласа. Җыен әйдә...

Куанырга ашыкмады әле Мирсәет. Вахитовның аны аңлавы, кечерергә-акларга омтылуы бер нәрсә. Ә башкалар — Казанда һәм Мәскәүдә үзен белүчеләр ни дияр? Ничек күренер ул кеше күзенә...

— Ашыкма, Мулланур, миңа әле суд булмаган...

— Нинди «суд» ул?!. Ташла син аны...

Шунда гына Вахитовның сүзләре чын икәнлегенә ышанды ул.

— Ә Казанда? Анда беләләрме?.. Анда ни йөзем белән күренермен?..

— Белсәләр соң,— диде Вахитов, битарафлыгын күрсәтергә омтылып.— Иптәш Сталин да белә.

— Иптәш Сталин?!.

— Әйе, иптәш Сталин сиңа шуны тапшырырга кушты: «Бер мөссаватчы азрак булыр. Революция корбансыз булмый, бүген үк Казанга юл тотсын. Берни булмагандай үз эшен дәвам итсен»,— диде.

— Берни булмагандай...— дип, Вахитов артыннан кабатлап, бу сүзләрнең асылына төшәргә омтылып, уйга калып торды Мирсәет. Шулай мөмкин була микәнни?!. Ничек инде ул «берни булмагандай?»

Иртәгесен Вахитов белән янәшә утырып, Идел буена юл тоткан махсус броневикта Казанга кайтып бара иде инде алар.

Күңелдә генә утлар яна... Күңелдә тынгылык юк. Ничек яшәргә хәзер?! Ганиләсе дә юк аның. Раузасы да... Рәсидәдән дә ераклашканнан-ераклаша бара... Гүя, дөнья бушап, шәрәләнеп калган иде аның өчен хәзер...

* * *

1918 нче елның май урталарында Мәскәүдә Татар-Башкорт республикасы мәсьәләсе буенча зур киңәшмә булып уза. Аны Милләтләр эше халык комиссары Иосиф Сталин һәм Мөселман эшләре халык комиссары Мулланур Вахитовлар уздыра. Идел-Урал төбәкләреннән чакыртылган утызга якын җаваплы иптәшләр арасында: Казаннан — К. Якубов һәм К. Грасис; Оренбургтан — Филипов һәм Г. Шәмгунов; Уфадан — В. Егошин һәм Г. Дәүләтшин; Пермьнән — Динмөхәммәтов; Сембердән — Х. Рәмиев һәм С. Гафуров; Екатеринбургтан — Ф. Сыромолотов һәм И. Тунтул; чуваш халкы вәкиле А. Краснов, мари халкы вәкиле В. Мухин; Мөселман комиссариатыннан Ф. Сәйфи, Ш. Манатов, Г. Җанбаев һәм башкалар катнаша.

Киңәшмәнең башында ук Казан губерна советы исеменнән Карл Грасис милли республика төзү идеясенең хата икәнлеген расларга омты-

лып кайнар нотык сөйли. Килгән вәкилләр югалып калалар бермәлгә. Чөнки бераүдә дә Ленин һәм Сталин иптәшләр тарафыннан көн тәртибенә куелган мәсьәләне кире кагу уе булмый. Әмма бу хакта сүз кузгалып, ул сүзне кузгатучы Казан вәкиле дә булгач, кайбераүләр сагая төшә.

Шундый хәлиткеч мизгелдә Татар-Башкорт республикасын яклап, үзләренең дә шунда керергә теләкләре булуын белдереп, чуваш һәм мари халкы вәкилләре чыгыш ясый.

Мулланур Вахитов республика игълан ителү вакыйгасының Татар-Башкорт хезмәт ияләре арасында Совет хөкүмәтенә ышаныч тудыруы хакында сөйли. Идел-Урал мөселманнары язмышындагы бу фактның Көнчыгыш халыклары арасында киң яклау табачагына өмет һәм ышаныч белдерә.

Камил Якуб, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Манатов, Гариф Җанбаев һәм башкаларның чыгышыннан соң, көн тәртибенә куелган мәсьәләнең урынлы икәнлегендә шик калмый. Киңәшмә, агымдагы елның 1 июнендә, Татар-Башкорт республикасын оештыру съезды чакырырга дигән карарга килә. Аны үткәрү урыны итеп Уфа шәһәре билгеләнә. Съездны оештыру һәм үткәрү Халык Комиссариатыннан М. Вахитов, Мөселман эшләре комиссариатыннан Г. Җанбаев, башкортлардан Г. Дәүләтшин, татарлардан К. Якубов, чувашлардан Д. Эльмин, марилардан В. Мухин һәм руслардан В. Егошин катнашында төзелгән махсус комиссиягә йөкләтелә.

Халык массалары арасында зур күтәренкелек һәм энтузиазм белән кабул ителә бу вакыйгалар, күпләп Кызыл Армиягә язылу башлана. Яшь Совет дәүләтен, үзләренә милли тигезлек һәм республика бүләк иткән өчен генә дә, саклап калырга, яклап көрәшергә әзер була татар, башкорт, чуваш һәм мари хезмәт ияләре. Зыялылар даирәсендә дә көчле була әлеге хәрәкәт.

Әмма съездны оештыру эше киң җәелдерелеп, инде тәмамланып килгәндә Үзәк комитетка һәм В. И. Ленин исеменә РКП/б/ Үзәк Комитетының Урал бюросы секретаре И. Тунтул, К. Грасис һәм Ф. Сыромолотовлардан кумәк гариза килеп төшә. Россиянең бөтенлеген таркату белән килешмәүләрен белдерә алар һәм, гомумән, Үзәк Комитетның «кемнәрдер тарафыннан уйланып чыгарылган милли мәсьәлә» тирәсендә мавыгуын аңламыйлар һәм аңларга да теләмиләр. Шул уңайдан протест белдерәләр.

Ленин, очраклы рәвештәдерме, түгелме, әлеге гаризага чамадан тыш зур игътибар күрсәтә. Аның белән һәммә Үзәк Комитет әгъзаларын таныштырып чыга. Һәм, мәсьәләгә ачыклык кертүен үтенеп, гаризаны Сталинга тапшыра.

— Россияне йолыккалап бетермибезме? — дигән сорау куя Ленин...

— Урыннардан килгән хатларга колак салу кирәк...

Алай икән! Имәндә икән чикләвек, диярсең.

Нәтиҗә ясала... Зур булмаган даирә өчен ул аермачык билгеле була. Әмма, Идел һәм Урал тарафларында, вакыйгаларның көне-сәгате белән катлаулана баруын истә тотып, ул хакта сүз чыгармый тору хәерле табыла. Шул рәвешле, Татар-Башкорт республикасының Оештыру съезды 1 июньнән башта 15 сентябрьгә күчереп торыла, ә сентябрьдә исә, Гражданнар сугышы башлануны сәбәп итеп, мәсьәләне хәл итү билгесез вакытларга чигерелә.

Кайбер җитди чыганаклар сөйләвенчә, әле майның 20 нче көнендә үк Съездны оештыру комиссиясе хәзерләгән смета кәгазьләрен Мулланур Вахитов Сталинга алып керә.

Милләтләр эше халык комиссарының йөзе чытыла:

— Җитди документ һәм финанс кәгазьләре шул арада эшләнәме?

— Йокы һәм ял турында онытып, өч көн, өч төн тырыштык, иптәш Сталин,— дип җавап кайтарды Вахитов. Күңеле күтәренке.— Андый чак-

та йокы турында уйлыйлармы?! Ничә гасыр көтелгән сәгать ич бу безнең халык өчен...

— Карарбыз... Калдырып тор, әнә,— дип, төребкәле кулы белән читтә торган өстәлгә ишарәли Сталин.

Югалып калырга тырышмый Вахитов һәм алдатырга да теләми.

— Юк, иптәш Сталин, анда калдыра торган документ түгел бу,— дип, каршысына ук китереп сала.

Әмма аңа карап кына, ябык кабинет һәм катлы-катлы ишекләр артында хәл ителгән мәсьәләгә караш үзгәрми... Комиссия хәзерләгән эш һәм финанс кәгазьләре тагы бер атна чамасы вакыт узгач кына хәрәкәткә керә. Сталин аларны «Бу эшне ашыктыру кирәк булмас...» дигән тамга ясап, урынбасары С. Пестковскийга чыгара.

* * *

Мирсәетнең Казанга нинди кәеф белән әйләнеп кайтуы аңлашылса кирәк. Шуның өстенә Казанның үзендә дә хәлләр мактанырлык булмый. Шәһәр партия оешмасында татар һәм рус большевиклары арасында мөнәсәбәт бермә-бер катлаулана төшкән. Атта да бар, тәртәдә дә, дигәндәй, гаеп кемдә, ә дөрселек кай тарафта икәнлекне һич аңларлык түгел.

Өстәвенә Мөселман эшләре комиссариатының үз эчендә дә хәлләр шактый киеренке. Мирсәет «эзсез югалгач» та аның урынына Казан губернасының Мөселман эшләре комиссары итеп билгеләнгән Сәхипгәрәй Сәетгалиев, мин-минлеге белән мавыгып китеп, байтак кына кадрларны биздергән, янсә үзенә каршы куйган булып чыкты.

Беренче күрешкәндә үк Мирсәетнең дә авырткан җиренә кагылды Сәетгалиев. Югыйсә, моңа кадәр хөрмәт белән карый иде кебек аңа, дустанә мөнәсәбәт урнашкан кебек иде араларында.

— Оялмыйча, ни башың белән монда кайтып кердең,— булды Сәхипгәрәйнең авыз ачып әйткән беренче сүзе.

Аның хәлендә мондый сорауларга җавап бирү җиңел түгел иде. «Башланды...», дип уйлап куйды күңеленнән. Нәкъ менә шундый төртелүләр, читләтеп-урап үзен рәнҗетергә, түбәнсетергә омтылулар сагайта да иде бит инде аны. Кемнән-кемнән, әмма Сәхипгәрәйдән көтмәгән иде ул үзенә мондый мөнәсәбәтне.

Казандагы ыгы-зыгыларның асылы ачыклангач, үз колагы ишеткәннәргә ышанмыйча йөрде ул бераз: Болак арты республикасы җиңелгәч тә, салым рәвешендә татар байларының байтак кына мөлкәте җыеп алынган булган. Хәер, байлар гына таланган булдымы икән?!. Моны башкарып чыгучы, төгәлрәк итеп әйтсәк, Татар бистәләрен талауны оештыручы Сәхипгәрәй Сәетгалиев үзе булган. Алтын-көмеш һәм ата-бабадан килгән кыйммәтле асылташларны өйборынча җыеп йөргән булып чыгалар.

Анысы бер хәл. Җыйган байлыкны бүлешкәндә, иң элек иптәш Шейнкман белән пычакка-пычак килә Сәетгалиев. Һәм шул нигездә үзара аралашмас, сәлам бирешмәс дәрәҗәгә барып җиткәннәр. Байлык булмаганда гына әйбәт, булса — бөтен җәнҗал шуңардан дип, юкка гына әйтмәгән борынгылар.

Кемгә күпме өлеш чыккандыр, әйтеп булмый. Әмма алтын белән илле мең тәңкәлек хәзинә Мөселман эшләре комиссариаты әгъзалары арасында бүленгән. Һәммәсе дә алмаган һәм алырга да теләмәгәндер, бәлки. Мисал өчен, Садыйк Әхмәтовның әлеге ямьсез күренешкә протест йөзеннән комиссариатны ташлап чыгып киткәнлеге мәгълүм.

Мулланур Вахитов һәм Мирсәет Солтангалиевләр кайткан хөрмәткә Мөселман эшләре комиссариатында җитди киңәшмә була. Агымдагы мәсьәләләр турында фикер алышканнан соң, әлеге дә баягы шул

«хәзинә бүлү» мәсьәләсе калкып чыга тагы. Һәм бер төркем иптәшләр Сәетгалиевне комсызлыкта гаепләп чыгалар, аны алыштыру, Солтангалиевне үзенең элекке эшенә кайтару кирәклеген күтәрәләр.

Мирсәет теш-тырнагы белән каршы чыга. Сәхипгәрәйне үпкәләтәсе килми аның, болай да, әнә, күрмәс борын ук күркә урынына кабара, кызарына.

— Юкса, без комиссариатта эшләүдән баш тартабыз. Сәетгалиев иптәш берьялгызы торып калачак,— дип куялар мәсьәләне.

Мулланур Вахитов та комиссариатның эшен начар, ә инде югарыда искә алынган «хәзинә бүлү»не большевиклар өчен оят күренеш, дип бәяли. Нәтиҗәдә, Солтангалиевне яңадан Казан губернасының Мөселман эшләре халык комиссары итеп сайлап куялар. Аңа каршы тавыш бирүче бер Сәхипгәрәй Сәетгалиев кенә була. Һәм шул вакыйгадан соң, бу эшне болай гына калдырмаячагын искәртеп, Мирсәетне рәнҗетеп-әрләп, ул чыгып китә. Шул китүдән байтак кына аралар Сәетгалиевнең тавышытыны ишетелми тора, гүя эзсез-нисез югала... Аны Уфага киткән дип тә сөйлиләр. Әмма соңыннан гына ачыклана, Казанда иң киеренке вакыйгалар барган ул җәйне Сәхипгәрәй сөяркәсе белән үз фатирында бикләнеп яткан булып чыга.

Нәкъ шул көннәрдә шәһәр читендәге урман-күлләр белән хозурланып ял итеп йөргән Шейнкман һәм Ольсеницкий иптәшләргә коралды юлбасарлар һөҗүм итә. Алар диңгезчеләр киемендә булып, кемнәргә юлыкканнарын да ачык белгәннәр булса кирәк.

— Болак аръягыннан талап җыелган алтынны кая куйдыгыз? — дип бәйләнәләр. Алтын таптыралар...

— Белмибез... Юк... Ул алтын Мөселман эшләре комиссариатында ич,— дип котылмак булалар.

— Беләбез,— дип, бугазларыннан алалар.— Җыелган байлыкның җитмеш проценты сездә.

Кисәтү йөзеннән Ольсеницкийны шундук атып үтерәләр. Ә Шейнкманны исә, үзләре белән бергә-бергә хозурланып йөргән яшь һәм үтә дә чибәр хатыны коткарып кала... Әмма ничек вә ни рәвешле? Белүче юк, ул кадәресе аларның гаилә сере булып кына кала. Чибәр ханымның түшендә һәм кулларындагы байлык, зиннәтле ташлар гына җиттеме икән?!.

Хәер, юлбасарларны күрүче — ирле-хатынлы Шейнкманнар гына. Ольсеницкий үтерелгән. Кем тарафыннан?.. Мондый сорауның куелуында шулай ук логика булса кирәк. Аларның бергә-бергә хәзинә яшерергә барган булулары да ихтимал бит. Губерна комитетына алынган алтынның эзсез югалуын истән чыгармыйк...

* * *

Самара өчен барган сугышлар Кызыл Армиянең җиңелүе белән тәмамлана. Шәһәрне ак чехлардан саклау өчен җибәрелгән Валериан Куйбышев та әллә ни майтара алмый, чигенергә мәҗбүр була.

Самарадагы вакыйгалар турыдан-туры Казанга да тәэсир итми калмый. Ак чехлар һәм акгвардиячеләрнең кай юнәлештә хәрәкәт итүләрен ачык белеп торган Казан гарнизонында тәртипсезлекләр башлана. Җиде меңгә якын кызылармияче шәһәр большевиклары җитәкчелеген — Шейнкман, Милх, Грасис һәм башка иптәшләрне урыннарыннан алырга дигән таләп куя. Иртәнге таңга шул таләп үтәлми икән, барысының да астын-өскә әйләндерәчәкләр.

Ашыгыч рәвештә гадәттән тыш Хәрби-революцион Совет төзелә. Өч кеше: Шейнкман, Солтангалиев һәм Грасис.

Гадәттәгечә, Мирсәеткә төшә таякның авыр башы. Шейнкман һәм Грасис аңардан Мөселман социалистлар полкы белән сөйләшеп каравын

үтеноләр. Баш кадерле ул, әнә ничек! Әгәр дә алар бунт күтәрүчеләргә кушылмаса, каршы чыкса — халне тәзәтү, коткару мөмкинлеге була әле. Чөнки мадъярлар һәм немец, латыш хәрби гаскәрләреннән торган «Интернациональ батальон» Советларга каршы чыгарга җыенмый.

Мирсәет шул сәгатьтә үк Мөселман эшләре комиссариатын җыеп ала һәм хәлне аңлата.

— Шул инде, татар коммунистларын артларына ут капкач кына искә төшерәләр... Башка чакта ни эшләргә, ни яшәргә ирек бирмиләр,— дип канәгатьсезлек белдереп алучылар табыла.

Әмма Мирсәетнең тәкъдиме кабул ителә, мөселман полкын кулдан ычкындырырга ярамый, дигән нәтиҗәгә киләләр.

Башкалар татар полкы сугышчылары белән күреп сөйләшергә юнәлә. Полк командирлары янына Солтангалиев белән Йомаголов килә. Гаҗәпләнүләренә каршы, хәрби гарнизонда урнашкан баш күтәрүче кызылармиячеләрнең офицерлары алардан өлгеррәк булып чыккан һәм сөйләшүләрне башлап та җибәргән булалар инде. Өстәлдә — шәраб. Шактый ук төшереп тә өлгергәннәр...

Татар большевикларының ни йомыш белән килүләрен авызлары ачылганчы ук чамалап алган гарнизонлылар коб ;аларын капшарга керешә. Корал белән янарга җыеналар.

— Ашыкмагыз, әфәнделәр,— дип кисәтә Мирсәет Солтангалиев.— Урамда безнең кешеләр. Сез чолганган, бәркая да качып котыла алмаячаксыз.

Бернинди чолганыш та булмый, әлбәттә. Әмма тапкырлык үзенекен итә. Шунда Мирсәетне узган елгы вакыйгалардан ук танып белгән бер офицер, татар егете, күрше бүлмәләрнең берсендә полк комитеты утырышы барганлыкны әйтә.

Солтангалиев шунда ашыга. Шәһәрдәге хәлләргә үз мөнәсәбәтен белдерә.

— Син нәрсә, безнең башка тай типмәгән,— дип җавап кайтаралар полк комитетында.— Баш күтәрүчеләрнең саны җиде мең чамасы. Ә без күпме? Безнең җиде йөз — сигез йөз сугышчыбыз бар күп булса.

— Сез Совет хөкүмәтен, большевикларны якларга тиешле,— ди Мирсәет, икеләнергә урын калдырмыйча.

— Ни өчен?..

— Шуның өчен, чөнки Совет хөкүмәте сезгә — татарларга һәм башкортларга республика игълан итте. Патшаның бу хакта кайгыртканы булдымы, кайсыларыгыз белә?..

Бу сүзләргә каршы төшеп булмый, әлбәттә. Әмма, ни өчен соң, кая карама Советларга каршы баш күтәрәләр... Үзләре оештырган кызылармиячеләр булып, алар буйсынырга теләми әнә Казан губерна комитетына... Уйланырга, икеләнергә урын бар, инкарь итеп булмый.

Мөселман социалистлары полкы командиры Н. Алимов икеләнүдә. Өзеп кенә әйтү җиңел булмый, чөнки ашыгып әйтелгән бер сүз бөтен полк язмышын хәл итүе мөмкин.

— Җиде йөз сугышчы җиде меңлек армиягә каршы тора алмый, ничек шуны аңламыйсыз,— ди ул, эче пошып.

Мирсәет үзенекен итә. Һәммәсен сискәндереп, каршысында торган өстәлгә китереп суга ул кинәт. Сугуы шундый булгандырмы, өстәлеме — аның почмагы яман сыкрап кителеп төшә.

— Аңламыйм... Һәм аңларга да теләмим! Сез баш күтәрүчеләргә иярмәсәгез, алар икеләнеп калачаклар.

— Бездә пехота гына, аларда һәммәсе бар,— пехотасы да, кавалерия дә, артиллерия дә... Шуның өстенә чехлар Сембергә килеп җиткән. Без бөтен татар халкын ут эчендә калдырачакбыз,— ди полк командиры Алимов.

— Татарга азатлыкны ак чехлар китерер дип уйлыйсыңмы? — дип каршы төшә Мирсәет.— Без үз азатлыгыбызны, республиканы якларга тиешле.

— Уйламыйм... Әмма алар безнең һәммәбезне юкка чыгарачак.

— Иптәш Алимов,— дип янә тавышын күтәрә Мирсәет.— Ул кадәр куркак булгач, Кызыл армиягә язылырга кирәк түгел иде! Йә, хәзер үк мин әйткәнчә эшлисең, йә полксыз гына түгел, башсыз да каласың,— дип, кесәсен капшарга керешә ул.

Өстәл янында тезелешеп утырган офицерлар сискәнеп киттеләр һәм берничәсе, үз командирларына ярдәмгә әзер икәнлекләрен белгертеп, аягүрә торып бастылар.

— Янамагыз миңа, иптәш Солтангалиев,— диде Алимов, салкын канлылыгын югалтмыйча.— Сездә булган корал миндә дә бар.

— Янамыйм. Кисәтәм генә... Мәнә-менә ярдәмгә Мәскәүдән зур көчләр килеп төшәчәк... Иртәме-соңмы, барыбер бирелергә туры килмәгәе дип әйтүем.

— Төшәчәк белән киләчәккә ышанып җиде меңлек гаскәргә каршы чыгыйкмы? Бу — башсызлык!

— Каршы чыгу соралмый, бунтка кушылмагыз. Интернациональ батальон кушылмый бит әнә. Тагы шунысы да мәгълүм булсын, Казанга бүген үк янә бер мөселман батальоны килеп чыкты. Аның башында төрек егете Мостафа Сөбхи тора. Төрекләр, әфганлылар һәм фарсылар Совет хөкүмәтен яклаганда сез кул кушырып утырырсызмы?!. Куркаклар сез, менә нәрсә!

Офицерлар телсез-өнсез калды, командирларына текәлгән иде карашлары. Ни генә әйтмә, куркак дигән сүзне күтәрү җиңел түгел ул ир-ат халкына. Ә хәрбиләр өчен аеруча...

— Безгә ни эшләргә? — диде Алимов, ниһаять, ризалыгын белдереп.

— Үзәк мөселман хәрби коллегиясенә тугрылыклы булуыгызны бөтен гарнизонга игълан итәсез. Башкаларны да Совет хөкүмәтен яклап көрәшергә чакырасыз.

Мирсәет белән Алимов шунда ук янәшә утырып, Мөселман полкы исеменнән гарнизон кызылармиячеләренә мөрәҗәгать яздылар. Иртәгесен таң белән мөрәҗәгать кызылармиячеләргә җиткерелә. Мөселман полкыннан соң ук Интернациональ батальон һәм Казанга яңа килеп төшкән Мөселманнар батальоны вәкилләре дә үзләренең Совет хөкүмәтен яклап көрәшәчәкләре турында игълан итәләр. Нәтиҗәдә, әнә шул рәвешле, Казан гарнизонында күтәрелгән бунт кан коюларсыз, югалтусыз гына бастырыла, көйгә салына.

Августның икенче көнендә исә, Үзәк Мөселман хәрби коллегиясе, үзенең рәисе Мулланур Вахитов һәм барлык җаваплы хезмәткәрләре белән бергә, Мәскәүдән Казанга күчеп килә. Ленинның: «Хәзер бөтен революция язмышы бер картага салынган: Казан-Урал-Самара фронтында чехословакларны җиңүгә. Бөтенесе дә шуңарга бәйләнгән»,— дигән сүзләренә җавап йөзеннән эшләнә бу.

Самара инде җиңелгән. Сембер үтелгән. Казан һәр тарафтан камалышта. Идел буйлап менгән дошман пароходлары көн-төн шәһәрне тупка тота. Ә Мәскәүдән вәгъдә ителгән өстәмә көчләр әле күренми. Кайбер мәгълүматларга караганда, алар Казаннан кырык чакрым ераклыктагы Зөя (Свияжск) тимер юл тукталышына килеп җитүен җиткәннәр. Әмма ни өчендер Казанга ашыкмыйлар.

Республиканың Хәрби-революцион Советы рәисе иптәш Троцкий да үзенең бронепоездын Зөядә туктаткан, дигән хәбәр йөри.

Камалышта калган Казанны шундый шартларда көч һәм корал җәһәтеннән күп мәртәбәләр өстен торган акчехлар һәм акгвардиячеләрдән саклап булмый, әлбәттә. Геройларча сугышкан Мөселман

хәрби частьлары һәм кызылармиячеләр Арча юнәлешендә вакытлыча чигенергә мәҗбүр булалар.

Шәһәр тоташ ут эчендә. Иң соңгы чиратта гына Казанны калдыручы 1 нче татар-башкорт батальоны белән Мирсәет Солтангалиев тә Арчага чигенергә мәҗбүр була. Муллануp Вахитовның чолганышта калып, әсирлеккә эләгүе һәм 19 нчы август көнне Казан Кремлендә вәхшиләрчә атып үтерелүе хакында ул белми әлегә.

Бер ай чамасы Арчада яшәргә насыйп була аңа. Әмма кул кушырып утырмыйлар. Казан арты авылларыннан, Кукмара, Мамадыш, Саба якларыннан күпмеңләгән егетләрне, ир-атларны корал тотып кызылармиячеләр сафына басарга, Казанны азат итү өчен һөҗүмгә күтәрелергә үгетлиләр...

Сентябрьнең унысында Казан азат ителә. Шул кыска гына вакыт эчендә Кызыл армиягә тупланган авыл егетләре аеруча батырлык үрнәкләре күрсәтеп сугышалар...

Җиңү хөрмәтенә Дворяннар җыены бинасы каршындагы зур мәйданда митинг уздырыла. Шунда беренче мәртәбә Лев Троцкий белән күрешеп таныша Мирсәет. Хәрби-революцион Совет рәисе Троцкий чыгыш ясый иң элек. Икенче булып Солтангалиевкә бирелә сүз.

Чыгышын тәмамлагач та, сулыш алыйм дип, бер читкәрәк китсә, ни күрсен: янәшәсенә Троцкий килеп баскан.

— Әйбәт оештыручы гына түгел, оста оратор да икәнсең, иптәш Солтангалиев,— ди ул аңарга, кулын сузып.

Солтангалиевнең исә югалып кала торган гадәте юк.

— Сездән калышырга түгел иде исәп, иптәш Троцкий,— дип елмая.

Кул кысып исәнләштеләр. Троцкий аңа үзен байтактан ишетеп белүе, урындагы иптәшләрнең аның хакында әйбәт фикердә булулары хакында әйтә. Һәм аңардан, һәлак булган Вахитов урынын, Үзәк Мөселман хәрби коллегиясен үз кулына алуын үтенә.

— Сездән башка кеше күрмим, иптәш Солтангалиев,— ди Лев Троцкий.— Мәскәүгә кайткач та мин бу хакта Ленин белән сөйләшермен. Шулай иткәндә Сталинның да килешми чарасы булмас.

Мирсәетнең баш тартырга омтылып каравы әһәмиятсез иде инде. Ул хакта тыңларга да теләмәде Троцкий.

— Үзәк Мөселман хәрби коллегиясе рәисе — Солтангалиев иптәш, без базарда түгел,— дип, кырт кисте үзен.— Җитәкчелек итүне кулыгызга алыгыз. Вакытлы мандат бүген үк үзегезгә тапшырылыр.

Шуның белән сүз бетте дигәндәй, хәрбиләрчә, кырт борылып, төз гәүдәсен туры тотып, кире китеп тә барды Троцкий.

* * *

Күп ара узмады. Көннәрнең берендә элемтәче кыз Мирсәеткә ашыгыч хәбәр китерде:

*«Казан. Губерна комиссариаты. Солтангалиевкә. Ашыгыч рәвештә Мәскәү белән элемтәгә керегез.*

**Сталин».**

Аның өчен көтелмәгән хәбәр иде бу. Солтангалиевнең Муллануp Вахитов урынына Мәскәүгә китәргә тиешлеген күпләр белә. Төгәл көне, сәгате генә мәгълүм түгел. Киеренке бер көтү белән яшәгән көннәре иде. Чөнки җаны ашкынып торса да, аягы тартмый ул тарафка, гомеренең иң авыр һәм катлаулы сәгатьләре шул кала белән бәйләнгән. Анда — аның иң кадерле кешесе, бердәнбер сабые Рәсидә яши. Һәм Раузасы. Раузасы... Кайчандыр һәр сулышын, һәр адымын аның хакында уйлап яши иде. Ә хәзер?.. Мәңгелек боз сыман нәфрәткә әверелгән

мәхәббәте инде. Бер шәһәрдә булып, бер үк юлларда йөрүдән курка инде ул аның белән хәзер.

Үз уйларына бирелеп торганда, колү авазы сискәндерде. Бакса, телеграф тасмасы алып килгән кыз китмәгән, шул гомер аның каршысында булган.

— Мирсәет абый,— дип, чаяланып елмая иде кыз.— Мин бит сезгә әле хат та китердем тагы. Ә сез күтәрелеп тә карамыйсыз. Кызларга күз салмас булдыгыз соңгы араларда...

— Кая, китер,— дип, кулын сузды ул.

Ә кызның исәбе чаялану, шаяруда икән.

— Биемичә бирмим монысын. Кызлар хаты...

Хатны баш очында күтәреп сикергәләп торган кызның кулыннан җәт кенә эләктереп өлгерде Мирсәет. Уйный-шаяра торган чагы түгел. Нишләсен, үпкәләгән атлы иреннәрен турсайтып китеп барырга мәҗбүр булды кыз.

Зәңгәр тышлы конвертны кулына алгач та, йөрәге «жуылдап» куйды Мирсәетнең. Куллары калтыранырга кереште. Хатның кемнән килүе күрсәтелмәгән булса да, язуыннан, беренче хәрефеннән үк танып алды — Раузадан.

Барып, ишекне эчке яктан бикләп килде иң элек. Ипле генә эш өстәле артына кереп утырды, әйләндереп-әйләндереп карады ул зәңгәр конвертны. Гүя, ниндидер серләр иңдерелгән иде анда. Ниһаять, ачарга җөрьәт итте. Ә тыны кысыла, күкрәк тутырып сулау мөмкин түгел...

Раузадан хат алу һәм ул хатларны кат-кат уку зур ләззәт китерә торган иде аңарга. Озын булыр иде аның хатлары, ягымлы һәм җылы булыр иде. Һәр сүз генә түгел, һәр тыныш билгесеннән сөю кайнарлыгы, сагынуы бөркелеп торыр иде... Кайчан да булса, аңардан, шул рәвешле, дәфтәр битенең яртысына сыйган кыска хәбәр алырмын дип, кем уйлаган. Хат озын түгел, җөмләләр кыска. Сүзләр санаулы гына. Ә язуы шул ук, элеккечә — ачык зәңгәр кара белән энҗе бөртекләреннән чиккән сыман пөхтә юллар тезелеп киткән:

*«Исәнме, Мирсәет?!.*

*Хат көтмәгәнсеңдер, әлбәттә. Әмма язмый булдыра алмыйм. Сине югалтуны икәнлекне хәзер генә белдем. Авыр миңа, бик тә авыр... Үз Бәхетемнең кадерен белми очынганмын, сикергәнмен икән — терсәкне тешләү мөмкин түгел инде. Бер кискән икмәк кире ябышмый. Тәнем хыянәт иткәндә дә җаным синеке, җаным синең белән булган. Синең дә ничек яратканлыгыңны белә идем...*

*Гафу сорамыйм. Кичерә алмасыңны яхшы беләм. Сагынам. Юксынам. Әмма күзеңә күренергә ярамаганлыкны да беләм. Барын да уйладым. Мин китәм. Кайда икәнлекне үзем дә белмим әлегә, әмма бик еракка китәм. Һәм һичкайчан үзеңне борчымаска, юлыңа аркылы төшмәскә, күзләреңә чалынмаска вәгъдә бирәм...*

*Рәсидә минем белән булыр. Аның өчен борчылма, кыз балага әни кирәк... Үз әнием бу кайгыны күтәрә алмады, аны җирләдем...*

*Хуш, бәгырем!.. Хуш, минем бердәнберем!..*

*1918 ел, августның егерменче көне. Рауза».*

Хатның Мирсәеткә нинди тәэсир ясаганлыгын аның хәлендә булып караган ир-ат кына аңлый алыр... Рауза белән танышкан сәгатьтән алып, аның белән бергә үткән көннәрен, айларын, елларын хәтердән кичерде ул тагы бер кабат. Аның бәхетсез балачагын, үсмер елларын искә төшереп кызганды... Газиз кызы Рәсидәсе турында уйланып өзгәләнде ата бәгыре... Барысын уйлады ул, һәммәсен энә күзеннән уздырды... Төш вакытлары җиткәнче ишек ачмады берәүгә дә. Өстәлгә йөз белән капланды да, онытылды... Бар бәхете һәм бөтен бәхетсезлеге дә үзе белән иде чөнки: йолдыз булып җемелдәшкән күзләрендә, бугазга килеп тыгылган авыр төердә...

Кызы Рәсидә һәм Рауза турындагы уйлар башыннан чыкмады аның. Әмма эзләргә дә омтылып карар арасы булмады...

* * *

Мәскәү елгасының аргы ягында, Зур таш күперне чыккач та сул якта Кремльгә каршы салынган өр-яңа йорттан фатир бирделәр Мирсәеткә. Оештыру һәм зур дәүләт эшләренә кереп чумды ул башы-аягы белән. Бер үзенә әллә ничә вазифа, тавык та чүпләп бетермәслек мәшәкатьләр. Мөселман эшләре халык комиссары буларак, ул турыдан-туры Сталинга буйсынса, Үзәк мөселман хәрби коллегиясе рәисе буларак Троцкийның урынбасары хисаплана. Шулар өстенә Көнчыгыш коммунист оешмаларының Үзәк Бюросы әгъзасы һәм башка күп кенә җаваплы эшләр салынды аның җилкәсенә. Аңарга бу вакытта нибарысы егерме алты яшь булуны, гаиләсез-хатынсыз икәнлеген дә искә алсак, Мирсәет Солтангалиевнең ниндирәк шартларда яшәвен һәм эшләвен күз алдына китерү кыен булмас.

Көн саен дип әйтерлек, ә кайчак көнгә берничә мәртәбәләр Сталин белән очрашып, озак-озак әңгәмәләр кылып, илдәге һәм фронттагы хәлләр турында фикерләшеп, бәхәсләшеп утырырга туры килә аңа. Бу сөйләшүләр Мирсәеткә ошый, ул канәгать була алардан. Сталинның үзе белән эчкерсез һәм ачык булуы хәйран калдыра аны. Революция һәм ил язмышы турында гына түгел, көндәлек шәхси тормыш, гыйшык һәм хатын-кыз мәсьәләләрендә дә ачылып китеп сөйләшкән чаклары була.

— Сиңа өйләнергә кирәк хәзер,— дип киңәш итә аңарга Сталин. Аталарча кайгыртып әйтә ул моны.— Юкса, үз-үзеңне кая куярга, кая барып бәрелергә белмисең...

— Шулаен — шулай да бит. Әмма ул турыда уйларга куркам. Кемгә эләкте шуңарга өйләнеп булмый.

— Мәскәү татар белән тулган. Кызлары берсеннән-берсе чибәр, ике уйлап торма,— дип киңәш итә Халык комиссары.

— Бер авызың пешсә — өреп кабасың, дигән сүз бар бездә. Кемгә эләкте, шуңа өйләнеп булмый шул, иптәш Сталин.

— Ә мин сиңа Халык комиссариаты һәм Үзәк Комитет исеменнән киңәш бирәм: Сузмаска... Өйләнергә! — дип елмая үз итеп, Солтангалиевнең аркасыннан кагып куя Сталин.— Ә мине кунакка чакырырсың, татар туенда булганым юк минем...

Шул очрашуларында ул үзенең тимер шкафыннан Мирсәеткә ун алтын сәгать бүләк итә: «Дусларыңа, якыннарыңа бүләк итәрсең», ди. Октябрь революциясенең беренче еллыгына дип, махсус заказ белән эшләтелгән сәгатьләр була бу.

Сталин, әнә, юмарт та була белә икән!.. Әмма язмыш шаяруымы, әллә башка бер-бер хикмәт белән, Мирсәеттән шул алтын сәгатьләрне алган Көнчыгыш хезмәткәрләре һәммәсе якындагы унбиш-егерме ел эчендә бер үк язмышка дучар ителә: кулга алыналар һәм юкка чыгарылалар. Гүя, исемле сәгатьләрне кире җыеп алалар.

Сталин холкындагы уңай яклар белән бергә, тискәресен дә әле шул көннәрдә үк үз җилкәсендә татып карарга туры килә Мирсәеткә.

Көннәрнең берендә, икәүдән-икәү генә социалистик революциянең Көнчыгышка йогынтысы һәм шул юнәлештәге файдаланылмаган мөмкинлекләр хакында җитди фикерләшеп утырган сәгатьләр иде. Яннарына, ниндидер йомыш белән, Троцкий һәм Валериан Куйбышевлар килеп керә.

Сталин урын тәкъдим итә үзләренә. Әмма керүчеләрнең йомышларын тыңлаганга кадәр үк, гел кирәкмәгән сүз кузгата шунда:

— Ә-ә-ә, теге беренче туп шартлаган авазны ишеткәч тә, Самараны ак чехларга калдырып качкан Куйбышев шушы мыни инде?! — диде ул, керүчене шул көнгәчә күрмәгән-белмәгән атлы булып.

Троцкий нәрсә? Башын артка ташлап, киерелә төшеп көлде бер рәхәтләнеп.

— Шул, үзе инде,— диде, кет-кет көлүеннән туктый алмый.

Башы белән өстәлгә кадалып утыручы, колак яфраклары чөгендердәй кызарап чыккан Куйбышевка күз төшереп алды Мирсәет. Кызганып куйды ул аны шул мәлдә.

— Ничек дип сөйләдең әле, Лев Давыдович,— дип, Троцкийга мөрәҗәгать итте Сталин.— Беренче пароходка ук утырган да, качкан дип әйттеңме?!.

Әнә ничек! Сталин кешене-кешегә ни рәвешле каршы куя белә икән... Айнып китте Троцкий да, көлмәс булды. Урындыгын өстәлгә тарта төшебрәк утырды. Ә Куйбышев, ул арада, нәфрәтләнеп, Хәрби комиссарга карап куйды.

— Ул бит әйләнеп кайтты, иптәш Сталин,— дип, инде Куйбышевны якларга итенде Троцкий. Башкача чарасы юк.

— Әйләнеп кайтты, дидең бит әле... Әйе, әйе: әйләнеп кайткан, дидең. Ләкин, ул юлы да, ничек дидең әле, кызылармиячеләрен ташлап качканмы?.. Мәнә сиңа, ә?!. Аны арканлап куярга кирәк булгандыр.

Каршы сүз әйтә алмады Троцкий. Әллә әйтергә теләмәдеме?..

— Әнә, иптәш Солтангалиев турында алай сөйләп булмый бит,— дип, көтмәгәндә, икенче тарафка ташланды, кыскасы, бер атуда ике куянга тидерергә булды Сталин,— Казаннан иң соңгы булып чыккан диләр аның хакында. Һәм беренче булып кергән... Шулаймы, Лев Давыдович?

— Дөрес, хак сөйлисез,— дип, хупларга, җөпләп куярга мәҗбүр иде Троцкий. Мирсәет турында начар сөйли алмый ул.

Ниһаять, Куйбышевның үзенә мөрәҗәгать итте Сталин:

— Кара... Башыңны күтәреп кара, иптәш Куйбышев. Күрмәсәң — күр, кызыл комиссар әнә шундый була ул! Хәтерләп кал, Солтангали-ев!

Ни өчен кирәк булды болар?.. Әлегедәй уен бигүк аңлашылып җитми иде әле Мирсәет өчен... Сталин ни өчен бу хакта менә хәзер, Троцкий белән Солтангалиев янында сөйләшергә кирәк тапкан?.. Югыйсә, Куйбышевны ялгызын гына чакырып, күзгә-күз сөйләшә, оялта һәм ачулана да алган булыр иде бит ул. Әмма алай эшләми. Уңайлы вакыт көтеп йөргән. Һәм, ниһаять, менә ул вакыт! Троцкийны кеше артында яман сүз сөйләп йөрүче итеп калдырды ул. Әлегедәй каршы куюлардан соң, телиме-юкмы, Мирсәеткә дә үз итеп, якын итеп карый алмаячак инде Куйбышев. Кеше күңеленең, ир-ат холкының әнә нинди нечкәлекләрен белеп эш йөртә, оста файдалана Сталин.

* * *

1918 елның ахырлары иде булса кирәк. Һәрхәлдә, җылы көннәр инде күптән узган, иртәдән кичкә кадәр юеш кар яуган иде ул көнне. Соң гына, инде кайтырга җыенып йөргәндә, телефон шалтырады Мирсәетнең эш бүлмәсендә: Сталин... Үзенә чакыра...

Юеш кар сыланган тәрәзәгә гамьсез генә карап нидер уйлап, уйга бирелеп басып тора иде Милләтләр эше халык комиссары. Мирсәетнең кергәнлеген ишетсә дә, борылып карарга, аның сәламенә җавап кайтарырга ашыкмады ул.

— Иптәш Солтангалиев,— дип дәште ул көттереп кенә.— Син төрекчә аңлаша беләсең булса кирәк.

Нигә юрарга белмәде Мирсәет аның бу соравын. Чөнки Төркия ясә бер-бер Көнчыгыш иле хакында сүз чыгамы, Сталин кулын гына селти, ул хакта сөйләшәсе дә килми торган иде. Үзе башлап сүз кузгатуы гаҗәп тоелды.

— Беләм, иптәш Сталин. Аңлаша да, сөйләшә дә беләм. Төрекчә белмәгән татар юк.

— Бер дә харап инде сез...

— Нишлисең, телебез һәм срак тарихыбыз уртак тамырлардан килә.

— Менә нәрсә...— дип суза төште Сталин.— Бу көннәрдә Мәскәү аша зур төркем төрек хәрби әсирләре уза икән. Германиядән үзләренә кайтып барышлары. Егерме мең әсир...

— Тыңлыйм, иптәш Сталин, егерме мең кеше аз түгел инде ул.

— Ничек уйлыйсың, Төркиядә Совет хакимияте урнаштырып буламы?

Авыр сорау. Әмма Мирсәет өчен ул яңа түгел. Әле Мулланур Вахитов исән чакта ук, бу хакта уйлана-хыяллана иде алар. Ләкин Сталин белән сөйләшкәндә, авызны үлчәп ачканың хәерле — монысын ул яхшы белә.

— Җиңел булмас, иптәш Сталин...

— Җиңел булса, синнән сорамас та идем.

— Һәрхәлдә, Төркиянең хәле бүгенгә мактанырлык түгел. Димәк, солтанатны бәреп төшерү өчен уңайлы шартлар өлгереп килә дип саныйм. Тик менә Совет хакимияте яисә социаль революция турында кистереп кенә әйтә алмыйм...

— Солтанатны бәреп төшерү дидең... Моны син ничек күз алдына китерәсең, иптәш Солтангалиев?..

Мирсәет өчен яңалык түгел бу сорау да. Әмма өздереп кенә җавап бирү җиңел түгел.

— Мин бердәнбер юл күрәм, иптәш Сталин. Бүгенге халыкара сәяси шартларда Төркиядә эчке революция җиңүе өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Һәм ул революцияне ясаучыга Советлар Россиясенә елышудан башка чара юк.

Сталин җаваптан канәгать түгел.

— Син һаман сузасың... Әйтеп бетермисең,— диде үзалдына.

— Төркиядә «яшь төреклек» хәрәкәте үсеп килә. Бу милли азатлык хәрәкәтенең башында төрек буржуазиясе, һәм, белүемчә, Мостафа Кемал әфәнде тора.

Әлегәчә юеш кар сыланган тәрәзәдән күзләрен алмаган иде Сталин. Шул гомер Мирсәеткә арка белән торып сөйләште ул. Ниһаять, кискен хәрәкәт ясап, йөзен борды һәм тимер салкынлыгы бөркелеп торган карашын әңгәмәдәшенә текәде.

— Төркиядәге хәлләрне мин уйлаганнан шәбрәк беләсең икән бит...

Аңламады Мирсәет: бу аның мактап әйтүе булдымы, тискәре бәясеме...

— Менә нәрсә,— диде Сталин, байтак дәшми торганнан соң сүзен дәвам итеп.— Ул әсирләрне тоткарлый төшергә булдык. Бераз хәл алсыннар, Мәскәүне күрсеннәр, дидек... Дәрәҗәле органнар тик ятмый торгандыр. Шулай да... Мөселман комиссариаты да йоклап калмасын иде диюем.

Сөйләшү шуның белән йомгакланды. Хушлашып аерылыштылар.

...Иртәгесен Сокольский циркы бинасында төрек әсирләре белән очрашып танышу өчен махсус митинг үткәрелде. Ике меңгә якын әсир китерелгән иде. Анда яшь Советлар Россиясенең бөтендөнья хезмәт ияләре өчен бердәнбер терәк булып торуы хакында иптәш Ярославский һәм Галимҗан Ибраһимовлар сөйләде. Мирсәетнең дә төрек әсирләре белән тәүге очрашуы шунда булды. Ул, хәбәрдар булганы кадәрле, Төркиядә көтелгән вакыйгалар хакында гоман кылды һәм Советлар Россиясендә яшәүче төрки милләтләрнең бүгенге хәле белән таныштырды.

Атна-ун көн дәвамында, һәр көн диярлек, Мәскәүнең татар эшчеләре клубында да махсус кичәләр, төрек әсирләре белән очрашулар үткәрелеп торды. Сәяси чыгышлар гына түгел, татар-башкорт җырлары да башкарыла иде ул кичәләрдә. Җырлы-биюле уеннар, хәтта үзешчәннәр тарафыннан татарча тамашалар да күрсәтелә. Төрек әсирләреннән бер өлеше мәҗбүр иткәнне көтеп тормыйча, үзләре үк теләп килә торган булды анда. Тора-бара әсирләрнең үз араларында да җыр осталары, шигырь чыгарырга һәвәс затлар барлыгы ачыкланды...

Аерым-аерым төркемнәр җыелып, кызу бәхәсләр кузгала иде еш кына. Төрекләр арасыннан да ул әңгәмәләрдә бик теләп катнашырга, сәяси мәсьәләләр куярга ашкынып торган әсирләр табылды. Андыйлар белән махсус очрашулар үткәрелә иде. Мөселман эшләре халык комиссариаты хезмәткәрләре ул көннәрдә кул кушырып утырмады. Төрек коммунисты Мостафа Сөбхи дә гел үз ватандашлары арасында булды...

Татар эшчеләре клубындагы шул очрашуларның берсеннән соң, Мирсәеткә, ялгыз калган мәлен туры китереп, йөзләрен сакал-мыек баскан, шактый өлкән яшьләрдәге бер аксак солдат мөрәҗәгать итте:

— Мирсәет әфәнде,— диде ул, авыр йөткеренеп.— Сезнең чыгыш ясаудан бик канәгать булдык... Төрек солдатлары сезне үз итеп, яратып искә алалар...

— Рәхмәт,— диде Мирсәет. Үзенә таныш булмаган чит-ят кешедән, өстәвенә чит ил гражданинынннан, шундый сүзләр ишетү кем күңеленә генә сары май булып ятмас икән.

Бераздан, як-ягына карангалап алгач, теге солдат тагы да пышылдый төшеп, төп сүзенә күчте:

— Мирсәет әфәнде, сезнең белән бер карт солдат күрепсөйләшергә тели иде. Кайчан һәм ничек вакыт таба алырсыз икән?..

— Рәхим итсен, килсен хәзер үк. Мин сөйләшергә әзер,— дип җавап кайтарды ул.

— Әфәндем,— дип, күзләренә текәлде аның солдат.— Бер-бер аулак җирдә урын һәм вакыт билгеләсәгез икән. Әйтер сүзе җитди һәм икәүдән-икәү генә сөйләшәсе килә аның...

Уйга калып торды Мирсәет. Әлбәттә, төрек әсирен эш урынына чакырып булмый да инде. Кертмәячәкләр. Фатирга чакырсаң да, әллә ничек...

— Торган өегез кай сокакта, әйтә алмыйсызмы, әфәндем?..

Сокак — урам дигән сүз төрекчәдә. Икеләнә төшеп булса да, үзенең торган урам һәм фатирын әйтми чарасы калмады аның.

— Язмадыгыз, онытырсыз ич?..

— Төрекнең хәтер гүзәл булыр, әфәндем. Чук тәшәккерләр итәмез,— диде ул. һәм ни рәвешле күзгә чалынмый гына каршысына килеп баскан булса, шул рәвешле үк иплә генә үз юлы белән китеп тә барды.

Үзалдына уйлап куйды Мирсәет: «Сукыр күп күрер, аксак күп йөрер, дигәннәре шул була торгандыр инде».

Өйгә кайтуына күп ара узмады. Караватка чалкан ятып Казан, Оренбург һәм Уфа шәһәрләреннән килгән гәҗитләр актаргалавы иде. Кемдер иплә генә аның ишеген шакыды. Барып ачса, ни күрсен, ишек төбендә әлеге дә баягы аксак төрек солдаты басып тора.

— Ни булды?.. Син бит үзем киләм димәгән идең?— дип, килүчене өйгә чакырырга да онытып, ишек катында тераләп калды ул.

— Йә инде, бусагаңнан кире борырга җыенмый торгансыңдыр бит?— дип, саф татар телендә дәште карт солдат.

Килүче артыннан ишекне элеп, түргә уздылар. Төрек әсиренең татарча сөйләшүе бер гаҗәпләндерсә, икенче гаҗәпләндергәне — Мирсәетнең фатирына килеп кергәчтен дә ул аксавын онытты.

— Сез кем буласыз?.. Сезгә миннән ни кирәк?— дип сорамый булдыра алмады Солтангалиев.

Юл капчыгын салып идәнгә куйды серле кеше. Аннан бүреген салды, манма су булган шинелен ишек катындагы элгечкә элтеп элде. һәм буыла-буыла йөткергәннән соң, карашын Мирсәеткә текәде.

— Ачуланма, энем,— диде, ихластан сөйләшәсе килеп.— Башкача булдыра алмадым. Алла да сакланганны гына саклыйм дигән.

Әлеге дә баягы бер үк соравын кабатлады Мирсәет:

— Сез кем буласыз?.. Ничек итеп, сез — татар кешесе, төрек әсирләре арасына килеп эләктегез?..

— Ашыктырма, энем... Мин барын да сөйләрмен хәзер үзеңә. Сөйләшер өчен килүем ләса.

Тагы буыла-буыла йөткерергә кереште ул. Шунда гына, аның хәлен аңлап, Мирсәет барып чәй куеп килде. Җылы оекбаш, өс-киемнәре тәкъдим итте килүчегә...

Чәй эчеп, җанына җылы иңгәч кенә аңлашырга кереште төнге кунак:

— Ишеткәнең бардыр, бәлки, мин Йосыф Акчура булам,— диде ул.

Аздан гына кулындагы чынаягын төшереп җибәрмәде Мирсәет. Менә сиңа очрашу! Ник белмәскә, татар дөньясында, төрки халыклар арасында Йосыф Акчуринны белмәгән кеше, булса да бик сирәк булгандыр ул елларда. Аның һәммә төрки халыкларының бер ана балалары булып, шуларны берләшергә чакырган мәкаләләрен дә укыганы бар. Чын төрек милләтчесе дигән аты киң таралган. Үзе соңгы араларда Төркиядә яши иде булса кирәк... Әмма әлеге йөзен сакал-мыек баскан, өс-башы шапшак солдатның шул зыялы зат булуына ышанасы килми.

— Сорбонна университетын тәмамлаган Акчурамы? — дигән сорау үзеннән-үзе чыкты аның авызыннан.

— Әйе...

— «Казан мөхбире»ндә мөхәррир булган кеше дә сезме?

— Әйе...

Җан кергәндәй булды Мирсәетнең күңеленә. Шик-шөбһәләре юкка чыкты дип әйтерлек. Тик менә, ничәмә-ничә телдә укый-яза белгән шул зыялы зат, ни рәвешле төрек әсирләре арасына килеп эләккән дә һәм ни өчен большевик Солтангалиевнең аңарга кирәге чыккан? Болары аңлашылмый.

Үзен Йосыф Акчура дип тәкъдим иткән төнге кунак берөзлексез йөткеренүеннән тукталган иде инде. Сүзләрне сайлап, кабаланмый гына сөйли үзе:

— Кыска гына вакытка дип кайткан идем. Революция чыгып тоткарланырга мәҗбүр булдым. Әсирләргә килеп кушылдым менә, аларны да җибәрергә ашыкмыйлар. Син ничек уйлыйсың, озак тотарлармы үзләрен?..

— Белмим шул,— диде Мирсәет. Чөнки башкача җавап бирә алмый иде ул әлегә.

— Сүз чыккач әйтим инде,— дип мөрәҗәгать итте Йосыф Акчура.— Өс-башлары юка, торган җирләре юеш вә салкын. Ашау яклары да бик яман, алманнардан кайткан төенчекләре саекты — кайгыртасы иде бит үзләрен?!.

Кара инде, бу хакта гел уйлаганы юк икән бит Мирсәетнең. Үзләре зарланмагач, һәммәсе дә көйле, җайга салынгандыр дип йөрелгән.

— Ярар, мин иртәгә үк бу якларын кайгыртырмын,— диде һәм җәт кенә өстәлдә яткан кесә дәфтәренә каләм алып нидер төртеп куйды.

Хәрби коллегиянең финанс һәм хуҗалык эшләре буенча җаваплы кешеләренә андый әмер чынлап та, иртәгесен үк җиткереләчәк һәм ярдәм йөзеннән хәл кадәрле чаралар да күреләчәк.

— Мин һәммә нотыкларыңны тыңлап бардым,— дип дәвам итте Акчура.— Сөйләгәннәрең кызык тоелды. Игътибарым җәлеп итте. Һәм шундый сорау туды күңелемдә: — Әйт әле, әллә мин большевиклар турында хата фикердә булганмынмы, әллә син үзең большевик түгелме?.. Әнә шул сорауга җавап эзләп килдем синең янга... Ләкин, алдан ук әйтим, бер олы үтенечем бар: Алла хакы өчен, дөресен, турысын әйт?!.

Мирсәет өчен сорау бик гади. Үз исемеңне әйт, дигән сыман гына. Икеләнергә урын калдырмаслык итеп җавап кайтарды ул:

— Мин чынлап та большевик, Акчура әфәнде. Бу форсаттан һич икеләнер урын юк.

Җаваптан бигүк эреп төшәргә ашыкканы күренми иде әле төнге кунакның. Янә бер мәртәбә, тәмен белеп кенә чәй йотып алгачтын, сакалын сыпыргаларга кереште ул.

— Алай дисең дә бит... Ә үзеңдә миллэтпәрварлык та бар күренә. Ишетеп белүемчә, большевиклар өчен бусы ят нәрсә, хәрам нәрсә.

— Милләт өчен яну, үз халкыңның бәхете өчен көрәшү — ул намус эше диеп беләм, Акчура әфәнде. Бу хис минем күңелемә изге анам сөте белән иңгән. Большевик булуым да, иң беренче нәүбәттә, шул олы хис галәмәте. Большевиклар һәм Совет хөкүмәте эшче халкы һәм авыл мужикларының мул тормыш коруы өчен көрәшә...

— Хуш, ярар,— дип, янә итагатьле генә сакал сыпырып куйды Йосыф Акчура.— Очы-очка ялганмый бит, энем. Соң, шулай икән, нигә ул большевикларның бар булышканы милләтчеләр әле? Исламчы да ярамый үзләренә, төрекче дә...

Инде Мирсәет уйга калды, сакалы булса, ул да сакал сыпыргалап алган булыр иде.

— Акчура әфәнде, большевиклар буржуаз милләтчеләрне өнәми...

— Милләт өчен ут йотуның «буржуаз»ы һәм «советча»сы булмый торгандыр ич. Ул намус эше, ана сөте белән иңә торган изге нәрсә дип, үзең үк әйттең түгелме?!.

— Юк-юк, әфәндем,— дип каршы төшәргә ашыкты Мирсәет.— Иң әүвәле, без һәммә милләт эшче-крестьяннарының бер дәрәҗә бәхеткә ирешүе әчен көрәшәбез. Икенчедән, социаль революция сыйныфлар арасындагы матди тигезсезлекне юкка чыгарачак.

Акчура җаваптан бигүк мәмнүн түгел иде булса кирәк.

— Тигезли торгач, һәммәсен дә тигезләп бетермәсәгез ярый да бит.

— Аңламадым, Акчура әфәнде?..

— Татар белән урыс, христиан белән мөселманны аера алмаслык бер нәмәрсә китереп чыгармассызмы дим, ул адәмнәрдән?.. Табигатьнең дә, энә, үзән җире була, калку җире. Сирәк кенә текә таулары да очрап-очрап куя. Бер урында чыршы-нарат үсә, икенчесендә — талтирәк, дигәндәй...

Йосыф Акчура сөйләгәннәргә аяк терәп каршы төшәргә ашыкмады бу юлы Мирсәет. Чөнки вакыт-вакыт үзенең дә шиккә төшкән, уйга бирелгән чаклары була торган иде. Милләтләрнең тигезлеге хакында сөйләргә генә җиңел ул, ә эштә исә күпкә авыррак. Казанда эшләү дәверендә боларны үз җилкәсендә аз кичерергә туры килдеме?!

— Сез сөйләгәннәрдә дә гыйбрәт бар анысы, бәхәсләшмим, Акчура әфәнде. Безнең төрки кавем, сыйныфыйлыктан бигрәк, милли азатлыкка омтылыш белән бәрләшер ул, бәлки. Ырымбурдагы Рәмиевләрне, мәсәлән, сыйнфый дошманым дип саный алмыйм.

— Ә Сембердән чыккан Акчуриннар сыйнфый дошманыңмы?

Күзләре очрашып, елмаеп куйдылар. Җавап шул елмаюда иде.

— Инде Төркиягә таба борыла төшик,— диде үзләшеп, актырып киткән Йосыф Акчура.— Шәхсән үзеңнең Төркиядәге вакыйгаларга мөнәсәбәтең нинди, Мирсәет?

Үзенең бала чактан ук төрек телендә әдәбият укып үскәнлеген һәм төрекчәдән тәрҗемәләре булуын хәбәр итте Мирсәет. Бүгенге көндә дә бөтен Көнчыгыш илләрендә, әсрым алганда, Төркиядә барган үзгәреш һәм милли-азатлык хәрәкәтләренең үсеше белән даими кызыксынуын сөйләде. Һәм уенда, шул милли хәрәкәтләргә таянып, Төркия, Иран, Әфганстан һәм гарәп илләрендә халыкны социаль революциягә күтәрү турында хыял йөрегәнлеген хәбәр итте. Якындагы елларда ук милли-азатлык хәрәкәтенә нигезләнгән бу революцион күтәрелеш Һиндстан һәм Японияга барып җитеп, Африка һәм Латин Америкасы илләрен колачлап алырга тиешле була. Көнчыгышка мөнәсәбәттә битараф булганнары өчен, Ленин, Сталин һәм Троцкий иптәшләр белән үзенең килешмәве, еш кына шул уңайдан бәхәсләшүләре турында да сөйләде. Аның тарафыннан әзерләнеп әле күптән түгел генә Милләтләр эше халык комиссариатында тикшерелгән «Көнчыгыш халыкларын азат итү берлеге» программасын да күрсәтте Йосыф Акчурага.

Йосыф Акчураны болар, әлбәттә, нык кына кызыксындырган булса кирәк. Мирсәет әзерләгән әлеге программаның бер нөсхәсен сорап ала ул һәм Төркиягә кайткач та аның белән милли азатлык хәрәкәте җитәкчеләрен таныштырырга вәгъдә бирә.

— Барчасы да кызык, әлбәттә, боларның,— дип куя Акчура бераздан.— Тик минә ул мәмләкәтләрдә сез теләгәнчә большевиклар хакимияте урнаштыру хыял гына булып калмасмы?

Бераз уйлана-икеләнә төшеп, ихластан җавап бирә Солтангалиев:

— Соң чиктә бит, Акчура әфәнде, һәр илдә дә большевикларның өскә чыгуы үзмаксат түгел. Милли-азатлык хәрәкәте үзе хәл итәр. Халык массалары үзләре хәл итәр. Колониаль изелүдән, Европа эре буржуазиясенең колы булудан азат итәргә кирәк халыкны. Шунысы әһәмиятлерәк! Хикмәт кемнең хакимияткә килүендә түгел!..

— Килешәм... Бусы белән аерата килешәм. Тик минә Төркиядә, сез теләгәнчә, коммунистлар түгел, башка бер сәламәт көчләр җиңеп чыкса, әйтик, моңа Руссиянең мөнәсәбәте ничек булыр дип уйлыйсың?

— Бик ихтимал, Акчура әфәнде. Шәхсән, мин монда зур бәла күрмим. Әмма Төркиядә социаль революция өчен һәм коммунистлар мәсләге өчен дә туфрак бик бәрәкәтле күренә, миңа калса...

— Мөмкиндер... Вә дә ләкин мин үзем вату-җимерү ягында түгелмен. Терәклекнең асылын аңлаган кеше буларак әйтәм. Аннан бит әле, аның башлап йөрүчеләре дә булырга тиешле.

— Бәр андый кеше, бар,— диде Мирсәет, икеләнергә урын калдырмаска омтылып.

Акчура да икеләнеп тормады.

— Кем, Мостафа Сөбхиме?..— дигән төгәл соравы белән чак аяктан екмады ул Мирсәетне.

— Әйе. Каян беләсез?

— Хикмәт каян белүдә түгел, энем Мирсәет. Мостафа Сөбхинең төрек әсирләре янынннан китеп торганы юк аның... Төркиянең үзендә дә бар Мостафалар. Әйтик минә, Мостафа Кәмал әфәндегә мин үзем күп өметләр баглыймын. Бу исемгә игътибарлырак булу ярар иде... Сәясәттә халыкка таянсак, мәдәниятта без баш-аягыбыз белән төрекчедер.

— Беләм, Йосыф әфәнде. Сезнең «Өч тәрәзи сәясәт» дигән китапны әле шәкертлек елларымда ук үзләштергән идем.

Чәй янында таңгача сөйләшеп чыкты алар. Фикер алыштылар, бәхәсләштеләр. Килешкән җирләре булды, килешмәгән... Мирсәет зур дулкынлану белән үзенең Татар-Башкорт республикасын тормышка ашыру юлында башкарган эшләре турында сөйләде. Әдәбият һәм шагыйрьләр турында сүз чыгып, ул бүгенге төрек әдәбияты белән кызыксынды. Акчура исә, Төркиягә исән-аман кайтып җиткәчтен дә аңарга Юныс Әмре шигырьләрен җибәрергә вәгъдә итте. Һәм, әгәр, хат алышу теләгең булса, дип, Мирсәеткә төрекләрнең күренекле әдибе вә фикер иясе Зыя Гүкальпның адресын калдырды. Үзләре дә даими хәбәрләшергә вәгъдә кылыштылар.

Урамнарга яңа көннең яктылыгы иңгәч кенә Йосыф Акчура, җилкәсенә биштәрен салып, аксаклый-аксаклый үз юлы белән китеп барды. Мәскәү елгасы аша салынган борынгы Зур Таш күпер аша чыгып, аргы якта күздән югалганчы тәрәзәдән күзәтеп калды аны Мирсәет.

Күбәләк сыман эре-эре җепшек кар ява иде аның эзләренә...

* * *

Әсәдуллаев йорты әле революциягә кадәр үк Мәскәү мөселманнары, ягъни татарларның мәдәни үзәге була. Бина мәһабәт, иркен, бөтен уңайлыклары бар. Бер сүз белән әйтсәк, чын мәдәният сарае. Янәшәдә

генә татар бистәләре. Урам һәм тыкрык исемнәренә кадәр монда шул хакта сөйли: Зур Татар тыкрыгы, Кече Татар тыкрыгы. Тагын тыкрыклар, тагын-тагын...

Революциядән соң, Әсәдуллаев йортының зур залы Татар эшчеләр клубы дип йөртелә башлый. Мәскәүгә килгән көннәреннән үк, буш вакыты булдымы, шунда тартыла, шунда омтылып яши иде Мирсәет. Чөнки монда чын татар дөньясы, монда таныш-белеш, монда яңа очрашулар, күрешүләр... Әледән-әле чыгышлар ясарга да туры килә иде үзенә.

1918-елның октябрь башлары иде булса кирәк, аны, татар дөньясында күренекле кеше буларак, Мәскәү яшьләре белән очрашуга чакырдылар. Зур зал тулы диярлек. Эшче вәкилләре, анда-санда хәрби киемле кызылармиячеләр, ә күпчелек — студентлар вә сәүдәгәрләр токымы булса кирәк. Ни генә булмасын, алар һәммәсе бер дикъкать һәм кызыксыну белән тыңладылар аны.

Яшьләр каршында чыгыш ясауның үзенә күрә хикмәтле яклары да була. Мөлаем йөзләр, ут булып янган күзләр әле бер, әле икенче тарафта яктырып, күз карашын өтеп-өтеп ала. Сәхнәдә, трибуна артында торып сөйләүченең һәр хәрәкәте игътибар үзәгендә. Әнә, бер-беренә янтая төшеп ике кыз нидер пышылдашып алды. Берсе елмайды, икенчесе сәер генә тартынып уңайсызланган кебек тоелды... Эшче яшьләр белән хәрби киемдәгеләр, аның сөйләгәнен бүлдереп, бернічә мәртәбә аягүрә торып дәррәү кул чаптылар. Читтәрәк, аерым төркем булып утырган аксөяк студентларга исә, соңгыларының кыланышы бигүк охшап җитмәде кебек. Бер-беренә сынаулы гына каранып, ак яка өстеннән әләктергән кара күбәләкләрен төзәткәләп алдылар.

Чү... Мирсәетнең теле көрмәкләнеп куйды кинәт. Фикере чуалды. Колаклары кызышты... Аның каршысында ук дип әйтерлек, икенче рәттә утырган таныш түгел туташ гаепле иде моңа. Зур коңгырт кара күзләр, алсу йөз һәм тулы иреннәр зиһенен чуалтты аның. Апак маңгай һәм шомырт кара чәч, муен аша күкрәккә салынган сыңар толым... Карашлары очрашкач та, кызның озын керфекләре калтыранып куйды, күзләрен яшерде ул. Хәтта бит алмалары кызышуын тойган сыман булды Мирсәет. Үз-үзен кая куярга белми иде кыз. Туташның ике як янәшәсендә утырган егетләр дә тойды булса кирәк шуны.

Чыгышын тәмамлап чыгу өчен шактый ук ихтыяр көче кирәк булды Мирсәеткә. Чөнки башка бер тарафка карап сөйләргә омтылса да, күз алдында әлеге мөлаем вә серле туташның сурәте торды.

Очрашудан соң, шул ук залның аргы башында җырлы-биюле уеннар башланып китте. Мирсәет тә катнашты уенга. Һәм зур түгәрәк ясап җырлап әйләнгән чагында, белмим, ни рәвешле, әллә очраклы, әллә түгел, шул туташ белән янәшә туры килде. Кулга-кул тотынып әйләнделәр, бергә биеделәр. Тик сүз әйтер, танышыр аралары гына булмады.

Ул кичне йокы кермәде аның күзләренә. Аннан соң кичләрендә дә шулай ук... Әлеге туташны очратырга өметләнеп, көн дә Татар эшчеләр клубына атлыга торган булды.

Көннәрнең берендә янә очратты ул аны. Бу юлы да кыз теге вакыттагы кебек ике егет янәшәсендә иде. Әмма күзләре — Мирсәеттә. Аны күрдеме — уңайсызлана, ояла, үз-үзен кая куярга белми башлый. Танышыр, бер-ике авыз сүз алмашыр ара гына табылмый. Ике егет, тагылганнармыни, үкчәсенә басып йөриләр үзенең.

Шулай да тәвәккәлләп карамый чарасы юк иде Мирсәетнең. Бу әле парлап бию, ягъни вальсның татар яшьләре арасына яңа кереп килгән чагы. Кыз биергә, әйләнергә, бөтерелергә ярата. Ә егетләре, итагатьлелектәнме, әллә оялчанлык галәмәте — чакырмыйлар үзен. Бию чамалы гына булса да, ике егет арасында оялчан басып торган кызны чакырырлык кыюлык тапты ул үзендә. Ни гаҗәп, кыз карышмады, егетләре дә каршы төшмәде.

— Сер булмаса, исемегезне әйтер идегез, туташ? — дип сүз катты Мирсәет, бераз дәшми-нитми генә биеп алгач.

— Фатыйма...— диде кыз, җәт кенә карашын яшереп.

— Мин Мирсәет булам...

— Беләм... Мин сезнең турыда һәммәсен дә беләм, Мирсәет абый...

— Кызык икән... Ул «һәммәсе»нәниләр керә инде? — дип, сорамый булдыра алмады Мирсәет.

Баксаң, чынлап та, кыз аның кайда һәм кем булып эшләвен генә түгел, инде бер мәртәбә өйләнеп — аерылган булуын да ишетеп белә икән.

Мирсәетнең ул хакта ишетәсе, сөйләшәсе килмәгән иде, әлбәттә. Нишлисең... Әмма үзен кызыксындырган сорауларга җавап алырга өлгерде.

— Башка кызларга, әнә, бераү дә юк. Ә синең, Фатыйма, бер үзеңә ике егет икән...

— Абыем һәм энем ич алар минем,— диде кыз, җанланып китеп. Абыем Али исемле, ә энем — Мирза. Матур егетләр бит, иеме, Мирсәет абый?

— Сүзем юк, Фатыйма, туганнарың да матур. Ә үзең, үзең... Яңа туган ай кебексең... Йомарланган май кебексең...

Аның ни диясен алдан ук белепме, бүлдерергә ашыкты кыз:

— И-и, абый, алай димәгез. Мин оялам,— диде ул.

Бию көе озак дәвам итми. Ә көтеп алынган тәүге вальс, гадәттә күз ачып-йомганчы тәмамлана торган була. Шуны алдан ук тоеп торган Мирсәет үзенең кызны озатасы килүе хакында да әйтергә өлгерде.

— Белмим шул, Мирсәет абый,— диде кыз, тартына төшеп.— Туганнарым артыннан ук ияреп кайтсак кына инде.

— Мин риза, Фатыйма...

— И-и, Мирсәет абый, юкка куанасыз, без бит монда, янәшәдә генә, Зур татар тыкрыгында яшибез...

Чынлап та, Әсәдуллаев йортыннан ерак түгел генә яши икән Фатыйма. Әмма ике туганы артыннан ияреп озатып кайткан арада ул тагы байтак кына мәгълүматларга иреште: Фатыйманың әтисе Әхмәт Ирзин берничә еллар элек вафат булган. Алар биш бала әниләре белән генә торып калганнар. Абыйсы Алидан соң, ул икенче бала. Тагы ике энесе һәм бер сеңлесе бар икән...

Ирзин фамилиясен ишеткәч тә кызыксынмый булдыра алмады Мирсәет. Сорап куйды:

— Нәрсә, теге данлыклы миллионер Ерзиннарга мөнәсәбәтегез юктыр бит?

— Без Ирзиннар,— дип, иң элек төзәтү кертергә кирәк санады Фатыйма.— Урыслар гына Ерзин диләр... Әйе, Мирсәет абый, мин шул, сез күздә тоткан Ирзиннар кызы булам. Нәрсә, куркытамы әллә, большевик кешегә безнең белән янәшә бару ярамыйммы?

Кыз, аның ни уйлаганын беләсе килеп, Мирсәетнең күзләренә текәлеп торды бермәл. Аңламассың, киеренкелек бар идеме ул караштa, әллә шөбһә яисә куркумы... Әмма, ни генә булмасын, аның гүзәллеге артканнан-арта гына бара, теләсә нинди хәлдә дә тоныкланып калмый.

Мирсәет өчен, чынлап та, көтелмәгән һәм шактый ук четерекле дә булган яңалык иде шул бу. Тире һәм каракул белән сату итеп, бөтен Россия күләмендә исеме мәгълүм булган Ирзиннарны белмәгән кеше юк. Мәскәүнең үзәгендә дип әйтерлек таш мәчет салдырган Садыйк Ирзин, димәк, аның күзе төшкән, аны йокысыз калдырган Фатыйманың бабасы була!..

Кыз үзе дә сизгер, аның шул мәлдә ни уйлап телсез калганлыгын абайлап алды ул.

— Мирсәет абый,— диде Фатыйма.— Ә сез беләсезме икән, Касыйм шәһәреннән Мәскәүгә килгәч тә безнең бабай, иң элек, самавырчы малай булып эшләгән монда. Миллионнарга ул бары үз тырышлыгы белән ирешкән. Анысы бер булса, икенчедән, безнең хәзер Ирзин дигән исемебез генә бар. Сугыш вакытында сәүдә йортыбыз янды, калган малыбызны сез инкыйлаб ясагач та тартып алдылар. Өебезгә кадәр кереп талап чыктылар...

Шуларны сөйләгән чакта кызның күзләренә карап алды Мирсәет. Һәр сүз, һәр тойгы, күңеленең һәммә тибрәнеше дәү, якты һәм аяз күзләрендә көзгедәге сыман чагыла бара иде аның. Кыргый һәм оялчан дип тә әйтерлек түгел үзен, әмма ихлас һәм эчкерсез булуында һич шик юк. Үен нәрсә турында сөйләми иде бит ул, шуңа җан әрнеше ачык сизелеп тора. Ләкин, ата-бабадан калган бөтен матди мирасны югалту да сындырмаган күренә үзләрен.

Ирзиннар — Ирзин булып калган. Горурлык һәм күңел көрлеге, рухи җегәр, үз дәрәҗәләрен белеп яшәү вә сөйләшү — сау-сәламәт! Әле берничә көн элек кенә, залда утырган чакларын хәтерләде аларның Мирсәет. Күзгә якты нур булып бәрелгән Фатыйманы аласыңмы, ир-ат туганнарынмы, алар үзгә бер сабырлык, мәһабәт горурлык беләнме, әллә каян аерылып, үзләренә җәлеп итеп торалар иде.

Янәшәсендә атлап барган кызның хәленә кереп, кызганып куйды үзен Мирсәет. Хәленә керде керүен, әмма кызганыч идеме соң ул?!. Юк, әлбәттә... Дөньяның бар нурын үзенә җыйган, янәшә барганда да, атлап түгел, дулкын дәртс белән йөзеп барган унсигез яшьлек гүзәл кызганыч була димени...

Туганнары әнә ике катлы мәһабәт йорт каршысына барып җиткәч керү юлына борылдылар. Корычтан коеп эшләнгән капка келәсенә үрелгәнгә кадәр үзара нидер киңәшеп алдылар. Ярым борыла төшеп дәшүче энеләре Мирза булды:

— Фатыйма апай,— диде ул, әле утырып җитмәгән яшүсмер тавышы белән. Кычкырмады, әмма ишетелерлек итеп дәште.— Бер биш минут бакчада йөреп торабыз.

Туганнар корыч капка артына, өй каршындагы бакчага кереп югалды. Һәммәсе ачык — Мирсәет белән Фатыймага тагы биш минут ара бирелә, артык түгел.

— Менә, Мирсәет абый, кайтып та җиттек,— диде Фатыйма, туктала төшеп. Һәм икенче каттагы ут алынган ялгыз тәрәзәгә ымлады.— Әнием безне көтә, йокламый.

— Сине көтүчеләр күп,— дип, бакчадагы туганнарына ишарә ясады Мирсәет тә.

Фатыйма, балкып, елмаеп куйды. Елмаю бигрәк килешә икән үзенә.

— Әйе, әнием каршысында минем өчен алар җавап бирә. Минем сакчыларым...

— Ә менә минем көтүчем дә юк, саклаучыларым да,— диде Мирсәет, уенын-чынын бергә кушып. Һәм янәшәләрендә торган ялгыз яшь каенга ымлады.— Менә шушы ялгыз кәкерә каен кебек. Күрәсеңме, әнә, ялгыз сары яфрак эленеп калган.

— Юк, Мирсәет абый,— дип каршы төште кыз.— Сез ялгыз түгел. Сез татар деньясында бик билгеле кеше. Сезне тыңлыйлар, сезгә ияреләр... Сез ышандыра беләсез. Сез сөйләгән чакта үзем дә, карале, дөрес сөйли бит бу абый, дип уйлап куйдым теге көнне...

Мирсәетнең уенда «биш минут» дигән сүз, инде узып бара торган биш минут. Җитди сөйләшүләр өчен ара калмаганлыкны ул яхшы белә. Күңелендә шом, моңсулык. Фатыйманы тагы күрерме ул? Аны ни рәвешле үзенә җәлеп итәргә дигән бердәнбер уй...

— Ә барыбер, Фатыйма, мин үземне, әнә шул каен чыбыгына эләгер-эләкмәс эленеп торган ялгыз сары яфракка охшатам.

Икесе дә шул тарафка карап торганда, кинәт җил чыгып, соңгы яфрак очып китмәсенме...

Рәхәтләнеп, сабыйларча онытылып көлеп җибәрде Фатыйма.

— Әнә, очты... Очты, күздән югалды, Мирсәет абый, сезнең яфрак.— Һәм рәхәтләнеп бер көлеп алгач, җитдиләнә төшеп, өстәп куйды.— Кеше гомерен яфракка тиңләү ярамыйдыр, Мирсәет абый.

Ишегалды тарафыннан, бакча яктан берәүнең йөткергәне ишетелде шул мәл. Табигый йөткерү түгел, «без көтәбез, биш минут узды», дигән хәбәр иде бу.

— Миңа керергә вакыт,— диде кыз, Мирсәеткә беренче кат күзләре белән текәлеп. Юк, китәсе, аерылышасы килми иде аның үзенең дә. Әмма гаилә тәртибе, үзен кайгырткан туганнары каршында җаваплылык күпкә әһәмиятле.

Мирсәет тә үтәдән күреп, аңлап тора иде боларны. Туры сорау бирергә җөрьәт итте ниһаять:

— Кайчан һәм кайда күрешә алабыз, зинһар әйт, Фатыйма?...

— Белмим шул,— дип икеләнеп калды кыз. Әмма суза торган чак та түгел, вакыт чикләнгән.— Якшәмбе көн музыка дәресләрем тәмамлангач кына күрешсәк иде. Башка көннәрдә иртәдән кичкә кадәрле мәктәптә булам. Әйтергә дә онытканмын бит әле, татар мәктәбендә укытам мин.

Якшәмбе көн көндезге икедә очрашырга вәгъдәләшеп аерылыштылар. Корыч капка шапылдап ябылды һәм бар тараф тынып калды. Шунда гына капка читендәге яшел калайга ак белән язылган эре хәрефләр җәлеп итте аның игътибарын: «Большая Татарская, 24». Хәтерләргә тырышып, күңеленнән кабатлады ул аны: «Зур Татар тыкрыгы, 24». Ә бераздан ике катлы өйнең тагы оч тәрәзәсендә бер-бер артлы ут алдылар. Тик аларның кайсы өмет булып кабынганлыкны ялгыз каенга терәлеп калган Мирсәет аера, ачыклый алмады.

Сөйләшенгән көн һәм сәгатьне һәр икесе түземсезлек белән көтеп алды. Очраштылар... һәм икәүдән-икәү генә Мәскәү елгасы читләтеп янәшә атлап китеп бардылар. Аңлашыр сүз, уртаклашыр хисләрнең чиге юк. Вакытның ничек үткәне һәм атлый торгач шактый ара киткәнлекләре дә сизелми калынган.

— Большевикларның кайда һәм нинди шартларда торганлыкларын беләсеңме, Фатыйма? — дип сүз кузгатты Мирсәет берзаман.

— Белмим шул,— дип башын чайкады кыз.

— Күрәсең киләме?...

Алдын-артын уйламастан җавап биреп куймасынмы кыз:

— Кызык булыр иде...

Каршыларында ук торган алты катлы соры өйгә күрсәтте Мирсәет. Атлый торгач, үзе яши торган йортка килеп чыккан иде инде алар.

— Менә Фатыйма, шушы йортта яши большевиклар... Хәтереңдәме, теге кичтә сезнең каршыдагы каенның соңгы яфрагы очып киткән иде? Көзге җилләр аны менә шушы тарафларга китереп чыгарды.

— Теге сары яфракнымы? — дип елмайды риясыз кыз. Һәм ялт кына Мирсәетнең каршысында бөтерелеп алды бер. Йөрәге җилкенүдән булгандыр!

Ничек итсә итте, юмалый-чакыра торгач кызны үзенә алып керде Мирсәет. Һәм аңарга түрдән урындык күрсәтеп, аягына чигеп эшләнгән йомшак Казан чүәге кидерде.

— Хатыныңнан калган чүәкме? — дип, сагаеп сорап куйды укытучы кыз.

— Мин монда үзем генә яшим,— дип искәртергә мәҗбүр булды Мирсәет. Кызның әледән-әле аның авырткан җиренә кагылып, хатынын искә төшереп торуы ошамый иде, билгеле.

— Ә хатын-кыз чүәкләре нигә кирәк булды?

Шунда гына, кызның начарлык теләүдән түгел, табигый көнләшү хисеннән генә шулай төпченүен төшенде Мирсәет. Һәм, тәвәккәлләп, кием элгеченнән тагыниләрдер күтәреп алып килде ул җәт кенә. Кызга сузды.

— Менә бу күлмәк тә сиңа... Һәм менә бу көмеш йөзек белән көмеш беләзек тә...

Кызда табигый инстинкт сөйләшә иде, гакыл түгел.

— Ой, нинди матурлар,— дип, куанып куйды ул.

— Менә болары да сиңа,— дип, кечке халат һәм алъяпкыч сузды Мирсәет.

Кыз, ниһаять, төшенде. Һәм телсез калып торды бермәл.

— Аңламадым... Бу ни диган сүзегез, Мирсәет абый?!— дип, болай да янып торган зур күзләрен ачып Мирсәеткә текәлде ул.

— Бумы,— дип, бармак очлары белән сак кына Фатыйманың күзләренә төшеп торган чәч чалымнарын күтәреп, сыпырып куйды Мирсәет. Аны кулыннан тотып торгызды һәм шундый ук саклык белән җилкәсеннән кочып алды.— Бу минем сиңа тәкъдимем, Фатыйма. Бу өйдә мин япа-ялгыз, дөньясында япа-ялгыз. Минеке бул, бергә яшик диган тәкъдимем, Фатыйма.

— Минме?... Сезгәме?...— дип гаҗәпләнде, аңлый алмыйча, югалып калды кыз.

— Әйе, нәкъ шулай. Дөрес аңладың, Фатыйма. Синсез бер көн, бер сәгать тә яши алмаячакмын моннан ары. Син минем бушап, шыр ялангач калган җанымны яңадан уяттың...

Кыз кулындагы күлмәк һәм башка бүләкләр шапылдап идәнгә килеп төште. Көтелмәгән яңалык чак аяктан екмады бугай аны.

— Сез большевик, Мирсәет абый. Ә мин... мин — сезнең өчен ят токым, миллионер Ирзиннардан...

— Сөйләмә... Берни дә сөйләмә, Фатыйма җаным,— дип, кочаклап алды ул кызны. Әллә кыз үзе аның кочагына аудымы, әйтү кыен.— Төрек солтаны кызы булсаң да ике уйладым юк! Бераүгә дә, һич бераүгә дә бирмим үзеңне. Син — тәкдирем минем...

— Юк, Мирсәет абый, юк... Булмас эшне сөйләмәгез, җибәрегез мине...

Куллары белән чәбәләнде. Мирсәетне читкә этмәк булды кыз, ә тәне вә җаны белән аңарга тартылды. Иреннәре булып, алар карышмады — ут булып янды, җиләк булып тамдылар...

— Мирсәет абый,— дип, дәшәр көч тапты Фатыйма үзендә.— Сез яхшы кеше бит, иеме... Мин сезгә ышанам, Мирсәет абый.

Фатыйманың аккош мамыгыннан да йомшаграк куллары аның җилкәсендә иде инде, аны иркәлиләр.

Шулай да кызның йомшаклыгыннан, үзенә булган ышанычтан файдаланырга ашыкмады Мирсәет. Бар ихтыяр көчен җигеп булса да, кочагында, ирен очларында уалган, эреп барган кызны янә кәнәфигә утыртты.

— Мине ташламассың, бары үземнеке генә булырсың, ярыймы, Фатыйма.

Кыз дәшмәде. Ни диярга белмәдеме, әллә ризалашуы булды — үзе белән янәшәдә утырган Мирсәетнең җилкәсенә, авыр сулап, башын салды.

— Сорау мәгънәсез тоелдымы әллә, ник дәшмисең, Фатыйма?

— Ни диярга белмим, Мирсәет абый... Авыр миңа...

— Сөйлә, Фатыйма җаным, бәлки мин ярдәм итә алырмын. Сөйлә, нинди борчуларың бар?

Тагы бер кат тирән сулыш алды кыз. Һәм башын күтәрде. Чәчләрен сыпыргалап алды, итәкләрен төзәтеп куйды.

— Әнием мине сезгә бирмәячәк, Мирсәет абый. Үлсә-үлә, әмма сезгә бирмәячәк. Җанында авыр таш булып ята аның «большевик» диган сүз. Ул ышанмый сезгә, һәммәгездән курка...

— Менә ничек,— диюдән тыш, ни чарасы булды икән шунда Мирсәетнең. Аклана башласынмы?... Юк, без андый түгел, без мондый, дип аңлатырга керешсенме?... Фатыйма бит уйнап сөйләшми, юкка гына дисеңме әллә, әнә, күз читләрендә кайнар яшь тамчылары чагыла аның. Әнисенең дә хаклы икәнлегендә шиге юк. Гомер бакый ата-баба җыйган малыңны шулай бер сәбәпсез талап чыгып китсеннәр әле... Кайсыбыз риза булыр иде икән... Йә, кайсыгыз? Ә биш бала белән торып калган тол хатынга яшәргә, улларын-кызларын аякка бастырырга да кирәк бит әле.

— Гозерләп сорыйм, Мирсәет абый, җибәрегез сез мине. Һәм һичкайчан, һичкайда очрашмаска тырышыйк бүтән. Миңа... бик тә, бик-бик авыр булыр сезне очраткан чакларымда. Зинһарлап сорыйм, кызганыгыз мине... Мирсәет абый...

Үзе сөйли, үзе яшьле күзләрен Мирсәеттән яшерә иде кыз. Ул да түгел, чарасызлыктанмы, тагы аның җилкәсенә китереп салды ялгыз башын.

Мирсәеткә дә җиңел түгел иде бу мизгелдә. Кулы белән кызны кочып, башын артка ташлый төшеп, уйга калды ул. Әллә белеп, әллә күңеле сизеп, тынлыкның, дәшми-тынмый гына утыруның андый чакларда теләсә нинди сүз һәм хәрәкәттән дә мәгънәлерәк икәнен сыный иде гүя.

Шактый озынга сузылган тынлыкны Фатыйма бүлдерде.

— Сезгә дә бик моңсумы, Мирсәет абый? — дип сорап куйды ул. Җаны сизгер, нечкә иде шул аның да.

— Моңсу да, авыр да, Фатыйма. Ә инде сине югалтсам, яшәвемдә мәгънә калмас.

— Алай димәгез, Мирсәет абый, сезнең тормыш көйле. Җаваплы эшегез, дәрәҗәле исемегез бар... Мин бит беләм, Әсәдуллаевлар йортына да бик күп кызлар сезне күрер, сезне тыңлар өчен генә йөриләр.

— Син бер генә, Фатыйма. Күзләрем башка һичкемне күрми. Миңа синнән бүтән берәүнең дә кирәге юк. Ишетәсеңме, Фатыйма?

— Ишетүен-ишетәм дә... Мин бит үзем дә, Мирсәет абый, ул клубка гел сезне күрер, сезне тыңлар өчен генә йөрим... Сезне тыңлый-тыңлый гел большевик булып бетә яздым инде. Шулай дисәм, әни ачулана, туганнарым көлә. Али абый да ошата сезне. «Әллә алдый, әллә дөресе шулай, ышандыра бит бу большевик»,— ди.

— Бәлки, әниең дә аңлар,— дип елмайган атлы булып, болай да сыенып утырган кызны тагы да үзенә тартарак төште Мирсәет.— Аның каршында бит минем һич гаебем юк.

— Белмим шул,— дип, икеләнеп калды Фатыйма.— Безнең әни кешелекле һәм юмарт ул үзе. Әмма намус белән яшәргә күнеккән. Талау һәм фетнә белән эш итүчеләрне җене сөйми. Ул мине һичкайчан гафу итмәячәк...

Сизә, сизми димени соң, кыз Мирсәетнең тәкъдименә күнәргә ошаган... Шушы мизгелне ычкындырса, алда ни буласын, дөньяның ничекләр үзгәреп, кай юнәлештә каршылыклар китереп чыгарасын, белсә дә бер Алла үзе генә белә торгандыр...

Фатихасын сорап кызның әнисе янына барырга дигән тәкъдим кире кагылды. Әнисенең сөйләшеп тә тормаячагын яхшы белә иде бит Фатыйма.

Димәк, бердәнбер юл кала... Тәвәккәлләргә, дигән нәтиҗәгә килде Мирсәет. Фатыймага ак алъяпкыч кидерде һәм чәй хәстәрли торуын үтенде аның. Ә үзе, кибеткә чыгып керәм дип, урамга ашыкты.

Кибеткә дә керде керүен... Әмма, иң элек, ишегалларында себерүче булып эшләгән мишәр агай янына кереп, аңа ике гозерен чиште: никах укырга сәләтле бер-бер укымышлы мөселман картын чакырып китерергә тиеш булды ул ашыгыч рәвештә. Агай бик теләп ризалашты:

«Цирек сәгать тә узмас, укымышлы мәзин үеңдә булыр»,— дип ышандырды.

— Икенче гозерем дә үтә әһәмиятле,— диде Мирсәет, агайга тулысынча ышаныч белдереп. Алдан ук хәстәрләп чыккан кәгазь кисәге тоттырды ул аңарга.— Берәр малаең мена шушы адрес белән барып, анда күрсәтелгән ханымга тапшырып кайтса икән шул кәгазьне.

Агай зиһенле, сөйләүченең авызыннан чыкмас борын ук һәр сүзне әләктерә бара иде.

— Булды, канатем,— диде ул, кәгазь кисәген ялт кына яннарына килеп баскан төпчек малаена сузып.— Кыз орлау белән ат орлау дигәндә, өрәтәсе юк безнең Сиргац халкын... — Һәм яратып кына малаеның йомшак җиренә сугып алды. Шылаймы, улым?! Бар ыцкын, улым, бер аягың монда булсын, икенцесе — анда...

Мирсәет сузган берничә көмеш акчаны җәт кенә кесәсенә шудырды да, малай өстен-башын киенә-киенә чыгып та йөгерде.

— Булдырабыз аны, атай. Бәлшәвик әзи өчен аяк җәл түгел!

Мирсәет кайтып кергәндә табын түренә менеп кунаклаган җиз самавырның түбәтәйләре әпипәгә әйттерә иде инде. Чәче төшмәсенгә дип, башына ак яулык та чөеп җибәргән Фатыйма. Үзләшә төшкән, яшь хуҗабикә сыман ишекле-түрле йөгереп йөри. Килештерә...

Вәгъдә ителгән мәзин озак көттермәде. Имам-хатыйбларың бер кырыйда торсын. Китабы бар, чалмасы һәм таягы дигәндәй, килештерепме, килештерә... Ул кергәнче, карышып, икеләнебрәк торган Фатыйма да керүчегә ул-бу сиздермәде. Никах җиренә җиткерелеп укылды, вәгъдәләр бирелде, чәй эчелде. Һәм килүче, аны-моны сораштырып, озаклап гәп корып утырмады, кисәтелгән иде, тизрәк китү юлын кайгыртты.

Икәүдән-икәү генә калдылар, ниһаять.

— Ни эшләдек без?!. Мирсәет абый, син нәрсә уйлап чыгардың инде?— дип, үпкә белдергән атлы булса да, Фатыйма артык коелып төшмәде, сер бирмәде. Шәһәр кызы — шәһәр кызы инде ул! Яшьлек җүләрлеген кая куясың тагы...

Бәйрәм итәргә дип, пилмән пешерү хәстәренә керешә алар икәүләшеп. Чаршау артына кереп халат киеп чыкты Фатыйма, халат өстеннән алъяпкыч. Чәчләрен яулык астына яшереп куйгач, гомер итәргә керешкән хуҗабикәдән һич аерырмын димә инде менә. Мирсәет ит туратырга кереште, ә Фатыйма камыр баса...

Нәкъ шул чакта ишек шакымасыннармы...

— Үзем барам,— дип йөгереп китте Мирсәет ишек катына.

Фатыйма бит әле берни аңламый. Фатыйма тырышып-тырышып камыр баса. Ишектән керүчеләр — аның әнисе һәм абыйсы Али. Бер-ике адым, нидер сизенгән сыман, алга уздылар. Күзләре аш бүлмәсенә төште. Табигый ки, телсез-өнсез калды һәр икесе, үз күзләренә үзләре ышанырга-ышанмаска белми тераләп каттылар.

Ә Фатыйма камыр баса. Өстендә халат вә алъяпкыч, башында, гадәти бер яулык. Ул аны-моны уйламый, як-ягына каранмый, үз эшен белә. Монда бит ул яңа кеше, кем кермәс тә кем чыкмас хуҗа янына.

— Әйдәгез, түрдән узыгыз,— дип дәште, ниһаять, шулай ук телен төшләп калган Мирсәет.

Шунда гына ялт итеп ишек катына күз төшереп алды Фатыйма. Һәм чайкалып куйды. Кулындагы уклау өстәл өстеннән тәгәрәп китте.

— Әни... Али абый...— дан башка берни әйтә алмады ул. «Нишләдең син?!» дигән кебек Мирсәеткә генә карап куйды.

Мирсәет — хуҗа кеше. Һәм мондагы тамашаны куертучы. Шуңа, берни булмагандай, ипле-тыныч тотарга тырышты ул үзен.

— Әйдәгез, узыгыз, уз... Утырышыйк иң элек, аннан аңлашырбыз,— дип, кунакларны түргә чакырды.

Фатыйманың әнисе — жыйнак гәүдәле, шактый ук калыная төшкән гадәти бер ханым икән. Өсте-башы белән булсын, төсе һәм үз-үзен тотышы белән булсын, күзгә бәрелеп тормый. Дөнья мәшәкатьләре һәм тормыш шактый ук талкыган күренә үзен. Иш өстенә куш дигән сыман, менә сиңа тагы, сулышына капкан. Әле булса тынычлана алмый газап чигә.

— Бу нинди тамаша тагы? — дип, чарасыз торып калган кызына дәште ул. Кунак өстәле янына узарга ашыкмады.

Үзенең ни кылуы, газиз әнисен ни дәрәҗә рәнҗетүен әле генә аңлый башлады кызый.

— Әнием,— дип, күкрәгенә барып капланды ул аның. Үксергә кереште.— Әнием, без сиңа хәзер үк аңлатырбыз. Тик тыңла, рәнҗи генә күрмә, ярыймы, әнием.

Үзеннән күпкә калку булган, буй җиткергән кызын читкә этәрер көч тапмаса да, кочагына алырга да ашыкмады анасы.

— Бу ни дигән сүзең, Фатыйма?!.— дип кабатлады ул. Мирсәет әллә бар, әллә юк, аны гүя күрмәмешкә салыштылар.

Али исә, озын буйлы чибәр егет, өлкәннәр сүзенә катышмады. Ишек катында эленеп торган көзге каршында чәчләрен төзәткәләгән атлы булып торды.

— Әнием,— дип мышык-мышык килде кыз бала.— Без Мирсәет абый белән...

Әмма җөмләне тәмамлар сүз тапмый тинтерәде. Хәер, аңлашыла иде ич инде болай да...

— Юк,— дип, кырт кисте ана.— Әйдә, киен, өйгә кайткач сөйләшербез. Монда сиңа берни дә калмаган.

Нишлим икән соң дип, яшьле күзләрен мөлдерәтеп Мирсәеткә карады кыз.

— Әби,— дип дәшәргә кыюлык тапты үзендә Мирсәет. Җылы итеп, ягымлы итеп дәште.— Без никах укытырга да өлгергән идек шул инде.

Кызның әнисе гүя күрми дә, ишетми дә иде Мирсәетне.

— Әйдә, әйдә, киен тизрәк, бетмәс монда...— диде ул, кызын ашыктыруында булып.

— Әнием, син бит беләсең,— дип, янә гозерләп карарга иде Фатыйманың исәбе.— Мирсәет абыйсыз мин бер көн, бер сәгать тә яши алмам. Сөйләгәнем бар, беләсең ич...

Ананың бәгыре каткан. Һич эрерлек күренми.

— Соңгы мәртәбә сорыйм. Кайтасыңмы-юкмы?

— Әнием, зинһар өчен дим, әйдә бергә кайтыйк. Мирсәет абыйны да үзебез белән алыйк.

— Юк,— диде ана, кырт кисеп.— Минем большевик өчен дип үстергән кызым юк.

— Әнием...

— Дөньяның ямен бетерделәр... Карга оясы кебек итеп, нәселебез, йорт-җиребезне тузгыттылар... Бирнәгә дип җыйган сандыгыңа кадәр шулар талап чыгып китте. Ә син...

— Юк, әнием, юк, Мирсәет абыйны син белмисең. Ул андый түгел. Ышанмасаң, әнә, Али абыемнан сора. Ул да белә, аның да күргәне, тыңлаганы бар...

Мин берни белмим һәм катышмыйм да дигән сыман, Али үзенең аяк очына карап торды. Әйе дә димәде, кире дә какмады — катышмады.

— Али,— диде ана кешенең ярсыган тавышы.— Киттек, безгә монда берни калмаган.— Һәм ишек катына җиткәч кире, соңгы мәртәбә, кызына борылып дәште.— Йә бүген үк өйгә кайтасың, йә бүгеннән ары минем Фатыймам юк.

Ишек шапылдап ябылды. Әнисе артыннан йөгереп килгән кыз баланың имән борыска башын куеп сулкылдаудан башка чарасы калмаган

иде. Мирсәетнең тынычландыру сүзләре генә аз иде шул аңа. Ана фатихасы булмау авыр, бик авырдыр шул кыз бала өчен.

Фатыйма белән Мирсәет көн саен диярлек барып йөрделәр Ирзиннар өенә. Ишек ачык булды үзләре өчен. Әмма әниләре сүзендә торды, кызына булсын, киявенә булсын, авыз ачып дәшмәде. Туйларына да аяк басмады.

Аның каравы туганнары Али белән Мирза килде ул туйга. Күренекле әдип Галимҗан Ибраһимов, Мирсәетнең бергә эшләгән дусларыннан Шәриф Манатов белән Измаил Фирдәвесләр була туйда. Һәм Иосиф Сталин... Сталин вәгъдәсендә тора, Мирсәет Солтангалиевнең 1918 елның октябрь ахырларында узган туй мәҗлесенә үзенең хатыны Надежда Аллилуева белән парлап килә ул.

Мәскәү елгасы аръягындагы Совнарком йортында, Мирсәетнең бер бүлмәле фатирында узган әлеге туй мәҗлесен башлап иң элек тост әйтүче дә Сталин булуы мәгълүм. Солтангалиевнең тынгысыз эшчәнлеген, Көнчыгыш вәкилләре даирәсендә хөрмәт казануын билгеләп үткәчтен, сүзен яшьләргә бәхет юллаган теләкләр белән тәмамлый ул.

— Фатыйма белән Мирсәетнең бәхетле совет гаиләсе коруларына мин нык ышанам,— ди Иосиф Сталин.— Аларга бәхет телим. Озын гомер телим. Йөзәр ел яшәвегезне телим. Уллар-кызларыгыз күп булсын. Шуның өчен эчик әйдә!

Сөйләү куәсе чамалы гына булса да, олы кунакның һәр сүзе зур күтәренкелек белән кабул ителә мәҗлестә катнашучылар тарафыннан. Иптәш Сталинның тосты өчен аягүрә торып чәкештереп эчәләр.

Надежда Аллилуева үзенең янәшәсендә утырган Фатыймага таба янтая төшеп, ихластан аның бит очларыннан үбеп ала.

— Бәхетле булыгыз... Күз тия күрмәсен, икегез дә шундый матур, яшьләр...,— дип пышылдый яшь киленнең колагына.

Фатыйма бәхетле, ул елмая, әнә, ут булып яна. Мирсәетнең дә куанычы күкрәгенә сыймый, иңнәрендә гүя канат. Әледән-әле үзләренә тимер салкынлыгы бөркелеп торган карашын төбәп утырган Сталинга, һәммә кунакларга чиксез рәхмәтле алар.

Әллә болай гына, әллә ихластан яшьләрне кайгыртуы иде, үзен кунаклар арасында иркен хис иткән Аллилуева иренә дә мөрәҗәгать итеп ала:

— Зинһар алай карама, күз тидерерсең. Күзең каты синең!

Дәшмәде Сталин. Аның ирен читләрендә чагылып алган елмаю чалымын тойса да, бер хәләл җефете тойган булуы ихтимал.

* * *

*«Соң дәрәҗә яшертен, Гыйнвар, 1919 ел.*

*Россия Коммунистлар партиясенең Үзәк Комитетына.*

*Хөрмәтле иптәшләр!*

*Казан комитеты карары нигезендә һәм аның исеменнән сезгә үтенеч белән мөрәҗәгать итәм:*

*Соңгы көннәрдә безнең тарафтан иптәш Свердлов исеменә телеграмма җибәрелгән иде инде. Халык депутатлары Советында рәис булып эшләү өчен иптәш Солтангалиевне Казанга кайтаруны үтенгән идек анда.*

*Уфаның алынуы сәбәпле контрреволюцион милли дәүләтләрне тар-мар итү ихтыяҗы көн тәртибенә килеп басты. Шундый шартларда мөселман милләтчелеген юмалау һәм тынычландыра төшү гаять зур әһәмияткә ия. Рәис итеп мөселманнарның үз вәкилен сайлаудан да отышлырак ни булырга мөмкин?!.*

*Солтангалиевне әлеге урынга куюдан югалту зур булмас иде. Ул рәис булып эшләгән тәкъдирдә дә иптәш Малютин киләкле сәясәтне үткәрәчәк. Ә җаваплылык Солтангалиевтә.*

*Бу комбинацияне тормышка ашыру файдасына тагы ике нәрсәне хәтерегезгә төшерәм.*

*1). Солтангалиевнең Казанда эшлисе килеп күп мәртәбәләр мөрәҗәгать иткәне бар;*

*2). РКП(б)ның Мөселман секциясе әлеге хәлендә бер эшкә дә сәләтле түгел. Чамадан тыш йомшак.*

*Шуларны истә тотып, без Үзәк Комитеттан ниятебезне тормышка ашыру юлында ярдәм көтәбез. Солтангалиев иптәшне, Мәскәүдәге Совет һәм партия эшләреннән бушатып, Казан партия Комитеты карамагына җибәрүегезне үтенәбез.*

*Иптәшләрчә сәлам белән:* **Михаил Жаков».**

Бу яшерен телеграмманың безгә әлегәчә мәгълүм булмаган байтак кына хикмәтләре булса кирәк. Ул — очраклы рәвештә генә тумаган. Чөнки Үзәк һәм җирле партия оешмалары арасында йөргән яшерен телеграммалар вә хатлар өчен Солтангалиев фамилиясе бик гадәти булып китә ул көннәрдә.

Шунысы хикмәтле тагын, Мирсәет Солтангалиевкә әлеге телеграмманы һичкем күрсәтми. Үзе артында шундый хат-хәбәрләр йөрү ихтималын күз алдына да китерә алмый ул, әлбәттә. Сирәк очрый торган оештыру сәләтенә ия татар егетенең дәрәҗсе иң югары даирәләрдә дә айлар-еллар белән түгел, көнс-сәгате белән үсә, ныгый барган чор була бу. Ә шулай да, кемнәрдер уйлана, кемнәрнеңдер ни өчендер эче поша...

Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең эше гөрләп бара дияргә була. Аның рәисе булган Мирсәет Солтангалиев тиз арада талантлы хәрби командирлар һәм сәяси оештыручылар корпусы булдыруга ирешә. Йосыф Ибраһимов, Камил Якуб, Шамил Усманов, Якуб Чанышевларның исеме татар-башкорт кызылармиячеләре даирәсендә зур ихтирам казана. Патша армиясендә хезмәт итеп, зур тәҗрибә туплаган офицерлар да бик теләп катнаша бу милли хәрби көчләрне оештыру эшендә. Алимбәкев, Алмаев, Әлмөхәммәтов, Мәүлетов һәм Крымов кебек дистәләгән командирлар татар-башкорт егетләреннән тарих сәхифәләренә кергән легендар частьлар туплап, яшь Совет дәүләтен яклап көрәшкә күтәреләләр. Революция язмышы хәл ителгән Көнчыгыш фронтының яртысын Үзәк мөселман хәрби коллегиясе кызылармиячеләре тәшкил итә ул авыр көннәрдә.

Җиңү артыннан яңа җиңүләр яулана. Үзләренә милли дәүләтчелек вәгъдә иткән Советлар өчен эшче һәм крестьян вәкилләре җаннарын кызганмый көрәшә. Әмма үзәктә мөселман хәрби көчләренең көнесәгате белән ныгый баруына сагаеп караучылар да булмый түгел.

1919 нчы елның гыйнвар урталарында Мирсәет Солтангалиев Сталин кулыннан Үзәк Комитет мандаты алып, Уфа шәһәренә ашыгыч командировкага җибәрелә. Максаты гаять җитди: Кече Башкортстан җитәкчеләреннән Зәки Вәлиди һәм Ильяс Алкиннар белән элемтәгә керү, алар карамагындагы хәрби берләшмәләрне Совет хөкүмәтенә каршы көрәштән аерып алу.

Солтангалиев юлга чыгып киткән көннең икенчесендә, ягъни гыйнварның уналтынчы көнендә, Милләтләр эше халык комиссариаты коллегиясе Мәскәү шәһәрендә гадәттән тыш киңәшмәгә җыела. Көн тәртибендә — Үзәк мөселман хәрби коллегиясе турында мәсьәлә. Фикер алышулар башланып китүгә үк, әлеге коллегиянең кирәклеге шик астына алына. Һәм тагы берничә көннән соң, махсус комиссия Үзәк мөселман хәрби коллегиясен бетерү турында карар кабул итә. Татар-башкорт кызылармиячеләре алга таба бары тик Бөтенроссия хәрби штабына һәм Хәрби комиссар Лев Троцкийга буйсынырга тиешле килеп чыга.

Нәкъ шул көнне һәм шул сәгатьтә тирән конспирация шартларында Уфа — Стәрлетамак юлы өстендәге бер башкорт авылында — акгвардиячеләр тылында — әлеге вакыйгалардан һичбер хәбәрдарлыгы булмаган Мирсәет Солтангалиев белән Зәки Вәлиди һәм Ильяс Алкин арасында җитди әңгәмә була.

Кече Башкортстан дип игълан ителгән республика башкаласы Темәс авылыннан килгән вәкилләр һәр икесе Мирсәет өчен яхшы һәм

күптәннән таныш. Әмма бу очрашу гадәти түгел. Моны, күптәнге танышлар янсә якташлар булудан бигрәк, Совет хакимияте өчен барган көрәшнең капма-каршы икс фронтында торган сыйнфый дошманнар очрашуы дип бәяләү хакыйкатькә ныграк туры килсә кирәк.

— Үзәк Комитет һәм Совет хөкүмәтенең тулы хокуклы вәкиле буларак, мин сезгә җитди тәкъдим белән килдем,— дип хәбәр итә Солтангалиев очрашуның башында ук.

Вәлиди белән Алкин бер-берсенә карашып үзара серле генә елмаеп куялар.

— Алай ук эредән сукаламасаң да ярар, якташ,— дип әйтеп куя Зәки Вәлиди, рәсмилекне өнәмичә.— Хәтереңә төшерәм, бәлшәвикләр Россиясендә түгел, башкорт авылында очрашабыз. Бездә диктатура түгел...

Елмаюыннан туктарга өлгермәгән Ильяс Алкин да сүз кыстыра:

— Ә башың өчен курыкма. Вәгъдә — иман бездә. Иркенләп сөйләшә-аңлаша алабыз. Сезнең «иптәшләр»дән аермалы буларак, аркага пычак кадый торган гадәтебез юк.

— Әфәнделәр, кисәтергә кирәк саныйм, әйләндереп-тулгандырып төртмә сүзләр әйтешеп утыра торган чак түгел,— дип, кисәтергә кирәк таба Мирсәет.— Чөнки бүген үк миңа кире Уфага юл тотарга кирәк.

— Тыңлыйбыз...

Зәки Вәлиди һәм Ильяс Алкин үзләренең җитди сөйләшүгә әзер икәнлекләрен белдерәләр.

Мирсәет тә, ниһаять, шартлы рәсмилектән арына төшеп, сөйләргә кереште:

— Без бер-беребезне яхшы белүчеләр. Тәү кат очрашуыбыз түгел. Шуңа, ачыктан-ачык, бар булганын уртага салып фикерләшү хәерле булыр. Советларга һәм партиягә мөнәсәбәттә хәзер үк уртак фикергә килә алмабыз, беләм. Монысы вакыт эше. Әмма безнең һәр өчебез өчен дә уртак вә газиз булган нәрсәләр бар. Әйтик, халык... Татар-башкорт хезмәт ияләре язмышы. Кече Башкортстан шартларында ике ут арасында калган башкорт авыллары, башкорт крестьяннары язмышы... Үзебезнең сәяси уңыш янсә югалтулар турында түгел, әнә шул Колчак фетнәчеләре белән Кызыл Армия арасында торып калган, ни эшләргә белми бәргәләнгән бахырлар хакында кайгыртуыбыз хәерле... Ильяс әфәнде Колчакның кем булуын белсә кирәк... Самарада Учредилканы куып таратучы башка һичкем түгел, әлеге дә баягы шул Колчак. Шулаймы, Ильяс әфәнде, сез анда әгъза булып тора идегез булса кирәк?!.

— Әйе,— дип, баш кагарга мәҗбүр иде Алкин.— Колчакны туган атабыз санарга җыенмыйбыз җыенуын, әмма ике ут арасында калучы кая булса да сыенырга мәҗбүр.

— Әмма Колчакка түгел,— дип эләктереп алды Мирсәет.— Кызылармиячеләргә каршы аткан һәр патроныгыз халык бәгыренә, үзегезнең татар-башкорт туганнарыгыз бәгыренә төбәлгән. Моны белергә кирәк иде бит!... Ә, Зәки әфәнде?... Ә, Ильяс әфәндә?... Сез бит, татар-башкорт тарихында очраклы кешеләр түгел, ни кылганны гына аңлый торган затлар. Миңамы сезне өйрәтергә?! Беләм ич, һәр икегез халыкның язмышын гына түгел, тарихын да өйрәнгән кеше... Адмирал Колчакның ата чукындыручы Ильминскийдан артык җире булыр дип уйлыйсызмы?!.

Ниһаять, куш уч белән яңакларына таянып утырган Вәлиди дә телгә килде:

— Бәлшәвикләргә ышаныйкмы? — дип сорады ул, сынаулы карашын Мирсәеткә төбәп.— Алар алдамас дип уйлыйсыңмы?!.

Икеләнер урын калдырмаска тырышып, шундук китереп куйды Мирсәет:

— Юк, алдамаслар!

— Ышанып булмый аларга да...

Зәки Вәлидинең тел төбендә булган икеләнү тойгысын сиземләү өчен күрәзәче булуың кирәкми, шундук чамалады Мирсәет.

— Большевикларның милли мәсьәләгә мөнәсәбәте ачыктан-ачык. Онытмаган булсагыз, Россия халыкларының хокуклары турында Декларация унҗиденче елда ук игълан ителде.

Вәлиди:

— Онытуын-онытмадык, әмма тел — сөяксез ул, ә кәгазь бүген бар, иртәгесен — юк. Гарантия кая?

Солтангалиев:

— Гарантияме?... Иптәш Ленинның имзасы! Иптәш Сталин имзасы!

Вәлиди көлемсерәп куйды, ирексездән:

— Имзалар куелыр ул. Һәм кире дә алыныр. Ленинның да сүздә — бер, эштә — икенче килеп чыкмас дип, кем әйтер?!.

Солтангалиевның Ленинга тел тидертәсе килми иде, әлбәттә:

— Ленинны сез белмисез...

Вәлиди:

— Беләм. Һәм әңгәмә дә кылганым бар. Күзләре хәйләкәр, айһай...

Солтангалиев:

— Ашыкмаска киңәш итәр идем. Иптәш Ленин сезне янә үзенә чакыра. Сезгә шуны тапшыруымны үтенделәр.

Вәлиди:

— Карарбыз... Бәлки янына да барып чыгарбыз. Әмма безне алай беркатлыга санамасыннар анда. Менә шул, Мирсәет якташ... Үзеңә дә шуны киңәш итәр идем, вәгъдәләренә бик ышанып бетмә. Үзләренә кирәк булганда вәгъдәләр бирелер ул, ә кирәгең беткәч, көнбагыш кабыгы урынына төкереп ташлаулары бик ихтимал.

Солтангалиев:

— Бар нәрсәне шик астына куеп яшәү мөмкин түгел, Зәки әфәнде. Ышанмау өчен нигез юк. Татар-Башкорт республикасы игълан ителү тарихи вакыйга түгелмени?

— Алла боерса, дип сөйләшегез, Мирсәет,— дип Ильяс Алкин катышып алды әңгәмәгә.— Республика дип, байтактан сөйлисез-сөйләвен. Әмма әлегәчә республика дигәнегезнең үзен күргән юк.

Мирсәеткә чират җитмәде, Вәлиди элеп алды сүзне. Күрәсең, Татар-Башкорт республикасы турында сүзләргә мөнәсәбәттә Алкин белән фикерләре уртак түгел иде аларның. Ни дисәң дә, Ильяс Алкин Кече Башкортстанга «ни чарадан бичара» килеп кушылган очраклы кеше.

— Әгәр дә мәгәр,— дип аңлатырга кереште Зәки Вәлиди.— Совет хөкүмәте Кече Башкортстанның мөстәкыйльлеген танымый икән, безнең бәлшәвикләр белән сөйләшер сүзебез юк. Бу минем катгый таләбем! Иң әүвәлге шартым!

— Сезнең бу тикле дә үҗәтләнүегез миңа аңлашылмый, Зәки әфәнде,— дип, сак кына бәхәскә кереп алды Мирсәет. Әмма төп бурычы — Кече Башкортстанны Колчактан аерып алу икәнлекне дә истән чыгармады.— Татар һәм башкорт үзара һичкайчан һәм һич нәрсә бүлешкән халыклар түгел. Булганы — уртак, булмаганы да шулай ук. Төрек-татар тарихын язган галим буларак, сез боларны миннән яхшырак беләсез булыр, Зәки әфәнде! Шул тарихи бергәлекне таркатырга омтылучы, татар белән башкорт арасына чиtән коручы сез булырсыз дип, һич уйламас идем. Бу эшне, бәлки, бик еракка кереп адашканга кадәрле туктатырга кирәктер, ә, Зәки әфәнде. Аерылганны — аю ашар, бүленгәнне — бүре ашар, дигән халык мәкален искә алырга иде бит?!. Татар белән башкорт арасына ясалма чикләр куюны мин күз алдыма да китерә алмыйм. Моны сабый чакта ук башкортлар белән аралашып үскән шушы изге җир, шушы гүзәл төбәк улы буларак әйтәм, Зәки әфәнде. Бүген аңлашмасак, иртәгә соң булыр! Соң булачак... Аһәңе оныкларыбызга барып җитәр бу низагның.

— Юк! — дип, янә бер мәртәбә катгый басым ясарга кирәк санады Вәлиди.— Мин ул Татар-Башкорт республикасы дигән сүзгә ышанмадым. Ышанмыйм. Һәм ышаначак та түгелмен! Күз буу, алдау өчен бирелгән буш вәгъдә, вакытлы бер тозак кына ул. Безгә һичкайчан берләшергә рөхсәт булмаячак...

— Тозак түгел, ялгышасыз, Зәки әфәнде...

— Ә мин, урыс бәлшәвикләренә ышанмыйм. Казан кем шәһәре? Аларныкы! Уфа? Аларныкы! Ырымбур? Ырымбурда да көн бетте безнең халыкка.

— Уфасыз, Казансыз, Ырымбурсыз республика булмас, Зәки әфәнде.

— Башкорт — дала халкы ул, авылда яши, җир белән көн күрә. Кече Башкортстан — авыл республикасы. Башкалабыз да авыл, Темәс авылы булыр. Бу инде хәл ителгән, Мирсәет туган, юмалавың артык.

— Ярый,— дип, чигенергә кирәк санады Мирсәет.— Мине ышандырдыгыз да ди. Ә инде Башкортстан авылларында кыйблясыз калган, кыйбласын югалткан кешеләр ни хәл итәр? Колчак талкый-тарткалый үзләрен бер яктан, икенче тарафтан кызылармиячеләр үч ала. Менә дигән асыл ир-атлар кырыла, Зәки әфәнде, шулар жәлке, шулар кызганыч миңа. Синең һәм минем туганнарым лабаса алар! Ничек шуңа битараф калырга мөмкин. Аларны кыйбладан яздыручы, адаштыручы сез, Зәки әфәнде! Һәм сез, Ильяс әфәнде!

Дәшми генә түзеп торган Алкин үзен иskә төшергәч тә акланырга ашыкты:

— Сез мине белмисез, Мирсәет иптәш,— диде ул, ихлас борчылуын яшермичә, аңлатырга теләп.— Минем өчен татар-башкорт кына түгел, һәммә төрки кавем бар. Мин Руссия мөселманнарының азатлыгы өчен көрәшүче. Ә ул азатлыкка омтылыш бүген бары тик Кече Башкортстанда калды. Минем монда — Зәки әфәнде янында булуым, иң элек шуның белән аңлатыла.

— Ярар, Ильяс әфәнде, шулай да ихластан әйтегез әле, сезгә Татар-Башкорт республикасы, ягъни бердәмлек кыйммәтлеме, әллә Кече Башкортстанмы?

— Татар-Башкорт республикасы юк. Ул сүздә генә. Һәм сүздән ары узармы әле ул?!. Ә Кече Башкортстан — бар, менә ул,— дип каршыларындагы өстәл өстендә яткан кәгазьләр арасыннан кулдан ясалган картаны алып күрсәтте Алкин.

Шул урында беразга бәхәсләрдән аерылып торырга мәҗбүр булдылар. Кунаклар хөрмәтенә әзерләнгән көндезге аш китерелде өстәлгә. Аш артыннан чәйләп тә алдылар.

Табын җыелып, ишекләр бикләнгәч, сүзне Зәки Вәлиди башлап китте.

— Мирсәет туган,— диде ул.— Дөнья күргән кеше буларак киңәш итәм үзеңә: ташла ул Татар-Башкорт республикасы дигән буш хыялыңны. Уфа — Казан арасындагы саф татар өязләрен кертегез дә мөстәкыйль Татарстан игълан итегез. Иң дөресе шул булыр. Ә Казанга ябышып ятмагыз! Казан кирәкми сезгә. Ул гомер буе, бугазга кадалган сөяк сыман, тынгылык бирмәс үзегезгә.

— Киңәшегез өчен рәхмәт, Зәки әфәнде. Сезгә яхшы мәгълүм, Казан борынгы башкалабыз безнең. Бүгенге көндә дә анда яшәүчеләрнең йөздән утыз дүрте татарлар. Бу сан, һичшиксез, арта бараячак. Ата-баба кабере яткан изге туфрактан баш тарту дөрес булмас ул. Казанны калдыру — үз-үзеңне башсыз калдыруга тиң!

— Үзегез беләсез,— диде Вәлиди битараф кына.— Минем эш — киңәш итү, ә колак салу янсә салмау — сезнеке.

Ниһаять, әңгәмәне йомгаклар вакыт җитеп килә иде. Сәгатенә күз төшереп алгач, Мирсәет болай диде:

— Зәки әфәнде... Ильяс әфәнде... Дөрес аңлаган булсам, мин шундый нәтиҗәгә килдем:

— Яле, яле, әйтеп кара,— дип, дәү авызын киң җәеп елмаеп куйды Вәлиди.

— Сезнең төп максат: Кече Башкортстанны саклау икән. Дөрес аңладыммы?

Баш кагып, ризалашканлыгын белдерде Вәлиди. Алкин дәшмәде, тыңлап утыруын дәвам итте.

— Ә Советларга каршы көрәшүдән туктамыйсыз икән, сез якын көннәрдә үк тар-мар ителәчәксез. Мин моны Үзәк Мөселман хәрби коллегиясе рәисе буларак әйтәм. Бу — бер. Икенчедән,— дип, чираттагы бармагын бөкте Мирсәет.— Дөрес аңлаган булсам, Кече Башкортстанның, автономия шартларында, Татар-Башкорт республикасына керүе турында сөйләшү өчен шулай ук каршылык күрмим...

Ильяс Алкин, ялт кына, ни әйтер икән дип, Зәки Вәлиди тарафына күз төшереп алды. Күрәсең, Казан татары буларак, аның өчен бу җавап әһәмиятле иде.

Вәлиди дә, гадәтенчә, аяк терәп карышырга ашыкмады. Уйлана төшеп бирде җавабын:

— Советлар безне алдамаган тәкъдирдә, үзебезгә тулы мөстәкыйльлек бирелгән тәкъдирдә, уйлап карарга була,— диде ул, чын ил агасыдай һәр сүзен үлчәп, җиде кат иләк аша үткәзеп.— Әмма мин боларга ышанып җитмим.

Солтангалиев:

— Ышанып җитү-җитмәү вакыт эше. Димәк, килештек дип санаргамы Зәки әфәнде?

Вәлиди:

— Шулай саный аласыз.

Солтангалиев кулын сузды Зәки Вәлидигә:

— Вәгъдә.

Вәлиди, җавап итеп, аның кулын кысты:

— Без ике сөйләшмибез. Беләсең?!.

Солтангалиев:

— Димәк, Башкорт хәрби берләшмәләре Кызыл Армиягә каршы атмаячак бүгеннән башлап.

Вәлиди:

— Атмаячак.

Кече Башкортстанның хәрби җитәкчесе булып торган Ильяс Алкинга төбәде Мирсәет сораулы карашын.

Алкин көттермәде:

— Зәки әфәнде әйткәнчә булыр,— дип, баш какты.

Үзенең бу көннәрдә Уфада 5 нче Армия штабында булуы турында хәбәр итте Мирсәет һәм юлга чыгарга ашыгып киенергә кереште. Кайтасы ара аз түгел. Салкын. Өстәвенә җәяүле буран себереп тора. Ә Мирсәетнең өстендә җиңелчә тун һәм папаха гына.

— Якташ,— дип мөрәҗәгать итте шунда ишек катынача озата чыккан Зәки Вәлиди. Һәм үз җилкәсеннән алып Мирсәеткә төлке толыбын сузды.— Мә, бүләгем булыр. Көн салкын. Суык тимәсен үзеңә.

Бу игътибардан күңеле нечкәреп киткәндәй булды Мирсәетнең.

— Ә үзеңә?...— диде ул, алырга-алмаска белми, икеләнеп.— Мич башында утырырга җыенмый торгансыңдыр ич?

— Башкорт илендә Зәки Вәлиди туңмас. Һәм толыпсыз да булмас, ал, Мирсәет!

Вәлиди, моңсу һәм уйчан гына кул болгап озатып калды... Ә Ильяс Алкин исә, Мирсәет белән янәшә утырып, авыл читенә озата чыкты аны.

*Ахыры бар*

# ШИГЪРИЯТ

## Рәдиф Гаташ

### КЫШКЫ УРМАНДА ЙОРТЛАР БАР

* * *

Кышкы урманда йортлар бар — ямь-яшел.
Яз түсендәге бер йортта мин яшим.

Тышта карлар... ә уйда ут: еракта
Ракеталар ява бүген — Гыйракта.

Шул тарафка баккан дөнья — дүрт күзе;
Эсселе-суыклы тора Җир үзе.

Бутаган — дин, тел, илләрне — сәясәт,
Кайсы хаклы? Кемдә хакыйкать, йә әйт?!

Илемдә кан азмы иде? Җитмиме?
Кан түгеп тә кан дошманлык бетмиме?

Кайда Акыл? Ник берсенең иркенә
Икенчесе кисә юл — гел җилкенә?

Каян синдә, гасыр, бу афәт ташы?
Хәвеф арта: үз-үзен дөнья ашый?

Табигатьнең җитәрме көч-сабыры?
Нишләрбез, Гаташ — мәхәббәт шагыйре?

Кисмәсме безне нәләт чор кайчысы? —
Һаман да уйда Бабичлар язмышы...

Ә урманда — гамьсез йортлар, ямь-яшел...
Дөньяда шул төсләр күп... белеп яшим!

* * *

Без кемнәр соң? — Ходайдан ваз кичкәннәр?
Күңеленнән иман нуры киткәннәр?

---

Рәдиф ГАТАШ (Гатауллин) — *шагыйрь, 1941 елда туган; татар һәм рус телләрендә уннан артык шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

Каян күбәйдек җирдә без — пис ирләр,
Денсез-моңсыз халыклар, кавем-илләр?

Буйсындык соң кайчан без Кара көчкә?
Язмышларны тапшырдыкмы Иблискә?

Тугач ук әнкә сөтеннән яздыкмы?
Фатихасыз калдыкмы без — аздыкмы?

Нинди хәл бу — илдә яхшы калмаса,
Барчабызны тоташ Дәҗҗал алдаса?

Ялган белән бакланса һәр уй, бар эш,
Аң үлсә, җан сүнсә — качса намус?

Без — таш җаннар... бәлки, җансызлар иле?
Ут-рух өрер бер пәйгамбәрме — килеп.

Кем уятыр йокы-афәттән шулай?!
Бер ходаймы? Башка чара юк бугай.

Сүз буйсынган, күр, ничек Кара көчкә:
Бу җыр-догам укыла көчкә-көчкә...

* * *

Аңладым, ниһаять! Сез — күз бугансыз,
Дәрес алгансыз кара китаптан Сез!

Югыйсә, акыл җуйдырган сихерне —
Ул сүзләрне беләсез ник яттан Сез?

Аһ, ул җырлар! Чын булмагач наз, уты —
Икейөзлелектән Сез көч тапкансыз!

Фәрештә канаты белән сыйпагач,
Күз дә йоммый чын Иблискә саткансыз!

Эссе хисләр кочагында йоклатып,
Тантана итеп, упкынга аткансыз!

Ни максат белән дип, юләр, баш ватам:
Тагын бер җанны гөнаһка тарткансыз!

Каян дисәм чын мәхәббәткә нәфрәт:
Ярата белгән өчен үч алгансыз!

Шул көе әле үзегез җырда Сез
Янәсе сөттән ак, судан пакь калгансыз.

Ничек акланырга белми ихлас Хис,
Ник көчле ул шулай Чыннан — Ялган сүз?

Ә ник үзем башны алып качалмыйм?!
Ник кирәк мин? — җибәрмисез һаман Сез?!

## Бабичка бер вариация

Тетрәп калды мәгълүмегез — хис колы:
Мандолинда... җанда уйный — Кыз кулы!

Нурланды бүлмәм, ял-якты өстәлем —
Моңарчы тарау яткан кәгазь тулы.

Җанланды зәгыйфь сурәт — ут алынды —
Җәбраилнеңме канаты кагылды?

Ачыкланды гомер алда: максатка
Гүя кинәттән туры юл табылды!

Җырлады җан, уй-фикерләрем ташты,
Рәсүлемә вәхи килгәндәй булды!

Арынды гөнаһ уеннан яшь хисем,—
Гүя җаннан әнкәм догасы узды!

... Миңлебай, әллә Әхмәтме? Абзыйлар,
Кем дип атыйк чын нәсел-каумегезне?! —

— Алиһәм! — дим киндер күлмәкле кызны...

* * *

«Тимәскә иде бит миңа —
Кагылмаска иде сиңа»... —
Сүзләрең әллә үрти,
Күзләрең җитди: «Кит», — ди...

...Кагылдым шул кулларыңа, —
Тидемме хис-кылларыңа? —
Чакырып җырлый инде,
Чигенеп булмый инде!

Инде күлә күзләрең дә,
Шул югыйсә сүзләрең дә:

— Тимәскә иде миңа!..
Килмәскә иде сиңа...

Чәнчер энәләрең барын
Оныттым — кагылдым шул;
Табындым да яшьлегеңә,
Үзем дә кабындым шул...

Хәзер җырлыйм үзем меңә:
— Тимәскә иде бит — миңа
Кагылмаска иде сиңа... —
Ә синең күзләр күлә:
— Болар бит — сүзләр генә...

* * *

Алсу иреннәрең синең, —
Тулышкан чияләрең
Тирбәлә иде якында —
Яшь идем, тиялмәдем...
Ни мәгънә бу? Үртәвеме
Әллә соң чибәрләрнең?!

...Үз итүләре идеме,
Өз безне, диделәрме?!
Ымсынсам да, уй-хыял тик
Яндырды иреннәрне.
Калкынды озак чияләр,
Нурланды, алсуланды,

Тирбәлде тойгы җилендә,
Ә кайчак моңсуланды...
Әрсез итмичә, Матурлык
Бәхетле иткән җанны!

Шул мизгелләрне сагынам,
Ут яна чигәләрем.
Хәзер дә күтәм — чакырып
Күлгәнен чияләрнең...
Үткәнме яшьлек? Өз дигән
Ымы юк чибәрләрнең...

Аһ, алсу чияләрем!..

* * *

Кыйчандыр Син саксыз тибәргән җанны
Кем ул танып, сөеп назлады аны? —

Кем — кошыма өмет канаты куйды?
Дәртләндерде, биекләргә очырды?

Салкын көннәрендә назлап җылытты?
Хуҗа тән — яралы кошын онытты...

Шонкармы бүген исеме? Башкамы?
Заты бүтән, горур: күккә ашкан ул!

...Бүген тагын юлымда Син очрадың...
Бар дөньямны сихри ямьдә нурладың.

Тагын (гаҗәп!) тәндә тойдым Кош-җанны...
Әллә Синме миңа кайтардың аны? —

Кайчандыр үзең ят күргән шул җанны?

* * *

Озын чәчләр дулкын-дулкын... Юлмы ул?
Ике күзең — ике тирән күлме ул? —

Тирбәләме якты урман шәүләсе?
Идел-йорт хисенең синме кәгъбәсе?!

Йә син Болгар асыллары нәселеннән
Серме — Сөнгә, Чирмешәнгә яшеренгән?

Әллә бу наз Кыпчактан кайтавазмы?
Яшь ирәннәргә чакыру-авазмы?

Мишәр... нугаймы шәҗәрәң, матурым?
Нинди мирас булып җанга атылдың?

Чәчләрең — тозак: мин аяк-кул җуйдым.
Миңеңә карап, илемә юл җуйдым.

Күзләрең тирәнлегендә күңелем,
Буй кыз, сиңа фида булсын гомерем.

Бер гыйбрәтме Гаташыңның язмышы?
Читтә, бәлки, ил гаменнән җан, хисе?

Сөембикәләр варисы — Милли яр!
Үзең юнәлт дөрес юлга — алып бар?!

## Зәйтүнә Мәүлүдова-Рәсулевага
### газәл-хат

Зәйтүнә ханым! Сезгә бу —
сезгә, Зәйтүнә ханым.
Гасыр ахырыннан барсын —
тагын мәдхия яздым.

Тукайга сез биргән илһам
чаткысы төште безгә —
Кабындым, сезне яд итеп,
ихластан уйный сазым!

Гүзәллеккә табынмаган — халкымда
кайсы шагыйрь?
Сезгә татар күңелендә бар энҗе-сүз
хәтта аз, дим...

Байрон, Пушкиннар яр сөйсә —
шул хакта күпме роман!
Сезнең хакта да ахрысы
бер матур әсәр лязем?!

Сөенерме рухыгыз тик —
борчыйсыз, димәссез бит?
Мин горур: татарча хисем,
Тукайча газәл яздым!

Халкым күңелендә бергә сез —
Тукай һәм аның яры...
Моннан да зур милли тәхет —
бармы, Зәйтүнә ханым?!

## Бишенче каләм. Синең хат

— Ниндидер көч каршы ахрысы миңа:
Бер-бер артлы дүрт (!) каләм белән сиңа
Язмак булдым — тыңламады берсе дә...
Бишенчесе бары буйсынды миңа...
Нинди көч соң? Ул нигә каршы миңа?

Әллә уйларым томанлы булганга
Сәер хәлләргә юлыгам бу айда:
Утырсам, арба-автобус туктала
Йә көтмәгәндә нәрсәмдер югала...
Гаҗәп түгелме? Аптырыйм шуңа да.

Яшерен бер көч... миннән үч ала бугай
Сине онытмавым өчен гел шулай...
Югыйсә, әйт, ни сәбәп бар соң моңа:
Шул каләмнәргә кадәр каныксын да!
Яшерен бер көч... көлә, шаяра бугай...

Нидер урти эштә, өйдә һаман да...
Ямь табалмыйм бу язда Казанда да.

Китәр идем еракларга... ә кая?
Шул каршы көч көтсә мине анда да:
Качып булмаса аңардан кайда да?!

Каләмем, дим, инде син дә сынма, йә,
Түз инде тагын беразга, тыңла, йә...
Бел: кыен бәхетен юллап язганда,—
Гүя соңгы өметенә таяна,—
Хәтта каләмгә ялвара Кыз бала...
... Карышма, бишенче каләм, ташлама!

## Борынгы касә

Саксыз тию ярамыймы чын-чыннан?
Бәллүр касә! Таныйм ләса чыңыннан!

Затлы бәллүр! Зеңли, җырлый ул әнә,
Путасында утлы күзме? — сүз яна:

— Шәраб эчмәгез сез миннән, гашыйклар:
Җанда сезнең ачы-татлы сагыш бар.

Сезнең өчен дәва — бәллүр чыңлавы,
Сусаганда кандырачак чынлап ул!

Түгелмен мин Җәмшид, Хәйям касәсе,
Төбемдә, бел, Мәҗнүн-Кайс күз яше;

Анда Ләйлә, Ширинnәрнең моң, уты,
Әбелхәят түгел, мәхәббәт суты...

Бәллүр — тулы, түгәрсез, кагылмагыз —
Сүзсез моңымны ерактан тыңлагыз!

Булырсыз хуш, исереп шул чыңымнан:
Ихлас йөрәкләргә мирас җырымнан...

# Ләбиб Лерон

## Болгавыр заман шагыйренә

Туңган йөрәкләргә җылы җитми,
Күңелләрдә назның аз чагы...
Кәгазь көймәләрдә йөзеп килгән
Яз турында бүген яз, шагыйрь!

Толпар сыман томырыла алмый —
Хисләр бүген хәлсез... бәйдәдер...
Яшел шәлен иңнәренә салган
Җәй турында яз син, әй, шагыйрь!

Кеше кебек шәрә чагы уйның,
Ялгызлыкның җанга үз чагы...
Кара җиргә яфрак булып яткан
Көз турында әйтче сүз, шагыйрь!

Боз-сөңгеләр кебек һәрбер кеше —
Бармак чиртсәң, шартлап сынадыр...
Канатлы ат булсаң әгәр бүген,
Кыш турында кешнә син, шагыйрь!

Җир хакында җырла син халкыңа,
Ил турында сөйлә борчылып...
... «Ильич лампасы»нда чебен эзе —
Безнең илдә ул да бер шигырь.

## Гаяз Исхакыйның кайтуы

Хаерчелек, атыш...
Бозык илдә
Тормыш итүләре бик авыр...
Ул киткәндә хәлләр шулай булган —
Бүгенгебез кебек болгавыр!

Ул киткәндә илдән күпләр киткән —
Урыс-яһүд киткән меңәрләп...
Ә татарлар... Кырда иген иккән...
Татар китсә... киткән... берәмләп.

Иген иккән татар үзе өчен,
Урыс өчен иккән — ал-ялсыз...
Язмышына каһәр укый-укый,
Гомер иткән алдау-ялгансыз.

Илдән киткәннәрнең сәбәпләрен
Бетермәсә дә ул төшенеп,

---

Ләбиб ЛЕРОН (1961) — *шагыйрь, «Яңгырның ял көне», «Күрше тавыгы көлә» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Читкә киткән милләттәшен сүккән,
Урыс белән бергә «төшереп»...

Хәер, читкә китмәгәннәрнең дә
Тетмәләрен теткән халык без:
Кирәк чакта — ат без, яки — эт без,
Кирәк икән шома балык без!

...Уйлыйм кайчак: илдән киткән чакта
Ул киткәндер кебек ак атта...
Сизенгәндер сыман, илгә кайту
Насыйп булмас, диеп, кабаттан...

Уйлагандыр, бәлки, киресенчә:
«Кайтып булыр әле ничек тә...»
Ул киткәндер, аның артларыннан
Калганнардыр өреп көчекләр!

«Исән булсак, бер кайтырбыз әле!» —
Дип киткәннәр кайтты яңадан —
Урыс кайтты... Яһүд... Татар гына
Артка калды бераз алардан...

Танк чылбырлары чыңлаганда,
Яңгыраган чакта: айт-два!
Үз иленә кайтты Набоковлар,
Солженицын кайтты... Кайттылар!

Үз кандашы, галим-голәмәсе
Аны саткан чакта ятларга,
Бугаздагы ачы төер булып,
Ватанына кайтты татар да!

Юлсыз Рәсәй буйлап, урап-урап,
Кайткандыр Ул безгә ничекләр...
Ул кайтканны күреп, каршысына
Чиный-чиный чапты көчекләр...

Хәерчелек, атыш...
Кешеләргә
Бозык илдә яшәү бик авыр...
Ул кайтканда хәлләр шулай иде —
Киткәндәге кебек болгавыр!

Ул кайтканда күпләр киткән иде,
Китешләре иде күпләрнең...
...Һәм сизмәде беркем Исхакыйның
Туган җирне Күктән үпкәнен...

## Бердәнбер ил

— Иң зур, иң бай ил! — дип җырга
Юкка, димсең, кергәндер...
Безнең ил ул — гаҗәеп ил:
Дөньясында бердәнбер!

Буш корсагын уа-уа,
Тиле кебек көлгән ил...
Безнең ил ул — алга карап,
Артка таба йөргән ил!

Бүтән илләр белмәгәнне
Үзе генә белгән ил:
Үлә-үлә яшәгән ил,
Байый-байый бөлгән ил...

Пөхтәлектә аерма юк:
Мәскәү ни дә, Чистай ни...
Безнең ил ул — сөрсеп яткан
Чучка сыман чиста ил!

Безнең илдә — бездә генә
Тузан ашый кешеләр...
Безнең илдә генә чери
Амбардагы көшелләр...

Безнең илдә күз яшьләре
Яңгыр булып явала...
Безнең илдә — бездә генә
Кешеләрне савалар!

Кызылтүшне хәтерләткән
Түтиләр һәм абыйлар
Безнең илдә — бездә генә
Кат-кат асфальт ямыйлар!

Безнең илдә генә кеше
Карап «урыс күге»нә,
Катлы-катлы йорт төзи һәм
Катлы-катлы сүгенә!

Безнең илдә чыпчык үлми,
Гүргә керми — үлсә дә...
Кош булып очалмый кеше,
Карга телен белсә дә!

Безнең илдә — бездә генә...
Без үзебез... Без инде:
«Хәерче» — «Мерседес» йөртә,
Хәер сорый президент...

## Без яшибез, әйе...

*Татарстан — Төтенстан...*
РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

Татарстан — Төтенстан...
Ул шулайдыр, әйе;
Без яшибез аска корым,
Өскә төтен җәеп!
Без яшибез, әйе...

Татарстан — Төтәрстан...
Бу да шулай, әйе...
Әле дә Әлмәт төбәгенең
Төти түбәтәе!
Без яшибез, әйе...

Татарстан — Тетрәстан...
Шулайдыр ул, әйе;
Түбән Кама, Чаллы янә
Тетрәп түбәнәйде!
Без яшибез, әйе...

Татарстан — Тотарстан...
Шулай, шулай, әйе;
Үзен-үзе тотып тора —
Кул-аягы бәйле!
Без яшибез, әйе...

Татарстан — Татырстан...
Шулай, дөрес, әйе;
Ничә еллар татый — исни
«Биштән торелгәнне»!
Без яшибез, әйе...

Татарстан — Татарустан...
Шулай. Хактыр. Әйе.
Гибридләнеп, гыйбрәтләнеп
Яткан чактыр, әйе!
Без яшибез, әйе...

Чәчмә әсәрләр

Миркасыйм Госманов

# ЧӘЧЕЛГӘН ОРЛЫКЛАР

## Голҗа татарлары

### Җан азыклары өләшеп

Алтай өлкәсе белән Чүгүчәк һәм Голҗа шәһәрләрендә XIX гасырның икенче яртысында ук татарларның якташлык төркемнәре, дөресрәге, милли мәхәллә булырлык җәмәгатьчелекләре оешып җиткән иде. Чүгүчәк һәм Голҗаларда шул гасырның ахырында ук татар мәхәлләләре өчен мәчет салдыру, балаларны үз ана телләрендә укытырлык махсус мәдрәсә булдыру кирәклеген аңлау шуны күрсәтә. Мәсәлән, 1874 елны Чүгүчәккә Корбангали хәзрәт имамлыкка чакырылган. Аның атасы Халид ага Казан өязе, Әтнә ягындагы Орнашбаш авылыннан Җидесуга килеп, Аягүз шәһәрчегендә яши. Шунда туып үскән, Симидәге татар мәдрәсәсендә белем алган, Бохара якларында да булып кайткан Корбангали Халиди имамлык итү, балалар укыту белән генә чикләнмичә, җирле халыкларның тарихларын өйрәнүгә дә игътибар бирә. Шул максат белән ул Уйгырстанның ерак төбәкләренә сәяхәтләр ясый, төрле чыганакларны җыя, аларны өйрәнә. Аның, «Тәварихы җәридәи җәдидә» һәм «Тәварихы хәмсәи шәркыйә»ише бай эчтәлекле басма китапларыннан тыш, кулъязма-автографлар да сакланып калган хезмәтләре дә тарихилык ягыннан әһәмияткә ия.

Димәк, Корбангали хәзрәт Халиди белән Чүгүчәк якларына тарихи фикер яралгылары да килгән икән.

Шәркый Төркестан җирләренә беренчеләрдән булып «Тәрҗеман» газитәсен алдыручы, аны таратучы, ил хәле турында шул газитәгә материаллар язып торучы да Корбангали Халиди иде. Ул 1913 елны Чүгүчәктә вафат була («Шура», 1913, № 6).

Элә татарлары да XIX йөзнең ахырларына таба үз мәхәлләләрен булдыралар. 1899 елны Бохарада белем алган Малмыж ягы егете Кәшфеләсрар Ваһаповны имам итеп Голҗага алдыралар. Шул елны ук ул татар мәчете (иске шәһәрдәгесе!) янында балалар укыта башлый. Кәшфеләсрар хәзрәт оештырган кадими стильдәге бу мәдрәсә, 1913—1914 елларда җәдид мәктәпкә әверелгәнче, туктаусыз эшләп килә. Җирле уйгырлар арасында да зур абруй казанган Кәшфеләсрар хәзрәтнең («Нугай дамелла багы» хуҗасының) 50 еллык имаматлеген һәм мәгариф эшләрендәге пионерлыгын 1950 елда Голҗа халкы махсус бәйрәм итеп билгеләгән, юбилярны алтын медаль белән бүләкләгән иде

---

Ахыры. Башы 3 нче санда.

(вафаты 1957 елда; аны күмүгә Голҗа халкыннан ун меңгә якын кеше катнаша).

1905 елгы революциядән соң Чүгүчәк һәм Голҗалардагы кадими мәдрәсәләр яңартылу — җәдитләшү белән бергә, Өремче, Торфан-Астана кебек башка шәһәрләрдә дә бер-бер артлы яңа мәктәпләр ачыла башлый һәм бу процесска зур өлеш керткән зыялылар татарлардан була.

1910 елда Чүгүчәктәге Кызыл мәчет янында Гомәр Абдуллинның тырышлыгы белән өч сыйныфлы яңа мәктәп ачыла, Гомәрнең Казан якларында белем алып кайткан улы анда беренче укытучы була. Соңра үсеп киткән бу мәктәп «Гомәрия» дип атала башлый.

1912 елны Өремче шәһәрендәге «Нугай мәчете» янында мәктәп ачылып, укытучылыкка Зиннәтулла әфәнде чакырыла. 1915 елны аның янында өч бүлмәле кызлар мәктәбе дә ачыла. Беренче елны анда 48 кыз бала укый, 1920 елда исә бу ике мәктәп киңәйтелеп, җирле халыклардан уйгыр, үзбәк, казакъ балалары да укуга кабул ителәләр. Мәктәп янында кечерәк кенә махсус китапханә дә эшли башлый. Мәктәп, нигездә, татарлардан хәйрия юлы белән җыелган акчага яши (ТКТ, 26 б.).

* * *

Голҗадагы татар мәктәбенең тарихы, белгәнебезчә, Кәшфеләсрар хәзрәт җитәкчелегендәге мәдрәсәдән башлана. 1910 елларга кергәндә, укучы балаларның саны артканлыктан, аны киңәйтү ихтыяҗы туа. 1913 елны, патша хөкүмәте эзәрлекләвеннән качып, бөтен гаиләсе белән атаклы мәгърифәтче Габдулла Буби Голҗага килгәч, мәктәпне киңәйтү, зурайту эшләре башлана. Искесе урнына 1914 елны ике катлы яңа мәктәп салына (дөрес, астагы катта кибет-магазиннар, өстә уку бүлмәләре була). Шәһәрдәге иң биек бинаның такта идәнле, зур тәрәзәле якты сыйныф бүлмәләрендә дәресләр укыта башлау җирле халыкка аерата көчле тәэсир ясый.

Яңа мәктәпкә «Мәктәбе нур» дигән исем бирелә. Аның хакында соңгы дәвер Уйгырстан тарихчылары болай язалар: «Төрле фәннәрне яңача укыткан, башлангыч һәм урта белем бирә торган бу мәктәп, Элә өлкәсендә генә түгел, бәлки бөтен төньяк Шенҗаң буенча да бердәнбер атаклы мәктәп иде. Бу мәктәптә бер татар балалары гына түгел, бәлки кардәш милләтләрдән уйгыр, үзбәк, казакъ, кыргызларның да балалары укыдылар. Шибә, дөңгәннәрнең дә уллары, кызлары укый иделәр. Хәтта ике кытай кызы да укып белем алган иде» (ТКТ, 27 б.).

Югарыда мәктәпнең кибетләр өстендә урнашкан булуы әйтелгән иде. Шул һәм башка шундый 60 кибетне арендага бирүдән, 20 гектарга сибелгән бидә-клевердан вә тагын хәрәкәттәге башка вакыф малларыннан алына торган файда-килер акчалары әлеге мәктәп өчен тотылган. Шуңа күрә аның бинасы һәрвакыт төзек, уку әсбаплары мул булып, укытучылары да югары эш хакы белән тәэмин ителгән. Ятим һәм ярлы гаиләләрдән чыккан балаларга акчалата ярдәм күрсәтелгән, мәктәп формалары бушлай бирелгән.

Җирле халыкка беренче вакытта «Нур мәктәбе»ндә хөкем сөргән кагыйдәләр, укучыларның тәртибе, аларның бер төстәге матур киемнәр — ак якалы формалар киеп йөрүләре кызык һәм гыйбрәтле булып тоела. Халыкны бигрәк тә ак алъяпкычлы кызларның да, йөзләренбитләрен капламыйча, мәктәпкә йөрүләре гаҗәпләндерә (уйгыр хатынкызлары, гадәттә, пәрәнҗә ябынып йөргәннәр).

Әйе, Габдулла Бубиның Голҗага килгәч башкарган эшләренең иң зурысы элекке татар абыстайлары янына җыелып һәфтияк чәйни торган

берничә вак-төяк «кызлар мәдрәсәсен» бетереп, алар урнына чын дөньяви кызлар мәктәбе ачу була. Мәгърифәтченең язмаларында бу хакта мөһим мәгълүматлар күп. Шулардан кайберләрен күчерү артык булмас.

Яңа мәктәп биналары салынып бетүдән канәгатьлек хисе хасил иткән Габдулла Буби бу эштә тырышлык күрсәтүчеләрдән иң элек бертуган Ситдыйк һәм Шакир Юашевларны, акча белән ярдәм итүче уйгырларны, дөңгәннәрне билгеләп үтә. Аерата Нурахун аксакал дигән дөнгән бае бу юлда башкаларга үрнәк булган икән. «Голҗада менә зур кызлар мәктәбен күрдек. Алла теләсә, озакламаен зур вә ыспай бер кыйраәтханә (китапханә — М. Г.) күрергә дә муафикъ булырбыз»,— дип өметләнә мәгърифәтче (Г. Буби. Кулъязмалар. II т. 13—14 кәгазьләр).

Яңа мәктәптә, мәгърифәтченең үзеннән кала, хатыны Хәдичә дә мөгаллимәлек итә. Укучы кызларга төрле фәннәрдән белем бирү өстенә аларга чигү чигү, кием тегү ише кул эшләре, аш-су әзерли белү буенча да махсус дәресләр оештырылган.

Чыннан да, күп тә узмый, мәктәп янәшәсендә «Нур кыйраәтханәсе» оештырыла. Монда алдынгы карашлы татарлардан җыелган төрле эчтәлектәге китаплар, Казан, Оренбург якларында чыккан күпсанлы журналлар, гәзитәләр, шулай ук чит илләрдән алдырылган төркичә басмалар туплана. Һәр нөсхәгә басылган түгәрәк мөһернең кырыйларына: «Голҗадагы барлык мөселманнар өчен гомуми», уртасына исә «Нур кыйраәтханәсе» дип язылган була. 1988 елда чыккан китапта: «Мондый китапларны хәзер дә Голҗа кешеләренең кулында очратырга мөмкин»,— дип раслана (ТКТ, 28 б.).

Г. Буби, әлбәттә, җирле халыкта кызлар укыту гадәте булмаганлыгын билгеләп үтә: «Голҗада кызлар укытырга нугайлардан башка әһәмият биргән кеше юк» (Г. Буби, 53 кгз.). Шуңа күрә фикердәшләре белән ул үзе ирешкән казанышларның тарихи әһәмиятен махсус билгели: «Бу көнгә кадәр Голҗа халкының төшенә дә кермәгән һәм башка йирдә дә мөселманнар арасында бик сирәк сигез сыйныфлы кызлар мәктәбе салдылар. Бу бина, бу көн Голҗадагы иң беренче биналардан хисапланадыр. Түбәсе тимер, яктысы күп, коридоры киң. Хәзерендә монда сиксәннән артык кыз укып ятадыр. Һәммәсе диярлек нугай (кызлары)» (Шунда ук, 56 кгз.).

Габдулла Бубиның ни дәрәҗәдәге ихлас мәгърифәтче һәм халыкка аң-белем бирүдә милли чикләнгәнлектән азат, сүзнең чын мәгънәсендә хөрлек тарафдары, табигый гуманист булуын аның хыялларын, ният-өметләрен чагылдыра торган түбәндәге сүзләре дә ачык күрсәтә: «Әгәр сыйхәтем ару булып, дәхи өч-дүрт ел монда торачак булсам, бик ихтимал, безнең бу мәктәптә бәлки таранчы вә дөңгән кызлары да күбәер вә, бик ихтимал, бәлки нугай кызлары кебек аларның кызларыннан да байтак кына мөгаллимәләр йитештереп булыр. Менә шул вакытта, мин бик нык ышанам, таранчылар белән дөңгәннәр арасында да тәртипле мәктәпләр ачылыр, тәрбияле вә мәгълүматлы аналар йитешер... Мин шуны көтәм. Шуның булачагына ике йирдә ике — дүрт кебек ышанам. Вә шушы өмид вә иманым сәбәпле һәрбер авырлыкларга түзеп вә һәрбер манигъларны (киртәләрне — М. Г.) атлап иҗтиһад итәм. Кем белә? Ихтимал, бәлки бу төрек вә татарлар ватаны аслисының да (асыл ватанының да — М. Г.) якты кояш күрер, үз хокукларын кайтарып алыр вә иске замандагы кебек зур шәүкәтләр сахибе булыр көннәре ерак түгелдер. Безгә фарыз — иҗтиһад. Тәүфикъ — Алладан» (Шунда ук, 56 а, б кгз.ләр);

Патша хөкүмәте тарафыннан панисламист һәм реакционер сыйфатында эзәрлекләнгән, төрмәләргә ябылган, совет хөкүмәте вакытында да милләтче һәм идеалист дип тамгаланган, исеме дә тыелган олуг мәгърифәтче Габдулла Бубиның бу изге теләкләре, тулысынча булмаса да, өлешчә тормышка аша (Шул ук Шәркый Төркестан — Уйгырстан

җирләрендә). Гәрчә Буби ачкан татар кызлар мәктәбе 20 елларда яңадан ирләр мәктәбенә кушылса да, 30 елларда Голҗада ачылган уйгыр кызлар мәктәбе 50 елларга кадәр аерым яшәп килде. Шушы мәктәп үрнәгендә башка шәһәрләрдә ачылган уйгыр кызлар мәктәбенең гомум саны дистәдән артык иде дип әйтсәм, дөреслеккә әллә ни хилаф булмас. Моның шулай икәнлеге алда китереләчәк материаллардан да күренер.

* * *

Әлбәттә, Голҗа ягында гомумән татарлар һәм бигрәк тә Габдулла Буби тернәкләндереп җибәргән бу прогрессив башлангыч, тәрәккыят хәрәкәте каршылыксыз гына бармый. Бигрәк тә кызларны укыту мәсьәләсе җәмәгатьчелекнең консерватив катламнарында каршылык тудыра. Үзләрен илнең әхлакый терәге, ата-баба йолаларының сакчысы дип ышанган кадимче руханилар (уйгырлар арасында андыйлар буа буарлык иде) «Нур мәктәбен» күзәтеп, аны контроль астына алырга омтылалар. Кайбер мөтәгассип татарларның өстерүләре аркасында кулларына камчы, каеш тоткан кара муллалар вакыт-вакыт татар мәктәбенә килеп, укытучыларга бәйләнеп, уку бүлмәләрендәге карталарны ертып, яңача җиһазларны туздырып йөриләр. Каршылык күрсәткән мөгаллимнәрнең чалбарларын салдырып, «дөрә сугарга» — тупас рәвештә кыйнарга да күп сорамыйлар. Кайвакытларын, баштарак, гарьләнгән укытучылар һәм өлкәнрәк шәкертләрнең үзләре, урындыклар күтәреп, басып керүчеләрнең өсләренә ташланып караганнар. Әмма тиздән саклануның күпкә уңайлырак чараларын да тапканнар: фанатикларның килүләре хакында сигнал-хәбәр булуга ук, элеккечә качып-посып йөрмичә, Казан басмасы китапларын яшереп куеп, кычкыра-кычкыра тәкбир әйтергә, йәисә берәр доганы ятларга тотынганнар. Махсус дин дәресләре дә үтә торган укучыларга мондый күчешләр артык кыен булмаган, билгеле (ТКТ, 29 б.).

Малай чакта шундый «инспекцияләр»нең берсе ничек тәмамлану хакында бер истәлек тә ишеткән идем. Рәсәйдән китерелгән географик хариталарны ертып бетерүдән, йәисә, аларны тиз-тиз яшерүдән туеп беткән татарлар Истанбулда басылган хариталарны юнәтәләр. Бер көнне, тикшерүчеләр килеп кергәч тә, мөгаллим абый аптырап калмый. Әле генә бармаклары белән күрсәтә-күрсәтә Урал тауларының мәгъдәннәре — җир асты байлыклары хакында сөйләп торган укытучы, кулын чак кына елыштырып: «Мәккә-и-мөкәррәмәгә тауаф кылыр өчен безнең бабаларыбыз менә бу юллардан барганнар,— дип, Идел буйлап төшеп, Кара диңгезләрне «кичә», аннары — Менә бу Шам шәрифләре булыр. Монысы — Мәккә, ә бу Мәдинә-и-мөнәүәрә»,— дип, тантаналы рәвештә тынып кала. Ни ишетүенә ышанмаган дамелла, ягъни «инспекция» башлыгы, харита янына килеп, бармак башы төртелеп торган җиргә карый. Анда, чыннан да, мөселманча итеп, Мәккә вә Мәдинә дип язылган була. Дамелла аңына килеп өлгергәнче мөгаллим абый әлеге харита өстенә Төркиядән килгән, уртасында Кәгъбә сурәте төшерелгән төсле шамаил элеп куя. «Мәккә-и-мөкәррәмәдә пәйгамбәремез Мөхәммәд галәйһиссәламнең мөкаддәс мәркаде (кабере — М. Г.) торыр. Без мөселманлар өчен Бәйтулла (Алла йорты — М. Г.) шушы булыр!» — ди. Аннары күзләре белән укучыларга ишарәләп, бармаклары белән Кәгъбә өстендәге язуга төртә. Ишарәне аңлап алган укучылар кычкырып укый башлыйлар: Ля иляһа илла-Аллаһ...

Мондый тапкырлык күрсәткән мөгаллимнең исемен сорашмаганмын вакытында. Әмма 40 еллардагы Голҗа татар мәктәбенең һәр бүлмәсендә диярлек төрле хариталарның ачыктан-ачык һәм гел исәнимин эленеп торуларын әле дә хәтерлим.

* * *

Габдулла Бубиның изге теләкләре тормышка ашу мәсьәләсенә кайтсак, монда сүзне күбрәк Уйгырстан авторларының үзләренә бирү хәерләрәк (документаль тегәллек тәэмин ителсен өчен чыганакларны тегәл күрсәтеп барыйк).

Татарларның Шәркый Төркестанда күпләп төпләнүләре һәм мәктәп-мәгариф эшләренә актив катнашулары ул якларда феодаль тәртипләрнең какшап, буржуаз-демократик мөнәсәбәтләрнең тернәкләнә башлаган чорына туры килүе махсус билгеләнгәч, «Татарларның кыскача тарихы» дигән китапның авторлары мәсьәләгә мондый гомум «кереш» ясыйлар: Уйгырстанның «төрле җирләрендә беркадәре дини мәктәпләр булса да, аларда фәнни тәгълим-тәрбия бирелми иде. Мәгърифәт сөюче татар зыялыларының көчләре һәм тырышлыгы аркасында мәктәпләрдә фәннәрне яңача укыту эшләре барлыкка килеп, заман таләбе канәгатьләндерелде. Мондый яңача укыту «җәдит» дип атала иде. Шулай ук җәдитчә тәгълим-тәрбия алган татар мәгарифчеләренең татарлар тарафыннан ук Казан вә башка җирләрдә нәшер кылынган дәреслек китапларының да Шенҗандагы төрле милләт халыкларының яңа мәгарифләрен барлыкка китерүдә уйнаган роле гаҗәп зур булган иде. Татар мәгърифәтчеләре җан-тән белән тырышып, һәртөрле милләт балаларын укытып вә тәрбияләп, Шенҗандагы башлангыч һәм урта мәктәп мәгарифенең тәрәккыйсе өчен зур өлеш куштылар» (ТКТ, 30 б.).

Мәсьәләне, әлбәттә, уйгыр җирләренә татарларның үзләре килүләренә генә кайтарып калдырырга ярамый. Урыннарда ихтыяҗ һәм таләп дигән җирлекнең барлыкка килүе дә зарур иде. Мәсәлән, XIX гасырның 70 елларында ук Көньяк Уйгырстандагы Артыш шәһәре тирәләрендә беренче дөньяви мәктәп оештыруга талпынып карау, Әкисак дигән җирдә заманча мәктәп ачып җибәрү факты шуны күрсәтә. Бу идеяне алга сөрүчеләр, беркадәре тормышка ашыручылар Хөсәен һәм Баһаветдин исемле ага-энеле, чит илләрдә, җөмләдән Төркиядә булып кайткан ачык фикерле егетләр булалар. (Соңрак алар Мусабаевлар дигән фамилиядә дан казанган атаклы байлар иделәр). Мәктәпләр эшли башлауга ук алар татар мәгърифәтчелеге торышын, казанышларын өйрәнү өчен, Казанга махсус кеше җибәрәләр, кулланмалар, үрнәк программалар алдырталар. Бер уңайдан Казанда яхшы белем алган татар зыялыларыннан Сәлахетдин әфәнде, Мөкәррәмә һәм Мөшфика ханымнар мөгаллимлеккә чакырылалар (ТКТ, 30 б.; монда һәм алга таба кеше исемнәре чыганактагыча фамилиясез китерелә).

1910 елларда тәрәккыйпәрвәр уйгыр зыялысы Максуд Мөхиди дә Россиянең төрле җирләренә сәяхәт ясый, Казан татарларының мәдәни тормышлары, рухи дөньялары, ирешкән казанышлары белән якыннан таныша. Иленә кайткач, ул заманави мәктәп ачу эшенә тотына һәм татар зыялыларыннан Хәйдәр әфәндене, берничә кеше белән бергә чакырып алып, Торфан-Астанада уйгыр балаларын укыттыра башлый. «Бу мәктәптә үтелә торган дәресләр иске мәдрәсәләрдән бик нык фәрекъ кылганлыгы өчен бер төркем мөтәгассипләрнең каршылыгына очраган иде. Бу мәктәптә укыла торган дәресләр ана теле, хисап, җәгърафия, табигать белеме, кул һөнәре, дин сабаклары вә башкалардан гыйбарәт булып, шигърият белеме дә үтелә иде. Шигърият дәресләрендә Габдулла Тукайның шигырьләре җыр тексты урнына кулланыла иде. Татар мәгърифәтчеләре, әллә нинди кысуларга карап чигенмичә, мөтәгассип көчләрнең киртәләрен җимереп, аерым укучылар белән дә индивидуаль рәвештә төрле фәннәр буенча дәресләр алып бара иделәр».

Максуд Мөхиди 1919 елда Чүгүчәктә яшәүче татар мөгаллимнәреннән ирле-хатынлы Мөхибулла әфәнде белән Гөләндәм ханым Хәбибуллиналарны Торфан-Астанага күчереп китереп мәктәпкә урнаштыра. Гөләндәм ханым мәктәп янындагы аерым бер йортта кыз балалар

укыта башлый. Аңардан беренче сабакны алган кызларның үзләре соңрак төрле уйгыр кышлакларында башлангыч мәктәпләрдә эшлиләр (ТКТ, 30—32 бб.).

Болардан яңа заман уйгыр мәгарифчелеге тарихында Гөләндәм ханым аерата бер урын биләп тора. Чөнки Шәркый Төркестан тарихында уйгырча махсус кызлар мәктәбе оештыру, кызларга яңача белем бирү тәҗрибәсе аның исеменә бәйле. (Югарыда бер күрсәтелгәнчә, Г. Буби өмет иткән андый уйгыр кызлар мәктәбе 30 елларда Голҗада да ачылган иде). 1921 елны ире үлеп, яңадан Чүгүчәккә кайткач та, Гөләндәм ханым ике кызлар мәктәбе ача. Аларның берсенә уйгырлар «Мәктәбе Гөләндәмия», икенчесенә «Мақсудия» дип исем бирәләр. Хәзерге уйгыр авторлары 40 елдан артык мөгаллимәлек иткән, яшьләргә җан азыгы өләшкән Гөләндәм ханымнан кимендә 6 меңгә якын кыз баланың дәрес тыңлавын, үз нәүбәтендә болардан йөзләгән мөгаллимәләр үсеп чыгуын икърар итәләр, шуңа күрә аны «яңа уйгыр мәгарифчелегенең сөекле анасы» дип атыйлар (ТКТ, 31, 33—34 бб.; Т. Каһһари. Гөләндәм-мәгърифәтче ана.— Сөембикә, 1991, №9; Абдулла Талип. Уйгыр мәгариф тарихыннан очерклар. Өремче, 1986, һ. б.).

Уйгыр мәктәпләрендә озак еллар эшләгән татар мөгаллимәләреннән Зәйнәп Габитова да игътибарга лаек. 1920—1926 елларда ул Голҗа татар мәктәбендә укыта. Аннары шундагы уйгыр, үзбәк, казакъ мәктәпләрендә укытып, 1963 елны 43 еллык стаж белән пенсиягә чыккан. Аңар бирелгән рәсми характеристикада карт мөгаллимәнең әлеге 43 елдан 25 елы мөдирлек эшенә багышлануы махсус күрсәтелә (документның бездәге ксерокүчермәсе буенча).

1910—1920 еллар арасында Шәркый Төркестанның көнчыгышындагы Кумул (Хами), Гучуң, Фукаң, төньягындагы Алтай, Җиминәй, Бурылытай, Дөрелбеҗен, Кубусар, Күктугай ише шәһәрләрендә ачылган яңача башлангыч мәктәпләрдә дә эшләүче укытучыларның күпчелеге алдынгы карашлы татар кешеләре булган һәм алар нигездә «уйгыр, казакъ, кыргыз кебек тугандаш милләтләрнең балаларын тәрбияләгәннәр» (ТКТ, 31—32 бб.).

Күп еллар буена төрле җирләрдәге уйгыр, казакъ һәм кыргыз мәктәпләрендә эшләгән татарлардан хәзерге уйгыр мәгарифе тарихчылары Зәйнәп Җылкыбаева, Рәшидә Шаһидова (Борһан Шәһиди хатыны), Талига апа, Нуретдин әфәнде, Әхмәт Фәрит әфәнде, Шаһивәли әфәнде Вәлиев һ. б. бик күпләрнең исемнәрен хөрмәтләп, олылап телгә алалар (ТКТ, 34-36, 37-38 бб.).

Болардан Нуретдин әфәндeнең эшчәнлеге аерата игътибарга лаек. Ул 20 елларда Фукаң нахиясендә (өязендә) казакълар арасында укытучылык итә, 1935 елдан башлап Фукаң базары дип аталган өяз үзәгендә урта мәктәптә кытай балаларына уйгыр теле укыта. Укытучысыз калган уйгыр балаларына аерым дәрес бирә. Шушы максаттан чыгып, мәчет янындагы бер бүлмәне үз көче белән ремонтлап, Фукаң базарындагы унбер гаилә уйгырлар өчен кечтеки генә мәктәп оештыра. Бу мәктәпкә Базардан читтәге уйгырларның, казакъларның балалары да агыла башлыйлар. 1936 елны әлеге бер бүлмәле мәктәп ике сыйныфлы итеп үзгәртелә. 1939 елны ул дүрт сыйныфлы, аннары алты сыйныфлы мәктәпкә әверелә. Шул рәвешчә төрле милләт халыклары арасында киң абруй казанган Нуретдин әфәнде 50 елларда Фукаң өязенең рәисе дә булып сайлана. Ул 1966 елда улә (ТКТ, 36—37 бб.).

Кашгар, Аксу якларындагы халыкка гомер буе аң-белем, мәгърифәт орлыклары сибеп йөрүче татар кешесенең берсе — Әхмәт Фәрит әфәнде. Ул 30 елларның башыннан алып уйгыр мәктәпләрендә укыта. 1934 елны Аксу шәһәренә килеп, укытучылар әзерли торган дарелмөгаллимин ачуга, анда күпләгән педагоглар тәрбияләүгә сәбәпче була. Шул якларда яшәүче кыргызлар арасында бер мәктәп тә булмавын белгәч, махсус эзләп, Түләмеш, Ибрай, Талип һәм Муллакорбан исемле дүрт

кыргыз егетен укыта. Башлангыч мәктәпләрдә укыта алырлык булып җиткәч, Әхмәт Фәрит әфәнде аларны үз исәбенә баштанаяк яңача — шәһәрчә киендереп, мөгаллимлек итәр өчен Акчи дигән җирдәге кыргызлар арасына җибәрә. Алар икешәрдән бүленеп, Караболак һәм Суташ дигән җирләрдә ике мәктәп ачалар. Дүрт-биш елдан Аксудагы дарелмөгаллимингә егерме малай алып киләләр. Хәзерге көндә Акчи ягы кыргызлары арасында егермедән артык мәктәп эшли икән (ТКТ, 37—38 б. б.).

Нуретдин әфәнденең мәктәп өчен бүлмә ремонтлауда, Әхмәт Фәрит әфәнденең яңача кием пропагандалау максатыннан үз акчасын тоту фактларын очраклы күренеш дип кабул итмик. ТКТ да мондый хәлләрнең башка мисаллары да бар: «1938 елны, Голҗа шәһәрендә уйгыр мәктәбен салган чакта, биш сыйныф бүлмәсенә җитәрлек агач, такта һәм ишек-тәрәзәлек материаллар юкка чыгудан, уку башланганчы мәктәпнең төзелеше бетмәү куркынычы туа. Бу хәбәрне ишеткән алдынгы фикерле татар Фәрит Габитов үзенә йорт салдырыр өчен әзерләп куйган материалларыннан алты метр озынлыктагы 49 бүрәнә, озынлыгы биш метр һәм калынлыгы дүрт сантиметр 100 данә такта, шулай ук биш ишек, ун тәрәзә рамын мәктәпкә җибәрә. Шулай итеп, ул әлеге мәктәптә укуларның үз вакытында башлануын тәэмин итә» (ТКТ, 39 б.).

Шәркый Төркестан халыкларының мәгарифчелеген үстерү, югары күтәрү юлында фидакярләрчә тырышып эшләгән илдәшләребезнең исемнәрен тагын да бик күпләп санап булыр иде. Ләкин йомгак өчен сүзне уйгыр халкының үз вәкиленә бирик. Күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм галим Абдулла Талип үзенең 1986 елда Өремчедә басылып чыккан «Уйгыр мәгариф тарихыннан очерклар» исемле китабында болай нәтиҗә ясый: «Яңа уйгыр мәгарифе өчен көрәш юлында тугандаш татар халкының угыл-кызларыннан чыккан укытучы зыялыларның һәм гомумән бер төркем мәгърифәтчеләрнең керткән өлешләре, түккән тир вә каннары аз түгел. Аларның бу өлешләре уйгыр мәгарифе тарихында мәңгелек урын алырлар. Бу шанлы хезмәтләре өчен уйгыр халкы аларга үзенең хисапсыз бурычлы икәнлеген белдерә» (ТКТ, 39 б.).

* * *

Габдулла Бубиның икенче бер теләге, күргәнебезчә, үзе нигезләгән яңа мәктәпнең гөрләп үсүен күрү иде. Шул ук вакытта ул Голҗадагы үз гомерен өч-дүрт ел белән чикләп, төш күргәндәй, дөрес юраган икән. Февраль революциясе җиңеп, патша хөкүмәте җимерелүгә үк, ул туган илгә ашыга. Ә монда репрессияләр, Гражданнар сугышы, ачлык... Әмма Голҗада да Унҗиденче елдан соң зур үзгәрешләр барлыкка килә; мәктәп тотып торучы татар җәмәгатьчелеге дә әлеге һиҗрәт дулкыннары нәтиҗәсендә сан ягыннан да, сыйфат җәһәтеннән дә нык үзгәрә. Моңарчы зур мәхәллә генә булып яшәгән татарлар дүрт-биш ел эчендә төгәл бер шәһәр тотарлык дәрәҗәдә күбәяләр. Чыннан да, күп тә узмый, Голҗа, дөресрәге, элекке Голҗаның — «иске шәһәр»нең — көнбатышында яңа шәһәр, Новый город — «Нугай гурыты» үсеп чыга. Ләкин аның хакында махсус сөйләүне киләсе бүлеккә калдырып, шул «яңа шәһәр»нең үзәген тәшкил иткән татар мәктәбе хакында да берничә юл язу зарур булыр.

Габдулла Буби чорында яңартылган, төзекләндерелгән татар мәктәбе 20 еллар башында, укучы балалар саны арткач, тагын бераз киңәйтелә, иске бина янына өстәмә бүлмәләр салына (ТКТ, 32 б.). Әмма тагын ике-өч ел узуга ул да җитми. Шуңа күрә, әлеге татарлар яшәячәк дип аерым салына башлаган «яңа шәһәр»нең планы төзелгән чакта, аның нәкъ уртасында яңа татар мәчете белән мәктәбенең урыны билгеләнгән була. Мәктәпнең кайчан һәм ничек салынуы хакында Габдерәүф Госма-

новның хатирә дәфтәрендә мондый җөмләләр теркәлгән: «1929 ел яңа каланың мәктәбен салуда, беренче булып фундамент салуда, Миркасыйм хаҗи Миршанов, Габделбари хаҗи Госманов, Кәшфеләсрар хәзрәт, Вәлишаһ Галиәкбәрев, Касыйм Фатыйхов һәм йәнә башка байтак татар картлары фундаментны куйган булдылар. Мәктәпне салуда завхоз булып хезмәт кылган Локман Госманов...

Голҗадагы яңа калада татар мәктәбен ачу мәрасиме 1929 елның 3 үктәберендә булды. Мәктәп Фатыйх Алдагаров (Аллаһъяриның — М. Г.) әнкәсенең бәдәлхаҗ акчасына һәм Фатыйх Алдагаровның кушкан акчага салына». (Искәрмә: «бәдәлхаҗ акчасы» дип, үзе ниндидер сәбәп белән хаҗ сәфәренә чыга алмаган кеше тарафыннан аның өчен Мәккәгә баручыга багышланган акчага әйтелә; әгәр андый акчадан файдалана алырлык шартлар табылмаса, билгеләнгән сума башка бәрәр хәйрия максатына да тотылырга мөмкин.)

Моннан күренә ки, яңа мәктәп салу эшен тантаналы рәвештә сиксәнтуксан яшьлек картлар башлап җибәргән булсалар да, аның матди нигезе меценатлыгы белән аерылып торган бер шәхес — Фатыйх Аллаһъяри тарафыннан тәэмин ителгән икән.

* * *

Төзелеш тәртибе, төзеклеге, йорт-җирләренең архитектурасы һәм урамнары буенча Голҗа шәһәреннән бөтенләй аерылып торган бу «яңа шәһәр»нең үзендә дә татар мәктәбе йөзек кашы шикелле иде. Иңе-буе иң кимендә ике-өч йөз метрлы төгәл бер кварталны тәшкил иткән зур территориясенең көнбатышында аның чатыр түбәле мәһабәт бинасы. Планы почмаклап язган русча «с» хәрефе сыманрак. Артык биек булмаган баскычтан менүгә, арба сыярлык зур ишекләр, атлап кердең исә, ат чаптырырлык киң-иркен коридорлар. Аның ике ягында тезелеп киткән ишекләрнең кайсысына керсәң дә, кырык-иллешәр метрлы якты, биек түшәмле сыйныф бүлмәләре. Һәр бүлмәдә икешәр-өчәр зур-зур тәрәзәләр. Икешәр бала утырган парталар, өч рәт булып тезелеп, бүлмәнең яртысын гына алып тора. Гадәттә, уникe яки унбиш парта. Каршыдагы укытучы өстәле артында зур язу тактасы.

Шундый нурлы бүлмәләрнең берсе, әлеге «с» хәрефенең көньяк башындагы иң читтәгесе, бу яктан санадың исә, иң беренчесе, әле дә күз алдында. 1941 елның якты беренче сентябрендә мине, таудан әле генә кайтып төшкән калкан колак кара малайны, шушындагы беренче «А» сыйныфына кертеп утырткан иде. «А» булгач, «Б» сы да бар иде... Үрә катып торган, кыеклап баскан ике-өч таякны сызарга өйрәткән беренче укытучым Гөлбану апай тәнәфестән соң безне «с» хәрефенең бөтенләй икенче башындагы 500 кеше сыярлык мәктәп клубына алып керде. Шундый зур иде ул клуб дигәннәре...

Үзәк ишектән тышка чыксаң, синең алда биш-алты футбол мәйданы кадәре киң-иркен кура-ихата. Аның уртарак төшендә, чыннан да, спорт мәйданнары: ике-өч җирдә волейбол, баскетбол уйный торган урыннар, өч-дүрт турник, ундүрт-унбиш метр биеклектәге кыек яткан, йәисә текә баскан спорт баскычлары. Аннары тагын киң ачык мәйдан, аннары гына хуҗалык урыннары: амбар-складлар. Бер якта йорт-җирне карап, бөтен хуҗалыкны тәрбияләп торучы Бәһрамия апа, аның зур мыеклы ире Әхмәдулла абзый, дүрт-биш баласы яши торган бүлмәләр. Аннан чак кына бире кайтсаң, рәшәткәле койма башлана: ишекләре һәрвакыт ачык капка. Шул капкадан кура аша узып көньякка атласаң, яшелгә буялган бер кечерәк ишеккә җитәрсең. Ләкин анда без кермибез, чөнки аның артындагы кечкенә ихатада гаиләсе белән мулла абзый тора. Аның йорты яңа татар мәчете янында.

Әлеге ишеккә кермибез дип әйтүнең сәбәбе шунда, ул ишектән атнага бер-ике мәртәбә дин дәресләре укытыр өчен килә торган мулла абзый үзе йәисә аның абыстае чыга иде. Ләкин күп вакытта башлангыч сыйныфларда җиңелләп кенә укытыла торган дин дәресләрен кыска җиңле күлмәкләр кия торган яланбашлы мөгаллимә апаларыбыз үзләре дә уздыралар иде. Шуңа күрә әлеге ишек артында торган муллаларны яхшылап хәтерләмим дә. Башта балалар арасында «күзлекле мулла» дип кушамат алган, гел кара күзлек белән йөрүче бәләкәй карт иде кебек. Аннары «елак мулла» булды бугай. Аның нечкә тавышы сөйләгәндә гел калтыранып тора иде. Аннары... хәтерләмим. Ә менә мәзинлек итүче Сәхиулла картны бер дә онытасы юк — шәп балыкчы иде ул. Үсмер чакта, Элә дәрьясы буена барып, көннәр буена бер балык та эләктерә алмый йөргән вакытта, чалбар балакларын төреп, яр буенда йөгереп йөргән кечкенә сакаллы Сәхиулла мәзинне күрсәң, бел дә тор: ун-унбиш маринка балыгын «чылбырлап» куйган булыр ул! Шулай ук илленче елларның башында «коммунист мулла» дип дан казанган Салих хәзрәтнең исеме дә хәтердә сакланган.

Дөрес, югарыда исеме кат-кат телгә алынган «нугай дамелла» — Кәшфеләсрар хәзрәт тә исән иде бу елларда. Ләкин ул «иске шәһәрдә» яши, татар мулласы булуга караганда, күбрәк гомум-шәһәр хәзрәте дә иде. Аның яки дини яктан шактый белемле, карыйлык — Коръәнне яттан укырлык хәлгә ирешкән уллары «яңа шәһәр» татар мәктәбенә килеп, дин дәресләре укытып йөрүен хәтерләмим дә, ишетмәдем дә. Кыскасы, бу мәктәптә уку программасы 30 еллардан ук нигездә дөньяви булып, дин дәресләре исә бик үлчәнгән, нык уйланган чамада укытыла иде.

* * *

Уку программасы дигәч тә, мине бүгенгә кадәр гаҗәпләндерә торган бер мәсьәлә бар. Ул ике, хәтта өч язулылык мәсьәләсе. Әлеге беренче сентябрь көнне Гөлбану апа өйрәткән төз һәм кыек сызыклар белән артык маташмадык — чын хәрефләрне дә өйрәнә башладык. Күп тә узмый, яңартылган гарәп әлифбасы нигезендәге чын татарчаны укый да, яза да белә идек.

Әмма дәреслекләрнең күпчелеге шул елларда Казанда басылган китапләр булганга, «урыс хәрефләре» белән басылган китапларны да — әлифбадан, туган телдән, хисап китабыннан башлап — дәрес саен диярлек укыдык. Андый китаплар җитмәгән чакта, элегрәк алдырган латинчасыннан да файдаландык. Укыганда шундый русча яки латинча басылганнарын уң яктан башлап укыйбыз, язганда исә, сулдан уңга борып, үзебезчә — татарча язабыз. Буталмадык та, адашмадык та. Нинди хикмәтле методика белән укытканнардыр, анысы хәзер дә минем өчен сер...

Голҗа татар мәктәбенең дәреслекләре хакында сүз чыккач, аның укытучылары тарафыннан ике уку китабы нәшер ителүе хакында да әйтмичә мөмкин түгел.

Боларның берсе 1935—1936 елларда төрле дәреслекләр нигезендә Малик Биктимирев төзегән «Җәгърафия» китабы, икенчесе «Туган тел» дәреслек-хрестоматиясе иде. Соңгысы революциягә кадәр Казанда икеөч тапкыр нәшер ителгән «Туган тел» материалларын файдалану, аларны орфографик яктан нык эшкәртү ысулы белән басылган иде. Казандагы өлгесеннән үзгә буларак, Голҗада Хөсәен Таранов матбагасында басылган «Туган тел»нең орфографиясе 1921 елдан соң гамәлдә булган язуыбыз кагыйдәсенә тулысынча буйсындырылган, шуңа күрә куллану өчен гаять җайлы иде. Өченче-дүртенче сыйныфларда үзем укыган шул ки-

тапның башы-ахыры өзелгән бер нөсхәсе хәзер дә шәхси китапханәмдә саклана.

Хәрефләренең матурлыгына караганда, аны, һичшиксез, Казанның элекке мәшһүр басмаханәләренең берсендә генә эшләнгәндер, дип уйларга мөмкин. Әмма бер полиграфик үзенчәлеге аның бары тик Голҗадагы типографиядә басылуын «фаш итә». Ул — кыска әйтелешле «ы-э» авазларын белдерә торган хәреф урынына асты-өстендә бернинди нокталары булмаган «бер теш»нең кулланылуы. «Б», «и» хәрефләренең сүз уртасындагы, мәгәр нокталарын җуйган шәкеле шикелле. Мондый хәреф төре бары яңа заман уйгыр язуы өчен генә характерлы. Әмма тел-грамматик җәһәттән ул «Туган тел» китабы саф татарча, төзек әдәбичә яңгырый иде.

Голҗадагы «Нугай гурыты», ягъни «яңа шәһәр» татар мәктәбен бүген болай авыз суларын агыза-агыза тасвирлавым ул чаклардагы, шул мәктәптә өч-дүрт ел укып йөргән заманнардагы тәэсоратым нәтиҗәсе түгел, әлбәттә. Ул вакытларда миңа әлеге мәктәп «шулай булырга» тиеш сыманрак күренә иде. Дөрес, 50 елларның башында, «иске шәһәр»дәге элекке татар мәктәбендә дә булганым бар. Бу вакытларда кибетләр өстендәге мәктәп «сыйныфларында» әллә нинди хөкүмәт конторалары утыра иде. (Татар җәмгыятенең хосусый милеге булган ул кибетләр, аларның өстендәге бүлмәләр һаман арендага биреләләр — керемнәре дә татар мәктәбе файдасына тотыла иде.) Миңа аларның коридорлары тар, бүлмәләре дә кечкенә булып тоелган иде. Үзем укыган яңа мәктәп белән чагыштырганда, байтак кайтыш һәм, гомумән, бик җайсыз иде ул бина. Ни кура-ихатасы, ни спорт мәйданнары дигәндәй. Өстәвенә, әйләнә-тирәдә кибетләр, сәүдәгәрләр — гомумән, базар... Хәзер менә Габдулла Бубиның 1914 елда зур мактаныч белән язылган сүзләрен, Уйгырстан авторларының шул «иске шәһәр» татар мәктәбенә биргән югары бәяләрен кат-кат укып утырам. Үзем елмаям: һәр чорның үз бизмәне, үз күзлеге. Әмма миңа кайчандыр «әллә ничек һәм кайтыш» булып тоелган иске мәктәп, тәптәнрәк уйласаң, хәзер мин мактап тасвирлаган чыннан да нурлы мәктәпнең нигезен тәшкил иткән икән ләбаса!

* * *

Безнең халыкның яңа җирләргә килеп күпләп урнашулары белән үк мәктәп-мәдрәсә оештырырга тырышулары, шул юнәлештә кыска вакыт эчендә зур казанышларга ирешүләре, минемчә, аның бай рухи һәм тарихи традициясеннән килә. Ул традиция халкыбызның элек-электән үк укый-яза белүгә омтылу, аң-белемгә, төрле гыйлемнәргә күңелдә хөрмәт асрау шикелле күркәм сыйфатларына барып тоташа. Чыннан да, татар барып чыккан җиргә аның язма теле белән үз китабы да барып җитә. Халыкның үзе никадәре таралган, ил һәм дөнья буйлап сибелгән булса, аның кулъязма һәм басма китаплары да шундый ук язмышка дучар ителгән. Шушы күренешне раслый торган бер-ике мисалга кыскача гына тукталып узам.

Югарыда Шәркый Төркестан якларына беренче төркичә басма сүзне, «Тәрҗеман» гәзитәсен алдыручы, аны пропагандалаучы Чүгүчәк имамы Корбангали Халиди икәнлеген әйткән идем. 1905 елдан соң чыга башлаган күпсанлы татар гәзитә-журналларын актара башласагыз, аларның күпчелегендә диярлек Голҗадан, Чүгүчәктән һ. б. Уйгырстан шәһәрләреннән алынган хәбәрләрне очратырга мөмкин. Димәк, ул якларда яшәүче милләттәшләребез үз халкының төп өлеше, асыл ватанны белән элемтәне даими сакларга, үз илләрендәге рухи традицияләрен дәвам иттерергә теләгәннәр икән.

Яңа дәверләрдә мондый традиция дәвамлылыгы басма сүз, басма китаплар белән тәэмин ителгән булса, элегрәк андый функцияне кулъязмалар үтәгән. Моны раслый торган фактларның бер-икесен генә китерәм.

1973 елны Алма-Атада үсмерчак дустым, сабакташым Равил Салихов белән очраштым. Ул миңа, кәсебем борынгы китапларны, иске документларны өйрәнү икәнлеген истә тотып, ике кулъязма бүләк итте. Китаплар турында сорашып, аларның 60 елларда Алма-Атага Кытайдагы Голҗа шәһәреннән килгәнлеген белдем.

Кулъязмаларның үзләрен актара торгач, аларның гаять озын юллар узган «сәяхәтче китаплар» икәнлеген дә ачыкладым. Мәсәлән, фарсы телендә 1158 ел һиҗридә (хәзерге календарь буенча 1745 елда) Әфганстандагы Кабул тирәләрендә күчерелеп язылган китап, Бохара һәм Сәмаркандлар аша узып, XIX йөзнең беренче яртысында Идел буена, Казанга килеп чыккан икән. Аннары аны чуар татар язмышы ерак Кытайдагы Голҗа шәһәренә илтеп ташлаган. XX гасырның 60 елларында исә, маоизм афәтләрен баштан кичергән, Алма-Атага килеп чыккан һәм 70 елларда ул яңадан Казанда. Кулъязманың төп тексттан артып калган ак битләрендә Казаннан Голҗага кадәр барып чыккан бер татар гаиләсенең «елъязма»сыннан аерым «сәхифәләр» теркәлгән...

Икенче кулъязманың язмышы да гыйбрәтле. 1822 елны Казан артында күчерелгән «һәфтияк тәфсире» бу. 1845 елны Казан округының Көтек авылында аны Халид исемле бәләбәйле кеше сатып ала. 1901 елны ул Оренбург өлкәсендәге Орск шәһәрендә... Ниһаять, тагын алтмыш-җитмеш ел узуга, Голҗадан, Алма-Ата аша йәнә Казанга кайтып төшә. (Бу ике «сәяхәтче» хакында «Каурый каләм эзеннән» исемле китабымда тәфсиллерәк язылган иде; 64—67 бб.).

XIX йөз белән XX гасыр башында Казанда басылып чыккан, Шәркый Төркестан шәһәрләрендә татарлар, казакълар, уйгырлар тарафыннан укылган миңа мәгълүм китапларны санап, тасвирлап чыгар өчен дә тагын ике-өч бит кирәк булыр иде... Кыскасы, татарларның ул якларда мәктәп-мәгариф өлкәсендә ирешкән бәхәссез казанышлары аларның төп ватаннарындагы рухи учакларының бер нурлы шәүләсе яки китаплар рәвешендә еракка чәчрәгән якты чаткылары икән...

* * *

Әгәр Габдулла Буби ачкан, соңра тагын ирләр мәктәбенә кушылган кызлар мәктәбендә 1914 елда сиксәнләп татар кызы укыган булса, сигезьеллык яңа татар мәктәбендә 40—50 елларда укучыларның саны 400 гә җитә язган вакытлары да аз түгел иде. Шуның яртысы кызлар иде, әлбәттә.

Укучыларның якынча 10—15, кайбер елларны хәтта 15—20 проценты башка милләтләрнең балалары була иде. Бер сыйныфка гадәттә өчдүрттән уйгыр, үзбәк, казакъ, кыргыз балалары туры килә. Татарчаны тиз үзләштерә торган төрки халыклардан тыш, ана телләре нигездә кытайча булган дөңгән балалары да безнең өчен ят түгел иде. Болары кабул ителү өчен, билгеле, берәр төрки телдән хәбәрдар булу шарт иде. Ә Шәркый Төркестандагы дөңгәннәрнең шактый өлеше диндәшләре булган уйгырларның телләрен яхшы беләләр, шуңа күрә татарчаны да тиз үзләштерәләр иде. Шундый «икс телле», мәгәр саф кытай һәм шибә кызларының да татар мәктәбендә уку фактлары мәгълүм.

Татар мәктәбенә килгән андый укучылар башта, әлбәттә, татарча әйбәт сөйләшә алмыйлар иде. Шулай да алардан көлү, аларның сөйләшү үзенчәлекләрен мыскыллау гадәтләрен хәтерләмим. Мәгәр берәр татар малае үз телен артык бозса, аңар эләгә иде. Мәсәлән, бе-

ренче сыйныфта чакта, казакъчалап җибәрүем өчен үземне казакъчалап насбай сорап, аннары «Насбай» кушаматы тагып, шактый үртәгәннәр иде.

Татар мәктәбенә кереп укучы башка милләт балаларының ата-аналары, гадәттә, тәрәккыйпәрвәр кешеләр дип исәпләнәләр иде. Төрки халыклардан андыйларның күп очракта хатыннары татар кызлары булу очраклары да аз түгел иде. Мондый катнаш гаилә балалары, һичшиксез, «нугай мәктәбенә» генә барачак. Шулай ук күренекле, югары дәрәҗәле уйгыр байларының, чиновник-түрәләрнең балалары да еш очрый иде безнең әлеге мәктәптә.

Голҗа татар мәктәбендә укыган уйгырлардан соңрак күренекле җәмәгать эшлеклеләре, әдипләр чыгу фактлары бар. Мәсәлән, 30 еллар ахырында анда укып киткән яңа заман уйгыр әдәбиятының классигы булган ялкынлы шагыйрь Лотфулла Моталлиб шундыйлардан. (1961 елны аның берничә шигыре минем өйрәнчек тәрҗемәмдә «Совет әдәбияты» журналында басылгач, мәрхүм Газый ага Кашшаф аның шигырьләрендә Г. Тукай, Һади Такташ иҗатларының тәэсирләре калку чагылуын, хәтта «ярылып ятуын» махсус билгеләп узган иде. Л. Моталлиб, чыннан да, уйгыр поэзиясен яңарткан, аны элекке таррак кысалы традицияләр чигеннән алып чыккан яңа чор шагыйре иде).

Сирәк-мирәк булса да, кайбер уйгыр һәм казакъ кешеләренең башка шәһәрләрдән, авыл җирләреннән дә балаларын Голҗага махсус җибәреп, шунда бер-ике кыш укытып алу очраклары да бар иде.

* * *

Югарыда бер-ике урында татар мәктәпләрен тотар, тәрбияләр өчен махсус вакыф милекләренең булганлыгы әйтелгән иде. (Вакыф милеге хәлле кешеләр тарафыннан мәчет-мәдрәсәләр, мәктәпләр файдасына бүләк ителә торган җир-су, җанлы мал һәм башка төр байлыктан оешкан. Бала-чагасы булмыйча дөньядан киткән байларның милеге дә вакыфка күчә иде.) Вакыф милеге исәбенә ярлы гаиләләрдән чыккан укучыларга, бигрәк тә ятим балаларга, кием-салым (җөмләдән, мәктәп формасы) белән һәм акчалата ярдәм күрсәтү даими гадәт иде. Андый укучыларга китап-дәфтәрләр дә бушлай бирелә иде. Мондый тәртип белән бәйле бер хәл хәтердә уелып калган. Өченче сыйныфта укый башлаган көннәрдә ата-аналар комитетының вәкиле уку бүлмәсенә кереп, өч-дүрт укучыга утыз-кырык дәфтәр, кара савыты, каләм һәм карандашлар биреп чыкты. Матур тартмадагы төсле карандашлар да бирде. Шулчак Малик исемле бер шук малай (аның ата-анасының берсе әллә үзбәк, әллә уйгыр иде): «Эх! — дип өстәлгә учлары белән сукты. — Әгәр минем әтием үлгән булса, миңа да бирерләр иде бит!» Башта көлдек, аннары «атасын ун дәфтәргә саткан Малик» дип үзен үчекләп йөрдек.

Мәктәп белән конкрет җитәкчелек итү җәмәгатьчелек тарафыннан сайланган ата-аналар комитетына йөкләнгән, матди тәэмин итү мәсьәләсе исә Татар җәмгыятенең кулында иде. Рухи тормыш һәм культура эшләрен башкару белән «Татар мәдәни-агарту оешмасы» диган махсус комиссия шөгыльләнде. Дөрес, төрле елларда бу оешма һәм комиссияләрнең структурасы, конкрет бурычлары үзгәреп торды.

Табигый, бөтен Төньяк Шәркый Төркестанда иң әйбәт уку йортларыннан исәпләнгән Голҗа татар мәктәбе (ТКТ, 32—33 бб.) җисмән барлыкка килүдә, матди яктан яхшы тәэмин ителеп озак яшәүдә ихлас күңелдән тырышучы җәмәгатьчелекнең, үз халкына белем бирү юлында гадәти саранлыкларын аңлы рәвештә читкә тибәреп торучы меценат байларның өлешләре бик зур иде. Моны күрмәү, күрә белмәү шөкеранасызлык, рәхмәтсезлек, димәк, әдәп-әхлаксызлык булыр иде.

Шулай ук күпләп туып-үрчеп, «күз йомганчы» үсеп җитүче, аннары тырыша-тырыша укып һәм укыган булып йөрүче балалар — кара танаулы шук малайлар, чәчби кызлар булмаса да, мәктәп-мәктәп булмас, булса да нурга тулмас иде.

* * *

Әмма ләкин нур дигәннән, аны бертуктаусыз иңдереп, аңнарга сеңдереп торучы күпсанлы мәгърифәт чыганакларын — бөтен гомерләрен укытучылык дигән иң авыр эшкә корбан кылган мөгаллимә апалар белән мөгаллим абыйларны — остазларны онытырга хакыбыз юк. Һәркем үзенең беренче укытучысын онытмаучан була. Мин дә, Голҗа мәктәбе турында сүз чыкса, иң элек Гөлбану апа Гафурованы искә төшерәм. Түгәрәк алсу битенә, йомры гәүдәсенә кызыл йон кофтасы шул кадәр килешеп тора иде! Әйтерсең лә, башка кием кимәгән ул... (Моннан ун еллар элек аның Пржевальск-Каракул шәһәрендә үлү хәбәрен ишеткәч тә, иң элек күз алдына шундый кыяфәттә килеп басты ул...)

Нур дигәннән, Голҗадагы беренче дөньяви татар уку йортының «Мәктәбе нур» дип аталуы, ул исемнең бирелүенә тарихыбыздагы нурлы затларның берсе Габдулла Бубиның катнашуы, анда укып чыккан мөгаллим-мөгаллимә абый-апалардан шактые яңа мәктәптә укытулары — үзе бер гыйбрәт, үзе бер бай тарихыбызның мөһим сәхифәсе. Төп йортында дөрләп янган учакның яктысы еракларда яхшырак күренгән төсле.

«Нур мәктәбе»ндә укып тәрбия алган, үз гомерен балалар укытуга багышлаган мәһабәт гәүдәле Мөнирә апа Вахитова мәктәбебездәге иң абруйлы укытучыларның берсе иде. Ул күп еллар уку бүлегенең мөдире булып та эшләде. (50 елларның башында Уйгырстанның иң күренекле вәкилләреннән бер төркем эчке Кытайга сәяхәткә җибәрелгәндә, шул төркемгә татарлардан Мөнирә апа да кертелгән иде. — ТКТ, 65 б.) Башлангыч мәктәп балаларына да тел дәресләрен гаҗәп кызыклы, әдәби әсәрләрне исә үтемле итеп аңлата алган Маһирә апа Ваһапова да истә калган.

Буби мәктәбендә белем алып, аннары үзләре дә укытучы булган шәхесләрдән Сәрвәр апа Биктимерова, Фатыйма апа Сәлимова, Бәнат апа Исмәгыйлева, Малик абзый Биктимеревларны күрсәтергә мөмкин. Болардан соңрак СССРда, аннары Төркиядә һәм Германиядә укып кайткан Малик абзый өлкән сыйныфларда математика, физика буенча дәресләр бирде. Бер ара ул мәктәп директоры булып та торган иде.
Мәктәп директоры булып эшләгән Гариф абзый Сираҗидан без, малайлар, бик тә шүрли идек. Ә менә аның хатыны Маһинур ападан, ул безне күпме генә орышса да (үзе рус телен укыта иде), без бер дә курыкмадык: зәңгәр күзләрендә ачу булмас иде.

40 еллар башында директор булып торган Әнвәр абый Госмановтан да укучылар курыкмадылар шикелле. Дәрестән соң мәктәп ишегалдында туп тибеп йөрүче малайларга кушылып йөгереп китә торган гадәте дә бар иде бугай аның. Ни өчендер, күп тә узмый, аны ерак уйгыр районнарының берсенә сөргенгә җибәрделәр...

Олылар гел «Әхмәт әфәнде», укучылар исә гап-гади итеп Әхмәт абый дип эндәшә торган, мин анда укыган чактагы соңгы директорның фамилиясен хәтерләмим. Әмма аның яшереп тәмәке тартучы малайларны тотып алып, бик ягымлы итеп әрләүләре, махрага акча әрәм итмичә, самавыр торбасыннан төтен йотарга киңәш итүләре һаман истә.

Әгәр коридорның бер башында көр тавыш, йәисә шаркылдап көлү ишетелсә, бел дә тор: бу башлангыч сыйныфларның яраткан укытучысы Рәйсә апай Кәримова булыр...

Мәктәптә эшләвен зур сыйныфларга математика укытудан башлаган, аннары укыту эшләре буенча мөдир дә булып торган Әсгать абзый Исхаков аз сүзлелеге, сабырлыгы белән аерылып тора торган иде. Әгәр аның хакында берәр яхшы сүз әйтергә теләсәк: «Ул бит Союзда укыган!» — дип «дәлилләп» куя идек. Аның энесе Мәргуб абзый Исхаков кытай теленнән дәресләр бирде. Әмма аның «Тән хәрәкәте» — физкультура буенча дәресләре безгә күбрәк ошый иде. Аның кебек үк озын буйлы Рәфкать абзый Юлдабайның да физкультура дәресләрен ярата идек. Ихтимал, алар кебек зур, озын буйлы булырга теләгәнбездер...

* * *

Мәктәпнең зур сыйныфларында белем бирү ни дәрәҗәдә булгандыр, анысын кистереп әйтә алмыйм. Чөнки дүрт сыйныфны бетерүгә, әтиебез мине, колактан өстерәп дигәндәй, рус мәктәбенә илтеп утырткан иде. Әмма шул дүрт ел эчендә дә татар әдәбияты, халкыбызның тарихы буенча шактый мәгълүмат аңга сеңеп калган. Тукай мирасы белән таныштыру, аның күп кенә шигырьләрен яттан өйрәтү — фарыз. Сәгыйть Рәмиев, Галиәсгар Камал, Фатыйх Әмирхан, Һади Такташ, Дәрдемәнд, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин, Мирсәй Әмир, Муса Җәлил, Шәйхи Маннур әсәрләре мәктәптә дә, өйдә дә кычкырып укыла. Үз ватаннарында әсәрләре тыелган, исемнәре дә телгә алынмый торган Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов китаплары да бездә мәгълүм иде. Русча укып йөргән чакларда да элекке мәктәбебезнең укучылары, бигрәк тә кайбер укытучылары белән өзлексез аралашу нәтиҗәсендә, миңа иске Казан басмалары, бигрәк тә «Аң», һәм «Шура» журналлары белән дә танышу, аларның кайберләрен «капшап карау» мөмкинлеге туган иде.

Голҗадагы татар яшьләре өчен тагын бер мөмкинлек бар иде: берничә төрки телләрдә аралашу, аларны яхшы аңлау нәтиҗәсендә уйгырча, казакъча, үзбәкчә гәзитә-журналлар, китаплар уку мөмкинлеге. Мәсәлән, казакъ акыннарыннан Абай, Шаһкәрим әсәрләрен, үзбәк әдипләреннән Абдулла Кадыйри, Хәмзә Ниязи китапларын мин шул елларда укыган, яраткан идем. Болар белән танышуга да әлеге татар мәктәбе укытучыларының сәбәп булуы бәхәссез...

Бер читеннән генә алып санап чыгылган һәм исемнәре аталмаган күп санлы мөгаллим-мөгаллимәләребез, яшь буынга белем бирү белән генә чикләнмичә, халык арасында аң-белем күтәрү эшләре алып бару буенча да аз эшләмәделәр. Гарәп хәрефләре латинга алыштырылгач, зурлар өчен махсус кичке курслар оештырылды.

Төп ватанда милли мәдәният өлкәсендә килеп чыккан язу алмаштыру кебек үзгәрешләрдән читтә калмау, бер яктан, рухи кыйблаұның кайдалыгына күрсәтсә, икенчедән, җәмәгатьчелекнең иҗтимагый аңына сәяси тәэсир җилләренең кайсы тарафлардан күбрәк исүенә ишарә итә.

Әйе, татар җәмәгатьчелегенең Голҗадагы мәдәни-агарту оешмасы тирәсендә йөрүчеләр, «Нугай гурыты» мәктәбендә эшләүчеләр 40 еллар башында өлкә һәм шәһәрдәге иң укымышлы, алдынгы төркемнәр булу белән генә чикләнмичә, шул елларда урнашкан сәяси, иҗтимагый тәртипләргә каршы актив көчләрнең берсенә дә әверелгән иде. Бу тенденция ахыр чиктә шул җәмәгатьчелекнең язмышы тамырдан үзгәрүгә, хәтта тагын яңа һиҗрәт дулкыннары ташуга да сәбәп булды.

## Үзенекен итеп, үз итеп тә...

Шәркый Төркестан якларында бер-берсенә сыенышып, ышыкланып төпләнгән татарларның чыккан җирләре дә төрле төбәкләр иде. Пермь-Вятка якларыннан алып, Казан-Сембер ләрне үтеп, Әстерханга кадәр; Ка

сыйм-Тамбовлардан башлап, тагын Казан-Уфаларны айкап, Төмән-Тубылларга хәтле аралардагы санаулы «җүнсез» шәһәрләр белән бихисап җирсез авыллардан чыккан кешеләр. Бер телем ипи, тотрыклы берәр кәсеп өчен туган җирләреннән һиҗрәт иткән — мөкатдәс каберләр белән кан кардәшләреннән мәҗбүри аерылып киткән кадерсез ходай бәндәләре, аларның газиз балалары иде болар.

Чыккан җирләре кебек ук, төс-кыяфәтләре дә аларның төрлечә иде. Кыр борынлы, кара бөдрә чәчле Казан арты көязләре белән шул ук яктагы аксыл чырае әллә ничек төссез урман кешеләренә охшаганнары; мәһабәт гәүдәле, зәңгәр күзле мишәрләр белән түгәрәк битләрендәге ике кара «өтере» янып торучы әстерханлы яки «төмәнлеләре». Бер-ике буын алмашмыйча «шомарып җитми торган» Яңавыл һәм Малмыж, Арча һәм Дүртөйле ягы кешеләре белән туганда ук «ялтырап» чыккан, «пирвай суртлыгын» һич онытмаган Пенза һәм Нижгар агайлары...

Ләкин алар, чыгышлары буенча төрле җирләрдән, төрле нәсел-тамырлардан булуларына, төрлечәрәк шивә-сөйләшләрдә аңлашуларына карамастан, үзләрен бер халык итеп сизә — татар дип белә. Патша хөкүмәте күпме аерырга теләгән типтәре генә түгел, адашып кына килеп чыккан башкорты да үзен шул ук халыкка нисбәт итә. Җирле кавемнәрдән уйгырлар белән казакълар, үзбәкләр белән кыргызлар да аларны үзара аерып тормыйлар — нугай дигән бер «таяк» белән сөрәләр.

Күпкә, бик күпкә кадәр мин кешеләре төрле кыяфәттәге халыкның үзен шулай гел татар дип атавын, башкаларның исә аны һаман нугай дип «тамгалавын» аңлый алмыйча йөрдем. Өстәвенә, ул яклардагы милләттәшләребезнең бу «кушамат»тан качмаулары да гаҗәбрәк иде (мәсәлән, үзбәкләр, уйгырлар үзләрен «сарт» дип атауны бер дә яратмыйлар, гәрчә казакълар һәм кыргызлар өчен алар гел «сарт» кына булсалар да). Һәрхәлдә, күпкә хәтле бу исем безгә соңгы 80—90 ел дәвамында, ягъни татарлар казакъ якларына, Урта Азиягә күпләп килә башлагач кына тагылгандыр, дип уйлап йөрдем.

Тикшерә башласаң, аның тарихы бик тирәнгә — Алтын Урда империясе җимерелү, Казакъ ханлыгы, Нугай Урдасы оешу дәверләренә үк барып тоташа икән. Мәсәлән, әлеге империя таркалып, көнчыгышта үзбәкләр, каракалпаклар һәм казакълар үз башларына аерым халык булып, этник җәһәттән оеша башлаган дәверләрдә, аларның көнбатышында күпсанлы нугай кабиләләре яшәгән. Нугай биләмәләренең төньягы белән Казан ханлыгына кергән җирләрнең көньяк өлкәләре нугайлар белән казанлылар өчен «уртак» булган. Мәсәлән, ханлыктагы зур бер өлкәнең «Нугай даругасы» дип аталу факты. Бу чорларда ул ике халык бер-берсеннән тел-лөгать, кием-салым ягыннан да әллә ни аерылмаганга охшый. Шуңа күрә иң элек казакъларның аңында аларның үзләреннән көнбатыштагы төрки халыкларның һәммәсен нугай дип атау гадәте урнашкан (XIV—XVI гасырларга карата казакълар әле дә «нугайлы чоры» дигән төшенчәне актив кулланалар). Казакълардан — үзбәк һәм каракалпакларга, төрекмән һәм уйгырларга да күчкән ул тарихи аң, икенче бер халыкны танып-белү аңы.

Мондый аңның тирән тамырлы икәнлегенә мин соңгы мәртәбә 1977 елда Таулы Алта автоном өлкәсендә булган чакта ышандым. Анда «Кушагач казакълары» дигән, Казагыстандагы төп халыктан 160—170 еллар элек аерылып, соңгы заманга кадәр изоляцияләнеп, консервацияләнгән хәлдә яшәгән бер төркем бар. Авыл советы җитәкчесенә үземнең Казаннан килүче татар галиме икәнлегемне әйтеп танышуга ук, бүлмәгә тагын бер казакъ кешесе керде. Хуҗа шунда ук мине аңар, ике дә уйлап тормыйча, «алыстан килгән нугаемыз» дип, автоматик рәвештә милли исемне «тәрҗемәләп» тәкъдим итте. Юкса, мин үземне нугай дип атамаган идем ләбаса!

Әйе, ул яклардагы гади халык арасында безнең исем шул рәвешчә нугай иде. Бары рәсми документларда гына татар этнонимы калкып чыга... Габдулла Буби язмаларында да нугай сүзе еш кулланыла — «мондый нугайлар», «нугай кызларыбыз»...

* * *

Нугай исеменә махсус тукталуның сәбәбе бар. Шәркый Төркестан җирләренә килеп урнашкан татарлар, үзләренең чыгышлары, туган җирләре, тел-шивәләре, элекке гореф-гадәтләре никадәр төрле-төрле булмасын, Уйгырстан шартларында яңадан оеша башлаган бер кавем шикеллерәк иде. Туй-мәҗлес, үлем-җитем, кунак-төшем һ. б. йолалары, конкрет алганда, бер генә төбәкнекенә, ягъни ни Казан, ни Уфа, ни Пенза якларыныкына охшамаган. Әмма татарларның барлык этнографик төркемнәренә хас сыйфатлар, күренешләр бергә тупланган. Икенчерәк итеп әйткәндә, милли йолаларның төрле вариантлары, һәр төбәккә хас элементлары бергә кушылган.

Бу күренеш тел-лексика байлыгында да нык сизелә иде. Мәсәлән, андагы татарлар өчен Казан артына гына, яки Уфа-Урал ягы белән Пенза-Сембер төбәкләренә генә хас сүзләрнең берсе дә диярлек ят түгел иде.

Шул ук вакытта гореф-гадәткә, телгә җирле халыклардан казакъ һәм уйгыр элементлары да мул керүен күрми мөмкин түгел. Казакъларда, әйтик, кадерле кунак өчен махсус мал (куй, бәрән) чалу йоласы бар. Гадәттә, иткә әверeләчәк терлекне өстерәп, кунак алдына китерәләр, аңардан «бата» — фатиха бирүне сорыйлар. Кунак кеше иреннәрен бер-ике кыймылдатып, ике учы белән битләрен сыпыра, шулай «батасын бирә». Габдулла Буби, мәсәлән, үз язмаларында Голҗа татарларының да туй өчен әзерләп катырган чәкчәкне кисә башлау алдыннан кунаклардан шулай «фатиха алу» гадәтен ирония белән махсус билгеләп үтә. Кыз йәрәшеп, никах хакында сөйләшкәндә дә, кыз ягының егет тарафыннан күп акча таләп итеп, озак сәүдәләшкәнен, аннары мул итеп туй уздырып, шартлаганчы ашапэчүләрен дә сәерсенеп яза ул...

Тел мәсьәләсенә килсәк, мондагы үзгәлекләр төрле төбәкләрдә төрлечә иде. Югарыда бер урында Алтай якларында тупланган татарларның телләре тулаемы белән казакълашу хакында әйтелгән иде инде. Аларның татарлыгы гореф-гадәтләренең бер өлешендә һәм милли аңнарында сакланган. Алтайлы татарларның хәзергә кадәр Кытайда яшәүчеләренең бик нык казакълашуы, шулай да казакълардан аерымланып яшәүләре хакында Уйгырстан авторлары тәфсилләп язалар. Аларның бер өлеше Алтайның үзендә торсалар, икенче кызыклы төркеме Актирәк (Кытайча Бәйяңхи) дигән җирдә яшиләр (ТКТ, 15—17, 23 һәм 71—80 битләр).

Андый тел казакъча сөйләүче алтайлы татарларны, дөресрәге, «чала казакъларны» Голҗада очратканым, хәзерге Алма-Атада да күргәнем бар. Үзләрен казакъ дип уйлауларын белә калсалар, шунда ук татар икәнлекләрен әйтергә ашыгалар алар. Нугай-мазар да дип тормыйлар.

Чүгүчәк, ягъни Тарбагатай ягы нугайлары да, гореф-гадәттә һәм аңда татарлыкны нык саклаган хәлдә, телләрендә шактый казакълашкан иделәр. Әмма Алтайдагыча бөтенләй диярлек түгел.

Голҗадагы төркемгә килсәк, монда, казакъча элементлар да шактый булганы хәлдә, уйгырча сүз берәмлекләре, чүгүчәклеләргә караганда күбрәк кулланыла иде. Шуңа күрә кунак-мәҗлесләрдә ике кешенең үзара сөйләшеп утыруына карап та, кайсысының голҗалы, кайсысының чүгүчәкле икәнлеген аеруы җиңел була иде. Чүгүчәктән Голҗа татар мәктәбенә килеп укучыларга бездән «эләккәләгән» кебек, аларның

үзләре дә безнең уйгырчалаштырып җибәрүдән рәхәтләнеп көләләр иде.

Өремче якларындагы нугайлар исә тагын да кызыграк: анда җыелган татарларның күпчелеге Голҗа, Чүгүчәк һәм Алтайдан чыгучылар булганга, аларда бөтенесе бергә тупланган, буталып беткән...

Ләкин шунысы да бар: мондый катнаш телле татарларның сөйләшләре бик үк тотрыклы да түгел иде. Әйтик, бер үк конкрет татар кешесе өйдәге карт ата-аналары белән чагыштырмача саф ана телендә сөйләшсә, эштәге милләттәше белән әңгәмәләшкәндә икенчерәк стильгә күчә. Ә инде күптәнге таныш казакъ яки уйгырлар белән аңлаша башласалар, татарлыгын да онытып җибәрмичә, өченче стильгә — шактый «корама» телгә авыша. Чөнки Голҗа, Чүгүчәк һәм Өремчеләрдә күптән яшәүче уйгыр һәм үзбәкләрнең, казакъ-кыргызларның күпчелеге дә татарчаны яхшы аңлыйлар иде. Бары Кашгар ягыннан килгән уйгырлар йәисә ерак таулардан төшкән казакълар белән очрашканда гына безнең нугай агай-энесе дә аларның ана телләрендә дә рәхәтләнеп гәпләшә ала иде. Шуңа күрә Голҗа татарлары «нәкъ болай», чүгүчәклеләр исә «гел тегеләй» дип кистереп әйтүе дә читен.

Җыеп әйткәндә, Чүгүчәк һәм Алтайларда, бигрәк тә Голҗада үзенә күрә бер махсус төркичә сөйләш — койне барлыкка килгән иде. Тел белеме теорияләрен, аның махсус атамаларын белмәгән кешеләр дә мондый күренешнең барлыгын, реальлеген инкяр итмиләр, бәлки ачык таныйлар. Шуңа күрә әлеге телнең киң, җәенке, ачык мәгънәсендә «ялпак тел» дигән үз исеме дә бар иде. Әгәр дөньялар шул килеш кала биреп, демографик тирбәнүләр, яңа һиҗрәт дулкыннары килеп чыкмаса, ихтимал, яңа бер төрки шивә-сөйләш оешкан булыр иде.

Шулай да, бер гомум уртак сыйфат булса, ул 50 елларга кадәрге төркестанлы татарлар телендә казакъча элементларның уйгырчага караганда, чагыштырмача күбрәк булуыннан гыйбарәт. Моңа, минемчә, Уйгырстанга узган гасырда ук җыела башлаган милләттәшләребезнең күбесенең элек беркадәре Җидесу өлкәләрендә яшәп алуы, соңрак баручыларының да күпчелеге шул Җидесу һәм, гомумән, Казагыстан «иләге» аркылы узуы төп сәбәп шикелле.

Әмма ничек кенә булмасын, никадәре тел үзгәртеп, бутап сөйләшмәсен, һәрбер нугай кешесе үз сөйләшен, иң төзек булмаса да, «чын татар теле» дип ышана. Туй-мәҗлесләрдә гел үз җырларын җырлый. Кулына төшкән татар китабын ул рәхәтләнеп укый. Тукай иҗатын азмы-күпме дәрәҗәдә белә, хәтта бер-ике шигырен, иң кимендә аерым строфаларын яттан хәтерли.

* * *

Телләр буталуга беркадәре кан катнашу фактларының да тәэсире бар, әлбәттә. Татарлар, нигездә, үзара өйләнешсәләр дә, аларның уйгырлар, казакълар, үзбәкләр, хәтта дөнгәннәр белән кодалашканнары да шактый. Татар егетләре аларның кызларын алуга караганда, тегеләрнең үзләре нугай кызларына өйләнү очраклары күбрәк иде. Урта Азиягә, Казагыстан һәм Кавказга хас бу күренеш Шәркый Төркестан өчен дә характерлы булган, күрәсең. Һәрхәлдә, укымышлырак казакъ, уйгыр, үзбәк ирләренең хатыннары яки әниләре татар түтәйләре булып чыкса, бер дә гаҗәп түгел иде. Мондый гаиләләр күпләп барлыкка килүгә безнең халык кызларының чагыштырмача ак тәнлерәк һәм чаярак булулары да, бәлки, тәэсир иткәндер. Аң-белем, тәрбия җәһәтеннән аерманы да истә тотарга кирәктер...

Катнаш гаиләләрнең корылуы күп очракта шома гына бармый иде, әлбәттә. Гадәттә, кыз ягының ата-аналары каршылык күрсәтәләр. Әмма яшьләрнең ихтыярлары өстен чыгып, катнаш гаилә барлыкка килә калса,

ул, нигездә, тотрыклы була (гомумән, ул якларда һәм ул заманнарда гаилә бозылу, ир-хатынның аерылышып йөрүләре кебек күңелсез хәлләр юк дәрәҗәсендә бик сирәк иде). Андый катнаш гаиләләрдә туган балалар җиренә, конкрет шартларына карап тәрбияләнәләр. Шулай да күбрәк татар җәмгыятенә, татар мәктәпләренә ышыкланалар, үзләрен татар дип исәплиләр. Атасы уйгыр яисә казакъ булуына карамастан, балаларының гел татар дип язылу фактлары да аз түгел. Бары Өремче һәм Алты шәһәр якларында, уйгырлар абсолют күпчелекне тәшкил иткәнгә, катнаш гаилә балалары тулаем уйгыр булып үсәләр. Әмма бер гаиләдә туган дүрт-биш баланың ике-өче — татар, калганнары уйгыр булып язылу очраклары да бар (ТКТ, 81—82 бб.). Өстәп шуны гына әйтергә кирәк, катнаш гаиләләрдән туган балалар күп очракта үзләренең ата-аналарына караганда матуррак, оригинальрәк кыяфәттә булалар иде.

Кыскасы, һәр милләт үз алдына аерым булып яшәсә дә, болар арасында милли антогонизм күренешләре юк дәрәҗәсендә иде. Моның сәбәбен, минемчә, 50 елларга кадәр хөкүмәт органнарының һәр милләткә хас, аның үзенә кадерле милли һәм рухи гадәтләргә, телгә, дингә тыкшынмавыннан эзләргә кирәк. Милли аралашу, халыкларның үзара кардәшләшү процессы югарыдан иңдерелгән декрет яисә көчләп тагылган, гел пропагандаланган инструкцияләр басымы астында түгел, бәлки табигый ихтыяҗ рәвешендә бара, шуңа күрә тыныч һәм чамалы иде.

Әгәр уйгырлар белән өйләнешүнең беренче очраклары, нигездә, гасырыбызның 10—20 елларына туры килсә, татарларның казакълар белән гаилә кору фактлары XIX гасырда, Җаек һәм Җидесу якларында башланып, аннан соң да дәвам иткән. Алтайга беренче булып килгән татар егетләренең казакъ кызларына өйләнүләрен әйткән идек инде. Бу процессның элгәрәк Җидесу өлкәләрендә дә булганлыгы шик тудырмый. Ул хәтта XX гасыр башында да дәвам иткән. Моңа мисал рәвешендә үз гаиләбез тарихыннан берничә сәхифә күчереп узам.

* * *

Әти ягыннан бабаларыбызның кайдан чыгулары хакында беркадәре язган идем инде. Әтинең анасы Бибизаһидәнең, ягъни Өлкән әниебезнең атасы Хөсәен хәзрәтнең 1870 елда Җидесудагы Ләпсе шәһәрчегенә килүе һәм шунда указлы имам булып торганлыгы, зур мәчет салдырганлыгы мәгълүм (Габдерәүф Госманов язмаларыннан). Корбангали Халиди кулъязмаларында тагын да киңрәк мәгълүмат бирелгән: Хөсәен хәзрәт ибне Исмәгыйль Аягуз илендә дөньяга килеп, шунда Мөхәммәдсадыйк хәзрәтнең пишкадәмләреннән була, аннары Кышкарга китеп, «анда берәр ел тордыктан соңра, Казанда Мөхәммәдкәрим хәзрәттән, аннары Салахетдин хәзрәттән» укый, Аягузга кайтып бераз имам булып торгач, Ләпсе каласына барып, утыз елдан артык шунда имам була. «Бу тараф голәмаларының беренче дәрәҗәдә галиме димәгә мөнасиб (лаеклы — М. Г.) бөек зат иде», — дип йомгаклый Корбангали хәзрәт. Шулай да Исмәгыйль бабаның Татарстанда кайсы төбәктән чыкканлыгы хәзергә мәгълүм түгел.

Әни яктан бабаларыбыз хакында да артык мактана алмыйм. Шулай да әнинең әтисе Локман Сәйфелмөлек улының (рәсми фамилиясе Мөлеков) Казан арты Балтач ягындагы Ор авылыннан чыккан кеше икәнлеген ишеткән идем. Үземе, атасымы чит җирләргә киткән — анысы мәгълүм түгел. Шулай да XIX гасыр ахырларында аның Җидесуда Кытай чиге буендагы Капал (русча — Копал) каласында сәүдә белән шөгыльләнүе бәхәссез. Шушы вакытларда ул Капал төбәгендәге казакъ-

лардан матай кабиләсенең башлыгы Торсын түрәнең кызы Кадичага (ягъни Хәдичәгә) өйләнә. Ничек итеп аксөяк казакъ түрәсе («түрә» дип казакълар гадәти нәчәлникләрне генә түгел, бәлки чыңгызыйлар нәселеннән дип исәпләнгән принцлар токымын — князьләрне атыйлар) үз кызын читтән каңгырып килгән нугайга биргәндер, монысы минем өчен сер... Һәрхәлдә, Локман бабайның шул никахтан ике кызы (Фәрваз һәм Гөлҗиһан), бер улы (Садыйк) була. Локман бабай үзе 1915—1916 еллар тирәсендә авырып үлә. Әниебез Гөлҗиһан (1905 елда туган) ике-өч ел Капалда мөгаллимлек итүче Зариф Бәширидән укый...

(Нәкъ шушы төштә, җәяләр эчендә, тагын бер истәлеккә мөрәҗәгать итү гыйбрәтле булыр.

Әниебез, дүрт-биш бала анасы булган чакларында да, үзенең сөекле укытучысы Зариф Бәширине сагынып, аңардан сабак алуы белән горурланып сөйли иде. Аның сүзләренә караганда, З. Бәшири ихлас күңелле тәрбияче, тырыш мөгаллим, зур шагыйрь, әмма шәхси тормышында бик бәхетсез кеше булган. Шулар хәтергә нык сеңеп калгангамы, мин бер елны Бәширине махсус эзләп киттем. 1960 елның гыйнвар ахырларында, кышкы каникул вакытында булды бу хәл.

Салават шәһәренә барышлый Уфада 5—6 сәгатькә тукталдым да, белешмәләр бюросыннан аның адресын алып, Черниковскийга юнәлдем. Ишекне ачкан марҗа әбие, кемгә килүемне белгәч, эчтәге ишекләрнең берсенә төртеп күрсәтте. Аннан бер күзе ябык, чандыр бабай кисәге килеп чыкты. Аягында киез итек, өстендә гадәти сырмак. Үзен эзләп килүемне белгәч, рәхим итүемне үтенде.

Бүлмәдә бер иске тимер карават, ялангач өстәл, ике-өч урындык кына. Борчып йөрүемнең сәбәбе әниебез икәнлеген әйттем. Карт сагайган төсле ялгыз күзен миңа таба борды.

— Сез Капалда торган чакта әнием сездән укыган икән...

— Әниегез кем кызы була? — дип бүлдерде Зариф ага.

— Локман Мөлекев кызы...

— Фәрвазмы, Гөлҗиһанмы?!

Шаклар каттым: кем әйтмешли, 40 елдан артык вакыт узуга, аның да егерме елы төрмәләрдә, сөргеннәрдә тузуга карамастан, кайчандыр үзеннән ике-өч кыш дәрес тыңлаган чәчби кызларның исемнәрен шулай керфек какканчы искә төшерер өчен нинди хәтергә ия булмак кирәк?!

1962 елның яз айларында, нәшрияттагы яшьләр редакциясенә керсәм, анда Зариф ага утыра икән. Мине күрүгә, исемемне атап: «Әниең Гөлҗиһан исәнме?» — дип сорады. Бу юлы инде карт эдип З. Бәширинең «әле генә Кытайдан килүче» кешенең анасын тануы өчен редакция мөдире Кыям Миңлебаевның күзләре шардай булган иде...)

* * *

1917 елны, февраль революциясеннән соң, З. Бәшири, илгә кайтам дип, Капалдан китә (ләкин Алма-Атада тукталып кала.). Аннары дөньялар бутала... Тынычрак җирләрдә шау-шуларның узуын теләгән Торсын түрә, Локман Мөлекевнең дә ятим балаларын, ягъни үзенең «нугай нәберәләрен» (оныкларын) бергә алып, 1918 елның башында дәүләт чигенең «теге ягына гына чыгып торырга» була... Кытай ягы тауларында күченеп йөргән Торсын түрә шунда җәйләүгә килгән якташы, иске танышы Апарый хаҗины очрата. Олы оныгы Фәрвазны хаҗиның улы Габдерәүфкә йәрәшәләр. Бер-ике елдан соң кодачасы белән артык күз кысыша торгач, хаҗиның өченче улы Габделәхәт тә Гөлҗиһанга өйләнә...

Шулай итеп, безнең гаилә дә катнаш канлы, яртылаш татар, чиреклап дигәндәй казакъ гаиләсе дә иде. Әмма төп тормыш шәһәрдә узып, туганнарның туксан проценты дип әйтерлек Казан арты ягы кешеләре бул-

ганлыктан, аннары аң-белем дә татар мәктәбендә кергәнлектән, үзебезнең «казакъ өлешен» без ерак тарих сыйфатында гына искә төшерә идек. Бигрәк тә әни үзе бу темага сөйләшергә артык яратмый иде. Гәрчә әбиебез, Хәдичә әбием, үлгәнгә кадәр телен, казакъча сөйләшен үзгәртмәгән хәлдә дә... Шул рәвешчә безнең нәселдәге чала-казакълык гаять кыска гомерле булып чыкты. Шуңа күрә мондыйларны «чала (яртылаш) татар» дип әйтү дөресрәк булыр кебек.

Бу истәлеккә шулай киңрәк тукталудан максат — Голҗа якларындагы кайбер катнаш гаиләләрнең элек ничегрәк үзгәрүләреннән бер мисал китерү. Шушы рәвештәрәк барлыкка килгән һәм нәкъ мин тасвирлаган юнәлештә милли аңнарын сайлаган чыгышлары буенча катнаш нәселләр — «чала татарлар» — Голҗада, Чүгүчәктә, бигрәк тә Алтай якларында, аз түгел иделәр.

Мондый «чала татарлар»ның күпчелеге, «саф» татарларның да шактый өлеше җәй көннәрен, хәзергечә әйтсәк, ял вакытларын таулардагы җәйләүләрдә йәисә шәһәрдән читтәрәк уйгыр кышлакларындагы җимешле бакчаларда уздырырга тырышалар иде. Бигрәк тә салкынча һавалы җәйләүләрдә. Чөнки Голҗаның җәе бик эссе һәм тузанлы була. Шуңа күрә «җәйләүгә чыгу» дигән сүз киң таралган, һәммәсенә аңлаешлы гыйбарә иде.

Әгәр җәйләрен җимеш бакчаларына барып торучылар күбрәк үзләре өчен өрек-абрикос, алма киптерү, как кою белән шөгыльләнсәләр, казакълар арасына җәйләүгә чыгучылары, тирмәләрдә яшәп, бераз вакыт күчмәннәрчә гомер кичерәләр. Ел саен җәйләүгә чыкмаган, шуңа күрә үз тирмәләре булмаган кешеләр, гадәттә, торак урынын казакълардан яллап алалар. Кымыз өчен бияләр тоту да шулайрак.

Үзләренең җанлы мал хуҗалыгы булган хәллерәк кешеләр, кагыйдә буларак, җиде-сигез бия, биш-алты сыер савалар, димәк, кымыз ачытып эчәләр, көндәлек сөт-каймактан тыш, кышлык май белән корт-эремчекләрен дә киптереп алалар. Ит өчен куй, бигрәк тә яшь бәрән табу проблема түгел — шалкан бәясе алар. Әмма иң мөһиме, Тукай әйтмешли, «ак күмәч белән ашарлык саф һава», бернинди шәһәр корымы, урам тузаны белән пычранмаган пакь табигать, ыгы-зыгысыз ике-өч айлык тыныч, мул тормыш...

Дөрес, җәйләүгә чыккан татарлар ипи пешерер, токмач-салма ясар өчен капчык-капчык оннарын да төяп киләләр. Монысыннан казакълар бераз елмаеп та куялар: сөт-кымыз, май-эремчек, яшь ит мул һәм иркен, арзан булган җиргә шул кадәре» «нан» ташу нәрсәгә?..

* * *

Голҗа татарларының шәһәр тормышы да үзенчәлекле дип әйтерлек иде.

Элек-электән монда торган һәм ишле-хәлле гаиләләр, гадәттә, патриархаль дип әйтерлек тормыш кичерәләр иде. Зур кура-ихаталы, бакчалы, бүлмә саны шактый йортларда өч буын бергә яши: әби белән бабай, аларның ике-өч уллары, шуның кадәрле киленнәре, болардан туган сигез-тугыз нәберәләр — оныклар. (Бу якларда баланың баласына онык дип, русчадан бозылган сүзне кулланмыйлар, бәлки «нәберә» атамасын йөртәләр, нәберәнең баласын исә «чөберә» дип әйтәләр иде.) Гаилә бик зураеп киткәч кенә, матди яклар мөмкинлек бирсә, улларының олыракларын аерып чыгаралар. Шулай бүленә-бүленә таралып беткән хәлдә (мондый процесс әби-бабай үлгәч кенә була), әлеге күбәүләшеп яшәгән олы йортта төпчек малай үз гаиләсе белән кала.

Һәр ир-хатында, гадәттә, дүртәр-бишәр бала була. Сигез-тугыз балалы кешеләр дә ят нәрсә түгел (кайберәүләрнең бер-ике генә баласы

булуын белсәләр, «хәлегезне аңлыйбыз» дигәндәй, мәгънәле генә баш изәп куялар...»). Шуңа күрә әби-бабай исән гаиләләрдә табын янында уннан артык, кайбер очракта егермегә якын кеше утырыр.

* * *

Безнең Госмановлар гаиләсе дә шундыйрак иде. Дүрт малай хатыннары белән; аларның дүртәр-бишәр балалары. Бары 1930 еллар башында Габделбари хаҗи ике зур улын аерып чыгара. Әмма Өлкән әни үлгәнче (ул 1950 елда вафат булды) әлеге зур гаилә барыбер таралмады диярлек. Шуңа күрә бу әби яшәгән төп йорт «өлкән кура» дип атала иде. Һәркөнне диярлек «өлкән курага» янәшәдә генә диярлек аерым яшәүче угыл-кызлар, аларның балалары килеп торалар.

Оныта язганмын: Өлкән әнинең, дүрт улыннан тыш, тагын тормыштагы дүрт кызы да, аларның да өчәр-дүртәр балалары бар иде. Өлкән әни янына бала-чагалар белән хәл белә килү бигрәк тә җомга һәм бәйрәм көннәре өчен зарури бурыч дип әйтерлек гадәт иде. Мондый чакларда табын, кыш булса, ике-өч бүлмәгә бүлеп, җәйләрен исә йөземле верандада торган биш-алты метр озынлыктагы өстәл янында уза. Балаларның берсе сөйли, икенчесе кычкыра, өченчесе чиный... Иң түрдә утырган Өлкән әнинең кашык белән өстәлгә шакылдатуы да артык тәэсир бирми. Бары аның «бабай урынында калган» олы улы, дәү әти, Локман барында гына артык шау-шу чыкмый. Ә көндәлек тормышта мондый зур гаилә кечкенә балалар бакчасы булган йортны хәтерләтә. Безнең әлеге зур гаиләбездә төп тәрбияче һәм «мөдир» вазифасында оныкларының һәммәсен үзенә якын итәргә тырышучы өлкән әниебез иде. (Әгәр бу Өлкән әни үзенең өч-дүрт киленен, җиде-сигез оныгын ияртеп, берәр җиргә барыр өчен, урамга чыгасы булса, башка татарлар: «Әнә, Апарый хаҗиның апарасы ташып килә!» — дип көлгәннәр, имеш.)

Олыларны хөрмәт кылу, туганнар арасындагы берәр олы кешегә аерата зур илтифат күрсәтү, аны барлык гаилә әгъзалары өчен иң зур авторитет итеп тану киң таралган күренеш иде. Яшьләрнең генә түгел, кырык-иллегә җиткән чал сакаллы ирләрнең дә әти-әниләре алдында, аракы эчү генә түгел, тәмәке тартулары да мөмкин булмаган әдәпсезлек санала. Һәм бу, гомум кагыйдә дип әйтерлек, киң таралган уртак күренеш иде (ТКТ, 87—88 бб.)

* * *

Шәһәрдә яшәүче татарларның гореф-гадәтләре, тормыш шартлары хакында сөйләгән чакта, аларның ашап-эчүләре, ризыклары хакында да берничә сүз әйтү артык булмас. Ипине, гадәттә, урыс мичендә өйдә пешерәләр. Ләкин һәрбер йортта диярлек танур (тандыр) да була. Мондый уйгыр «мичендә» пешкән ипи үзенчә тәмле һәм озаграк сакланучан булуы белән дә кулай иде. Аш-суларның күпчелеге татарча. Токмач белән пәрәмәч тә, салма белән бәлешләр дә гадәти. Туйларда, бәйрәмнәрдә әзерләнә торган милли ризыклар (чәкчәк, кош теле, гөбәдия, катлама, бөккән, сумсалар, төрле өй пәрәннекләре һәм чәй тәмләткечләре...) барысы өчен дә таныш һәм уртак. Әлбәттә, һәркем булдыра алган хәтле тырыша, хәленә карап әзерләнә.

Уйгырстан авторлары туй-мәҗлесләрдә татар ризыкларының уйгырлар, казакълар тарафыннан да актив кулланылуын билгеләп узалар (ТКТ, 108 б.). Ләкин, минемчә, мондый тәэсир берьяклы гына булмады. Дөреслектә татарлар үзләре дә җирле халыкның тәэсирен күбрәк татыдылар. Мәсәлән, үз ризыкларыннан тыш, төркестанлы татарлар уйгырларның, казакъларның ризыкларын да яратып ашыйлар, андыйларны үз

өйләрендә дә еш әзерлиләр. Уйгырча пешергән пылау, казакъча «аскан ит» хакында артык сөйләп торуның кирәге юк. Әмма гарнирга бирелә торган һәр «токмач-макарон»ның озынлыгы берәр метрга җитә язган лагъманне, һәр пилмәне йодырык хәтле мәнтене дә татарларның тәмам үзләштереп өлгерүләрен махсус билгеләп үтү зарур. Гамфаң ише (монда лагъмандәге камыр-гарнир урнына дөге кулланыла) деңгәннәрдән кергән тәгам да аларга ят түгел. Бу ише ризыкларны еш куллану җирле яшелчәләр, бигрәк тә ачы борыч-серкәләр белән дуслашуны да тәэмин иткән иде.

Мәгълүм булганча, үз ватаннарында яшәүче татарларның зур өлеше елкы итеннән әзерләнгән казы-карта хакында бөтенләй диярлек онытa язган йәисә аны каклаган казга алмаштырган. Чүгүчәк һәм Голҗа татарлары, хәлләреннән килә калса, сугымга кысыр бия суйдырырга, шуның итеннән казы-карта ыслатырга тырышалар иде. Тик алар казыны Касыйм-Сергач рецепты буенча түгел, бәлки казакъларлардагыча махсус каралтыда төтенгә ыслап, аннары казанда пешереп ашыйлар иде.

Ниһаять, шуны да билгеләп узыйк, соңрак Голҗа-Чүгүчәклердән күченеп китүчеләрнең — яңадан СССРга кайтучы, хәтта Төркиягә йәисә ерак Австралиягә һиҗрәт итүчеләрнең Уйгырстанда иярләшкән ризыкларын һаман яратып ашаулары, йәисә аларны сагынып сөйләүләре мәгълүм...

* * *

Милләттәшләребезнең чит-ят даирәләрдә үз йөзләрен ничек саклавын, шул ук вакытта җирле тормыш элементларын ни дәрәҗәдә кабул итүләрен калку итеп гәүдәләндерә торган күренешләрнең берсе — ул Чүгүчәк һәм Голҗаларда архитектурага, шәһәр төзелешенә алар керткән өлештән гыйбарәт. Моңа иң характерлы мисал рәвешендә Голҗадагы урысчалап «Новый город» дип аталган, аннары җирле халык тарафыннан «Нугай гурыт»ка үзгәртелгән каланы күрсәтергә мөмкин.

Голҗа шәһәренең иске өлеше, шәрык традициясенә муафикъ рәвештә, балчык йортлардан, тар һәм кәкере-бөкере урамнардан гыйбарәт иде. Урамнары да, йорт тәрәзәләре гел кура-ихата ягына гына караганлыктан, «күзсез», «чукрак» шикелле булган. Дөрес, 1871-1881 еллар арасында, ягъни өлкәдә Россия администрациясе хөкем сөргән вакытларда, шул иске шәһәрдә төзелгән берничә кыска урам һәм аерым бииналар үзләренең тышкы кыяфәтләре белән башкаларыннан беркадәре аерылалар иде. Тик мондый урам һәм йортлар, нигездә, Россия консуллыгы тирәләрендә генә булган. Шулай ук XIX гасыр ахырында иске шәһәрдә үсеп чыккан кайбер йортлар, җөмләдән Шәрәфетдин бай Габидов салдырган таш кибетләр һәм соңрак төзелгән татар мәктәбе бинасы да, үзенә күрә яңалык иде. Тик мондыйлар гына гомум стильне үзгәртмәгән.

20 елларның башында исә, югарыда күрсәтелгән һиҗрәт дулкыннары нәтиҗәсендә татарларның саны күзгә күренеп ишәю аркасында, аларга күпләп яңа йорт салу ихтыяҗын тудырган (ТКТ. 52 б.). Шуңа күрә алар күмәкләшеп, шәһәрнең көнбатышындагы, җирле халык телендә «Сай буе» дип атала торган Гулча инеше артындагы буш җирләрне сатып алганнар (шәһәр исеме шул «үзәнчек» мәгънәсендәге монгол тамырлы сүзгә барып тоташа бугай...)

Ләкин йорт салу, шәһәрнең яңа өлешен төзү стихияле рәвештә генә бармаган. Аксакаллардан Фазылҗан Юнич, Хәсән Биктимерев, байлардан бертуган Закирҗан, Ситдыйк һәм Фатыйх Аллаһъярилар, Галиәхмәт Садри, Низаметдин Шәмсетдинев һ. б. җитәкчелек иткән җәмәгатьчелек шәһәр салуда моңарчы Шәркый Төркестан тарихында күрелмәгән юлны сайлаган иде. Иң элек махсус белемле урыслардан җир үлчәүче, төзүче

инженерлар яллап, әлеге сатып алынган җирне төз һәм киң урамлы кварталларга, кварталларны исә аерым хуҗалыкларга биреләчәк төрле зурлыктагы участокларга бүлдергәннәр.

План буенча һәр урамның ике ягында да арык булган. Җәйләрен ул арыклардан бакчаларны сугарыр өчен су килгән, язларын һәм көзләрен исә шул ук арыклар буйлап яңгыр, кар сулары агып киткән. Шуңа күрә урамнарның урта төшләре, читләренә караганда, биегрәк итеп түшәлгән иде. Арыкларның да тышкы якларына (йорт-кура тарафларына) тигез итеп ак тирәкләр — шәм кебек төз, сөңгедәй очлы булып үсә торган затлы чинарлар утыртылган. Аннары киң тротуарлар. Шуннан соң гына йорт-җир биләмәсе башланган.

Тротуардан соң төз сызык буенча йортлар салынган. Урамга карап төзелгән тәрәзәләрнең капкачлары кичләрен ябылган, иртәләрен, йорт йокыдан уянган төсле, ачык торган. Гәрчә йортларның үзләре күп очракта чи кирпечтән (саманның бер төреннән) салынган булсалар да, нигезләр һәм түбә кәрнизләре, гадәттә, яшькелт-соры төстәге яндырылган кирпеч белән тышланган була иде. Йорт диварлары акшарланып, нигез өлешләре корымнан эшләнгән кара белән буялган. Шуңа күрә һәр язда яңадан акшарлана, буяла торган әлеге йортлар, бәйрәмчә киенгән көязләр төсле, күзләрне иркәләп тора иде.

Ара-тирә гел яндырылган кирпечтән төзелгән йәисә саман диварның тышкы ягы таш белән тышланган йортлар да очраштыргалый иде. Шулай да җирле һава шартлары өчен саман кирпеч кулайрак булган: мондый йортлар эссе җәйләрен кызмаган, кышларын исә таш кебек артык суынмаган...

Һәр йортның янында печән төялгән машина сыярлык зур агач капка — урыс капкасы. Тик Голҗа халкы аны «нугай капкасы» дип кенә белә. Тәрәзә капкачлары кебек үк капкаларның да күпчелеге яшелгә, зәңгәргә буялган. Һәр капка янында диярләк дүрт-биш кеше сыярлык такта утыргыч...

Тышкы яктан караганда менә шулай җитди план белән салынган иде Голҗадагы яңа кала — Нугай гурыты. Югарыда әйтелгәнчә, аны планлаштыруда әлек рус белгечләре катнашканлыктан, димәк, беренче чор рәсми документларның күпчелеге дә русча төзелгәнлектән, ул башта «новый город» дигән шартлы исем белән аталган. Әмма анда йорт-җир салып яши башлаган халыкның күпчелеге, кимендә сиксән биш-туксан проценты татарлардан гына гыйбарәт булганга, җирле халык әлеге русча шартлы «новый город» кәлимәсен «Нугай гурыт», ягъни «татар каласы» дигән, тарихи җәһәттән акланган исемгә үзгәрткән.

Голҗада, аның көнчыгыш өлешендә, татар каласыннан тыш, махсус үзбәк шәһәрчеге дә бар иде. «Үзбәк мәлесе (мәхәлләсе)» дип аталган, йорт саны ягыннан «Нугай гурты»ннан бераз зуррак та булган бу милли бистәнең дә архитектурасы үзенчә иде: урамнары тар, кәкере-бөкере, йортлар урамга «аркалары» белән баскан, капкалары кечкенә. Соңрак андый шәһәр төзелешен Ташкентның, Бохараның иске өлешләрендә күрдем.

Шәһәрдә сан ягыннан руслар да шактый иде. Тик алар, әллә дини яктан үзара таркау булганга (православныйлар белән бергә баптистлар, староверлар да шактый иделәр), шәһәрнең төрле төшендә таркау хәлдә яшәделәр. Дөрес, чиркәве белән «Рус гимназиясе» дип аталган зур гына мәктәбен Нугай гурытының төньяк читенә, ләкин шәһәрчекнең территориясенә кертеп салганнар иде. Ихтимал, яңа кала өчен җир бүлеп, аның планын билгеләгән чакта, хезмәттәшлек итүче русларның соравы буенча шулай килеп чыккандыр.

Голҗадагы «Нугай гурыт»ын бик тәфсилләп тасвирлаган Уйгырстан авторлары андый төзек һәм үзенчәлекле архитектурага ия шәһәрчекнең Шәркый Төркестанда башка бер җирдә дә очрамавын билгелиләр (ТКТ, 52 б.). Мондый фикер белән килешергә дә, килешмәскә дә мөмкин.

Чөнки Нугай гурытының, Үзәк Азиядәге бүтән шәһәрләргә туры килми торган хосусиятлары күп булган шикелле, башка җирләрдә, җөмләдән, Россиянең һәр почмагында яшәүче татарларның үз бистә-авылларына да охшамаган яклары бар иде. Беренчедән, бу үзгәлек югарыда күрсәтелгәнчә, төзелеш материалы сыйфатында чи кирпечтән — саманнан файдалануда чагыла. Икенчедән, бакчалы кура-ихаталарда арык системалары булу характерлы. Өченчедән, иң мөһиме, йорт түбәләренең йөздән туксан тугыз очракта чатырлы түгел, бәлки яссы булып, балчык белән түшәлүендә. Ниһаять, дүртенчедән, арыклы-чинарлы урамнарның үзләре дә җирле хосусиятка өстәмә мисал була алалар.

Кыскасы, җыеп әйткәндә, Голҗадагы Нугай гурыт ул Уйгырстан шәһәр архитектурасы өчен зур яңалык булган шикелле, татарларның үзләре өчен дә гадәти, ягъни типик бер бистә — шәһәрчек кенә түгел иде. Башка җирләрдә очрамый торган мондый төзек планлы, үзенчә архитектуралы шәһәрнең барлыкка килүе хакында төрле яклап уйлый торгач, сәер һәм гыйбрәтле генә нәтиҗәгә килдем мин. Голҗага җыелып төпләнгән татарларның болай искитмәле эзлеклелек, шул ук вакытта җирле һава шартларының таләпләрен дә исәпкә ала торган сыгылмалык белән төзек шәһәр салуга омтылулары, шул юнәлештә яңа шәһәр тибын иҗат итә алулары аларның шәһәр культурасына булган тарихи сагышларын гәүдәләндерсә кирәк. Бу фикеремне дөрес аңлар өчен бабаларыбызның XVI гасыр урталарыннан соң шәһәр культурасыннан тәмам дип әйтерлек дәрәҗәдә аерылу, ерак авылларга, чит җирләргә сөрелү, Казагыстан һәм Урта Азия җирләрендә дә йорт-җиргә ия булу хокукыннан мәхрүм ителү фактларын искә төшерү дә җитә. Голҗада исә теләгән төштә җир сатып алу, аны үзеңчә үлчәп-печү, йорт-каралтысын да җаның сөйгәнчә эшләү мөмкинлекләре туган, димәк, иҗатка да юл ачылган иде.

* * *

Мәсьәләне иҗади рәвештә хәл итүне йорт-җирләрнең эчке хосусиятларыннан да күрергә мөмкин. Иң элек, эссе һавалы табигать шартларын исәпкә алып, аш пешерә торган бүлмәне — ашханәне — төп торак бүлмәләреннән аерым салу кулай табылган. Ашханәнең бүлмәсе түгел, хәтта ишеге дә аерым. Анда, казан-учактан тыш, ипи пешерә торган зур кирпеч мич тә була. Күпчелек татар йортларының кура-ихатасында, бер читтәрәк, уйгырча «ипи мичe» — танур (тандыр) да торыр.

Идәне, түшәме такталы, диварлары акшарлы торак бүлмәләре калай белән тышланган «галанка» яисә «контрамарка» системасындагы мичләр белән җылытылган. Голҗада мичкә ташкүмер ягалар иде.

Йокы бүлмәләрендә тимер караватлар, кунак һәм аш бүлмәләрендә исә биек өстәлләр, урындыклар. Түшәк-урын, пәрдә, чаршау, келәм-палас ише «йомшак» җиһазлар гел татарча, шәһәрләрдә яшәүче татарларныкыча. Сәке ише безнең авыл йортларына хас җайланмалар бөтенләй диярлек юк.

Дөрес, кайбер татарларның ашханәләрендә балчыктан эшләнгән, астыннан казан-учактан чыга торган төтен юлы узган, шуңа күрә беркадәре җылына торган «кан» системалы «сәкеләр» дә очраштыргалый иде. Ләкин мондый җылыту ысулы бик сирәк. Күп очракта андый сәкеләр «салкын» булалар иде. Мәгәр аларның өстенә киез яисә иске келәм түшәлү, шуның өстенә тәбәнәк аш өстәле куелу, өстәл тирәсенә көрпәчләр җәелү шактый киң таралган иде. Кунак-төшем булмаганда, шушы ашханәләрдә дә ашап эчәләр (безнең хәзерге кухняләрдә капкалап алу кебек), әмма кеше-мазар килсә, бигрәк тә сыйлы кунаклар булса, табын, һичшиксез, аш бүлмәсендә яисә залда ук әзерләнгән.

Күпчелек йорт-кураларның ишек алдында җәйләрен йөзем яфраклары белән капланган, күләгәләнеп тора торган зур ачык верандалар да эшләтелә иде. Май керүгә үк эссе һәм тынчу аш бүлмәләреннән, бигрәк тә ашханәләрдән качып чыгып, шул йөземле верандада ашапэчәләр, сентябрь ахырларына кадәр шулай дәвам итәләр иде.

Кура-ихатаның түр ягында, торак йорты, ашханә бүлмәләреннән мөмкин кадәр ерактарак, лапас-абзар була. Анда, хәлләренә карап, сава торган сыер, арбага җигәр өчен ат, симертеп суя торган бер-ике баш сарык, аран һәм улаклар булыр яки, иң кимендә, биш-алты тавык кыткылдаган кетәк торыр. Кайдадыр шул тирәләрдә стеналары чи кирпечтән йәисә балчык коймадан (дувалдан) сугылган, чокыры тирән казылган бәдрәф-әҗәтханә.

Кура-ихатаның икенче башында алма, өрек, шафтали, чия агачлары үсеп утыра. (Баштагы план буенча Нугай гуртындагы һәр кура-участокның зурлыгы йорт-җир, абзар-лапас, алма бакчасы өчен җитәрлек дәрәҗәдә исәпләнгән булган; тик соңрак, бакча өчен исәпләнгән өлешнең аерым чыккан балага бүленеп бирелүе йәисә башка кешеләргә кисеп сатылуы аркасында, кайбер хуҗалыкларның андый йорт янындагы бакчалардан мәхрүм булганнары да аз түгел иде.) Шуңа күрә күпчелек гаиләләр өчен җитәрлек өрек, алма, чия, шафтали, йөзем җимешләре һәр йортның үзендә үк үсә, үзендә үк өлгерә иде диярлек.

Дөрес, Нугай гурытта торучыларның берсе дә диярлек кура-ихата территориясендә кишер-суган, бәрәңге- кәбестә ише яшелчәләр үстермәгәннәр. Аларның көндәлеккә кирәкләрен урамнарда кычкыра-кычкыра сатып йөриләр. Гадәттә, «сәйвәңзә» — яшелчәче дип атала торган кытайлар һәм дөңгәннәр. Бик очсызга. Кышлык яшелчәне исә көзләрен потлап-потлап капчыгы белән сатып алып, базга салып куялар. Кавын-карбызларны да дистәләп-дистәләп кенә, хәтта санап та тормыйча, арбалап кына сатып алалар — шулай бик арзанга төшә. (Илленче елларның икенче яртысында илгә кайткан голҗалы татарларны иң беренче гаҗәпләндергән, сәерсендергән күренешләрнең берсе — ул җиләк-җимеш һәм яшелчәләрнең күпчелеген базарларда килолап, граммлап сату иде...)

Шулай итеп, йорт-җирнең эчке тәртибендә дә Голҗа татарлары, ул якларга нисбәтән оригинальлыкны саклаган хәлдә, җирле шартлардан килеп чыккан тәртипләрне дә үз иткәннәр, үзләштергәннәр икән.

* * *

Татарларның Шәркый Төркестан җирләренә алып килгән мөһим яңалыкларының берсе мунча дисәм, әллә ни ялгышмамдыр кебек. Моның белән мин уйгырларны юынмый торган халык дип әйтергә җыенмыйм. Зур шәһәрләрдә хаммамнар эшләгән, өйләрендә исә алар, ислам кагыйдәләрен җитди рәвештә үтәүче мөселманнардан буларак, госел коенганнар, тасларда утырып юынганнар (базарларда тегермән ташы кадәрле җиз һәм калай таслар — дәү ләгәннәр сатыла иде). Әмма «пешеп үләрлек» кайнар сулы, җәһәннәмдәй эссе ләүкәле мунчалар ул яклар өчен барыбер ят нәрсә булган. Моның шулай икәнлеген Голҗадагы бер фактган да күрергә мөмкин. Андагы шәһәр халкына хезмәт күрсәтүче җиде мунчаның берсе хөкүмәт милке, икенчесе ул якларга егерменче елларда килеп чыккан Чехов исемле урыс кешесенеке булса, калган бишесе татарларныкы иде. Боларның да беренче дәрәҗәлесе Төмәндә туган, Симидә пристань тоткан, гасыр башында ук Голҗага күченеп килгән Себер бае Миркасыйм хаҗи Миршанов төзегән зур мунча булды.

Авыл-кышлакларда торучы татарлар исә, туган якларына хас гадәт буенча, мунчаларын су буйларына илтеп салырга яратканнар. Мондыйлары уйгырларның җырларына да кергән:

Үстәң якыйлап маңсам,
Нугайларның мунчаси,
Кечик кинә ярым бар —
Кызыл гулниң гончаси...

(Канал буеннан барсам, Нугайларның мунчасы, Кечкенә генә ярым бар — Кызыл гөлнең гонҗәсе... — ТКТ, 46 б.)

## Кайда барса да Тукае белән

Төрле язмышлар, төрле юллар, төрле кәсеп-сәбәпләр аркасында Шәркый Төркестан җирләренә җыелган татарлар ул якларга, кем әйтмешли, төркеме-төркеме белән үзләренең «җен-пәриләрен дә» бергә алып барганнар иде. Пәйда булулары белән берәүләрен сөендергән-көендергән андый «җен-пәри» дигәнебез иң элек театр уйнау эше бу якларда моңарчы бер дә күренмәгән «коточкыч бидгатләр»дән — гөнаһлардан гыйбарәт булган. Моның шулай икәнлеген аңлар өчен, сан ягыннан аз булса да, гел русча киенеп йөри торган үз морзалары, тылмачлары булган татарларны алып карыйк. Урам тулы ачык битле марҗаларына күнегеп беткән шул Казан, Уфа, Оренбург мөселманнарының да театр сәнгатен никадәре авырлык белән кабул итүләрен искә төшерик.

Шәрекъ дөньясының бер кечкенә кисәген, хәтта аның да Урта гасырлар торгынлыгында озаграк тоткарланган караңгы почмакларыннан берсе булган, шуңа күрә һәр яңалыкка карата бигрәк тә «җитди», кырыс кыланган Уйгырстан шартлары өчен театр сәнгате тагын да куркынычрак афәт рәвешендә тоелган булса, бер дә гаҗәп түгел. Әллә кемнәрнең, халык алдына чыгып, юри «шамакайланулары», бигрәк тә хатын-кызларның, хак мөселманнар алдында, пәрәнҗәле чапан бөркәнеп йөрисе урынга, әдәпсезләнеп йөз яшермәүләре...

* * *

Дәрес, Шәркый Төркестан җирләренә беренче булып аяк баскан татарларның үзләре өчен дә театр-мазар ят нәрсә иде әле. Шулай да, уйгырларның «мөселманлык әкрен генә иңәр» дигән мәгънәдәге мәкаленә муафикъ рәвештә, татарларның бидгатләре дә, сизелмичә генә дигәндәй, тамыр җибәреп ала. Күченеп килүче халыкның саны ишәюгә бәйле бу процессның беренче чаткылары дөньяви татар мәктәбе ачылу белән «ялтырый» башлый. Элек андый чаткылар укучы балалар, аннары аларның ата-аналары өчен оештырылган әдәби кичәләр, үзешчән концертлар рәвешендәрәк барлыкка килә. Габдулла Бубиның инде безгә мәгълүм язмаларында 1914—15 елларда ук Голҗада әдәби кичәләр уздыру фактлары кат-кат телгә алына. Шунда ук автор кайбер мөтәгассип татар байларының, аларны хуплаучы җирле руханиларның мондый яңалыкларны өнәп бетермәүләрен, кайбер әдәби кичәләрне, концертларны уздырмаска маташуларын да теркәп куя. Тәгәрмәчкә таяк тыгучылар арасында Россия консулының булуы да күрсәтелә (ул хәтта концерт вакытында мәктәп өчен хәйрия максатыннан җыелган акчаны да тартып алуга кадәр барып җиткән икән).

Югарыда фанатик руханиларның татар мәктәбенә дәрес вакытларында басып керү, яңа җиһазларны җимерә-җимерә «инспекция» ясау фактлары китерелгән иде. Мондый тупас тыкшынуларга бер сәбәп «мах-

сус кызлар мәктәбе» ачылу булса, икенче мөһим сәбәпнең әлеге әдәби кичәләр, концертлар икәнлеге дә бәхәссез.

Голҗага Г. Буби һәм башкалар килү, Россиядән вакытлы татар матбугаты агыла башлау белән царизм хөкүмәтенең Кытайдагы үз «подданныйлары» арасында мәгърифәтчелек хәрәкәте канат җәюдән, революцион фикер таралудан куркуы патша консулының әле күрсәтелгән гамәлләреннән дә ачык чагыла. Шулай итеп, империянең үзендә генә түгел, ерак Уйгырстан җирләрендә дә татарлар арасындагы прогрессив хәрәкәтләрне бастыру юлында патша хөкүмәте надан байлар, фанатик руханилар белән кулга-кул тотынышып эшләгән иде.

Әмма яңалык барыбер җиңеп чыга. Һәрбер төбәктә диярлек илдәшлекләрнең үзара саннар ишәеп, саннар сыйфатка әверелә барган саен, әдәби һәм үзешчән түгәрәкләрнең төрләре дә, эчтәлекләре дә күзгә күренеп үзгәрә. 20 елларда ук Чүгүчәктә, Голҗада, мәсәлән, кыллы инструментлардан торган махсус музыкаль түгәрәкләр оеша. Түгәрәк әгъзалары моннан элегрәк яшерен рәвештә җыела торган хосусый квартиралардан чыгып, мәктәп биналарында шөгыльләнә башлыйлар. Мандолина, гитара, скрипкәләрдә уйнарга өйрәнүләрдән тыш, гадиләштерелгән ноталар ярдәмендә көй-җыр текстлары да күбәйтелә. Милли татар моңнары белән бергә, русча романслар, казакъча, испанча, французча бию көйләре дә күбәйтелә.

* * *

Аерата әдәби-драматик түгәрәкләрнең эшчәнлекләре активлаша. Кара байларның, мөтәгассип муллаларның андый түгәрәкләргә катнашучыларны «урам себеркеләре» дип әрләүләренә җавап рәвешендә Чүгүчәктәге, аннары Голҗадагы татар яшьләре Галиәсгар Камалның «Беренче театр» исемле сатирик комедиясен сәхнәгә кую белән җавап бирәләр (ТКТ, 41 б.). Гомумән, Чүгүчәк, Өремче, бигрәк тә Голҗа шәһәрләрендәге драмтүгәрәк һәвәскәрләре тарафыннан 20-50 еллар арасында, Г. Камал әсәрләреннән тыш, Мирхәйдәр Фәйзинең «Асыльяр», «Галиябану», Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар», Х. Ибраһимовның «Башмагым», Фәтхи Бурнашның «Таһир-Зөһрә», Мирсәй Әмирнең «Көнлекче Әхмәт» пьесалары кат-кат сәхнәгә куелганнар иде. Мондый зур күләмле спектакльләрдән тыш, җыр-бию концертлары вакытында аерым пьесаларның өзекләре, бер пәрдәлек скетчлар да тамашачылар игътибарына тәкъдим ителгәли иде.

Зур күләмле спектакль дигәннән, 40 еллар урталарында «Таһир-Зөһрә» трагедиясенең куелышы ике кич дәвам иткәнлеген, бу спектакльгә керүнең төгәл бер проблемага әверелүен олырак яшьтәге голҗалылар озак вакыт риваять итеп сөйләделәр. (Безнеңише малайшалайларга өйдә елап калу, аннары зурларның дулкынлана-дулкынлана фикер алышуларын тыңлау бәхете генә эләккән иде...)

Голҗадагы драмтүгәрәк хакында сөйләгән чакта аның эшенә иң актив катнашучылардан Мәхмүд Аллаһъяри, Маһинур Сиражи, Нәҗия Төхфәтуллина, Рәхим Сәфәргали, Гыйләҗетдин Хәйри, Хәмит Төхфи һ. б. исемнәрен махсус атарга кирәк.

Спектакльләр чын-чынлап сәнгать әсәре булсын өчен аларга бутафория элементлары, җөмләдән грим ясау осталыгы да кирәк иде. Гримерлык «ролен» 30—40 елларда күренекле җәмәгать эшлеклесе, өлкә газитәнең баш мөхәррире Хәбиб Юнич, иң абруйлы укытучыларның берсе Малик Биктимеревләр башкарган иде.

Рәхим ага Сәфәргали (1906—1970, Алма-Атада вафат) драмтүгәрәк эшчәнлегенә артист буларак та, аның әдәби «секторын» җитәкләүче сыйфатында да актив катнашкан иде. Бу «шигырь җене кагылган», үтә хиснә бирелүчән кеше башкаларны да мавыктыру сәләтенә ия иде. Рәхим ага

җитәкчелегендә «Галиябану» пьесасы буенча Голҗада куелган спектакль соңгы тамашаларның берсе булды бугай. Кыш буе барган күңелле репетицияләрне, зал тулы тамашачылар белән очрашу минутларын хәтерләткән кечкенә фоторәсем аерата кадерле миңа. Ул 1953 елның мартында төшерелгән.

1954 елда исә тагын һиҗрәт дулкыннары башланды...

* * *

Шәркый Төркестан татарлары арасындагы һәвәскәр театрчылык хакында сөйләгән чакта бу күренешнең уйгыр җәмәгатьчелеге тарафыннан, гомумән, ничек кабул ителүен белү дә әһәмиятле. Димәк, Уйгырстан авторларының үзләренә сүз бирү дөресрәк булыр. «Татар халкы, — диелә моңарчы кат-кат мөрәҗәгать ителгән китапта, — үзләренең театр сәнгатен, сәхнә эшләрен булдыру һәм үстерүгә күңел бирүләре белән генә чикләнмичә, кардәш милләтләрдән уйгыр, үзбәк, казакъ халыкларының да театр сәнгатьләре тууга, үсүгә зур өлеш кертте. Уйгыр, үзбәк халыклары арасында феодаль тәртипләр озаграк хөкем сөреп, иске карашлар өстенлек иткәнгә күрә, сәхнәләргә хатын-кызларның чыгып уйнаулары бөтенләй мөмкин булмаган хәл иде. Шундый авыр шартларда оеша башлаган уйгыр, үзбәк театр һәвәскәрләре зур кыенлыклар кичерәләр, хатын-кыз рольләрен ирләргә тапшырырга мәҗбүр булалар иде. Менә шул вакытта ярдәмгә татар хатын-кызлары килделәр. Алар үзешчән уйгыр, үзбәк, казакь театрларында хатын-кыз рольләрен оста башкарып, спектакльләрнең уңышка ирешүен тәэмин иттеләр» (ТКТ, 42 б.).

Китап авторларының бу хәбәрен үз истәлекләрем белән дә куәтли алам. 1942—43 елларда (төгәл әйтә алмыйм) югарыда телгә алынган Дахыяңзы кышлагында торган чагыбызда да, җирле уйгыр мәктәбенең укытучылары да бер спектакль куйганнар иде. Аның нинди әсәр һәм кемнеке булуын хәтерләмим, билгеле. Шулай да сәхнәгә алсу төсле хатын-кыз күлмәген кигән, каш-күзләрен кап-кара, бит-кыяфәтен кып-кызыл итеп, кирәгеннән артык буяп ташлаган, какча гәүдәле, колгадай озын буйлы бер мөгаллимнең чыгуы әле дә күз алдында. Чөнки моңарчы тып-тын утырган тамашачыларның гөҗ килеп шаулый башлаулары, шаркылдап көлеп җибәрүләре хәтердә уелып калган. Ләкин шул вакытта үземдә туган бер сорауга әле дә җавап таба алмыйм: ни өчен бу рольдә шул ук мәктәптә мөгаллимә булып эшләүче, безгә килгәләп йөри торган татар кызы Фәйрүзә апа чыкмады икән? Әллә ул мескен ятимә кыз үзенең бик нык шадра булуыннан оялды микән? Хәер, мин бераз читкә тайпылдым бугай...

Башка тугандаш милләтләрнең театр хәрәкәтләре тууга, тернәкләнүгә өлеш керткән күпсанлы татар хатын-кызлары арасында Фәридә Алиева аерата дан казанган. Аның хакында мондый сүзләрне укыйбыз: «Фәридә Алиеваның сәхнә хәяты Чүгүчәктә башланган булса да, ул 1936 елны Өремчегә күчеп килгән һәм анда татар театрына катнашып, «Асылъяр», «Сүнгән йолдызлар», «Башмагым», «Галиябану», «Көнлекче Әхмәт», «Яшәртү» исемле спектакльләрдә катнашкан иде. Ул, болар белән генә чикләнмичә, «Гариб-Сәнам», «Фәрһад-Ширин», «Анаргөл», «Рабига-Сәгыддин», «Чиңмудән» ише уйгырча спектакльләрдә баш рольләрдә уйнаган иде. Шулай ук казакьча спектакльләрдән «Кыз Җебәк», «Шога» исемле әсәрләрдә дә төп рольләрне башкарып, «Шенҗаң болбылы» дигән исемгә лаек булган иде» (ТКТ, 43 б.).

Голҗадагы татар хатын-кызлары да тугандаш халыкларның драмтүгәрәкләренә актив катнашканнар. Моның хакта шул шәһәрдә яшәгән, иҗат иткән үзбәк шагыйре Насрулла Фәрһатиның истәлеге сакланып кал-

ган: «Ул елларда үзбәк һәвәскәр театры тарафыннан куелган «Арзыгөл», «Ләйли-Мәҗнүн», «Пәдәр көче» (ата ихтыяры — М. Г.) шикелле драматик һәм музыкаль әсәрләрдә катнашкан татар хатын-кызлары рольләрне бик оста башкарсалар да, телләрен бөтенләй үзгәртә алмыйлар иде. Сөйли башлауга ук тамашачылар сәхнәдә татар кызлары икәнлеген белеп алалар иде. Шулай да уен күңелле дәвам итеп, уңышлы тәмамлана иде» (ТКТ, 44 б.).

Күп тә узмый, татар хатын-кызлары салган бу сукмаклар буенча сәхнәгә уйгыр, үзбәк, казакъ хатын-кызлары да чыга башлый. Шул рәвешчә яңалык тәмам җиңә. Ул гадәткә әверелә.

* * *

Татарлар китергән «җен пәриләр»нең икенче бер төркеме сыйфатында матбагачылык һәм әдәби хәрәкәт сыманрак күренешләрне дә атарга мөмкин.

Уйгырларның безнең матбагачылыкка мөнәсәбәтләре хакында сөйләгән чакта, татар гәзитә-журналлары белән уйгыр зыялылары элек-электән үк яхшы таныш булуын истә тотарга кирәк. Кырымтатар телендә атаклы мәгърифәтче Исмәгыйль бәй Гаспралы чыгарган «Тәрҗеман» гәзитәсенең XIX йөз ахырларында ук Төркестан җирләрендә укылуы хакында мәгълүматлар күп.

1905 елдан соң Казан һәм Оренбургларда күпләп чыккан гәзитә-журналларда Уйгырстанда яшәүче татарлар аркылы ул якларда киң таралыш таба. «Вакыт» гәзитәсе, «Шура» журналы битләрендә Шәркый Төркестан хәбәрләре, хәтта уйгыр авторларының материаллары да басыла башлый. Мәсәлән, уйгыр шагыйре Назархуҗа Габдесамат «Шура»га үз иленең хәлләре, туган халкының мәдәнияте хакындагы кызыклы мәгълүматлар белән катнаша.

Матбагачылык тарихына кагылабыз икән, СССРдагы уйгырлар белән мөнәсәбәтне дә онытмаска кирәк. Алма-Атада чыга башлаган «Садаи Таранчы» (Таранчы тавышы) исемле гәзитәнең редакторы шагыйрь Зариф Бәшири иде. Тәҗрибәле татар журналистларыннан Сабирҗан Шакирҗанов-Кормаши, Кәбир Бәкер, Фатыйх Сөләймановлар да Җидесуда уйгыр вакытлы матбугаты оешуга өлеш кертәләр. (С. Моллаудов, Г. Сәгъдеваккасов мәкаләсеннән карагыз: «Казан утлары», 1967, № 9; Совет уйгыр матбугаты хакында киңрәк мәгълүматны түбәндәге уйгырча китаптан табарга мөмкин: Мөнир Ерзин. Уйгыр совет матбугатының тарихы. Алмута, 1980. Китап авторы Уйгырстаннан кайткан татар кешесе. (Советлар илендәге уйгырлар тарафыннан чыгарылган мондый гәзитә-журналлар Шәркый Төркестан җирләрендә дә беркадәре таралыш таба. 20—30 елларда Голҗа, Чүгүчәк, Өремче һәм башка шәһәрләрдә дә уйгырча гәзитәләр чыга башлый. Җирле татар укымышлылары да әлеге хәрәкәткә сизелерлек өлеш кертәләр.

Объективлык өчен сүзне уйгыр авторларына бирү хәерлерәктер. Мәсәлән, Шәркый Төркестанда туып үскән, ул якларның тарихын, мәдәниятен яхшы белгән шагыйрь һәм журналист Торсын Каһһари болай яза: «Уйгыр-татар мәдәни бәйләнешләрнең матур үрнәкләрен матбугат өлкәсендәге хезмәттәшлектә дә күрергә мөмкин. Чөнки Шәркый Төркестандагы Голҗа, Чүгүчәк шәһәрләрендә торучы татарлар җирле уйгырлар, казакълар белән тыгыз аралашып яшиләр, аларның телләрен, гореф-гадәтләрен яхшы беләләр, омтылышларына теләктәш булып, төрле өлкәләрдә кулга-кул тотышып гамәл итәләр. Менә шушы табигый бердәмлекне расларга теләгәндәй, җирле матбугат та, гәрчә ул нигездә уйгыр һәм казакъ телләрендә чыгып килсә дә, тату яшәгән тугандаш халыклардан татар һәм үзбәкләр өчен дә аңлаешлы җиңелрәк телдә басыла, аларның барысына да бертигез дәрәҗәдә хезмәт итә. Әлбәттә,

гарәп әлифбасы нигезендәге язуның да традицион уртак булуы мондый хезмәттәшлек өчен вакытында яхшы җирлек була. Мондый хезмәттәшлеккә китергән сәбәпләр турында сөйләгәндә, уйгыр журналистикасының чагыштырмача яшь, ә татарларда исә матбагá өлкәсендә электән үк бай тәҗрибә тупланыуын күрсәтергә кирәк. Менә шуңа күрә 1934 елда Голҗада «Элә дәрьясы», аннары «Шенҗаң-Элә гәзите» исемендә уйгыр телендә чыккан гәзитәнең оештыручысы һәм баш мөхәррире исеме кат-кат аталган татар җәмәгатьчелегенең аксакалы Фазылҗан Юничнең угылы Хәбиб Юнич (1906—1945) булган булса, 1945 елдан соң нәшер ителгән «Инкыйлаби Шәркый Төркестан гәзите»нә татар мәктәбенең элекке укытучысы Әсгать Исхаков (1921—1976) җитәкчелек итә. (Бу кеше соңрак зур дәүләт эшлеклесе дәрәҗәсенә күтәрелә, әмма 60—70 елларда котырынган «культура революциясе» вакытында төрмәдә һәлак була — М. Г.).

Матбугат өлкәсендәге бу хезмәттәшлек татар белгечләренең оештыру эшләренә актив катнашуы белән генә чикләнми, әлбәттә. Алар тарафыннан язылган материаллар да җирле гәзитә-журналларда еш басыла. Сыйфатлы әсәрләр язып, гәзитә-журналларның эчтәлеген баетуда сизелерлек өлеш керткән журналистлардан Борһан Шәһиди, Рәхим Сәфәргали, Әнвәр Локман, Хәмит Төхфи, Мөнир Ерзиннарны махсус атап күрсәтергә кирәк. Болардан әдәбият өлкәсендә Рәхим Сәфәргали белән Хәмит Төхфи бигрәк тә актив эшлиләр» (Торсын Каһһари. Уйгыр-татар мәдәни багланышлары тарихыннан. «Казан утлары», 1977, № 11, 162—163 бб.).

* * *

Татарлар үз ана телләрендә дә вакытлы матбугат булдырырга омтылып карыйлар. Мәсәлән, 1933 елда Рәхим Сәфәргали һәм Татар мәдәни-агарту оешмасының икенче актив әгъзасы Мирзакамал Хәйриләр татарча журнал чыгару эшенә алынмакчы булалар. Тик җирле хөкүмәт мондый омтылышка юл бирми. (Әмма кысу һәм чикләүләрнең иң авыры туган илдән, сталинизм хөкем сөргән СССРдан татарча китаплар, гәзитә-журналлар аз килү, хәтта вакыт-вакыт бөтенләй өзелеп тору дисәм, әллә ни арттыру булмас.) Шулай да, мондый тыюларга, чикләүләргә карамастан, халык үз әдәбияты белән кызыксынудан туктамады. Моңа, ихтимал, татар мәктәпләрендә укыла торган әсәрләрнең кайберләре уйгыр мәктәпләре программаларына кабул ителү, шул рәвешчә милли горурлык өчен стимул арту фактлары да өлешчә сәбәп булгандыр. Һәрхәлдә, яңача белем алган уйгыр укымышлылары яңа дәвер татар әдәбиятыннан беркадәре хәбәрдар булалар иде.

Мәсәлән, Г. Тукайның «Туган тел», «Шүрәле» әсәрләре уйгыр мәктәпләрендәге барлык уку программаларына кертелгән булуы (Т. Каһһари. Күрсәтелгән мәкалә, 162 б.) үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли.

Яшь уйгыр зыялылары арасында Һади Такташ шигырьләре дә мәгълүм иде. Милли азатлык өчен көрәш юлында яшьли корбан булган ялкынлы уйгыр шагыйре Лотфулла Моталлибның татар мәктәбендә укыган чакта Тукай һәм Такташ чишмәләреннән су эчүен уйгырлар һәрвакытта да махсус билгеләп узалар (ТКТ, 32 б., Т. Каһһари, 162—163 бб.).

Уйгырлар арасында төрле чаралар белән классик татар әдәбиятының үрнәкләре, мәсәлән, Тукай—Такташлардан тыш, Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов, Фатыйх Әмирхан, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев әсәрләре дә пропагандалана иде. Җирле татарлардан да уйгырча матбугатта үз әсәрләрен, бигрәк тә шигырьләрен, татар телендә бастыручылардан иң элек Хәмит Төхфине атарга кирәк. Бу хакта Т. Каһһари болай яза: «Ул

1944 елдан башлап «Азат Шәркый Төркестан», «Инкыйлаби Шәркый Төркестан», «Алга» газиталәрендә, «Иттифак» журналында, «Альманах» исемле җыентыкта күпләгән шигырьләр бастырды... Аның көрәшкә өндәү рухы белән сугарылган ялкынлы әсәрләре... әле бүген дә үз әһәмиятен югалтмаган. Чөнки аның иҗаты Шәркый Төркестандагы тарихи вакыйгалар, иҗтимагый шарт, көрәш хәрәкәтләре белән тыгыз бәйләнгән» («Казан утлары», 1977, № 11, 163 б.).

Алга таба күрербез, бу «иҗтимагый шарт» һәм «көрәш хәрәкәтләре» дигән нәрсәләр тормышның үзен дә тамырдан үзгәртеп ташлый...

Татар әдәбиятының Шәркый Төркестан халыклары арасында болай популярлык казануында, басма сүздән тыш, ул якларда эшләгән күпсанлы мөгаллимнәр белән бергә татар җәмәгатьчелекләре уздыра торган әдәби кичәләрнең дә рольләре аз булмагандыр дип уйларга мөмкин. Андый әдәби кичәләрнең беренчеләре Габдулла Буби тарафыннан 1914—15 елларда оештырылган булуын бер кат әйткән идем инде. Бу традиция Голҗада моннан соң да өзелмичә дәвам итте диярлек (Чүгүчәк, Өремче якларында да андый түгәрәкләрнең актив эшләгәнлеге мәгълүм).

* * *

Шагыйребез Габдулла Тукай истәлегенә багышлана торган әдәби кичәләр аерата популяр иделәр. Тормыш шартлары, иҗтимагый-сәяси вәзгыятьләр мөмкинлек биргән саен Тукайга багышланган кичәләр уздырылып килде. 1944—45 елларда Шәркый Төркестанның төньяк-көнбатыш өлкәләрендә, ягъни тарихи Җуңгариядә милли-азатлык өчен көрәш сугышлары кабынып киткәнлектән, 1946 елны Тукайның 60 еллык юбилеен махсус билгеләү өчен мөмкинлекләр булмый. Шуңа күрә шагыйрь истәлегенә багышланган бәйрәмнәрне 1947 елда уздырырга туры килә. Бу тантананың әдәби кичә өлешенә, унөч яшьтәге мәктәп укучысы буларак, үзем дә якыннан катнашкан идем. Әмма аның хактагы сүзне, вакыйгаларның әһәмиятен вакытында ук яхшы аңлап истәлекләр язган Торсын Каһһарига бирәм. Ул әлеге бәйрәм көннәрен шактый төгәл тасвирлый (кайбер өстәмәләрем җәяләр эчендә тәкъдим ителер).

«...600 дән артык кеше сыйдырышлы зур зал, тантаналы итеп җыештырылган сәхнә әле дә күз алдында. Сәхнә түрендә шагыйрьнең зур портреты чәчәкләргә күмелеп тора. (Аны татар егете Гаяз Исхаков ясаган, аннары шул рәсемнән фотоиллюстрацияләр эшләп таратылган иде — М. Г.) Тукайның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган (Рәхим Сәфәргали укыган — М. Г.) докладтан соң, тантаналы кичәнең әдәби-музыкаль өлеше башланды. Сәхнәгә бер-бер артлы яшьләр, мәктәп укучылары чыга; җырлар яңгырый, шигырьләр укыла. Шагыйрь әсәрләре нигезендә эшләнгән инсценировкалар куела...

Тәнәфес вакытында зур фойега чыгабыз. Анда — җирле рәссамнар тарафыннан Тукай әсәрләренә ясалган рәсемнәр күргәзмәсе. Менә бүрәнәгә кулы кысылган кыргый — мәгәр күңелләргә күптән таныш, якын Шүрәле, әнә елга чоңгылыннан атылып чыккан Су анасы...

Әмма Голҗа татарлары тарафыннан зур әзерлек, тырышлык белән уздырылган бу кичәдән калган иң мөһим истәлек, минемчә, Тукай шигырьләреннән тупланган кечкенә мәҗмуга булды. Мин хәзер дә аны еш-еш кулга алам. Аның тышлыгында эре хәрефләр белән: «Г. Тукай. Сайланма шигырьләр» дип басылган. Бераз түбәндәрәк мондый багышлау: «Шагыйребез Габдулла Тукайның дөньяга килүенә 61 ел тулу мөнәсәбәте белән бастырылды». Иң аста — «Нәшире: Голҗа татарларының мәдәни җәмгыяте. 1947. Голҗа», — дигән сүзләр язылган.

Югарыда әйтелгәнчә, бу китап авыр шартларда, сугыш хәрәкәтләре тәмам сүрелеп җитмәгән бер чорда басыла. Шуңа күрә аның күләме артык зур түгел: тышлык һәм титул битләрен исәпкә алмаганда, барлыгы 17 генә бит. Ләкин мәсьәлә китапның күләмендә түгел, бәлки эчтәлегендә һәм рухында иде. Чөнки Шәркый Төркестанның бер өлешендә карагруһ гоминданчылар хакимиятен бәреп төшергәч дөньяга чыккан бу китап символик мәгънәгә ия.

Җыентыкның икенче битендә шагыйрьнең портреты бирелгән, туган һәм үлгән еллары күрсәтелгән (рәсем авторы Г. Исхаков — *М. Г.*). Хәмит Төхфи тарафыннан язылган ике битле кереш сүздән соң 22 шигырь бирелә: «Шагыйрь», «Әхлаксызлык», «Нәсыйхәт», «Алтынга каршы», «Сәрләүхәсез», «Милли моңнар», «Чын вә ялган», «Кыйтга», «Шекспирдан», «Толстой сүзләре», «Өзелгән өмит», «Сагыныр вакытлар», «Ваксынмыйм», «Тәләһһеф», «Теләнче», «Буран», «Туган җиремә», «Төлке вә йөзем җимеше», «Васыятем», «Тәэсир», «Туган тел», «Пар ат» (Китапның «Шагыйрь» кебек программа характердагы әсәрдән башланып, «Туган тел» һәм Казанга багышланган «Пар ат» белән тәмамлануы, һичшиксез, игътибарга лаек факт. Җыентык 20 нче елларда Татарстанда гамәлдә булган, яңартылган гарәп алфавитында, әсәрләрнең тел-стиль үзенчәлекләре сакланган рәвештә басылган — *М. Г.*).

Җыентыкка кергән әсәрләрнең Тукай мирасын, бу ялкынлы иҗатның кайбер үзенчәлекләрен әзме-күпме чагылдыруын әйтү белән бергә, кереш мәкаләнең дә идея юнәлешенә, рухына игътибар итәсе килә: «Тукайның яшәгән дәвере, — диелә анда, — Чар Русиясенең (чар — патша. — *М. Г.*) иң котырган дәверенә туры килгәнгә, аның күпләгән шигырьләре иҗтимагый характерга ия булды. Ул үзенең шигырьләрендә залимнардан, өстен сыйныфлардан ачы көлде, изүчеләрне аяусыз рәвештә сүкте...»

Ниһаять, Казаннан әллә кайларда еракларда татар телендә чыккан бу китапның 700 нөсхәдә «Инкыйлаби Шәркый Төркестан» исемле уйгыр халык матбагасында — демократик рухтагы нәшриятта басылып чыгуын искәртеп узасы килә.

...Минем кулдагы бу кечкенә китап дөньяга чыкканнан бирле бик күп җилләр исте, бик күп сулар акты» (Торсын Каһһари. Уйгыр-татар мәдәни багланышлар тарихыннан. — «Казан утлары», 1977, № 11, 164—165 бб.).

Форсаттан файдаланып, истәлеккә шуны гына өстисе килә: 1986 елны, Тукайның 100 еллыгына катнашу өчен Казанга килгән Т. Каһһари, әлеге китапның уникаль нөсхәсен Казан университеты китапханәсенә бүләк итте.

Тасвирланган тарихи вакыйгалар хакында минем үземдә дә бер зур һәм кадерле истәлек саклана, дөресрәге, язу өстәлем янында стенада эленеп тора. Ул — әлеге кичәдә сәхнәдә торган Тукай сурәтенең кечкенә генә фотокүчермәсе...

## Тагын һиҗрәт...

Укучы игътибар иткәндер, язмаларымның соңгы өлешләрендә социаль һәм сәяси төшенчәләрне аңлаткан сүзләр күбрәк очрый башлады: иҗтимагый шартлар, милли-азатлык көрәше, өстен сыйныфлар, сугышлар һ. б. Бу очраклы түгел. Чөнки 40 елларның урталарында элек тә бик үк тыныч булмаган Уйгырстан җирләре кискен иҗтимагый сәяси бәрелешләр, сугышлар аренасына әверелгән иде. Хәер, 40 елларның вакыйгаларын дөрес аңлар өчен, сүзне, кыскача булса да, 30 еллардан ук башларга кирәктер.

Югарыда 1933—34 елларда Дөңгән сугышлары исемендә кабынып алган баш күтәрү хәрәкәтләрен телгә алган идем инде. Чынлыкта бу ел-

ларда бер-берсенә башка булган өч-дүрт юнәлештәге көчләр бәрелешәләр. Жөңгария якларындагы гади халык исә моны дөңгәннәр белән уйгырлар, йәисә дөңгәннәр белән кытайлар арасындагы сугыш яки революция хәрәкәте рәвешендәрәк аңласа һәм, рәсми әдәбиятта шулай аңлатылса да, ул асылда Кытай дәүләте тирәсендә зур мәмләкәтләр арасында барган катлаулы көрәшнең тышкы чагылышы иде. Дөресрәге, зур империалист мәмләкәтләр җирле реакция белән демократик, милли азатлык чаткыларын ясалма рәвештә кыздырып, дөрләтеп җибәргән иде. Чөнки Шәркый Төркестан өлкәләренең чималы һәм җирасты байлыклары өчен XIX йөздә кабынып алган көндәшлек дәгъвалары XX гасырда да дәвам иткән.

Һәрхәлдә, кем нәрсә генә сөйләмәсен, шул «Дөңгән сугышлары» нәтиҗәсендә Шенҗаң провинциясендә хакимиять башына, Гоминдаң хөкүмәтенең иске вәкилләрен бәреп төшереп, Шең-шисәй исемле яңа генерал-губернатор килә. Тиздән ул бөтен Шенҗаң җирендә эчке Кытай хөкүмәте белән артык исәпләшмәгән «мөстәкыйль политика» йөртә башлый. Совет дәүләте белән тыгыз мөнәсәбәтләр урнаштыра, сәүдә-экономик бәйләнешләренә киң мөмкинлекләр бирә. Сәясәт өлкәсендә исә баштарак, чамалап кына, социализм идеяләрен пропагандалауга да юл куя ул. Шуңа күрә Шең-шисәйне кайберәүләр коммунист дип игълан иттеләр, икенчеләре соңрак фашист дип тамгаладылар. Чынлыкта аның кем булганын бер алла гына беләдер. Шулай да бер нәрсә бәхәссез: башта тормышка кайбер демократик элементлар, хөкүмәт идарәсенә беркадәре төзеклек биргән Шең-шисәй 1937—1939 елларда Шәркый Төркестанда тоталь репрессия кампанияләре дә уздырган иде. Шул елларда Шенҗанда кулга алынган, төрмәләрдә черетелгән кешеләрнең саны йөз меңнән артып китә (ТКТ, 55 б.). Бу корбаннар арасында йөздән артык татар кешеләре дә бар иде.

Бер үк вакытта Шең-шисәйнең шәхес культы да урнаштырыла: кайда карама, аның портретлары. Исеме дә аның хәзер үзгәрә төшкән — Шең-дубән. Урам-мәйданнарда гел шул исем... Рәсемнәргә килсәк, берсендә ул алты чатлы йолдыздан торган зур кокардалы фуражкадан булыр. Икенчесендә аргамак атка атланган. Өченчесендә, атын сикертеп баскан килеш, кылычы белән кизәнеп торыр, җилкәсендә исә Кавказ буркасы сыманрак нәрсә булыр. Дүртенчесендә — җитди кыяфәтле, генерал кителендә... Кыскасы, тегендә «халыклар атасы» Сталин бабай булса, монда «мәрхәмәтле һәм баһадир» Шең-дубән хәзрәтләре!

Дөрес, беркадәре аерма да булды бугай. Мәсәлән, «халыклар атасы», хәзер мәгълүм булганча, коллективизация дәвамында конфискацияләнгән байлыкка, малга ач калырга хөкем ителгән колхозлар, совхозлар яки үзен-үзе туйдыра алмый торган гигант заводлар төзегән, репрессияләнгән миллионнарның сөякләре белән гигант дәүләтнең иксез-чиксез кысыр киңлекләрен ашлаган икән. Шең-дубән исә башта социализм идеяләре файдасына авышкан алдынгы яшьләрне, ачык фикерле зыялыларны меңәрләп-меңәрләп төрмәләргә яшергән, үзенә ошамаган байларның мал-мөлкәтен конфискацияләгән иде. Ләкин завод-фабрикалар да, колхоз совхозлар да төзеп тормаган ул. Җыелган байлыкны, алтынга әверелдереп, Швейцария ише чит ил банкыларына сала барган. (Моның шулай икәнлеге соңрак мәгълүм булды. Икенче дөнья сугышы вакытында Гитлер гаскәрләре Советлар Союзын «яулап бетерә язган» көннәрдә ул, Сталин белән араны өзеп, яңадан эчке Кытай хөкүмәтенә якыная. Күп тә узмый, Чан-кайши хөкүмәте яңадан Шең-шисәйгә әверелгән экс-губернаторны «чакырып ала». 1949 елны, Мао җитәкчелегендә коммунистлар җиңеп чыккач, Шең-шисәй Тайваньга кача... Әгәр Чан-кайшиның улы Мәскәүдә укыган, коммунистлар партиясенә якын торганлыгын истә тотсак, Шең-шисәйнең дә бер ара шул тирәләрдә буталганлыгы бик ихтимал...)

* * *

Шенҗаң, ягъни Шәркый Төркестан хөкүмәте 1942 елда тышкы сәясәтен үзгәрткәч, аннары башыннан Шең-шисәй киткәч, реакция тагын да көчәя төшә. Советлар Союзы белән сәүдә-экономик мөнәсәбәтләр тәмам өзелә, советларча фикер йөртүче кешеләр дисталәп-йөзәрләп кулга алына. Төзек юллар юклыгыннан эчке Кытай белән икътисади элемтәләре зәгыйфь булган Шәркый Төркестанның хуҗалыгында зур кыенлыклар пәйда була.

Бу үзгәрешләргә гоминдаң хөкүмәтенең шовинистик сәясәте дә өстәлә. Мәсәлән, тормышның һәрбер өлкәсендә диярлек көчләп кытайлаштыру политикасы барлыкка килә. Хәтта мәктәпләрдә дә «бөек хансу (кытай) телен» көчләп укыту, дәресен белмәгән укучыларны кыйнау күренешләре ешая. 1944 елны Голҗа татар мәктәбендә дә кытай теле буенча дәресләрне өстән билгеләнгән бер солдат кисәге алып барган иде. Аның кулындагы озын линейкасын әле дә яхшы хәтерлим: бер иероглифны белмәсәң, учыңа ике-өч мәртәбә, дүрт-биш «хәрефне» яза алмасаң, ун-унбиш тапкыр суга иде.

Шул рәвешчә, социаль-иҗтимагый шартлар кире якка үзгәрү, ягъни сәүдә-хуҗалык өлкәләрендә торгынлык барлыкка килү, шовинистик милли политика хөкем сөрү — халыкта власть ияләренә карата ризасызлык хисләрен, каршы тору гамәлләрен көчәйтә. Мәсәлән, шул елларда Голҗада «Инкыйлаби һәйъәт» исемле революцион оешма барлыкка килеп, аның җитәкчеләренең берсе Хәбиб Юнич булуы мәгълүм. Һәм, ниһаять, 1944 елның көзендә Элә вилаятенең төрле төшләрендә гоминдаң хөкүмәтенә каршы баш күтәрү, корал тотып сугышка кушылу башлана. Мондый баш күтәрүләрне рәсми хакимият ияләре «караклар», «бандитлар» чыгышы дип игълан итәләр. Голҗадан ерак түгел Нылкы тауларында Фатыйх Мөслимев дигән татар җитәкчелегендә казакъ һәм уйгырлардан оешкан партизан отрядлары 7 ноябрь көнне Голҗага бәреп керәләр. Атна-ай эчендә элек нибары 70-80 кешедән генә торган Ф. Мөслимев (1906—1976), уйгыр баһадиры Гани батыр (1902—1981) җитәкчелегендәге әлеге кечкенә отрядлардан зур-зур полклар, хәтта шәп коралланган дивизияләр оешып чыга. Гоминдаң гаскәрләре җиңеләләр, чигенәләр, качалар. Революцион хөкүмәт барлыкка килә. Унөч кешедән торган министрлар кабинетына мәгариф назир — министры сыйфатында Хәбиб Юнич тә керә. Ләкин, күп тә узмый, 1945 елның 19 февралендә 1906 елда туган Х. Юнич авырып үлә. (Ул үлгәч, үзе ун ел дәвамында җитәкчелек иткән газитәнең нәшриятына, типографиясенә аның исеме бирелгән һәм тагын ул яшәгән урам да «Х. Юничи күчәсе» дип аталган иде. Аны дәфенләү мәрасиме күп халыкны җыюын үзем дә хәтерлим...)

Мөстәкыйльлек игълан иткән, әмма нибары Шәркый Төркестанның өч вилаятеннән (Элә, Тарбагатай һәм Алтай өлкәләреннән, ягъни Җөңгария өлешеннән) генә торган әлеге дәүләткә «Азат Шәркый Төркестан» дигән исем бирелә. Үз байрагы, үз армиясе, хөкүмәте һәм рәис-президенты булган «мөселман дәүләте». Ләкин аны бер чит мәмләкәт тә рәсми рәвештә танымады бугай...

* * *

Шәркый Төркестанның өч өлкәсендә барлыкка килгән бу баш күтәрү хакында соңрак төрле теорияләр барлыкка килде. Гоминдаңчы кытайлар аңа башта тәртип сөйми торган ат караклары — бандитлар хәрәкәте дип карадылар, баш күтәрүчеләр җиңеп чыккач, моны ул хәрәкәткә руслар корал белән ярдәм итү нәтиҗәсе дип аңлаттылар. Гоңсандаң, ягъни коммунист кытайлар исә аны Шенҗаңда рәис Маоның энесе җитәкләгән

марксистлар оештырган социалистик революциянең бер чаткысы сыйфатында игълан иттеләр. Совет тарих фәненең ачык өлешендә 1944—45 елларда Уйгырстан-Җөңгариядә барган ул вакыйгалар хакында ләм-мим дип әйтерлек. Чит илләрдәге «буржуаз фальсификаторлар»ның китапларына карасаң, анда... гел «Совет чынбарлыгына яла ягулар...» Хәер, бу мәсьәләгә кереп тору да минем бурыч түгел. Шуңа күрә 1944—45 елның көзендә вә кышында Голҗада барган канлы сугышлар, урамнарда атышлар, аунап яткан кеше гәүдәләре, ниһаять, сугыш тынган араларда малайлар белән патрон гильзалары җыеп йөрүләребез хакында да озак язып тормыйм. Бары шуны гына билгеләп узам: сугышлар бераз басыла төшүгә, элек юкка чыккан сәүдә маллары — төрле тукымалар, әзер кием-салым, вак-төяк көнкүреш әйберләре, тәмле кондитер ризыклары Союздан — Советлар иленнән тагын мул дәрья булып агыла башлаган иде.

Ел-ел ярым чамасы вакыт узуга, Алтай якларында дәвам иткән сугышлар да, мөстәкыйльлеген сакларга теләгән Усман батыр хәрәкәтен исәпкә алмаганда, туктады сыман. Эчке Кытай хөкүмәте белән сөйләшүләр бер өзелеп, бер дәвам итү процессында Азат Шәркый Төркестан хөкүмәтенең җитәкчеләреннән премьер-министр Әхмәтҗан Касыйми, генерал Исхакбәк, министр Әбделкәрим һәм тагын дүрт-биш кешенең, Советлар Союзы аркылы Пекин ягына очкан чакта Себердә, «авиация катастрофасында» һәлак булулары халыкны тетрәткән иде. Өч өлкәдә оешкан әлеге дәүләтнең исеме тора-бара «Инкыйлаби Шәркый Төркестан» булып үзгәрде. Димәк, «азат-мазат» түгел. Рәсми идеологиядә Чан-кайшины артык мактамасалар да, элеккечә сүкмиләр дә иде инде.

Аның каравы Совет иле белән элемтәләр тагын да көчәя төште. Көнкүреш, хуҗалык кирәк-яракларыннан тыш, китап-журналлардан ни телисең, бик арзан бәягә барысын алырга мөмкин. «Советский Союз», «Огонек», «Работница»ише журналларны актарсаң, СССРдагы «мул тормыштан» исең китәрлек. Ышанмаслык та түгел, чөнки Голҗага агылган байлыкның иге-чиге юк диярлек.

Кинолар ни тора! «Чапаев»ны, мәсәлән, без, үсмерләр, ун-унбиш мәртәбә караганбыздыр. «Тракторчылар» дигән фильмны кат-кат карагач, колхозчы буласың килеп китә иде. «Дуңгыз караучы һәм көтүче» исемле фильмнан соң андагы чибәрне генә түгел, чучканың түгәрәк тәнавын да чупылдатып үбәрдәй буласың. Ә «Кубан казаклары!»... «Себер җирләре хакындагы хикәятләр!»

...Бу елларда Советлар Союзыннан татарча китаплар, кайбер журналлар да килә башладылар. Элек Татарстанны, татар халкын, «инде беткәндер» дип уйлаучыларның фикерләре «юкка чыкты». Чөнки ул китапларга, журналлардагы материалларга карасаң, республикадагы тормыш, андагы милли культура чәчәк ата иде. «Батырлар китабы»н укучылар исә үз халкының бөек җиңүгә керткән өлеше белән ихлас горурландылар...

Бу елларда, элек бер ажгырып алган кытай шовинизмыннан җилләр искән кебек, иске администрациягә хас ришвәтчелек, бюрократизм, ягъни түрәләр золымы да юкка чыккан, 40 еллар башында пәйда булган вак милләтләрнең эчке тормышларына тыкшыну гадәтләре дә бөтенләй беткән иде. Мәктәпләрдә кытай телен көчләп, кыйнап укыту тәмам оныталган, уку-укыту эшләрендә дә зур мөмкинлекләр ачылган иде. Теләсәң, урыннарда басылган уйгырча дәреслекләр буенча укыт, теләсәң, Мәскәү, Ташкент, Казан һәм Алма-Ата китапларыннан файдаланып укучыларны өйрәт.

Сәясәт, идеология өлкәләрендә урнашкан табигый плюрализмга, чын демократик мөнәсәбәтләргә экономик җанлану да өстәлгән. Югарыда күрсәтелгәнчә, Советлар иле белән сәүдә җанланган. Ә «союзный» товарларның сыйфатлары, сыйфатлары нинди иде!..

һәрхәлдә, 1945—1950 еллар арасында, әлеге Инкыйлаби Шәркый Төркестан хөкүмәте вакытында, шул дәүләт составына кергән өч өлкәнең иң тыныч, иң мул, иркен һәм хөр дәвере булгандыр, дисәм, әллә ни ялгышмам кебек.

Ул вакытлардагы чынбарлыкны болай уңай яктан гына искә алуыма үземнең үсмер һәм яшь егет чагымның романтик рухы да сәбәптер, бәлки. Чөнки әле генә тасвирланган вакыйгалар, безнең гаиләбәз тормышына да нык тәэсир ясаган шикелле, минем үз язмышымның да киләчәген билгеләгән иде. Шуңа күрә гаилә истәлекләренә тагын бер кат мөрәҗәгать итү артык булмас дип уйлым.

* * *

Югарыда, гаиләбезнең Дахыяңзы кышлагындагы хәлләрен сөйләгән чакта, 1944 елның көзендә әтиебезнең гоминдаң властьларыннан качып, Фатыйх Мөслимев чакыруы буенча, таудагы партизаннарга китүе, ике яшь бала белән калган әниебезнең йорт тоткыны хәлендә калуы язылган иде (минем, өлкән әниебез кулында торып, Голҗадагы татар мәктәбендә укыган чагым). Әти, шулай итеп, кыш буе тауларда сугышларга катнашып йөри. Яз айларында Дахыяңзы кышлагы кытайлардан азат ителеп, әниебез тоткыннан исән-имин котылгач, ул тагын шул кышлакта «сакчы идарәсенә», ягъни милициягә эшкә билгеләнә.

1945 елның җәендә тәгътил-каникул вакытында Дахыяңзыга кайткач, әтине мин хәрби киемдә күрдем. Шул вакытларда безнең өйгә Голҗадан СССР консулы килүен, рус телендә әти белән озак әңгәмәләшеп, аракы эчеп утыруын хәтерлим. Соңра аның шулай халык арасында «сәвит паспорты» алырга өндәп йөргәнлеген аңладым. һәрхәлдә, 1946—48 елларда Шәркый Төркестандагы совет паспорты алучыларның саны, элекке белән чагыштырганда, йөзәр мәртәбә арткан, дисәләгән меңгә җиткән иде.

Берәр елдан, якын тирәләрдә сугышлар тәмам басылгач, ни өчендер әтине юл төзү идарәсенә күчерделәр. Аннары ул ничектер тиз арада барлыкка килгән, гөрләп баеп киткән Совет гражданнары җәмгыятенең терлекчелек хуҗалыгына җитәкчелек итә башлады. (Ул хуҗалыкта ел саен диярлек 40—50 мең баш куй, 7—8 мең мөгезле терлек, 5—6 мең елкы малы булып, аларның бер өлеше ел саен Советлар Союзына җибәрелә тора, «буш урынга» җирле халыктан тагын мал сатып алына иде.) Бу аның үз «белгечлегенә» якынрак кәсеп иде бугай.

Мондый хосусый фактларга махсус тукталуның үз сәбәбе бар. Беренчедән, төп йорттан (Өлкән курадан) бүленеп чыккан җиде кешелек, ягъни әти, әни һәм биш баладан торган үз гаиләбезнең иң күңелле, һәр җәһәттән дә мул чаклары шушы елларга туры килде. Икенчедән, 1947 елның көзендә әти мине, колагымнан өстерәп дигәндәй, татар мәктәбеннән алып, рус гимназиясенә бирде: «Урысча укы, илгә кайта калсаң, кирәге булыр».

Шул рәвешчә, буе колгадай була язган үсмер малай килеш, тагын беренче сыйныфка кереп утырдым. (Шуны да әйтергә кирәк, бу елларда татарлардан, үзбәк һәм казакълардан рус мәктәбенә кереп укучыларның саны күзгә күренеп арткан, электән эшләп килүче рус гимназиясе җитми башлагач, Совет консуллыгы тарафыннан тагын бер зур мәктәп ачылган, аңа Сталин исеме бирелгән иде.) Әтиебез үзе юньләп укый алмаган кеше булса да, балаларына белем бирүдә көчен кызганмый, бигрәк тә аларны матди мөмкинлекләрдән чикләми иде. Китап кирәк икән — мә акча, теләгәнеңне ал; рус теле авыр бирелә икән, өстәмә дәресләр өчен укытучы яллый. һәрхәлдә, бу елларда үз бүлмәм бер кечкенә китапханә рәвешен ала язган һәм үзем дә, «әдәбият җене кагылган» кешедәй, төннәр буе теләсә нинди китапны «су кебек эчә» башлаган идем.

Җәйләрен исә бөтен гаиләбез белән тауларга — сөт һәм кымызлы, май һәм яшь итле җәйләүләргә китәбез. Анда әти терлекчелек хуҗалыгы белән мәшгуль, ә мин күбрәк аучылык белән мавыгам: тау кәҗәләре, архарлар аулаучы казакъ мәргәннәре тирәсендә чуалам (бу хактагы истәлекләремнең бер өлеше «Киек сукмакларында» дигән 1968 елда чыккан беренче китапчыгымда тасвирланган иде...) Көзләрен тагын мәктәп-гимназиядә. Кичләрен гомер күбрәк татар җәмгыяте каршындагы әдәби, һәвәскәр драмтүгәрәкләрдә уза; төннәрен йотылып-йотылып китап укулар... яки кинотеатрларга барып, «Тракторчы», «Кубань казаклары» кебек фильмнарны карау...

* * *

1949—1951 еллар дәвамында, Мао хөкүмәте белән элемтәләр көчәю нәтиҗәсендә, әлеге Инкыйлаби Шәркый Төркестан дәүләтендә әллә нинди сәер үзгәрешләр барлыкка килә башлады. Иң элек аның рәсми исеменнән «Инкыйлаби» (революцион) дигән сүз кителеп төште, аннары Төркестан урнына Шенҗаң атамасы күбрәк кулланыла башлады. Тора-бара яңадан Кытай халык җөмһүрияте составындагы Шеңҗаң-уйгыр районы (провинциясе) барлыкка килде. «Усал телләр»нең сүзләренә караганда, мондый үзгәрүгә «тышкы тәэсир» сәбәп булган...

Дөрес, үзгәрүләр, рәсми шигар-лозунглардан башка буларак, шома гына бармады. Социализм төзи башлау белән бергә, аның махсус оештырылган ачлык-кытлыгы да булып алды. Мәсәлән, 1952 елның җәендә шәһәрдә өч-дүрт ай дәвамында карточка системасы хөкем сөреп, авылкышлакларда аннан да мөшкелрәк булган иде. Аннары кинәт, җәй урталарында, ашлык җыелып беткәнче үк, тагын муллык урнашты... Әллә нинди сәбәпләр белән репрессияләр дә оештырылды. Болардан «өч каршы хәрәкәт» дигән әкәмәт исемле бер кампания бик тә характерлы иде. Имештер, бюрократизмга, исрафчылыкка һәм дәүләт-халык милкен урлауга каршы көрәшәбез дип, бетмәс-төкәнмәс җыелышлар, демонстрацияләр оештырылды. Хөкүмәт идарәләрендә эшләүчеләр андый җыелышларда кычкырыша-кычкырыша бер-берсен талау, «фаш итү» буенча чын-чынлап сабантуй ярышлары оештырдылар. Бу кампания, бу истерика белән мавыгу шул кадәргә барып җитте ки, кайбер хезмәткәрләрнең хыянәт итеп «урлаган» сумаларының күләме адәм ышанмаслык чамага — миллионнарга барып җитте. Андыйларның мал-мөлке конфискацияләнде. Конфискацияләнгән милекнең бәясе «урланган» сумага җитмәсә, «хыянәтче» кеше туганнарыннан, танышларыннан бурыч йәисә ярдәм сорап, теләнеп йөри башлады... Хезмәткәр үз ишен, бер бүлмәдә утырган коллегасын «фаш итү» белән генә чикләнмичә, угыл ата өстеннән язып бирү, энесе үз агасын сату кебек махсус оештырылган ямьсез, кешелексез күренешләр дә күбәйде. Шушы махсус оештырылган кампанияләр вакытында сүзнең гамәлдән аерылу, элекке иҗтимагый актив кешеләрнең тынып калып, мәйданга яңа «көрәшчеләр» чыгу, эш эшләгән кешеләрнең эзәрлекләнеп, бернинди казанышлары булмаган бәндәләрнең күкрәк сугу фактларын күп күзәтергә туры килде.

Гаепләрен таныган «җинаятьчеләрне» ачык суд белән үлемгә хөкем итеп, халык алдында ату процесслары да булып алгалады. Андый вакытларда алдан әзерләнеп куелган намуссыз җаннар, гадәттә, люмпеннар, хөкемителәчәк кешене гаепләүче ролен уйныйлар. Алар халык алдында акырып-бакырып, үзләренең ничек «рәнҗетелүләрен» игълан итүдән тыш, әле генә атып үтерелгән «җинаятьченең» мәетен таптый-таптый, «Маожучи атаның гаделлегенә» дан җырладылар.

Мондый кансызлык процессларының ике-өчен үз күзләрем белән күзәтеп торган идем...

* * *

Нигездә Кытай дәүләте гражданнары, аның да хезмәтчеләр катламы, интеллигенциясе арасында оештырылган мондый шомлы кампанияләр совет гражданнарына, татар һәм рус мәктәпләренең укытучыларына турыдан-туры адресланмаса да, шомлы җилләрдән алар да читтә калмадылар. Җирле администрация системасында эшләгән татар, үзбәк, казакъ һәм рус милләтеннән булган совет паспортлы кешеләргә дә эләккәләгән очраклар аз түгел иде.

Күп тә узмый, бу кампанияләрнең «ялгыш оештырылуы», йәнәсе рәис Мао күрсәткәнчә түгел, бәлки чамадан арттырып җибәрелүе, шул рәвешчә «хаталар ясалуы» икърар ителде. Дөрес, бу кампанияләр котырып барган чакта совет гражданлыгы булган татар, рус, казакъ һәм үзбәк яшьләреннән дистәләгән-дистәләгән кеше дәүләт чиген бозып, СССРга чыгу ягын карадылар. Күп тә узмый, Голҗадагы совет гражданнарыннан йөзләгән кешенең махсус намаиш-демонстрация белән СССР консуллыгы алдына җыелулары да мәгълүм факт. Кешеләрнең кулларындагы транспорант һәм плакатларда «Ватанга кайтырга телибез!», «Ватан, без синең белән!» дигән сүзләр иде. Ихтимал, әлеге «хаталар» хакындагы «икърар»га мондый чыгышларның да сәбәбе булгандыр.

Һәрхәлдә, кышын һәм яз айларын ажгырып барган әлеге «өч каршы хәрәкәт» җаен тәмам сүрелгән иде. «Җинаятьләре фаш ителеп», төрмәләргә ябылган меңләгән кешеләр өйләренә кайттылар, конфискацияләнгән мал-мөлкәтләренең бер өлешен дә кире алдылар. Атылып үтерелгән йәисә тән җәзаларына түзә алмыйча үз-үзләрен юк итүчеләрнең гаиләләре алдында гафу үтенүләр башланды. Нәүбәтендә мондый «хаталар» барлыкка килүдә «гаепле» кешеләрнең үзләре тагын үлем җәзасына хөкем ителделәр... Шул рәвешчә — партиянең «зирәк җитәкчелеге аркасында», тагын... «гаделлек тантана итте!..»

Канлы вакыйгалар безнең фамилияне дә читләтмәде. Әтинең энесе Габделмәтин абзый, өч-дүрт көн йоклатмыйча кыйнап сорау алу нәтиҗәсендә, «контрреволюцион хәрәкәт» буенча фикердәшләренең исемлеген, «яшергән коралларны» алып бирәм дип, идән астына төшеп, үзен-үзе бугазлый...

Татар мәктәбе буенча Зөфнүн исемле бик әйбәт укый торган бер кыз сабакташым бар иде. Аның лагерьда яткан атасы Габделкәрим агадан озак кына хәбәр булмый. Эзләп килгән Зөфнүнне лагерь сакчыларының берсе, бакча түренә алып бара да кечкенә түмгәкне күрсәтеп, кулына көрәк бирә: «Атаң шунда ята, ышанмасаң, казып кара...» Унбиш яшьлек кыз ялгыз түмгәк янында елап кичкә кадәр утыра...

* * *

Әлеге 1952 елның җәендә оештырылган намаиш-демонстрация нәтиҗәсез калмады, әлбәттә. 1953 елның ахыры белән 1954 елның башларында СССР һәм Кытай дәүләтләре арасында ике илдәге үз гражданнарын төп ватаннарына кайтару буенча махсус килешү төзелде. Моңа, бәлкем, Советлар Союзында «халыклар атасы»ның үлүе дә өстәмә сәбәп булгандыр... Һәрхәлдә, шул килешү нәтиҗәсендә, 1954 елның җәй башларында Шәркый Төркестандагы совет гражданнарының үз илләренә кайту процессы башланды.

Әлбәттә, илгә кайту дигәч тә, аны гел бәйрәм рәвешендә генә аңларга ярамастыр. Авыр булды бу процесс. Бигрәк тә олы яшьтәге кешеләр өчен. Алар, бер тарафтан, СССРда калган туганнарын, кардәшләрен онытмаганнар, күңелләре шуларга таба тартыла; икенче яктан, туган илләрендәге революциягә кадәрге авыр тормышны йәисә 20—30 еллардагы ачлык афәтләрен дә яхшы хәтерлиләр. Гомумән, кан-

га сеңеп, буыннарга үтеп кергән, шул рәвешчә нәселләргә дә бирелә язган ач үлемнән курку хисе күпләрне борчыды, аларны көне-төне уйланырга, икеләнергә мәҗбүр итте.

Язмаларым башында махсус әйтелгәнчә, Шәркый Төркестанда яшәгән татарлар арасында ул якларда очраклы рәвештә төпләнеп калганнары да, мул-иркен тормыш эзләп килгәннәре дә, ач үлем куркусыннан качып чыкканнары белән большевизмны, социализмны кискен рәвештә кире какканнары да бар иде. Димәк, илгә кайтуны хәл кылу һәркем өчен индивидуаль рәвештә чишүне сорый торган четерекле мәсьәлә иде.

СССРга кайту фикерен кыю рәвештә яклаучылар, мәсьәләне, күп уйлап тормыйча, җиңел хәл кылучылар, табигый, яшьләр булдылар. Алар, мәктәпләрдә Советлар Союзында басылган дәреслекләр буенча тәрбияләнүдән тыш, «Огонек» ише журналларны күбрәк актарып, «Кубань казакълары» шикелле кинокартиналарны да ешрак караучылар иде. Әлбәттә, кем әйтмешли, тайга ияреп җилкенгән карт алашалар да аз булмады. Кайберәүләр өчен күченү кәсепкә дә әверелә язган иде бугай...

Моның өстенә, халкыбызның бер гаҗәеп сыйфатын — табигый милли патриотизмын да истән чыгармыйк. Ул кайда һәм ничек яшәмәсен, төп ватаны булган Татарстан, Казан якларыннан кайчаннар гына киткән булмасын, ниһаять, үз ватанында чакта җәбер-золымнар, ачлык-афәтләр күргәнлеген ни дәрәҗәдә истә тотмасын — барыбер үзен туган иленнән читтә йөрүче, горбәтлектә интегүче итеп хис кыла. Угыл-кызларын, нәberә-оныкларын шул хистә тәрбия итә. Моңайса, «Агыйделкәй» җырын җырлый, тарихи хәтер ныгытырга кирәк тапса, Сөембикә язмышын риваять итеп сөйли, ихтыярын ныгытыр өчен Тукай шигырьләрен яттан укый. Һич булмаганда, шул исемне дога рәвешендә кабатлый... Чит җирләрдә туган яшьләрнең аңына да боларның барысы кергән, сеңгән була. Шуңа күрә гаиләдә, туганнар арасында, илгә кайту мәсьәләсе каралган чакта, хәлиткеч сүзне һәрвакытта диярлек яшьләр әйткән иде.

Шулай да гаиләләр бүленгәләү, бер өлеше калып, икенчеләре илгә кайту очраклары да аз булмады.

Кайбер икеләнүчеләрнең ихтыярларын социализм төзүче кытай коммунистларының, кетмәгәндә барабаннар суга-суга, төрле яңа кампанияләр уздыруы, озак еллар дәвамында җайланган тормыш шартларын туздыруы, аннары «хаталарны төзәтәбез» дип, тагын күз чыгарулары сындырды.

Җирле хакимият вәкилләренең совет гражданы булган яшьләр арасында совет паспортын тапшырып, кытай гражданлыгын кабул итү буенча төрле тәшвикать — пропаганда алып бару (рәсми сәясәттә ике ил арасындагы «мәңгелек дуслыкка» дан җырлаган килеш!) киләчәкнең шактый шөбһәле икәнлеген раслаган иде (минем үземә дә ике мәртәбә шундый тәкъдим булган, риза була калсам, дәүләт хисабына СССРга укырга җибәрелү ихтималы вәгъдә ителгән иде...). Мондый адым да ихласны кайтарды...

Берәүләре: «Ярар, монда яңа сынаулар узып ахмак булганчы, инде сыналып беткән сәвит социализмында яшәп карыйк...» — дип, кулларын селтәп бер карарга килделәр. Икенчеләре: «Кайда барсаң да, кара сакалың икән», — дип фәлсәфи нәтиҗә белән язмыш алдында тез чүгәргә мәҗбүр булдылар. Юкса улларының, кияү-кызларының китеп барулары бар. «Чит илләрдә солтан булганчы, үз илендә олтан бул», — дип, айнык нәтиҗә чыгаручылары да аз түгел иде.

Кайда барсаң да, бер кояш, дип, бөтенләй кузгалмаучылар да табылды. (Болар хакында тагын сүз булыр әле...)

Ниһаять, әллә ни зур булмаган бер төркем бөтенләй икенче тарафларга, мәсәлән, Төркия, Америка яисә Австралия якларына китү ягын чамалады.

Шулай итеп, кайчандыр төрле һиҗрәт дулкыннары нәтиҗәсендә ят җирләрдә бергә җыелып төпләнгән, яңа җирләрне үз итеп яши башлаган халык яңадан күтәрелде, яңадан күчenә башлады, җил очырган яфраклардай тагын таралып бетте. Биш-алты ел дәвам иткән бу процесс ахырында Шәркый Төркестандагы татарларның 80 (сиксән) проценттан артыгы СССРга кайтып, төрле җирләргә сибелде.

Дистәләгән еллар буена тырышлык һәм акыл, җегәр һәм белем, һөнәр һәм эзлекле хезмәт нәтиҗәсендә тупланган мал-милек, гөрләгән мәхәллә һәм калалар тузып таралдылар, кабызган аң-белем, мәдәни хәят учаклары бер-бер артлы сүнеп калдылар — җилгә очтылар... Ул якларда кала бирүчеләр өчен алай түгелдер, бәлкем. Әмма күченеп китүчеләрнең үзләре өчен — һичшиксез...

Үзбәкләрнең, СССРдан киткән казакъларның күпчелеге дә шулай үз илләренә кайттылар. Русларның да шактые. Тик аларның сизелерлек өлеше, бигрәк тә баптист һәм староверларының күпчелеге Израиль аша Австралиягә, Канадага таба юл тотуны хәерлерәк санадылар...

Илгә кайтучыларның күпчелеге башта чирәм җирләрендә совхоз-колхозларга килеп урнаштылар. Мөһаҗирләрне болай совхоз-колхозларга урнаштыру, гәрчә башта ул күпчелеккә ошамаса да, күченеп килүчеләрне эш белән тәэмин итү, аларга шартлы бурыч белән матди ярдәм күрсәтү күзлегеннән караганда, минемчә, дөрес уйланылган чара иде. Чөнки яңа шартларда бераз хәл җыйган кешеләр аннары үзләре теләгән якларга күченеп китә алдылар.

1955 елның июнь ае уртасында безнең гаиләбез дә, Элә елгасы буйлап дәүләт чиген узып, Көнчыгыш Казагыстандагы Талды-Курган якларына килеп чыкты. Шул рәвешчә 36 елдан соң ике яңа буын алмаштырган гаиләбез белән элегрәк, ягъни XIX йөзнең урталарыннан алып, бабаларыбыз йөз елга якын гомер кичергән җирләргә — бәрәкәтле Җидесу туфрагына кайтып төштек. 1958 елны, бабаларыбыз Олы Мәңгәрдән чыгып китүгә йөз илле ел чамасы вакыт узуга, үз бабам Габделбари хаҗи туугa нәкъ йөз ел тулган көннәрдә, мин Казанга кайтып төштем. 15 июньнең төнге унбер сәгате иде. Вокзалның көтү залындагы такта эскәмиясендә, Казан газитен укып яткан килеш, йокыга китүемне сизми калганмын...

Берәү җилкәмнән йолкып уятты. Милиционер икән: «Освобождай зал, уборка идет!..»

Казанда беренче кичем шулай узды.

Иртәнге алты. Һава ачык, яңа көн нурлы, якты иде.

Сакко-Ванцетти урамында, сәгать җидедән үк «баш төзәтә башлаучы» агайлар белән тулы кафеда, Казандагы беренче ризыгымны ашап торган чакта, бөтенләй таныш булмаган шәһәрдә эшне нәрсәдән башлаячагым хакында чын-чынлап уйларга туры килде.

Казанның озын көнe — гомеремнең яңа чоры шулай башланып китте...

* * *

Югарыда төрле чорларда Шәркый Төркестанга җыелган татарларның кимендә 80 проценты чамасы СССРга кайтып китүләре әйтелгән иде. Кытайда калучыларына килсәк, алар хакында түбәндәге мәгълүматларны күрсәтергә мөмкин.

Уйгырстан авторларының язуларына караганда, 50 елларның башында Шәркый Төркестан җирләрендә «якынча 6000 тирәсендә» татар кешеләре булган. 1960 елларның башында, халыкның зур өлеше үз иленә кайтып китү нәтиҗәсендә, аларның саны «якынча 2000 чамасы» гына кала (ТКТ, 1 б.). Ләкин, 1982 елда алынган җан хисабы буенча, татарларның саны 4106 кешегә җиткән, ягъни 20 ел эчендә икеләтә арткан икән (2 б.).

Бу саннарга махсус игътибар итүнең сәбәбе шунда, әлеге 6 мең белән 2 мең дә кирәгеннән артык «якынча» күрсәтелгән саннарга охшый (күпмилләтле дәүләтләрдә вак халыкларның саннарын махсус кечерәйтеп күрсәтү, аннары бөтенләй «юкка чыгу» фактлары — ул киң таралган күренеш икән...).

1953 елда игълан ителгән рәсми документларның берсендә «Көнбатыш-төньяк Кытайда», ягъни Шәркый Төркестанның Җөңгария өлешендә 8 меңнән артык татар яшәве күрсәтелгән икән (Ташкенттан Ә. Госманов җибәргән мәгълүмат). Һәрхәлдә, 1982 елга нисбәт ителеп, шактый төгәл күрсәтелгән 4106 җанны «терәк сан» итеп алсак, ә халыкларның табигый үрчү һәм үсү темпы елга 5—6 проценттан узмавын истә тотсак, әлеге «2000»нең үтә чамалы булуы ап-ачык. Әгәр шушы бик якынча санны да Кытайда калган егерме процентка тигез дип исәпләсәк, 50 елларның уртасында Шәркый Төркестанда 10000 (ун мең) чамасы татар кешесе яшәгәнлеге ихтималга якын. Шул ун меңнең якынча өчтән берсе Голҗа шәһәре һәм аның тирәләрендә яшәүчеләр дип уйларга кирәк.

Димәк, 80 еллар башында 4000нән арта язган татарларның саны бүген 5000 гә таба якынлашкан булырга тиеш (кешеләр туып, үрчеп кенә түгел, бәлки үлеп, кимеп тә торалар бит).

Хәзерге Шәркый Төркестанда яшәүче татарларның таралу статистикасы да игътибарга лаек. Мәсәлән, 80 елларда алынган җан хисабы буенча, Уйгырстанның мәркәзе Өремче шәһәрендә 610, Голҗа каласы һәм Элә вилаятендә 915, Чүгүчәк-Торбагатай өлкәсе һәм аның күрше тирәләрендә 443, Алтай якларында 1206, Санҗы автоном өлкәсендә 820 татар кешесе булган икән. Моннан тыш унбиш-егермеләп саналган татарларны Төркестанның башка өлкә һәм шәһәрләрендә дә очратырга мөмкин (ТКТ, 2—3 бб.).

* * *

Алтай һәм Актирәк (Бәйяңхи) якларындагы өлешчә казакълашкан татарларны исәпләмәгәндә, бүген Шәркый Төркестанда торучы илдәшләребез, нигездә, шәһәрләрдә яшиләр. Авыл җирләрендәге халыкның күпчелеге элеккечә игенчелек, малчылык белән көн күрсәләр, шәһәрдәгеләренең зур өлеше — хезмәткәрләр. Традицион мөгаллимлек кәсебе дә татарлар арасында һаман популяр. Башлангыч һәм урта мәктәпләрдәге күпсанлы мөгаллимнәрдән тыш, соңгы елларда югары уку йортларында эшләүчеләрнең, инженер һәм фән хезмәткәрләренең саннары сизелеп арта бара икән. Моның сәбәбен Уйгырстан авторлары иң элек татарларның укуга, белем алуга бик зур игътибар итүләре белән аңлаталар. Соңгы вакытларда, дип язалар алар, «татарларның аң-белемгә булган мөнәсәбәтләре аерата көчәюе аркасында, аларның мәгариф өлкәләрендәге казанышлары бик тиз тәрәккый итте. Яшьләрнең югары уку йортларына керү күрсәткечләрен алсак, һәр ун мең кешегә 101,3 студент иң беренче урынны тәшкил итә» (ТКТ, 69 б.). Димәк, реаль 5 мең кешедән чыгып фикер йөртсәк, 80 еллар башындагы татар студентларының реаль саны 50 кеше була дигән сүз!..

1990 елның җәендә Өремче университеты янындагы үзәк Азияне өйрәнү институтының директоры доцент Зариф Дулатов Казанга килгән иде. Милләттәшебез белән ул яклардагы хәлләр хакында ачыктан-ачык әңгәмәләшеп утырган чакта, мин әлеге «статистик алымнан» көлеп куйдым. Минем иониянең сәбәбен Зариф әфәнде дөрес аңлап алды:

— Алай көләргә ашыкмагыз,— диде ул үз нәүбәтендә, елмаеп.— Илле студент белән Уйгырстанда беренче урынны алу әллә нәрсә түгелдер, бәлки. Әмма, соңгы статистика буенча, безнең татарлар арасында укый-яза белмәгән бер кеше дә юк икән. Бу күрсәткече белән аз санлы халкыбызның бөтен Кытай халык җөмһүрияте буенча беренче урында торуына ничек карыйсыз?

Сүзне дәвам итәр өчен дәлилләрем шактый булса да, мин үз өемә килгән кунагым белән артык бәхәсләшмәдем. Чөнки аны эчтән борчыган мәсьәләләрнең кайберләре миңа болай да мәгълүм иде. Әйтик, бер җирдә дә хәзер үз ана телендә укыта торган татар мәктәбенең калмау мәсьәләсе... Әйтик, Казанда басылган татарча китапларның утыз елдан артык ул якларга бер дә килмәве...

Әйтик, кечкенә-кечкенә төркем булып, анда-монда сибелеп яшәгән милләттәшләребезнең интенсив рәвештә уйгырлаша, казакълаша барулары... Әйтик, мәхәллә мәктәпләре оештыру, кечкенә җәмәгатьчелекнең милли-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен матди мөмкинлекләр булмау, меценатлык итәрлек социаль катламнарның бөтенләй юкка чыгу мәсьәләсе...

* * *

Бәхәсне дәвам итмәүнең, дөреслекне тулысынча әйткәндә, башка сәбәпләре дә бар иде. Мәсәлән, «автоном» булса да, үзенең республикасы, ягъни «дәүләтчелеге» булган дүрт-биш миллионлы халыкның милли-мәдәни мөмкинлекләре соңгы 60—70 ел эчендә ничек үзгәрүен белә торып, шул зур халыкның да 150 миллион арасында эреп бетә баруын күрә торып, андагы дүрт-биш мең җаннан гына торган кечкенә кавемнән нәрсә таләп итәргә? Андагы «ага милләт»нең — хуҗа халыкның саны миллиардтан артык икәнлеген дә онытырга ярамый... Демографик мәсьәләләргә кагылгач, соңгы елларда Шәркый Төркестандагы мөһим үзгәрешләрне дә исәпкә алырга кирәк. Мәсәлән, 1958 елда алынган җан исәбе буенча, андагы халыкның гомум саны 5 миллион 850 мең булып, болардан уйгырлар 3 миллион 960 меңне, кытайлар якынча 1 миллионны, казакълар, монголлар, дөңгәннәр, кыргызлар һ. б. калган халыклар миллионны тәшкил иткән икән. 1990 елгы рәсми исәп буенча хәзер Шенҗаң-Уйгыр автоном районында 15 миллион 116 мең кеше яши икән. Шулардан, әгәр статистика ахыргача дөрес булса, 7 миллион 195 мең кешене уйгырлар, 5 миллион 696 меңне кытайлар, 1 миллион 107 меңне казакълар, 682 меңне дөңгәннәр, якынча 140 меңне монголлар, калган өлешне башка вак халыклар тәшкил итә икән («Коммунизм туғьи» газитасе, 1990, 28 ноябрь, Алма-Ата). Шулай итеп, 30 ел дәвамында уйгырларның җан саны ике мәртәбә дә күбәя алмаган булса (үрчем 80 процент тирәсе генә), сөйләшүләре бердәй дөңгәннәрне кушып санасаң, «кытай телле» халыкның рәсми саны алты тапкырдан артык күбәйгән икән! Әгәр халык санын алган чакта исәпкә керми торган, мәгәр гел кытайлардан гыйбарәт хәрбиләрнең дә Уйгырстанда миллионга якынлыгын истә тотсаң, әлеге үсешнең җиде тапкырга җитә язуын күрәсең... Шулай булгач, милли политикасында «социалистик интернационализм» идеяләре хөкем сөргән, гомумхалык саны миллиардтан арткан дәүләттәге биш бөртек татарның студентлар саны азлыгына бәйләнеп торуның мәгънәсе бармы соң?!

Кунак белән бәхәсне дәвам итмәүнең тагын бер мөһим сәбәбе дә бар иде. Ул 1954—1960 еллар тирәсендә Шәркый Төркестаннан кайткан алты-җиде мең чамасы татарларның аннан соңгы язмышлары. Мәсәлән, теге якларда чакта гел Казанны сагынган, Агыйделкәй буйларын мактап җырлаган, моңайган чакларында «Карурман» көен сузган, күңелле мизгелләрендә «Әпипә»гә биегән халыкның, СССРга чыккач, ата-бабаларының төп ватаннарына кайтучылары бер дә булмады диярлек. Һәрхәлдә, ике-өч гаиләне генә исәпкә алмаганда, андыйларны бөтенләй очратмадым дип әйтерлек. Казагыстан, Үзбәкстан, Кыргызстан шәһәрләренә сибелеп, таралып беттеләр алар. Элекке Голҗа һәм Чүгүчәкләрдәге бердәмлек, оешкан җирдәшлек сыйфатлары гадәти туган-тумачалык, иске танышлык кысаларыннан чыкмый хәзер. Шулай да һаман «Әпипә»гә

биилəр, «Каз канатлары»н җырлыйлар, Сарман буйларын да телгә алалар... Кызык күренеш, сəер халык...

Ара-тирə кайберлəре ата-бабаларының урыннарына зиярəт итəр өчен кайталар. Берəүлəре төп ватаннарының матур табигатенə соклансалар, икенчелəре бу яклардагы халыкның ачтан кырылып бетмəүлəренə гаҗəплəнəлəр. Мəсəлəн, сиксəненче елларга кадəр кайтучыларның кайберəүлəре: «Карале, монда да начар тормыйлар икəн!» — дип гаҗəплəнделəр (элекке авыр тормыш хакындагы төшенчəлəр шул дəрəҗəдə каннарга сеңеп беткəн, күрəсең!).

Махсус сəфəрлəреннəн канəгатьсез калучылар да аз түгел. Əйтик, 60 елларның ахырында Алма-Атада бер мəҗлестə элекке якташларымнан кайберлəре, Казанда булуларын əйтеп, аның иске һəм пычрак икəнлеген тасвирлый башлады. «Кайтыгыз да себерегез Казан урамнарын! — дидем гарьлəнеп.— Сезнең өчен аны французлар килеп тазартып, чистартып бирмəстер бит!»

Чак кына тотып ярмадылар үземне.

Сəер халык...

Ташкəнттə элекке сабакташларымның берсе Татарстанда милли мəдəниятнең үсмəвен тəнкыйтьли башлады. Түзмəдем: «Аны кем үстерергə тиеш?» — дип сорадым. Мине ишетмəгəн кебек, үземə сорау бирде ул: «Эш хакың күпме? Фатирың ничə бүлмəле?» Җавапны ишеткəч, кулын селтəде: «Монда эш хакың ике тапкыр күп, фатирың да, иң кимендə, өч бүлмəле булыр иде!»

Күңелсез фəлсəфə...

Билгеле нəтиҗə...

## Йомгак... түгел

Кереше, махсус бүлеклəре булган язмага йомгак та кирəк шикелле. Тик мин аны язмаска булдым. Чөнки китабым конкрет вакыйгага, тəгаенлəнгəн процесска түгел, бəлки халыклар үсү, таралу, яңа шартларда үзгəреп яшəү ише башы да, ахыры да юк, «мəңгелек хəрəкəт»кə багышланган. Димəк: «Тарих менə шулай тəмамланды»,— дип, нокта куеп булмас шикелле.

Дөньяда бара торган милли процессларның соңгы вакытларда, бигрəк тə безнең илдə, искитəрлек дəрəҗəдə катлаулануын исəпкə алсак, андый категорик нəтиҗəлəрнең урынсызрак булуы тагын да яхшырак аңлашыла. Аннары минем бурыч мəгълүм бер процесска төгəл бəя бирү, соңгы хөкемне чыгару да түгел. Максатым икенчерəк һəм шактый тыйнак: халкыбызның бер кечкенə өлеше башыннан кыска вакытта кичкəн һəм гыйбрəтле, һəм сəер «вакыйгаларны», шулар хакында үземə мəгълүм материалларны бергə туплау, кəгазьгə теркəп кую.

Əтрафлы йомгак ясап, категорик хөкем чыгарудан баш тартуның икенче сəбəбе дə бар. Телəсə нинди хəллəрне тасвирлаганда аны абсолют тулы һəм төгəл итеп гəүдəлəндерə алмыйсың. Тарих белеменең бер хосусияты бу. Шуңа күрə мин, китабымны йомгаклап ябмыйча, аны «ачык» калдырырга булдым. Бəлки киләчəктə яңа мəгълүматлар өстəлер, нəтиҗəдə икенчерəк фикерлəр дə хасил булыр...

Бəлки, «ачык килеш калган» китапның мəгънəви дəвамы рəвешендə башка иллəрдə яшəүче илдəшлəребез хакында да махсус язылыр. Əгəр халкыбызның һəм бай, һəм фаҗигале тарихын адəм рəтле (объектив рəвештə) язарга телəсəк, аның «үзəген» — төп баганасын яхшы белгəн шикелле, «ботаклары», таралып очкан яфраклары хакында да хəбəрдар булырга тиешбез.

*1991 ел, 8 февраль — 15 март.*
*Крутушки-Казан.*

*Фәйрузә Исмәгыйлева Казанда университет тәмамлаган. Хәзерге көндә ул Азнакай районының Карамалы авылында яшн, тәрбияче булып эшли.*

*Язучылар берлегенә аның «Татлы саташу» дип исемләнгән кульязма җыентыгы керде. Җыентыкка тормышның күп төрле тармакларын сурәтләгән шигырьләр тупланган. Шигырьләре җылы, үзенчәлекле — каләмдәшләреннән нык аерылып торган әзер китап булып күзаллана. Ул китап кайчан дөньяга чыгарын гына әйтү кыен, чөнки заман катлаулы, республикаларның һәм шул исәптән нәшриятларның да ярлы чагы.*

*Без алга өмет белән карарга өйрәнгән халык. Фәйрузә язудан туктамас, китабын күрүгә дә ирешербез. Әлегә аның шигырьләрен укучыга газета-журналлар аша тәкъдим итәбез.*

*«Казан утлары» өчен мәхәббәт турындагы шигырьләрен тупладык, ишетсеннәр ир-атларыбыз хатын-кыз тавышын. Бүген безнең шактый караңгы юлларны да шул тавыш яктыртып тора ич.*

*Рөстәм МИҢГАЛИМ*

# Фәйрүзә Исмәгыйлева

## Сиңа

Күз алдымнан
Әзгә генә дә
Китми бит
Сурәтең...

Җилтерәтеп кайчак,
Шул сурәткә
Килә
Җан өрәсем!

## Фәрештәләр

«Бәхетлеме син? Бәхетлеме?»
Әллә бәхетсезме? Әйт инде».
Күзләремне рәхәт йомдырып,
Сорау алалар миннән...

«Көчсезлеген тойган иңнәрдән
Китмәсә ике фәрештә —
Бәхетлемен, чиксез бәхетле!»,
Дип пышылдыйм мин эчтән.

...Төшләремдә түгел, ә өнемдә
Бу саташу булган икән.
...Фәрештәләр булып иңнәремә
Синең куллар кунган икән...

## Сәер...

Сәрхүшне дә аңлыйм хәзер:
Айныр-айнымас халәттә
Соңгы тапкыр, соңгы, диеп,
Үреләдер ул шәрабкә...

...Булдыралсаң, бу «сәрхүш»не
Син, сөеклем, кичер генә:
Соңгы килү, диеп тагы
Үреләм бит ишегеңә...

## «Әллә кем»гә

Абый да, җаный да түгел син,
Керләнмәгән саф күңел син,
Көнемне, күгемне ямьләттең,
Әйе,
Беркем дә түгел син миңа
Һәм шул ук вакытта...
Әллә кем!

## Алданган кыз

Гөрләвекләр шау-гөр килеп
Бер-берсенә кушылалар,
Язның шушы ашкынуы
Кешеләрнең һушын ала.

Һушсыз күңел — ялкын гына...
Ә сөйгәне якын гына...
Гөрләвектәй ашкына кыз —
Чакыр гына... чакыр гына...

Гөрләвекнең өсләрен күр,
Бозлана инде иртәгә.
...Язларның кичке акылы
Ярамый икән иртәнгә...

## Синсез

Синдә табам мин тынгылык.
Синсез миңа дөнья кысан.
...Тик кулларың итеп нигә
Ишек тотканны кысам?!

Килер идеммени сиңа,
И, күңелем кушмаса?
...Бикле ишек тоткан гына
Күрешә дә... хушлаша...

## Бер кызга

Икегезне күрдем:
Күзгә күз идегез
Һәм иренгә-ирен.
...Мин дә бит Аңардан
Кайчандыр, бик күптән,
Бер тилергән идем...

Хәзер дә шул чакны
Сагынадыр, димә,
Кызыга бу, димә.
...Ә шулай да бүген
Өзелепләр минем
Син буласым килә...

## Хушлашу

Син — мәхәббәтнең, гүя,
Серле күле.
Тартыла, тик чумалмый
Минем күңел.

Элек үк чирканчыктан
Курка идем.
Күл буена килүләрем
Юкка иде.

Кемдер миңа чәчрәтеп
Көлә иде...
Кире китүне генә
Белә идем...

Тәрәзәңнән үк борылам,
Керәлмим мин,
Чөнки чирканчык алырга
Теләмим мин.

Чәчрәтмә утлы суың —
Вакланмасын.
...Сөюгә көзен чуму
Акланмас ул.

...Бу төн гаҗәеп моңсу
Һәм боек та...
Таңда ул әйләнер инде
Төнбоекка?!

## Сүз әйтмәгез

Күктә
канатларын җилпеп
күбәләк очса,
бик матур.
...Тик, менә,
күтәрелә күккә
утызга җитеп килүче
бер хатын.

Бу күренешне,
үтенәм мин,
юрамагыз афәткә...
Сүз әйтмәгез,
рәнҗетмәгез берүк
нахакка!

...Тезмәгез юлларына
чәчәкләр.
Кызыкмас ул —
аның үз чәчәге бар...
Үзе тапкан бәхете,
үз киләчәге бар.

...«Күбәләк түгел, ә оча!» —
димәгез, —
рәнҗетмәгез нахакка!
Сакларга тели ул
үзен
вакланулар,
хәерчелек,
зарланулар дигән
афәттән!..

Ул искәртергә тели
мәхәббәтнең
зурлыгын.
Ул тоярга тели
яшәүнең
хозурлыгын!

...Сүз әйтмәгез
Хис канатында
оча белүче
бу хатынга...
...Оча бирсен —
җирдәге тормышын
әз генә булса да
матурлап.



## Азат Вергазов

# КАЙТУ

РОМАННАН ӨЗЕК

### 1

Рәфис каты итеп Шәмсүннең ишеген шакып куйды. Шулвакыт эчтә калын тавышлы этләр өрергә тотынмасынмы! Рәфис бермәлгә каушап, аптырап калды. Аннары, Шәмсүннең эт халкы белән әвәрә килә торган гадәтен исенә төшереп, елмаеп куйды: «Һаман шул әкәмәтен ташламаган икән».

Бүлмә ишеге ачылуга, ике кулын як-якка җәйгән Шәмсүн пәйда булды.

— Рәфис! — дип кычкырды ул, тавышына шатлыклы төсмер бирергә омтылып. Ләкин Шәмсүннең куанычны аңлатырга тиеш булган йөз чалымы күзләрендәге арыганлыкны, ирен кырыендагы эшлекле кырыслыкны яшереп бетерә алмады.

Хуҗаның тавышы ягымлы тонга күчү белән этләр өрүдән туктады һәм шыңшый-шыңшый икесе ике якка барып сузылып ятты.

— Тау белән тау гына очрашмый, дуслар һәрвакыт очраша, — дия-дия, Шәмсүн Рәфискә елышып, аны кочып ук алды. — Нихәлләрдә яшисең, дус кеше? Сорашып белештем — күрше районда баш зоотехник булып эшлисең икән. Мактадылар үзеңне. Ничава, без дә кимен куймыйбыз. Әле менә...

Шәмсүннең бераз шапырынырга яратуын Рәфис белә иде. Аның бу гадәтеннән көлгәли дә иде. «Котылмаган икән бу чиреннән, котылмаган...»

Өстәл каршындагы яшькелт тышлы йомшак кәнәфигә барып елышкач, ул бүлмәне күздән кичерде. Стеналар табигый төсен саклаган имән фанер белән тышланган, ике якка артлы урындыклар тезелгән, өстәл янындагы тумбочкага чылтыратканда кош сайравы авазы бирә торган ике телефон аппараты һәм зәңгәрсу төстәге селектор куелган.

Шәмсүн юаная төшкән гәүдәсе белән күн кәнәфигә ярым яткан хәлдә, кызарып торган калын күз кабаклары астыннан тар сызыктай елтыраган яшькелт күзләрен балкытып, сорашуын белде:

— Йә, тормышлар ничек? Бу якларга нинди җилләр ташлады үзеңне?

— Әнидән хат алдым.

— Нәрсә язган була карчык?

---

Азат ВЕРГАЗОВ (1932) — *прозаик. «Дулкыннар ни сөйли?», «Уяну» һәм башка китаплар авторы. Зеленодольск шәһәрендә яши.*

— Әнинең аяклары йөрми.

— Алай... Ну, ничава, без аны әйбәт докторга күрсәтеп карарбыз.

Шәмсүн, күз кабакларын күтәрә төшеп, Рәфис моңа ни дип җавап бирер икән, дип көтте. Ләкин Рәфис дәшмәде, урыныннан җайсыз гына кузгалгалап, тамагын кырып куйды да, үзалдына карап утыра бирде. Тын гына утырса да, җыерыла төшкән киң маңгае, дугадай бөгелгән куе кашлары һәм соңгы көннәрдә аксылланып киткән чырае җанындагы киеренкелекне яшерә алмады.

«Ничек сүз башларга үзе белән? Коры рәсмилек мәгънәсез һәм көлке булачак. Ни әйтсәң дә, студент еллары аның белән бергә узган, бер бүлмәдә яшәлгән, бер табактан аш ашалган...»

— Әни янында булдым, хәлен белдем, анысы табигый,— диде ул сүрән генә.— Минә синең янга килеп чыгуым ни сәбәптән дип уйлыйсың?

— Дуслар янына кермәскә... Бик шәп булган! Минә иртәгә иртүк икәүләп ауга барырбыз, үзең беләсең, монда кыр тавыгы, куян... У-у-у!

— Куян, кыр тавыгы беркая качмас. Башта ул кайгы түгел әле. Әнине карарга кеше юк. Әтинең үз хәле хәл.

— Әллә бөтенләйгә кайтыргамы исәбең?

— Әгәр шулай булса?

— Бернинди гаҗәп эш юк. Без институтта укыганда ук икебез бер хуҗалыкта эшләү турында хыялланмадыкмыни?

— Аннан соң күп сулар акты бит.

Бу ни дигән сүз икән дигәндәй, Шәмсүн авызын ярым ачып Рәфискә текәлеп торды. Тик искитәрлек мәгънә тапмады, ахры, кулын селтәп киң итеп елмайды.

— Юкны сөйләмәче, ыслушай!— Ул бер кулын шап итеп Рәфиснең җилкәсенә куйды.— Әйдә, лутчы безгә киттек. Иркенәеп чәй эчеп сөйләшеп утырырбыз. Хәзер мин өйгә шалтыратыйм да.— Ул ашыкмый гына бер якка янтаеп телефон трубкасына сузылды. Рәфис җәһәт кенә Шәмсүннең трубка тоткан кулын эләктереп алды.

— Ашау качмас. Син минә шуны әйт: мине эшкә урнаштырмакчы буласың. Ул урын буш түгелдер ич?

— Һе, исең киткән икән, бушатабыз аны! Дуслар өчен барын да эшләргә була!

Рәфис чырасы сытты.

— Эшләп яткан кешене эшеннән куыпмы?

— Ул үзе дә китәргә йөри иде.

Рәфис сабакташы Шәмсүннең көлемсерәп елтыраган кысык күзләренә, һаваланып өскә чөелгән йомры иягенә, кәнәфидә ярым яткан масаюлы кыяфәтенә күз төшереп алды.— Әлегә эш мәсьәләсендә бер сүз дә әйтә алмыйм,— диде ул авызы кибүдән аңкавына ябышкан телен авыр кыймылдатып,— хуҗалык белән таныш түгел, кешеләрегезне дә белеп бетермим...

— Кит инде, ыслушай,— дип кычкырып ук җибәрде Шәмсүн,— дөньяга бүген тугандай кыланма! Безнекедәй хуҗалыкны табасың бар әле! Көйләнгән хезмәт урынына килүеңә сөен!

Шәмсүннең йөзендәге елмаюына үз өстенлеген тоюдан барлыкка килгән кешегә кимсетеп карау чалымнары да килеп кушылгач, Рәфиснең күңеле тәмам кырылды. Күзгә күренмәс тимер кыса тагы да кысылып, аяк-кулларын гына түгел, бөтен гәүдәсен, хәтта эчке әгъзаларын да хәрәкәтләнмәслек итеп бер зур төенгә җыеп китергән төсле тоелды.

Рәфиснең бу халәтен сизде Шәмсүн һәм моны кырыс, туры сүзле булып маташкан дустын җиңүе итеп кабул итте, шуңа күрә, ике арадагы мөнәсәбәтләр юньләп ялганып җитмәс борын башланган вакытсыз уенын туктатырга булды.

— Ярый, үпкәләмә, мин болай гына,— диде ул дустанә елмаеп.— Нигә юк белән баш авырттырабыз әле. Әйдә, тор, киттек безгә!— Ул Рәфиснең кулыннан тотып йолыккалый ук башлады.

Этләр ялт кына аяк өстенә басып бер-ике мәртәбә ачулы тавыш биреп алдылар. Шәмсүн: «Ятырга!» — дип боергач, бурзайлар: «Без өергә кирәк дип аңладык ич... гафу, гафу», — дигән кебек, салынкы колаклы башларын түбән иеп һәм күзләрен гаепле мөлдерәтеп үз урыннарына чигенделәр.

— Ярар инде, ыслушай, — диде Шәмсүн Рәфисне урыныннан ук тартып торгызып, — күпме уйланырга була. Син бигрәк кызлар кебек назланырга өйрәнгәнсең. — Шәмсүн, башын артка ташлап, хахылдап көлде.

«Гадәтләре дә, көлүе дә үзгәргән».

— Шәмсүн! — диде кинәт кенә Рәфис эзләгәнен тапкандай итеп. — Сезгә барырга өлгерербез, әйдә, авылны әйләнеп килик!

— Тәки ашыгасың, ыслушай. Хәер, сәгать ике тулган икән инде. Алай булгач, хәзер ашханәгә кереп тиз генә тамак ялгап чыгабыз да аннары мин сиңа үз биләмәләремне күрсәтермен.

Ашханә башка биналар шикелле үк ак кирпечтән салынып, совхоз идарәсе янына урнашкан иде.

— Мин сиңа башта гомуми залны күрсәтәм, — диде Шәмсүн һәм үзе хуҗаларча тәвәккәл атлап алдан кереп китте.

Чиратта киемнәре мазутка буялган дүрт-биш ир-егеттән гайре бер кем юк. Рәфис култыкса эченә кереп тәлинкәле ашны көрән подноска куйган гына иде, зур-зур атлап Шәмсүн килеп җитте.

— Син нишләмәкче буласың, ыслушай, — диде ул шелтәле тавыш белән. — Тәлинкә-подносыңны кире куй да, әйдә, минем арттан!

Рәфис берни аңламыйча сораулы карашы белән аңа текәлде.

— Һай, шушының кирелеге! — диде Шәмсүн ачулана төшеп.

Тәлинкәләрен кире куеп Шәмсүн артыннан ияргәндә, Рәфис механизатор егетләрнең үз артларыннан йөз чөергәндәй караш ташлап калуларын абайлады.

Алар кергән җыйнак бүлмә кыйммәтле обойлар белән бизәлгән, озын аяклы аскуймаларга утыртылган гөл савытларыннан стеналарга үрмә гөлләр сузылып киткән. Тәрәзәдәге алсу ефәк пәрдә капрон тасма белән як-якка җыйнап куелган. Бүлмә читендәге шомартып ялтыратылган көрән төстәге кечкенә шкаф өстендә сөяктән ясалган һәртөрле хайван сыннары. Өстәл-урындыклар кызыл агачтан эшләнеп, үз төсе саклансын өчен үтә күренмәле махсус буяу белән шомартылган.

Хуҗалар килеп керүгә, нинди тылсым беләндер, кечкенә шкаф ягыннан акрын гына җиңелчә көй яңгырый башлады. Ишектә зифа гәүдәсенә сыланып торган ап-ак халатлы, сөрмәле күзле бик мөлаем туташ пәйда булды. Шәмсүн аны бармагы белән ымлап үз янына чакырып алды.

— Нәрсәләр бар сезнең анда, Сәйфия?

— Сез ярата торганнарның барсы да бар, — диде туташ ягымлы елмаеп.

— Ярар, әзерлә!

Мөлаем хатын, нидер әйтергә теләп, бусагада тукталып калды.

— Бар, бар, Сәйфия, эшеңдә бул, — диде Шәмсүн, — анысын мин үзем карармын.

«Анысы» дигәне әлеге ялтыравыклы сыннар тезелгән шкафта гына икән. Шәмсүн җитез хәрәкәт белән шкаф тартмасыннан биш йолдызлы коньякны алып, өстәлгә шалт итеп китереп утыртты, челтер-челтер рюмкаларны тезеп чыкты. Кара икрадан, каймак өстәлгән помидор салатыннан авыз итеп, юка телемләп киселгән ит белән кыздырылган бәрәңге ашап утырганда да Рәфис үрмә гөлле стена артында гына тракторчы егетләрнең булыр-булмас итле ашны шупырдатып эчүен ишетеп торгандай булды. Әйтерсең, аларның берсе менә хәзер ишекне төбенәчә каерып ачар да, йөзенә ачы нәфрәт чыгарып текәлеп карар кебек иде. Күңелендәге авыр тойгы, хуш исле тәмләткечләр салып әзерләнгән ризыкның кадерен киметте, ул ашаса ашады, ашамаса — юк,

юньләп чәйнәмәгән килеш тамагын авырттыра-авырттыра ашык-пошык йотканда, тончыгуданмы, әллә бүтән сәбәптәнме, күзләреннән яшь чыкты.

Рюмкадагы эчемлекне күтәреп куйгач кына, ул тынычлана төште, миснә сарылган сөрем дөньядагы гаделсезлекне тигезләгәндәй итте. «Вөжданны йөгәнләүнең иң гади ысулы»,— дип ачы көлемсерәде Рәфис.

— Сезнең бу бүлмәгез бик зәвыклы эшләнгән,— диде ул аннары салават күпере төсләре балкыган стенага күз йөртеп.— Тормышның кадерен белеп яшисең, дус кеше.

— Мәһы бирергә исәп юк,— диде Шәмсүн Рәфиснең бу сүзләренә күңеле булып.— Ләкин шуны аңла — син әйткән бу кадерле тормыш миңа җиңел килде дип уйлыйсыңмы? Ух, башта ничек иза чигәргә туры килде... Син безнең авыл хуҗалыгы идарәсе рәисен беләсең инде. Һашимовны әйтәм... У-у, нинди үзсүзле, каты күңелле кеше ул! — Шәмсүн шешәдән фужерга минераль су салып эчте дә сөйләп китте.— Әйе, күпме газап чиктем, шелтәләр ашадым... Исәбе-хисабы юк. Һашимов хәзер генә яхшы, башта ул минем җаныма аз тимәде. Бервакыт шулай, җир кибәр-кипмәс, совхозның люцерна җирләрен күрсәтегез, дип алҗытты. Җир үтә пычрак, җитмәсә, өстән явып тора, ә люцерна җире басуның читендә үк иде. Ул, киребеткән УАЗга утырып, шул җирләрне карарга китте. Берәр чакрым киттеләрме-юкмы, кереп чумды болар баткакка. Трактор белән тартып чыгарырга туры килде. Бераздан тракторы да сазга батты. «Ат иярләп китерегез!» — дип бәйләнә генә бит. «Иярләр юк»,— дип карыйм. «Совхозда ияр юкмы? Җир астыннан табыгыз!» — дип җикеренә бәдбәхет. Үзәгемә үтте ул Һашимов дигәннәре. Чәчемне агартты.

— Чәчең бик агарганга охшамый әле,— дип кинаяле көлемсерәде Рәфис.

— Чөнки гел генә газап чигәргә димәгәндер. Безгә дә бәхеттән өлеш чыкты. Ауга йөрү галәмәтенең файдасы инде... Шулай берчакны куян эзенә төштем дә бурзайны ияртеп киттем эз буйлап. Ничә чакрымнар бер тирәне әйләнгәнмендер, чистый кара тиргә баттым. Берзаман куаклык арасыннан зуп-зур куян атылып чыкмасынмы! Тик чакмага басып өлгермәдем, шартлау яңгырады. Куяным чапкан уңайга бөтерелеп тәгәрәп китте дә, ап-ак кар өстенә кан тамчылары чәчрәтеп тынып калды. Бурзайлар, һау-һау өреп, шул якка томырылдылар. Ләкин барып җитмәделәр, бер урында сикергәләп абайлап өрергә тотындылар. Шулчак куаклар арасыннан бергә тоташкан аксыл төстәге сырма-чалбарын киң патронтаж каешы белән буган, бүреген ак япма белән каплаган озын буйлы кеше пәйда булды. Җен ачуым чыкты.

— Син нәрсә, дим, анаңнан ялангач туган нәмәрсә! Мин бит...

Теге кеше ялт борылып карауга, телемне тешләдем.

— Казбек Зиннәтович? Иптәш Һашимов...

— Әйе, мин,— ди бу.

— Ни... гафу...

— Зарар юк.

— Сез дә ауга йөрисезмени?

— Күргәнеңчә.

Шул көннән башлап аның белән еш кына очраша торган булып киттек. Менә шулай, дус кеше, кеше белән кеше очрашмый тормый. Беркөнне шулай кыр үрдәге аттырып шашлык кыздырткан идем. Киек кошның шашлыгы, о-о, нинди шәп була! Ә менә көртлек ите белән дөге өстенә мул итеп кишер тураган пылауга җитми шулай да. Әмма... Үзең атып алган җәнлек яки киек кошны берни дә алыштыра алмый. Һәр эшнең бит аның җае бар. Синең белән дә ул нәрсәне әмәллибез әле, ыслушый.

— Яз җиткәч киек җәнлекләрне аулау тыеладыр бит,— дип сүзгә кушылды Рәфис.

— Һей, ыслушай, мин сиңа карап-карап торам да исем китә, кайда гына яшәдең соң син моңарчы. Урман каравылчысы яки лесничий белән әшнәлегем дә булмагач, нинди хуҗалык җитәкчесе ди мин. Кул гына җитми менә. Эш муеннан. Шулай да киек җәнлек итеннән өзелми идек әле. Бу арада гына бетеп китте. Теләсә кемгә әйтеп аттырып булмый, алар итен бозалар гына, тәмен бетерәләр. Ул эшнең ярыйсы гына рәтен белгән кешем чирләп китте чукынган, больнистә ята. Ә шулай да, синең хакка, бер-ике көннән бу эшне оештырабыз, ыслушый.

Рәфис инде ашаудан туктаган, Шәмсуннең туенып беткәнен түземсезлек белән көтеп, әледән-әле тәрәзә ягына күз ташлаштыргалап утыра иде.

— Хәзер, ыслушый,— диде Шәмсун Рәфиснең торып китәргә чамалавын күреп,— мин сиңа Актай шәһәрен күрсәтәм,— ул башын артка ташлап ихласланып көлеп куйды.— Ә нәрсә, чынлап та шәһәр!

Рәфис белән Шәмсун ашхананең арткы тар коридор буйлап тышкы ишеккә үтешли, үзләренә туену өчен махсус ясалган кечкенә бүлмәдән ялкау гына авыз-борынын ялаштыргалап бурзайлар килеп чыкты.

Ишек төбендә Шәмсуннең «Волга»сы аларны көтеп тора иде. Хуҗалар чыгуга, шофер моторны кабызып җибәрде. Этләр өйрәнелгән гадәтләре буенча кабина эченә атылдылар.

— Җәяү генә йөрик,— диде Рәфис.

— Әйдә соң,— дип Шәмсун риза булды.

Тышта көн аязып, болытлар арасыннан кояш балкыган. Елтыр нурлар кар җемелдәвенә әйләнеп күзне чагылдыра, күз кабаклары кысылып тар сызыкка әйләнә. Шәмсуннең болай да кысык күзләре бөтенләй йомылган кебек.

Кояш җылысы көнне шактый йомшарткан, көрән төскә кергән карлы юл баскан саен шыгырдап иңә, тирә-юньгә терлек тизәге катыш сусыл кар исе таралган. Урам буйлап барганда Рәфиснең йөрәк турысында аңлатып булмый торган газаплы һәм татлы бер төен хасыйл булды. Атлаган саен яшьлектәге истәлекләр белән бәйле бу рәхәт әрнү йомгагы йомарлана барды, бөтен җанны биләп алды, аны юкка чыгару мөмкин түгел иде. Үзенең бу сәер халәтен Шәмсун сизми микән дип яшертен генә аның ягына күз төшереп алды.

Тик бу бәхетле кеше бурзайларның әле берсенең, әле икенчесенең озын йонлы муенын кытыклап уйный, шәлперәйгән колакларын, очлы борыннарын угалап шаяра, авыр гәүдәсе белән селкенгәләп алардан качкан була. Тегеләре бар куәтләренә сикереп хуҗалары янына килеп җитәләр дә, арткы аякларына басып Шәмсун кулындагы ит кисәгенә очыналар. Югарыга чөелгән йомры калҗаны һавада килеш авызлары белән «һап» итеп эләктереп алгач, Шәмсун:

— Менә, маладис!— дип этләрне мактап куя.

Төзелешләрдән калган ком-балчыклар, тигезсез түмгәкләр белән аралашкан яңа таш йортларны күрсәтә-күрсәтә, шушында үсеп чыгачак шәһәр турында кайнарланып сөйли башлагач, Рәфис үз-үзен битәрләде: Юкка гына аның хакында начар уйлыйсың. Шундый ук беркатлы, ихлас җанлы икән ич Шәмсун».

## 2

Аның әйткән сүзен үтәми калмаячагын Рәфис белә иде. Чынлап та, кояш баюга барганда капка келәсен шалтыратучы кем булыр дип атылып чыкса, каршында җиңелчә кыска куртка кигән Шәмсун басып тора иде.

— Нәрсә, син, кич җиткәнче үк капкаңны бикләп куйдың,— диде Шәмсун гөрелдәвек тавыш белән.

— Эти эшедер инде,— дип акланды Рәфис.

— Ярый, аңардан зыян юк, ауга дип алмага килдем үзеңне,— диде Шәмсүн икеләнерлек урын калдырмый торган боеручан тавыш белән.— Тиз генә киенеп чык та элдерәбез. Сиңа да мылтык алдым.— Ул капка төбендәге УАЗ машинасына таба ымлады.

— Әле хуҗалык белән дә юньләп танышмаган,— дип сөйләнә башлаган Рәфиснең авызын тиз япты.

— Өлгерерсең,— диде ул катгый итеп,— башта ау хуҗалыгым белән танышып җибәр. Бару белән кирәк-яракны әзерләп куярбыз. Хәер, минем ярдәмчеләремнең анысына гына башы җиткәндер. Кыскасы, бар әзерләнеп чык. Биш минут сиңа!

Тышта көн болытлы иде. Бертуктаусыз сибелгән кар күбәләкләре боз бөртекләренә әйләнгән. Гүя алар Рәфиснең күңел кылларына шыбырдап бәреләләр дә зеңгелдәп моңарчы йокымсыраган уйларны уятып җибәрәләр. Уй-хисләрне яңартучы сәбәп — табигатьнең дуамаллануыннан битәр, бу көннәрдә баштан кичкән хәлләр, шуңа бәйләнешле истәлекләрдән килә бугай. Кино тасмасыннан төшкәндәй, тере картиналар күз алдында бер-бер артлы алышынып тора: менә студентлар тулай торагындагы Шәмсүн белән икәү яшәгән зәңгәрсу стеналы кечкенә бүлмә. Бакчага карый торган бердәнбер тәрәзәсе булган бүлмәдә җиһазлар күп түгел. Ике як стена буенда ике агач карават. Баш башында буявы купшый төшкән озынча тумбочкалар. Уртада — кечерәк өстәл, өстәл тирәсендә тирәүле берничә урындык.

Шәмсүн караваты ягындагы таш стенада аучылар тормышын чагылдырган рәсемнәр: иңенә ике көпшәле мылтык аскан, биленә патронтаж ураган, җирән мыегы як-якка салынып төшкән аучы, аның шапрынулы хикәятен: «Әйдә, сиптер агай!» — дигән төсле хәйләкәр ышанмаучылык белән тыңлаучы әңгәмәдәшләре, төрле токымдагы ау этләре...

Шәмсүннең көн аралаш ауга йөрүләре... Кич-кырын йә баштанаяк лачма суга батып, янсә кыш бабайдан ак карга уралып, арып-алҗып бернинди табышсыз кайтып керүе, идән уртасына утырып бөтен бүлмәгә юеш итек, чолгау һәм шуның ише нәрсәләрен тарата-тарата чишенүе, кастрюльләрне шылтырата-шылтырата тамак ялгап алганнан соң, караватына авып йоклап китүе күз алдыннан йөгерде.

...Җәлпәк ботаклы нарат агачлары белән уратып алынган йорт янына җиткәч, сарыга буялган биек коймалар артында абайлап өргән эт тавышлары ишетелде. Капка белән янәшә урнашкан каравылчы йортыннан кыска тун кигән базык гәүдәле, каракучкыл йөзле кеше күренде. Шәмсүнне күрүгә, ул очлы иреннәрен җәя төшеп елмаеп җибәрде.

— Әңгер-меңгер куерганчы килеп җитүегез яраган,— диде ул сүзләрен иреннәрендә чәпелдәтеп,— югыйсә, әнә болытлар куера, ява-рга тотынса юлны мәлҗерәтүе дә бар.

— Таныш бул,— диде Шәмсүн, минем хуҗалык буенча ярдәмчем Минәт булыр бу. Эшне шома йөртә торган егет. Кирәгең чыкса, югалып калма, аңа гына әйт. Хәзер әйләндереп чыгарыр.

«Кайдадыр күргәнем бар бит бу кешене,— дип үз алдына пышылдады Рәфис.— Исеме дә таныш».

Ау өенең стеналарына болан, аю, бүре сурәтләре чигелгән кыйммәтле паласлар эленгән. Йокы бүлмәсе ярым караңгы. Каз мамыгы тутырып ясалган түшәк-ястыклар өстенә сыек яктылык сирпелә. Идәндә аю тиресе җәйри.

Аш-су бүлмәсендәге табында бизәкле япмасы ачылып куелган алтын йөгертүле савыт-сабалар.

Уң як ишектән керүгә — сауна. Кызу парлы ләүкәдән төшүгә ятып ял итү өчен йомшак киезле ятаклар. Стена-түшәмендә төсле пыялалардан җыелган витражлар. Гаять зур залның аргы башыннан бассейн сузылып китә. Ул түм-түгәрәк күлне хәтерләтә. Кыш-яз көннәрендә дә аның тирәсендә ямь-яшел каеннар үсә. Бу ясалма күл бина эченнән тышкы

якка ук чыгып китә һәм җәйге коену урыны белән тоташа. Җәйге күлне бассейннан зур тимер ишекләр аерып тора. Теләгән кеше шул ишекләр аша кыш көне дә табигать кочагына чыга ала.

«Менә кайда икән җәннәт»,— дип тел шартлатты Рәфис.

Ак халат кигән мөлаем ханым аш-су ташый башлады. Буы чыгып торган тавык шулпасы, киек кош итләре, гөбәдия-пәрәмәчләр... Ни генә килеп кунакламады табынга!

«Болар бар да минем хөрмәткәме?» — дип гаҗәпләнде Рәфис.

Табынга утырышып алгач, Шәмсүн алтын йөгертелгән рюмкаларга әрмән коньягы агызды да сүз башлады.

— Бүгенге мәҗелесебез, минем сабакташым, дусым Рәфиснең совхозыбызга урнашып эшли башлавы уңаеннан оештырылды. Баш зоотехник булып урнашуы шайтаныма олаксын, алар бездә дистәләгән булды. Килә тордылар, олага тордылар. Иң мөһиме — Рәфис яшьлек дустым. Ул, шушы авыл кешесе булгач, монда төпләнеп тә калачак әле. Ягез, бу олы вакыйга уңае белән күтәреп куйыйк.

Табындагылар Рәфискә күзләрен җелтерәтеп алдылар да, тын да алмыйча рюмкаларын бушаттылар.

Бар кешедән дә күбрәк сөйли торган Минәт ашыкмый гына торып басты. Беркавым нечкә иреннәрен очландырып елмаеп торды.

— Болай ул, туганнар: ягъни мәсәлән, һәр мәҗелеснең үз төсе, әйтергә яраса, үз тәме була. Аның төсе турында Шәмсүн Хәерович әйтте инде. Мин кабатлап тормыйм,— ул астан сөзеп Рәфискә карап алды,— ә тәме... Юк, Гайшә җиңги пешергән телеңне йотарлык нигъмәтләр генә түгел, бүтән хикмәтләр генә дә түгел, иң әһәмиятлесе, бу йортның үз җисеменә туры килә торган хасиятендә. Ә бу четерекле эш нәкъ минем өстә. Осталыгым ни чамалы булган, иртәгә аудан кайткач әйтерсез. Хәзергә минем ул эшкә уңышлыклар теләп, рюмкаларны куюдан гайре чара юк.— Көлешүләр, чөлтер-чөлтер рюмкалар чыңлавы, голт-голт йоткан авазлар, тамак кырулар, лач-лыч чәйнәгән тавышлар гына ишетелеп торды.

Шәмсүннең, сокланган кыяфәт белән Минәткә карап торуыннан, хуҗа кеше аңа карата аерата җылы мөнәсәбәттә, ахрысы, дип уйлады Рәфис. Карашын үзенә чәнчегәнен күргәч, Минәт көлемсерәде.

— Син мине танымыйсың, ахры, ә мин сине яхшы хәтерлим, сабакташ. Исеңдәме, бервакыт Кадыйрҗан абый белән сүзгә килгән идең. Шелтә алсаң алдың, әмма сүзеңнән кире кайтмадың. Шунда мин сине...

— Кара малай! — дип кычкырып ук җибәрде Рәфис.

— Нәкъ үзе! — диде Минәт очлы иреннәрен ерып.— Барысы да миңа шулай дип дәшә иде.

Хәтерли Рәфис, ничек кенә хәтерли әле! Физкультура дәресе иде. Кызлар ял иткән арада малайлар озынлыкка сикерергә тиеш иде. Ә Рәфис аягына чолгау чорнап кирза итек киеп килгән. Сикерәм дип ничек итеп кызлар алдында шул чолгавыңны ялтыратып итегеңне саласың? Ә кызлар арасында зәңгәр күзле, җиңел гәүдәле Гөлфинур бар. Салмады Рәфис итеген, укытучы абыйлар кат-кат таләп итсә дә салмады. Билгеле инде, сикерүдән дә баш тартты. Авыр итекләр белән бик сикерә дә алмассың. Әлеге кара малай аңа күн чүәкләрен биреп тормакчы иде. Рәфис анысыннан да баш тартты. Укытучы Кадыйрҗан абый кызып китте. Кызлар алдында Рәфиснең беләгеннән эләктереп алды да директор бүлмәсенә сөйрәп керде. Директор яныннан чыккач, буш класска кереп түйганчы бер эчен бушатты: бугазына бөялгән гарьлек дулкыны ярсып-ярсып тышка бәреп чыкты. Җитмәсә, шул чак мыштым гына янына Гөлфинур килеп баскан. Үзенә күз атып йөргән егет кисәген юатып маташа, имеш... Йә, шундый очракны ничек хәтереңнән чыгарасың!..

Табындагыларның дәррәү кубарылып урыннарыннан торуларына күтәрелеп караса, ишек катында Һашимов басып тора. Өстендә аучылар

кия торган яшькелт куртка, билендә патронтаж. Ә янында үзеннән бик күпкә яшь чибәр ханым.

Һашимов шау итеп барысы белән дә күрешә башлаган иде, Рәфисне күрүгә чырае бозылып китте. Шулай да сер бирмәде, аның белән дә җылы гына кул алышты.

Яңадан утырыштылар. Яңабаштан тостлар әйтелде. Һашимов үзен тыйнак тотып, рюмкага авыз тидереп кенә алды. Аның каравы, кабарып торган коңгырт чәчле, соры күзле чибәр ханым ялындырып тормады, озын тырнаклы нечкә бармагын бик килешле тырпайтып рюмка биленнән эләктереп алды да төбенәчә эчеп бетерде. Табын янында шундый ханым булгач, ирләрнең йөзенә көләчлек кунды, берсеннән-берсе уздырып, көлкеле вакыйгалар сөйли башладылар. Ау турындагыларыннан башланган бу әңгәмә гыйшык хәлләренә барып тоташты. Табын кыза барган саен сүзләр куерды, инде беркем дә әңгәмәдәшен тыңламый иде. Ә ханым бөтенләй чәчәк атты.

— Музыка! — дип кычкырды ул. — Минем бисем килә!

Һашимов аңа иелеп нәрсәдер пышылдады, ләкин чибәркәй кул селтәде дә көй яңгырый башлауга биергә чыкты. Ул уртага Һашимовны сөйрәгән иде дә, тегесе карышты, канәгатьсезлек белдереп чыраен сытты. Тик ханым аптырап калмады, кулыннан тотып Шәмсүнне тартып чыгарды. Шәмсүн аның белән биегәндә Рәфискә әледән-әле күз салып нидер аңлатып маташты. Ханым моны сизде. Табында ят булган егетне каерыла-каерыла күзе белән «ашарга» тотынды. Ул да булмады, Шәмсүннең зал уртасында бер үзен калдырып, бераз тотрыксызрак хәрәкәт белән Рәфисне биергә чакырды.

Рәфискә уңайсыз иде. Ул үзенең бу мәҗлестә инде артык кеше булуын сизә, үзен көчләп диярлек энәләр өстендә утыргандай хис итә иде.

Биюләр тәмамлануга, ханым вак-вак атлап Һашимов янына йөгереп килде дә аның битеннән үбеп алды.

— Үпкәләмәдеңме, җаным! — дип шар кычкырып җибәрде ул. — Юк бит, үпкәләмәдең бит! Алайса үп мине!

Һашимов кызарынды, бүртенде, әледән-әле Рәфискә күз атып, ханымга нидер аңлатырга тырышты.

Ханым шаркылдап көлеп җибәрде.

— Куркагым минем, — диде ул Һашимовның шома битеннән иркәләп, — бар да үз кешеләр ич, нигә коелып төштең, җаным!

Рәфискә әнә шул сүз генә җитмәгән икән. «Бар да үз кешеләр. Ә менә мин чит кеше, — диде ул үз-үзенә. — Ашка төшкән таракан».

Ул тиз генә урыныннан торды да ишеккә таба атлады.

Шәмсүн аны куып җитте.

— Син кая кузгалдың әле?

— Башым авырта, саф һавага чыгам, — дип ялганлады Рәфис.

— Аңлыйм мин сине, — диде Шәмсүн, — нишлисең бит, менә ничек килеп чыкты. Ярый, без моның үчен кайтарырбыз әле. Синең белән безнең көннәребез алда. Син, бераз тын алгач, әйләнеп кер, ыслушый.

Ләкин Рәфис әйләнеп кермәде.

## 3

Кичке салкын төште. Җиргә төтен сыман томан сарылган. Шул куе аксыллык арасыннан пәйда булган бина Рәфискә әллә ничек ят булып, тәбәнәкләнеп күренде. Әйтерсең, томан катламы яңа төзелеп яткан бу соры корылмаларны бөтен авырлыгы белән изгән, җиргә сеңдергән.

Абзарга килеп керүгә, аның битенә җылымса һәм йомшак һава бәрелде. Сыерларның улакка туралган чөгендерне шытырдатып чәйнәве, савымчыларның резин итекләрен юеш сайгак буйлап лыштырдатып саву аппаратларын әзерләп йөрүләре күзгә чалынып калды. Ха-

тыннарның кайберсе астыртын гына Рәфис ягына карап алды да, берни күрмәгәндәй сүрән караш ташлап, үз эшендә булды.

Тулы гәүдәле кискен карашлы Бану исемле хатын янына килеп туктады ул.

— Йә, ни хәлләрең бар, Бану?

Бану Рәфис ягына борылып та карамыйча:

— Әйбәт әле,— диде, һәм кызу-кызу гына китеп, саву стаканнарын аклы-каралы сыерның имчәкләренә кидертә башлады.

Рәфис бермәлне Бануның киеренке йөзенә, ике күз арасына сызык ясап дугаланган куе кашларына карап торды. Күңелен эретерлек җылы сүз әйтмәкче булды, тик бу барып чыкмады, аның үзенең дә авыз эче кибеп киткән, яңаклары кырышкан төсле иде. Ул тамагын кырып алды, киеренкелекне киметер өчен авыз эченнән үзенә генә билгеле көй шыңшып бүтән савымчылар янына китте. Ләкин алары да яңакларын өрдереп тавыш-тынсыз эшләүләрен беләләр. Рәфис үзләренә дәшмәсен дигән кук, бер дә кирәкмәгәнгә сыерларына «Пуга, пуга!» — дип кычкырып, арткы саннарын учлары белән чапылдата-чапылдата каядыр кугандай итәләр иде.

Рәфис бу читләшүнең серен аңламаудан гаҗиз иде: ят кеше итеп күрәләрме аны, әллә нидән дә булса хәтерләре калганмы? Моның өчен әле сәбәп юк, булуы да мөмкин түгел, чөнки ул бары эшкә тотына гына. Үзләре шундый кыргый дияр идең, кумәк хезмәттә мондый хәл булмый, нинди йомыкыйлар да бер-беренә ачылып-туарылып китә. Һәрхәлдә, бу салкынлык өчен Рәфис беренче чиратта үзен битәрли, алар белән бергәбер тәүге очрашуда ук уртак тел табып китә алмавына газаплана иде. Ләкин күңел кыллары бозланып туңган хатыннар белән тел ачкычы таба алмыйча, үзеңнең көчсезлегеңне, булдыксызлыгыңны тамаша кылып абзар сайгакларын күпме таптарга була! Абзардан чыгып китәр алдыннан Рәфис гел чыркылдарга ярата торган каракучкыл йөзле Рәниягә караш ташлап алды. Ул башка хатын-кызлар кебек иренен бүлтәйтеп йөрми, авыз ачып сүз дәшәргә дә йөрәге җитми, гүя сүзсез киеренкелеккә ул гаепле һәм шул авыр хәлдән чыгу көченнән килми иде. Чынлап та, хатыннарның кара көеп йөрүе аның аркасында булды бит, яңа туган бозаурга бәйле вакыйга аркасында.

...Терлек абзары янындагы тиреслектә нәрсәдер селкенә кебек тоелды. Рәния игътибар белән текәлеп баккан иде, яшь бозау аяклары күреп алды. «Бозауның арткы аяклары ич бу. Ә баш ягы? Баш ягы тирескә күмелеп калган».

Рәния бозауның сап-сары тояклы аякларыннан сак кына тотып сөйрәп чыгарырга теләде, әмма булдыра алмады. Таудай өелгән тиресне ул куллары белән ашыга-ашыга йолыккалады да, тагы бозауны суырып алмакчы булды, тик көче җитмәде. Өстәвенә, каты тартып япь-яшь бозауның берәр җирен зарарлармын дип курыкты. Ул шулай шактый азапланды, тирләп-пешеп чыкты. Алай да булмагач, атылып абзарга керде.

— Бозау тирес астында калган!

— Тирес астында? Кем бозавы?

— Кемнеке, кемнеке... Тиз булыгыз инде!

Хатыннар йөгерешеп чыктылар да сәнәкләр, көрәкләр белән тиресне актара башладылар. Бераз казыгач, Бану бозауның арткы аякларына ябышып, бар көченә тарта башлады.

— Акрын! — дип чәбәләнде Рәния,— буынын тайдырып чыгарасың бит!

— Кит әле ичмасам! — дип җикеренде Бану.— Эчемне пошырып торма!

Озын буйлы, ябык гәүдәле хатын кулларын тирескә эчкәре үк тыгып бозауның дерелдәгән гәүдәсенә тотынды. Ике-өч хатын сөйри-тарта торгач, салам-тизәк белән аралашкан катнашма астыннан мескен бозауны йолкып чыгардылар. Шулчаклы авырлык астында сәгатьләр буе ятып яс-

сы рәвешкә кергән бозау талпынып та карамады, аңарда җан әсәре бармы-юкмы икәне дә сизелми иде.

— Үлгән ич инде бу! — диде Саимә.

Рәния бозау өстенә иелде дә колагын аның күкрәк турысына куйды.

— Йөрәге тибә, бозау тере! — диде ул шатланып.— Әйдәгез, тизрәк абзарга — җылыга кертик, сөт эчертеп карыйк үзенә!

— Эчте ди, эчми ни...

— Тот, Рәния баш ягыннан,— диде Бану таләпчән тестә,— күпме сатулашырга була!

Бозауны абзарга алып кереп ипләп кенә салам өстенә яткырдылар. Кайсы аның аякларын селкетеп карады, кайсы катып калган гәүдәсенә җан кертмәкче булды. Ләкин бозау башын артка ташлаган хәлдә күзләрен йомып, хәрәкәтсез ятуында булды.

— Чынлап та беткән бу,— диде Бану өметсез төстә,— чокырга алып барып күмәсе генә калган.

— Бозауны үтергән өчен баштан сыйпамаслар. Синең сыер кичә бозаулады түгелме?

— Бозауласа соң, бозавы беркая китмәгән... Теп-тере...

— Бу кемнеке була соң инде алай булгач? Ничек тиреслеккә барып чыккан.

— Минемчә,— диде Саимә кашларын җыерып,— синең ул сыер икене бозаулаган булган.

— Бернеме, икенеме, буласы булган инде, әйдә, катып тормагыз, Шәмсүн йә Рәфис күренгәнче алып барып күмик. Синеке-минеке дип тормаслар, барыбызны да премиясез калдырырлар. Күмдек, бетте-китте, барыбызның да бозаулар бармы — бар!

Шулвакыт Рәния атылып барып бозау өстенә ятты.

— Күмдермим! Үлмәгән ул... Мин аны терелтәм!

— Кара, бу тиле-милене... Тор, яхшы чакта, юньсез! — Бану Рәниянең иңнәреннән эләктереп бозау өстеннән сөйрәп алмакчы булды. Тик Рәния аның саен бозауны кочаклап еларга җитешеп ачыргаланып кычкыра иде.

— Бирмим бозауны, бирмим!

Берничә хатын Рәнияне бозау өстеннән йолкып ыргытты. Барсы да җыйнаулашып әле үлеп бетмәгән җан иясен терлек абзарыннан шактый читтә үсеп утырган карт имән төбенә алып китте. Рәния яңадан торып бозауны алып калмакчы булып чәбәләнсә дә, аны якын җибәрмәделәр.

Бозауны күмеп бетереп туң җир кантарларын тигезли-тигезли, беленмәсен өчен өстенә салам сибеп маташканда, Бану хәвефле пышылдады:

— Рәфис килә!

Хатыннар мыштым гына терлек абзарына ашыктылар.

...Рәфис ике урамны тоташтыручы тар тыкрык чатында урнашкан, урталай ярылган юан бүрәнәләрдән салынган терлекчеләр йортын карап чыгарга булды. Йортның тәрәзәләре зур, тәрәзә йөзлеге сырлап-нитеп тормыйча туры сызыклы итеп эшләнгән.

Ишек алдына шактый кар түшәлеп, өй алды баскычлары күгелҗем төскә кереп бозланып каткан. Ишек элмәгенә тагылган һәм коңгыртланып күгәргән озынча тимер йозак бикләнмәгән иде. Рәфис чүп-чар тулган өйалды идәннәренә шыгырдатып басып эчкә кергәч, аны кәефне кыра торган тынчу исле ямьсез күренеш каршылады: стеналарга ябыштырылган сары обойлар ертылып беткән, урыны-урыны белән саргаеп һәм кубып зәгыйфь кош канатлары кебек салынып тора. Идәндә ертып яки бөгәрләп ташланган һәртөрле эш кәгазьләре аунап ята.

Рәфис озынча тимер караватка елышып, бөтен гәүдәсе бөрешкән хәлдә озак кына хәрәкәтләнмичә утырды. Бүлмәдәге таркаулык аның үзенә дә тәэсир иткән, аяк-кулының һәр буыны ихтыяр көчен югалтып таралып төшкән төсле. Чемердәп тәненә үрмәләгән чиркандыргыч суыктан дерелдәп-дерелдәп китсә дә, ул урыныннан

кузгалмады. Кымшанса — эчендә калган барлы-юклы җылы да чыгып бетәр, ул чагында бөтен әгъзаларына бозлы һава кереп тулар сыман иде. Хәтта җаны да оешып каткан, фикер агышы тукталган кебек. Уйлап баксаң, тән һәм җанының болай туарылып китүе бүлмәдәге таркаулыктан гына түгел икән. Аларга ялганып, терлекче хатыннарның нигәдер тетрәнеп яшеренгән гаепле карашы күз алдында чекерәеп торды. Шушы хәленнән чыгарга теләп, Рәфис йон одеал җәелгән карават өстендә утырган килеш, куллары белән төрле-төрле күнегүләр ясап карады. Ләкин аның бу хәрәкәтләре сүлпән, яшәү ярсулыгын җуеп оеган дөньясын салкын өнсезлектән чыгарып җибәрерлек түгел иде.

Үзенең шулай йомшарып, көчсезләнеп калуына ачуы чыкты. Шуңа үртәлеп урыныннан сикереп торды һәм кызу-кызу атлап өйдән чыгып китте. Урамга чыгуга ул, бозланган юлга чыртлатып басып, өер-өер кантарларны читкә аттыра-аттыра юырткан атлы җайдакны күтеп алды. Ферма мөдире булып эшләүче Галим абзый икән. Ул атының соргылт ялына ябышып килгән уңайга, кыска гәүдәсен салмак атылдырып, вак бозлар сибелгән карлы җиргә сикереп төште.

— Рәфис Гәрәевич,— диде ул ярсуыннан тотлыга-тотлыга.— Рәфис Гәрәевич, эшләр харап!

— Ни булды?

Галим абзый сүзен әйтә алмыйча авызын мүкелдәтеп торды, бугазындагы төере тирбәлеп алды.

— П-пәхри ярына су төшкән!

Рәфис берни аңламыйча күзен челт-челт йомгалады.

— Төшсә соң?

— Су ургылып ага. Ат белән дә чыгар хәл юк! Сыер савучылар бүленеп калды бит! Сыерлар савылмады!

Менә хәзер генә эшнең нидә икәнен төшенде Рәфис. Әйе, эшләр начар: совхозның барлык савымчылары диярлек моннан җиде чакрымда урнашкан Әлкәс авылыннан иде.

Ул зур киеренкелек белән күзләрен берьяктан икенче якка йөртеп, нишләргә икән, дип торды.

Капыл гына бер карарга килеп тракторчыларны эзләп китте. Ләкин ферма ишеге төбендәге таудай өелә башлаган тирес өеме янында трактор чанасы сызып калдырган буразнадай эздән гайре берни күрмәде. Ул каударланып абзарга килеп керде. Өстенә кыршылган тун, башына колакчын малахай кигән карт, абзар эчендәге соры бетон баганага сөялеп, гамьсез генә тәмәке көйрәтеп тора иде.

— Кайда тракторчылар? — дип сорады Рәфис ачуына буылып.

— Кайтып киттеләр,— диде карт бер дә исе китмичә.

— Ничек кайтып киттеләр?

— Мин дә: «Кая барасыз?» — дигән идем дә, синең ни эшең бар, дип җикеренделәр генә.

Рәфиснең иреннәре тетрәнде: «Үз энең шул рәвеш битеңә төкерсен әле! Ну, Хәдис!»

Бөрчек-бөрчек шадралы панель йортның тәмәке төпчекләре дә себерелмәгән ишеге төбендә ул өйдән чыгып килүче Хәдиснең ябыгып коры сөяккә калган хатыны Нәсимәгә бәрелә язды.

— Хәдис кайда? — дип сорады ул каты тавыш белән.

— Йоклый иде шул,— диде хатын чак ишетелерлек итеп.

— Кайда ул, күрсәт! — Рәфис куркуыннан ап-ак булган хатынны ияртеп өйгә керде һәм барысын да аңлады: җәлпәк бите кызарып, маңгаена тир тамчылары бәреп чыккан алыптай ир, майланган киемен дә салмыйча, идәндә гырлый-гырлый йоклап ята иде.

— Алай,— диде Рәфис гаҗиз булып.— Һәрвакыт шулай исереп кайтамы?

— Һәрвакыт дип... Булгалый инде.

Эчендә кайнаган ачудан Рәфиснең бөтен тәне киеренке бер хәлгә килде, куллары үзеннән-үзе йомарланды. Аннары көч-хәл белән үзен кулга алып, ни үле, ни тере булып куырылып басып торган Нәсимәгә «хуш» дип тә әйтмичә, ишекне каты ябып өйдән чыгып китте.

«Икенчесе кайда икән инде? Анысын эзләп тапмый булмый,— дип үз алдына сөйләнде Рәфис.— Анысы да шулай кыегайган булса?» Каравылчы карт анысына барып әйткән, ахры. Садри исемле бу егет кыюсыз адымнар белән үзе бирегә таба килә иде.

Егет Рәфис янына ике адым килеп җитмичә тукталды да, җилкәләрен тырпайтып ияге белән комбинезон якасын ышкыштырды. Кыяфәт гүя: «Мин шундый тинтәк малай инде»,— дия иде.

Рәфис, ни әйтергә инде моңа, дигәндәй текәлеп карап торды да, көтмәгәнчә тыныч тавыш белән:

— Бар, тракторыңны кабыз да чана тагып бирегә кил. Тиз бул! — диде. Ул арада Галим абзый белән партоешма җитәкчесе булып эшләүче Айрат Бәдретдинович килеп җитте.

Тагын берничә минуттан алар трактор чанасына утырып юлга чыктылар. Рәфискә зур чанасын сусыл кардан чыштырдатып сөйрәүче кара җанварга охшаган трактор бик акрын бара кебек тоелды. Җанын кая куярга белми бәргәләнеп, ул трактор чанасының башыннан икенче башына йөренде. Аннары, сабырлыгын җыеп, чана табаннарыннан ике якка сибелеп калган сусыл карга карап бара башлады.

Айрат Бәдретдинович үзенә сиздерми генә яңа баш зоотехникның хәрәкәтләрен күзәтеп бара. Бер ымсыз барганга аның күптән эче поша, сүз кузгатырга теле кычыта иде.

— Бер уйлап баксаң,— диде Айрат Бәдретдинович ишелеп-ишелеп артка шуучы кар буразнасына карашын текәп,— узган вакыт та эреп баручы юеш кар кебек төрле якка чәчрәп юкка чыга. Яшәгән гомернең, мөгаен, күбрәк өлеше әнә шул чапырдап кимегән көпшәк бозлардай файдасызга югала торгандыр.

— Бу — кешенең үзеннән тора,— диде Рәфис сүрән генә.

Рәфиснең аның сүзенә кушылуыннан Айрат Бәдретдиновичның кәефе күтәрелеп китте.

— Синдәй чагымда мин дә әлләниләр кыйратырмын кебек идем. Чәпчергә яратканга тал чыбыгы аз ашамадым. Кайбер тәкъдимнәрне мин Шәмсүнгә дә әйтеп карадым. Тик мондый чакта аның күзләрендә килешмәүчән чаткылар кабына иде. «Син хуҗамы монда, әллә минме?» — дип гел әтәчләнә иде. Алга сикереп чыгуның мәгънәсе юклыгын аңлап, эчтән тына торган булдым. Нишлисең, карт көнемдә эшемнән куылып авылдан китәсем килмәде.

— Алай,— диде Рәфис,— алай...

Трактор йөрешен бик нык акрынайткан күк тоелды.

— Кызурак, кызурак! — дип ашыктырды ул тракторчыны.

Трактор моторы бөтен көченә эшли башлады. Кинәт кызу алдырып китүдән, чанадагы кешеләр артка сөрлегеп куйды.

Рәфис ерактан ук күрде: Пәхри ярының Әпәлигә таба күтәрелеп киткән өске ягы зәңгәрсу-күгелҗемләнеп елтырый, ә түбән өлеше диңгез сыман киңәеп каршы яктагы тәбәнәк калкулыкка чаклы җәйрәп ята. Ярның аргы тарафындагы калку төбәктә бер төркем хатын-кызлар, үзләренә якынлашучы тракторны күргәч, кычкыра-кычкыра кул изи башладылар. Кемдер көлеп җибәрде, берсе төркемнән аерылып ярга таба йөгерде. Яр якынлашкан саен, ургылып аккан ташкын киңәя барды, су өстендәге аксыл-зәңгәр төстәге көпшәк боз кисәкләре салмак кына якынлашып, юл турысына җиткәч, ниндидер күзгә күренмәс көч этеп җибәргәндәй, капыл тизлекләрен арттыралар иде.

Айрат Бәдретдинович кар өстендә җем-җем иткән нурлар чагылышыннан күзләрен кысып, ярның аргы ягындагы хатын-кызларны берәмберәм барлый башлады:

— Наҗия, бар, Кәримә, Алсу... Ә Гашия кайда? Вәт син ә! Барсыннан да катырак кычкыра торганнары бар, ә шыпыртлары — юк! Ул бераз тын торды, аннары Рәфискә борылып әйтеп куйды: — Ташкын да шулай бит, уртада өерелеп-шаулап акканы иңкүлеккә җитә, ә чит-читтагы тымызыгы йә карга сеңә, йә бөтерелеп-әйләнгәләп чоңгылга төшә. Менә бит ул ничек килеп чыга!

Тракторчы егет кабинадан сикереп төшеп, чана янына килде. Ул да аптырап калган иде.

— Чананы агызмас микән? Бигрәк котырып ага бит.

Рәфис әле булкылдап-шаулап аккан суга, әле аргы якта «Нәрсә булыр?» — дип көткән хатын-кызлар төркеменә карады. Төркемнең иң алдындагы хатын:

— Җә, нәрсә куркып калдыгыз? — дип кычкырды. — Бер суга акканнан әллә ни булмас!

Алсу аңа мөлаем тавышы белән кушылды:

— Садри, яле, егетлегеңне күрсәт, солдат була аласыңмы икән, карап карыйк!

Урта яшьләрендәге хатын кыланчыкланып:

— Сынатсаң, өйләндермибез дә үзеңне! — дип чәрелдәде.

Хатын-кызлар шаулатып көлешеп алдылар.

Садри кулын селтәде дә җәһәт кенә сикереп кабинага менеп утырды, үзе кабинадан башын чыгарып чанадагыларга:

— Сез төшәрсез, бәлки? — дип кычкырды.

Айрат Бәдретдинович белән Галим абзый аякларын чана кырына атландырып төшәргә омтылганнар иде дә, тик Рәфиснең урыныннан кузгалмавын күреп кире уйладылар.

— Әйдә, кузгал! — дип боерды Рәфис. Үзең ярда калып, яп-яшь кешене ярсып аккан ташуга кертеп җибәрү егетлек булмас иде, дип уйлады ул.

Трактор тилереп аккан ташуга акрын гына борынын төртте дә, кискен хәрәкәт белән ыжгырып өскә күтәрелде, аннары гайрәтле талпынып кызу тизлек белән ярсып бөтерелгән суга кереп китте. Чылбырлар арасыннан ябырылган су ташкыны тракторның тимер тәненә бәрелеп ачу белән югары сикерде, тирә-юньгә бозлы тамчылар чәчрәде. Чана табаннары каты җиргә тимәгәнгә, дулкыннар аны түбәнгә сөйрәде, куәтле агым чана артыннан тракторны да бер якка янтайтты. Машина чытырдый-чытырдый бар көченә тартылып агымга каршы бара башлады. Ташкын-су гүя чананы кешеләре белән трактордан аерып алырга теләп тартышты.

Тракторчы егет гүя машинага береккән. Бербөтен җан булып әле бер рычагны тарта, әле икенчесен. Рингтагы боксер кебек, шашкын табигать көченә накаут ясарга ирек бирми иде.

Рәфис, чана кырына сөялгән озын агач саплы багорны суга төшереп, тимерле очын астагы бозга кадады һәм агымга каршы этенә-этенә: «Их, тагы аз гына!» — дип, тешләрен кысып куәт бирде.

Ярдагы хатын-кызлар ах-вах итештеләр, барысының карашы аларда, күңелләре белән тартып алырдай булып тырышалар иде.

Ниһаять, соңгы омтылыш. Трактор борынын өскә чөеп ярга талпынды да, каты үкереп хатын-кызлар җыйналган ярга тырмашып менде. Ул тимер өслегеннән бозлы сулар агыза-агыза борылырга өлгермәде, хатын-кызлар чанага ябырылды.

Рәфис, кыска киемнәре астыннан кара халатлары күренеп торган савымчылар янында чия төсендәге куртка кигән, иңнәренә сары чәчләре дулкын-дулкын булып сарылып төшкән чибәр кызны күреп: «Кайдан килеп чыккан бу шәһәр сандугачы?» — дип уйлап куйды. Шулчак «шәһәр сандугачы» Рәфискә борылып карады һәм егет аны таныды.

— Гөлфинур! — дип кычкырды Рәфис үзенең кайда икәнен дә онытып. Ләкин үз янына атылып килгән егеткә кыз бернинди җылылык катмады. Ни өчендер, аның йөзе боек, күз карашы үтә моңсу иде.

Гөлфинурның мондый битарафлыгы Рәфиснең күңелен сүрәнләндереп җибәрде: «Оныткан икән». Ул аңа авыз ачып бүтән сүз дәшмәде. Ак кәгазьдәй агарынып калган чыраена, бөтенләй онытылып китеп, йокыга талган күк сөрлегеп-сөрлегеп куюына гына борчылып әледән-әле күз төшергәләде. Трактор, хатын-кыз чыр-чуын иңләтеп бөтерелеп шаулаган су ташкынына кергәндә, Гөлфинур чак кына егылып китмәде. Аны бары янында басып торган Галим абзый гына тотып калды.

— «Ни булган аңа, авырып китте микәнни? — дип уйлады Рәфис.— Тагын янына барып хәлен сорашыргамы әллә?»

Кинәт, шартлауга охшаш коточкыч тавыш чыгарып, трактор ике-өч мәртәбә пытырдап алды да пырх-пырх итеп тынып калды. Садри ярсыйярсый моторны кабызырга тырышса да, машина тынсыз иде. Шашынган су көче трактор чанасына бәрелеп, аны аяусыз рәвештә агым уңаена сөйрәвен дәвам итте.

Садри кабина ишегенә ябышып чылбырлар буйлап трактор алдына үрмәләп чыкты һәм майга, корымга катып беткән копотны ачты. Әйе, шикләнгәне дөрескә килде: тышчасы чатнаган карбюраторны ул тимер чыбык белән тарттырып бәйләп куйган иде, шул шартлап өзелгән. Тырпаеп калган тимер чыбык кисәге кыска булып чыкты, яңадан бәйләп куярга җитмәде. «Их,— дип сукранды Садри,— ничә мәртәбә инженерга әйттем бит шул карбюратор хакында. «Юк» дип җавап бирде». Минһат складында бар иде ул, ләкин акчасыз бирмәде.«Ул склад исәбендә түгел, минем үземнеке»,— дип җавап бирде. Сатып алырга Садриның акчасы җитмәде. «Инде нишләргә? Авылга кире кайтмый булмый. Ничек тә акча юнәтеп Миннәттән шул карбюраторны сатып алырга кирәк. Ләкин ничек ярга чыгарга?..»

Садри, кабина ишегенә тотынып, күбекләнеп котырган су чоңгылына төшә башлады. Ярсып аккан дулкынга тиюгә, көчле агым аягын читкә ыргытты. Садри яңадан өскә күтәрелергә мәҗбүр булды. Багор белән чананың түбәнгә агуын тоткарларга маташкан Рәфис Садриның бу хәрәкәтен күреп аңа кычкырды:

— Нишлисең син, юләр? Агып китәсең бит.

Су шавын җиңеп, Садриның тонык һәм нечкә тавышы ишетелде:

— Авылга кайтмый булмый, Рәфис абый. Карбюратор кирәк.

— Карбюратор? — Рәфис аптырап әле котырып аккан суга, әле яңадан сак кына түбәнгә шуышып маташкан Садрига карады.

— Тукта, мин үзем,— диде ул аякларын чана борты өстенә атландырып.

Айрат Бәдретдинович шунда ук Рәфиснең кулыннан эләктереп алды.

— Җүләрләнмә!

— Сез барыбер берни таба алмыйсыз, мин кайтам авылга! — диде Садри.

Ул итекләре белән су агымын җиңеп астагы боз катысына басты, ләкин шунда ук шуып егыла язды, күбекләнгән дулкыннан калкып торган гусеница чылбырына чак ябышып өлгерде.

Ярдагы хатын-кызлар коточкыч тавыш белән: «Ай!» — дип кычкырып җибәрделәр.

Рәфис тагын бортка ыргылды, тик яңадан аны кире сөйрәп төшерделәр.

— Җибәрегез, тотмагыз мине! — диде Рәфис ярсып,— егетне харап итәрсез бит!

— Иң яхшысы, багорны суз, багорны!

Рәфис шунда ук төшенеп алды һәм омтылышлы хәрәкәт белән багорның ыргаклы башын Садрига сузды. Садри багорның ыргагыннан эләктереп алды.

Рәфис бар көчен куеп багорның Садри ябышкан башын ярга таба бора башлады. Аңа ярдәмгә Айрат Бәдретдинович белән Галим абзый ташланды. Алар, өчәүләп, багорны сак кына шудыра-шудыра Садрины

ярга чаклы җиткерделәр. Хәзер Садрига ыргакны ычкындырып, ярга ябышып калырга кирәк иде. Ул бу омтылышны ясар өчен астагы бозны типкәләп аякларына терәк урын ясады. Һәм шуннан капыл гына этенеп алга сикерде дә, ярга барып капланды.

Бар да җиңел сулап куйдылар. Ләкин егет салкын суга нык кына чыланган иде.

— Йөгер, тукталып торма! — дип кычкырды аңа Рәфис.

Кулларын як-якка селки-селки үзләреннән ерагая баручы озын буйлы егеткә карап ул эченнән көрсенеп куйды: «Их, йомшаклык күрсәттем бугай... Миңа чыгарга иде ярга. Япь-яшь егетне куркыныч алдына куйдым». Тик үз-үзен битәрләргә ашыккан икән — һич көтелмәгән хәл булды.

Ыгы-зыгы арасында Рәфис Гөлфинурын бөтенләй исеннән чыгарган. Кызның хәлсезләнеп чана кырыена чак-чак тотынып торуын да, зур боз кисәге кинәт килеп бәрелүдән чананың чайкалып китүен һәм Гөлфинурның артка сөрлегүен дә күрмәгән. Кызны тотып калырга дип ябырылган хатын-кызларның үзәк өзгеч тавышына борылып караганда, куәтле ташкын эченә очкан кызыл курткалы гәүдә генә күзенә чалынды Рәфиснең. Ул үз-үзен белештермичә кубарылып шул якка ташланды. Аның миеннән: «Кыз йөзә белмидер»,— дигән уй чәнчеп үтте. Шул секундта ук үзе дә кыз артыннан түбән сикерде. Ташкында бөтерелгән боз кисәкләрен аралап бер-ике талпынуда кызның саргылт чәч учмасын күмә-күмә актарылган чоңгылга колач салып килеп җитте һәм кисәк хәрәкәт белән аска чумды. Шунда ук аның бармаклары йомшак тәнгә кагылды. Ул кызны сул кулы белән эләктереп өскә чыкты һәм уң ягына ятып күгелҗем боз белән капланган ярга таба йөзә башлады. Салкын су тәнен бозлы утка салып өтте, аңын томалагандай итте. «Бирешмәскә, бирешмәскә!» Кар-бозлы сөзәк ярга чыгып җиткәндә, кыз бер сүз эндәшми, бары ярым ачык иреннәре генә дер-дер калтырый иде аның.

Аз гына тын алу нияте белән, Рәфис кызның йомшарган һәм салмакланган гәүдәсен кардан арчылып кибәргә өлгергән калку җиргә куеп торды. Күкселләнеп киткән йөзенә күз төшереп куркып китте: «Әллә үлә инде?!» Ул үз-үзен белештермичә аңа капыл ташланып иңнәреннән тотып селекте:

— Гөлфинур, ач күзеңне! Гөлфинур!

Ләкин Гөлфинур озын керфекләрен тибрәтеп тә бакмады, йөзендәге бер сызык та үзгәрмәде. Ул аңсыз иде.

Чанадагылар суга төшәргә маташсалар да, котырган ташкын эченә керергә йөрәкләре җитмичә, ыгы-зыгы килделәр.

Рәфиснең үз хәле дә шәптән түгел: киемнәренә сеңгән бозлы су тәнен калтыратты, теше-тешкә бәрелеп аптыратты. Ләкин ул моңа әһәмият бирмәде, кулмәге тәненә ябышкан җыйнак гәүдәне күтәреп, кызулый-кызулый авылга ашыкты. Кызның тәне дерелди, башы аска каерылган, бергә укмашып салынып төшкән чәч учмасыннан җиргә тамчы тама иде.

Рәфис, куллары талгач, уң аягын калкурак боз түмгәгенә терәп һәм буыннары туңып каткан тезен көч-хәл белән бөгә төшеп, кызны кулларыннан ычкындырмыйча гына бераз утыртып торды. Ул аның хәлсезләгән һәм тотрыгын югалткан муенына, үзенең күкрәгендә гамьсез яткан гәүдәсенә текәлеп торды, аңа берничек тә ярдәм итә алмавына көрсенеп куйды, тирә-юненә күз йөртеп нәрсәдер эзләгәндәй итте, тик өметләнерлек берни дә тапмады, яңадан кызны ике кулы белән күкрәк турысына сыендырып, абына-сөртенә алга кузгалды.

«Тизрәк авылга җитәргә!» Бу теләк шул чаклы тыелгысыз һәм омтылышлы иде, ул ботинкаларына сеңгән суның атлаган саен чыңгылдавын да сизмәде.

Шифаханәнең авыруларны кабул итү бүлмәсендәге ак җәймә җәелгән ятагына салгач, Рәфис бер мәлне Гөлфинурның тагын да аксылланып киткән йөзенә, ярым-ачык күзләренә карап торды. Бугазыннан кайнар дулкын бәреп чыкты. «Гөлфинур! Кайдан килеп чыктың соң син? Ничек болай булды?...» Бу өндә чарасыз наз да, кызгану да бар иде.

Ыгы-зыгы килеп йөргән шәфкать туташлары, туңудан дер-дер калтыранган кызның юеш күлмәкләрен алыштырырга дип коры киемнәр күтәреп кергәч, ул онытылып торуына уңайсызланып, үз-үзен битәрлибитәрли ишеккә юнәлде.

## 4

Икенче көнне аны Гөлфинур янына кертмәделәр. Ул өченче көнне дә кызның палатасына эләгә алмады.

— Ярамый! — диде дәвалаучы врач кискен итеп.

Рәфис тәшвишкә төште. «Хәле тагы да авырайды микәнни? Әллә мине күрергә теләмиме Гөлфинур? Янына кертмәскә үзе кушканмы?» Соңгы көннәрдә борчулы уйлар белән яшәде Рәфис. Йокысы качты. Черемләп киткәндә дә шул кызый төшенә кереп йөдәтә иде. Үпкәрәнҗеш тулы күзләрен Рәфискә текәр иде дә, бер сүз дәшми тик басып торыр иде. Ә күз карашы нәкъ яшь чактагы кебек.

... «Бүген дә палатасына кертмәсләр микән?» Кием элгечтә эшләүче ак халат кигән тулы гәүдәле хатын, Гөлфинурның исемен ишеткәч, берниндн сүз катмыйча Рәфискә ак халат алып бирде. Рәфис халатны җилкәсенә элеп таш баскыч буйлап өскә күтәрелгәндә, алда көткән билгесезлектән йөрәгенең дулкынланып тибүен тойды. Ул килеп кергәндә Гөлфинур күзләрен түшәмгә текәп тыныч кына ята иде. Ишек ачылган тавышны ишеткәч, ул күзләрен шул якка текәде, ләкин бу караштан сөенеч тә, гаҗәпләнү дә укып булмады.

— Мине танымыйсың мәллә, Гөлфинур?

— Таныйм, Рәфис.

Әйтерсең, алар гади танышлар гына булганнар, гүя соңгы очрашу белән хәзергесе арасында дистә гомер ятмый.

— Нихәлләрең бар соң, Гөлфинур?

— Ярыйсы.

— Бәлки, син миңа ачулана торгансыңдыр?

— Нигә ачуланыйм... Рәхмәт, бозлы судан алып чыккансың.

Бу сүзләр шулчаклы салкын, битараф төстә әйтелде ки, Рәфис моңа каршы ни дип җавап бирергә дә белмәде. Ул Гөлфинурның һаман түшәмгә текәлгән сүрән карашына, кәгазь битедәй ап-ак йөзенә, мендәргә таралып төшкән саргылт чәчләренә әледән-әле күз төшергәләп тын гына утырды. Үзен ялгыш килеп эләккән чит бер кеше итеп сизде, әрсезләнеп йөрүенә үз-үзенә ачуы чыкты.

— Ярый, мин китим инде алайса, — диде ул ярым пышылдап, — тизрәк терел.

— Рәхмәт.

Рәфис арты изелеп беткән киез башмакларын кыштырдатып ишектән чыгып киткәндә, Гөлфинур бер мизгелгә генә аның ак халат ябынган киң җилкәсенә сүрән карашын сирпеп алды. Палата ишеге ябылып, бушап калган коридорда аяк тавышлары тынгач, ул яңадан акшарланган түшәмгә текәлде һәм бик бирелеп нәрсәдер карый башлады. Әйтерсең, түшәмнең кытыршы өслегендә аның өчен бик әһәмиятле нидер бар, шуны төшенмәсә, тезәлмәслек югалту булыр шикелле. Әйе, түшәмгә төбәлеп күңелендә язылганнарны укыды ул, бөтен җанын тутырган, бәгырен җәрәхәтләгән язманы укыды.

Кызның күз алдында тагы шул ук йөз — айлар буе күңеленнән бер сәгатькә дә китеп тормаган, бөтен тынычлыгын алып газапка салган чырай пәйда булды. Гүя ул түшәмнән аңа карый, җентекләп һәм сынап, моңнар тулы күзенә бага. Аннары әүвәлгечә ак тешләрен ялтыратып киң итеп елмая. Бу вакытта аның каракучкыл йөзе нурга күмелә, кара күмердәй күзләреннән очкыннар чәчелә.

— Камил...— дип, түшәмдәге сурәткә еламсырап пышылдады Гөлфинур.— Камил, ни өчен миңа шулчаклы мәрхәмәтсез булдың син?...

Әнә ул шунда — Гөлфинур яшәгән тулай торакның тумбочкасы өстендә ята Войничның «Кигәвен» романы. Аның тышлыгына язылган сүзләр дә чекерәеп тора. «Язмышыңның корбаны буласым килми». Боздай салкын, кара язмыштай мәрхәмәтсез сүзләр. «Бу синең үз кулың белән язылган сүзләр, Камил! Тик белмим, ничек яздың икән син бу сүзләрне? Язганда кулың калтырамады микән? Ләкин... ләкин кем аркасында туды соң ул син әйткән язмыш? Кем гаепле? Шул көнне минем өчен бөтен дөньяның нурлары сүнгән кебек булды бит, син шуны беләсеңме, Камил? Юктыр. Югыйсә, икенче көнне үк атылып яныма килгән булыр идең. Ә мин сине барыбер көттем. Өзелеп-өзелеп көттем. Үзем эшли торган рәссамнар остаханәсе тәрәзәсеннән көннәр буе күземне алмый идем. Килмәдең шул, килмәдең. Сиңа да үзеңне җиңү җиңел булмагандыр. Кайнар йөрәк хисен салкын акылның җиңүе бик авыр нәрсәдер ул, Камил. Эчә башлавың да шуннандыр синең. Бу хакта ишеткәч, мин түзмәдем, өеңә бардым. Син аек идең. Мине күргәч, таштай катып калдың. Авызыңны ачып бер сүз дә әйтә алмадың.

Мин бөтен рухымны җыеп:

— Мин сине аңладым. Рәнҗемим. Тик зинһар эчмә! — дидем дә сиңа күтәрелеп карарга да куркып, йөгереп чыгып киттем. Аннары... аннары сине очратып йөрәгемне бозмас өчен үз авылыма кайтып киттем. Ләкин күңелдәгеп чәчеп калдырып булмый икән ул, Камил. Кайда барсаң да ул синең белән ияреп бара икән. Аңгы-миңге булмасам, трактор чанасыннан да егылмас идем мин. Башыма ябырылып килгән шәфкатьсез уйлардан үземне талатып атналар буе монда да ятмас идем».

Янына Рәфис керер алдыннан гына ул елап алган иде. Йомшаклыгын, көчсезлеген яшьле күзләреннән Рәфис күреп алмасын тагы дип курыкты ул, шуңа күрә, аның ягына карамаска тырышты, ул палатадан чыгып киткәч, Гөлфинур бары аның турында уйларга, икесе арасындагы якты истәлекләрне тергезергә теләсә дә, алар күз алдына килмәде. Һаман шул соңгысы — бәгырьне телгәләп бетергәне әрсезләнде, тәмам тигәнәккә әйләнде.

## 5

Колак төбендә җил улый, бер сулкылдап узып китә, бер сузып-сузып ниндидер ямансу көй сызгыра. Каршыдан биткә бәргәне томанлы сурәт алып килә дә эреп юкка чыга. Үткәне, югалганы урынына башкасы килә. Ачыграгы, җетесе — Гөлфинур сурәте. Йөрәкне авырттыра, уйларны тузгыта торган тынгысыз сурәт. Инде күптән күңелдә бер көе, тыныч кына йөргән таныш йөз ничек шулай җанын актарып ташлады әле? Юк, үзен алдый гына Рәфис. Ул бит үзе аңа кузгалырга ирек бирмәде. Йөрәген уңайсызлап талпынып куйганда да, аны көчләп куып җибәрде. Ни өчен бу гүзәл заттан кача иде соң ул? Нигә дип еллар буе үзенә тартып торган зәңгәр күзләр каршына ашкынып-шашынып томырылмады? Әйе, укыды, вакыты тыгыз булды. Вакыты табылыр иде әле. Ләкин бу очрашуны кичектерә килде. Утка килеп керермен дә, укуым уку булмас, барсы дөрләп янар, юкка чыгар, дип курыкты. Тик бу четерекле мизгел каршысына үзе килде. Көтмәгәндәгә сынау, бәхетсез очрак булып.

Бу сынауны үтә алдымы соң ул?

Башын югалтып бозлы суга сикерүе — сынауны кичүе түгелмени. Ләкин ни өчен Гөлфинур салкын аңарга карата? Әллә бу Рәфискә генә шулай тоеламы? Хәле авыр булганга ачылып-чәчелеп китә алмыймы?

Кабул итү бүлмәсендә аны таныйлар иде. Тулы гына гәүдәле хатын бер сүз дә дәшмичә аңа ак халат, чүәкләр бирде. Рәфис үзенә таррак булган халатны җилкәсенә ябынып, аягына янчелеп беткән чүәкләрне әлләтереп баскычтан икенче катка менә башлады. Бер басма, ике, өч... «Тагы шулай салкын каршылармы икән Гөлфинур? Тәки әрсезләнеп йөри, дип уйлармы?» Ул туктапып калды. Ак халатлы ике шәфкать туташы аңа бәрелә язып түбән төшеп китте. «Нишләп йөрисең, бүтән килеп йөрмә!» — дисә? Томан эчендә кабат хасыйл булган зәңгәр күзләр каядыр читкә, ул аңламаган, исенә китермәгән тарафка бага иде. Рәфис тотрыксыз хәрәкәт белән ак халатын иңнәреннән сыдырып төшерде, баскыч култыксасына тотына-тотына түбәнгә шуышты.

Җил туктаган, төнге урам тын һәм караңгы. Багана башларында зәгыйфь янган электр лампалары һәм тәрәзәләрдән ара-тирә сибелгән зәңгәрсу утлар куе караңгылыкны җиңә алмаганга, сыек энгергә күмелеп утырган авылның аргы ягы аеруча караеп күренә.

Кайдадыр якында гына тонык моң булып, челтерәп су акканы ишетелә иде. Ерганаклар шулай челтерәп агамы соң? Ул салмак адымнар белән челтерәү ишетелгән якка таба атлады. Юк, бу ерганак тавышы түгел, югарыдан агып төшкән су шаулавы. Якынайганнан-якыная барган хикмәтле шарлавыкны эзләп, ул инде авыл башына ук килеп чыкты. Карт өянкеләр белән уратып алынган аулак төбәккә озын гына агач улак куелган. Су шул улактан шарылдап агып төшә икән.

Җәй көне бу тирәдә чишмә саркып ятканын белә иде Рәфис. Әмма улакны беренче мәртәбә күрүе. Моңга төренеп чыңлаган чишмә тавышын ул тын да алмый тыңлады. Бу чың соңгы көннәрдә бер-бер артлы килеп чыгып торган күңелсезлекләрдән, борчулардан арган җанын ял иттергәндәй булды. Гүя, каяндыр офыклар артыннан ефәктәй йомшак җил тирбәлә-тирбәлә исә дә, күзгә күренмәс нечкә кылга чиртеп-чиртеп ала. Чирткән саен моңсу чакырулы аһәң дулкын-дулкын булып яз исе аңкыган дөньяга тарала. Төнге урамның куе караңгылыкка төренгән аргы башыннан тонык һәм сагышлы җыр ишетелә:

> Сагындырды сызылып таңнар атуы,
> Әнкәемнең иркәләп уятуы...

Егет кеше күкрәгеннән ташып чыккан бу моң гадәти түгел, нечкәтер кыргыйрак булып үксеп чыга иде.

> Кайтам инде туып үскән ягыма,
> Кырпарыма, тугайпарыма.

Бу аһәң сагышка салып кына калмый, дөньяның һәртөрле ваклыкларыннан арындыра, күңелне сафландыра. Әмма төнге авазларны тыңлап күпме өнсезләнеп йөрергә була. Алда — тормыш мәшәкате, ыгы-зыгылы борчулар. Аларны кичекмичә чишәргә, бер дә булмаса, чишелеш юлын табарга кирәк.

Бетмәс-төкәнмәс уйларына уралып йөри-йөри, ул терлек каралтылары янына килеп чыгуын сизми дә калды.

Чү, каралтылар янына түшәлгән тиреслектә кем казына соң? Энгерменгергә күмелгән тонык офык яктылыгында бу кеше, куркыныч әкияттән калкып чыккан сәер җанвар төсле, караеп тыпырчына иде.

Рәфис шикләнеп, як-ягына карана-карана сак адымнар белән шул җан иясенә якынлашты.

— Галим абзый?! Төнгә каршы нишлисең монда?

— Күрмисеңмени?

Әйе, Рәфис ап-ачык күрде. Тынчу исле пар күтәрелгән тау чаклы тирес өеме янында чанага җигелгән юан бәдәнле ат йоклаган сыман башын иеп тора. Галим абзый сәнәген тирес өеменә батырган да басылып тыгызланган катламны аерып куптарырга азаплана. Ул кечкенә гәүдәсе белән чүгәләп үк беткән. Бер кулы сәнәкнең төбендә, икенчесе сапның уртасында. Үзе артка каерылып көчәнә, ыңгыраша. Нәрсәдер шыгырдый, нидер шыртлый.

— Син нәрсә, Галим абзый,— диде Рәфис,— төнлә казынмасаң, көн беткәнме?

— Хуҗа кушты. Бу тиресне иртәгә күзем күрмәсен, диде.

— Бар кайт, Галим абзый,— диде Рәфис тыныч кына,— юкка чиләнмә.

Галим абзый турайды, кулы белән чебен кугандай итеп чәбәләнде.

—Юк, юк, сез нәрсә?! Хуҗадан арт сабагымны укыттырасым килми.

Һаман куера барган төн караңгылыгында тагы да кечерәеп, мескенләнеп калган Галим абзый Рәфискә язмыш аръягына чыгарып ташланган кызганыч җәнлектәй күренде.

—Бар, бар, Галим абзый, кайт, җавабын үзем бирермен,— диде ул аңа рәхимле итеп.

Галим абзый кечкенә, ләкин имән төбедәй нык гәүдәсен туры тотып, вак-вак адымнар белән куе караңгылыкка кереп югалгач та, өнсезләнеп, оеп утырган каралтылар янында Рәфис кая барырга белмәгәндәй кагаеп торды. Абзар тәрәзәләре аша тонык кына булып сыерларның салмак күшәве, ара-тирә пошкырып-йөткеренеп куюлары колакка килеп керде.

## 6

Иртәнге салкынча һава аяк астындагы суларны җыя төшкән: кечкенә күлдәвекләр өстенә юка пыяла сыман булып үтә күренмәле боз өлгеләре каткан, кичәге юеш кар измәләре каты ярма бөртекләренә әверелгән — баскан саен шатыр-шытыр килә. Аксыл томан кабарынкы мамык өемнәредәй өер-өер булып җиргә сарылганга, каршыңа килгән кешеләрнең билдән түбән өлеше бөтенләй күренми.

Рәфис үзеннән бер телеграф баганасы арасы гына ераклыкта күләгә төсле чайкалган тәбәнәк гәүдәгә карап елмаеп куйды.

«Кем булыр бу?»

Сөртенеп егыла язды, ахры, бер мәлне гәүдә аксыл куелыкка чумып алды.

«Томанда чумып ала, юкса кем икәнен таныр идем».

Аның башына уйлар чәбәләнеп килде: «Томанда югалмасын иде шул алар. Эчке дөньялары, кичерешләре ап-ачык булсын иде». Ул үзе белән иңгә-иң торып эшләүчеләр хакында уйлады.

Аның хәзер үк кемнедер, үзен аңлый торган кешене эзләп табасы, күкрәгенә бөялгән төерне чишеп җибәрәсе килде. Ләкин кайда соң андый кеше? Җанында тулышкан уй-борчуларны сыйдырыр кеше кайда?

Көрәнсу халатларын җилфердәтеп абзардан берәм-берәм чыгучы савымчылар, Рәфиснең хәлен аңлагандай, уйларыннан сискәндерергә теләмәгәндәй, аның ягына башларын да бормыйча төрлесе төрле тарафка шым гына таралыштылар.

Бану гына адымнарын акрынайтты, аннары бөтенләй туктап калды. Ул соңгы көннәрдә җанын кая куярга белмичә бәргәләнеп-сукаланып йөрде. Аның белән кешечә сөйләшергә теләгән Рәфискә каты бәрелгәне, аннан килеп, бозау белән булган вакыйга тора-бара үз-үзен күралмауга әйләнеп, өенә кайткач та ярым өнсез хәлдә каударланып йөрде.

Рәфис башта Бануны абайламады. «Ул да минем шикелле дөньясыннан үткән мәллә?» — дип уйлады Бану.

— Нинди хәсрәткә чумган баш зоотехник?

Каршына ук килеп баскан Бануны күргәч тә Рәфис, буталчык төштән арынып бетмәгән кеше төсле, күзләрен челт-челт йомгалап торды. Аннары, үзен оеткан дөньядан көч куеп аерылырга теләгәндәй, алга таба омтылышлы хәрәкәт ясады.

— Уйланырлык нәрсәләр җитәрлек,— диде ул авыр сулап.

Бану нәрсәдер төшенергә теләгән чәнечкеле карашын Рәфискә кадап торды да, болай әрсезләнүнең мәгънәсезлеген төшенгән күк, башын иеп кайту ягына йөгерде.

— Тукта әле, Бану!

Рәфис ике якка җәелгән кулларын киң итеп селти-селти үзеннән ераклаша баручы хатын артыннан ашыкты.

— Ни өчен минем белән сөйләшүдән качасың син? Син генә түгел, сез барыгыз да...

— Бу юлы качмаска уйлаган идем. Сез үзегез бит...

— Ничек мин үзем? Мин күптәннән сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшергә омтылам. Бәлки, берәр ярдәмем, яхшылыгым тияр иде.

Эчке киеренкелек вакытлыча кимегән, йомшарган гына иде, ахры. Бануның куе кашлары дугаланып килде, коңгырт күзләреннән чәнечкеле очкыннар чәчрәде.

— Яхшылык? Нинди яхшылык турында сөйлисез сез? Без сезнең кебек җитәкче кешеләр белән алай кәнфитләнергә гадәтләнмәгән. Хәер, сезнең сүзегез бер булыр инде: сөт, сөт, сөт! Тагы ни көтәсең сездән. Шәмсүн әнә сезнең шикелле хәйләләп-шомартып маташмый, ачык итеп ярып сала. Өстәвенә, сүгенергә дә күп сорамый. Ә нәрсә, алай аңлашылырак төшә ич.

— Син хаклы түгел.

— Хаклымы, түгелме — нәрсә бар, шуны әйтәм... Әй, нәрсә сөйләнеп торырга, әллә үзегез белмисезме. Башта гына сез... Аннары, бүтәннәр кебек шул бер көйне көйлисез.

— Кызыл почмак һаман шундый хәлдәме?

— Кем кагылсын аңа? Кемгә кирәк ул? Ә менә тикшерү киләсе булса, ялт иткән булыр, кайгырмагыз! Ансын алдан хәбәр итәләр, өлгерергә була. Самаварын китереп куярга да, коймак пешерергә дә, музыкасын көйләп җибәрергә дә... Безгә өр-яңа халатлар биреп курчактай киендерергә дә өлгереп була, сез кайгырмагыз!

Рәфис шуңа игътибар итте: тулы гәүдәле булса да, эштә боҗыр кебек җитез бу хатын телгә дә шактый үткен, һәр сүзгә беренче булып катнаша, сүзен туры әйтә, кемнеңдер хәтерен калдырырмын дип тә, җитәкчеләр алдында дәрәҗәм төшәр дип тә шикләнми. Хәер, Рәфис тәҗрибәсе буенча тагы шунысын белә: эшендә ут уйнаткан кеше туры сүзле була, ул-бу чыга калмагае дип куркып тормый. Баскан җире тайгаграк булганнар гына як-ягына карап эш итүчән.

— Беләсеңме, нәрсә,— диде Рәфис тәвәккәл бер карарга килеп.— Әйдә, бүген үк кызыл почмакны үзебез менә диган итеп җиһазлыйбыз.

— Терлекчеләр йортынмы? Нәрсә белән?

— Табарбыз. Үз өстемә алам.

Бану ышанмыйча Рәфискә карап торды да, мәсхәрәле елмаеп кулын селтәде.

— Юк, син кул селтәмә,— диде Рәфис инанган тавыш белән.— Барысы да китеп өлгергәнче хатыннарга дәш, ирләрне дә чакырырга онытма!

Бану ышанмыйча карап торды да, капыл кубарылып хатыннар артыннан йөгерде.

Хәтәр эш кузгатмакчы иде Рәфис. Ул бу хакта элегрәк Шәмсүнгә дә әйтеп бакты. Ләкин хуҗа кеше мәсхәрәле төстә күзен кысып, бармагы белән чигә турысын гына бораулап күрсәтте.

...Кыйсылары ялтыравыклы көрән өстәл, кайсылары килешле бизәкләр төшерелгән шкаф, бүтәннәре банкет залларында гына була торган, арткы терәве заманча эре фигуралы итеп эшләнгән утыргычлар күтәргән хатыннар, кояш нурлары мәлҗерәткән киң урамга сибелеп, терлекчеләр йортына таба атлыйлар. Совхоз җитәкчеләре һәм районнан килгән дәрәҗәле кешеләр кереп сыйлана торган бүлмәдән алып чыккан бу җиһазларны авыл халкының күбесе әле беренче мәртәбә күрә. Ә ул хәзинәләрне күтәргәннәре, барган җирләреннән тукталып, күз явын алырдай елтыравыклы өстәл-шкафларны урамның кары агарып торган чистарак төшенә сак кына куялар да, шома өслеген бармаклары белән сыйпап-сыйпап карыйлар. Һәм тагын бу кыйммәтле нәрсәләрне җилкәләренә атландырып, яисә, кулларына күтәреп, боламыктай кар суын ера бирәләр. Пышылдашып кына сөйләшкән бу хатыннарның йөзләрендә сагаюлы серлелек, гүя алар гадәти генә бер эш башкармыйлар, ә моңарчы яшәп килгән һәм инде җимерелмәс кагыйдәгә әверелгән кануннарны аяусыз төстә пыран-заран китерәләр. Вакыт-вакыт күзләрендә җиңүчән сөенеч балкып куя, җирнең хуҗалары итеп тою хисе эчкә яшеренгән урыныннан кыюсыз гына баш калкыта. Тирә-юньгә картлар, бала-чагалар җыйналган. Алар өчен бу — үзенә күрә бер тамаша, моңарчы бер төрле агылган тормышның яңарып алуы. Аннары терлекчеләр йортында эш кызды!

Киеренкелектән еш-еш сулаган, ахылдаган, йөткеренеп куйган тавышлар ишетелде. Куллар, билләр талса да, маңгай, аркаларга салкын тир бәреп чыкса да, мускулларның рәхәт тулышуы, тән буйлап йөгергән кайнар кан, үпкәләргә ябырылган җылы тирес исе физик хезмәтнең савыктыргыч ләззәтен тойган кеше өчен үз һәм күнегелгән иде. Янәшәдә генә бил турайтмый тирләп-пешеп эшләгән кешеләр Рәфискә якынрак, аңлаешлырак булып китте. Аның бу кешеләр белән шаярып сөйләшәсе, үзендә туган күңел күтәренкелеге аша хисләрен уртаклашасы килде. Ә өмәдәшләре, төймәләрен ычкындырган куртка чабуларын җилфердәтеп, ишек алдын җыештыруларын беләләр.

— Сезнең бала тудыру йортында булганыгыз бармы? — дип сорады Рәфис җыелган халыктан. Җавап бирүче булмагач, көлемсери төшеп дәвам итте: — Менә шул йортта туган балалар бөтенесе бер бүлмәдә рәт-рәт булып тезелешеп яталар. Барысы бер-берсенә охшаш, һич аерып алырлык түгел. Кешеләр дөньяга яралганда бар да бер төсле. Ә аннары аерыла башлыйлар: монысы ак йөзле, йә сипкелле, тегесе усал, бусы юаш. Мәктәптә укыганда — берсе сәләтле, гел «бишле»гә укый, икенче берәве авыр үзләштерә. Ә укып чыккач — агроном, зоотехник, инженер, терлекче, игенче һәм башкалар булып китәләр. Агроном иген үстерәм дип кырлар буйлап чаба, зоотехнигы терлек абзарларында кагая. Һәркайсы үз эшен иң зарур дип саный...

Рәфиснең бу әңгәмәсен тыңлап торучылар, ул сөйләгән сүзләрне йотып барудан битәр, йомгакның очын ничегрәк төйнәр икән дип көтәләр иде.

— Күрәсез, кешеләр үсеп җиткәндә белеме белән дә, холыклары ягыннан да, эшләгән эшләре буенча да гаять төрләнәләр. Бу хәл кешеләрне беркадәр бер-берсеннән читләштерә, хәтта каршылыкка китерә. Ә кешеләр үзара тату яшәргә, дус булырга тиешләр. Моның өчен нишләргә кирәк?

Рәфис, җавап көткәндәй, жыелып торучыларның әле берсенә, әле икенчесенә карады. Чынлыкта, ул бернинди җавап көтмәде, чөнки ул җавап аның үзендә иде. Ул бары шул рәвешле кешеләрнең игътибарын үзенә юнәлтте генә.

— Йә, ни эшләргә кирәк? — дип кабатлады ул һәм дәвам итте: — Бер-берсеннән үзгә эштә эшләүче кешеләрне вакыт-вакыт җыеп бер төрле, бер характердагы эшкә кушарга кирәк!

Бар да җанланып киттеләр, үзара көлешә-сөйләшә башладылар.

— Менә әйтәсе сүзен әйтеп бирде ичмасам!
— Сорау биреп мәшәкатьләнәсе итмәде.
— Һай, Рәфис!
— Шулай, шулай,— дип кычкырды Рәфис тавышны басып,— бары бер төрле хезмәт кенә кешеләрне тигезләштерә, бер төрле итә. Хуҗа кеше дә кирәк тоткан, аңа буйсынган кеше дә шул ук кирәкне тоткан!
Рәфис бер мәлгә авыл ягына күтәрелеп карады һәм чырае бозылып китте.
Авыл ягыннан, кунакка баргандай киенеп-ясанып, Гөлфинур килә иде. Кызның өстендә алсу төстәге җиңел бишмәт, башында норка бүрек. Рәфиснең иреннәре канәгатьсез кыймылдады: «Ныклап хәл кермәс борын ник килә инде. Җитмәсә, ничек киенгән. Тапкан көязләнер вакыт».
Гөлфинур, биек үкчәләре белән берни булмагандай кәс-кәс басып килде дә, тәккәбер генә кулларын биленә таянып тукталып калды.
— Миңа ни эшләргә кушасыз? — Аның җете кызыл итеп буялган иреннәренә елмаю кунды.
Галим абзый ике кулын киң итеп җәеп, киндер куртка чабуларына шап итеп сугып куйды.
— Һай алла, биергә дә, җырларга да кушмыйбыз, аның өчен фасоның килгән булса да.
Гел башын иеп көндәм генә йөргән кешедән мондый сүз чыгуы барсының да күңеленә хуш килде. Ирләр читкә карап тыелып кына көлештеләр дә, астыртын рәвештә Рәфис ягына күз ташлап алдылар.
Гөлфинурның авырып ятуы хакында күбесе белми иде. Шуңа күрә, ирләрнең хахылдавы Рәфиснең йөрәгенә тиде, ул Гөлфинурны кызганып куйды.
— Син кайт булмаса,— диде ул кызга сабыр гына.
Гөлфинур күтәренке тавыш белән шар ярды:
— Бәй, нигә кайтыйм, эшләргә дип килдем ич мин.
Галим абзый әллә нишләгән иде бүген. Алыштырып куйганнармыни! Ул тагын бу нәзберек кыз белән төчеләнеп тормады.
— Әйдә, мин сиңа эш табып бирәм,— дип Гөлфинурны ияртеп абзар эченә кереп китте.
Биш минут үтмәгәндер, ачудан кызарынган-бүртенгән Гөлфинур эчтән атылып чыкты.
— Син мине мыскыл итмәкче, Кәрлә тәре, шәһәр кызына әйләнгән, имеш... — Еш-еш сулаудан аның юка борын яфраклары дерелди, кабарынкы иреннәре үпкәләгән баланыкы төсле бүлтәйгән иде.
Гөлфинур артыннан канатларын җәеп кызулаган Галим абзый да килеп чыкты. Гаҗизләнүдән йөзе бозылган, ул мөлаем кызның әле алдына, әле артына чыгып, акланган тавыш белән тотлыга-тотлыга (баягы кыюлыгы кая киткән!) сөйләнә бирде:
— Н-ниткән м-мыскыл итү ди ул, синең с-сыер сава белмәвеңне мин кайдан белим... Х-хатын-кыз булгач...
Гөлфинур Галим абзыйның каршына ук очынып килде.
— Син ни өчен минем белән авыз чайкыйсың, ә? Кем булдың ул хәтле?
— Гөлфинур, кызма әле...
— Кызармын әле мин сине! Кәрлә!
Ул кинәт борылды да бозлы җиргә шак-шок басып китеп тә барды.
Кешеләрдәге ашкынулы дәрт шул мизгелдә үк сүнде, сүрелде... Җыелып торучыларның берәүләре сәнәкләренә таянып тынып калды, икенчеләре кесәләренә шап-шоп сугып тәмәке эзләгәндәй итте. Эчпошыргыч тынлыкны куертып баш очына келсу сөрем эленде. Кешеләрне дәү һәм соргылт канаты белән изеп торган тынчу авырлыкны ишәргә, юкка чыгарырга кирәк иде. Тик моны эшләү җиңел түгел, нидер күкрәкне кыса, яңак сеңерләрен тарттырып тора.

Рәфис, әлеге киеренкелекне берьюлы селтәп ыргытырга теләгәндәй, кулындагы сәнәген югары күтәреп көч белән кар өеменә кадады.

— Тәк, иптәшләр,— диде ул тавышына көр яңгыраш бирергә омтылып,— барыгызга да рәхмәт, тырыштыгыз, ә тырышлык җилгә очмас...— Ул сүзен дәвам итәргә теләде, ләкин әйтәсе сүзе тиз генә тернәкләнеп китә алмады.

Ирләр күңелсез хәлне саран кырыслык белән эчләренә йоттылар да, тәмәке пыскыта-пыскыта, кояш нурыннан мәлҗерәп тирес исе аңкыта башлаган көрәнсу сукмак буйлап китеп бардылар. Рәфис аларның канатлары каерылган кошлар кебек тезелешеп китеп баруларын кар яктысыннан чагылган күзләрен кысып беравык карап торды да көрсенеп куйды.

Үз-үзеннән канәгатьсезлек хисе бөтен барлыгын биләп, аның сынын катырды. Ачылып китеп сөйләшер өчен җайлы вакыт иде бит. Шундый якынлыкны үзе эзләп тапкан иде. Күңелләр ачылган, ул теләгән дулкынга корылган кебек иде. Шуны тотып ала алмады бит ул, алмады... Кем гаепле? Әлбәттә, беренче чиратта үзе. Һәм тагын — Гөлфинур. Менә син нинди икән әле Гөлфинур... Көчсез һәм һаваланучан.

...Шәмсүн районнан кайтып төшүгә, хуҗа тирәсендә әйләнергә яратучылар кыйммәтле җиһазларның терлекчеләр йортына урнаштырылуы хакында төкми-чәчми аңа җиткерделәр, билгеле. Тагын беравыктан артык ярсудан кызарынган-бүртенгән Шәмсүн терлекчеләр йортының ишеген каерып ачты.

— С-син,— дип кычкырды ул Рәфискә шашынып,— үзеңнең ни кыланганыңа аз булса да хисап бирәсеңме, юкмы?!

— Буласы булган инде,— диде Рәфис сабырлыгын җуймаска тырышып.— Хәзер кире кайтарып булмый.

Рәфиснең мондый тынычлыгы Шәмсүнне бөтенләй чыгырыннан чыгарды.

— Була! Ничек кенә була әле! Әллә син мине һәрбер башбаштаклыгыңа юл куяр дип уйладыңмы?

— Булдырасың икән, моны үзең эшлә!

— Һе, нинди ансат,— Шәмсүн чыраен сытып тешләрен шыкырдатты.— Син кашыклап борыч сибеп ботка пешереп куй, миңа шуны ашаргамы? Юк инде, ыслушай, ул ботканы үзеңә йотарга туры килер!

— Турысын әйткәндә, син тәкъдим иткән сыеңа ябырылырга җыенмыйм. Һәм сиңа да бер чорналган йомгакны кирегә сүтәргә ирек куймам!

— Ничек?!

— Үзең уйлап кара, халык алдында кем булып чыгабыз без аннары? Камыр, чүпрәк!

Соңгы сүз Шәмсүнгә айныткыч тәэсир итте. Аның шартларга җиткән ачулы йөзе шиңә төшеп, күз карасында рәнҗеш катыш ризасызлык пәйда булды.

— Син мине нинди хәлдә калдырдың, ә? Җитәкчеләр алдында, бигрәк тә Самат Рәшитович алдында... Яхшы! Шулай да булсын. Тик белеп тор, ыслушай, мин моны синең исеңә төшерермен әле!

— Син кирәкмәгәнгә чәпчемә! Иң яхшысы менә нәрсә хакында баш ватыйк: тиздән сөт кими башлаячак,— диде Рәфис астан сөзеп карап.

Шәмсүннең кашлары маңгаена сикерде.

— Ничек кими башлаячак?

— Шулай. Чөнки сыерларның бозаулау графигы ел әйләнәсенә тигез бүленмәгән. Күбесенең сөт ташлау чоры май-июнь айларына туры килә. Әле анысы да бик үк ачык түгел. Кыскасы, төгәл планлаштырылган график юк.

— Кем төзергә тиеш соң ул графикны?

— Без төзергә тиеш. Ләкин ул графикның нәтиҗәләре тагын тугызун айдан гына сизелә башлаячак.

— Шуңарчы кул кушырып утырыргамы исәбең? Бездән район сөт сорый, аңлыйсыңмы шуны?

— Аңлыйм. Һәм кул кушырып утырырга да исәп юк. Рационнарны үзгәртү, сыерларны карауның режимын камилләштерү юлы белән без хәлдән килгәннең барысын да эшләрбез. Ләкин аның белән генә сөт кимүдән барыбер тулысынча котыла алмыйбыз.

— Юу-у-ук! Бу сүз түгел, сөт артырга тиеш! Бездән моны район җитәкчеләре, ахыр чиктә партия таләп итә! Фәкать шулай!

Ул шулай диде дә, ерак юл йөреп арган кеше төсле, ишек яңагына тотына-тотына чыгып китте.

## 7

Идарәнең икенче катына менә торган, уентыкланып беткән таш баскыч кырыйларына кайсы арзанлы материя белән тышланган кыска тун, кайберсе җылы сырма кигән, битләре ачык һавада эшләүдән янып коңгырт төскә кергән ир-атлар сырышкан. Төрле йомыш белән килүче бу ирләрнең берәүләре тезләрен кочаклап утырган хәлдә, аркаларын буявы купшып беткән таш стенага терәп, икенчеләре кырын яткан килеш терсәкләре белән баскыч култыксасына таянып, өске ишек почмагына чүмәшеп утырган Мәхмүтнең «башыннан кичкән» мажараларын тыңлый.

Ияге очлы булганга, яңагы озынча булып күренгән Мәхмүт кыска тунының каптырмаларын ычкындырып җибәргән, эт тиресеннән тегелгән йонлач бүреген учына йомарлаган да, пәке белән ялтыратып кырылган башын ара-тирә ышкыштыргалап һәм бераз кабалана төшеп яңгыравыклы тавышы белән сөйләвен белә. Сөйләгәндә ярыйсы ук сакаулый. Гадәттә, сакау кеше «Р» хәрефен әйтә алмый, Мәхмүт исә киресенчә: үзе әйтә алмаган «Л» хәрефе урынына «Р»ны әйтеп җибәрә.

— Йөри торгач бер көн шурай таурарга кереп чыкканмын. Биек-биек таурар. Очына карасаң, бүрегең төшеп китәррек. Йөрим таурарда. Өстә шушы кыска тун, җиркәдә — нике көпшәре мыртык. Тау битендәге тар сукмактан барам. Сукмакның бер ягында киртрәч кыя менеп киткән, икенче ягында — тирән упкын. Упкынга карарга ярамый, карасаң беттең — башың әйләнеп төпсез упкынга очасың. Шуңа минем күз кыя киртрәчрәрендә. Тау кәҗәсе күренмәсме дим. Күзрәрәм тарганчы карыйм. Юк, күренми генә бит. Инде кояш та баюга таба бара. Ә тау кәҗәсе — юк! Бервакыт,— Мәхмүт аягына басты, нидер күргән кебек бүлтәеп торган коңгырт күзләрен тәрәзә ягына төбәде,— зур таш артында нидер серкенә. Мин сураудан да туктадым. Әйе! Тау кәҗәсе! Кара төстә, мөгезе чорнарып-чорнарып киргән. Акрын гына җиргә тезрәндем. Куррарым берән дәү-дәү ташрарга ябышып үрмәри башрадым. Ташбака кебек акрын гына үрмәрим.— Мәхмүт баскычка ятып үрмәләгән хәрәкәт ясады, тыңлаучылар да шул якка сөрлекте.— Артык серкенмәдем дә төсре, берзаман минем тау кәҗәм арт аякрары берән тауның таш киртрәченә тек итеп типте дә, бер якка тайпырды. Ни булды икән дип як-ягыма карасам, ни күзрәрем берән күрим, тау кәҗәсен бозау шае юрбарыс эзәррекрәп киргән икән...

Тыңлап торучы малай: «Әнекәем!» — дип кычкырып җибәрде, ак сакаллы карт: «Шартлата Мәхмүт»,— дип куйды.

— Биррәһи, шартратмыйм! Ипидер менә!

— Әйдә, сөйлә, сөйлә! Дәүәтинең зиһене таралган инде.

Иске йонлач бүрегенең югарыга кайтарылган колакчыны түбән салынып төшкән абзый хәйләкәр көлемсерәп күзен кысып куйды.

— Нишрәргә мин әйтәм. Юрбарысны атып ексам, шартрау тавышыннан өркеп кәҗәм әррә кайрарга качып китәчәк. Ә тау кәҗәсе миннән ерак әре. Шуннан, беткән баш беткән дим, киттем кәҗә артыннан. Юрбарыс та миннән кармый. Мин барсам бара, мин туктасам туктый. Эшрәр

ярышуга китте. Минме, юрбарысмы? Кайсыбызга эргә тау кәҗәсе? Менә кайда мәсьәлә...

Кинәт тышкы якта выжылдап директор «Волга»сы килеп туктаганы ишетелде. Баскычка сырышкан ирләр ашыга-кабалана аякларына бастылар, карт-корысы бөкерәйгән җиреннән торая алмыйча билен язып азапланды.

Өстенә ялтыравыклы күн тышлы, норка якалы тун, башына кабарынкы ондатра бүрек кигән Шәмсүн үзе белән тигезсез хор ясап исәнләшкән кешеләргә борылып карамый гына, муены белән бергә катып калгандай башын сизелер-сизелмәс селкеп, үз дәрәҗәсен белүче җитәкчегә хас нык һәм ышанычлы адымнар белән өске катка менеп китте. Бүлмәсендәге йомшак күн кәнәфигә җәелеп утыргач, Һашимов шалтыраткачы булышчылары тарафыннан өстәлгә пөхтәләп тезеп куелган көндәлек белешмәләрне тиз-тиз карап чыкты. Кәгазьләргә башын иеп, авыз эченнән нидер сөйләнә-сөйләнә кайсыбер саннарны төзәтеп маташты. Эш белән үтә мәшгуль күренсә дә, аның уйлары яңа гына китапханәдә эшли башлаган Гөлфинур янында йөзә иде. Ул аны беренче тапкыр фермада өмә ясаган көнне күрде. Соңыннан урам пычрагын тынычсызларга теләмәгәндәй сыгылмалы билен тирбәлдереп йомшак кына басып йөрүе, аңа зәңгәр күзләрен уйнатып назлы чытлыклануы һәр көнне күзенә чалынып кала иде.

Кичә ул Шәмсүнгә очрамады. Ни өчендер, аны күрмәсә, аяз көне болытлы булыр кук тоелды. Өенә кайтышлый ул шоферына машинаны китапханә янында туктатырга кушты.

Гөлфинур өстәл янында нидер язып утыра иде. Шәмсүнне күргәч, ул каушап-кызырынып урыныннан торды.

— Исәнмесез,— диде чак-чак ишетелер тавыш белән.— Әйдәгез, түргә узыгыз.

— Ничек яшәп ятыш? — дип сорады Шәмсүн көр тавыш белән.

— Ярыйсы. Күргәнегезчә.

Шәмсүн күз карашын аслы-өсле киштәләргә тезелеп куелган китапларга юнәлдерде, аннары бүлмәне күздән кичерде.

— Да,— диде ул канәгатьсез тавыш белән,— бай яшәмисез, безнең кул җитми, димәк. Фәкать шулай.— Капыл гына ул Гөлфинурга борылды:— Нигә минем янга кереп берни сорамыйсыз?

— Нәрсә сорарга соң? — диде Гөлфинур аптырап. Аңа матур җиһазланган бу бүлмә бар яктан да җитеш сыман тоела иде. Урындык, өстәлләр өр-яңа. Телевизор бар.

— Нәрсә сорарга дисезме? — Шәмсүн күзләрен җелтерәтеп кызга озак кына карап торды. Аның бу чәнечкеле карашын күтәрә алмыйча, Гөлфинур керфекләрен түбән төшерде.— Исемлек язып кертерсез. Мәсәлән, бу телевизор урынына, төслесен алып куярбыз. Бәлки башка әйберләр дә кирәктер. Тәрәзә пәрдәләрен дә алыштырсаң, зыян итмәс. Соңгы модалысы кирәк. Фәкать шулай!

— Рәхмәт,— диде Гөлфинур һәм күзләрен нурландырып Шәмсүнгә күтәрелеп карады.

Гөлфинурның йөрәкне дулкынландыра торган шул вакыттагы карашын күз алдына китереп матур уйларга чумып утырганда гына, сул ягындагы өстәлчеккә куелган телефонда гөжләү-шытырдау ишетелде. Аның артыннан көн дә шушы вакытта яңгырый торган таныш тавыш:

— Хәлләр ничек, Шәмсүн Хәерович? — дип сорады.

— Хәлләр ярыйсы, Казбек Зиннәтович,— диде Шәмсүн — сөтне ике литрга арттырдык, ит тапшыруны...

Ул берәм-берәм шактый тигез тавыш белән машинкада басылган сводканы укый башлады. Ашламаларны кырга чыгару санын әйткәч, Һашимов аны бүлдерде.

— Аз-аз, Шәмсүн Хәерович, ашламалар чыгаруда сынатасың. Тизлекне бермә-бер арттырырга кирәк.

Шәмсүн муенын кашып куйды.

— Тырышырбыз, Казбек Зиннәтович.

— Син буш вәгъдәләр бирергә остарып киттең әле, дус кеше. Вәгъдәне аны үтәргә дә кирәктер бит.

— Үтәрбез, Казбек Зиннәтович.

— Үтәрбез, үтәрбез,— дип, ризасыз тавыш белән Шәмсүннең сүзен кабатлады Һашимов.— Мин бәлки бүген үк сезнең якларга килеп чыгармын әле. Сезне Башкарма комитетта тикшерми булмас. Ату сез анда шактый ялкауланып киттегез.

Шәмсүннең кәефе китте. Начар сөйләште бүген аның белән Һашимов. Гомердә болай кыланганы юк иде. «Менә сиңа әхири,— дип мыгырданды Шәмсүн үз-үзенә,— ышан син аларга!»

Шулвакыт ишектә Мәхмүтнең баягы маҗаралы хикәятен тыңлаучыларның берсе — Кыш бабайга охшаган карт күренде.

— Керергә рөхсәттер бит? — диде ул сакалын учлап сыпыра-сыпыра.

— Нәрсә булды тагы иртә таңнан? — Шәмсүннең тавышы ачулы иде.

Бабай сакалын учлаган килеш аптырап ишек төбендә тукталды.

— Нәрсә дип... ни... йомыш бар иде, улым...— Ул, Шәмсүн күрсен дигән шикелле, күкрәгендәге орден планкаларына күз төшереп алды.

Ләкин Шәмсүн аның бу ымын сизмәде.

— Башка вакытта сөйләрсең йомышыңны,— диде ул шактый коры итеп,— хәзер вакытым юк.— Ул картны бер селтәү белән күз катыннан юкка чыгарган кыяфәт белән өстәл өстендәге кәгазьләрен актарырга тотынды. Кирәклесен тапмады, нервлы хәрәкәт белән шалт та шылт китереп өстәл тартмаларын ачып япты.

Бабай Шәмсүннең кыланышын сакал-мыек эченнән чак күренгән авызын ача төшеп, аптырап карап торды да, кыюсыз гына сорап куйды:

— Кайчан килим соң?

Шәмсүн «Син китмәдеңмени әле, карт шайтан» дигән ачу катыш мәсхәрәле караш белән аңа карап алды да, теш арасыннан сөзеп:

— Башым болай да каткан чакта аптыратма әле, ыслушай,— дип чәпчеде.— Кайчан бушыйм, шунда килерсең!

Карт, кәкре башлы таягын култык астына кыстырып Шәмсүн янынннан чыгышлый, ишек төбендә сулыш та алмыйча күзләрен тондырып үз чиратларын көтеп торган кешеләргә: «Сөйләшергә дә теләми бәдбәхет»,— диде. Һәм тотрыгын җуя башлаган тезләрен авыш-тәвеш китереп тар коридордан кайту ягына тырыклады.

Шул арада кабул итү бүлмәсенә йокылары ачылып өлгермәүдән күзләрен уа-уа, сүлпән атлап белгечләр, бригадирлар кереп тулды. Алар эчпошыргыч сүрән тавыш белән көн мәшәкатьләре, эштәге тоткарлыклар хакында зарланыштылар.

Бераздан секретарь өстәлендәге телефон моңлы итеп чыңлап алды. Һәм секретарь кызый:

— Яхшы, Шәмсүн Хәерович,— дип ягымлы көйләде. Аннары калынаеп киткән таләпчән тавыш белән бүлмәгә җыйналучыларга дәште:

— Шәмсүн Хәерович сезгә керергә куша.

Кыршылып беткән тышлы тун яки куртка кигән белгечләр урындыкларын шыгырдатмаска тырышып урнашып беткәч, Шәмсүн, гадәттәгечә, берәм-берәм барсына да күз йөртеп чыкты. Башта Галим абзыйга төртелеп торды, анысы тетрәнеп киткән сирәк керфекләрен түбән төшергәч, күңеле булып, күз бәбәкләрен башкаларга күчерде. Аннары стена буенда утыручылардан каядыр өскә карап:

— Кайда бүтәннәр? — дип сорады.

— Озакламый килеп җитәрләр,— диде Айрат Бәдретдинович, баш очындагы тәрәзә ягына каерылып карап.— Орлыкларның тишелү дәрәҗәсен тикшереп соңардылар.

— Бүген сезнең белән язгы-җәйге эшләрнең планын кабул итәчәкбез,— диде Шәмсүн.— Исегездә тотыгыз: бу планны тикшерергә

һашимов үзе киләчәк. Кырга ашламаларның әлегәчә аз чыгарылуы өчен безгә нык кына эләгәчәк.— Ул яңадан кысык күзләрен Галим абзыйга текәде.

Галим абзый канатларын җәеп урыныннан торып басты. Аның калку маңгае астына яшеренгән күзләре гаҗизләнеп ялтырый иде.

— Шәмсүн Хәерович,— диде ул нечкәрәк тавыш белән,— нишлим соң, үзегезгә мәгълүм, ферма янындагы тиресне чыгарып бетердек, бүтән тиресе дә җук бит аның.

— Баш сиңа нәрсәгә, ыслушый,— дип кычкырып җибәрде Шәмсүн. Аның яшькелт күзләре кая барып сугылырга белмәгәндәй арлы-бирле йөгерә иде.— Кыймылдат азрак миеңне, әгәренки андый нәрсә синдә булса... «Беларусь» тракторына арба так та хуҗаларга йөреп, тиресләрен алып чык! Ишегалларын пычратып кына ята ул аларның, кая куярга белми аптырыйлар.

— Син, Шәмсүн Хәерович, бу ягын да исеңнән чыгарма,— дип сүзгә кушылмакчы иде Айрат Бәдретдинович, Шәмсүн аңа җикеренде генә:

— Ә син катышма, ыслушый, нәрсә әйтәсеңне беләм. Агроном, бригадирлар эше бу димәкче буласың. Алар да, һичшиксез, катнашыр бу эшкә. Фәкать шулай!

Айрат Бәдретдинович терсәкләрен тезләренә куеп, ике учы белән яңакларына таянып утыра иде. Бу рәвеш ул йоклап киткән кешегә охшый. Чынлап та, ул уйларына бирелеп, Шәмсүннең: «Хәзер барыгыз да чәчү планнарыгызны тиешле тәртипкә китерегез, берәр сәгатьтән яңадан җыелырсыз»,— дип белгечләрне чыгарып җибәргәнен сизмәде. Күтәрелеп караганда, өстәл янында Шәмсүн белән Рәфис кенә утыра иде.

— Белмим, белмим,— диде Рәфис үз-үзенә әйткән кебек Шәмсүнгә,— синең кешеләр белән сөйләшүең миңа һич кенә дә ошап бетми.

— Ошап бетми? Харап икән алайса...— Ул, күзләрен зәһәр елтыратып, мәсхәрәле көлемсерәде.—Ниләр генә эшлим икән соң, ыслушый, сиңа ошар өчен? Алдыңда тезләнимме? Каршыңда үрмәләп йөримме?

Рәфис берни дәшмичә ничектер сүрелеп, дәртен югалткан караш белән алдына карап утыра бирде.

Рәфис бу кара-каршы әйтешүдә үзенең хаклы булуын сизә, әгәр директор Шәмсүн түгел, бүтән берәү булса, үз дигәнен ярсып-ярсып яклар иде. Шәмсүнгә карата ул моны эшли алмый, элеккеге дусты аны дөрес аңламас, ул чагында директор белән икесе арасында киеренке мөнәсәбәт урнашыр. Бу хәл, һичшиксез, эшкә зыян итәчәк. Болай да кешеләр арасындагы бозны ничегрәк эретергә дип чәбәләнгәндә, хуҗа кеше белән дә аңлашылмаучылык килеп чыкса, хәлләр түзеп тормаслыкка әйләнәчәк...

— Ошап бетми,— дип кабатлады Шәмсүн озакка сузыла башлаган тынлыкны бозып,— бүген әнә һашимов килә, бик шәп итеп ошатыр барыбызга да... Шундый ошатыр, аның белән чагыштырганда мин сезнең янда әүлия булып калырмын.— Аннары Рәфискә борылды:— Син, ыслушый, теге ашханәдән ташыган җиһазларны кире үз урынына алып килеп куйган бул! Мин һашимовны майлы киемле тракторчылар янына утырта алмыйм.

— Утырса, ни була,— диде Рәфис үҗәтләнеп.

— Әйе,— дип зәһәрләнеп кычкырды Шәмсүн,— сиңа ни, үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын. Ояты сиңа түгел шул аның. Боерам: хәзер үк кушканны эшлә!

Шулвакыт, ишекне кыймыйча гына ачып, Хәдис белән Рәния килеп керде. Алар артыннан ук, ишек ябылганчы кереп калыйм дигән төсле, ялт кына Мәхмүт эчкә елышты.

— Сезгә нәрсә кирәк?— дип җикеренде Шәмсүн.

— Аларны бирегә мин дәшкән идем,— диде Рәфис ничектер үзгәреп киткән тавыш белән.

— Ни булды тагы?

— Үзләре сөйләп бирсен.

Хәдис берни дәшмичә йонлач бүреген кулларында йомарлап, башын аска игән хәлдә басып торуын белде.

Рәния бередә үзен артык кеше итеп тойды. Ул гади савымчы гына бит, директор, баш зоотехник янында бик кечкенә кеше ич ул. «Нигә дип Рәфис абый Хәдис хакында миннән әйттерергә теләде икән соң? Үз энесе булганга микәнни?» Ул үзенең тиктомалдан кызара баруын сизде. Артына яшеренгән кулларын йодрыклады, каушавын, йомшаклыгын идәнгә коярга теләгәндәй, бөтен гәүдәсе белән тураеп иңнәренә төшкән чәч учмасын чайкалдырып башын селкеп алды. Маңгай өстендә кыска итеп кискән кара чәчләре күзләренә таралып төште. Ул аларны кулы белән өскә сыпырды, тирән сулыш алып сүз башлады:

— Менә ни, бу Хәдис,— диде ул үз тавышының еракта яңгыравына гаҗәпләнеп. Шәмсүннең түземсезләнеп өстәл өстендәге кәгазьләрне әле бер җиргә, әле икенче урынга күчерә башлавын күреп, Рәния әллә ничек җыерылып калгандай булды.— Сезнең алда кыен миңа... Булдыра алмасам, гафу итәрсез инде.— Ул башын түбән иеп гаепле елмаеп куйды. Аннары чем-кара күзләрен кыса төшеп нәген өскә чөйде. Болай иткәч, каушау билгеләре тәмам юкка чыгып, чыраена кырыслык иңде.— Турысын әйткәндә, минме, бүтәнме, кемдер бу сүзне әйтергә тиештер инде. Оят бит, үзебез нинди гүзәл чорда яшибез, тормыш алга бара, дибез. Ә чынлыкта ни күрәбез: беребез сәбәпсез нисез эшкә чыкмый, икенчебез җиңелрәген эзли. Иң-иң ямьсезе — исереклек. Бу бит күрәләтә үз-үзеңне хайван дәрәҗәсенә төшерү. Юк, мин дөрес әйтмәдем, болай әйтү безнең терлекләрне кимсетү була. Мин... мин аларны яратам.— Ул бүлмәне нурга күмеп елмайды.— Әйе, яратам...

— Ни өчен эшен ташлап китә дә, аракы эчә ул Хәдис?— дип дәвам итте ул.— Чөнки аңа диңгез тубыктан. Эчендә җаны булган кеше эшне кызулатырга тырышыр иде. Юк шул, юк. Йөрәге үлгән Хәдиснең.

Рәниянең билен кыса төшкән чем кара кофта аша зифалыгы беленгән гәүдәсенең дәртләнеп алга омтылуын, кызларча тулышкан битләренең дулкынланудан алсуланып китүен, чем-кара күзләренең очкынланып януын күреп торды Рәфис. Кызның чәч учмасы сызылып киткән кашларына сибелеп төшкән, үпкәләгән сыман алга бүлтәйгән иреннәреннән кайнарланып чыккан сүзләре ачык һәм йөрәккә үтәрлек иде.

Үзе белән очрашканда һәрвакыт оялып комач кук кызара торган бу кызның күңелендә җыйналган уйларын сөйләгәндә шулай кыю һәм усал була алуына гаҗәпләнде Рәфис. Әйткән сүзеңә бөтен барлыгың белән инанганда гына, шул инануны гамәлгә ашырырга бик нык теләгәндә генә бу шулай була торгандыр. Икеле-микеле фикер төссез һәм буталчык булса, айнык фикер гадәттә кыю була шул. Ләкин аның үзен — Рәфисне аңларлармы? Үз энесен бирегә китереп җитәкче кешеләр каршына бастыруын бер кәмит кую дип кенә карамаслармы?

— Җә,— диде Айрат Бәдретдинович Рәния сөйләп бетергәннән соң Хәдискә карашын төбәп.— Ни диясең инде син моңа каршы?

Кинәт Хәдиснең кашы-күзе җимерелеп, иреннәре очлайды.

— Нәрсә әйттермәкче буласыз сез миннән?— дип кычкырды ул хәтере калган тавыш белән.— Әйтүдән ни мәгънә? Начар трактор бирдегез, атлаган саен ватыла, дип әйтмәдеммә? Кем ишетте? Трактор частьлары эзләп аягым калмады, кайсыгыз күрде? Җитмәсә, эшләми тик ята дип прастуй яздыгыз. Мин анысына аңлаттым, тегесенә аңлаттым, ыжлап та бирмәделәр! Эшлексез, җилкуар, лудыр дип газитка яздылар...

Хәдис өстәл янында утыручыларга үпкәле тавыш ташлап, тынып калды.

Айрат Бәдретдинович, кырыс караш белән кыска гына итеп янындагыларга карап алды да, күзләрен өстәлдәге язуларына төшерде. Көрсенеп башын кашып алды.

— Үз гаебеңне кешегә аударма, ыслушый,— диде шул ара Шәмсүн Хәдискә һәм күз катында яткан кәгазьгә ишарәләп өстәп куйды.— Менә мин бу приказда сине өч айга ремонт эшләренә күчереп торырга дип яздым.

Хәдис гамьсез генә торган җиреннән кубарылып алга бер адым атлады.

— Ремонтка? Ә трактор? — ул ярдәм сорагандай Рәфискә таба борылып карады, анысы көрсенеп башын аска иде.

Шәмсүн катгый итеп әйтеп салды:

— Тракторыңны башка берәүгә биреп торырбыз. Фәкать шулай!

Хәдис малайларча ачынып кычкырды.

— Кемгә?

— Табарбыз!

Хәдиснең йөзенә кан йөгерде, ул үҗәтләнеп башын чайкады.

— Табасыз икән, тракторны төзәтергә дә бүтән кеше табыгыз! Ике аягымның берсен дә атламыйм.

— Син кара аны, егет кисәге! — Шәмсүн кинәт кабынганга тотлыгып торды.— С-сүзеңне үлчәп сип! Аннары җыеп ала алмассың!

— Өркетмәгез мине, бу совхоздан башка да эш бетмәгән. Муенга камыт табылыр әле!

Хәдис кулларын ярсып айкый-айкый олы атлап бүлмәдән чыгарга барганда Шәмсүн өстәлгә сугып кычкырды. Хәдис шунда ук туктап Шәмсүнгә борылып карады. Аның күзләре зур булып ачылган, йөзеннән кан качкан иде.

— Яхшылыкның кадерен белмисең икән, статья белән куам мин сине, малай актыгы!

Хәдис каушап тотлыгып:

— Ни... мин бит,— дип авыз эченнән ботка пешерә башлаган иде, Шәмсүн аңа сүз әйтергә бирмичә:

— Ычкын моннан, селәгәй авыз! — дип аяк тибеп кычкырды.

## 8

— Шунда исбатлап маташмасаң соң,— диде Шәмсүн район башкарма комитеты утырышыннан чыккач Рәфискә,— синең ул дәлилләреңне кем тыңлый, бары үзеңә чокыр казыйсың. Ярар, ди идең дә бетте-китте. Ул чагында эзсез-нисез шома гына узып киткән булыр иде.— Ул шулай диде дә, машинасына утырып бүтән эшләрен юлларга китте.

«Шәмсүн бу яктан хаклы,— дип уйлады Рәфис үзе генә калгач,— чынлап та, үҗәтләнеп маташуым белән андагыларның игътибарын җәлеп иттем шул. Икенче яктан, дәшми калу үзеңә тынычлык китерсә дә, эш өчен файдага түгел лә. Мәсьәлә ачылмыйча, чишелмичә кала. Их,— ул көрсенеп куйды,— шунда иптәшләрчә сөйләшеп, эшне бергәләп ачыкларга тырышсак, ничегрәк итеп хәлне төзәтү турында киңәшсәк, ни була? Шуның өчен җыйнала торганбыздыр бит? Ә алар: «Син ник алай, син ник болай?.. Син... Син... Тукта, ник әле алар миңа «син» диләр, ә мин бит «сез» дип эндәшәм ул кешеләргә? Ни өчен югарыдан торып сөйләшә алар? Юк, сөйләшү дә түгел бу. Гүя мин ниндидер хәтәр җинаять эшләгәнмен дә, алар мине хөкем итәләр. Йөзләрендә, күзләрендә — дошманлык, җирәнеп йөз чөерү...»

Ул шул хәлләрне зиһене аша уздырып торганда, үзенә атап дәшүдән сискәнеп китте.

— Гөлфинур?

— Син кайтасыңмыни бүген?

— Кайтмый нишлисең.

— Безнең семинар бүген бетми әле. Мәдәният сараенда безнекеләр кичә үткәрә.— Гөлфинур башын бер якка кыегайтып мут кына елмайды.— Теләсәң, чакырам үзеңне.

Көтмәгәндә юлыккан бәхетнең чынлыгына Рәфиснең күңеле ышанып бетми иде әле. Шуңа күрә, ни дияргә дә белмичә, ул сүзсез калып кызга карап торды.

Ә Гөлфинур, берни булмагандай, ачылып-чәчелеп сөйләде дә сөйләде:

— Син миңа үпкәләгәнсеңдер инде. Гафу ит мине. Хәлем мактанырлык түгел иде. Мең-мең рәхмәт сиңа. Син булмасаң, бу көннәрне күрер идемме мин... Ничек матур булып яз килә, Рәфис! Тирәкләрнең яңа борын төрткән бөреләрен күр син. Каен кәүсәләре буйлап югарыга ашкынган тереклек суының чөмердәгән авазы ишетелә сыман. Әйтерсең, талантлы композитор иҗат иткән илаһи симфония. Боларның барысын бары синең аркаңда күрәм, ишетәм мин, Рәфис!

Әйе, бу — таныш. Бу — чат Гөлфинур. Үз-үзен тотышының көтмәгәндә үзгәрүе белән Рәфисне еш кына аптыраашта калдырган, телсез иткән кызый. Ә шулай да Рәфискә рәхәт. Күңеле аксыл болытлар арасында йөзә, хатирәләр дөньясына күчә.

...Уеннар, биюләр өчен билгеләнгән биек түшәмле, аллы-гөлле утлар балкыткан иркен зал. Ашкынулы музыка ишекләрдән, тәрәзәләрдән урамга бөтерелеп чыгып өермәдәй тулганып ала да, кире кайтып заманча киенгән егет-кызларны элеп алып селкеп сала. Яшьләр ташкыны стенада биешкән төсләр чиратлашуына кушылып бер яктан икенче якка авыша-авыша дерелдәп тора, бутала. Шул ыгы-зыгыда нурлы йөзләр, бәхетле күзләр чагылып кала. Нигәдер алар йөрәккә дә, зиһенгә дә кагылмый. Ә йөрәккә кагылганы... Рәфиснең каршысында ук елмайганда түгәрәк бит уртасы уймаклана торган көләч зәңгәр күзле, сусыл кызыл иренле кыз. Аның хәрәкәтләре җитез, буй-сынының сыгылмалыгы нәфис. Елтырап торган аксыл йөзе, дулкын-дулкын булып ике якка сибелеп төшкән саргылт чәчләре күңелне алгысытып һаман якыная, карашының оялчан серлелеге күз катында ук. Кара керфекләрен чак тибрәтеп зәңгәр очкын сипкән күзләре белән бер мәлгә тутырып карап алганда йөрәгең уелып киткәндәй була.

— Рәфис,— диде Гөлфинур,— безнең яңадан, ничәмә-ничә еллардан соң очрашуны син нәрсәгә юрыйсың?

Рәфис капыл гына кызның һәрнәрсәгә гаҗәпләнеп карый торган кыңгырау чәчәгенә охшаш күзләренә бакты.

— Бәхеткә, Гөлфинур, бәхеткә...

Томырылып караучы зәңгәр күзләр нурлар чәчеп балкыды.

Шаулы һәм дәртле ритмда тирбәлгән, очынып сикеренгән кешеләр диңгезендә Рәфиснең бөтен гәүдәсе җиңеләеп юкка чыккандай булды, ул үзенең кайнар һәм ярсулы хәрәкәтләрен тоймады, тирә-юньдә ашкынып биюче егет-кызларны күрмәде. Гүя барысы — күңелләрне очындырган дәртле көй дә, уйнаклап җемелдәгән төрле төстәге утлар да, хәтта дәртләнеп биючеләр дә бу гүзәл кызга табынып, ташып-шашынып әйләнә-бөтерелә кебек иде.

Көтмәгәндә очраган бу куанычны ул тотып кала алмас, рәхәт мизгел елтыр терекөмештәй шуып учыннан чәчелер сыман тоелды.

Икенче көнне төштән соң, җәяүләп кенә Актайга кайтырга чыгып, урман уртасына җиткәч, карлы-бозлы яңгыр коярга тотынды. Башта киң ябалдашлы чыршы астына кереп ышыкландылар. Явым озакка китте. Куе чыршы ылыслары аша да тып-тып тама башлады. Рәфис җиргә кадалган дүрт таякка плащын тарттырып, үзенә күрә өскормә ясап маташты. Шулай итә-итә кич җитте, караңгы төште. Егет коры ботаклар табып, учак ягып җибәрде. Кичке урманның һәм чатнап янган учакның һич ка-

батланмас хозурлыгы бар иде: кызгылт яктылык шәүләсе сихри эңгергә төренгән ялангач юка һәм ялпак ботаклы чыршылар буйлап үрмәли дә, дерелдәп-калтырап түбәнгә шуыша. Салкынча парлы һавага яшь ылыс һәм юеш кар исе таралган. Карт чыршы кәүсәсенә сөялгән килеш шушы илаһи матурлыкка таң калып утырасы да утырасы. Берең учакның бер ягында, икенчең — теге ягында. Яңакларны алсулатып, күзләргә очкын кабызып учак тик яна бирсен. Әнә шулай кара-каршы утырганда бер-береңнең йөзендәге, күз карашындагы һәр үзгәрешне, һәр омтылышны сиземлисең. Сөйгәнеңнең күз карашы тирә-юньдәге сихри гүзәллеккә кушылып күңелдә иң саф тойгылар уята. Бер-береңнән менә шулай аерымрак утыру да бик җиткән. Алай гына да түгел, бу яхшырак. Бүтән вакытта Гөлфинурның Рәфис белән бер-берсенә сыенышып торган чаклары булыр әле, булыр. Ләкин ул монда егетне үзенә якын да китерергә теләмәде. Якын китерсә, рухын сафландыра торган әлеге пакьлек, хозурлык кимер, хәтта юкка чыгар сыман иде. Бер мәлне Рәфис аның янына килеп, кулларын кызның иңнәренә салырга теләгәч, ул хәтта үпкәләп бер ялгызы кайтыр юлга чыгып китте. Әле кызның алдына, әле артына чыгып шактый ялынырга туры килде Рәфискә. Әйе, яшь чакта үзеңнең сөйгәнеңә артык зур таләпләр куясың икән ул. Гөлфинурның уенча, Рәфис, иңнәренә кагылып, бу кичнең кагылмас хозурлыгын, илһамлыгын хөрмәт итмәде. Кызның хисләрен, ни уйлавын егет аның күз карашыннан, кымшанырга куркып утыруыннан ук сизәргә тиеш кебек иде. Сизмәгән икән, димәк, ул аны җитәрлек ихтирам итми, яратуы да шуның тикле генәдер.

Үҗәтлеге бераз йомшарып яңадан әлеге чыршы төбенә кире килгәч тә, кытыршы кәүсәгә сөялеп озак кына керфек какмый утырды ул.

Бер кат күңел утырып, кайтырга кузгалгач, алар шундый тамашага тап булды: кызгылт-гәрәбә төсендәге төлке җир астыннан кар катыш кап-кара балчык кантарлары очырта-очырта ике тәпие белән дә тычкан оясы казый иде.

Рәфис тавыш чыгармаска тырышып сак адымнар белән төлке янына якынлашты. Һәрвакыт сак булган бу җәнлек бүген үз шөгыленә шулчаклы бирелгән ки, ул берни сизми иде. Баш ягы инде үзе казыган чокырга бөтенләй күмелгән, алтынсу көлтә койрыгы гына чокыр өстендә ялкынланып дөрләп яна. Рәфис кулын акрын гына сузып бу табигать гүзәлленең койрыгын тотып карамакчы булды. Тик, алтынсу йоннарын җилфердәтеп, көлтә койрык ул кулын сузган саен башка якка күчә иде. Ниһаять, тырыша торгач, ул койрыкның ап-ак чугын эләктерә алды. Тик бер мизгелгә генә! Төлке шунда ук бөтен гәүдәсен сыгылмалы талпындырып чокырдан атылып чыкты да, озын койрыгын сөйрәп аклы-каралы алан буйлап йөзеп китте.

Гөлфинур бу табигать иркәсенә кул изәп калды.

## 9

Шәмсүн күн тышлы йомшак кәнәфиенә сөялгән көе тәрәзә ягына күз ташлады. Парлана төшкән тәрәзә аша беркем дә күренмәгәч, урыныннан торып ишек катына килде дә, түгәрәк көзгегә карап каты һәм буйсынмас чәчен бик тырышып артка тарап маташтьі. Яңадан тәрәзәгә күз салып алганнан соң, кәнәфиенә утырып тынып калды.

Соңгы вакытта Рәфис һәм Айрат Бәдретдиновичлар белән ике арадагы килешмәүчән мөнәсәбәтләрне зиһененнән куып, гомумән, бу дөньяның ыгы-зыгылы мәшәкатьләреннән арынып, чистарынып калу теләге аның бөтен барлыгын биләп алды. Бу омтылыш тирә-юнь караңгылыкка чумып, җир йөзе тынып калган минутларда һәр көн ябырылып килә, тик ни өчендер, ул әрсез һәм ябышкак хисләреннән бөтенләй үк котыла алмый. Уйлары бүтән хисиятләр белән яшәгәндә дә, кайда-

дыр якында гына әлеге нәрсәнең тынгысызланып хәрәкәтләнгәне сизелә, өрәктәй күзен чекерәйтеп үзен белгертеп тора. Бүген ул шуларның барысын да бер селтәнү белән куып җибәрергә теләп, күңелен аздырып, тынычлыгын җимергән аксыл йөзле, күркәм гәүдәле Гөлфинурны үз янына — идарәгә дәшкән иде. Шул кызның оялчан мөлаемлек белән капыл гына үзенә күз ташлап алуы, йөрәккә май яккандай саф тавышы күңелендә яңарып, күкрәк турысын кытыклап куйды. Ул, тынгысызланып, кулындагы сәгатенә күз төшерде. Сәгать телләре беркемгә исе китмәгәндәй тын гына сигезгә якынлашып килә иде. «Килмәс микәнни чукынган кыз?» Ул шулай дип уйларга өлгермәде, кыяр-кыймас кына ишек шакыдылар. Шәмсүн урыныннан торып ишекне үзе ачмакчы булды, ләкин эчендә кузгалган бу омтылышны йөгәнләп (үз дәрәҗәңне һәрчак саклый белергә кирәк), шунда ук бу уеннан кире кайтты.

— Керегез, кер,— диде ул көр тавыш белән.

Ишек акрын гына ачылып, дулкынланып торган саргылт чәчләре чия төсендәге юка пальто иңнәренә таралып төшкән Гөлфинур килеп керде. Ул гүя үзе белән болыннарда гына үсә торган чәчәк исләре, яшьлек балкуы алып килде. Бүлмә эче кояш нурына коенгандай булды.

— Нигә чакырдыгыз? — диде ул назлы мөлаемлек белән.

Аның зәп-зәңгәр күзләре сорау, аптырау катыш зур итеп ачылган, уртасы батып торган түгәрәк бит уртасы алсуланып яна иде.

Шәмсүн Гөлфинурдан күзен алмыйча, урыныннан кузгала төшеп, саран ишарә белән аңа урын тәкъдим итте.

— Ашыкмагыз,— диде ул ягымлы таләпчәнлек белән.— Сөйләшербез, аңлашырбыз. Әйе, фәкать шулай.

Гөлфинурга Шәмсүннең җитәкчеләргә хас кырыслыгы, хатын-кыз чибәрлегә каршында баш иеп үзен арзанайтып маташмавы ошады. «Һәркайда үзе булып кала белә икән».

— Безнең бурыч,— дип сөйләп китте Шәмсүн,— авылга килеп эшли башлаган һәр белгечнең ничек урнашып китүен, эшне ни рәвешле башлап җибәрүен барлау, аның тормыш шартлары турында кайгырту.— Ул, кулларын өстәлгә җәелгән пыяла өстендә кушырып, алгарак елышып өстәп куйды:— Бигрәк тә сезнең кебек чибәр туташлар хакында.

Гөлфинур кызара биреп башын түбән иде.

— Рәхмәт инде.

— Йә, ничек, мин әйткәннәрне китерделәрме сезгә?

— Әйе.

— Эш шартлары канәгатьләндерәме инде сезне?

— Ярыйсы бугай.

— Бугаймы, ярыйсымы?

— Ярыйсы,— диде ул ярым пышылдап.

— Гаиләгез зур бугай. Әти-әниең, тагы...

— Ике сеңелем,— дип өстәде Гөлфинур.

— Вәт, вәт, өеңдә тыгынлык булгач, сиңа (ул үзе дә сизмәстән «син»гә күчте) уңайсыз түгелме соң? Ни әйтсәң дә, мәдәният эшлеклесе бит. Зур эшләр белән шөгыльләнергә кирәк булыр.

Шәмсүн ни әйтергә тели икән дип, Гөлфинур аңа төпченеп карап алды, ләкин директорның елмаюлы карашыннан әллә ни укый алмады.

— Нишлисең, түзәрбез инде,— диде ул яңадан керфекләрен идәнгә кадап.

Шәмсүн турайды, аннары каршыда утырган Гөлфинурның иңнәренә калын учын куеп мөлаем һәм шул ук вакытта катгый итеп әйтте:

— Түзәргә кирәкмәс, Гөлфинур акыллым. Мин сиңа яңа төзелгән йорттан квартир бирермен. Әйе, әйе, кайсын телисең, үзең сайларсың.

Гөлфинур Шәмсүннең көтелмәгән тәкъдименнән аптырап һәм каушап китте. Беравык ни әйтергә дә белмичә торды.

— Шулай, Гөлфинур,— диде Шәмсүн,— профкомдагылар минем сүздән чыкмаслар.

Шунда ук ул тәвәккәл хәрәкәт белән телефон трубкасына сузылды.

— Наилә, иртәгә сәгать бишләргә профкомны җыйнарсың. Ә аңа чаклы миңа кереп чык. Аңладың? Аңласаң, яхшы.

— Рәхмәт сезгә,— диде Гөлфинур дулкынланып. Ничек сиздермәскә тырышса да, аның тавышы калтыранып чыкты.

Сандугач тавышлы телефон чыңлап алды. Шәмсүн Гөлфинурга карый-карый ниндидер катгый боерыклар бирде. Кыз аларын тыңламады. Бары Шәмсүннең: «Фәкать шулай»,— дигән сүзен генә ишетеп калды.

Аңа урыныннан торырга һәм ихтыярын каушата торган бу якты, бай җиһазлы бүлмәдән чыгып китәргә кирәк иде. Ләкин ул оеп, хәлсезләнеп киткәндәй урыныннан куба алмыйча йомшак һәм уңайлы кәнәфигә сеңеп утыруында булды. Ниндидер күзгә күренмәс җепләр гүя аны шул урынга бәйләп куйган да, уңайсызлап, сынын катырып бара, бу җайсыз халәтеннән ычкынып китәргә комачаулый иде.

— Син әйт кенә,— диде Шәмсүн Гөлфинурга елыша барып,— мин сиңа бөтенесен эшләрмен.

— Абау, әлегә берни кирәкми.— Ниһаять, ул үзен бәйләп торган җепләрне өзеп урыныннан торды.— Мин китим инде. Әниләр юксына башлагандыр.

— Тагын килеп чык, Гөлфинур, минем чакырганымны көтмә!

Акрын һәм йомшак адымнар белән ишеккә таба атлаучы Гөлфинурның пәлтәсе аша да зифалыгы сизелеп-сизелеп киткән биленнән коча төшеп, Шәмсүн аны озата чыкты.

Урамның электр яктысы сибелүдән җемелдәгән йомшак карына басып барганда, Гөлфинур директор белән очрашу тәэсиреннән айный алмыйча, аңлаешсыз томанлыкны ергандай аңгы-миңге булып, хәзер генә булып үткән сөйләшүнең мәгънәсенә төшенергә тырышты. Нинди кеше соң ул Шәмсүн? Кешеләргә үтә дә миһербанлы җанмы? Әле килеп урнашырга өлгермә, сиңа менә дигән квартир тәкъдим итсен, имеш.

Әллә ул миңа гына шундый игътибар күрсәтәме? Тышкы кыяфәтем ошап, үзенчә, шул юл белән минем күңелемне яулап алмакчымы?.. Анысы булмас, билгеле. Тик нигә дип чибәрлегең алдында баш иючеләрне файдаланып калмаска? Бирсен фатирын.

Гөлфинур бераз калынрак, шулай да бик килешле иренен җыя төшеп үзалдына көлеп куйды. Аннары, кеше-мазар күрмәде микән дип, як-ягына каранып алды. Ләкин кечке урам буп-буш. Рәфисне очратып, көтмәгәндә тап булган сөенече белән уртаклашасы килде.

Ул аны көндәгечә фермадан өенә кайта торган тар сукмакта көтеп алды. Караңгылык сөреме эченнән бераз як-якка чайкала төшеп атлаучы таныш гәүдә калкуга, араларны якынайтырга ашыгып, үзе аның каршысына атлады, сагыну һәм сөенеч белән тулы гәүдәсе белән сарылып егетнең таза муеныннан кочып алды. Тәнгә-тән сыенган җаннар бушлыкны юкка чыгарды, кайнарланган иреннәр каударланып, ашкынып бербереен эзләде. Ниндидер бер мизгелгә җир йөзендә берни дә: үзләре басып торган кар-бозлы төбәк тә, яннарында гына язга сусап утырган аксыл каен да, хәтта салкынча дымлы һава да калмады...

— Ай!

Гөлфинур йөгереп килгәндәй еш-еш сулый иде.

Моңарчы меңләгән гашыйклар кабатлаган, ләкин һәрберсе өчен йөрәгенең беренче талпынуы, ачышы булган сүзләр иреннәрдән өзелеп төште:

— Мин сине... яратам!..

Хисләрнең ургып чыккан ярсуы үз ярларына кайткач, Гөлфинур назлы иркәләнеп саргылт чугы таралып төшкән маңгаен Рәфиснең күкрәгенә куйды.

— Сөенечем бар бит, Рәфис...

— Безнең бу очрашулардан да зурмы?

— Һәр куанычның үз урыны... Миңа квартира бирәләр!

— Квартира? Кем бирә?

— Шәмсүн Хәерович әйтте...

Рәфиснең күкрәгендә эчендә ниндидер шыксыз нәрсә кузгалып куйды.

— Ул әйтер. Фатир мәсьәләсен профком хәл итә бит.

— Профкомда минем сүздән чыкмыйлар, ди.

Рәфиснең күңелендә әле генә тантана иткән бәйрәм артка чигенде, теге өмә кенендәгедәй чемердәп, салкын ризасызлык дулкыны ябырылып тәнен чытайттыргандай итте. Ул акыл көче белән йөгәнләп, бу аек омтылышның тышка бәреп чыгуын тоткарлады. Боздай агым ургылып әле тормышның, хакыйкатьнең ни икәнен аңламаган нәзберек кызның аңа карата булган йөрәк ялкынын сүндерер дип курыкты ул. Бик юка бәллүрне идәнгә төшереп ватарга курыккан кеше күк, ул аңа бик саклык белән болай диде:

— Гөлфинур, үзең уйлап кара, совхозда ничә дистә кеше квартир көтә. Араларында бөтен гомерен фермада яки кырда эшләп, инде пенсия яшенә якынлашып килүчеләр дә, дүрт-биш баласы булганнар да бар. Әгәр син килеп җитмәс борын фатир алсаң, алар ни дияр? Ничек итеп шул кешеләрнең күзләренә карарсың. Аннан соң...

Ул: «Шәмсүн квартирны сиңа тикмәгә бирмәс, ниндидер яшерен максаты бардыр»,— димәкче иде, тыелып калды.

Ул сүзләрне әйтмәсә дә, Гөлфинур үпкәләп аскы иренен бүлтәйтте, берни дәшмичә Рәфистән аерылып кыр ягына таба атлады. Каршы сүз әйтсә, үзенекен исбатлап кычкырынса, Рәфискә җиңелрәк булыр иде. Ә болай үпкәләп-кабарынып авызына су алуы... Рәфис аны куып җитте.

— Ярар, бу хакта сөйләшмик,— диде ул аны тынычландырырга теләп.— Әйдә, әнә тегендә, коры җир чыккан тау башына меник.

Ул ай яктысына уралып, балкып күренгән Әпәли тавына төртеп күрсәтте. Гөлфинур, егетнең теләгенә каршы килмичә, алга атлавын белде.

Рәфис кирелеге, үзсүзлеге белән җиңәргә сәләтле кызга һәрчак ташлама ясавына, аның җитди ялгышларына каршы ныклы киртә куя алмавына эченнән генә көенеп, бу хәлдән ничегрәк итеп чыгу хакында уйланып барды. Ул кызга күз төшереп, аның йөзендә катып калган үпкә, гарьләнү чалымнарының әле һаман эремәвен күрде һәм күңелсез сөйләшүне бүгенгә калдырып торырга булды.

Тау өстендә тармакланып үскән карт имән янына җиткәч, алар тукталып калдылар. Тимердәй каты кәүсәле бу мәһабәт агач тирәсендәге кардан арчылган җирдә инде беренче яшел үсентеләр тибеп чыккан.

Рәфис сүзләренә хәтере калган булса да, Гөлфинур өчен анысы эчкәрегесе, бөтен дөньясын яулап алганы түгел, тыштагысы, җиңелчәсе генә иде. Күңел асылын сөенеч белән күмгәне барыбер юкка чыкмаган, шулай тоташ килеш тулышып яшәвендә. Рәфиснең фатир хакында бүтән сүз катмавын ул үзе белән килешүе, һич югында санлашуы итеп кабул итте. Шуңа күрә әлеге эчкәреге куаныч дулкыны тышкы күңелсезлекне бик тиз ерып атты.

Гөлфинур, капыл гына кузгалып, ай нурлары коенган уйсулык буйлап йөгереп китте. Бик килешле зифа гәүдәсен уйнатып чапканда ул яп-яшь колынның сыгылмалы хәрәкәтләрен кабатлагандай булды.

— Умырзая! — дип кычкырды ул җирдә баш калкыткан чәчәкләргә нелә-нелә.

— Кирәкми, өзмә! — диде Рәфис аның янына ашыгып.

— Нигә?

— Алар болай да кыска гомерле.

— Өзмәгәнгә карап гомерләре озаямы?

— Һәр үсенте табигать биргәнне яшәп бетерсен иде.

— Һәм кешеләр дә.

— Әйе, кешеләр дә...

Алар бик якын торалар иде. Һәр икесе каршындагы күзләрдә үзен күрде, кайнар сулышлары бөтерелеп аралашты. Менә үзара тартылуны

җиңеп торган көч сарыф ителеп бетте, иреннәр комсызланып, йомшарып бер-берсенә сарылды.

Сыенышкан тәннәрнең сулкылдавы, йөрәкләрнең ашкынып тибүе нинди генә кайнар сүзләрдән дә аңлаешлы һәм үтемле иде. Шуңа алар, кайнар кочакта эрегән хәлдә, бер сүз дәшмичә утыра бирделәр.

— Ай, мин куркам, Рәфис! — диде, ниһаять, Гөлфинур калтыранган тавыш белән.

Рәфис бу сүздән сискәнеп китте һәм аптыраган караш белән кызның ничектер тилмереп баккан күзләренә карады.

— Куркасың? Нидән?

— Мин сиңа бик ияләшеп киттем.

— Бу начармыни, Гөлфинур?.. Ике йөрәкнең бер-берсенә тартылуы гөнаһ эшмени?

— Аңламыйсың, белмисең син!.. Без... без бервакытта да бергә була алмаячакбыз бит.

Гөлфинур шул сүзләрен әйтеп, Рәфиснең күкрәгенә капланды. Елый идеме ул, әллә йомшак һәм кайнар иңнәре нерв киеренкелегеннән шулай дерелди идеме — анысын Рәфис белә алмады.

Егет кызны тагы да үзенә кыса төшеп үтенеп-ялварып сорады.

— Әйт, зинһар, ник алай дисең? Ник без бергә булмаска тиеш ди?

Гөлфинур Рәфиснең күкрәгеннән аерылмаган килеш үрсәләнеп башын ары-бире боргалады.

— Анысын сорама! Мин аны бервакытта да сиңа әйтмәячәкмен!

— Ни өчен, Гөлфинур, ни өчен?..

— Юк, юк!

Әйе, хәзер ул елый иде. Аның күз яшьләре Рәфиснең юка күлмәге аша үтеп, күкрәген пешерде.

Бераздан Гөлфинурның шашынып ярсуы басыла төште. Бары аратирә тирән итеп сулыгып кына куя иде ул.

Рәфис тә аны бүтән борчымаска теләп сүз катмады, шул көе, үз җае белән бер ачылыр, эчендә утлы йомгак булып йомарланган зур төенне чишәр, дип көтте.

Ләкин Гөлфинур чишелергә ашыкмады. Ташыйсы ташып беткәч, акрын гына башын күтәреп читкә карап утырды. Хәзер ул тәмам суынып, барысыннан да ваз кичеп, дөньясына аяусыз бер тойгы белән рәнҗеп бага төсле иде.

Шулай сүзсез утырганда Гөлфинурның күз алдыннан тагы җәрәхәтле истәлекләр уза башлады.

...Гөлфинурның туган көне. Һәртөрле ашамлыклар белән тулы өстәл. Шәрабның ниндие генә юк... Җыр-бию. Рокка шашынганчы бию. «Башым әйләнә минем, Камил...» «Күрше бүлмәдә ятып торырсың, бәлки». Стеналар, түшәм, аның кырында яткан Камил зырлап әйләнеп каядыр чиксезлеккә очып китә... Камил аны кысып кочакласа да, әлеге газаплы очышны туктата алмый. Аннары... аннары саташулы төш... Бөтен дөньясын актарып ташлаган коточкыч төш!

Соңыннан Гөлфинурга баласын табарга рөхсәт итмәде Камил: «Безнең әле берниебез дә юк бит, Гөлфинур. Йорт-җир дә, кием-салым да... Тормыш корырга иртә әле безгә. Ашыкмыйк».

Туй алдыннан гына Камил Гөлфинурны врачка күренергә мәҗбүр итте. «Без бер-беребезне яхшы белергә тиеш», — диде ул.

— Синең балаң булмаячак, — диде врачлар.

Аннары китап тышлыгындагы әрнеткеч язу: «Язмышыңның корбаны буласым килми».

Коточкыч... Коточкыч!

Гөлфинур яңадан үксеп, Рәфиснең күкрәгенә сыгылып төште.

**Искәрмә:** А. Вергазовның бу романы тиздән тулысынча Татарстан китап нәшриятында басылып чыгачак.

# ПУБЛИЦИСТИКА

## Әмирхан Еники

# ЯЛГАННЫ ЯКЛАУ

Тукай клубында булып узган бер җыелышны минем искә төшерәсем килә. Аңа инде егерме елдан артыграк вакыт үтеп китте. Числосын-көнен дә тәгаен генә хәтерли алмыйм, әмма җыелышның үзен һич тә онытасым юк.

Безнең гомердә җыелышлар күп булды, төрле заманда төрлесен күрергә туры килде — күбесе инде онытылып та бетте. Тик турыдан-туры үзеңә кагылганы гына каядыр хәтер төбендә онытылмыйча сакланып ята. Мин сөйләргә теләгән җыелыш әнә шундыйлардан. Үземә кагылган өчен генә сөйләп тору кирәкмәс тә иде бәлки, әмма бу очракта сүз башлыча Тукайга кагыла — Тукаебыз турында барачак. Бары шуңа күрә генә мин моннан 20 ел элек булып узган ул җыелышны яңадан искә төшерүне кирәк таптым.

1971 елны безнең нәшрият «Тукай атеизмы» дигән бер китап бастырып чыгара. Авторы З. А. Ишмөхәммәтов. Күргән, белгән кешем түгел. Бары күпмедер вакыттан соң гына аның Казан университетында философия кафедрасы укытучысы икәнлеген ишетеп белдем. Тукайга багышланган китабы бәлки фәлсәфә өлкәсендәге фәнни хезмәте булгандыр.

Шунысы кызыклы, бу кешенең китабы турында миңа шул ук университет профессоры, Тукай иҗаты белән махсус шөгыльләнүче Ибраһим Нуруллин башлап әйтте: «Тукайны дәһри иткән бер китап дөньяга чыкты, син шуны табып укы әле»,— диде...

Билгеле, мин тиз арада ул китапны табып алдым — урта форматта, 71 бит, бәясе дә 11 тиен генә... Һәм шунда ук бик игътибар белән мин аны укып та чыктым.

Төп мәсьәләгә күчкәнче, алдан ук шуны әйтеп куясым килә: китапның авторы бу фани дөньяда юк инде. Әмма китабы турындагы минем карашны, уйлыйм ки, ишеткән булырга тиеш. Чөнки мөнә монда язылачак фикерләремнең күбесен мин әлеге Тукай клубындагы җыелышта чыгып әйткән идем инде. Үзе ул җыелышта булмаса да, кемнәрнең нәрсә сөйләгәнен аңа җиткергәннәрдер, әлбәттә. Китап турындагы сүз автор колагына барып җитмичә калмый ул.

Ишмөхәммәтов кереш сүзендә үк инде ачыктан-ачык «Тукай — атеист» дип белдерә. Бу сүзнең мәгънәсен яхшы аңласам да, бер төрле дә шик калмасын өчен, русча-татарча сүзлекне ачып карарга булдым. Әйе, дөрес, нәкъ мин аңлаганча бирелгән: «атеист — дингә (аллага) ышанмаучы, динсез, алласыз, дәһри»... Тукаебыз әнә шундый кеше икән! Минем өчен бу әр-яңа бер ачыш булса да, артык гаҗәпләнмәдем. Идеология таләпләреннән чыгып, бездә Тукайны төрле вакытта төрлечә бәяләү аз булмады; кайчандыр аны милләтче дип тә, вак буржуа шагыйре дип тә

атадылар. Соңгы елларда инде аңа революцион-демократ диган исем беркетелде. Гомумән, Тукаебызны коммунистик идеологиягә кыскарак тезген белән ныграк бәйләп куярга тырышу һаман үзен сиздереп килде. Ишмөхәммәтовның бу хезмәте дә шуның бер үрнәге түгел микән?

Хуш, мөхтәрәм философ Тукайның атеист (дәһри) булуын нәрсәдән чыгып, ничек итеп нигезли соң? Цитаталарга күчик. «...Күренә ки,— дип яза китап авторы,— марксистик-ленинчыл идеология йогынтысында шагыйрь азатлык җырчысы, хезмәт ияләрен социаль һәм милли изелүдән коткару өчен актив көрәш юлына баскан революцион-демократ булып формалашты. Сыйнфый көрәш логикасы Тукайны социализм идеясенә китерде» (8—9 битләр).

Болай булгач, Тукайның атеист икәнлеген исбат итү бер дә читен булмаска тиеш. Марксизм-ленинизм йогынтысына эләккән кеше ата дәһри инде ул!.. Һәм Ишмөхәммәтов та моны һәр яклап исбат итәргә тотына: «Ул (ягъни Тукай. Ә. Е.) ислам диненең халык интересларына ят нәрсә икәнен, диннең эксплуататорларга халык аңын томамлау коралы булып хезмәт итүен ачып салды, динне сыйнфый һәм милли изүне аклау чарасы итеп файдаланган реакцион көчләрне фаш итте, ислам руханилары белән полиция аппараты арасындагы союзның реакционлыгын күрсәтте. Тукай ислам диненең күп кенә догмаларын, әхлак нормаларын, дини йола һәм бәйрәмнәрен кискен тәнкыйть утына тотты» (66—67 бит).

Җитмәс микән?... Юк, аккорд рәвешендә тагын бер кыска гына өзек китерик: «Иҗатының соңгы елларында хәзерге диннәрнең төп идеясен — алла идеясен тәнкыйтьләү югарылыгына күтәрелде»,— дип яза автор... Ягъни мәсәлән, Тукай алланы инкарь итүче шагыйрь дә икән әле. Хәер, бусы инде үзеннән-үзе дә аңлашыла: атеист бул да, алланы инкарь итмә, имеш!

Дөресен әйтергә кирәк, Ишмөхәммәтов Тукай иҗатын шактый тирән сөреп чыккан. Тукайга таккан һәр сәяси тезисын ул шагыйрь иҗатыннан күп мисаллар китереп, үзенчә дәлилләп тә бара.

Ә Тукайдан барысын да табарга була. («Күктә ни булмас дисең, очсыз-кырыйсыз күк бит ул!»). Турыдан-туры атеизм тегермененә су кояр-дайларын да! Тормыштан аерылган кадим мәдрәсәләрдән, кара надан ишан-муллалардан, комсыз-азгын байлардан әче көлеп яки ачынып язган юллар азмыни аңарда?! Алар барысы да безгә мәгълүм. Тик биредә шуны гына ачыклап үтәсе килә: Тукай атеизмга хезмәт итәрдәй әнә шул шигъри юлларын кем йогынтысында бирелеп язды икән?.. Китап авторы «марксизм-ленинизм йогынтысында» ди. Ләкин минем моңа нигәдер ышанып бетәсем килми. Бик яшьли, бик вакытсыз үлеп киткән шагыйрь Маркс белән Ленин исемен, ихтимал, ишетеп белгәндер, әмма аларның тәгълиматын төннәр утырып «моталәгә кылырга», мөгаен, өлгермәгәндер. Минем фикеремчә, шагыйрьгә иң көчле йогынтыны тормыш үзе ясаган булырга тиеш. Кыска гына гомер, ә нинди ачы язмыш! Бала чагыннан ук күпме «какканны-сукканны» күрмәгән ул!... Кан төкерсә дә, соңгы сулышына чаклы кулыннан каләмен төшермәгән... Күзе күпне күргән, колагы күпне ишеткән. Шуның өстенә ходай аңа сизгер акыл, көчле рух та биргән. Аның заманында төрле фикри юнәлешләр, төрле сәяси агымнар күп булса да, ул шуларның берсенә дә иярмичәтагылмыйча, дөнья турында фәкать үзенчә уйлаган, үзенчә фикер йөрткән. Барысыннан да өстен торган ул! Ихтимал, шуңа күрәдер дә ул чактагы татар дөньясы бөтен каршылыклары, бөтен якты-караңгы яклары белән үзенең тулы чагылышын аның иҗатында таба да инде. Һәм менә шушы гаять бай әдәби хәзинәдән кемнәр генә хәзер файдаланмый да, кемнәр генә үз максатына хезмәт иттерергә тырышмый?! «Тукай атеизмы» шуның кычкырып торган бер мисалы түгелме?

Тырышкан китап авторы, нык тырышкан! Күп чүпләгән Тукайдан үзенә кирәкне... Шагыйрь иҗатын өстән генә белүчеләрне (әйтик, бөтен шигырьләрен дә укый алмаганнарны) тәмам ышандырырлык. Әмма без

беләбез ич, Тукайның аллага инанып, аллага сыенып язган шигырьләрен дә. Андыйлары да аның аз түгел ич! Билгеле, китап авторы да аларга күз йомып үтә алмый, теләсә-теләмәсә дә: «Тукай иҗатында дини мотивлар да юк түгел»,— дип әйтергә мәҗбүр була. Хәтта әле, кемнәр беләндер килешкәндәй, «Тукай аллага ышанган дигән фикер табигый» дип әйтергә дә мәҗбүр... Ләкин шуның артыннан ук ул бу «табигый фикерне» тизрәк кире кагарга да ашыга. Иң элек Тукайдагы дини мотивларның кайдан килүен аңлатып, автор болай дип яза: «Сүз Тукай атеизмының чикләнгәнлеге турында бара. Дини традицияләр йогынтысыннан ул тәмам арынып җитә алмады, дингә карата килешмәүчәнлек принцибын ахырына кадәр эзлекле үткәрмәде, дини идеологиягә ташламалар ясады»... Әмма нидән килә соң Тукайның мондый «принципсызлыгы»? Баксаң ул, бичара, «эшчеләр сыйныфының тарихи миссиясен, аның пролетариат диктатурасы аша социализмга илтүче сыйнфый көрәшенең асылын тирәнтен аңлый алмаган» икән. Кызганыч, әлбәттә... Ләкин мондый үтә җитди нәрсәләр турында минем философ кеше белән бәхәскә керәсем килми. Бәлки шулайдыр, бәлки алай түгелдер, мәгәр шагыйребезне «атеист» дип атаган икән инде, аңардан бик гади бер сорауга ачык кына җавап аласым килә: йә — Тукай аллага ышанганмы, әллә ышанмаганмы?..

Билгеле ки, бу иң төп сорау һәм җавап та бик төпле, ышандырырлык булырга тиеш. Шуны яхшы аңлап булса кирәк, Ишмөхәммәтов башта К. Марксны үзенә ярдәмгә чакыра. Маркс бабай болай дип әйткән икән: «Атеизм алланы инкарь итүдән, бу инкаръ итү аша кешенең барлыгын раслаудан гыйбарәт». (Бик үк аңлап та җиткермәдем: нигә, аллага ышанучы кешенең барлыгына ышанмый микәнни?!) Әнә шуңа таянып инде Ишмөхәммәтов җавап бирергә әзерләнә: «Шушы теоретик положениене,— дип язып китә ул,— критерий итеп алып, без өйрәнелә торган проблеманы ике яклы итеп куябыз: 1) шәхес буларак Тукай аллага ышанганмы? 2) халык тормышында алла идеясенең роленә аның карашы?»

Хәзер инде бу куелган сорауларга Тукайның үзеннән җавап бирдерергә дә була. Моның өчен китап авторы шагыйрьнең «Үземнән гыйлавә» дигән ике юллык шигырен китерә:

*Ышандык бер ходайга, бер вә бардыр дип вә ялгыз, дип,*
*Сөйли тел: кайнигәч, кайне, кәләш дип һәм дә балдыз, дип.*

Һәм шушы гүя уйнап кына язылган ике юллыктан чыгып, философ иптәш үзенең гаять җитди нәтиҗәсен ясый да инде:

«Тукай бу әсәрендә гүяки: әгәр дә мин «алла» сүзен еш кулланам икән, аны алла барлыгына ышанганлыктан кулланмыйм, бары тик «кайнигәч», «кайне» сүзләрен кулланган кебек кулланам, ди. Димәк, бу әсәр нигезендә (нинди көчле дәлил! Ә. Е.) Тукай аллага ышанган дип әйтеп булмый, киресенчә, әсәрдән моңа капма-каршы нәтиҗә килеп чыга» («Тукай атеизмы», 34 бит)

Гафу итегез, әмма мондый нәтиҗә белән килешүе һич кенә дә мөмкин түгел. Бу зур ялган һәм ачыктан-ачык фальсификация!... Мин, Тукайны кече яшьтән укып үскән кеше буларак, аның аллага инанып һәм аллага сыенып язган шигырьләрен күп китерә алыр идем. (Совет заманында җыентыкларына кертелмәгән кайбер шигырьләрен дә хәтерлим әле мин). Ләкин Ишмөхәммәтов «нәтиҗәсен» юкка чыгарыр өчен шагыйрьнең күпләргә мәгълүм «Васыятем»не искә төшерү дә җитә. Соңгы юлын гына алыйк:

*Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен, күреп актык сүзем:*
*Күр, нә рәсмә тулган иман берлә Коръән садремә!*

Садремә, ягъни күңелемә, ә «әһле тәкфир» дигәне алласыз, динсез дип әйтүчеләрне аңлата; димәк, шагыйрьнең ул сүзләре аны атеист (алласыз) ясаучыларга каршы турыдан-туры әйтелә. Васыять ул — үләр

сәгатен көткән кешенең соңгы сүзе, соңгы теләге, һәм ул, һичшиксез, үтәлергә тиеш. Шуңа күрә дә Тукайны җирләгәч, Касыйм хәзрәт аның васыятен кабере өстендә кычкырып укый да.

Инде «Васыятем»нән башка алланы яд итеп язган бик күп шигырьләрен, аеруча балаларга атап язганнарын да искә төшерсәк, Тукайның «атеизмыннан» нәрсә генә кала?.. Менә мәктәпкә аяк атлап керү белән без ятлый башлаган һәм күмәкләшеп җырлаган «Туган тел»нең соңгы ике юлы:

*И туган тел! Синдә булган иң элек кылган догам:*
*Ярлыкагыл дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне ходам!*

Йә, бу юллар бала күңелендә аллага сыену хисен уятмыймыни?! Яки менә «Васыятем» белән бер елда (1909) басылган «Аллаһе тәбарәкә вә тәгаләә» исемле шигырьнең беренче юллары:

*Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!*
*Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син аллага!*

Минемчә, бу юлларны шәрехләп торуның һич кирәге юк. Инде уйлап карыйк; үзе аллага ышанмаган шагыйрь балаларны ышанырга өндәп шигырь яза алыр идеме? Бигрәк тә һәр төрле яраклашудан өстен торган Тукай?.. Әгәр без бер генә минутка Ишмөхәммәтов нәтиҗәсе белән килешсәк, Тукаебыз кем — сабыйларны да алдый алучы икейөзле, бик түбән бер кеше булып чыга түгелме соң?!. Бу бит бөек Тукайны соң дәрәҗәдә хакарәтләү була ләбаса!.. Китап авторы әзрәк шуны уйлый белде микән?

Ләкин аның бик гайрәтләнеп, бездән шагыйрьнең дингә, муллаларга, байларга каршы язган ачы тәнкыйтьләрен кая куясыз, дип соравы мөмкин. Әйе, Тукайда күп алары да һәм берәү дә моны инкарь итәргә җыенмый... Тукай бит ул татар халкының көчле уяну вакытында мәйданга күтәрелеп чыккан һәм милли азатлык белән социаль гаделлекне үзенең иҗатында бик нык үрә белгән шагыйрь. Әмма аның тәнкыйть сүзләре, Ишмөхәммәтов язганча, «Урал» үрнәгендә диннең капиталга хезмәт итүен яхшы аңлауданмы, әллә булмаса, искелекнең, наданлыкның милли прогресска киртә булып торуын җимерергә теләүдәнме туганнар?.. Миңа калса, соңгысы дөресрәк булырга тиеш. Чөнки, беренчедән, бик кыска гомерле «Урал» гәзитәсенең Тукайга нинди дер җитди йогынты ясавына ышануы читен; икенчедән — бусы иң мөһиме — алланы яд иткән шигырьләренең бик күбесе «Урал»дан соң язылганнар. Шулай булгач, нинди үрнәк, нинди йогынты турында сүз булырга мөмкин?..

Аннары ул заманның алдынгы әдипләре искелек тарафдарларын аз тәнкыйть иткәннәрмени, мәгәр берәү дә бит аларны «алласызлар» дип игълан итәргә ашыкмый. Ни өчен әле бер Тукайга гына мондый мәртәбә?.. Чөнки Тукай ул — татар халкының аңында һәм йөрәгендә сакланып килгән иң якын, иң кадерле зат иясе. Менә ни өчен аны безнең коммунистик идеологиягә ныграк бәйләү кирәк тә булган. Әмма бер шарт белән — революцион-демократ булу өстенә, ул әле атеист та булырга тиеш!

Тик шулай да күрәләтә ялганга бару нигә кирәк иде? Нигә Тукайның рухи халәтенә саграк килеп, аны тирәнрәк аңларга тырышып карамаска? Кешенең рухи дөньясы бик катлаулы, бик серле, кайчагында ул үзе дә аңлап бетерә алмый аны... Чынлап та, «Болгар»ның тар бүлмәсендә яткан, мәчетләргә йөрмәгән, мәгәр Коръәнне укырга яраткан, кайбер харәм эшләрдән дә тыела белмәгән хөрлек сөюче Тукай шулай да ни өчен әле аллага инанган, аллага сыенган? Моңа җавапны, бәлки, аның ачы язмышыннан — ятимлегеннән, ялгызлыгыннан, әҗәленә тигән авырудан эзләргә кирәктер. Ни үкенеч, шундый иртә ачылган даһилык, ту-

мыштан ук гарше әгъләләргә җилкенгән күңел, ә яп-яшь көенә аны нинди тәкъдир көтә?.. Караңгы салкын кабер... Мондый хәлдә ничек итеп ул изге бер кодрәт иясенә сыенмасын, шуңардан үзенә юаныч өмет итмәсен ди?!..

Тукайның «Васыятем» белән бер айда «Әлислах»ның бер үк санында басылган «Күңел» шигырен генә алып карагыз. Бу ике шигырь арасында шагыйрьнең шул чактагы рухи хәлен аңлаткан тирән уртаклык бар.

*«Инкисар ит гадәтеңчә, ян күңел, сызлан күңел!*
*Күп соекледер бөтеннән — таңрега сыенган күңел.»* —

дип башлана ул... Күрәсез, бер үк вакытта язылган ике шигырендә дә Тукай үзенең таңрегә инанганын һәм сыенганын ачыктан-ачык әйтеп тора. Әйе, тагын ни кирәк? Мисалларның китерелгән кадәресе дә җитәр шикелле — калганын һәркем үзе дә табып укый ала. Монда иң мөһиме, Тукайдан идеология эзләү белән генә чикләнмичә, аның рухи халәтен тоя-аңлый белү дә кирәк. Шул чакта гына чын хакыйкатьне дөрес чамалап булачак.

Болар барысы да фәлсәфә укытучысы Ишмөхәммәтовның китабын укыгач, табигый рәвештә үзеннән-үзе күңелемдә туган уйлар. Кабатлап әйтәм, сүз 1971 елда чыккан китап турында бара. Әмма ләкин югарыда изһар ителгән уйларым, гәрчә егерме елдан соң язылса да, турыдан-туры шул чактагы кичерешләрем белән бик нык бәйләнгән... Дөресен әйтим, ул кичерешләр миңа бер дә тынгы бирмәделәр. Бездә бит тарих һәм әдәбият өлкәсендәге «фәнни хезмәтләр»дә ялган — фальсификация белән шөгыльләнү аз булмады. Ахырда менә Тукайны чүт ли большевикка әйләндереп, алланы инкарь итүче дәһри дә ясадык. Әйе, бу да оят белмәгән әрсез ялган түгелмени?!...

Билгеле, мондый ялган белән килешеп, дәшми калуны акыл да, намус та күтәрә алмый иде. Ничектер — язып мы, сөйләпме — мин үз сүземне әйтергә тиеш идем. Шунсыз күңел һич тә тынычлана алмас кебек иде. Мәгәр матбугатка ышаныч аз. Идеология сагында торучыларның миңа сүз бирүләре бик икеле... һәм мин сүземне язучылар җыелышында әйтергә булдым. Тукаебызга кагылган шундый нечкә мәсьәлә, минем уемча, аларны һичшиксез кызыксындырырга тиеш иде.

Җыелыш, башта әйткәнемчә, 71 елның җәендә, дөресрәге август аенда булды шикелле — шулайрак хәтеремдә калган[1]. Тукай клубында халык шактый иде — «Аккош күлен»дә һәм үз дачаларында ял итүчеләр дә килгәннәр иде. Җыелышның нинди уңай белән чакырылганын хәзер инде хәтерли алмыйм, ләкин башта ук әзерләнеп килгән чыгышымның көн тәртибенә сыйганын яхшы хәтерлим. Чөнки бу мине борчып торган мәсьәлә иде. Чыгыш ясарга яраганлыгын белгәч тә мин сүз сорап, президиумга записка да җибәрдем. Һәм ни хикмәттер, миңа сүзне озаклamый бирделәр дә.

Тагын шуны да әйтергә кирәктер: ул елларда әле минем үз замандашларымның да һәм үземнән өлкәннәрнең дә бик күбесе исән-саулар иде. Алар алдына чыгып сөйләвем беренче генә түгел, яхшы беләләр мине, шулай ук төрлесе төрлечә уйлыйлар да минем хакта. Без кичергән чорыбыз өчен бу бик табигый хәл иде... Менә мин яңадан шул замандашларым алдында.

...Минем кулымда чыгышымның алдан әзерләп килгән кыскача гына тезисы бар иде. Шуның буенча мин өч мәсьәләгә тукталырга тиеш идем: 1) Аллага мөнәсәбәт. 2) Дингә мөнәсәбәт. 3) Дин әһелләренә мөнәсәбәт.

---

1 Җыелыш протоколын эзләтеп карасам да, хәзергә әле уп табылмады. Ә. Е.

Билгеле инде, 10—15 минутлык чыгышта әйтәсе килгәннәрнең барысын да әйтеп бетереп булмый; шулай ук кулдагы тезис буенча гына да барып булмый — аны бер читкә куеп, тизрәк башыңа килгәнне әйтеп калырга ашыгасың... Сөйләү осталыгы да мактанырлык түгел, тотлыгам, кабаланам, сузып сөйлим. Вакытны да һич чамалап булмый, шуңадыр ахрысы минем алдыма: «Әмирхан абый, бәлки җыйнаклый төшәрсез»,— дигән записканы да тиздән китереп салдылар. Мәгәр монысы вакытны күп алудан гына түгел иде шикелле...

Хуш, нәрсә әйтеп өлгердем мин?.. Әгәр моны искә төшерә башласам, моңарчы язганнарны яңадан кабатларга туры килер иде. Төп максат исә минем Тукайның аллага ышанган шагыйрь булуын исбат итәргә тырышу иде. Калган ике мәсьәлә буенча мин китап авторы белән зур бәхәскә кереп тә тормадым. Әйе, дидем мин, Тукай дини хорафатларны, реакцион дин әһелләрен күп тәнкыйть иткән, ләкин нинди караштан чыгып — автор язганча, диннең капиталга хезмәт итүен нәкъ большевикларча аңлапмы, әллә булмаса, көчле уяну чорын кичергән татар халкының тәрәккыятына комачаулык итүчеләрне, һаман да искелеккә тартучыларны фаш итү максаты беләнме — бу икенче мәсьәлә, моны һәркем үзенчә аңлата ала. Әмма дә динне, муллаларны тәнкыйть итү — ул әле алладан ваз кичү түгел. Дини догмаларны тәнкыйть итеп тә, аллага ышанучылар тарихта аз булмаган. Тукай яшәгән заманда моның бик ачык үрнәге — Лев Толстой. Шушы бөек зат гомере буенча диярлек рәсми чиркәүне һәм аның иң югары әһелләрен рәхимсез тәнкыйть итеп килде. Шуның өчен аны, бәддога укып, чиркәүдән аердылар. Әмма Толстой соңгы сулышына кадәр аллага беткәнче ышанган кеше булып калды. Һәм берәүнең дә башына аны атеист итү кебек тузга язмаган уй килмәячәк.

Ә ни өчен әле без Тукаебызны ансат кына атеистка, ягъни алласызга әйләндерәбез? Шул ук Толстойга Тукайның мөнәсәбәте үзе генә дә безгә аны дөресрәк аңларга ярдәм итмимени? Бөек философ-әдипнең тирән мәгънәле аерым фикерләрен шигырьгә салган Тукай аның үлү хәбәрен, ниһаять, ишеткәч: «...Русиянең мөхтәрәм мөхәррирләреннән тезелгән мөбарәк тәсбихның очындагы бисмилласы, Мәрьям анасы, яки имамы өзелде»,— дип язды түгелме соң? Алласыз кеше бу очракта дини төшенчәләрне шулай рәттән кулланып язар идемени?..

Безнең шагыйрьнең аллага инануын, аллага сыенуын бик күп шигъри юллары, бигрәк тә балаларга атап язган шигырьләре ачыктан-ачык әйтеп торалар ич!.. Һәм мин кире кагуы мөмкин булмаган дәлилләр рәвешендә, вакытка сыйган кадәр, аның «Васыятем»ен дә, балалар өчен язылганнарын да укып күрсәттем. Иң ахырдан Ленинның «правда не должна зависеть от того, кому она должна служить» дигән сүзләренә таянып, мин Тукайга карата да бер төрле дә, аз гына да ялган булмаска тиеш, дидем.

...Сүземне тәмамлагач, сәхнәдән төшеп, үз урыныма барып утырдым. Дулкынлануым көчле булган икән, һаман үземне тынычландыра алмыйм, хәтта бер теземнең сикергәләп куюын да тыя алмыйм. Ә залның реакциясе нинди, бармы ул?.. Халык никтер тик кенә, тын гына утыра. Президиумда да хәрәкәт сизелми. Бу хәл миндә гаҗәпләнү катыш ниндидер бер ямьсез шик тудырды: мин сөйләгәннәрнең аз гына да тәэсире булмады микәнни? Сүз бит Тукай турында, нинди дә булса бер реакция уятырга тиештер бит инде ул! Ләкин ни өчен бөтенесендә дә мондый салкын битарафлык?.. Янәшәмдә утыручылар да гүя шул битарафлыкны бозмас өчен таш сындай селкенмиләр дә...

...Президиумга карыйм. Анда кимендә биш-алты кеше утыра. Хәзер инде мин шуларның икесен генә хәтерлим: урта бер җирдә, өстәлгә кулларын җәеп салып, туп-туры залга карап, Гариф Ахун утыра; өстәл очында, аз гына читтәрәк, үзен кочаклагандай беләкләрен тотып, авыр

башын ия төшеп, алдына гына карап Хәсән абзый Туфан утырган...Ниләр уйлый икән аның чал башы?!..

Күпмедер авыр тынлыктан соң президиумда утыручылардан кемдер бераү, ниһаять, торып сүз башлады. Кем иде соң ул? Һич кенә дә бит исемә төшерә алмыйм. Гариф Ахун түгел иде микән? Аның сөйләгәнен хәтерлим, ләкин беренче булыпмы — тәгаен генә әйтә алмыйм... Кызганычка каршы, мин җыелышлардагы чыгышларны язып барырга өйрәнмәгәнмен, ә 20 елдан соң барысын да төгәл искә төшерү мөмкин түгел икән. Әмма бер нәрсәне бик ачык итеп әйтә алам, ул җыелышта башлап сөйләүченең дә, аңардан соң чыгучыларның да әйткәннәре барысыныкы да бер төсле булды: Тукайның аллага ышануын исбат итеп маташу нигә кирәк әле? Тукай безнең өчен аллага ышануы белән кадерлеменни?.. Шуның белән бөекмени ул? Һәм, гомумән, Тукай иҗатының дини ягына игътибарны туплауны берничек тә аклап булмый. Кыскасы, Еникинең бүгенге чыгышы урынсыз һәм кирәксез бер чыгыш, иптәшләр!

Ахырдан гына Хәсән абзый да торып сөйләде. Тукайны бик яхшы белүче һәм бик яратучы дәшми калуны килештермәгәндер инде. Аның нәрсә әйтәсен көтеп утыручылар да булгандыр — ул шуны да, ихтимал, сизгәндер... Дөресен генә әйткәндә, аның хәле шактый четерекле иде — мин моны сөйли башлавы белән үк сизеп алдым. Нәрсә диде ул, безнең күп газап кичергән шагыйребез?

— Тукайның бит «Васыятем»еннән башка «Мөхәрриргә» дигән шигыре дә бар ич!.. Без әнә шуны күбрәк истә тотарга тиешбез — дини рухтагыларын түгел, ә гражданлык рухындагыларын...

Менә аның китергән мисалы һәм әйткән фикере шул. (Билгеле, мин монда төп мәгънәсен генә китердем.) Мәгәр Тукайның «Мөхәрриргә» дигән шигыре турыдан-туры Гаяз Исхакыйга атап язылганын Хәсән абзый белергә тиеш иде. Чөнки моннан берничә ел элек кенә Ташкенттан Казанга килеп киткән, кайчандыр Гаязга бик якын торган Шакир карт Мөхәммәдъяров Хәсән абзый бүлмәсендә сөйләшеп утырганда (Маяковскийда торган чагында) безнең икебезгә ул шигырьнең махсус Исхакыйга атап язгылганын, һәр юлын укый-укый, бик әйбәт аңлатып биргән иде. Онытты микәнни, әллә онытмаса да кыюлыгы җитмәме?.. Шигырьнең бит кемгә атап язылганы Тукай томнарындагы искәрмәләрдә юк. Шулай булгач, җыелышта утыручыларның да бик күбесе аны белми торганнардыр — инде белсәләр дә Хәсән абзыйга берәр төрле гаеп ташлау мөмкин булмас иде. Чөнки Тукайның һәр җыентыгына кергән шигырен Гаяз Исхакый исеме белән бәйләү үзе гаять зур гаептән саналыр иде... Хәлбуки, ул шулай; охранка күзәтүе аркасында күп вакытын читтә үткәрергә мәҗбүр булган мәшһүр мөхәррирне Тукай чакырып-дәшеп яза:

*И мөхәррир! Кайсына биргән яшен күз кибриа!*
*И мосаувир! Кемгә биргән пакъ вә чын сүз кибриа!*

*Кайт әле монда ватанга, кайт әле, саргайтмәле!*
*Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы кер, рия!*

*Җанлырак тормыш та бетте, шанлырак бер эш тә юк,*
*Бер-берен чәйни бишенче елдагы күп әүлия.*[1]

*Алты ел торды чупансыз, айрылышты яшь көтү;*
*Карт бүре күк, бары корган айрым-айрым бер оя.*

*«Ул Гомәрдән курка шайтаннар» дигән төсле рәсүл,*
*Бер карашың иң шомд ялганчыны сүздән тыя...*

---

[1] Бу юллар безнең хәзерге заманга да гаҗәп туры киләләр; кичәге коммунист җитәкчеләр бүген бер-берсен чәйнәмиләрменни?! (Ә. Е.)

Гаҗәеп шигырь!.. Нинди тирән хөрмәт һәм өмет булган Тукайда Гаяз Исхакыйга карата!.. Хәзер инде бу исбат ителгән бәхәссез хакыйкать.

Ярый, булмаса яңадан Тукай клубындагы җыелышка кайтыйк әле... Күрдегез инде, бөтен сөйләүчеләрнең дә минем чыгышка мөнәсәбәте бер төсле булды; нигә кирәк, ни әһәмияте бар, урынсыз чыгыш!.. Миңа кушылучы, һич югы мине аңларга тырышучы берәү дә булмады. Тулы бердәмлек! Йә хода, дип сыкранып утырам, сүз бит Тукайның аллага ышануын аклау турында бармый, ә бәлки бөек шагыйрь турында бары тик саф дөресен язу кирәклеге турында бара. Неужели шуны аерып булмый, бик ачык әйттем ләбаса!.. Юк, хикмәт монда мине аңламауда түгел шикелле. Төп сәбәп тирәндәрәк ята булса кирәк, чөнки берәү дә минем белән килешмичә, Тукай, әлбәттә, аллага ышанмаган, дип әйтмәде. Шулай ук мине чыгып сөйләргә мәҗбүр иткән китап турында да ләм-мим!... Әллә берсе дә күрмәгән-укымаган, әллә инде Тукайны марксист итәргә тырышучы галимгә каршы чыгуны кирәк тапмаган?! Гаҗәп түгел... Уяулык белән саклык безнең гамәлләрдә ул чакта һәр вакытта алдан йөри — без моңа күптән өйрәнеп беткән идек инде.

Шулай итеп, мин, дөреслекне яклыйм дип, башыма бер дә кирәкмәгән авыр газап алдым. Җыелыштан рухи кыйналып, тәмам ватылып кайттым. Икенче көнне нәшриятта эшләүче шагыйрьдән, дачада очрашкач, юри генә:

— Йә, кичәге җыелыш синдә нинди тәэсир калдырды, — дип сораган идем, ул чыраен сыта биреп, бер генә сүз белән:

— Кызганыч! — диде.

— Нәрсә... кызганыч?

— Сезнең чыгышыгыз.

Шулай ук та мыни әле?!.. Бу инде чөй өстенә тукмак булып төште... һәм мин берничә көннәр буена һаман бер нәрсәне уйлап баш ваттым: хатам минем нәрсәдә, кайсы ягы белән чыгышым кешеләргә бу хәтле ошамады икән?.. Әйтергә теләгән фикеремнең дөреслегендә бөртек тә шигем юк. Алайса хикмәт нәрсәдә?.. Бәлки, чыгышымда акцентларны дөрес куя белмәгәнмендер?.. Моның әһәмияте зур, кешеләр бит сүзеңә карап кына түгел, ничегрәк итеп әйтүеңә карап та хөкем итәләр... Бәлки Тукайның томнарына кермәгән шигырьләрен укуым да күпләргә ошап бетмәгәндер. Нәтиҗәдә, Тукай бер яклырак — артык динлерәк килеп чыккандыр... Моны яратмаулары бик мөмкин.

Әмма ләкин эшнең асылы минем ничек сөйләүдәмени, мин күтәреп чыккан мәсьәләдә түгелмени?!.. Сүз нигә шул хакта бармый, нигә барысы да бер балык башын чәйни — кирәкми, ярамый, имеш!.. Бу бит төп мәсьәләдән качу!.. Йә, кем кызганыч — алармы, минме?!..

Әнә шулай күпме генә баш ватсам да, төрлечә уйлап күпме генә үземне газапласам да, акылым минем, компас теле шикелле чайкала-чайкала да, һаман бер юнәлеш ноктасына килеп төртелә: кем хаклы — минме, әллә теге, кем үзе, философ иптәшме?.. Менә шуны кемнәндер әйттерәсем килә. Әйдә, ул кем дигәнем, миңа каршы сөйләүчеләрнең күбесе шикелле үк, коммунист булсын, идеологиясе дә бик төзек булсын, тик Тукайны яхшы белсен дә, дөресен әйтүдән курыкмасын!.. һәм, ничектер, үзеннән-үзе минем исемә кылт итеп Сәйфи агай Кудаш килеп төште. Гаҗәп тә түгел, чөнки ул — читтә яшәүче, бездәге хәлләргә бер төрле дә мөнәсәбәте юк, димәк, аңа чын үз фикерен әйтү бер дә читен булмаячак. Аннары иң мөһиме — ул исәннәр арасында иң карт шагыйрь, Тукайның замандашы диярлек, Тукай иҗатын энәсеннән-җебенә чаклы белүче дә... Менә кемгә мөрәҗәгать итәргә кирәк, дидем мин бер дә икеләнмичә.

Мәгәр мөрәҗәгать хатымны Сәйфи агайга ни өчендер 3 октябрьдә генә җибәргәнмен. Күрәсең, уйланып йөрү дә һәм утырып язу да бик озакка сузылган. (Гадәтем шундый — уйлаганны тиз генә әйләндереп са-

ла белмим.) Кызганычка каршы, хатның күчермәсен үземдә калдырмаганмын, ничегрәк, нинди сүзләр белән язылгандыр инде ул — хәзер, билгеле, исемә төшерә алмыйм. Сәйфи агада сакланса, дөньяга бәлки бер килеп тә чыгар әле.

Билгеле, мин хатыма җавапны ышанып көттем, чөнки моңа кадәр дә аңа язган хатларым бервакытта да җавапсыз калмый иде. Сәйфи агайның, хат язу минем өчен иҗат эше ул, дип әйткәне дә бар иде. Ә монда Тукай мәсьәләсе! — картны ул, һичшиксез, кузгатырга тиеш иде.

...һәм менә аның 15 октябрь куелган 34 битлек хаты озакламый миңа килеп тә җитте. Гаҗәеп бер хат бу!.. Иң элек минем хатым Сәйфи агайның бик борчулы һәм мәшәкатьле чагына туры килгән. Җәмәгате Мәгъфүрә апа каты авырып киткән булган. Сәйфи агай көне-төне диярлек авыру карчыгын карау-дәвалау хәстәренә керешкән. Мондый чакта каяндыр, кемнәндер килгән хатны онытып тору да бер дә гаеп булмас иде. Ләкин кайгысы-мәшәкате ни хәтле генә зур булуга карамастан, Сәйфи агай минем хатны бер генә минут та онытып тора алмаган. «Чөнки Тукай мәсьәләсе безнең үз язмышыбыз. Тукай — халкыбызның вөҗданы, намусы һәм иманы!. Шуңар күрә мин мондый вакыйгаларга тамашачы булып кына кала алмыйм»,— дип яза ул җавап хатының башында ук. Әйе, минем мөрәҗәгать хатым карт шагыйрьне чын-чынлап дулкынланырга мәҗбүр иткән икән; «Әгәр дә дулкынланмасам, бу хатны язарга кулга каләм дә алмаган булыр идем мин»,— ди ул үзе дә. Һәм бераздан янә өстәп яза: «Синең хатыңны укыгач, мин башка эшләрне баштан чыгардым. Тик Мәгъфүрәнең генә кәефе начарланмасын! Мине хәзер ике нәрсә биләп алды: Тукай һәм аның намусын, сафлыгын һәм дөреслеген яклаган өчен әрләнгән Әмирхан Еникиев дигән язучы биләп алды». (Җәя эчендә генә шуны да әйтеп узыйм: күптән түгел Казаннан килеп киткән, миңа һәрвакыт тискәре караган бер әйбәт шагыйрь: «Без әле үзебездә Әмирхан Еникине тәмам хур иттек»,— дип сөйләнеп йөргән. Бу хәбәр дә, хаттан күренгәнчә, Сәйфи агайның колагына килеп кергән икән.)

Әнә шул рәвешчә кайгысы зур чакта, эш-мәшәкатьләр арасында Сәйфи агай ирексездән күңелендә туганнарын ак кәгазьгә салыр өчен үзенең 34 битлек хатын язарга керешә дә инде. Билгеле, мондый озын хатны ул берничә көннәр буена, бүлә-бүлә, хәтта бер кичне дачасына китеп, ялгызы Тукай рәсеме каршысына утырып та яза. Хатның эчтәлеге гаять бай: Тукайның үзе, иҗаты, яшәгән заманы, шулай ук аның исеме тирәсендә төрле заманда булып узган бәхәс-карашлар турында, аннары Сәйфи агайның Тукайга шәхсән үз мөнәсәбәте турында да бик иртә тәңресенә юнәлгән үксез-ялгыз шагыйребезгә карата әрнүле тирән йөрәк җылысы белән бик тәфсилле итеп язылган... Әмма мин, бик теләсәм дә, бу хатны иясе исән чакта, аның рөхсәтеннән башка дөньяга чыгара алмыйм. Иске әлифбада кулдан язылган хатның күчермәсен машинкада бастырып, Сәйфи агайның үзенә җибәргән идем, иншалла, дөньяга бер чыкмыйча калмас дип ышанам.

Хәзер исә мин үзем кузгаткан мәсьәләгә ачык җавап булырдай урыннарын күчерү белән генә чикләнәм. Иң элек Сәйфи агай «Тукайның дини хиска сугарылган һәм алла кодрәте алдында баш игән шигырьләрен»нән күп кенә аерым юлларны тезеп чыга. 32 шигырьдән ул, махсус сайлап тормыйча, бары күзенә ташланганнарын гына күчереп алган. Һәм бу шигырьләр барысы да бишенче елдан соң, «Урал»да чыгуыннан туктагач, 1908 белән 13 еллар арасында (үлгән көненә кадәр) язылганнар. Ягъни алар Тукайның шагыйрь һәм акыл иясе буларак тәмам җитлеккән, фикри хөрлеккә ирешкән чагына туры киләләр.

Сәйфи агай әлеге шигъри юлларны китергәннән соң менә нинди нәтиҗә ясый: «Тукайның халык күпчелеге тарафыннан шулай бик тиз танылуын, сөелүен һәм табыныр дәрәҗәдә культка әйләнүен, мин үзем

шушы рухтагы шигырьләрнең катнашуыннан башка күз алдына да, акыл капкасы төбенә дә китерә алмыйм».

Янә болай диеп тә яза: «Әгәр дә Тукай шушы шигырьләрен язмаган булса, киң халык катламы аны ул чакта шулай кабул итмәгән һәм йөрәк кәгъбәсенең түренә утыртып та куя алмаган булыр иде!» Димәк, Сәйфи агай Тукайның халык шагыйре булып танылуын турыдан-туры дини рухтагы шигырьләре белән дә бәйләп карый.

Шулай да Тукайның андый рухтагы шигырьләрен халык ни өчен шулкадәр яраткан, күңеленең түрендә саклаган, күбесен яттан белгән — бигрәк тә балаларга атап язганнарын?.. Моның сере нәрсәдә?..

Сәйфи агай моны болай аңлата: «Алар (ягъни ул шигырьләр) дини, илаһи булулары белән түгел, бәлки балаларда сафлык, пакьлек, тугрылык, аңлылык, туганлык, кешелеклелек, намуслылык һәм ата-анага, олыларга хөрмәт итү тойгылары тәрбияләүләре белән әһәмиятлеләр»... һәм бу аңлату белән килешмичә һич мөмкин түгел — кайсыбыз гына бала чагыбызда тәңрене даими исебезгә төшерүче Тукай абыебыздан әхлак сабагы алмадык соң?!

Сәйфи агай хатыннан мин тагын бик күп өзекләр китерә алыр идем, ләкин чикләнергә мәҗбүрмен. Хат Тукайның аллага, дингә мөнәсәбәтенең бик күп якларына кагыла, бик күбесен үзенчә аңлата, ләкин боларның барысы белән дә танышыр өчен хатның үзен укып чыгу кирәк. Әйткәнемчә, киләчәктә мондый мөмкинлек, һичшиксез, туар.

Инде монда китерелгән кадәресе безне кызыксындырган мәсьәләгә, минемчә, тулы ачыклык кертте: Сәйфи агай да Тукайның аллага инанган һәм сыенган шагыйрь булуын раслый, шуны күп дәлилләр белән исбат итә. Янә иң мөһиме — Сәйфи агай хатын укыганнан соң, мин Тукайның аллага мөнәсәбәтен тагы да тирәнрәк аңлагандай булдым. Татар халкы бит күпме гасырлар буена аллага инанып яшәгән, авыр язмышын да, киләчәккә ышанычын да аллага багълаган һәм бу аның какшамас иманына әверелгән. Менә шуны бик яхшы белгән, бөтен барлыгы белән тойган Тукай да, билгеле инде, халыкның иманына тугрылыклы булып калган. Әмма бу иман аңа үз заманының иң алдынгы фикер иясе булырга, халыкның аңын томалап торган бөтен искелекне, динне кәсепкә әйләндерүне, наданлыкны, түбәнлекне, бозыклыкны кодрәтле каләме белән көйдерергә һич тә комачаулык итмәгән. Ул бит чын мәгънәсендә милли азатлык, социаль гаделлек, рухи тазалык җырчысы иде.

Сәйфи агай хаты минем хаклы булуымны раславы белән күңелемне тынычландырса да, мин әле һаман да башымнан кичкән хәл турында гаҗәпләнеп уйланудан туктый алмый идем. Әлеге җыелышта утыручыларның күбесе, бигрәк тә өлкән яшьтәгеләре, Тукай иҗатын Сәйфи агайдан ким белми торганнардыр лабаса. Бәлки әле Тукайның аллага мөнәсәбәтен дә нәкъ аныңча аңлый торганнардыр. Ләкин ни өчен соң алар Сәйфи агай кебек чын уйларын әйтергә теләмичә, барысы да миңа каршы чыктылар? Кайда, нәрсәдә моның төп сәбәбе? Һәрхәлдә, Тукайны алласыз дәһри дип тануда түгелдер инде. (Берәү дә бит ачыктан-ачык алай дип әйтмәде.) Төп сәбәп — чын хакыйкатьне белеп торган хәлдә, аны икърар итәсе килмәүдә түгел микән?.. Без бит үзебез өчен уңайсыз, әйтик, намусыбызга кагыла торган дәреслекне күрмәмешкә салынырга күптән өйрәндек.

Гаҗәп, кайчагында без гади генә нәрсәне дә аңлый алмыйча җәфаланабыз. Менә минем белән дә шулай булды. Туктале, мин әйтәм, җыелышта утыручыларның һәммәсе дә алласызлар ич! Җитмеш-сиксән проценты коммунистлар, болар инде ата дәһриләр... Башкача булуы мөмкин дә түгел. Чөнки большевиклар властьны тартып алган көннән башлап, без халыкны диннән, алладан биздерү шартларында яшәп киләбез. Динне, дин әһелләрен төрлечә кысу, чикләү һәм хурлау большевикларның көндәлек сәясәтенә әйләнде. Ахыр чиктә, бөтен җирдә

мәчетләрне ябып, муллаларын сөреп яки үтереп бетерделәр. Билгеле, бу барлык диннәргә карата да шулай эшләнде. Бөтен империя күләмендә дин корытылды, бары кайбер җирләрдә генә аның зәгыйфь учаклары сакланып калды. Советлар Союзы тоташы белән диярлек алласызлар иленә әверелде.

Инде язучыларга килсәк, алар бит әнә шул дәһрилекне (фәнчә әйтсәк, атеизмны) рәсми сәясәткә әйләндергән коммунистик идеяләргә бил бөгеп хезмәт итүчеләр. Бәс шулай булгач, совет язучысының аллага ышануы асла мөмкин түгел. Теләсә-теләмәсә дә ул алладан ваз кичәргә тиеш. Безнең берише картырак әдипләребез исә, кайчандыр шәкерт чакларында тәһарәт алып мәчеткә йөрүләренә карамастан, революция булу белән үк диннән һәм алладан тизрәк ваз кичтеләр. Күрәсең, алар моны үзенә күрә бер рухи азатлык дип кабул иттеләр. Һәм шул «шатлыктан» динне корытуда шактый активлык та күрсәтеп өлгерделәр. (Моның өчен ул елларда язган әсәрләрен искә төшерү дә җитә.)

Минем яшьтәгеләргә исә дин йогынтысы бик аз тиде. Мәктәпләрдә дин сабагы укыту бетерелде. Мин үзем, мәсәлән, динне ике генә кыш укып калдым. Аннары безнең яшьлек комсомол көчәеп киткән вакытларга туры килде. Ә комсомол булып йөрүчеләр өчен агрессив дәһрилек зур җегетлектән санала иде.

Шуннан совет чорында дөньяга килеп, сугыштан соң әдәбиятка аяк баскан яшьләрне алсак, алар инде тумыштан ук дәһриләр. Чөнки күбесенең ата-аналары алласыз, ягъни атадан балага күчкән дәһрилек. Кайчандыр аллага ышану буыннан-буынга күчеп килгән булса, безнең нисбәттән бик кыска совет чорында да алласызлык шундый ук күренешкә әйләнде, дияргә ярый.

Инде Тукайга мөнәсәбәт мәсьәләсенә килгәндә, безнең алласыз язучыларыбыз һәммәсе дә аны халкыбызның иң сөекле бөек шагыйре дип таныйлар, аның даһилыгы алдында берсүзсез баш иялар. Бу инде бәхәссез хакыйкать!

Һәм менә мин, алар шикелле үк күптән алланы оныткан бер язучы, Тукай мәсьәләсендә аларның объектив гадел хөкемнәренә ышанып, Тукай атеист (ягни алланы инкарь итүче) дигән ялганга каршы чыгуны шулай да кирәк таптым. Һәм мөхтәрәм язучыларның минем чыгышны ничек, нинди канәгатьсезлек белән каршы алуларын сез күрдегез инде.

Ничек кенә аңларга соң бу һич көтелмәгән феноменны?.. Озак газаплы уйланудан соң, мин ахырда шундый нәтиҗәгә килергә мәҗбүр булдым: күрәсең, Тукайның аллага ышануын исләренә төшерүне алар үз вөҗданнарына кагылу, үз намусларына тукыну шикеллерәк кабул иттеләр. Чыннан да, Тукайның алланы инкарь итмәвен исбатлап тору, бигрәк тә дини шигырьләрен укып күрсәтү аларга нигә кирәк? Болай да беләләр ич! Ә менә Ишмөхәммәтов язганча, Тукай чынлап та алласыз дәһри булса, аларның җаннары тынычрак булыр иде... Әнә шул рәвешчә, моннан егерме ел элек мөхтәрәм язучыларыбыз җан тынычлыгын саклау өчен һәм безне тәмам биләп алган рәсми идеология хакына, Тукай турындагы ялганны, теләпме-теләмичәме, күмәкләшеп якларга мәҗбүр булдылар. Дөреслектән качуны мин башкача аңлый да алмыйм, аңлата да алмыйм.

*1991 ел, август.*

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Азат Әхмәдуллин,**
филология фәннәре докторы

# ТАРИХНЫ ЯҢАДАН ЯЗГАНДА...

Совет чоры драматургиясенең тарихы дистә еллар буе төзелде һәм язылды. Бер системага китерергә тырышылды. Бу эштә аерым уңышларга да ирешелде. Ләкин кичә уңыш дип саналган аерым урыннарда хаталар да, ялгышулар да җибәрелгән. Инде шуларны озакка сузмыйча төзәтергә кирәк. Әмма озак еллар төзегәнне тиз генә ватып, яңаны төзүгә омтылу һәрвакыт уңышлар гына китерми. Бу процессның никадәр авыр булуын без инде илебез мисалында күрдек. Октябрь революциясеннән соң ил һәм халыклар өстеннән узган вату-җимерү туфаны әле бүген дә эзләрен саклый.

Яңаны төзегәндә, әлбәттә, материал яңа булса яхшы. Шуңа да драматургиябез тарихын яңача язганда, иң беренче чиратта, яңа материалга мөрәҗәгать итү мөһим. Ә ул бездә бар! Әле материалның ниндие генә, затлысы — Гаяз Исхакый драматургиясе! Совет чоры әдәбияты тарихында бу олы язучының үлмәс мирасыннан килгән традицияләр, аларның ни дәрәҗәдә уңышлы дәвам иттерелүе, әлбәттә, беренче дәрәҗәдә искә алыначак. Бәхеткә каршы, традицияләр белән генә дә эш бетми: Г. Исхакый 1917 елдан соң да әле җитди драматургик мирас калдырган — аның 5 драмасы һәм комедиясе бар. Шулардан өчесендә («Дулкын эчендә», 1920—37; «Җан Баевич», 1923; «Олуг Мөхәммәт», 1944—47) татар совет драматургиясенең бигрәк тә тәүге чорларында җитешмәгән яклар сәнгатьчә үтемле итеп куела. Болар — изге күңелле булу, миһербанлык, явызлыкны кабул итмәү һәм кире кагу кебек югары кешелек кыйммәтләрен яклау. Бередә социалистик революциянең бәхәсле һәм, кызганычка каршы, берьяклы үстерелгән мәсьәләмаксатларын ачык итеп кую, хәтта урыны белән кире кагу да бар. Димәк, реаль чынбарлыкны дөрес һәм тулы чагылдыруга омтылу ягыннан татар драматургиясенең тагын да бер җитди тармагы бар. Хәзер аны милли драманың үсеш концепциясендә җентекле өйрәнү нәүбәттәге бурыч булып тора.

Соңгы 70—80 ел эчендә чит илләрдә яшәгән милләттәшләребез тарафыннан язылган сәхнә әсәрләре булуы да мәгълүм. Мәсәлән, финляндияле Хәсән Хәмидулла пьесалары. Аларны туплау, өйрәнеп чыгу — шулай ук чираттагы кичектергесез эшләрдән саналадыр.

Болар аңлашыла, болар бәхәс тудырмый. Һәм болар, ачык ки, чагыштырмача җиңел эшләнә торган эшләрдән. Иң авыры — моңарчы кат-кат расланганнарны яңача бәяләү, кайберләрен кире кагу, аерым фактларны да, кайсыбер күренешләрне дә үзгәртеп аңлату һәм язу. Ягъни аларга чын фәнни, дөрес бәя бирү, тарихтагы урыннарын билгеләү.

Бүген аерым мәкалә һәм чыгышларда артык кайнарланып китеп, гомумән, бөтен совет әдәбиятын кире кагу, аны үткәндәге әдәбиятлардан түбән төшү, кирегә чигенү, хәтта юк әйбер, мираж дип расларга тырышулар урын ала. Моның белән килешүе кыен. Совет әдәбияты дигән күренеш бар, яши һәм яшәячәк. Дөрес, аның зур-зур кимчелекләре дә, үсеш авырлыклары да булган. Бүгенге югарылыктан аларны күрү һәм тәнкыйтьләү җиңел. Ләкин һәр нәрсәне тарихи, шул вакытлардагы шартлардан, сәяси, идеологик һәм эстетик нормалардан чыгып аңларга тырышырга һәм бәяләргә кирәк. Ул ялгышулар буш җирдә тумаганнар. Нәрсәләр тудырган аларны? Ни өчен әдәбиятыбыз һәм сәнгатебез ялгыш сукмактан кереп киткән? Боларны дөрес аңлау һәм бәяләү шул чор әдәбиятындагы аерым әсәрләрнең тарихи урынын билгеләргә дә ярдәм итәр.

Билгеле булганча, Октябрьдән соң формалашкан әдәбиятның сурәтләү объекты да, тормыш материалы да яңа иде һәм аның өчен иҗтимагый хәрәкәт тә яңа иде. Бу

яңалык, иң беренче, эшче сыйныфның җәмгыять үсешендә уйный башлаган роленнән киле. Эшчеләрнең хезмәтен, көнкүреш шартларын, шәхси һәм гомуми мәнфәгатьләрен, омтылышларын сурәтләүдә татар әдәбияты Г. Колахметов һәм Ш. Камаллар башлаганны дәвам иттерде. Эшченең тагын да бер өлкәдә — сыйнфый азатлык көрәшендә тоткан урынын кушып тасвирлый башлады әдәбият. Ләкин яңа шартларда, җәмгыять догматик идеология кочагына килеп кергәч, бу сыйныф бик тиз фетишлаштырылды. Әдәби әсәрләрдә дә ул шулай тасвирлана башлады. Башка сыйныфларның, төркемнәрнең иҗтимагый үсеш хәрәкәтендәге һәм җәмгыятьтәге урыны, роле санга сугылмый, алай гына да түгел, түбән төшереп аңлатыла иде. Менә ни өчен безнең күпчелек сәхнә әсәрләребездәге эшчеләр вәкиле — һичшиксез, акыллы да, өйрәтүче дә, җитәкче дә! Хәтта интеллигенцияне дә өйрәтә ул: яшәргә генә түгел, көрәшергә дә өйрәтә! Крестьян турында инде әйткән дә юк: эшчедән башка берни дә эшли алмый торган сыйныф ул. Хәтта җир эшкәртергә, кайчан чәчәргә, ничек урып-җыюны оештырырга кирәген дә өйрәтә эшче. «Шушы интеллигентларны артларына тибеп, партиядән куалап чыгарасы иде»,— ди Г. Колахметовның «Яшь гомер» драмасындагы эшче Вәли. Ләкин шул ук вакытта Вәли болай эшләргә ярамавын, интеллигенциянең азатлык көрәше өчен кирәк булуын да яхшы аңлый. Совет чорындагы драмаларда исә зыялыларга нәк шундый кимсетүле караш беръяклы үстерелде. Ә бит интеллигенция — милләтнең акылын, иҗат көчен, намусын үзендә туплаган катлау.

Революцияне, гадәттә, яшьләр ясый. Бездә дә революцион көрәш елларында яшьләр диктаты эш йөртте. Моның уңай ягы булган кебек, аерым кимчелекләре дә бар. Өлкәннәрнең бай тәҗрибәсен, өлешчә үлем-бетем фәлсәфәсеннән туа торган сабырлыкны, акыл белән эш йөртүне яшьләрнең кискенлеге, дөньяга мәңгегә килгән төстә хис итүе басып китте. Вату-җимерү, мәчет манараларын кисү, муллаларга, дингә каршы көрәш... Олы буын боларны шулай кискен рәвештә хәл итмәс иде. Алдагы көн турында конкрет уйлый белмәү һәм теләмәү, синнән соң тормышны дәвам итәчәк буын хакында тиешенчә кайгырта белмәү, мәңге яшәрдәй кылану — кыскасы, «үтә-революционлык», артык оптимизм бөтен яшәешне дә, әдәбият-сәнгатьне дә басып китте ул чакны. Кичәге драма әсәрләрен шул сәрем катлавыннан чистарта башласаң, аның бик калын булуын күрәсең. Пьесаларның фикеренә дә, художество эшләнешенә дә үтеп кергән ул сәрем.

Билгеле инде, бу вату-сыту фәлсәфәсе буш җирдә тумады. Хәзер социалистик революция һәм Гражданнар сугышы чорында аермачык булып күренә башлаган кансызлыкны, миһербансызлыкны большевиклардан, хәтта Ленинннан гына киле дип раслау бар. Ләкин нигез сәбәпләр тирәндәрәк, әлбәттә. М. Горький үзенең «Интеллигенция һәм революция» дигән мәкаләсендә болай ди: «...нәкъ менә социаль тигезсезлек, сыйнфый система (...) көнчелекне, комсызлыкны, явызлыкны, күрә алмауны һәм шәфкатьсезлекне уятучы булып тора да».

Сыйнфый тигезсезлек янына әле татар иҗтимагый аңының милли-дини изелүдән риза булмавы да килеп кушыла иде. Менә ни өчен, гәрчә аның асыл мәгънәсе иҗат көчләрен, яңаны төзү көчләрен уяту булса да, революция, нигездә, җәмгыятьнең рухи һәм икътисади үсеш процессын тагын да югарырак баскычка күтәрү максаты белән ясалса да, аңарда бер үк вакытта вату-җимерү омтылышы да яши, билгеле бер шартларда ул өстенлек алып китә, иске җәмгыятьне һәм, гомумән, искене җимерү романтикасы белән кушылып кечәя. Мондый көрәш романтикасы драматургияне дә илһамландырып торды, ә бераздан хәтта киресенә әверелә башлады: һәрнәрсәне җимерү, бетерү, сыту, сәбәреп түгү рухы алга серелде. 20 нче еллар драматургиясендә иң күренекле образлар тибыннан берсе булган, кешенең рухи азатлыгы кебек изге идеалны алга сөргән Кабил дә (һ. Такташ — «Җир уллары трагедиясе»), кызганычка каршы, бу омтылышында эшне туганын үтерүдән башлый, җимерүче булып алга баса. Әсәрдәге икенче күренекле персонаж — Идея образында да шул сыйфат алга чыгарыла.

Янсә бөтен әсәрләре көрәш рухы белән сугарылган язучы Г. Ибраһимовта сыйнфый нәфрәтнең чагылышына игътибар итегез. «Яңа кешеләр» драмасында Батырханның «канлы юл — изге юл!» дигән формуласы буш җирдә тумаган. «Эшче-крестьян халкына контрреволюционерларның башлары өстеннән азатлыкка барырга туры килә»,— ди ул. Дөрес, «борчылып йөреп» әйтә, әмма аның шикләнүләре шул борчылудан ары узмый, аның ышанычы — югарыдагы төп формулада. Әдәбият исә, кешелекнең зур рухи табышы буларак, иҗтимагый аңның бер төре буларак, әлеге формуланы олы гуманизм хакына кире кагарга, һәрхәлдә, аны шик астына алырга тиеш иде. Шул ук драмадагы икенче персонаж Шәйбәк картның «кан түгүгә киткәч, шәп түгел инде ул» дигән ышанычын көчле яңгыратырга тиеш иде автор. Ә бит бу фәлсәфи фикерләр бирелешендә диндар рухлы кеше итеп бирелгән Шәйбәк карт сүзләре гуманизмны яклый. Ләкин чынлыкта алай булмады. Әдәбият, шул җөмләдән драматургия дә, сыйныфлар бирелешендә пролетариатның җиңүен, еш кына канлы җиңүен ләззәтләнеп сурәтли башлар. Ф. Достоевский куйган сорау искә төшә: әгәр дә нигезенә бер генә кеше гомерен салып калдырырга туры килсә дә, сез бәхетле киләчәк архитекторы булырга ризамы? Бу сорауны бөек психолог Достоевский шагыйрь Пушкин турындагы нотыгында биргән. Монда әдәбиятның олы гуманистик вазифасы ачык чагыла.

Безнең революцион пьесаларыбызда исә бәхетле киләчәк өчен күпме гомерләр харап ителә. Әмма әлеге хәл шулай тиеш дип карала. Әдәбият, матурлык сәнгате шулай булырга тиешмени?!

Совет чорындагы әдәбиятыбызны өйрәнгәндә һәм анализлаганда без, әлбәттә, революциягә кадәрге әсәрләргә аваздаш якларны күрсәтү белән бергә, алардан аерылып торган якларга да игътибар бирергә тиеш булабыз. Поэтика өлкәсендәге мондый аерымлыкларны күрү һәм күрсәтү көч, осталык сорый. Бигрәк тә драматургиядә. Чөнки ул — шактый ук консерватив жанр. Ләкин бирелә жанр поэтикасы байый бара. Сюжет һәм композициядә дә, образлар системасында да шуны күзәтергә була. Мәсәлән, революциягә кадәргедән аермалы буларак, совет чорында драматургия күмәк күренешләр белән иркен эш йөртә, сәхнәгә катнашучылар итеп халык массасын чыгара. Бу — хәлиткеч сүзне әйтүче буларак халыкка төп рольне бирергә омтылудан килә. К. Тинчурин һәм Ф. Бурнаш, Ф. Сәйфи-Казанлы һәм Ш. Усманов, Т. Гыйззәт һәм Н. Исәнбәт сәхнәдә җанлы күмәк күренешләр иҗат итүнең матур үрнәкләрен бирделәр. Бу — бер генә мисал. Андыйларны тагын да китерергә була.

Шулай да яңа принциплар иң элек образлар системасында күренде. Кешене, аның ролен аңлауда, аны иң башта көрәшче төсендә тәкъдим итүдә булды. Мондый геройларны драматурглар башлыча түбәндәге әхлак һәм иҗтимагый нормаларга ия булган көрәшчеләр рәвешендә күзаллыйлар. Герой өчен иң изге хис, иң мөһим хис — халык бәхете өчен көрәш. Г. Коләхметов һәм Г. Исхакый пьесаларында герой характерында үзәк сыйфат төсендә күрсәтелә башлаган бу билгене совет драматурглары тагын да югарырак күтәрделәр, аны байрак иттеләр. Ләкин ике чор геройларындагы мондый сыйфатлар арасында аерымлык та бар. Совет драматурглары сурәтләгән көрәшче элеккеге, асылда зыялы көрәшчедән үзенең туры сызыклырак, хәтта бәгырьсезрәк булуы белән, үзе өчен көрәш юлын бик тә ачык дип санавы белән, бу юл берьдәнбер дип чын күңелдән ышануы белән аерылып тора.

Татар әдәбиятында традицион булган хатын-кыз темасын хәл итүдә дә үзгәлек бар. Элекке геройлар хатын-кызны җәмгыятьнең иркенле әгъзасы, ирләр белән тиң итеп күрәсе килеп эш йөртә. Һәм бу — гуманлы идея: укучы һәм тамашачы күңелендә хатын-кызны олылау һәм хөрмәтләү тәрбияли иде. Ә инде совет драмасындагы геройлар хатын-кызны үзе белән тиң күрә, моны — хәл ителгән, дип саный, аңа ирләр белән бертигез таләпләр куя. Хатын-кызны олылау һәм хөрмәтләү каядыр икенче планга чигә. Димәк, гуманлылык та кими. Хатын-кызның, иң әүвәл, ана булуы исәпкә алынмый башлый. Шушы хакыйкатьны беренче булып күреп алган һәм «Югалган матурлык» исемле пьесасында мөһим проблема төсендә күрсәтергә теләгән Һ. Такташ тәнкыйть ителә. Бу фактта рәсми идеологиягә туры килмәүнең тулы бер фәлсәфәсен күргән вульгар социологизм тәнкыйте язучыны сыта, бүтәннәргә дә сабак булсын дип тырыша.

Хатын-кызны җәмгыятьнең тулы хокуклы әгъзасы төсендә кабул итү гаилә нормаларын аңлауга һәм художестволы сурәтләүгә дә үзенең тәэсирләрен кертте. Электе үзенә күрә бер кальга (крепость) кебек ябык булган гаилә, әйтерсең лә, бөтен эчке күренеш-серләре белән ачып ташланды. Җәмгыять өчен, тирә-күрше өчен, коллектив өчен үтәдән-үтә күренеп тора торган ачык хәлгә килде. Тигез мәхәббәткә, бер-береңне хөрмәт итешүгә корылган, акчадан, байлыктан, дини гореф-гадәтләрдән азат булган гаилә пропагандаланды. Семья иҗтимагый тормышка һәм хәлләргә ныграк тартып кертелде, аның төп вазифаларыннан иң зурысы һәм изгесе булган — кешелекне дәвам иттерү, балалар тәрбияләп үстерү вазифаларына игътибар кимеде. Дөресрәге, алар онытыла башлады.

Яңа герой гуманизмның үзен дә яңача аңлый иде инде. «Кешене ярат» диген гуманлы таләпне ул конкретлаштырды: «изелгәнне ярат, хезмәт иясен ярат»,— дип куйды. Бу — рәсми идеология таләбе, ягъни эшчеләр партиясе әзләкле һәм нык кул белән үткәрә торган таләп иде. Аның гомумкешелек кыйммәтләрен юкка чыгару мөмкинлеге дә бар булып чыкты. «Пролетар гуманизм» дигән мәгънәгә артык бирелеп, аның асылда бер генә сыйныф мәнфәгатьләрен алга куйганлыгын исәпкә алмыйча, әдәбият сыйнфый интересларны гомумкешелек кыйммәтләреннән алга чыгарып тасвирлауга күчте. 20—30 елларда да, аннан соң да драматургиядә пролетар сыйныф интереслары белән гомумкешелек мәнфәгатьләренең үзара мөнәсәбәте бозылды. Югыйсә бит В. И. Ленин да ачык итеп: «Марксизмның нигез идеяләре ноктасыннан караганда иҗтимагый үсеш интереслары пролетариат интересларыннан өстен»,— дигән (Ленин В. И. Полное собрание сочинений, 4.т., 220 бит.)

Тагын бер мөһим мәсьәлә. Без моңарчы әдәбиятның, шул җөмләдән драматургиянең дә алга үсешендәге үзенчәлекләрне художестволы аңның үзгәрүеннән, аның нинди типта булуыннан чыгып билгели идек. Әдәбият белән җәмгыять арасындагы үзара мөнәсәбәттән әдәбият тормышның яңа өлкәләрен ничек итеп ача, төп жанрларга караган әсәрләрдә драматик коллизия ничек үзгәрә, бер дә булмаса, художество стильләре ничек алмашына — шулардан чыгып билгели идек. Нәтиҗәдә еш кына әдәбиятның үсеш баскычлары граждацлык тарихындагы баскычлар белән тәңгәл куеп карала иде. Инде хәзер болар янына тагын да бер мөһим билгене кушу сорала. Әдәби дәверләрне аерганда, аларны бер-берсеннән мөстәкыйль караганда, һичшиксез, чор-

ның кешелек проблематикасын исәпкә алырга кирәк. Моны үзәктәге белгечләрдән берсе дип карарга кирәк.

Әлбәттә, әдәби процессның барышын өйрәнгәндә бүген дә җәмгыятьнең, халык тормышының аерым дәверләрен исәпкә алмау мөмкин түгел. Моның ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын әдәбият галимнәре, тәнкыйтьчеләр дә, бөек язучылар үзләре дә кат-кат әйтә килгәннәр. М. Горький «Рус әдәбияты тарихы» исемле хезмәтендә язучыларның иҗатын рус тарихының мөһим баскычларын ничек чагылдыруына карап бәяли. Шулай була торып та, без бүгенге күзлектән чыгып әдәбиятның үсеш дәверләре нигезендә кешегә мөнәсәбәт, кешене ничек итеп күзаллау һәм кешене ни дәрәҗә кешелекле итеп сурәтләү ятарга тиеш дип әйтәбез. Драматургия үсешен дә шул яссылыкта өйрәнү зарурлыгын алга сөрәбез. А. С. Пушкин бер дә юкка гына: «Иң ышанычлы үзгәрешләр холыклар үзгәрүдән килеп чыга»,— димәгән.

Шул җәһәттән караганда, татар совет драматургиясенең безнең көннәргә, ягъни 80 елларга кадәрге чорын кешене коллектив эчендә генә карап, шәхеснең үз мәнфәгатьләренә тиешенчә игътибар биреп җиткермәү вакыты дип бәяләргә тиеш булабыз. Дөрес, марксизм тәгълиматы буенча, бары тик коллектив эчендә генә шәхси ирек булырга мөмкин. Бу фикерне танымау дөрес булмас иде. Шәхеснең азатлыгы аның үзенең кешеләргә кирәклеген аңлауга, җәмгыять эшләренә мөнәсәбәте һәм катнашы булуга бәйле. Ләкин бу бәйләнештә үзара акыллы һәм дөрес мөнәсәбәт, тиешле пропорция булырга тиеш. Совет чорындагы драматургиядә исә, кызганычка каршы, коллектив һәм шәхеснең диалектик берлеген берьяклы аңлау барлыкка килде. Коллектив мәнфәгатьләре алга чыгарылып, шәхси интереслар сүзсез рәвештә артка чигерелде. Әсәрләрнең күпчелегендә коллектив белән шәхес коллизиясе вакытында шәхесне коллектив изеп-сытып уза иде. Ә шәхеснең эчке сыкранулары, шул вакыттагы трагедиясе драматургия тарафыннан исәп-санга алынмады. Ф. Энгельс термины белән әйткәндә, «пролетар-плебейлык аскетизмы», бүгенгечә әйтсәк, «революцион аскетизм» карашы өстенлек алды, сәхнәнең иректә үсүенә тоткарлык ясады. Нәтиҗәдә пролетариат теләкләре алдында гомумкешелек кыйммәтләре дә артка чигерелде, онытылды, аяк астына ташланды.

Татар совет драматургиясендә, бигрәк тә аның беренче чорларында еш сурәтләнгән конфликт классицизм чорындагы төп конфликтны искә төшерә. Анда да бит шәхси теләк-омтылышлар гомуми максат — көчле дәүләт, үзәкләштерелгән дәүләт интереслары алдында, гомуми теләкләр каршында чигенә. Ләкин бу коллизия классицизм әдәбиятында геройның эчке кичерешләрен тиешенчә сурәтләп хәл ителә. Бигрәк тә трагедияләрдә шулай. Ягъни, герой-персонаж өчен гомуми интересларга юл бирү, дәүләт мәнфәгатьләре хакына баш ию процессы эзсез узмый, тирән психологик кичерешләр тудыра. Ә бездәге драма һәм трагедияләрдә мондый конфликтны хәл итү икенче төрле характер ала: шәхси интереслар коллектив һәм революция максатлары алдында сүзсез-эзсез чигенә, кеше шулай тиеш дип, артык рухи газапларсыз гына үзен корбан кылуга бара. Сыйнфый һәм революцион билгеләнгәнлек өстенлек алу нәтиҗәсендә татар совет драматургиясендә психоанализ арткы рәттә калды. Геройларның психологик кичерешләре, хисләр-кичерешләр тирәнлеге еш кына мелодрама төре карамагында гына булып чыга. Ә мелодрамада психологизм үзенең примитивлыгы, сайлыгы белән аерылып тора.

Совет әдәбияты кебек үк, татар совет драматургиясенең дә аерым мәсьәләләрдә ялгыш тарафларга кереп китүе, илдәге иҗтимагый-политик һәм икътисади шартлар белән билгеләнә. Монда Сталинның шәхес культы, догматизмның бер җимеше булган вульгар социологизм, әдәбиятны һәм сәнгатьне идеология чарасы итеп кенә карау кебек күренешләр беренче рольне уйный. Шулай да язучыларның тормышны һәм кешене сурәтләүдә берьякка кереп китүендә мондый сәбәпләрне генә күрү җитеп бетмәс. Мондый тенденцияләрнең тууында төп сәбәпләрдән тагын берсе һәм мөһиме — революциягә кадәрге тормыш, андагы социаль һәм татарлар өчен тагын милли изелү түгелме икән?!

Мин мәсьәләсен генә алыйк. Татар җәмгыятенең үсешендә, кайбер объектив сәбәпләр нәтиҗәсендә дә әлбәттә, үз кабыгына бикләнү, дөньяда бара торган процесстан читтәрәк тору кебек, урта гасырчылык, хәтта схоластика кебек яклар да көчле иде. Моның сәбәпләре үз дәүләтең булмауга, дини-милли изелгәнлеккә, ягъни рус самодержавиесенең колониаль политикасына барып тоташа иде. К. Насыйри, Г. Тукай, М. Гафури, Г. Исхакый, Г. Колахметов, Г. Ибраһимов кебек алдынгы язучылар моны күрделәр. Русларның үзләрен буйсындырып торучылар икәнен белсәләр дә, тәрәккыять ягыннан алдарак булуларын, татарның һәръяктан руслар белән уратып алынганлыгын һәм милләтебезнең алга үсеше, иң әүвәл, рус җәмгыяте белән бәйле булуын аңлады алар. «Мин моңганчыга кадәр,— ди Г. Исхакыйның «Тартышу» исемле драмасындагы бер персонаж,— татарны тәрәккый иттерү дип әллә никадәр сөйләсәм дә, шуның өчен үземне корбан кылырга риза булсам да, бу минутка кадәр татарның алга китүе Русиянең алга китүе белән, Русиянең идарәсенең яхшыруы белән бергә үскән, бергә бәрәккән икәнлеген хәтеремә китермәгәнмен. Әйе, иптәшләр, безнең эшемез рус халкының эше белән бергә бәйләнгән, рус халкы тәрәккый итмәгәндә, без тәрәккый итә алмыйбыз. Русиянең идарәсе үзгәрмәгәндә, без бер эш эшли алмыйбыз.»

Ә менә татарны моңарчы миллә́т буларак саклап калуга зур өлеш керткән дин хезмәткәрләре, бигрәк тә XIX гасырда һәм XX йөз башында, билгеле бер дәрәҗәдә гомуми прогресска оппозициядә булып чыкты, үз эченә генә бикләнүне яклады. Алга узып шунысын да әйтик, менә ни өчен татар әдәбияты консерватив динчеләр белән көрәштә артык дәрәҗәдә кискен һәм актив булды. Бу активлык шунда да күренә: Тукайдан һәм Исхакыйдан башлап барлык дип әйтерлек язучылар дини фанатизмны фаш итте. Укучылар шул рухта тәрбияләнде. Совет чорында исә бу тенденция үзенә философик, идеологик җирлек һәм мул җим тапты, яңа көч белән дәвам иттерелде. Нәтиҗәдә, дини фанатиклык белән көрәш, гомумән, дин белән сукырларча көрәш төсен алды. Бу җәһәттән татар әдәбияты башка төрки әдәбиятлар арасында да, татар драматургиясе башка жанрларга караганда да алданрак барды. Диннең үзәгендә яткан гомумкешелек кыйммәтләрен оныту, санга сукмау алга таба ничек итеп рухи ярлылыкка, әхлакый кыйбланы югалтуга китергәнен әйтеп тору кирәкме икән?!

Шулай, жанр буларак тугач та, драматургия руслар белән аралашуны, алардан өйрәнүне, русча яхшы белүне хуплады, шуның өчен көрәш алып барды. Ләкин бу юнәлештәге эшнең дә чамасы булырга тиеш — революциягә кадәрге драма монысын да күрде. Ф. Әмирхан «Тигезсезләр (яңа кешеләр)» исемле әсәрендә руслар узган баскычның — үз милләтеңнән йөз чөерү, манкортлыкка төшү чорының бездә дә башлануын хәбәр итте. Андый кешеләрне, Фонвизин комедиясендәге мәгълүм персонажны күздә тотып, ул «Иванушка-Абдулка» дип атады. Мондый кимчелекне Г. Исхакый да тәнкыйтьләде: «Ул әле икеләнә иде» исемле хикәясендә рус әдәбияты тәэсирендә тәрбияләнгән бер егетнең милләт кызларыннан йөз чөерүен үткен көлкегә алды.

Ф. Әмирхан һәм Г. Исхакый бик вакытлы чаң суккан күренеш совет чорында инде рәсмиләштерелде, яклау тапты һәм пропагандаланды. Драматургия дә тартып кертелде аңа — ачык тенденция төсен алган бу ялгышлыкка. Әйе, татар җәмгыяте руслашуга керел китте. Драматургиядән дә шул таләп ителде. Пьесаларда рус кешесе образлары бары тик яхшы яктан кына, безнең халыкка ярдәм итүче буларак кына сурәтләнергә тиеш иде. 20 нче елларның ахырларыннан башлап, бигрәк тә 30 нчы елларда, сәхнә әсәрләрендә рус персонажлары булмаса, андый пьесалар тәнкыйть ителде, сәхнәдән алып ташланды. Мәсәлән, Ф. Бурнашны «ханнар, сарайлар былбылы» дип типкәләгәндә иң көчле аргументларның берсе менә шул була. Мондый тәнкыйть «тормышны дөрес чагылдыру» дигән сүзләргә таянды: әнә бит, диделәр, социалистик чынбарлыкта, әйтик, фабрика-заводларда руслар күпме эшли, димәк, пьесаларда юк дигәндә дә яртысы рус персонажы булырга тиешле! Кыскасы, рәсми сәясәтне — партия оешмалары үз кулларында нык тоткан политиканы — тормышка ашыруда әдәби тәнкыйть тә, драматурглар да күндәмлеккә мәҗбүр ителде.

Шулай булса да, руслашып үз милләтенә, туган теленә төкереп караучыларны тәнкыйть итү юк-юк та булгалый. Бигрәк тә беренче елларда. Мәсәлән, К. Тинчурин «Американ» (1923) комедиясендә: «Мин французча, инглизчә, немецча, хәтта японча укытуны да аңлыйм, ә инде татарча өйрәтүне һич башыма сыйдыра алмыйм. Безгә, татарларга, культура кирәк, ә алар татарча укытып маташалар»,— дип зарланучы космополит мирза Насих Николаевичтан көлә. Ләкин мондый тәнкыйть өчен безнең драматургларның кыюлыгы калмады инде.

Урыслашуның милләтебезне нинди начар нәтиҗәләргә, ахыр чиктә бетүгә китерүен Татарстандагы һәм Советлар Союзындагы хәлләрне читтән күреп яшәгән, кимчелекләрне тәнкыйтьләү мөмкинлегенә ия булган Г. Исхакый гына яктырта алды. Аның 1923 елда язылган, 1939 елда Берлинда басылган «Җан Баевич» исемле комедиясе тулысы белән шуңар багышланган. Мондый әсәрләр, һәм, инде анда әйтелгәнчә, Исхакыйның эмиграциядә иҗат ителгән башка пьесалары 1917 елдан соңгы чордагы драматургиябез тарихын тулырак, фәннирәк өйрәнү мөмкинлеге бирә. Театрыбыз тарихын да. Шул, ук «Җан Баевич»ның, мәсәлән, Хельсинкида татар үзешчәннәре тарафыннан сәхнәләштерелүе мәгълүм.

Жанр ягыннан үзенчәлекле булу драматургияне башка әдәби төрләргә караганда да хаким политиканы актив пропагандаларга мәҗбүр итте. Чорга авазда́ш булу бигрәк тә сәхнәгә сукты. Ни өчен? Чөнки чор сулышы, замана билгеләре ачык чагылмаса, бүгенге геройлар гәүдәләнмәсә, театр пьесаны, гадәттә, куярга ашыкмый.

Әйе, татар драматургиясендә ялгыш тенденцияләр формалашты. Ләкин, бер бөтен процесс итеп караганда, аның жанр буларак үсүе тукталмый. Тематикада гына түгел. Ә тагын нәрсәдә соң? Иң беренче жанр төрләрен үзләштерүдә һәм жанр поэтикасын баетуда. Чыннан да, шул ук 30 нчы елларда аңарчы әле борынлап кына килгән жанр төрләре туа һәм ныгый. Тарихи драма формалаша, лирик драма берничә күренекле әсәр бирә, фольклорга нигезләнгән пьесалар языла (ә алар арасында «Хуҗа Насретдин» кебек җәүһәрләр бар).

20 нче елларның ахырларыннан башлап драмада конфликт шактый сыегая. Бу, иң әүвәл, заман темаларына һәм проблемаларына караган пьесаларда күзәтелә. Аларда конфликт шактый схематик, образлар системасы да бай түгел, типлар юк дәрәҗәсендә. 30 нчы елларда да, әле хәтта 50 елларда да иң күп кабатланган конфликт кулаклар белән, кулак һәм динчеләр калдыклары белән көрәш рәвешендә оеша. Бу инде

мәгълүм: социализм төзелеше алга барган саен, сыйнфый көрәш кечәя бара дигән сәнгатькә күчерелүе! Тормыш катлаулылыгын, тормыш дөреслеген гәүдәләндерү җәһәтеннән бу еллар драмасында актан-ак уңай геройлар да, кара буяулар белән генә сурәтләнгән тискәре персонажлар да артык яңалык алып килми. Алар ярыйсы ук ясалма, чөнки конфликт алдан билгеләнгән юнәлештә хәл ителә: дошманнар җиңелә һәм җәзалана, эшче яки хезмәт иясе вәкиле җиңеп чыга, тантана итә. Тормыш һәм сәнгать дөреслегенә иң якын торганнары исә — ике арада калган, адашкан, уртаклыктагы геройлар. Шундыйлардан бөтен бер сыйныф — крестьяннарның революциягә килүендәге күпсанлы юлларыннан берсен шактый ук үзенчәлекле һәм тәэсирле итеп тасвирлаган Биктимер карт (Т. Гыйззәт — «Ташкыннар») үсеп чыкты. Крестьянның күмәкләштерү чорындагы эчке кичерешләрен бирү ягыннан Ярулла (Ф. Бурнаш — «Ялгыз Ярулла») тормышчан билгеләргә ия. Ш. Усманов «Кичеккән фәрман» драмасындагы үзәк персонажлардан берсе булган Харис Садыйков образы белән революциянең тегермән ташы арасына эләккән эре характерны ачып бирде.

Ике лагерь арасында адашып калган геройларны комедия һәм сатира төрләре дә уңышлы төстә күрсәтә алды. Моңа мисаллар итеп Н. Исәнбәтнең «Һиҗрәт» һәм К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр» комедияләрен алырга була. Яңа мөнәсәбәтләр урнаша һәм ныгый барган шартларда туган, киләчәге «зур» булган кимчелекләрне — бюрократлыкны, карьерачылыкны, яңага аркаланып, аларны үзенә файдага борып кеше исәбенә яшәүне, «кызыл» мещанлыкны һ. б. сатира шулай ук уңышлы фаш итә башлады. Дөрес, мондый әсәрләрнең сәхнәгә узу һәм сәхнә юлы артык борчулы, артык авыр һәм катлаулы булды, авторлары тәнкыйть күсәге татый тордылар. Әмма андыйлар да, аз булса да язылды. Мисаллары — К. Тинчуринның «Хикмәтле доклад»ы, Н. Исәнбәтнең «Портфель» кебек пьесалары, Ф.Бурнаш һәм Ә. Фәйзи комедияләре. Кыскасы, татар совет драматургиясенең гаять авыр шартларда да аерым уңышларга ирешүен яңа тарихны язганда күрә белергә һәм күрсәтә белергә кирәк.

Алда күрсәтелгән тенденцияләрне искә алып татар драматургиясенең совет чорындагы тарихын язганда, аның әсәрләрен анализлаганда, аңлашылса кирәк ки, моңарчы идеясе ягыннан югары дип билгеләп йөртелгән аерым пьесалар артка чигерелергә, ә моңарчы күләгәдә калганнары алгарак чыгарылырга тиеш булачак. Иң беренче, анализ вакытындагы иң төп принцип саналган социаль конфликт эзләү, һәр әсәрне сыйнфый көрәш ноктасыннан чыгып кына бәяләү үз урынын гомумкешелек мәнфәгатьләре ни дәрәҗәдә чагылган булуын аңларга тырышуга бирергә тиеш. Ләкин бу һич драматургиянең иҗтимагый вазифасын бөтенләй дә санга сукмаска туры киләчәк дигән сүз түгел. Әдәбият, шул исәптән драматургия дә — иҗтимагый аңның бер формасы, тик художестволы чагылыш формасы. Димәк, яңа тарих язганда да әсәрнең иҗтимагый фикер үзешендә тоткан урынына нык игътибар булырга тиеш. Әмма аның художестволы форма икәнен генә истән чыгармаска кирәк. Ягъни, драматургия тарихын яңадан язганда сәнгатьчелек ягыннан да үсеш тарихы булуын онытмаска кирәк.

---


## Кадерле укучылар!

«Казан утлары» журналына 1992 елның икенче яртысына өстәмә язылу башлана. Бәясе: бер айга — 10 сум, алты айга 60 сум. Индексыбыз — 73210.

Язылу бәйсез дәүләтләр бердәмлегенең барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә.

# ТУКАЙГА ТУГРЫ БУЛЫП...

**ЯЗУЧЫ Фәнзаман Баттал белән әңгәмә**



*— Фәнзаман әфәнде, Сез матбугатта моннан берничә ел элек кенә күренә башласагыз да, халкыбызның яратып укыла торган язучысына әйләндегез. Әсәрләрегезнең бик тә үткен темаларга язылган булуы, кешеләрнең үзәгенә үткән нәрсәләрне дөп-дөрес итеп әйтеп бирүегез, сүз һәм җөмләләрегезнең ут уйнатып торуы — кыскасы, ук аткан саен «унлы» очкога тидерүегез һәммәбезнең күз алдында булды. Бу хакта берниндн дә бәхәс юк. Укучы Сезнең әсәрләрне эзләп йөри, көтеп ала, алай гына да түгел — Сезнең язганнарны мактап редакцияләргә эчкерсез хатлар да юллый. Шул уңайдан барыбызны да кызыксындырган сорау: менә шушылай халыкчан һәм үтемле итеп язу осталыгына тормышның нинди «университетлары» өйрәтте?*

— Укучы минем иҗатны ничек бәяпидер — аның эше. Әмма шунысы хак, гаделлеккә, милләтемә зыян салырдай фикер язудан сакланырга тырыштым. «Университет» мәсьәләсенә килсәк, шөкер, тормыш мине сабый чактан ук үз башым белән уйларга, нәтиҗә ясарга өйрәтте: ачлыгын һәм ятимлеген дә, бихисап гаделсезлекләрен һәм интегүләрне, җәфа чигүләрне дә китереп кенә торды. Мин аларны гомеремдә күргән сөенеч-шатлыкларга караганда файдалырак дип саныйм. Хәзерге балалар тормышы хакында уйланган саен аларны кызганып та куям. Иртән торуларына барысы да әзер: җылысы да, ризыгы да, уку әсбаплары да, уенчыклары да, киемнәре дә... Бар белгәннәре — телевизордан... Безнең буын балалары, өйдә җылы булсын өчен, иртәнге караңгыдан бәләкәй чана тартып, чыбык-чабык, коры-сары, салам җыеп кайтырга чыгып китәләр иде. Язга чыккач, көздән җирдә калган черек бәрәңгеләрне эзләү дисеңме, ашарга яраклы үләннәрнең барысына да җитешү дисеңме... Уенчыкларын да үзебез ясыйбыз, мал-туарны да үзебез карыйбыз, китаплар өчен сумканы да (букчаны да) үзебез тегәбез. Бер уйласаң, бу гамәлләрнең барысы да иҗат, барысы да яшәү өчен ябышып яту, рәхимсез тормышның күзенә туры карап көрәшү. Менә шушы балачагымны мин хәзерге балалар тормышына алыштырмас идем. Хәер, бу әңгәмә балалар журналы өчен түгел.

Тормышны университетка тиңләсәк, аның беренче мөгаллимнәре, әлбәттә, ата-ана булырга тиеш. Бүгенгедәй хәтердә, мәктәп елларымда беренче шигырем басылып чыкты. Совет илендәге бәхетле тормыш турында иде ул:

*Никадәр салкын, буранлы*
*Булса да бу салкын кыш,*
*Мин тоям һәрбер урында*
*Язгы хис, язгы сулыш.*

*Чөнки минем туган илем*
*Бәхет һәм шатлык иле.*
*Безнең дәртле йөрәкләргә*
*Үтә алмый кыш җиле,—*

дигән строфалар белән тәмамланган бу шигыремне әткәй укып чыкты да: «Һы, һы, һы-ы-ы!» — ди-ди озак кына кызарып утырды. Аннары, пионер галстугымның очыннан тартып, тәрәзә янына китерде.

— Әнә, күр, Дүсә әбиеңнең өе бүген-иртәгә өстенә җимерелеп төшәчәк. Бәхетле ил карчыгымы ул? Әнә тегендәрәк аякларын сугышта өздергән хәерче әй борынча килә. Шулмы шатлык? Ике энең белән ике сеңлең бер атнада ачтан үлде. Бәхетле ил балалары булганга күрә үлделәрмени алар?!.

Шуннан соң «шып» итеп маңгайга тәртте.

— Менә монда рәтең бар икән бит. Сүз җаен, язу тәртибен дә беләсең икән. Шулай булгач, ходай биргән миеңне дөрес эшләт! Дөресен яз, нәселгә кызыллык китермәштубы!

Әнкәйгә килсәк, анысы ай буе көлеп йөрде. Сүз чыккан саен: «Карале, атасы, бу бәхетле ил баласына нәрсә ашатыйк микән?», «Быелга бүрек алмасак та ярар, аның дәртле йөрәгенә кыш җиле үтми икән бит»,— кебегрәк сүзләрне сибә торды. Аның кебек үк тәртмә телле кешене бүтән күргәнем юк минем. Тормышның тузга язмаган һәрбер вакыйгасын әллә нинди кызыкларга төреп сөйли белә иде мәрхүмә. Әгәр дә минем сатирик һәм юмористик әсәрләрем кызык табып көләрлек икән, аларның күбесе — әнкәм мирасы... Язганнарымда фәлсәфә, гаделлек һәм хакыйкать булса — алары әткәмнән килә.

Сез, Мансур әфәнде, әле яңа гына: «Матбугатта берничә ел элек кенә күренә башладыгыз»,— дигән сүзне дә ычкындырдыгыз. Юк, мин матбугатта 14-15 яшемнән күренәм. Йөзләрчә шигырьләр, хикәяләр, очерклар бастырган кеше мин. Ләкин сәяси калыптагы әйберләрне өстәл астында сакларга туры килде. Сәбәбен үзегез дә беләсез: аларны каядыр тәкъдим итү, басылып чыгар дип өметләнү файдасыз иде. Халыкның күңелендә кайнаган, аны борчып килгән ихлас темаларны бөтен хаклыгы белән күтәрми торган язучы, минемчә, укучыларга газиз түгел. Коммунистик системада исә чын сүзне сөйли алмый иза чигүче мин генә булмадым.

*— Безнең бу әңгәмәбез апрель аенда басылып чыгачак. Җирго, халыкка Тукайны биргән айда... Мәңгелек Яңарыш турында уйландырган яз аенда... Милләтебез уяна башлаган бу чорда без яңадан да Тукай тормышына, Тукай иҗатына әйләнеп киләбез. Кат-кат уйланабыз... Ә Сезне — иҗатта тоткан юлы белән аңа бик тә аваздаш булган әдипне — бүген бу исем нәрсәләр турында уйландыра? Иҗатчы һәм гражданин буларак, Тукайның бигрәк тә нинди сыйфатлары җитми безгә?*

— Кыюлык, гаделлек, фидакарьлек җитми. Халык мәнфәгатен барысыннан да югарырак күтәрү җитми!.. Тукай үз тормышының девизын барыбызга да әйтеп калдырган. Аның тәп псевдонимы «Шүрәле» бит. Әнә шул «шүрәлинский девизында» болай ди:

*Теләсәң кемне сук яки макта,*
*Берәү белән дә булма иттифакта.*

«Иттифак»ы союз, бердәмлек, дуслык дигән сүз инде — бусы күпләргә мәгълүм. Халкы, милләте хакына Тукай беркемнең дә хәтерен саклап маташмаган. Дуслары, каләмдәшләре белән бергә кайнап яшәсә дә, аларны яратса да, Тукаебыз вакыты-вакыты белән һәркайсын диярлек «борычлап» яшәгән. Әйтик, Сәгыйть Рәмиев халык мәнфәгатеннән ерак торучы «Бәянел-хак» журналына эшкә керә. Шунчак Тукай «Кешехайваннар» дигән язмасында Сәгыйть Рәмиевне кем сөяк ташласа, шуңа койрыгын селкүче, рәхмәт әйтүче хайванга тиңли. Билгеле, исем-фамилиясен күрсәтеп бетерми, «С. Р.» дип кенә куя. Ләкин һәр зыялы аның кемгә төртелүен бик яхшы аңлый! Югыйсә, Габдулла белән Сәгыйть якын дуслар, бер-берсен яратучы, ихтирам итүче шәхесләр бит!.. Тукай халыкка хыянәтне беркемгә дә гафу итмәгән. Ул салкын канлы хирург сыман. Авыртамы-юкмы, халык тәненә йогу ихтималы булган һәр шешне кисә дә ташлый. Ул милләтне, аның зыялы затларын чеметеп тә, яңаклап та, терттереп тә, келеп һәм мыскыллап та айныткан. Тукай — шул чорның ачы даруы, алтын бaганасы, рәхимсез хөкемдары.

Инде хәзер үзебезгә карыйк. Яшерен-батырын түгел, бер-беребезне әледән-әле кисәтеп торабыз: «Аның турында каты язма инде, хәтере калыр», «Алай ук тәнкыйтьләмә, халык алдында дәрәҗәсе төшәр», «Бу җөмләне алып ташла, үпкәләр»... Әшнәлектә, үзара ялагайлыкта яшәүче язучылары, журналистлары, сәяси эшлеклеләре булган милләтнең берчакта да үсәчәге юк. Тукайны куркыткан нәрсә дә нәкъ шул. Ачынган, тирә-ягындагы бушбугазларны күреп көенгән минутларында:

*Бездә бәйтак зур авызлы, оста телле бәндәләр,*
*Тик күренми купне белгән, тук күңелле бәндәләр,*

— дип язган. Бездә дә тук, ягъни бай күңелле бәндәләр бармак белән генә санарлык. Зур авызлы тел бистәләре буа буарлык. Тукайлар кирәк, Тукайлар!..

*— Бүген бездә күп китап чыгаручы каләм ияләре бәйтак. Орденлы һәм югары исемле әдипләр дә җитәрлек. Әмма күңелдә һаман Тукай кебек, Җәлил сыман, Исхакый шикелле шәхесләр...*

— Югары исемнәр дә кирәктер, бәлкем. Әдипнең, сәнгать кешесенең иҗат «дәрәҗәсен» белү өчен Сез күздә тоткан исемнәр белән укучылар да кызыксына кайчак. Әле күптән түгел генә бер очрашуда язмача сорау бирделәр. Ягъни, минем дә берәр олы исемем бармы? «Бар! — дидем.— Миңа туган әтиэмдә ук Фәнзаман дигән гомерлек исем биргәннәр!» — дидем. Язучы өчен үз исеменнән, фамилиясеннән югарырак, олырак исемне бер кем дә бирә алмый. Әйтик, шул ук Габдулла Тукайга, Фатих Әмирханга, Гаяз Исхакыйга, Һади Такташка, бу чоргарак та килсәк, Нәкый Исәнбәткә, Әмирхан Еникигә, Аяз Гыйләҗевка, Гамил Афзалга, Нурихан Фәттахка, Мөхәммәт Мәһдиевкә тагын бер исем яки дәрәҗә тагудан нәрсә артаб? Әсәрләре юньле булса, әдәбият әһелләрен мулла кушкан исемнәре укучы теләгән югарылыкка менгерә дә куя! Азмы бездә халык кемлеген дә белмәгән орденлы, дәрәҗәле әдипләр!.. Әз генә алга — тарихка карыйк. Бездән соң яшәячәк буын: «Туктале, бу язучының СССР Язучылар бирлегендәге стажы күпме икән, нинди орденнар, мәртәбәле исемнәр алды икән?» — димәячәк. Бөтен абруең, сәйкемле сөягең әсәрләреңдә күренәчәк. Күп роман-

нар, томнар чыгарган, үзе исән чакта козырь булып, алланың кашка тәкәсе булып яшәгән әдипләрнең дә онытылуы, ә кайберләренең халык күңеленә хуш килерлек әз генә иҗаты белән дә әдәбият йолдызлыгында беркеп калуы ихтимал. Тарих ул җиз иләк сыман. Ул кирәклеләрен генә сайлый, калганнарын, йомшак кына итеп әйткәндә, югалта.

Хәер, андый язучылар да кирәк. Табигатькә карагыз: әгәр төз нарратлар, мәгърур имәннәр янында вак-төяк куаклар үсмәсә, ул имәннәрнең, наратларның зурлыгын белмәс идек. Кәҗә тавышлы җырчылар булмаса, Илһам Шакировның кемлеген аңламас идек. Әдәбият дөньясында да шулай.

*— Типик татар совет язучысы ул нинди? Без аннан арына алдыкмы әле?*

— Кайберәүләр аннан тиз арынды. Чөнки башка язучылар коммунистик системаны бәхетле тормышка алып баручы бердәнбер система дип ихлас күңелдән алданган чорда да, бу тәр әдипләр күңелләре белән икенче дөньяда яшәделәр. Дөресен әйтергә кирәк, андыйларның шактый өлеше иҗатка кул селтәде, байтагы эчүгә бирелде. Гаепләп тә булмый. Тирә-ягында бер тормыш кайнасын, ә син шуңа капма-каршы фикерле, сюжетлы әсәр язып ят, имеш. Йөрәгеңә, вөҗданыңа каршы гамәл кылу бик авыр ул. Дөрес, алай да язып була, язганыңны да бастырып була. Хәтта сине беркатлы укучының шагыйрь итеп, әдип итеп тануы да ихтимал. Гонорарга, ягъни акчага да алтырамассың, өстеңдә иман сату исәбенә алынган кием булыр, алдыңда халкыңның тарихына, өметләренә хыянәт итеп тапкан ризык торыр. Димәк, балаларың да хәрам ашап үсәр... Аңлый белгән, уйлана белгән кеше өчен коточкыч бит бу! Нәселең дә пычрана дигән сүз!

Күпләр шулай яшәде. Телне, милләтне корыту, шәхси сәләтләрне сүндерү максатына алып баручы партиягә мәдхия укыган язучылар аз булдымы? Кулак дигән исем тагылган иң тырыш, иң маһир крестьяннарны үтерүгә, сөргенгә сөрүгә куанып иҗат ителгән әсәрләр вагонлап чыгарылмадымыни? Шактый китапларның уңай геройлары да җан кыючылар ләбаса! Аларның авторлары көчләп үтерелүчеләрнең урынына үзләрен куеп карый беләләрме? Җәлладның балтасы төшәр, пулясы керер мизгелдә кеше нинди халәткә килә, ничек тилмереп карый — шуларны күз алдына китереп, йөрәк аша кичерә алалармы? Маңгаена пистолет төбәлгәч, котылу форсаты калмавын аңлагач, ул нишли?.. Әле монда тавык суярга да күп бармый. Ничек инде минем ашыйсы килгәннән генә бу җан иясенең күзләре кояш күрүдән мәхрүм булырга тиеш, дисең...

Кистереп әйтә алам, әдәпсезлеккә, рәхимсезлеккә, мәрхәмәтсезлеккә өндәүче әсәр адәмчә тормышта җирәнү хисе тудырачак. Ә җирәнгеч нәрсәне беркемнең дә кулга аласы килми. Әле күптән түгел генә авылдашым кунак булып китте. Киштә-киштә китапларыма хәйран калып, сокланып утырган җиреннән карашы кинәт кенә сүрелеп куйды моның. Кыяр-кыймас кына Гариф Гобәйнең «Коръән серләре» нә төртеп: (бармагын тидермәде...) «Үзең юньле генә кеше инде син, ә бу китапны һаман саклыйсың икән әле»,— диде. Яхшы аңладым: бу кешенең миңа карата ихтирамы бик нык кимеде... «Миңа Ленин, Сталин томнарын да, Гитлер «иҗатын» да, «Коръән серләре»н дә белергә кирәк, укучыларның күзен чын хакыйкатькә ачканда мисаллар, өзекләр китерү өчен кирәк»,— дип тә карадым. Юк, барыбер, күңелендә юшкын калды... «Совет язучылары»ның күп китаплары әнә шундый хөкемгә дучар булачак. Ләкин аңа карап әдәбият фәкыйрьләнмәячәк. Ник дигәндә, ялган диңгезендә коенуга караганда хакыйкатьнең бәләкәй генә күлендә коену мәслихәтрәк.

«Совет язучысы» дигән төшенчәнең әдәбиятка, гадел һәм вөҗданлы әдәбиятка биниһая югалтулар китерүен тирән аңлаган хәлдә дә шул юлдан чигенмәскә тартышучыларны күрдек. Алары үткән елда да коммунистик идеяләргә теш-тырнак белән ябышып ятарга маташтылар, чынбарлыкка юл алган әдәбиятны туктатырга тырыштылар. Кабатлап әйтәм: тирән аңлаган хәлдә!.. Мәсәлән, КПССның кешелек тәрәккыена иксез-чиксез зыян китерүе, аның һичшиксез бетәчәге турында язган ике-өч елда шактый мәкаләләр яздым. Басылган кадәреләре үзләрен милләтнең акыл иясе дип санаган кайбер кешеләрдә шашар нәфрәт тудырды. Матбугатта чыккан зур-зур язмаларын хәтерле укучылар онытмаганнардыр әле: бу фәкыйрегезне нинди генә әшәке сүзләр белән күммәделәр! Хәтта барысы да бер сүзне кабатлады: КПССка тел тидергәне өчен Фәнзаман Баттални судка бирергә, төрмәгә тыгарга! Аларның әрләтүләреннән куркып калмаган дистәләрчә укучылардан редакцияләргә мине яклап хатлар агылды. Шуннан соң барлык газеталарда да «изге» партия турында бәхәс купты. Ахырын күрдегез: партия җимерелде һәм аны сагынучылар юк диярлек.

Ә бит төрмә белән янаучылар арасында язучылар да бар иде! КПССка гашыйк булганга идеме соң аларның болай тартышулары? Түгел! Хикмәт шунда, аларның бөтен иҗатлары социалистик реализм, коммунистик фәлсәфә, советча яшәү рәвеше белән сугарылган. Күпме китаплары юкка чыгачак... Әнә шул ихтималдан куркытылар «чын совет язучылары».

Ләкин Әмирхан Еники, Нәкый Исәнбәт, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Батулла кебек әдипләрнең, минемчә, вөҗданнары тыныч. Алар иҗатында коммунистик кибәк тә

юк, яки, булган сурәттә дә, бик аз. Анысы да әдәбияттан читләштерелмәү хакына гына кушылган — әз генә җилгәрсәң дә милләтебез аларның әсәрләрен гомер-бакый үзенеке дип санаячак.

Иҗатка карата төп фикерем шушы: кайсы да булса сәясәткә ялагайланып, көчлеләргә тәлинкә тотып язуга караганда бөтенләй язмавың артыграк.

*— Татар милләтенең азатлык өчен көрәшкә чыгуы... Татар язучысының роле, урыны... Мәйданнарга чыгу... Кайбер әдипләр моны кирәксенми. Кайсылары актив каләмдәшләрен гаепләп чыга... Ә Сез нинди фикердә?*

— Татар халкы кайда — татар язучысының да урыны шунда. Халкы мәйданда икән — мәйданда, милләте азатлык өчен сугыша икән — ул да сугыша, халкы бетә икән — ул да бетә... Язучы бит ул үз халкының төнендәге бер күзәнәк. Халык аннан башка яши дә аладыр, ә язучы үз халкыннан башка яшәренә исәп тота икән, ул инде язучы да, кеше дә түгел.

Ходайның шактый бәндәләре кебек үк, язучыларның да кайберләре ике урындык уртасында утырырга тырыша. Урыс шовинизмы (фашизмы булмаса ярый әле!) җиңә икән, ялт кына урыс урындыгына шуыша: «Мин сезнең яклы!» Әгәр халкыбыз башка милләтләр кебек үк тулы бәйсезлеккә ирешә икән, алар тиз генә безнең яктагы урындыкка күчеп: «Без дә сезнең белән булдык»,— диячәкләр. Әле андыйлар җиңүдән соң чын көрәшчеләрнең башына басып сөйләшүчән булалар.

Көне килер, милләт һәркайсыбызны үлчәп, барлап карар... Тукайның зурлыгы, даһилыгы нәрсәдә? «Мияубикә», «Кәҗә белән Сарык әкияте» кебек әсәрләр иҗат итүендәме? Минемчә, түгел. Тукай халык рухын тәрбияләүче иҗтимагый-сәяси мәкаләләр язып яшәмәсә, милләтенә элек эшләп торучы кара йөзләрне фаш итеп тормаса, халык аны хәзер яратканча ярата алыр идеме? Юк! Тукайның бөеклеге нәкъ менә «коеп куйган поэт кына» түгел, бәлки «общественный деятель дә» булуында.

Мәйданнарга мин микрофоннан нотык сөйләү өчен чыкмыйм. Анда чыгыш ясаучылардан өстәмә акыл алырга да өметләнмим. Ник дигәндә, үз башымда да шул үк проблемалар, чишелешләр вә фикерләр кайнап тора. Митингларга чыгуымның максаты — халыкның йөзенә карау, рухын үлчәү. Өмет бармы безнең милләттә? Азатлыкка сусавы ни дәрәҗәдә? Ярты юлда туктап калырдай түгелме? Мөнбәрләрдән, сәхнәләрдән сөйләү сәләтем юк. Берничә мең кеше алдына чыгып бассам, каушыйм да калам. Ярты фикеремне дә әйтә алмыйм. Ә менә миллион кеше «алдында» җиңел сөйлим. Бу сүзләрем белән мөштәриләрне (подписчикларны) күздә тотам. Чөнки 250.000 данә чыга торган «Татарстан яшьләре»н кимендә миллион кеше укыйдыр дип фараз кылам. «Социалистик Татарстан» да тернәкләнеп китте. Аның да тиражы зур. Ул «трибуна»дан да кимендә ярты миллион кешенең игътибарын җәлеп итәргә мөмкин. Радиодан да чыгышлар ясап торам әле.

Актив һәм көрәшче каләмдәшләрен гаепләүче язучылар турында сөйлисем дә килми. Шулай да сүзсез калу ярамый. Бер сүз белән әйткәндә, көнләшәләр. Ягъни: «Ничек әле бу Фәүзия Бәйрәмованы (башка шәхесләр исемен дә язарга була) бөтен халык таный, ә мине бар дип тә белмиләр?!» Узган елның март уртасында үткәрелгән язучыларның зур җыелышында сез дә булдыгыз кебек, Мансур әфәнде. Хәтерегездәдер, анда СССР Язучылар съездына делегатлар сайладык. Егермеләп кандидат арасында Фәүзия Бәйрәмова да бар иде. Эчтән генә күрәзәлек кылып утырам: «Кемне-кемне, Фәүзияне сайлыйлар инде. Чөнки җөмһүрият, милләт язмышы өчен янып, өзгәләнеп көрәшә һәм аның изге максатын һәр язучы күреп-аңлап тора. Милләтенә дошман булган язучының гына каршы тавыш бирүе мөмкин монда. СССР Язучылар съезды трибунасыннан милләтебезнең ашкынулы өметләре, хәрәкәтләре турында сөйләү ихтималы да туса тагын!» Шуннан соң яшерен сайлау мәгълүматлары бәян ителде. Фәүзиябез төшеп калган!.. Каләмдәшләрем өчен оялдым да, яндым да.

Дөресен әйтим, Фәүзиянең иҗатына сокланганым юк хәзергә. Милли көрәштәге һәр адымын, һәр фикерен хуплау да дөрес түк булмас. Ләкин ул — милләтнең шиксез бәхете. Фәүзия күренмәсә, безнең хатын-кызларыбыз сәясәтне ирләр эше дип кенә белеп, җөмһүрият максатын да аңламыйча яшәрләр иде әле. Шул үрнәге өчен генә дә зур хөрмәткә лаек ләбаса!

Милли хәрәкәтнең киңәюенә татардан туган урыс телле язучыларның бәхил түгеллеге аеруча күзгә ташлана. Бөтен татар туган телдә сөйләшүгә, укуга күчсә, безнең иҗатның хаҗәте бетәр, дип шүрлиләр. Аларны милләт язмышы борчымый. Монысы — минем фикер генәдер, бәлки...

*— Сезне, Фәнзаман әфәнде, үтә милләтче, татар белән урыс арасына ут салучы дип гаепләргә маташучылар да бар. Редакцияләргә килгән хатлардан да сизелгәли бу. Моңа карата нәрсә диярсез?*

— Соравыгызны тыңлап бетерүгә үк абайладым: «әгәр», «әйтик» сүзләрен еш кабатларга туры килер миңа...

Әле кичә генә төн уртасы үткәнче эшләп утырырга туры килде. Ял итеп алу максаты белән телевизорны ачтым. Беренче программада «Пятьдесят на пятьдесят» дигән тапшыру бара, Петербург «На все сто» исемле тапшыру күрсәтә. Икенче программада бер поп вәгазь укый. Ә бу сәгатьтә Татарстан телевидениесе әһелләре йә күптән йокыда, йә үзләре дә балалары белән бергә поптан хәер-фатиха алып утыралар. Хет шунда «Егерме бишкә егерме биш» дигән тапшыру да юк, ичмасам. Гарьлек тә, хурлык та...

Әгәр мин Мәскәү телевидениесенең тәүлек саен 50-60 сәгать буе үз сәнгатен, үз сәясәтен, үз динен, үз телен сеңдерүе белән килешеп бетмәсәм, татар телевидениесе дә туган телдә һичьюгы 15 сәгать тапшырулар бирергә тиеш, дисәм шул буламы үтә милләтчелек?

Әгәр мин, урыслар басып алганчы татарлар хәзерге Татарстаннан ун-унбиш мәртәбә зуррак биләмәнең хуҗасы булганнар, дип язсам, дөресен аңлатсам — шул буламы ике милләт арасына ут салу?

Әйтик, Татарстан Югары Советындагы шовинист депутатлар безнең Ватанны Россиянең чүплеге, сукыр эчәгесе итеп калдырырга тырышалар. Әгәр дә мин шуларга каршы чыксам, татарлар да кешеләр, татарлар да азатлык алырга хаклылар, дип язсам — шул булдымы экстремистлык?

Әгәр дә мин, һәр халык үзенә кирәкле ризыкны үзе үстерсен, бер милләт тә башкалары җилкәсендә яшәмәсен, дигәнмен икән — шуның өчен гаепләргә тиешләрме мине?

Әгәр дә безнең сабыйларыбызны дөньяга килгән көннәреннән үк туган телдән мәхрүм итәргә тырышалар икән, мин шуңа көенә-көенә әсәрме, мәкаләме язам икән — шул буламы гаделсезлек?

Татар халкының кимсетелүенә кагылышлы мондый мисалларны йөзләп, меңләп китерә алам. Бөтенләй үк ике аяклы хайванга әйләнмәгән кеше минем таләпләрне, өметләрне дөрес аңларга тиештер. Әле «минем» дип ялгыш ычкындырдым. Болар бит барысы да милләттәшләребезнең уртак таләпләре! Әнә шул изге таләпләрне, омтылышларны кирегә сукалаучы бәндәләргә мин бары тик мыскыл белән карыйм. «И, надан, ту яңадан мәгърифәтле анадан»,— димен. Болары, кызганычка каршы, үз сүзләрем түгел...

*— Язучылар берлеге инде кирәкми дигән сүзләр йөри... Ә безнең татар өчен ничек икән?*

— СССР Язучылар берлеге турында сорау түгелдер инде бу. СССР империясе белән бергә, иншаллa, анысы да таркалды. Әмма берлекме ул, иттифакмы, әллә берләшмәме — ниндидер оешма кирәк. Киңәшеп яшисе, бер-беребезгә таянасы, өлкәннәргә хөрмәт күрсәтәсе, яшьләрнең күзен ачасы бар. Кемгәдер матди ярдәменең дә кирәк булуы мөмкин. Үлем-җитем дә ерак йөрми...

Ләкин бу иттифак китаплар нәшер итүдә үз әгъзаларына өстенлек дауламаска тиеш. Гомумән, кайсы язучының китаплары үтемле, кайсысыннан нәширләргә файда күбрәк керәчәк — китап басучылар үзләре хәл итсен. Бик сәер хәлләр күреп яшибез бит: кайсыдыр шагыйрь китабы өчен 4-5 мең сум (хәзерге чүп акча турында әйтмим) гонорар ала, ә китабыннан кергән файда 100-200 сум... Милләткә файда бармы шуннан? Юк. Тиражы аз икән, димәк, сораучылары да аз. Гомумән, язучылар халык кесәсеннән бушлай бер тиен дә алырга тиеш түгелләр. Гонорарны да китап сатылып беткәннән соң гына түләргә тиешләр дип беләм. Ягъни, мәгълүм процентын... Гонорар китап китергән керемнән һичничек артык булмаска тиеш. Боларын сүз уңаенда әйттем.

*— Әйе, Сезнең сүз дөрес. Ләкин монда кайбер искәрмәләр дә булырга тиештер. Мисал өчен, бүген Сез һәм мин мактаган Тукай шигырьләре дә, Дәрдемәнд һәм Туфан әсәрләре дә нәширләргә табыш бирмәскә мөмкин. Әмма алар милләткә, һичшиксез, кирәкле китаплар. Димәк, мондый очракларда инде нәширләр бер-бер җаен табарга тиеш булачаклар. Ә болай, тулаем алганда, әлбәттә, Сезнең сүз — дөрес. Мин үзем дә күптән инде шундый фикердә йөрим.*

*Сезгә тагын бер сорау бирәсе килә. Соңгы еллардагы милли хәрәкәт турында нинди фикерләрегез бар?*

— Милли хәрәкәтнең бер генә юлы калды — җиңеп чыгу. Бу юлы да җиңмибез икән, соңгы мәртәбә мәтәлдек дигән сүз. Чираттагы упкыннан котылу булмаячак. Күп милләттәшләрнең авызыннан гел бер җөмләне ишетәм: «Йә җиңү, йә үлем!» — диләр. Беренче карашка кайнар кебек, әмма башкача әйтеп булмый хәзер. Рәсәй империясе тормәсеннән мөмкин кадәр тизрәк котылырга кирәк. Күреп торабыз, бу империянең бер чакта да тотрыклы булганы, адәмчә яшәгәне юк. Кан коюлар, басып алулар, переворотлар... Адәмчә яшиселәре дә юк. Үткән ел ахырында «Татарстан яшьләре» газетасында «Әллә каргыш, әллә язмыш» дигән зур мәкаләмдә бу хакта тәфсилләп яздым инде. Игътибар итегез: Рәсәйнең җире зур, әмма иген үстерерлек мәйданнары юк диярлек. Чөнки ул басу-кырларны дистә еллар, гасырлар буе ташландык хәлдә тотты — тәрбия кылмады. Крестьяннары да юк санында — урыслар тулаем диярлек

шәһәрләргә күчеп бетте. Шунысы да бар, бу халык гомер-бакый башка дәүләтләрне, халыкларны яулап-талап яшәде. Әгәр кем дә кем гомер буе фатир басып яшәгән икән, картаймыш көнендә генә намуслы хезмәт белән яши алмаячак. Бу очракта да шулай... Кабатлап әйтәм: мөмкин кадәр тизрәк котылырга — бәйсезлек алып, Берләшкән Милләтләр Оешмасына сыенырга кирәк! Дөрләп яна торган өй эчендә әкрен кыймылдамыйлар. Ә Рәсәй яна... Аны башка халыкларның каргышы яндыра.

Мин үзем, мәсәлән үлемгә дә әзер. Милләтең дә калмаслык булгач, яшәүдән ни мәгънә?! Монысын да онытмыйк: Жириновский кебекләрнең идея-сәясәте җиңә икән, бер татарга да рәхим-шәфкать тәтемәячәк. Алдыбызда көтә торган вакыйгалар каршында Явыз Иван китергән һәлакәт уен гына булып тоелачак. Россиянең тиз арада гына демократик юл белән яши алачагына өметем юк. Димәк, фашизмның килүе бик ихтимал. Аңлаган кеше аңларлык: ул хәрәкәткә Россия хөкүмәте каршылык күрсәтергә теләми. Фашизм күп халыкларны кырып бетерергә өнди, ә Россиянең Югары судында аның лидерларына карата тиешле статьяны табарга тырышмыйлар. Югыйсә бер кешегә үлем белән янасаң да хөкем итү тәртибе бар. Халыкара законнар да сугышка өндәүне, геноцидны тыя. Россия җитәкчеләренә исә, үз телләре белән әйтсәк, все нипочем!...

Кайберәүләрдән: «Россия зур, урыслар күп, алар белән көрәшеп, җиңүгә ирешеп булмаячак»,— дигән сүзләрне ишетәм. Ишеткән саен балачагымның бер вакыйгасы искә төшә. Ятим чагым. Нибары ун яшь. Йорттан-йортка кунып йөрим. Беркөнне, тамак өзелеп ачкач, күрше авылдагы түтәй ашатмасмы дип, Кәҗә Байларга киттем. Яз көне бу. Карның шулпаланган вакыты. Аякта сәләмә оек белән чабата икәнен истә тотсак, аяк һәрвакыт су эчендә. Бервакыт өлеге авылга җитәрәк, күлдәй җәйрәп яткан үзәнлек аркылы бара башладым. Чумып китмәү өчен аска карап атлыйм. Бервакыт башымны күтәреп карасам, котым очты: алдымда, мөгезләрен җәйләп, муенын җыерып, таудай үгез басып тора. Җылыйм, күзләренә тилмереп карыйм — ни сөзми, ни китми. Тик басып торгангадыр, аякларны карлы су ашый. Ниһаять, сабырым бетте, бүрекне салдым да, җиппенә-җиппенә, ачырганалып кычкыра-кычкыра үгезгә ташландым. Әллә куркып куйды, әллә көтелмәгән сәер хәлгә аптырады хайван — кинәт кенә борылды да китеп барды... Моның белән нәрсә әйтергә теләвем аңлашылгандыр: тәвәккәллек кирәк! Ачырганалып, өзелеп китәрдәй булып көрәшергә кирәк. Соңга калуыбыз ихтимал... Үз теләге белән бер генә арысланның да майлы калҗаны авызыннан ычкындырасы килмәвен беләбез лабаса! Демократияле уен оештырып, империя аз санлы халыкларны үлем йокысына талдырмакчы. Максаты берәү генә: бер милләтле — урыс милләтле килечәгенә бара.

*— Язарыгызга азыкны, чималны ничегрәк табасыз? Иҗади тормышыгыздан берничә эпизодка тукталмассызмы икән?*

— Мин ике «фронтта» иҗат итүче кеше. Бераз шаяртып әйтсәм, көн аралаш хикәяләр язам, көн аралаш публицистикага хезмәт итәм. Публицистик язмаларга «азыкны» ничек табуым турында сөйләп тә торасы юктыр — аларны көндәлек тормыш бөтен муллыгы белән зиһенгә тутырып тора. Тыгызлап, шартларлык итеп тутыра. Республикада сәяси температура нинди — миндә дә шундый.

Инде дә сатирик, юмористик әсәрләр язу өчен «азык» табуга килсәк, тормышыбызда анысы да муллан. «Һәр яхшыда начар якның берсе булгай» дигән сыман: беренче карашка изге булып, табигый булып тоелган хәлләрнең дә көлке яклары, камиллектән ерак сыйфатлары бар. Игътибар белән күзәтә белсәң, дөнья — көмитләр сәхнәсе кебек. Ә без, кешеләр, шул сәхнәдәге комиклар. Һәркайсыбызның бармагы үзенә кәкре: данны да, малны да күбрәк эләктерергә тырышабыз, шуның хакына хәйлә-мәкерләргә керәбез, алдыйбыз, алданабыз. Кайчак бик җитди максатлы кешеләрнең дә көлке булуын күрәсең. Әйтик, шушы көннәрдә генә бер танышым тәүбә кылып утыра: «Юк, парин: болай яшәп булмый... Эчүне бөтенләй ташлыйм. Исләп тә карамаячакмын! Аннан соң өйләнеп җибәрәм. Халидәне алып кайтам». Дикъкать белән тыңлап утыргач: «Ә ни өчен Халидәне?» — дип сорыйсы иттем. Танышым, шуны да аңламыйсыңмыни, дигәндәй, күземә гаҗәпләнеп карады: «Ул бит гармунчы! Эчкән чакларымда бер уйнап җибәрүе дә ни тора. Күңелең булганчы җырлыйсың, эчмасам!...»

Кайберәүләр миңа: «Ир — хатын, егет — кыз темаларына күп язасың»,— дип кинәя белдерәләр. Шулаен да шулайдыр. Ләкин мин боларның мәңгелек тема икәнен дә онытмыйм. Дөньяда сәясәт тә, хезмәт мөнәсәбәтләре дә үзгәреп бетәр, бүгенге күп проблемалар юкка чыгар, ә ир белән хатын калыр, мәхәббәт калыр һәм... хыянәт тә калыр.

Әлбәттә, тормышның башка тарафларына да игътибарсыз яшәп булмый. Укучыларым сизеп торадыр, сәяси хикәяләрем һәм монологларым да күп, көнкүреш кызыклары турында да күп язам. Гомумән, тормышта ни булса, әсәрләремдә дә шулар...

Чираттагы һәр әсәремне матбугатка тапшырганда күңелгә шик тә керә. Әгәр үзең кызык өчен, күңел ачу өчен дип язган нәрсәңне укыганда укучы ике-өч тапкыр да елмаеп куймаса, хикәямдә үзен, танышларын күрмәсә — эш харап. Әле менә чираттагы

хикәямнең беренче җөмләләрен язып куйдым: «Дөньяда иң бәхетсез бәндәләр — хатын аерган ирләр. Ул мескеннәр үзләрен тәгәрмәче төшеп калган күчәр шикелле хис итәләр. Мондый күчәр җиргә дә тиеп сыдырыла, теләсә кемнең коймасына да килеп терәлә. Йомшак дегетле тәгәрмәч эчендә йөргән чакларын сагынмый җае юк...» Язганда көлгән булам, куанам. Ә укучы көләрме? Белүе кыен.

*— Иң яраткан әдибегез кем? Ни өчен? Аның Сезнең иҗатка тәэсире булды дип уйлыйсызмы?*

— Мин бер генә әдип турында әйтеп чикләнә алмыйм.

Тукай — Тукай инде ул. Канымда да, йөрәгемдә дә, сулый торган һавамда да Тукай бар. Әгәр мин елга мең сәгать буе китап укыйм икән, шул вакытның яртысында Тукайны укыйм. Яттан белсәм дә укыйм. Кыюлыкны да, рухны да, әдәбиятка мәхәббәтне дә шул бирә. Тукай — һәр күзәнәгемә көч биреп торучы аккумулятор сыман.

Тел байлыгым фәкыйрьләнеп киткән кебек тоелса, Фатих Хөсни белән Мөхәммәт Мәһдиевкә тотынам. Аларны укыганда туган телнең мөмкинлекләренә, иксез-чиксез байлыгына, бөгелмәле-сыгылмалы булуына сокланып туймыйм. Алар миңа күп еллар буе бармак яныйлар һәм: «Курыкма, тирәнгәрәк кер, син әле ләззәт күленең кырында гына чыпырдыйсың, чын рәхәтне белмисен!» — диләр сыман. Ә инде чын сатира, сокландыргыч сатира Илья Ильф белән Евгений Петровта.

Тәэсир ягына килсәк, әлбәттә, күпләрнең тәэсире тигәндер. Шикләнмим, ходай мине дә язучы итеп яраткан. Ләкин дистәләрчә, йөзләрчә әдипләрнең тәэсиреннән, йогынтысыннан башка кайсыбыз гына үсә алды икән? Бу очракта:«Нәкъ менә шул өлкән әдиптән өйрәндем»,— дип әйтергә телем бармый. Әле кайчак үземнән шактый яшь язучылар да сокландырып куя. «Әх, сабакы, булдырган бит!» — дигәнемне, куанганымны үзем дә сизми калам. (Минем «сабакы» иң яраткан кешеләремә әйтелә). Гомумән, әдәбиятта ничә яшьтә булуыңның әһәмияте юк. 30-40 яшьтә дә өлкән, үрнәк язучы булырга мөмкин. 60 тан үткән «яшь язучыларны» да беләбез.

*— Хәзерге яшьрәк буын сатириклар иҗаты Сездә нинди уйлар уята? Аларда нәрсә яхшы, ә ниләр җитми?*

— Бу сорауга җавабым иң кыскасы булыр, мөгаен. Яшьләрдән мин чын сатирага, юморга сәләтле бер генә кешене — Зөлфәт Хәкимне генә беләм. Күпчелек табышларына сөенеп яшим. Иҗатындагы кимчелекләргә килсәк, ул аларны үзе күрәчәк — камилләшү өчен кабилияте җитәрлек. Ходай гомер бирсен дә тыйнаклыктан аермасын — татар әдәбиятына бик өметле сатирик килә. Ник берәү генә дисәгез, үзем дә Сезгә сорау бирәм: кайсы чорда чын сатирикларның ишле булганы бар?

*— Безнең байтак кына әдипләр урысчага тәрҗемә ителергә тырыша. Ә сез, нишләптер, алай эшләмисез. Сезгә әллә дөнья күләмендәге дан кирәкмиме?*

— Сандугачның үз талында сайравы хәерле, диләр. Үз миллөтемә хезмәт итә алсам да бик бәхетле булыр идем. Бала чактан ук тәрҗемә әсәрләрен өнәп бетермәдем. Әле урыс телендәге сүзләрнең яртысын да аңламаган үсмер чагымда ук китапханәдән «Давылда туганнар» дигән китапның тәрҗемәсен алып кайттым. Кем тәрҗемә кылгандыр, анысын хәтерләмим. Әмма шунысы хәтердә, һәр җөмләсен укып чыккан саен абынып егылгандай булам. Адым саен түмгәк, адым саен чокыр... Интегә-интегә ике-өч битен укыгач, урысчасын табу өчен (мәктәп программасы буенча аны уку мәҗбүри иде) кабат чыгып киттем. Урысчасын уку — ул телне бик начар белсәм дә рәхәтрәк булды.

Сатира-юмор әсәрләрен тәрҗемә итү, минемчә, яңа әсәр язуга караганда да четрекледер. Никадәр канатлы кәлимәләр, туган телеңә генә хас гыйбарәләр, мәкальләр, фразеологик тәгъбирләр, әйтемнәр, сүз уйнатулар бит анда. Урысча чыга торган коллектив авторлы китаплар өчен хикәяләремне, фельетон һәм очеркларымны шактый тәрҗемә иттеләр итүен. Әмма, дөресен әйтим, берсчакта да канәгать калмадым. Минемчә, һәр сүзнең үзенчә яңгырашы, мәгънәсе генә түгел, үзенчә төсе дә, исе дә бар. Шуларның кайсын да булса югалтсаң, нинди тәрҗемә инде ул?! Безнең халыкны җиде миллион (хаклыкта ике мәртәбә күбрәк булуына иманым камил), диләр бит. Әсәрләремне шуның бер миллионы укыса да миңа бик җитә. Кемнәрдер артыннан үз әйберләремне тәрҗемә иттерүне кайгыртып йөрергә минем вакытым юк. Андый гамьнең башыма да кереп чыкканы юк иде әле. Ярый Сез искә төшердегез... Ә инде дөньякүләм дан турында шаяртып әйтәсез, билгеле. Әле үз халкыңның үз итүен тоя алсаң да баш күккә тияр иде. Хәер, анысы да кирәкми. Баш әйләнүе бар. Баш әйләнсә — бетте! — иҗат та юк, үзең дә юк.

*— Якын арада нинди китапларыгыз дөнья күрәчәк? Безнең китап басу эше турында Сез нинди фикердә? Бу өлкәдә без Тукай чорыннан ерак киттек микән?*

— Нәшриятта тоткарлык чыкмаса, китапларымны бастыру юлга салынды кебек. Әле ел ярым элек кенә «Сакалыңа ут капса...» исемле хикәяләр җыентыгым дөнья күргән иде. Кибетләрдән җил-давыл алып китте сыман — берничә атнада сатылып та бетте. Хәтта, укыдыгыз микән, «Татарстан яшьләре» ндә шырпы кабыдай гына укучы хаты басылды. Имеш, 25 тиенлек шул китапчыкны базарда өч тәңкәгә сатып утыручылар да күренгән. Күңел булу өчен күп кирәк мени — валлаһи мәгәр, шуңа да тиле кебек сөенеп йөрдем. Инде менә якын арада «Безнең сурәт» дигән җыентыгым чыгып җитәр. Анысы — публицистика. Татар халкының сурәтен күзаллауга бер омтылыш. Без үз милләттәшләребезне зурлыйбыз бит инде... Ихлас, тырыш, дибез, сабыр һәм батыр, дибез... Куркаклары, аумакайлары да күп түгел микән? Кыскасы, бу китап татарның кимлеге турында. Кәгазь кытлыгы аркасында быелгы планга керә алмыйча алдагы ел планына калган «Гөнаһ шомлыгы» дигән күләмлерәк китабым нәшриятта ике ел ята. Хәтерем ялгышмаса, йөзгә якын сатирик, юмористик хикәяләр туплаган идем. Дүрт көз белән шуны көтәм. Өстәл тартмамда «Ике этка бер сөяк» дигән сатирик повестым ята. Күптән әзер. Әмма нәширләргә тапшыру өчен батырлыгым җитми. Сәбәбе — хәзерге дөнья агышының күз иярмәслек тизлеге. Кичәге проблема бүген өчен искерә, бүгенгесе иртәгәгә ярамый. Каләм тыга-тыга йөдәдем инде. Ахыры нәрсә булып бетәр... Аны бирергә җөрьәт итмәсәм, яңа хикәяләремне тәкъдим итәрмен. «Азгын ирне ничек үтерергә?» дип исемләрмен, ахры, ул җыентыкны. Уңышлырак исем табуым да ихтимал. Публицистик язмаларым көндәлек матбугатта өледән-өле басылып торса да, киләчәктә публицистикадан торган китап чыгарачагыма шикләнәм. Сәбәбе шул ук: вакыйгалар тиз үзгәрә, республиканың, милләтнең максатлары да яңарып тора. Публицистика өчен көндәлек матбугат отышлырак.

Китаплар басуга, ягъни нәширләр хезмәтенә булган мөнәсәбәтемне бая әйтеп үттем инде бераз. Җилкендереп торучы өметем дә бар: киләчәктә шәхси басмаханәләр ачыла башлар кебек. Барыбызга да мәгълүм, хәзергә тегә яки бу китабын дөньяга чыгарту өчен язучылар нәширләр алдында тезләнә. Баш ияbez, ялварабыз. Алдагы елларда, мөгаен, куласа икенче якка әйләнер: үтемле китабың булса, китап басучылар язучылар артыннан үзләре йөрер. «Зинһар, бүтән нәширгә бирмә, әфәндем, миңа бир. Әҗерен дә яхшы түләрмен, затлы итеп бастыру чарасын күрермен»,— диярләр. Түләү мәсьәләсе дә кызыктырмый түгел. Әле әйтеп үттем: «Безнең сурәт» дигән биш табаклык китабым чыга... Исәпләп карасаң, андагы язмаларны иҗат итү өчен айлар сарыф ителгән. Никадәр уйланулар, борчылулар, йокысыз төннәр!... Әҗере хакында тел өрәм итеп әйтесе дә килми — күп булса кулга 1000-1100 сум тиячәк. Элек ул ярап тора иде. Ә хәзер? Бер сарык бәясе бит, ходавәндә! Анысы да әләкми бугай әле. Мин андый акчаны радиога бер сәгатьлек тапшыру ясап та алам. Анысына киткән хезмәт 2-3 көннән артмый. Тик шунысы кызганыч, радио тапшыруы морҗадан чыккан төтен сыман — тарала да бетә, онытыла... Килешү белән рәссамлык итсәм (андый һөнәрем дә бар), хәзерге 1000 сумны эшләү өчен бер көн җитә.

— *«Үтемле китабың булса» дигән сүзеңә кире кайтыйк әле, Фәнзаман әфәнде.*

— Нәрсәсенә кайтып торасың инде аның?! Үтемле китабың юк икән, потың бер тиен. Киләчәк нәширләре язучылар исемнәре дә күп күренсен дип кенә биш тиенлек куян урынына ун тиенлек зыян ясап ятмаячаклар. Кимендә 50 мең, 100 мең тиражлы китаплар гына басачаклар алар. Язганың шуны да тартмый икән, «әнә юлың, кодагый» кебегрәк сүз белән озатачаклар һәм дәрес эшләячәкләр! Сез искәрткән Тукай чоры кире кайтырга тиеш, Мансур әфәнде. Иртәгә макулатурага әйләнәчәк китаплар басылмаячак. Шул чорны ашкынып көтәм.

— *Хәзер бездә тыюлар да юк шикелле. Әмма сатира һаман әллә ни тернәкләнеп китә алмый әле... Сәбәпләре нидә икән? Тормыштамы, язучыдамы?*

— Тыюларның берчакта да бетәсе юк, ахры. Җиңелчә юмор гына тоткарлыксыз үтә. Күпчелек мөхәррирләр, күп аларына кискенрәк язма яки хикәя килеп керсә, әле хәзер дә сагаеп калалар. Хәер, нишлисең бит, алар да 440 ел буе башка бер халыкның колы булып яшәгән татарның балалары. Республикабыз мөстәкыйль дип рухланып сөйләшкән чакта барчасы да батыр кебек, милләтпәрвәр кебек... Илле дә мәгәр шул минутта алларына көтелмәгән, исәп ителмәгән бер мәкалә салсаң, шомланып калалар. Маңгай күзләре сиңа карый, күңел күзләре — Мәскәүгә.

Соңгы биш-алты елда фикерләремне үткәрү өчен җан-фәрман килүемне үзем беләм дә, ходай белә. Моннан дүрт ел чамасы элек Татарстанның союздаш булырга тиешлеген куәтләп яздым. «Юләр сатма инде»,— дип, шул абзацларым сызып ташладылар. Дүрт ел элек «Вечерняя Казань» газетасы кебек үк татарча газета кирәклеген күтәрдем. «Синең башка гына килә инде тузга язмаган фикерләр»,— дип, бик озак кирелләнделәр. Тарткалаша торгач, анысын үткәрә алдым. 1990 ел язында: «Иртәме-соңмы, империяләр барыбер таркала» дигән җөмләмне, «артык зур кабиләләр

барыбер таркала» дип төзәтteләр. Ленин сүзләрен китерә-китерә Татарстанның Союздан, Россиядән аерылып чыгу хокукы барлыгын исбатлаган идем, мәкаләмнең үл өлеше юкка чыкты. КПССны фаш итеп язган мәкаләләрем, памфлетларымның күбесе басылмады... Ул чакта карап торганыбыз ике генә газета иде бит әле. Бигрәк тә «Социалистик Татарстан» редакциясе бөгырьне корытты. (Хәзергесенә артык үпкәм юк, халыклашып бара.) Әле ярый «Татарстан яшьләре» юл бирә килде. «Шәһри Казан» да чыга башлагач, хәл тагын җиңеләйде. Югыйсә, кычкырып елыйсы килгән, үртәлүдән ми кабарган, кан кайнаган чаклар күп булды. Шунысына сөенәм Татарстан әкренрәк кыймылдаса да, минем кебекләр хыялланган юл белән бара. Әгәр дә матбугатта тоткарлыклар, тыюлар булмаса, бүгенге проблемаларның хәл ителгәнлеген күрәсе кешеләр идек инде. Яхшы беләбез бит: беренче фикерне, нигездә, язучылар, галимнәр, журналистлар күтәрә. Аннан соң ул халык фикеренә әверелә, тора-бара тормыш таләбе дәрәҗәсенә күтәрелә. Минемчә, фикерне тыю — халыкның тәрәккыена аяк чалуга тиң.

Сораудагы темадан читләштем кебек. Әмма боларны әйтмичә ярамый. Сатираның язмышы да матбугатның ни дәрәҗәдә иркле булуына бәйле ләбаса! Ә ул кәнфит тә, майлы калҗа да түгел. Тормышның бөтен «кәкре-бөкресен», гөнаһларын, киртәләрен өтәргә, яндырырга тиеш ул. Аның үзенә киртә куйдыңмы, сатирик жанрларга йөз тоткан каләм ияләре чигенүне хуп күрә. Ансат бит: майлы-җайлы мәкаләләр, хикәяләр яз, хезмәт алдынгылары турында очерклар сырлап утыр — бәхәс тә юк, талашу да кирәкми, ә тормыш йоклаган көе утыра бирә, милләтең дә айнымыйча эри бара... Сатирикның дөньясы зарарлы цех кебек ул. Тукайны ни өчен яшьли янып үлгән дисез? Туберкулез гына түгел аның сәбәбе! Түгел!...

*— Иң соңыннан бер кызыграк сорау: Тукай кебек мәшһүр булырдай, олы дан алырлык әдип татар тарихында тагын туа алырмы икән, киләчәктә?*

— Туа алмаячак. Иманым камил — беркемгә дә: «Мин инде Тукай дәрәҗәсенә җиттем!» — дияргә туры килмәячәк. Аның иҗаты, шәхесе хакында уйланган саен бер нәтиҗәгә килеп тертеләм: безнең кебек ике аяклы, ике куллы адәм сурәтендә яшәсә дә, Тукай ул кеше булмаган, татар дөньясын кузгату, айныту, сискәндерү өчен ходай тарафыннан җибәрелгән пәйгамбәр булган! Зинһар, көлмәгез, бу фикеремнең раслыгын тарих үзе исбатлаячак. Күрмисезмени, 27 яшьлек язучыларыбыз акып да утыртып өлгерми әле. Ә ул аксакалларыбыз да хәйран калырлык гамәлләр кылып өлгергән. Тукайның олуглыгын аңлап, бәяләп бетерерлек кешеләр тууына да шикләнәм.

Ләкин үз замандашларын аның сыман чеметәчәк, кытыклаячак, сөендерәчәк, күзләрне яңа максатларга юнәлдерәчәк әдипнең туарына ышанам. Гамил Афзал дәрәҗәсендә булырмы ул, югарыракмы — анысын әйтүе кыен, әмма туачак. Аның мөһим бер шарты бар: Татарстан азат һәм бәйсез булырга тиеш. Читлектә вәемсыз кенәрипләр, тутый кошлар гына үсә ала, ә киң канатлы бөркетләр өчен иркен дөнья һәм хөррият кирәк. Онытмыйк, Тукайның иҗат еллары демократияле чорга туры килгән. Алай да цензура барыбер тынгылык бирмәгән — кискән, төзәткән, бозган... Хак булса, үләр көннәрендә дә: «Аһ, шушы цензура бөгырьне таламаса!...» — дигән сүзләрне тәкърарлап яткан. Бәлки, ул: «Таламаса, озаграк яши алган булыр идем»,— дип әйтергә теләгәндер.

Тукайның бердәнбер булуы хәерле. Һәркайсыбыз яшүсмер чакта Тукайга тигезләнергә өмет баглый. Яши-яши аңлыйбыз — булмый! Көчебез дә, сәләтебез дә җитми... Ә шул арада халык өчен азмы-күпме файда китереп калабыз. Тукай ул үлемебезне дә җиңеләйтә. Соңгы сулышта: «Гомрем иртә өзелә, шуңа күрә иҗатым да кыска булды»,— дип үкенә алмаячакбыз. Шулай дисәк, Тукай көләчәк...

**Әңгәмәне Мансур Вәлиев әзерләде.**

**Рафаэль Мостафин,**

**Рәис Даутов**

# РЕПРЕССИЯЛӘНГӘН ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ

## Гали Рәхим



Мөхәммәтгали Мөхәммәтшакир улы Габдерәхимов 1892 елның 4 ноябрендә Казанда сәүдәгәр-коммерсант гаиләсендә туа.

«Җир йөзе» исемле беренче фәнни-популяр китабы 1909 елда дөнья күрә. Революциягә чаклы «Ак юл» һәм «Аң» журналларында даими языша, халык авыз иҗаты әсәрләренә нигезләнгән әкият-хикәяләрен, шигырьләрен һәм мәкалә-рецензияләрен бастыра. «Дача кайгысы» исемле комедиясе 1914 елда сәхнәдә уйналып уңай бәя ала. Шәрекъ шагыйрьләреннән тәрҗемә шигырьләре 1919 елда аерым җыентыкка тупланып басылып чыга.

Г. Рәхимнең революциядән соң иҗат иткән әдәби әсәрләре күп түгел: бер төркем лирик шигырьләр, берничә хикәя, «Җанвар» (1919) исемле пьеса һәм «Идел» (1921) исемле повесть. Бу елларда ул татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыеп бастыра, тирән аналитик мәкаләләр, рецензияләр яза. Аның унга якын фәнни хезмәте һәм дәреслекләре аерым китап булып басылып чыга. Әлбәттә, туктаусыз эзәрлекләүләр булмаса, әдип тагы да нәтиҗәлерәк эшли алыр иде.

Г. Рәхим 1931 елның 6 маенда ОГПУ органнары тарафыннан кулга алына (Җ. Вәлиди, С. Җәләл һ. б. белән бергә) һәм «контрреволюцион милләтчелектә» гаепләнә. 1932 елның 11 маенда булган суд аны биш елга ирегеннән мәхрүм итә. Ул Ак диңгез-Балтыйк каналы төзелешенә җибәрелә. Тырыш хезмәте өчен срогыннан алда, 1934 елның 22 августында, иреккә чыга. Казанга кайтып, педагогия институтындагы элекке эшенә урнаша алмагач, 1936 елның көзеннән 1938 елга чаклы Дәүләт банкында финанс хезмәткәре булып эшли. 1938 елны яңадан кулга алына, берничә ел Казанның төрле төрмәләрендә иза чигә. 1940 елның 27 февралендә Махсус киңәшмә утырышы аны гаепсез дип таба һәм иреккә чыгара. Ләкин аны беркайда да эшкә алмыйлар. Исәнлеге шактый какшаган әдип гомеренең соңгы елларын ачлыкта интегеп яши. 1934 елның 3 мартында Г. Рәхим илле яшендә вафат була. Кабере Казанның Яңа Бистә зиратында.

---

Дәвамы, башы 2, 3 саннарда.

## Ибраһим Салахов



Ибраһим Низами улы Салахов 1911 елның 30 августында Казакъстанның Күкчәтау шәһәрендә эшче гаиләсендә туган. Башта мәдрәсәдә, аннары туган шәһәрендәге җидееллык татар мәктәбендә белем алганнан соң, 1928—1931 елларда Казан педагогия техникумында укый. Шунда укыганда шигырьләре, әдәби парчалары белән яшьләр-балалар матбугатында катнаша башлый. Техникумны тәмамлагач, берникадәр вакыт газета-журнал редакцияләрендә эшли, аннары өч елга якын гаскәри хезмәттә була. Бу чорда әдипнең «Мәхәббәт һәм өмет» дигән повесте языла, «Ярату» (пьеса), «Дуэль» (повесть) һәм «Постта» (шигырьләр) исемле китаплары басылып чыга.

И. Салахов — әдип Г. Ибраһимовны илле еллык юбилее белән котлап язылган күмәк хатның авторларыннан берсе һәм Ялтага барып, ул котлау хатын Г. Ибраһимовның үз кулына тапшыручы. 1937 елның 25 октябрендә кулга алынгач, аны нәкъ менә «халык дошманы» (Г. Ибраһимов?!) белән контрреволюцион яшерен элемтә тотуда, аңа арадашчы булып хезмәт итүдә гаепліләр. Шул уйдырмаларга таянып, СССР Югары судының күчмә сессиясе И. Салаховны ун елга ирегеннән мәхрүм итә һәм «Гулаг архипелагы»ның җәһәннәмнәрен гизәргә җибәрә. Әдип Колыма прискаларында исәнлеген какшата, аягын имгәтә, күзләре начар күрә башлый. 1947 елның 25 октябрендә срогын тутырып азат ителгәч тә, Казанда күренергә аның батырчылыгы җитми, кабат кулга алынудан куркып, казакъ далаларында качып яши. Фәкать 1953 елда Сталин үлгәннән соң гына ул җиңел сулыш ала.

1957 елда И. Салаховның Казанда дүртенче китабы — «Дала дулкыннары» исемле шигырьләр җыентыгы басылып чыга. «Яңадан туган» язучы зур дәрт белән яңа әсәрләр язарга тотына: 1965 елда «Күкчәтау далаларында» исемле романы, 1971 елда «Төн кызы» исемле хикәяләр җыентыгы, сиксәненче елларда «Иманнар тамыр җәйгәндә» исемле тарихи романы һәм совет концлагерьларын фаш иткән «Колыма хикәяләре» исемле документаль-хроникаль повесте дөньяга килә. Соңгысы өчен әдип 1990 елда Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнде.

И. Салахов хәзер дә туган шәһәре Күкчәтауда яши һәм әдәби иҗат эшен дәвам итүче.

## Сирин



Сирин Хәниф улы Батыршин 1896 елның 14 декабрендә Татарстанның хәзерге Баулы районы Кәрәкәшле авылында крестьян гаиләсендә туа.

Беренче шигырьләре Гражданнар сугышы елларында Бөгелмәдә чыга торган «Юксыл» газетасында басыла. Әмма аның үзенчәлекле шигъри таланты егерменче еллар ахыры — утызынчы елларның беренче яртысында гына ачыла башлый. Шул чорда ул балалар өчен берничә рәсемле китап һәм зурлар өчен «Тамчылар» исемле (1931) искиткеч моңлы, эчкерсез шигырьләр җыентыгы бастырып чыгара. Ләкин аңа яңа иҗат хыялларын белән озак юанырга туры килми: 1935 елның 23 августында ул кулга алына. Берничә язучы белән берлектә контрреволюцион оешма төзеп, Советка каршы пропаганда алып баруда гаепләнә (58 статьяның 10 һәм 11 пунктлары), 1936 елның 31 гыйнварында Махсус киңәшмә карары белән биш елга ирегеннән мәхрүм ителә.

Лагерьдан Сирин рухи яктан сындырылып, иҗади яктан тәмам сүнеп чыга. Туган авылына кайткач, ул, әдәбияттан бөтенләй читләшә, колхозда гади умартачы булып эшли. Аның 1959 елда чыккан «Шигырьләр» китабы да нигездә элек язылган әсәрләреннән төзелә.

Сирин 1969 елның 23 ноябрендә туган авылы Кәрәкәшледә вафат булды.

## Фатих Сәйфи-Казанлы



Язучы-прозаик, драматург, публицист, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәтфатих Камалетдин улы Сәйфуллин (әдәби псевдонимы — Фатих Сәйфи-Казанлы) 1888 елның 22 мартында элекке Казан губернасының Спас өязе Карамалы авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа.

Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, җәдит мәктәпләрендә мөгаллим булып эшли башлый, 1915—1917 елларда «Галия» (Уфа) мәдрәсәсендә, революциядән соң Казан техникумнарында, хәрби курсларда, Татар Коммунистлар университетында, педагогия институтында тарих һәм иҗтимагый фәннәр укыта. Февраль революциясе көннәрендә Уфада татар эсерлары органы «Ирек» газетасының нашире (редакторы — Г. Ибраһимов), ә совет чорында «Кызыл Татарстан» (1923—1925) газетасы, «Яңалиф» (1927—1929) журналының редакторы була, республика Мәгариф һәм Җир эшләре комиссариатларында төрле җаваплы вазифалар башкара.

Ф. Сәйфи-Казанлының нәфис әдәбият, публицистика, әдәби тәнкыйть өлкәсендәге иҗат эшчәнлеге дә революциягә кадәр үк нык эзгә салына. 1907—1917 еллар арасында язылган «Мөкаддәс хезмәт», «Безнең заман», «Ямьсез тормыш», «Җәмәгать хадиме» пьесалары, күп санлы публицистик мәкаләләре, совет чорында иҗат ителгән повесть-хикәяләре, «Өч нарат» романы, «Дошманнар», «Зәкуан мулла шәҗәрәсе», «Зөбәрҗәт» кебек драмалары, популяр характерда язылган тарихи хезмәтләре, брошюралары — болар барысы да татар әдәбияты хәзинәсенең үзенчәлекле бер өлешен тәшкил итәләр.

Ф. Сәйфи-Казанлы 1936 елның 16 сентябрендә кулга алына. Кайчандыр эсерлар партиясендә әгъза булып торганлыгына нигезләнеп, аны хөкүмәт башлыкларына һәм партия җитәкчеләренә каршы һөҗүм әзерләүдә, милләтчелектә һәм башка шуның ише уйдырма «җинаятьләр»дә гаепилиләр. 1937 елның 3 августында Махсус киңәшмә (ОСО) үзенең ябык утырышында әдипнең «эшен» карап, аны иң югары җәзага — атарга хөкем итә. Хөкем карары ике көннән соң — 1937 елның 5 августында гамәлгә ашырыла. Күмелгән урыны Казанның Архангел зиратында дип фараз кылына.

## Сәгыйть Сүнчәләй



Шагыйрь һәм тәрҗемәче Сәгыйть Хәмидулла улы Сүнчәләев 1889 елның 2(14) августында Саратов губернасының Хвалын өязе Иске Мастак авылында туа. Әстерхан, Казанның иске мәдрәсәләрендә белем алып, 1908 елда экстерн тәртибендә учительлеккә имтихан тотканнан соң, 1915 елга кадәр Пермь губернасы авылларында балалар укыта, ә 1915—1917 елларда Уфа шәһәр китапханәсенең татар китаплары бүлеге мөдире булып эшли. Шагыйрь һәм тәрҗемәче буларак, бу чорда аның «Күл — күз яше» (1908), «Шильон мәхбүсе» (Байроннан тәрҗемә, 1911), «Төрле шигырьләр» (1912), «Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре» (1913), «Әл-Мансур» (Һейнедән тәрҗемә, 1913) исемле китаплары басылып чыга.

1917—1918 елларда С. Сүнчәләй Уфада «Авыл халкы», «Көнкүреш» газеталары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, 1919—1922 елларда Россия Милләтләр халык комиссариатының Кырымдагы вәкиле, 1923—1926 елларда Башкортстан Мәгариф комиссариатында коллегия әгъзасы һәм сәнгать бүлеге мөдире, 1926—1927 елларда Россиянең Измир шәһәрендәге (Төркия) генераль консуллыгында драгоман (тәрҗемәче) хезмәтләрендә була. Совет чорында әдипнең «Ихтилал шигырьләре» (1918), «Революцион шигырьләр» (1919) исемле шигъри җыентыклары, «Тәхетләргә ләгънәт» (1924) дигән драмасы һәм 1961 елда «Сайланма әсәрләре» дөнья күрә.

С. Сүнчәләй беренче мәртәбә 1927 елның 2 июлендә кулга алына. Аны солтангалиевчелектә гаепилиләр. Ике атнадан иреккә чыгарсалар да, шул вакыттан башлап аны да-

ими күзәтү астында тоталар. 1929 елның 28 февралендә, шул ук «гаеп»не сәбәп итеп, яңадан төрмәгә алып киталәр. 1930 елның 28 июлендә ОГПУ коллегиясе солтангалиевчелектә гаепләнеп кулга алынган 77 кешенең егерме берен, шул җөмләдән С. Сүнчәләйне, иң югары җәзага — атарга хөкем итә. 1931 елның 13 гыйнвар карары белән үлем җәзасы ун еллык концлагерьга алыштырыла. Әдипне башка солтангалиевчеләр белән бергә Соловки хезмәт колониясенә озаталар. Шунда ул авыр хезмәт шартларында, ачлык, хурлау-кимсетүләр кичерә-кичерә алты елдан артык җәфа чигә. Ләкин аның газаплары болар белән генә бетми: дәһшәтле 1937 ел җитеп, солтангалиевчеләр «эше» яңадан архивтан чыгарыла. Шул елның 9 октябрендә Ленинград өлкәсенең УНКВД «өчлеге» (тройкасы) С. Сүнчәләйне һәм тагы берничә дистә «солтангалиевчене» атарга хөкем итә. Хөкем карары 1937 елның 27 октябрендә шул ук Соловки лагеренда гамәлгә ашырыла.

Талантлы шагыйрь, тәрҗемәче, Тукайның якын дусты Сәгыйть Сүнчәләйнең гомере әнә шулай фаҗигале рәвештә өзелә.

## Гурий Тавлин



Гурий Иванович Тавлин 1925 елның 25 декабрендә Татарстан җөмһүриятенең Зәй районы, Урта Багряж авылында туган. Күрше авылларындагы урта мәктәпне тәмамлагач, 1942 елда хезмәт юлын Түбән Биш җидееллык мәктәбендә укытучы булып башлаган. Мәктәптә укыган елларында «Яшь ленинчы» газетасының актив хәбәрчесе булган. Аның тәүге шигырьләре шул газетада дөнья күргәннәр.

1943 ел башында Кызыл Армия сафларына чакырылып, сугышчан юлын, танкист буларак, Курск дугасында башлаган. Аннан соң Днепрны кичү дәһшәтендә катнашкан. Украинаны, Белоруссияне, Польшаны фашист юлбасарлардан азат итү өчен аяусыз бәрелешләрдә күрсәткән фидакарьлекләре өчен өч орден һәм төрле медальләр белән бүләкләнгән.

1946 елда Армиядән демобилизацияләнгәч, Г. Тавлин Казан дәүләт педагогия институтына укырга кергән. Студентлык елларында «Кызыл Татарстан» һәм «Яшь сталинчы» газеталарында берничә шигырен, Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз», В. Ажаевның «Мәскәүдән еракта», Б. Бхаттачарианың «Ачлык» романнарына караган рецензияләрен бастырган. 1950 елның 23 январенда нахак яла нигезендә кулга алынып, совет строена каршы милләтчелек рухында контрреволюцион агитация алып баруда гаепләнгән һәм Татарстан югары суды тарафыннан 10 елга ирегеннән мәхрүм ителеп, Себергә озатылган.

1954 елның 10 апрелендә СССР Югары Суды, Татарстан югары судының Тавлинга караган хөкем карарын юкка чыгарып, Татарстан дәүләт иминлеге комитетыннан аның эшен яңабаштан тикшерүне таләп иткән. Яңадан тикшерү Г. Тавлинның бернинди җинаять тә эшләмәгәнлеген ачыклаган һәм ул 1954 елның 22 сентябрендә тулысынча реабилитацияләнеп тоткынлыктан азат ителгән.

Ирек яулагач, партиядә торгызылып, педагогия институтын тәмамлаган. Әмма «элекке халык дошманына», утсыз төтен булмый, аны юкка гына биш елга якын сак астында тотмаганнардыр дип, яшь буынга белем, тәрбия бирүне ышанып тапшыруны кулай күрмиләр. Тавлин башта Казанны судан саклау буенча инженерлык корылмалары төзелешендә, Казан елгасы аша дамба-күперләр төзүдә эшли. Аннары, төрле район газеталарында эшли, «Кызыл Татарстан» газетасында әдәби хезмәткәр, бераз вакыт сәркатип була, китап нәшриятында, хроникаль фильмнар студиясендә мөхәррирлек итә, Биектау районында радиотапшырулар оештыра. 1972 елда, педагогия институтын тәмамлаганнан соң унҗиде ел гомере узгач кына, мәктәптә эшли башлый.

Гурий Тавлин «Сары яфраклар коела», «Йолдызлар безгә иңешә», «Тәвәккәл таш яра», «Алгы сызыкта» һәм башка исемнәрдәге китаплар авторы. Аның беренче зур әсәре булган «Дунай дулкыннары» романы кулъязма килеш Татарстан дәүләт иминлеге комитетында юк ителә. Үзе кичергән вакыйгаларга нигезләп язылган «Афәт» романының беренче һәм икенче кисәкләре 1990 һәм 1991 елларда «Казан утлары» журналында басылды.

Хәзер Казанда яши.

## Адлер Тимергалин



Адлер Камил улы Тимергалин 1931 елның 1 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Иске Минзәләбаш авылында укытучы гаиләсендә туа.

1950 елның 10 гыйнварында, КДУның физика-математика факультетының икенче курсында укыган чагында, ул, Советка каршы пропаганда алып баруда гаепләнеп, кулга алына. Башка бик күпләрдән аермалы буларак, А. Тимергалин чыннан да Сталин һәм Коммунистлар партиясе политикасын тәнкыйтьләп, милли азатлыкны яклап листовкалар яза, аларны халык арасында тарата. Шул ук елның 13 мартында игълан ителгән суд карары белән ул мәҗбүри рәвештә акылдан язганнар шифаханәсенә ябыла. (Янәсе, шундый акылдан язганнар гына Советка каршы ачыктан-ачык көрәш башларга мөмкин.) Ел ярым көчләп «дәвалаганнан» соң, 1951 елның 5 октябрендә аны туганнары карамагына авылга кайтарып җибәрәләр. Булачак әдип, Ташкент якларына китеп, укуын дәвам итә, аннан соң туган якларында укытучы булып эшли.

А. Тимергалинны татар әдәбиятында иҗатын тулысынча фәнни-фантастика жанрына багышлаган бердәнбер язучы дияргә була. 1959 елдан башлап бу жанрда аның дистәләрчә хикәя һәм повестьлары, унга якын китабы дөнья күрде. Әдипнең «Ике хикәя, бер хыял», «Ерак планетада», «Мәңгелек хатирәләр», «Кохау ронго-ронго», «Космостан кунаклар», «Адашкан йолдыз», «Таш әпиһә» һ. б. китаплары яшь укучылар арасында зур популярлык казандылар.

## Кәрим Тинчурин



Кәрим Гали улы Тинчурин 1887 елның 15 сентябрендә хәзерге Пенза өлкәсенең Демьян Бедный районы Таракан (Белоозерка) авылында крестьян гаиләсендә туа.

Беренче сәхнә әсәрен («Моназарә», 1906) мәдрәсәдә укыган чорында ук яза. 1910 елда бу беренче профессиональ театр труппасы «Сәйяр»гә актер булып керә һәм шул вакыттан башлап үзенең бөтен гомерен татар театр сәнгатен һәм драматургиясен үстерүгә багышлый. Ул ел саен диярлек берәр-икешәр пьеса иҗат итә һәм татар драматургиясенең классигы дәрәҗәсенә күтәрелә. 1922 елда аның җитәкчелегендә Казанда Татар дәүләт театры ачыла (хәзер Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры). Драматургның «Беренче чәчәкләр», «Сүнгән йолдызлар», «Американ», «Җилкәнсезләр», «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл» кебек әсәрләре, татар әдәбиятының классикасына әверелеп, бүген дә театр тамашачысына көчле эстетик тәэсир ясыйлар.

Атаклы драматург илле яшьлек юбилееның икенче көнендә, 1937 елның 16 сентябрендә кулга алына. Аңа нинди генә гаепләр такмыйлар, хәтта Япония шымчысы булуда да гаеплиләр... Әдип сүзендә нык тора, накха гаепләрнең берсен дә танымый, палачларның йөзенә төкерә. 1938 елның 14 ноябрендә Махсус киңәшмә (ОСО) аны атарга хөкем итә. Шул хөкем карары нигезендә 1938 елның 15 ноябрь таңында, 1 сәгать 50 минутта тәрмә палачлары әдипне атып үтерәләр.

Мәете Казанның Архангел зиратында күмелгән булырга тиеш.

## Гомәр Толымбай



Габделхак Җәләлетдин улы Шәһиәхмәтов 1900 елның 14 апрелендә Сембер губернасының Буа өязе Толымбай авылында мул тормышлы крестьян гаиләсендә туа.

Егерменче еллар башында Казан көндәлек матбугатында (бигрәк тә «Безнең юл» журналында) аның «Г. Толымбай» псевдонимы астында бер-бер артлы сугышчан рухлы мәкаләләре һәм агитация характерындагы әдәби әсәрләре басыла башлый. Егерме елга якын сузылган иҗат гомерендә аның утызлап китабы басылып чыга. Алар арасында вульгар социологизм рухында сугарылган берьяклы хезмәтләр дә («Татар буржуа теле — безнең тел түгел», «Фатих Әмирхан» һ. б.) реалистик рухта язылган матур-матур хикәя, повестьлар да бар («Түбән Елгада», «Куян солдат», «Әндәр бабай», «Кызыл армиядән кайткач», «Мужик фәлсәфәсе», «Яз көне», «Дүрт туган» һ. б.). Г. Толымбай балалар өчен дә хикәяләр яза («Без үскәндә», «Кечкенә чакларда», «Минем әти» җыентыклары).

Гомеренең соңгы елларында ул Татарстан дәүләт нәшриятының матур әдәбият секторы мөдире булып эшли. 1937 елның 10 апрелендә партия җыелышы аны ВКП(б) сафларыннан чыгара. Шул ук елның 8 июнендә НКВД органнары тарафыннан кулга алынып, «контрреволюцион троцкийчы оешмада» катнашуда гаепләнә. НКВДның эчке изоляторында һәм Пләтән төрмәсендә утыра. 1938 елның 8 маенда СССР Югары судының күчмә сессиясе аны иң югары җәзага — атарга хөкем итә. Карар шул ук көнне җиренә җиткерелә.

## Хәсән Туфан



Хәсән Фәхри улы Туфан (1924 елда «Туфан» псевдонимын алганга кадәр ул Гелзизин, Хәзрәтов, Кусинов фамилияләрен йөртә) 1900 елның 9 декабрендә элекке Казан губернасының Аксубай волосте Иске Кармәт авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа.

Егерменче еллар уртасында басыла башлап, 1927 елны ук үзенең татар поэзиясендә кабатланмас эз калдырган «Урал эскизлары», «Ике чор арасында», «Башлана башлады», «Бибиевләр» поэмаларын иҗат итә. Утызынчы еллар башында ул инде татар поэзиясенең алгы сафларына чыгып, әйдәп баручылар рәтенә керә. Әмма 1935 елда «Ант» поэмасы басылып чыгу белән шагыйрь аяусыз тәнкыйть уты астына эләгә. Бу поэманы ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты зарарлы әсәр дип таба. 1940 елның 19 ноябрендә шагыйрь НКВД органнары тарафыннан контрреволюцион миллләтчелектә гаепләнеп кулга алына. 1942 елның 7 мартында НКВД гаскәрләренең хәрби трибуналы аны үлемгә хөкем итә. Ләкин шул ук елның 21 мартында үлем җәзасы ун ел төрмә һәм тагы биш елга хокукларын чикләү белән алыштырыла. Шагыйрь Свияжск (Мари АССР) һәм Потьма (Мордва АССР) лагерьларында авыр эшләрдә эшләп срогын тутыра. Срогы тулу белән аны судсыз-нисез гомерлек сөргенгә Себергә җибәрәләр. Ул тагы биш ел Новосибирск өлкәсенең Устарка районында күзәтү астында яши, колхозда көтүче һәм терлекче булып эшли. 1956 елда азат ителеп, Казанга кайта.

Иң авыр шартларга да карамастан, Туфан төрмәдә дә, сөргендә дә иҗат эшеннән туктамый. Бу чорда аның «Иртәләр җитте исә», «Гөлләр инде яфрак яралар», «Чәчәк сибелә җилдә», «Моабитны күрдем төшемдә» кебек иң көчле, сәнгать ягыннан иң камил шигъри җәүһәрләре иҗат ителә. Шагыйрь Тукай, Такташлар традицияләрен дәвам итүче классик дәрәҗәсенә күтәрелә.

Х. Туфан 1981 елның 10 июнендә Казанда вафат булды.

## Шамил Усманов



Шамил Хәйрулла улы Усманов 1898 елның 26 декабрендә Саратов губернасының Кузнецк өязе Пәндәлгә авылында мөгаллим гаиләсендә туа.

Ул — әдәбият мәйданына турыдан-туры Гражданнар сугышы эченнән, совет власте өчен үз-үзен аямыйча көрәшкән кызыл гаскәр арасыннан күтәрелеп чыккан язучыларның берсе. Аның тәүге иҗат тәҗрибәләре булган «Канлы көннәрдә» һәм «Беренче адым» драмалары Гражданнар сугышының иң нык кызган чагында — 1919 елда языла һәм кульъязма хәлендә фронт сәхнәләрендә туктаусыз уйналып йөри. 1920 еллардан башлап язучы проза жанрында да актив иҗат итә, күп санлы хикәяләрен бастыра. 1935 елда ул үзенең иң зур әсәрен — «Легион юлы» дилогиясен тәмамлый. Укучылар аның «Памирдан радио» исемле хыялый повестен дә (1925) бик җылы каршылыйлар. «Кичеккән фәрман» исемле пьесасы утызынчы еллар уртасында Татар академия театры сәхнәсендә уңыш белән бара.

Язучы 1937 елның 7 апрелендә «Казанское подворье» кунакханәсендә кулга алына. Аны солтангалиевчелектә, Мохтаров, Борындыков, Енбаев, Мансуров һ. б. «контрреволюцион элементлар» белән элемтә тотуда, советка каршы пропаганда алып баруда гаепләгәннәр. Берничә ай буе Казанның Плетән төрмәсендә һәм НКВДның эчке изоляторында — Черек күлдә туктаусыз җәзалыйлар. 1937 елның 3 декабрендә НКВД тикшерүчеләре (Шелудченко һ. б.) сорау алу вакытында атаклы язучыны кыйнап үтерәләр.

## Мин Шабай



Мин Гариф улы Шабаев 1913 елның 28 апрелендә хәзерге Башкортстанның Кушнаренко районы Каратәкә авылында ярлы крестьян гаиләсендә дөньяга килә.

Сабый чактан ук ятим калып, алты яшеннән үз көнен үзе күрә башлый. Кулакларга батрак булып хезмәт итә, беспризорник булып ил гизә, тәмам юлдан язу дәрәҗәсенә җитә. 1931 елның көзендә урлашып йөргән өчен кулга алына. Чекистлар аны Мәскәү өлкәсендәге Хезмәт колониясенә урнаштыралар. Колониядә чакта ул белем ала, әдәбият белән таныша, кеше буларак аякка баса. Шунда аның үзендә дә иҗат дәрте уяна: 1934 елда «Таныл» (елга исеме) дигән озын хикәясе басыла.

Колониядән соң М. Шабай көндәлек матбугатта бер-бер артлы матур өһәңле лирик хикәяләрен, очеркларын бастыра. Колхоз-совхоз театрларында аның пьесалары куела. 1941 елда Казанда «Уйналмаган скрипка» исемле хикәяләр җыентыгы басылып чыга. 1942 елның 21 ноябрендә ул икенче мәртәбә кулга алына. Бу юлы аны Совет властена каршы агитация алып баруда гаеплиләр. 1944 елның 8 мартында СССР НКВДсы каршындагы Махсус киңәшмә аны җиде елга иреккеннән мәхрүм итәргә хөкем кыла. М. Шабай Колыма якларында, Төньяк тау-руда идарәсенең Водопьянов исемендәге прискасында иң авыр шахта эшләрендә эшли. 1949 елның 2 июнендә фидакарь, тырыш хезмәте өчен срогыннан алда азат ителә. Ләкин туган якларына кайтып китәргә өлгерми — шул ук булмаган «җинаять» өчен яңадан кулга алына һәм 1950 елның 22 июлендә шул ук ОСО карары белән Колыма якларында гомерлек сергенгә калдырыла. Магадан өлкәсенең Спорный поселогында яши һәм эшли.

Казанга ул 1955 елны гына кайта һәм дәртләнеп иҗат эшенә керешә. 1959—1964 елларда язучының «Бездә ел буе яз» исемле очерклар китабы, «Тормыш баскычлары», «Тормыш чакыра» исемле хикәя җыентыклары һәм «Уяну» исемле тарихи-социаль романы басыла (беренче кисәк). Ләкин, исәнлеге нык какшаган булу сәбәпле, ул барлык иҗат планнарын тормышка ашыра алмады, 1963 елның 5 сентябрендә 50 яшендә вакытсыз вафат булды.

## Сәрвәр Әдһәмова



Сәрвәр Сабир кызы Әдһәмова 1901 елның 5 апрелендә элекке Оренбург губернасы (хәзерге Чиләбе өлкәсе) Троицк шәһәрендә мөгаллим гаиләсендә туа.

Казанга күчеп килү, әдәбият-сәнгать кешеләре белән якыннан арапашу, ниһаять, күренекле язучы Кави Нәҗми белән гаилә тормышы корып җибәрү аны әдәби иҗат эшенә якынайта. С. Әдһәмова балалар өчен шигырьләр, хикәяләр, пьесалар иҗат итә. Егерменче еллар уртасында аның әдәби тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге дә башланып китә. Ул Л. Толстой, Н. Тихонов, А. Чехов, А. Пушкин әсәрләрен тәрҗемә итә. Утызынчы еллар дәвамында М. Горькийның барлык төп әсәрләре диярлек аның тәрҗемәсендә татар укучысына барып ирешәләр.

1938 елның 4 гыйнварында С. Әдһәмова «халык дошманы хатыны» буларак кулга алына. Шул ук елның 11 августында махсус киңәшмә аны 58 статьяның 10 нчы һәм 12 нче пунктлары буенча ун елга ирегеннән мәхрүм итәргә һәм биш елга хокукларын чикләргә хөкем итә. С. Әдһәмова төньяк лагерьларында урман кисә, аяк-кулларын өшетә. 1940 елның 16 октябрендә аны кассация буенча тулысынча аклап иреккә чыгаралар.

Казанга кайткач, С. Әдһәмова тәрҗемә эшләрен дәвам итә, дистәләрчә рус һәм дөнья классикларының китапларын татар укучысына җиткерә. Кызыклы мемуаристәлекләр язып бастыра. Ул 1978 елның 10 ноябрендә Казанда вафат булды.

## Мирсәй Әмир



Мирсәяф Мәсәлим улы Әмиров 1907 елның 6 гыйнварында Уфа губернасының Эстәрлетамак өязе (хәзер Башкортстанның Мәләүез районы) Җиргән авылында крестьян гаиләсендә туа.

1926 елны Казанга килеп, сәнгать техникумына укырга керә. Шул ук елларны аның иҗат эшчәнлеге дә башланып китә. Ул авыл тормышы турындагы көлкеле кыска хикәяләрен бастыра. Утызынчы еллар башында аның «Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре» һәм «Командир» исемле повестьлары язылa. 1933 елны «Безнең авыл кешесе», 1935 елны «Агыйдел» исемле атаклы повесте басыла. Соңгысының сәхнә варианты өчен язучы 1974 елда Г. Тукай премиясе белән бүләкләнә.

1937 елның сентябрендә М. Әмир Татарстан Язучылар берлеге рәисе итеп сайлана. Ике ай үтүгә, 4 декабрьдә ул НКВД органнары тарафыннан кулга алына. Плетән төрмәсендә утыра. Каты җәзалауларга карамастан, «гаебен» танымый, нык тора (аны 58 статьяның 12 нче, 10 нчы һәм 11 нче пунктлары буенча гаепліләр). ТАССР Югары судының 1939 елның 19 мартында булган коллегия утырышы аны (гомердә булмаган хәл!) тулысынча аклый һәм шундук сак астыннан иреккә чыгарырга карар кыла.

Ватан сугышы елларында М. Әмир «Миңлекамал» (1944) драмасы белән зур иҗади уңышка ирешә. Аның «Тормыш җыры» (1946), «Җыр дәвам итә» (1947), «Минем хатын» (1955) һ. б. драма әсәрләре дә театр сәхнәләрендә зур уңыш белән бара. 1959 елда язучы ике кисәктән торган «Саф күңел» романын төгәмамлый. «Җан көеге» (1969), «Балыкчы ялганнары» (1971) һ. б. әсәрләре дә укучылар тарафыннан бик җылы каршылана.

М. Әмир РСФСРның берничә чакырылыш Югары Советы депутаты, РСФСР Югары Советы Президиумы рәисе урынбасары булып сайланды, дәүләт орден-медальләре белән бүләкләнде. Ул 1980 елның 1 июнендә Казанда вафат булды.

## Садри Җәләл



Садретдин Хәйретдин улы Вәлидов (әдәби псевдонимы — Садри Җәләл) 1891 елда Казан губернасының Тәтеш өязе Апас авылында туган. Буби мәдрәсәсендә һәм Казандагы Учительская школада белем ала. Соңгысында укыган елларында каләм тибрәтә башлап, «Аң», «Ак юл» журналларында беренче хикәяләрен бастыра. Татар морзалары тормышыннан алып язылган һәм 1914 елны «Аң» журналында дөнья күреп, шуннан соң аерым китап рәвешендә берничә мәртәбә басылган (соңгы басмасын 1991 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарды) «Дим буенда» исемле романтик повесте аңа аеруча шөһрәт китерә.

С. Җәләлнең Октябрьдән соңгы иҗат эшчәнлеге дә игътибарга лаеклы. Хикәяләр язуын дәвам иттерү белән бергә, ул көндәлек темаларга мәкаләләр, яңа чыккан китаплар турында рецензияләр яза, М. Горький, Дж. Лондон, Ф. Шиллер, Д. Мамин-Сибиряк кебек классик әдипләрнең аерым әсәрләрен тәрҗемә итеп бастыра, юмор-сатира жанрында күп кенә фельетоннар, сатирик парчалар иҗат итә.

С. Җәләл — сталинчыл репрессия шаукымына эләккән татар әдипләренең беренчеләреннән. Аны 1931 елның 6 маенда шифаханәдә дәваланып яткан җиреннән алып китәләр. Шул ук көнне кулга алынган туганнан туган абыйсы Җамал Вәлиди, галим-язучы Гали Рәхим белән берлектә, аны да «солтангалиевчеләрнең Казандагы яшерен филиалын» төзүдә гаеплиләр. 1932 елның 11 маенда ОГПУның Махсус коллегиясе С. Җәләлне биш елга ирегеннән мәхрүм итү турында хөкем карары чыгара. Хөкем карарын үтәү өчен әдипне Ак диңгез-Балтыйк каналы төзелешенә, хезмәт колониясенә җибәрәләр. Срогын тутыргач, авыр хезмәттән, ачлы-туклы яшәүдән сәламәтлеге тәмам какшаган, ярым сукырайган С. Җәләл 1935 елда Казанга гаиләсе янына кайтып егыла.

Гаиләсе тәрбиясендә азмы-күпме хәл алгач, ул сукырлар җәмгыятендә эшли башлый. Аннары, кыска вакытлы курсларда укып, якын танышы профессор Л. И. Шулутко (1897—1971) ярдәме белән ортопедия һәм травматология институтына массажчы булып эшкә урнаша.

Әмма утызынчы елларның икенче яртысыннан тагы да көчлерәк кабынып киткән репрессияләр шаукымы С. Җәләлне кабат тимер читлеккә китереп керттә (1937). Плетән тәрмәсендә күпмедер ябылып ятканнан соң аны, каты авырып китүе сәбәпле, төрмә шифаханәсенә күчерәләр. Тагын бераздан, хәле бөтенләй начараюын күреп, төрмә машинасы белән өенә кайтарып куялар. Шуннан соң инде ул озак яши алмый: 1943 елның 29 июлендә дөнья куя. Кабере Казанның Яңа Бистә зиратында.

---

## Кадерле укучылар!

«Казан утлары» журналына 1992 елның икенче яртысына өстәмә язылу башлана. Бәясе: бер айга — 10 сум, алты айга 60 сум. Индексыбыз — 73210.

Язылу бәйсез дәүләтләр бердәмлегенең барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә.

# СЫНЧЫ КАДИМ ҖӘМИТОВ

ИҖАТ ПОРТРЕТЫ



Яңарыш чорының хәбәрдарлык җилләре безгә тарихыбызның яшерен катламнарына үтеп керергә мөмкинлек бирде. Шуның белән бергә без татар мәдәниятенең үткәнен дә, бүгенгесен дә тирәнтенрәк аңлый-күрә башладык. Татарстаннан читтә яшәүче байтак кына күренекле милләттәшләребезнең исемнәре безгә әле соңгы елларда гына килеп иреште. Һәм без аларны хәзер көннән-көн күбрәк очратабыз. Әнә шул татар язучылары, композиторлары, рәссамнары моңа кадәр «совет мәдәнияте вәкилләре» дигән гомум «бүрек» астында йөриләр, күренмиләр иде. Аларның иҗаты да нигездә үз халкына-милләтенә билгесез булып, танылмыйча кала килде. Әмма бит шунысы бар, иҗат кешесе кайсы гына төбәктә яшәсә дә, әгәр ул нәсел-нәсәбен оныткан бер маңкортка әйләнгән булмаса, үз милли тамырларыннан аерыла алмый, аның иҗади омтылышлары табигый рәвештә милли үзенчәлекле әсәрләрдә чагылыш таба. Һәм, киресенчә, үз милләте белән «кендек җепләре» бәйләнмәгән иҗатчылар еш кына рухи бушлыкта асылынып калалар, иҗатларында үз шәхесеннән дә, халкы-милләтеннән дә читләшеп, бөтенләй сүнү-сулуга дучар булалар. Туган туфрагыннан йолкынган, тамырлары корып, сулган-шиңгән гөлне хәтерләтәләр алар.

Бер кызыклы законлылык бар: иҗат кешесе никадәр талантлырак булса, аның үз ил-җиренә, халкына булган тартылу көче дә шулкадәр тирәнрәк була. Бәхетебезгә, Мәскәүдә яшәп иҗат итүче татар сынчысы Кадим Җәмитов хакында да без хаклы рәвештә шулай дип әйтә алабыз. Кадим Җәмитов үзен татар халкының язмышы белән бербөтен тоеп иҗат итә, үзе туып-үскән Татарстан туфрагы белән даими рухи бәйләнештә тора.

Сынчы Кадим Җәмитовның әсәрләре белән танышу мөмкинлеге татар тамашачысы өчен әле күптән түгел генә ачылды — узган ел Санкт-Петербургта татар сәнгатенә багышланган «Татарт-91» күргәзмәсендә Кадим Җәмитовның «Мөселман карты» исемле әсәре экспозициянең үзәгендә булды. Бу сын күргәзмә залын композицион бер бөтенлеккә туплап тора һәм гаять зур әхлакый-эстетик көчкә ия иде.

Залның нәкъ уртасында Кәгъбәне символлаштырган кара таш — куб каршында күңеленнән генә дога укып торган мөселман картының зур булмаган сыны урын алган. Сын үзе ачсу-көрәнрәк шамот ташыннан уеп ясалган. Догада оеган аксакал, кулларын кушырып, агач эскәмиядә утыра. Аның ни сакалы, ни түбәтәе, ни ачык зур маңгае, карап торуга, әллә ни ис китәрлек түгел шикелле. Тормышта без мондый бабайларны аз күргәнме?! Әмма әнә шул гади мөселман карты — үзебезнең татар бабае тамашачы күңелен актара да ташлый. Гаҗәп бай тойгылар уята ул. Шуңа күрә дә аның катыннан озак китә алмый торасың.

Ислам сәнгатендә, билгеле булганча, җан ияләрен, шул исәптән, кешене дә сынландырып күрсәтү шактый сирәк күренеш. Шунныктан булса кирәк, сынчы мөселман картының сын-сурәтен бик саран чаралар белән тасвирларга омтыла. Бабайның бөкрәя төшкән гәүдәсеннән ниндидер бер кырыслык, дөнья рәхәтләреннән инде күптән ваз кичкән суфыйлык-тәкъвалык һәм шул ук вакытта олуг бер тыйнаклык бәркелеп тора. Сынчы аңа бер генә кирәкмәгән, артык сызык та өстәмәгән. Ул үзенең иҗат ялкынын бер изге максатка — дога кылып утыручы картның эчке көчен-җегәрен, рухи бай дөньясын ачып салуга туплаган. Бабайның башындагы гади генә түбәтәе безгә ирексездән мәчет гөмбәзен хәтерләтә. Аның бөтен торышы-кыяфәте Алласы белән олуг-изге бер-

лектә иңәнлеген чагылдыра, аңардан бәркелгән күзгә күренмәс изге нурланыш-балкыш татар халкының рухын-җанын ача да сала.

Шулай итеп, без үзебез өчен гаҗәп үзенчәлекле яңа бер оста сынчы рәссамны ачтык. Ул — Кадим Җәмитов. Аның татар халкының рухына, хис-тойгылары дөньясына шулай тирән үтеп керә алуына сокланмый мөмкин түгел. Сынчының иҗатында үз милләтенең үткәне һәм бүгенгесе, уй-хыяллары һәм өмет-омтылышлары, дәрте-җегәре һәм эшчәнлек-тырышлыклары — һәммәсе дә, көзгедәге шикелле ачык-анык булып, тулы образлы чагылыш таба.

Шулай итеп, татар сынлы сәнгатендә без күптән көткән яңа оста пәйда булды. Табигать бушлыкны яратмый, диләр. Хактыр. Чөнки татар халкының олуг талант иясе Бакый ага Урманченың арабыздан китүенә күп тә үтмәде — аңа алмашка яңа осталар килә.

Дөресен әйтергә кирәк, хәзер үз иҗатларында милли образларны, милли характерларны чагылдыручы, милли сәнгать теленең шигърияген үзләштергән, гасырлар тирәнлегеннән килә торган халык иҗатының асылын аңлаган рәссамнар Татарстанда юк дәрәҗәсендә аз. Ә бит татарларның халык сәнгатендә борынгы төрки-мәҗүси тамырларга үрелеп үскән урта гасыр ислам-мөселман мәдәнияты да, соңгы йөзләрдә шуларга катлам-катлам өстәлә барган европалаша төшкән мәдәният та ачык чагыла.

Кем ул Кадим Җәмитов?

Тумышы белән Кадим атаклы Казан арты якларыннан. Төгәлрәк әйткәндә, Саба районының Олы Арташ авылында туып үскән егет. Сынчы рәссамнарга хас иҗат биографиясе өчен ул әле чагыштырмача яшь кеше — аңа кырык алты яшь. Көч-җегәренең, иҗат дәртенең ташып торган чагы, диярго була. Кадим Җәмитов, менә егерме елдан артык инде, Мәскәүдә яши. Ул башта шунда СССР рәссамнары берлеге каршындагы иҗат яшьләре берләшмәсенә йөри. Аны 1983 елда СССР рәссамнары берлегенә әгъза итеп алалар.

Кадим Җәмитовның сәнгатькә юлы шома гына булмый. Хәер, ул үскән елларда — торгынлык чоры дип яманаты чыккан чорда — бигрәк тә «вак» милләт вәкилләре өчен кемгә генә шома булды икән ул юл?!

Гади татар авылында, гади крестьян гаиләсендә туган малай бик иртә, бала чагыннан ук рәсем сәнгате белән мавыга-кызыксына башлый. Бу һәвәслек бигрәк тә мәктәптә уку елларында көчәеп китә. Күрәсең, авыл мәктәбендәге табигый мөлаем күтәренке рухи атмосфера, андагы укытучы апа-абыйларның синең һәр омтылышыңа көч-куәт биреп, үсендереп торулары дөньяга да якты күз белән карарга, аның буяу-төсмерләрен тулырак тоярга ярдәм иткәндер.

Мәктәптә уку елларында Кадим Шәмәрдән мәктәбендә рәсем дәресләре алып баручы укытучы, үзешчән рәссам Виль Гарипов турында ишетә. Ишетә һәм... кабына. Ерак араны якын итеп, шактый чакрымнарны җәяүләп үтә малай, шул укытучы абый белән очрашырга бара. Очрашалар. Виль Гарипов, бу үҗәт малайның күзләрендәге илһам чаткыларыннан сихерләнеп, аңа Казан рәсем сәнгате училищесына керергә ярдәм итәргә алына. Кадимгә рәсем дәресләре бирә башлый.

Әмма татар мәктәбен тәмамлаган күп кенә егет-кызлар язмышы Кадимне дә сагалап тора: рәсем сәнгате училищесындагы гел рус телендә генә үткәрелә торган кабул итү имтиханнарының нечкә иләгеннән үтә алмый авыл малае. Алай да Кадим күңелен төшерми, бер ел тырышып әзерләнә һәм Ижаудагы Удмурт дәүләт педагогия институтының графика сәнгате бүлегенә уңышлы имтихан тота. Әйе, Казан һәм анда оялаган урыс-яһүд белгечләре кабул итмәсә, әнә шундый «вак милләт вәкилләрен» сыендыручы Ижау яшәсен!

Югары уку йортын тәмамлаганнан соң, Кадим Җәмитов армиядә хезмәт итә. Әкренләп үзенең белеме җитәрлек булмаганына төшенә ул һәм, Мәскәүгә барып, профессионал сынчы рәссам В. А. Табах остаханәсендә сынчы һөнәренең нечкәлекләренә өйрәнә башлый. Шунда ул биш ел дәвамында сынчылык сәнгатенең әлифбаннан алып соңгы хәрефенә кадәр дигәндәй, барлык адымнарын үтә: гипс, таш, агач, бронза, шамот — егет кулы коел-уел карамаган бер генә әйбер дә калмый. Остазы Владимир Табах искиткеч тирән белемле, киң эрудицияле кеше була. Ул үзенең укучысына, сынчылык сәнгате белән бергә, тормышны танып-белергә өйрәтә, психология, эстетика, этика фәннәрен таныта; сәнгатьнең шигърият, музыка, театр кебек башка өлкәләрендә дә егетнең зыялы булып үсүенә ярдәм итә. Нәкъ менә шунда, сынчылык сәнгате осталыкларына өйрәнеп, Кадим профессионал рәссам булып җитлегә. Рәсми рәвештә нинди дә булса сәнгать югары уку йорты дипломы алып чыкмаса да, ул бик тиз арада үзенең шәхси стиле, иҗат төсмерләре, милли йөзе белән танылып өлгерә.

Озакламый Кадим Җәмитов әсәрләре күргәзмәләрдә күренә башлый. Аның иҗаты һәр күргәзмәдә тамашачы игътибарын җәлеп итә. Кадимнең зур булмаган әсәре — «Курайчы» сыны беренче мәртәбә 1971 елда автономияле республикаларның Бөтенсоюз күргәзмәсенә куела. Аз гына буяу салынган гипстан эшләнгән шул кечкенә сын зур уңыш казана һәм аның авторы Кадим Җәмитовны профессионал сынчы рәссам итеп таныта. Шуннан соң инде сынчы бер-бер артлы төрле күргәзмәләрдә катнаша башлый: республика күләмендәме, бөтенсоюз күләмендәме, чит илләр күләмендәме — һәркайда әсәрләре танылa бара. Аның иҗаты бигрәк тә 1985 елда Германиядә булып үткән «Сын-

сурәт һәм мөхит» дигән тематик күргәзмәдә зур яңгыраш таба. Кадим Җәмитовның бакырдан чокып эшләнгән «Шатлык» исемле әсәре табигый зурлыгындагы хатын-кыз сыны була. Бу әсәр үзенең пластик образлылыгы, хисси җылылыгы белән дә, үзенчәлекле формасы белән дә борынгы Римнең урман алиһәсе Дианага тиңләшерлек образ була. Әсәрне атаклы Третьяков галереясе сатып ала һәм ул шул музей байлыгына әйләнә.

Соңгы елларда Җәмитовның байтак кына әсәрләре Германия сәнгать сөючеләренең шәхси коллекцияләрендә урын ала. Бигрәк тә аның «Курайчы», «Бабай», «Тукай» дигән зур булмаган сыннары сәнгать сөюче чит ил кешеләренең күңеленә хуш килә. Шул рәвешле, төрле образлардагы татар милләте вәкилләре Европа илләренә юл яра. 1991 елда Австриядә булып үткән күргәзмәдән соң, Кадим Җәмитовның «Савыгу» әсәре Венадагы Милли нәфис сәнгать музее тарафыннан сатып алына.

Кадим Җәмитов 1990 елда Мәскәүдә үзенең беренче шәхси күргәзмәсен оештыра. Күргәзмәгә сынчының төрле жанрлардагы утыз дүрт әсәре куела.

Ә менә татар сәнгате күргәзмәсендә аңа бары тик узган ел — 1991 елда гына катнашырга туры килде. Гомумән, «Татарт-91» күргәзмәсе илебезнең төрле төбәкләрендәге татар рәссамнарының иҗатын берләштергән беренче күргәзмә иде. Анда Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Алма-Ата кебек төрле җирләрдән килгән рәссамнарның иҗаты шактый тулы чагылыш тапты. Ә инде сынчы рәссамнар арасында /алары да байтак иде/, һичшиксез, Кадим Җәмитов иҗаты барысыннан да аерылып торды. Саны белән генә түгел /унике әсәр/, аның әсәрләре милли үзенчәлекле, тирән эчтәлекле, фәлсәфи җыелма образлы һәм заманча булулары белән истә калды. Кадимнең күргәзмәгә куелган барлык әсәрләре диярлек шамот ташыннан ясалган иде. Кадим аны бигрәк тә ярата, үз итә, үзенең иҗади стиленә яраклаштыра белә. Шамот — эреп пыялаланганчы яндырылган аерым төр үзле балчык ул. Аны ясалма таш, дисәң дә буладыр. Сынчылар кулында шамот аерым бер җылылык белән өртелә, җанлы матдә тойгысы калдыра. Сын кою өчен шамотның нинди эсселектә һәм нинди формада яндырылу сыйфаты да зур роль уйный. Әсәр сынчы тарафыннан әүвәл гипстан эшләнә, шуның эченә шамот тутырып коела. Аннары ул махсус мичләрдә яндырыла. Кадим исә үзе ясаган сыннарга сизелер-сизелмәс кенә төс-буяу салырга ярата. Ул буяуларны йә сынны яндырып койганчы сала /монысы кайнар ысул дип атала/, йә яндырганнан соң /монысы салкын ысул була/. Сынчының иҗади уй-максаты нинди булуга карап, образларның — сын-сурәтләрнең тәэсир итү көче дә төрлечәрәк килеп чыга. Әмма, нигездә, Кадим Җәмитов сынның аерым детальләренә генә төсмер өстәп җибәрә, шуның белән образның характерлы үзенчәлеген ача төшә. Мәсәлән, «Тукай» сынында ул, төс кулланып, шагыйрьнең чәчләрен, күзләрен һәм күкрәгенә сыланып яткан шарфын гына ассызыклап үтә. Шуның белән Тукай ничектер җанланып-«терелеп» китә, аңардан лирик шигъри бер җылылык бәркелеп тора башлый шикелле. Төс-буяуларны белер-белмәс чамасыз куллансаң, ул сиңа үч итәчәк — әсәрне «үтерәчәк», бары тик оста сынчы кулында гына төс образны баету чарасына әверелә, әсәргә тормышчанлык бирә. Без Тукайның бик күп портретларын хәтерлибез, алар, гадәттә, салкын мәрмәрдән яки авыр бронзадан эшләнгән була



Габдулла Тукай



Галиәсгар Камал



Сәгыйть Сүнчәләй

иделәр һәм шагыйрьнең сын-сурәт образын билгеле бер стереотип калыпта тота килделәр. Кадим Җәмитовның Тукае исә бөтенләй башка. Ул безгә — гади җир кешеләренә бик тә үз, бик тә якын. Аңарда ясалма ялган купшылык та, нинди дә булса рәсмилек тә юк. Ул — романтик сын-сурәт. Әсәрдән егетләрчә саф-садә уй-хыяллар, күтәренке шигърият сирпелә. Безнең алда шагыйрьнең дөньяга ягымлы, аңлаучан җылы карашлы образы җанлана. Ләкин шул ук вакытта Тукайның киемендә, килеш-килбәтендә аның бөеклеге, олы таланты ачык төсмерләнә. Әйе, бу егет шагыйрь булу өчен дөньяга килгән һәм аның бар шәхесе-калбе, бар язмышы алдан «тәкъдиренә язылган» икәнлеген аңлыйсың. Шулай итеп, Кадим Җәмитов сынчылык сәнгатендәге иске кануннарны жимереп ташлаган, ул Тукайны бөтенләй башкача — үзенчә күрә-күзаллый алган һәм шагыйрьнең әле без моңарчы күрмәгән гүзәл яңа образын иҗат иткән.



*Камил Мотыйгый*

Кадим Җәмитов үзе иҗат итәргә алынган персонажының, гәүдәләндерергә теләгән образының сын-сурәтен эшләгәндә тышкы охшашлык белән генә канәгатьләнеп калмый. Аның өчен образның билгеле бер мохиттә яшәве, үз чоры белән багланышта булган композицион чишелеше табылу мөһим. Сынчы, шул рәвешле, үз әсәрләренең сәнгати кыйммәтен раслап кына калмый, ә бәлки героеның тарихи чынбарлык белән бәйләнешен, бүгенге белән мөнәсәбәтен дә ачып бирә. Чор һәм шәхесләрнең үзара бәйләнешләре шулай сәнгати чаралар аша кабат яңара. Кадим үзе сурәтләргә алынган героеның тышкы охшашлыгын ул яшәгән тормыш-көнкүреш белән шулкадәр оста, табигый итеп бәйли ки, тамашачы әсәрне: Әйе, нәкъ шулай, нәкъ тере үз чоры кешесе бу!» — дип, икеләнүсез кабул итә. Ә юкса бу үзенчәлекне сынчы саран гына бер-ике деталь аша ачып сала.



*Фатих Әмирхан*

Кадим Җәмитов иҗатының төп юнәлешләреннән берсе — татар зыялылары арасыннан акыл иясе, рухи остаз булырлык шәхесләрне, тирән шигъриятле шагыйрь образларын сынландыру-җанландыру. Шул образлар аша ул үз халкының язмышын гәүдәләндерә, аның рухи омтылышларын сурәтли. Шул ук вакытта сынчы иҗат кешесе буларак үзен дә тулырак ача бара, илһамының яңадан-яңа якларын үстерә, тулыландыра, баета. Бу җәһәттән караганда Кадим Җәмитов бигрәк тә татар халкының тирихы, аның болгар чоры, хәтта әле мәҗүсилек чоры белән дә мавыга. Аны татар әдәбиятының үткәне-бүгенгесе, аерым алганда, Тукайлар чоры кызыксындыра. Тукайны исә ул бала чагыннан ук ярата, шагыйрьнең «Су анасы», «Шүрәле» әкиятләрен ятлап үскән авыл малае хәзер дә аның шигырьләреннән башка яши алмый — аларны кат-кат укый, һәр укыган саен үзенә яңа якларын ача бара. Кадимне, Тукай шигърияте, шагыйрь язмышы белән бәйле рәвештә, аның якын дус-ишләре — Фатих Әмирхан, Сәгыйть Рәмиев, Сәгыйть Сүнчәләй һәм башкаларның образлары тарта.



*Сәгыйть Рәмиев*

Менә сынчының «Дуслар» дип исемләнгән композициясе /сез аны журналыбызның тышлыгында күрәсез/. Габдулла Тукай белән Фатих Әмирхан көтелмәгән лирик-психологик образлар булып сынландырылганнар. Кадимнең бу әсәре 1990 елда иҗат ителгән һәм беренче мәртәбә Мәскәүдәге шәхси күргәзмәсендә күрсәтелгән. Без исә аны «Татарт-91» күргәзмәсендә тамаша кылдык. /Биредә «Татарт-91» күргәзмәсенең Санкт-Петербургтан Казанга килүен һәм зур уңыш

казануын, аерым әсәрләрнең соңыннан кайбер гарәп илләренә, хәтта Австралиягә кадәр барып кайтуларын да искәртеп үтәргә кирәктер. Кадим Җәмитовның «Дуслар»ы күргәзмәдә зур бәя алды, тамашачылар бу әсәр яныннан өзелмәделәр. Г. Тукай белән Ф. Әмирхан сынчының яраткан материалы — төсле шамоттан коелган. Кадим материалның фактура үзенчәлекләреннән бик оста файдалана: аерым кытыршы-шадралыклар, яргаланып кайнап чыккан таш-балчык аңа образларның сурәт охшашлыгын табуда ярдәм итә. Сынчы сын-сурәттәге геройларының чәчләренә, каш-күзләренә, битләренә һәм костюмнарына сизелер-сизелмәс кенә төс-буяу салган: шуның белән аларны үз чоры кешеләре итеп җанландыра алган. Фатих Әмирханның тимер кыршаулы чын күзлектән булуы, кулына агач тәрепкә тотып торуы деталь буларак шулай ук бик үзенчәлекле һәм көтелмәгәнчә. Шул гади генә агач тәрепкә Фатих Әмирханның тәпле акыллы, тормыш-көнкүреш мәсьәләләрендә тәҗрибәле икәнлеген искәртеп тора шикелле. Г. Тукай өчен Ф. Әмирханнан да ышанычлы якын дус булмаган. Әнә шул мөнәсәбәтне күрсәтү өчен сынчы Ф. Әмирхан гәүдәсен куышлап эшләгән һәм Г. Тукайны шул куышка сыендырган. Шагыйрь шулай итеп дусты тарафыннан үзенә яклау һәм җан тынычлыгы таба. Фатих Әмирхан исә Тукайны иңнәреннән кочып алган, аны язмыш кыйнауларыннан аралап калырга, үз канаты астына алырга тели кебек. Тукай кулларын күкрәгенә кушырган да үз эченә бикләнгән, ул башкалар белән артык аралашмаучан, күбрәк ялгызлыкка омтылучан трагик шәхес, кырыс дөнья алдында чарасыз бер шагыйрь. Ф. Әмирхан исә, киресенчә, тәрепкәсен бер суырып алыр да, теләсә кем белән гәпләшергә-сөйләшергә, фикер алышырга тотыныр төсле. Шулай итеп, ике дусның капма-каршы образлары аша Кадим Җәмитов алтын урталыкны тапкан: әйе, болар аерылмас җан дуслар! Болар — бер үк уй-хыяллар, бер үк язмыш белән бәйләнгән фикердәшләр, аларны гаҗәеп тирән рухи туганлык берләштерә. Шул рәвешле, сынчы татар әдәбиятының бу ике бөек вәкилен рухи көчле, дуслыклары белән бер-берсен баетып-тулыландырып яшәүче шәхесләр итеп сурәтли алган. Тукай белән Әмирханның хөрлек-азатлыкка булган омтылышлары, милләт өчек җаннарын да фида кылырга өзер торулары тамашачыны, әлбәттә, битараф калдыра алмый.

Габдулла Тукай темасы Кадим Җәмитовның иң соңгы хезмәтләрендә тагын да тулырак ачыла. Бу — алты сын-сурәттән торган скульптур серия «Тукай һәм аның чордашлары» дип атала. Алты образ, алты сын-сурәт. Һәм һәркайсы үзенчә ачылган образ-шәхесләр. Менә Габдулла Тукай үзе, менә Галиәсгар Камал, менә Фатих Әмирхан, Камил Мотыйгый, Сәгыйть Рәмиев, Сәгыйть Сүнчәләй — дуслар, чордашлар, үз заманының зыялылары, татар мәдәниятының йолдызлары. Биредә дә Кадим Җәмитов шул ук шамот ташыннан искиткеч оста файдаланган. Кытыршы-шадра шамотның яшь татар зыялыларының йөзләренә контраст булуы күңелләрне тетрәндереп җибәрә. Безнең алда — якты дөньядан бик иртә киткән тарихи шәхесләр. Алты сын-сурәт бербөтен җыелма образга әверелә: алар мәңгелек, алар бөекләр, алар һәрчак безнең арада. Ирексездән күзләргә яшь килә... Болар бит безнең рухи җаннарыбыз, шулар аша безнең аңыбыз-фикеребез формалашкан, ата-бабаларыбыздан калган рухи байлыкны — гореф-гадәт, йолаларны — милләтебезнең асылын тәшкил иткән бетмәс-төкәнмәс акыл хәзинәсен шушы бөекләр безгә мирас итеп калдырганнар бит. Карагыз әле  сез аларга: бөтен сын-торышлары белән алар безнең өчен газиз, кадерле, якыннар. Уйласаң, алар бит безнең замандашларыбыз да була алыр иделәр кебек. Ләкин сынчы аларны шундый итеп сурәтләгән — без күреп торабыз: алар безгә үткәннән кайтканнар. Күңелләребезне кузгатып тетрәндерү өчен кайтканнар. Алар алтысы бер авыздан безгә: «Онытмагыз безне! Онытмагыз телебезне! Онытмагыз динебезне!» — дип оран салалар шикелле. Бигрәк тә Тукай, Тукайҗан... Мондый да ачы фаҗигале Тукайны әле без белми идек.

Кадим Җәмитов әлеге алты олуг затның һәркайсына үзенә генә хас холык-характер салырга тырышкан. Әмма аларның алтысын да берләштергән уртак сыйфатлар да бар: бу асыл затларның үз халкына-милләтенә тоташкан тамырлары нык-тирән, тормышка карашлары ачык-максатчан, әхлаклары саф-садә, берсендә дә тук канәгатьлек галәмәте юк — алар һаман тынгысызлыкта-эзләнүдә. Тулаем алганда, Кадим Җәмитовның бу сериясе — драматик һәм трагик шәхесләр галереясе.

Кадим Җәмитовны һәрвакыт дулкынландырып, иҗат ялкынын сүнми-сүрелдерми илһамландырып тора торган икенче зур тема — борынгы болгар чоры, Идел Болгары. Сынчы бу темага да әледән әле әйләнеп кайта тора. Нигездә бу юнәлештә иҗат ителгән әсәрләр — күләмнәре белән зур булмаган сын-сурәтләр. Алар нинди дә булса аерым бер әкияти образ яки башка берәр сюжетка корылганнар.

Менә Кадим Җәмитовның «Зөһрә йолдыз» исемле композициясе. Әсәрнең нигезендә болгар заманнарыннан ук, ә бәлки аннан да элегрәктер, буыннан-буынга сөйләнеп килә торган, безнең каныбызга сеңгән борынгы кыйсса — Айдагы Зөһрә кызның фаҗигале образы. Бу әсәр таш һәм бронзадан коеп эшләнгән. Сынчының уенча, иңнәренә көянтә-чиләк аскан Зөһрә кызның тишек чиләкләре безнең күңелләрдәге хыял-идеалларның чынга ашмаслыгын гәүдәләндерә. Кадим Җәмитов, шулай итеп, ассоциатив образлы сәнгать теле белән татар халкының тирән фаҗигасен — гасырлар буе аның һәрдаим азатлыкка, мөстәкыйльлеккә омтылышын — иң изге хыялын сөйләп бирә. Шул ук вакытта биредә икенчел ишарә дә — тормышыбызның рухи бай-тулы булуына омтылу, ка-

милләк-матурлык хыялы да чагылып тора. Әмма ни кызганыч: безнең ул якты теләкләребез дә, кырыс чынбарлыкка үрелеп, буй житмәс Зөһрә йолдыз булып кала килә.

Билгеле булганча, Идел болгарлары ислам динен кабул иткәнгә кадәр мәҗүсиләр булганнар: алар төрле потларга, Тәңрегә табынганнар, табигать күренешләрен сынландырып яшәгәннәр. Кадим Җәмитов үз иҗатында бу теманы да читләтеп үтми. Аның «И Тәңрем»,«Ырымлау» кебек әсәрләре шул хакта сөйли. «И Тәңрем» әсәрендә Тәңресенә ялваручы мәҗүси төрки-болгар хатыны гәүдәләндерелә. Хатынның башында, әйтерсең лә калфак булып, ярымай балкып тора. Кеше гомер бакый табигатькә табынып яшәгән, бөек Табигать-ананың көч-кодрәтенә инанып килгән. Тәңре — кояш алласы. Аңа капма-каршы буларак ярымай куелган, ул да әле гади җир кешесе — хатын-кыз башында балкый. Күк йөзендәге ике җисем — Кояш белән Айның тәүлек әйләнәсендә бер-берсен алыштырып торуы, беренчедән, Җирнең мәңгелек хәрәкәттә булуын сынландырса, икенчедән, мәҗүси хатын-кыз образы аша алар тәңгәлләшә-тигезләшәләр, кеше гомеренең дә һәрвакыт хәрәкәттә, үсештә булуына ишарәлиләр. «Ырымлау» дип исемләнгән икенче әсәрендә Кадим Җәмитов шулай ук күккә багып нәрсәдер укынучы хатын-кыз образын иҗат иткән. Монысы шамот ташыннан ясалган. Бу очракта хатын-кыз Тәңресенә ялвармый, күрәсең. Аның укынуы берәр төрле ырым — әфсен-сихерләү булырга мөмкин. Ул кулларын күкрәгенә кушырып куйган, ә түшендә — тәңкә-чуплылардан җыеп эшләнгән муенса-хәситә. Хатын, мөгаен, теге дөньядагы гайре табигый көчләрне чакырадыр. Бәлки ул шаманлыкка һәвәс бер заттыр. Бүгенге телгә күчереп әйткәндә, экстрасенсорика, парапсихология белән шөгыльләнәдер. Ә бәлки ул хатын яңгыр гына теләгәндер, бәлки әлеге борынгы йола шул заманнар аша безгә килеп җиткәндер. Менә шундый фараз кылулар-уйланулар Кадим Җәмитов әсәрләрен тамаша кылганда бик табигый. Без шул рәвешле үткәннәр белән бүгенгене бер җепкә үрәбез.

Кадим Җәмитов соңгы вакытта татар халкының шулай ук бик борынгы һәм изге әкияти образлары булган «Сак белән Сок» исемле әсәр иҗат итү белән мавыга. Уңышлар телик аңа!

Безнең бу язмаларыбыз, Кадим Җәмитов иҗатындагы тагын бер үзенчәлекле жанрны искә алып китмәсәк, тулы булмас шикелле. Сынчы даими эшләп — иҗат итеп килгән ул жанр, сынчылар теле белән әйтсәк, а н и м а л и с т и к а жанры дип атала. Ә инде гадиләштереп, халык теленә күчереп әйткәндә, ул да булса, безнең тирә-юнебездәге кош-кортлар, җәнлек-җанварларның сын-сурәтләрен ясау. Кайчандыр, әле иҗатының башлангыч чорында ук, Кадим Җәмитов нәкъ менә шул эт-мәче, әтәч-тавык кебек җан ияләренең сыннарын ясау белән мавыга. Бу мавыгу еллар үтү белән тирәнәеп, зур осталык биеклекләренә күтәрелә, шул рәвешле һаман дәвам итә. Сынчы кешеләрнең тормыш-көнкүреше кош-кортлар, җәнлек-җанварлардан аерылгысыз икәнлеген ассызыклап иҗат итә. Ул әнә шул кош-кортлар, җәнлек-җанварларда да кешеләргә хас холык-табигать күрә белә. Шуларны, кирәксә, ачы каһкаһәгә кадәр күтәреп, кирәксә, нечкә киная-елмаю белән генә сурәтләп, берсеннән-берсе кызыклы сын-сурәтләр ясый. Өстәлгә яки китап киштәсенә генә куярлык вак сын-сурәтләр Кадим Җәмитов кулы астында шундый булып сынлана-лар-җанланалар ки, исең-акылларың китәрлек була. Менә, әйтик, «Ата мәче» сыны. Суйган да каплаган — безнең җәлекләребезгә төшкән тук бер түрә бит бу! Йөнсә «Әтәч» сыны — болай кукраеп йөрүче бушбугазлар азмы әллә безнең арада? «Козгын» исә тагын үзенә бер төрле тип-образ. Кыскасы, бер карыйсың — гади кош-кортлар, икенче карыйсың — гаҗәп кызыклы холык-табигатьле безгә таныш затларның җыелма образлары. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәктер, Кадим Җәмитов бу жанрда гадәти юмористик-сатирик яссылыкта гына тукталып калмаган. Ул тирәнгәрәк, эчкәрәк үтәргә тырыша, еш кына көтелмәгән фәлсәфи уйлануларга барып чыга. Мәсәлән, аның «Ахырзаман» исемле композицион әсәре тамашачыда әллә никадәр ассоциатив тәэсирләр уята. Композициядә — мәче, әтәч, тавык һәм төлке образлары. Аларның — гадәти тормыш шартларында бер-берсенә кан дошман булган терекләк ияләренең — ахырзаман көнендә — якты дөнья белән хушлашыр алдыннан булган үзара мөнәсәбәтләре безне тетрәндереп җибәрә. Сынчының әйтергә теләгәне шул: кешеләр, акылыгызга килегез — дөньяга экологик һәлакәт якынлаша... Бу әсәр юкка гына Австриядә күргәзмәгә куелмагандыр шул.

Ә менә «Яз» дип исемләнгән гаҗәеп җылы, якты әсәрдә Кадим Җәмитов анималистика жанры кысасында гына кала алмаган: безнең алдыбызда — күбәләк, тиен һәм әрләннәр белән бербөтен булып үрелгән гүзәл кыз сыны — Яз образы. Сынчы безне якты дөньяны, шул якты дөньяда бар булган һәр җан иясен — кыскасы, бар табигатьне яратырга, һәрчак сак-кайгыртучан булырга өнди.

Сынчы Кадим Җәмитовның иҗаты әнә шулай тулаем яшәү-тереклек итүгә дан җырлаудан, үз халкыңның милләт буларак үлемсез икәнлегенә инанудан гыйбарәт. Милли мәдәниятыбызның ирекле-бәйсез рухта яңаруы һәм үсүе шартларында Кадим Җәмитов иҗаты безне яңадан-яңа казанышлары белән куандырыр дип өметләнәбез.

Иншалла, шулай булсын!

**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова,**
сәнгать белгече.





## РЕФЕРЕНДУМ: ХАЛЫК «ӘЙЕ» ДИДЕ

Парламентыбыз, Татарстанның дәүләт статусын күтәрү максатыннан чыгып, «Татарстан республикасының Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы договорлар нигезендә коручы суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты булуына сез ризамы?» дигән сорау белән җөмһүриятебездә яшәүче гражданнарга мөрәҗәгать итәргә, ягъни 21 мартта референдум уздырырга дигән карар чыгарды. Куелган сорауга халык «әйе» яки «юк» дип җавап бирергә тиеш иде.

Татарстан республикасының референдум үткәрү буенча Үзәк комиссиясе референдумның цивилизацияле иппәр үрнәгенчә тыныч шартларда узуын билгеләп үтте һәм тавыш бирү нәтиҗәләре турында хәбәр итте. Сайлауда катнашкан гражданнарның 61,4 проценты референдумдагы сорауга «Ә Й Е» дип тавыш биргән.

Шулай итеп, референдум Татарстан Республикасында яшәүче төрле милләт вәкилләре Татарстанның тулы мөстәкыйльлеген, бәйсез дәүләт булып яшәргә тиешлеген тагын бер кат раслады. Референдум барышына күзәтчелек итү максаты белән, дөньяның күп кенә илләреннән рәсми вәкилләр, күпсанлы журналистлар килгән иде. Соңыннан алар референдумның демократик шартларда узуын билгеләп үттеләр.

Әйтергә кирәк, референдум алды көннәре зур фикер каршылыклары, көрәш, төрле яклап басым ясау шартларында узды.

Россия Федерациясе Югары Советы 1992 елның 5 мартында Татарстан Республикасы Президентына, халкына, Югары Советына мөрәҗәгать белән чыкты, Татарстан җитәкчелеген сепаратизмда, «татар халкының башка халыклар белән гасырлар буена килгән элемтәләрне өзәргә һәм Россия Федерациясе составыннан чыгарга» омтылуда гаепләде. Россия Федерациясенең конституцион суды исә, Татарстанда уздырылачак референдум законга каршы килә, дип нәтиҗә чыгарды. Татарстанның мөстәкыйльлеккә омтылуын, бөтенхалык референдумын үткәрүне беренчеләрдән булып Башкортстан Югары Советы Президиумы хуплап белдерү белән чыкты. Аңа Чечен Республикасы Президиумы да кушылды. Татарстан Президенты М. Шәймиев, Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Татарстан Республикасы Премьер-министры М. Сабиров исемнәренә АКШ, Финляндия, Төркиядән, Санкт-Петербург, Мәскәү, Киев, Рига, Уфа, Оренбург h. б. бик күп шәһәрләрдән килгән хат-телеграммалар төрле илләр, төбәкләргә сибелгән татар халкының бердәмлеген раслады. Ә Россия демократик партиясенең Казан бүлекчәсе, «Согласие» төркеме, Мәскәүдә чыгучы күпсанлы газета-журналлар, радио-телевидение тапшырулары референдумның максатын төрлечә бозып күрсәтергә тырыштылар. Татарстан Президенты М. Шәймиев берничә мәртәбә Татарстан халкына мөрәҗәгать белән чыкты. Мәскәү телевидениесе аша чыгышлар ясап, ул, референдумның төп максаты Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турындагы Декларацияне раслау, дип белдерде. Татарстан Югары Советының 18 мартта узган чираттан тыш сессиясендә дә бу хакта ачык әйтелде. Анда Россия Федерациясе Югары Советының Милләтләр Советы рәисе Рамазан Абдулатипов та катнашты һәм Татарстанның бәйсезлеккә омтылуын хуплап чыгыш ясады.

Референдум алды көннәрендә Татарстан язучылары да актив эш алып бардылар. Апрның гомуми җыенында кабул ителгән Татарстан халкына мөрәҗәгатьләрендә референдум үткәрүнең төп мәгънәсе ачык чагылдырылган иде. Ул матбугат битләре аша халыкка җиткерелде. Байтак кына әдипләр референдум көнне сайлау участокларында күзәтчеләр сыйфатында катнаштылар.

## БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАРЛАРЫ КАЗАНГА ҖЫЙНАЛА

Татарстан Президенты М. Шәймиев Бөтендөнья татарлары конгрессын уздыру турында Указ чыгарды. Конгресс 1992 елның июнь аенда җөмһүриятебез башкаласы Казанда үткәреләчәк.

Указда әйтелгәнчә, мондый карарга татар халкының үз телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, традицияләрен яңадан торгызуга бәйле күпсанлы мөрәҗәгатьләр һәм республикадан читтә, шул исәптән чит илләрдә яшәүче татарлар белән икътисади, мәдәни бәйләнешләрне киңәйтүгә, үстерүгә юнәлгән омтылышлар нигез булып тора.

Татарстанның Премьер-министры М. Сабиров җитәкчелегендәге әзерлек комитеты шушы зур форумны үткәрүнең комплекслы программасын тормышка ашыруда киң эшчәнлек алып бара.

## ӘДӘБИ ҖЫЕН

28 февральдә Татарстан Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында әдәби ел йомгакларына багышланган зур җыен булды. Аны Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары Зиннур Мансуров ачты һәм иң элек ул Татарстан Язучылар берлеге һәм «Туган як» мәдәни җәмгыятенең Гаяз Исхакый исемендәге бүләкләре бүләкләрне язучы Ибраһим Нуруллинга һәм шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановка бирелүен игълан итте. Шушында ук Бөтендөнья рыцарьлар Конференциясе парламентының дәүләт секретаре Әбрар Кәримуллин публицист язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлимгә шушы оешманың рыцарьлык таныкнамәсен һәм билгесен тапшырды. Аннан соң әдипләр сафына кабул ителгән 22 кәләм иясенә таныкнамәләр бирелде.

Әдәби фонд директоры Ш. Мостафин оешманың хәзерге хәле, алда торган мөһим мәсьәләләр, әдипләрнең тормыш-көнкүрешен җайлау, яхшырту юллары турында сөйләде. Татарстан китап нәшрияты директоры Х. Әшрәфҗанов китап бастыру

эшендәге кыенлыклыр һәм алардан чыгу юллары турында чыгыш ясады. Чаллы Язучылар оешмасының җаваплы сәркәтибе Р. Хисмәтуллин татар әдипләренең былтыргы иҗаты һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге турындагы фикерләре белән уртаклашты.

Әдәби ел йомгакларына багышланган киңәшмә көн тәртибендәге актуаль мәсьәләләр хакында язучылардан Р. Фәйзуллин, Н. Әхмәдиев, М. Әгъләмов, Ф. Зөлкарнәев, Р. Зәйдуллә, З. Хөснияр һ. б. чыгыш ясады.

### «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

Моннан 74 ел элек, 1918 елның 12 мартында, Казан губерна Советының мөселман комиссариаты һәм партиянең губерна комитеты мөселман секциясе бюросы органы булып чыга башлаган «Эш» исемле газета, җөмһүриятебез халкы белән бергә, катлаулы юл узды, халыкка мәгърифәт өләште. Ул, җөмһүриятебезнең тормышындагы үзгәрешләргә карап, төрле елларда төрле исем белән чыкты: «Эш», «Татарстан», «Татарстан хәбәрләре», «Кызыл Татарстан», «Совет Татарстаны» «Социалистик Татарстан».

Бүгенге сәяси һәм икътисади хәлне истә тотып, үзенең күпсанлы укучыларының фикерен кабул итеп, газета 25 февральдән «Ватаным Татарстан» исеме белән чыга башлады.

### КАЗАНДА — ЯПОН МУЗЫКАСЫ

24—29 мартта җөмһүриятебездә беренче мәртәбә япон һәм татар музыкасы халыкара фестивале узды. Анда Япониядән килгән 21 кешелек делегация катнашты. Алар арасында Токио нәфис сәнгать һәм музыка университеты профессоры, Япониянең иң күренекле композиторларыннан берсе Тейдзо Мацумура, композиторлар Тосиро Маюдзуми, Харуко Накадзима, Италиядә, Франциядә Гран-при алган Сан Сато, Парижда үткән халыкара конкурс лауреаты Юкикадзу Судзуки, Ютака Такахаси һәм башкалар бар иде.

Фестиваль көннәрендә кунаклар җөмһүриятебезнең үткәне һәм бүгенгесе, татар халык иҗатыннан үрнәкләр белән таныштылар, композиторларыбыз әсәрләрен тыңладылар. Композитор Рәшит Кәлимуллинның «Ерактагы көккүк авазы» операсы, Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты, Индус Якубовның «Джельсомино» операсы һәм башка әсәрләр кунакларда уңай тәэсир калдырды. Фестиваль көннәрендә япон музыкасына да зур урын бирелде.

Әлеге фестиваль ике халыкның кыпчакта тагын да ныграк дуслашуы, аралашуы өчен җирлек салды.

### ЕКАТЕРИНБУРГ ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘ

Март аенда Свердловск өлкәсе татарларының «Халык авазы» дигән иҗтимагый сәяси газетасы дөнья күрде. 300 мең татар яшәп яткан бу төбәк хезмәтчәннәре газетаның беренче санын зур куаныч белән кабул иттеләр. Аның битләрендә өлкә тормышы, татар теле һәм мәдәнияте язмышы, милли күтәрелеш мәсьәләләре урын алган.

Хәерле юл сиңа, яңа газета! «Халык авазы» бүгенге көнебез авазларына килеп кушылсын.

### ТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ҮЗӘГЕ: ЯҢА ГАЗЕТА

Февраль аенда, рус телендә, «Известия ТОЦ» дигән газетаның 1 нче саны чыкты. Татар иҗтимагый үзәгенең үз газетасын рус телендә чыгара башлавына берничә сәбәп бар. Болар — милли матбугаттагы уй-фикер һәм информацияләрнең рус мәктәпләрендә укып белем алган буынга һәм русларга вакытында барып җитмәве, местәкыйльлек идеясенең Татарстан гражданнарына мөмкин кадәр тизрәк, тулы һәм дөрес барып җитүенә омтылыш.

Материалларның эчтәлеге, көн кадагындагы мәсьәләләргә нигезле җавап бирүе белән газета укучыларның игътибарын үзенә тарта.

### САНКТ-ПЕТЕРБУРГ: ИСЛАМ ТУРЫНДА

Февраль аенда Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамбле Санкт-Петербургта булды һәм Исламның тергезелүенә багышланган бөтендөнья форумының гала концертында чыгыш ясады. Егерме өч илдән җыелган дин әһелләре, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашкан әлеге форумда Исламны яңадан тергезү проблемалары, аның тарихы, традицияләре һәм алга таба язмышы турында олы сөйләшү булды.

Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамбле шундагы концертта «Шәрык дөньясы» дигән махсус программа күрсәтте. С. Сәйдәшевнең «Шәрык биюе» һәм «Татар вальсы» чит ил вәкилләрендә аеруча соклану тудырды.

# ТАНЫШ БУЛЫЙК: ФОАТ ГАРИФУЛЛИН

Татарстан җөмһүриятенең атказанган фән эшлеклесе, химия фәннәре докторы профессор Фоат Әсәт улы Гарифуллин белән беренче танышуым радиода, концертмейстер булып эшләгән чагымда булды. Аның һәвәскәр җырчы буларак чыгышына мин рояльдә ярдәм иттем. Ул очрашуыбыз бик эчкерсез узды, күптәнге дустымны очраткандай хис иттем үземне. Язмабызны уңышлы тәгәлләгәч, шул ук көнне дигәндәй, Фоат мине спортның авыр атлетика төре буенча спортчылар секциясенә йөрергә дә «җикте». Чөнки ул үзе — спорт мастерына кандидат.

Рәссамнар, шагыйрьләр арасыннан бик күпләр Фоат белән дустанә мөгамәләдә. Гаҗәп тә түгел — дустым, гомумән, сәнгатькә, шигъриятькә ихлас гашыйк кеше. Ул үзе дә тыңлаучыларның күңеленә хуш килерлек итеп халык көйләрен, композиторларыбызның әсәрләрен башкара. Моңлы җырлавы белән беррәттән, классик шагыйрьләрнең (бигрәк тә — Тукай, Дәрдемәнд), бүгенге шагыйрьләребезнең әсәрләрен яттан оста башкару сәләтенә ия. Шул ук вакытта үзе дә шигырьләр, көйләр иҗат итә. Матбугат битләрендә музыка сәнгатенә кагылышлы актуаль проблемалы һәм истә калырлык мәкаләләр белән чыгыш ясап та таң калдырган иде ул безне.

Милли азатлык өчен көрәш чоры, демократия өчен көрәш дәвереннән аермалы буларак, сүздән эшкә күчү таләбен көн тәртибенә бөтен кырыслыгы белән куйды. Ф. Гарифуллин да үзенең җәмәгать эшчәнлеген гамәли яссылыкта гаҗәеп куәт белән җәелдереп җибәрде. Ул химия-технология институтының үзе җитәкләгән кафедрасында татар бүлеге оештыруга иреште. Һәм, шунысы куанычлы — ул татар телендә белем алуны юлга салу белән генә канәгатьләнеп калмады — бүлек студентларына татар музыка сәнгате буенча факультатив рәвештә лекцияләр тыңлау мөмкинлекләрен дә ачты.

Гомумән, үз идеяләрен, план-максатларын тормышка ашыру сәләте Ф. Гарифуллинның төп һәм иң кыйммәткә ия сыйфатыдыр дип уйлыйм. Аның чит илләрдәге (Германия, Англия һ. б.) озакка сузылган фәнни-иҗади командировкалардагы эшчәнлеге дә галимнең эшлеклелеген исбатлаучы дәлилләрдер. Шуңа күрәдер, студентлар каршында да профессорның абруе зур — алар аның лекцияләренә бик теләп һәм яратып йөриләр.

Халкыбыз шундый зыялыларын тудырып торганда, киләчәгебезгә өмет өзелмәс, шик-шөбһәләр таралыр, күңелләребездә шатлык нурлары сүнмәс.

Фоат Гарифуллин Дәрдемәнднең мәшһүр «Кораб» шигыренә үзенчәлекле көй иҗат иткән. Җыр халыкчан, моңлы, формасы төзек, ихлас күңелдән туганлыгы сизелеп тора. Әсәрнең сәнгати әһәмияткә ия икәнлегенә ышанып, нәшир итәргә хаклы саныйм.

**Ренат ЕНИКЕЕВ,**
ТССРның Г. Тукай исемендәге
Дәүләт бүләге лауреаты, композитор.

# Кораб

Дәрдемәнд сүзләре | Фоат Гарифуллин музыкасы

Шаулый диңгез, җил өрәдер,
Җилкәнен киргән кораб;
Төн вә көндез ул йөзәдер —
Юл бара ят ил карап.

Исте җилләр, купты дулкын,
Ил корабын җил сөрә.
Нинди җилләр, нинди упкын
Тарта безне, җан сорап?



Бәясе 1 сум 80 тиен

Индекс 73210

Аерым сатып алучылар өчен 3 сум



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARİ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен во Всесоюзный каталог